ЯХЪЯ АБДУЛЛИН

МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ

* УЙЛАНУЛАР *

"ФӘН"

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
ТАРИХ ИНСТИТУТЫ

Яхъя АБДУЛЛИН

МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ: УЙЛАНУЛАР

«Фән» нәшрияты
Казан — 1999

УДК 323.1
ББК 66.5 (2 Рос. Тат); 87.3
А 12

Татарстан Фәннәр академиясенең Редакция-нәшрият советы карары буенча басыла

Фәнни мөхәррире фәлсәфә фәннәре кандидаты
Фәрит Солтанов

Яхъя Абдуллин. Милләт язмышы: уйланулар. — Казан: «Фән», 1999. — 317 бит.

Китапта фәлсәфә фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле академигы Яхъя Габдулла улы Абдуллинның соңгы елларда язылган хезмәтләре тупланган. Аларда төрле темалар чагылдырыла. Әмма аларның барысында да авторның татар халкының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турындагы уй-фикерләре яктыртыла һәм шулар әйтелгән язмаларны берләштерә. Китап милләт язмышына битараф булмаган укучыга тәкъдим ителә.

ISBN 5-7544-0138-8

© «Фән» нәшрияты, 1999

КЕРЕШ

Татар халкы чал тарихтан алып бүгенгә көнгәчә авыр, сикәлтәле юллар аша үтте. Язмыш аны зур сынауларга дучар итте. Югалтулар да биниһая булды. Бу авыр язмыш, бу сынаулар аның улларын һәм кызларын, әлбәттә, уйландырмый калмадылар. Милләтнең аяныч хәле, аның азатлыгы, моңа ирешү юллары турында милләтпәрвәрләр арасында баш ватучы җаннар да аз булмады. Күбәүләр ачык көрәшкә дә ташландылар. Әмма патша самодержавиесенең һәм большевистик идарәнең аларга карата хөкеме аяусыз булды, күбәүләр сындырылды, ә сынмаганнар юкка чыгарылды. Шулай да, бу авыр сынауларга һәм зур югалтуларга карамастан, халкыбыз милләт буларак үзен саклап кала алды һәм бу очракта аның күңеленә тирән урнашкан миллият тойгысы үзенең хәлиткеч ролен уйнады.

Сиксәненче елларның азагында илдә башланган үзгәрешләр безгә дә ачы язмышыбыз, киләчәгебез, милләт буларак үзебезне саклап калу һәм аның турында тагы бер мәртәбә уйланырга мөмкинлек тудырды. Милли хисләребезне, теләк-омтылышларыбызны без телдән дә, язма сүз белән дә ачыграк әйтә башладык. Дөрес, милләт һәм аның язмышы турында уйланулар, коммунистик-шовинистик идеологиянең басымы никадәр көчле булмасын, элек тә тәмам сүнмәде. Болар — телебез, тарихыбыз, мәдәниятыбыз, мирасыбызга багышланган һәм кат-кат цензура иләкләре аша үтеп матбугатта чыга алган язмаларда үзләренең чагылышларын таба алдылар.

Мәгълүм булганча, партия үзәк комитетының Татарстанда идеология эшенең торышы турындагы 1944 елгы карары һәм шуның нигезендә партия өлкә комитеты тарафыннан үткәрелгән сәясәт безнең тарихыбызны һәм мәдәни ядкарьләребезне бөтенләй сызып ташлады. К.Насыйри һәм Г.Тукайдан башка милли мәдәниятыбызга зур өлеш керткән олы әдипләребезнен мирасына кара мөһер сугылды, аларның исемнәрен дә телгә алырга

ярамады. Шулай да халкыбызның аек акыллы уллары һәм кызлары аларны халык күңеленә кире кайтару юлларын туктаусыз эзләделәр, Бу эзләнүләр бушка китмәде. Акрынлап матбугат битләрендә Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди, Н.Думави кебек күренекле шәхесләрнең мирасы уңай яктан бәяләнә башлады. Минем үземә дә Г.Курсави, Ш.Мәрҗани, Ш.Култәси кебек олы затларның тарихыбызда һәм мәдәниятыбызда тоткан урынына объектив бәяне торгызуда үзләренең өлешләрен кертүчеләр арасында булу насыйб булды. Инде җитмешенче еллар башында ук бу мөтәфәккирләр иҗатының фәлсәфи эчтәлеге ачылып салына башлады, бу иҗатның мәгърифәтчел рухта булуы ачыкланды, шуның белән бергә татар иҗтимагый фикеренә зур фәлсәфи эзләнүләрнең хас булганлыгы да расланды. Шул ук елларда моңа кадәр реакцион дигән мөһер сугылып килгән җәдитчелек хәрәкәтенең дә прогрессив юнәлештә булганлыгы басым ясап күрсәтелде.

Әмма бу омтылышларны гамәлгә ашыру ифрат авыр шартларда барды. Сиксәненче елларның уртасына кадәр Г.Курсави турында да, Г.Утыз-Имәни (әл-Болгари) турында да, Ш.Мәрҗани турында да объектив фикерне турыдан-туры, ачык итеп әйтеп булмый иде әле. Ул елларда мирасны барлауны, аңа үзләренең өлешләрен керткән олы затларыбызның иҗади җимешләрен өйрәнүне марксистик идеология кысаларында алып барырга туры килде. Бу юнәлештә фәнни-тикшеренү үткәрүчеләр шушы методология таләпләренә җайлашырга, теләгән фикерне әйткәндә эзоп теле кулланырга мәҗбүр иделәр. Башкача мөмкин булмады. Әмма шушы кысаларда гына булса да рухи мирасны барларга, ачарга, өйрәнергә һәм халыкка җиткерергә тырышылды.

Сиксәненче елларның икенче яртысында исә башлаган яңарыш җилләре бу җилкенүләрне яңа баскычка күтәрергә, сүзне-фикерне ачыграк әйтергә мөмкинлек тудырды. Ә торабара без милләт, аның язмышы һәм мирасы турында мәсьәләне бөтен кискенлеге белән күтәрә, олы затларыбыз турында цензура рамкалары хакында уйламыйча ачык фикер йөртә башладык. Фикерләүдәге ошбу мөһим үзгәрешләр укучыга тәкъдим ителә торган шушы басмада да күпмедер күләмдә үзенең чагылышын тапты.

Менә җыентыкка кертелгән һәм «Г.Тукай: халык язмышын күз алдында тотып» дип исемләнгән мәкалә. Ул 1986 елны язылган. Анда шагыйрь-мөтәфәккир халкыбыз турында уйлап

яшәгән һәм иҗат иткән олы шәхес буларак гәүдәләндерелә, аның социаль фәлсәфәсе һәм әхлакый карашлары ачып салына. Әмма Г.Тукайга монда бирелгән бәяләмә сыйнфый анализ нәтиҗәсе буларак яңгырый. Шушындый ук тенденция Г.Атласига багышлап язылган мәкаләдә дә үзен сиздереп тора (1985 ел). Ә менә 1988 елда язылган «Яңача фикерләү һәм татар иҗтимагый фикере тарихының кайбер мәсьәләләре» исемле язмада яңарыш җилләре инде үзләрен нык кына сиздерәләр. Бу мәкаләдә миллият мәсьәләсе, милли фикер һәм рухи мирас мәсьәләсе инде турыдан-туры күтәрелә һәм бөтен кискенлеге белән куела. Мәкалә тулаем миллилекне ачыктан-ачык яклау һәм торгызу идеясе белән сугарылган. Әмма шул ук вакытта бу мәкаләдә дә әле моңа кадәр иҗтимагый фикердә хакимлек иткән төшенчәләргә ташлама ясала. Бу бигрәк тә бәяләмәләрдә сыйнфыйлык мәсьәләсенә мөрәҗәгать итүдә үзен сиздерә. Бу каршылыклы тенденция Г.Ибраһимов (1990 ел) белән Н.Думавига (1989) багышланган мәкаләләрдә күзәтелә.

Аннан соң язылган мәкаләләр исә бу яҫалмалыктан акрынлап арына баралар, ә «Җәдитчелек һәм хәзерге заман» (1991 ел) һәм «Ислам. Тарих. Заман» (1992 ел) исемнәре белән бирелгән мәкаләләр инде бу басымнан бөтенләй азат рухта язылганнар, аларда марксистик методологиягә хас сыйнфыйлык таләпләре урынына бәяләмәләрдә объектив булырга омтылыш, мәсьәләне миллият позициясендә торып яктыртырга тырышу өстенлек итә. Ш.Мәрҗани (1997) һәм Гаяз Исхакый (1991) турындагы мәкаләләр дә марксистик кысалардан тәмам арынып язылган. Бу язмаларның методологик базасын объективлык, тарихчанлык һәм миллият рухы тәшкил итә. Дөрес, бу тенденция әле 1980 елда язылган, әмма ул вакыт дөньяга чыга алмаган, Риза Фәхретдинов турындагы мәкаләдә дә үзенең ачык чагылышын тапкан иде. Бу факт безнең арада инде күптәннән мираска объектив караш индерүгә омтылыш яшәгәнлеген күрсәтеп тора.

Милләт язмышы, аның авыр үткәне һәм киләчәгенә бәйле уйлар Америка (1988 ел), Төркия (1990 ел) һәм Гарәбстанга (1991 ел) сәяхәтләр вакытында алган тәэсирләр тасвирланган язмаларда да үзләренең чагылышларын таптылар. Ә китапның дүртенче бүлекчәсендә тупланган мәкаләләрнең төп пафосы исә — милләтнең азатлыгы, бәйсез киләчәге. Бу мәкаләләр

1991—1997 елларда — милли күтәрелеш елларында язылдылар һәм аларда шул чорның рухы үзенең чагылышын тапканлыгы күренеп тора.

Бу көрәшнең төп максаты — азатлык, милләтнең мөстәкыйль киләчәге. Бу юнәлештә инде күп кенә үрләр яуланган. Шулай да тулы бәйсезлектән без әле бик ерак. Бу көрәштә милләттәшләребез арасыннан күп кенә фидакарь җаннар үсеп чыкты. Әмма милли лидерлар үзләренең тирәсенә әле бөтен милләтне туплый, халыкның барлык катламнарын уята алмадылар. Әлегә милли битарафлык бик көчле. Бу чирне җиңми торып милләт азат була алмаячак. Бу китап шушы максатка ирешүдә үзенең күпмедер өлешен кертер, дигән өмет белән укучыга тәкъдим ителә.

Яхъя Абдуллин
1994 ел, гыйнвар.

I

ЯҢАЧА ФИКЕРЛӘҮ ҺӘМ ТАТАР ИҖТИМАГЫЙ ФИКЕРЕ ТАРИХЫНЫҢ КАЙБЕР МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Соңгы елларда илдә бара торган процесслар һәм яңарыш күренешләре җәмгыятьнең рухи тормышын да читләтеп үтмәделәр. Бу процесс белән бәйле үзгәрешләр мәдәният һәм идеология өлкәсенә дә, гасырлар дәвамында тудырылган рухи хәзинәләргә карашка да үзләренең тәэсирләрен ясамый калмадылар. Әйтелгән хәзинәләр фәлсәфи фикерләүгә бәйләнешле мирасны да, социологик идеяләрне дә, иҗтимагый-политик, тарихи һәм хокукый теорияләрне дә, әхлакый һәм эстетик карашларны да колачлыйлар. Бу фикерләр, идеяләр, теорияләр һәм карашларның тарихи үсештә каралган системасы иҗтимагый фикер тарихының эчтәлеген тәшкил итә.

Шәхес культы идеологиясе һәм административ-бюрократик басым, билгеле булганча, мәдәният тарихын өйрәнүчеләр өчен зур кыенлыклар тудырды. Гыйльми тикшеренүләрне марксистик методология билгеләгән кысаларда гына алып бару мөмкинлеге, галимнәр яшәргә һәм эшләргә мәҗбүр булган сәяси һәм психологик вазгыять, чын мәгънәсендә мөстәкыйль фикер йөртү һәм эзләнүләр мөмкинлеге калдырмады. Бу вазгыять татар мәдәнияты тарихын, шул хисаптан иҗтимагый-фәлсәфи фикер тарихын өйрәнүдә дә бик аяныч нәтиҗәләргә китерде. Татар мәдәниятының һәм иҗтимагый фикернең Г.Курсави һәм Ш.Мәрҗани кебек асыл затлары алпавыт-буржуаз идеологлар дип типкәләнеп киленде, ә аларның мирасы халыкка каршы юнәлдерелгән реакцион күренеш дип кире кагылды.

Унтугызынчы гасырның соңгы чирегендә татарлар арасында җәдитчелек исеме астында мәгърифәтчелек характерындагы зур иҗтимагый хәрәкәт туды. Халкыбыз тормышында уңай роль уйнаган бу прогрессив хәрәкәткә дә реакцион-буржуаз дигән мөһер сугылды. Хәтта татар мәдәниятының Ф.Әмирхан

һәм Дәрдмәнд кебек вәкилләре дә буржуаз идеологлар дип кире кагылды. Г.Ибраһимов халык дошманы дип игълан ителде, ә әсәрләре китапханәләрнең ябык бүлекләренә бикләнеп куелды. Борынгы заманнардан һәм урта гасырлардан калган мирас исә халык өчен ят булган феодаль-ханлык идеологиясе чагылышы дип бәяләнде.

КПССның XX һәм XXII съездлары карарлары, Сталин шәхесе культы теориясенә һәм гамәленә булган ачы тәнкыйтьләр үткәннән калган мирасны бәяләүгә кагылышлы догматик карашларны билгеле бер рамкаларда гына булса да ерып чыгарга мөмкинлек тудырган кебек булды. Мәдәният һәм иҗтимагый фикер тарихын өйрәнүдә күпмедер җанлану сизелә башлады. 50нче еллар азагында Ф.Әмирханның эшчәнлеге һәм иҗаты яңача, уңай яктан бәяләнә башлады. Г.Ибраһимовның исеме дә онытылу пәрдәләре артыннан тартып чыгарылды һәм фән өлкәсендә эшләүчеләр аның бай мирасын өйрәнү мөмкинлеге алдылар. Тора-бара Җ.Вәлиди, Дәрдмәнд кебек мәдәниятыбызның онытыла башлаган вәкилләренең исемнәре дә кире кайтарылды. 1964 елда Р.И.Нәфиговның «Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли» исемле китабы басылып чыкты. Бу китапта татар иҗтимагый фикере тарихын өйрәнүгә яңа ориентирлар төсмерләнде. Бу тенденция И.Нуруллинның 1971 елны чыккан «Путь к зрелости» дигән китабында алга таба үстерелде.

1976 елда бу юлларның авторының «Татарская просветительская мысль» дигән китабы дөнья күрде. Бу китапта татар мәгърифәтчеләренең фәлсәфи һәм иҗтимагый-сәяси карашларына һәрьяклы анализ ясалды, Г.Курсави, Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов һәм Ш.Күлтәси кебек мөтәфәккирләр һәм мәдәният эшлеклеләре эшчәнлегенең һәм мирасының мәгърифәтчелек характерында булганлыгына басым ясап күрсәтелде. Шушы ук авторның «Джаддидизм, его социальная природа и эволюция» дигән хезмәтендә (кара: «Из истории татарской общественной мысли», Казань, 1979) бу зур иҗтимагый хәрәкәт үзенең объектив бәяләмәсен тапты. Ф.Газизуллинның «Дорогой правды» (Казань, 1979) дигән хезмәтендә татарлар арасында үзенең яңгырашын тапкан икътисади теорияләргә дә тиешле анализ бирелде. Р.М.Әмирхановның матбугатта чыккан хезмәтләрендә революцион-демократик хәрәкәт һәм аның идеологик әсаслары турында яңа фикерләүләр дә чагылышларын таптылар.

Әмма илнең иҗтимагый тормышында урнашкан торгынлык тенденцияләре, ә җитәкчелектә административ-бюрократик ысулларның тамыр җәюе фәнни-тикшеренү өлкәсендәге бу уңай чаткыларның тәмам тернәкләнүенә мөмкинлек бирмәделәр. Административ басым нәтиҗәсе буларак татар иҗтимагый фикере тарихына кагылышлы бик мөһим хезмәтләр басылып чыга алмый калдылар, чыкканнарында да официаль мөхәррирләр керткән төзәтмәләр һәм цензура сызулары аркасында тарихи чынбарлык үзенең ярым-ярты чагылышын гына таба алды, яки бөтенләй бозып күрсәтелде. 1978 елда Казан университеты нәшриятында мәсәлән, М.Мәһдиевның «Влияние общественной и эстетической мысли на развитие татарской литературы» дигән хезмәте басарга хәзерләнгән иде. Китап вакытлы матбугатта чыккан бай мирасны, архивтагы чыганакларны һәм татар мәдәниятының күренекле вәкилләренең әсәрләрен һәрьяклап өйрәнү нигезендә язылган һәм үз эченә ифрат бай фикер вә мәгълүмат туплаган иде. Әмма бу китаптагы күтәренке рух ул вакытта идеологик тормышның тезгеннәрен үз кулларында тоткан түрәләргә ошамады. Аңа карата шул вакыттагы идеологик вазгыять рухына тәңгәл килердәй бәяләмә бирә алырдай рецензентлар да табылды. Шуларның тырышлыгы белән инде чыгаруга әзерләнеп беткән китап таратылып ташланды.

1979 елда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында «Общественная и философская мысль в Татарии начала XX века: общее и особенное в развитии» дигән һәм авторлар коллективы тарафыннан язылган китап тәмамланды. Китапның кульязмасында татар иҗтимагый фикере үсешенең мөһим мәсъәләләренә анализ бирелгән иде һәм анда татар мәдәниятының күренекле эшлеклеләренең фәлсәфи, социаль-политик, эстетик һәм әхлакый карашлары үзләренең чагылышын таптылар. Кульязма бай фактик материал нигезендә һәм архив материалларына таянып язылган иде. Ул кат-кат Мәскәү нәшриятларына да, Татарстан китап нәшриятына да тәкъдим ителде. Китапның кульязмасы заманында урнашкан тәртипләр нигезендә төрле даирәләргә, шул хисаптан марксизм-ленинизм институтына рецензиягә җибәрелде. Рецензентларның карары катгый булды: басарга ярамый, чөнки авторлар бик күп татар исемен кулланалар һәм игътибарларын башлыча татар мәдәниятына, аның тарихына юнәлдерәләр.[1]

Әле быел гына (1988 ел) Мәскәүдә, «Наука» нәшриятында Р.У.Әмирхановның «Татарская демократическая печать (1905—1907 гг.)» дигән китабы басылып чыкты. Китапта татар иҗтимагый фикере тарихына кагылышлы бик әһәмиятле мәсьәләләр күтәрелә. Әмма ул басылып чыкканчы кабат-кабат рецензияләнде. Аның битләрендә мөхәррир кайчысы күп уйнады. Нәтиҗәдә китап кискәләнгән, туракланган хәлдә, почмаклары тигезләндерелеп, мөхәррирләр һәм рецензентларга ошамаган күп кенә мөһим фикерләр һәм бәяләмәләр алып ташлангач кына дөнья күрә алды.

Хәзер дөньякүләм бара торган процесслар, ил эчендә туган вазгыять безнең алдыбызда, бүгенге хәлебезгә, халкыбыз алдында торган проблемаларга, үткәнебезгә һәм киләчәгебезгә яңача карау кирәклеген бөтен кискенлеге белән куйды. Бу мәсьәләләрдә инде күптән көткән борылыш партия үзәк комитетының апрель (1985 ел) пленумыннан соң күзәтелә башлады.

Иҗтимагый тормыш мәсьәләләрендә яңача фикерләү мәдәният тарихын, шул хисаптан аның мөһим өлешләреннән булган иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер тарихын өйрәнүгә яңа перспективалар ачты, бу өлкәдә фәнни тикшеренүләр алып баруның моңа кадәр арткы планга чигерелгән, яки бөтенләй кире кагылып килгән методологик принципларын яңадан торгызырга һәм кулланышка кертергә мөмкинлек тудырды. Бу принциплар арасында беренче чиратта гомумкешелек (гуманизм) принцибы килеп баса һәм бу принцип белән партиялелек, сыйнфыйлык принцибы арасындагы мөнәсәбәт мәсьәләсен дөрес чишү проблемасы калкып чыга. Моңа кадәр иҗтимагый күренешләрне тикшергәндә партиялелек, сыйнфыйлык принцибы өстенлек итеп килде. Җәмгыять тормышы мәсьәләләрен өйрәнүче галим телиме ул, юкмы — карала торган проблемаларны партиялелек, сыйнфыйлык позициясеннән чыгып бәяләргә һәм яктыртырга мәҗбүр иде. Шуның өстенә шәхес культы идеологиясе хакимлек иткән шартларда бу принципны куллану догматик калыпларга салынды. Нәтиҗәдә ул принцип чиктән тыш күпертелгән (гипертрофик) төс алды. Г.Курсави һәм Ш.Мәрҗани кебек олы мөтәфәккирләрнең иҗатына һәм җәдитчелек хәрәкәтенә бирелгән, инде әйтеп үтелгән берьяклы һәм тенденциоз бәяләмә моның ачык мисалы булды.

Г.Курсави һәм Ш.Мәрҗаниләрнең тормышы һәм эшчәнлеге татар буржуазиясенең формалашуы чорына туры килде. Шуңа күрә аларның иҗатында шул чорның рухи халәте, аңа хас

тенденцияләр, шул хисаптан татар буржуазиясенең омтылыш һәм теләкләре дә үзләренең чагылышын тапмый кала алмадылар. Буржуаз фикер йөртү, әлбәттә, татар мәгърифәтчелеге үсешенең бер этабын тәшкил иткән җәдитчелек хәрәкәтендә дә үзен сиздерде. Совет чорында татар буржуазиясенә карата урнашкан тискәре караш, аны реакцион көч дип күзаллау, бу сыйныфның XIX гасырдагы эшчәнлегенә дә күчерелде һәм ул үзенең формалашуының беренче адымнарында ук реакцион көч булды дигән фикер тамыр җәйде. Һәм шушы позициядән чыгып Г.Курсави белән Ш.Мәрҗани мирасын бәяләүдә дә, җәдитчелек хәрәкәтен аңлауда да берьяклылык өстенлек итте һәм аларга реакцион дигән кара мөһер сугылды. Бу очракта хәтта К.Маркс, Ф.Энгельс һәм В.Ленинның буржуазиянең феодаль мөнәсәбәтләргә һәм уртагасырчылыкка каршы көрәштә, феодализм белән чагыштырганда прогрессив булган яңа, капиталистик житештерү мөнәсәбәтләре урнаштыруда уңай роль уйнаганлыгы турындагы кат-кат әйтелгән күрсәтмәләре дә бөтенләй искә алынмады.

Әйтергә кирәк, узган дәверләрнең фән һәм мәдәният эшлекләренең иҗади мирасында, аларның нинди сыйнфый позициядә торуларына һәм аерым очракларда эзлексезлек күрсәтүләренә карамастан, гомумкешелек һәм гуманизм тенденцияләре, кеше шәхесе һәм халык турында борчылу күзәтелә килде. Г.Курсави һәм Ш.Мәрҗаниларның мирасында башыннан ахырынача, мәсәлән, кешенең аңын урта гасырга хас булган схоластика басымыннан коткару, милләт алдында социаль, экономик һәм фәнни прогресс юллары ачу, аның сәяси һәм хокукый тигезлеген тәэмин итү белән бәйләнгән гомумгуманистик идеяләр ялтырап тора. Бу идеяләр җәдитчеләр эшчәнлеге нигезендә дә яттылар.

Яки менә татар иҗтимагый фикере үсешенең элгәрерәк дәверләреннән бер мисал — XVI гасыр Казан шагыйремөтәфәккире Мөхәммәдъяр мирасы. Аның иҗатына ул яшәгән чор, әлбәттә, үзенең мөһерен сукмый калмады. Әгәр бүгенге көн дәрәҗәсендә торып фикер йөртсәк аның иҗади мирасында без һичшиксез сыйнфый вә тарихи чикләнгәнлек таба алырбыз. Шул ук вакытта бу мираста без заманының гуманистик идеаллары чагылышын да, төгәлрәк итеп әйтсәк, гаделлек һәм кеше бәхете идеяләрен дә, шагыйрьнең үз халкы турында уйланулары да табабыз. Ә бу идеаллар, мәгълүм булганча, гомумкешелек кыйммәтләренең аерылгысыз өлешен тәшкил итәләр.

Чынбарлык каршылыклы, шулай да бербөтен. Шуңа күрә сыйнфый мәнфәгатьләрне һич кенә дә гомумкешелек мәнфәгатьләренә каршы куярга ярамый. Теге яки бу заманның прогрессив сыйныфлары һәм аларның идеологлары күтәреп чыккан идеяләр, аларның тарихи чикләнгәнлекләренә карамастан, гомумкешелек идеалларын да чагылдыралар. Гуманизм принциплары вә шәхес иреге тантанасына бару юлында яңа адым булып торалар. Шуңа күрә В.И.Ленинның гомумкешелек принципларын сыйнфый чикләнгәнлектән өстен куюы, «марксизмның төп идеяләре яктылыгында җәмгыять үсешенең мәнфәгатьләреннән өстен тора», дип әйтүе һич кенә дә очраклы түгел (кара: Ленин В.И. Хезмәтләренең тулы җыентыгы. 4 т. 220 б. Рус телендә).

Мәдәни мираска карата беръяклы караш тамыр җәюдә сыйнфыйлык белән миллилек арасындагы мөнәсәбәтләрне беръяклы һәм тупас рәвештә күзаллау да үзенең яман ролен уйнады. Шуның нигезендә милли мирасны тикшерүдә һәм бәяләүдә гаделлектән ерак торган һәм бик чикләнгән караш урнашты. Үз халкыңның үткәненә, аның рухи хәзинәләренә игътибар итү, хәтта милли мәдәният мәсьәләсен аз гына кузгату да, милли үзаң чаткыларының ялтырап китүе дә кире мәгънәдә милләтчелек һәм милли чикләнгәнлек күренеше дип бәяләнеп киленде. Милләтчелек мөһере ябыштырылудан шүрләп зыялыларыбыз милли мәдәният мәсьәләләрен күтәрүдән куркып калдылар. Бу безне ахыр чиктә рухи хәзинәләребездән аеруга китерде, халкыбызның әхлакый традицияләре, аның көндәлек тормышының нигезендә яткан гореф-гадәтләре, гасырлар буена аның рухи тормышын бизәкләп торган этик һәм эстетик карашлар акрынлап арткы планга чигенә башладылар. Хәзер халкыбыз бу иләмсез процессның нәтиҗәләрен татырга мәҗбүр. Милли мәдәниятыбыз традицияләреннән һәм халкыбызның гореф-гадәтләреннән аерылу нәтиҗәсендә туган һәм тирән тамырлар җибәреп өлгергән рухи бушлык җирлегендә милләтнең үткәненә, аның мәдәниятына, рухи мирасына, теленә, традицияләренә бөтенләй битараф караштa торган буын үсеп чыкты. Соңгы вакытларда шушы рухи бушлык җирлегендә «Казан феномены» исеме белән зур шау-шу куптарган һәм яшь сугыш чукмарларын берләштергән төркемнәр барлыкка килде.

Бу күңелсез күренешләр бөтен кискенлеге белән безнең алдыбызга мәдәниятыбызның инде онытыла башлаган элементларын яңадан торгызу, халкыбызның рухи мирасын барлау һәм

кайтару, мәдәниятыбыз тарихын һәм милли традицияләребезне тирәнтен өйрәнү заруриятен куя. Милли мәдәниятыбызның аерылгысыз өлеше буларак иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер тарихы да тормышыбызның рухи нигезләрен торгызуда мөһим роль уйный ала. Әлбәттә, мәдәниятның башка элементлары кебек үк иҗтимагый-фәлсәфи фикердә дә сыйнфыйлык үзен сиздереп тора. Әмма шул ук вакытта бу фикердә гомумкешелек тенденцияләре дә, милли үзенчәлекләр дә калкып торалар. Шуннан чыгып без тулы ышаныч белән иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер тарихын өйрәнүнең методологик нигезен гомумкешелек (гуманизм) һәм сыйнфыйлык башлангычлары диалектикасын, милли һәм сыйнфый мәнфәгатьләрнең үзара үтеп керүен искә алып эш итү тәшкил итә дип әйтә алабыз. Бу исә безнең алда рухи һәм мәдәни мирасны өйрәнүдә, узган чорларда формалашкан фәлсәфи идеяләрне һәм иҗтимагый фикерләр тупланмасын өйрәнүдә яңа офыклар ача.

Иҗтимагый һәм фәнни фикернең үзәген фәлсәфи фикер тәшкил итә. Татар иҗтимагый фикере тарихын өйрәнүдә туган авыр хәл соңгы чиктә илдә фәлсәфи фән мәсьәләләре тирәсендә урнашкан вазгыять белән дә билгеләнде. Шәхес культы идеологиясе һәм шуның нигезендә үткәрелгән гамәлләр фәлсәфәне сәясәт хезмәтчесенә, шуның өстенә асылы бозык, юлбашчының ихтыярына буйсындырылган сәясәт хезмәтчесенә әйләндерде. Бу сәясәт фәлсәфи фикерләүгә, гомумән мәдәнияткә коточкыч зарар китерде. Нәтиҗәдә фәлсәфи эзләнүләрдә кырыс догматизм, схоластик фикер йөртү, тәкълидчелек һәм авторитетлар язганын шәрехләү белән мавыгу кебек гамәлләр өстенлек алды. Фәлсәфәнең бурычы асылы бозык, юлбашчы теләгенә яраклаштырылган һәм чынбарлыктан аерылган сәясәтне, шуның нигезендә башкарылган эш-гамәлләрен яклауга кайтып калды. Бу исә фәлсәфи-тарихи эзләнүләрдә үзенең чагылышын вакыйгаларны, аерым шәхесләрнең эшчәнлегенә кагылышлы фактларны берьяклы яктыртуда һәм тарихи сәхифәләрне бозып күрсәтүдә тапты.

Бу яктан 50 елларда Мәүлә Колый һәм Г.Утыз-Имәни (Әл-Болгари) иҗатына карата урнашкан карашлар гыйбрәтле. Мәүлә Колый да, Г.Утыз-Имәни (Әл-Болгари) дә, билгеле булганча, фәлсәфи фикер йөртүче шагыйрьләр. Мәүлә Колыйның хикмәтләре — шигъри әсәрләр. Әмма аларда шигъри калыпларда кеше һәм ул яши торган дөньяга кагылышлы мөһим фәлсәфи

мәсьәләләр тикшерелә. Автор аларда үзенең фикерләрен суфизмга хас тышчаларга төреп бирә. Менә шушы факт Мәүлә Колыйның (һәм Г.Утыз-Имәни — Әл-Болгариның да) мирасын суфичыл-мистик, реакцион һәм халыкка дошмани дип бәяләүгә нигез итеп алынды. Ә чынлыкта исә суфичылык бик катлаулы, каршылыклы күренеш иде. Суфи шагыйрьләрнең әсәрләрендә еш кына мистицизм тенденцияләре дә, дөньявилык та күзәтелә һәм гаделсезлеккә каршы социаль протест өскә калкып тора. Алар үзләренә гуманизм идеяләренең үтеп керүе, чынбарлык һәм кешенең дөньядагы урыны турында аек фикер йөртү белән дә характерланалар. Мондый тенденцияләр Мәүлә Колый һәм Г.Утыз-Имәни — Әл-Болгари әсәрләрендә дә күзәтелде. Әмма 50 елларда бу олы затларны реакционлык мөһере белән тамгалап каләм тибрәтүчеләр аларның фәлсәфи мирасының бу ягын ничек кенә булса да читләтеп үтәргә тырыштылар.

Әйтелгәннәр һич кенә дә фәлсәфәне бөтенләй сәясәттән аерырга тырышу дип аңланмасын. Хәзерге заманда иҗтимагый тормыш өлкәсендә фәнни тикшеренүләр алып баручы бер генә галим дә, шул хисаптан фәләсиф тә, сәясәттән бөтеләй читләшә алмый. Бүгенге көндә сәясәт җәмгыять тормышына да, аерым шәхеснең язмышына да һичшиксез үзенең тамгасын сала. Шулай да сәясәтнең фәлсәфәгә булган шушы тәэсиренә дә карамастан, яңача фикерләү иҗтимагый фәннәр белән шөгыльләнүчеләргә, шул хисаптан иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер белгечләренә нинди мөмкинлекләр ачты соң? Беренче чиратта яңача фикерләү төрле караштa торучыларга үзләренең позицияләрен яклау мөмкинлеге, иҗади бәхәсләр мөмкинлеге, өлгергән проблемаларны, шул хисаптан фәлсәфи-тарихи тикшеренүләр өлкәсендә дә, ирекле рәвештә уйлау-фикер йөртү мөмкинлеген тудырды. Яңача фикерләү һәртөрле иҗади фикерләүгә үлем элмәге салучы унификацияләү (бердәйләштерү) күренешләреннән, догматизмнан һәм схоластик акыл сатулардан арыну мөмкинлеге тудырды. Һәм безгә татар иҗтимагый һәм фәлсәфи фикере тарихын өйрәнгәндә моны тулысы белән файдаланырга кирәк.

Яңача фикерләү фәлсәфә тарихы өлкәсендәге эзләнүләргә карата алгы планга методологик принцип буларак иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер үсешендәге каршылыкларны бөтен тулылыгы белән исәпкә алып эш итү зарурияттен куя. Моңа кадәр безнең бу өлкәдәге тикшеренүләр иҗтимагый фикер үсешендәге бары прогрессив тенденцияләрне генә өйрәнүгә юнәлде-

релгән иде. Бу сыйнфыйлык принцибын берьяклы аңлау, бу принципны күпертүнең нәтиҗәсе булды. Бу берьяклылык, сыйнфыйлык принцибын артык күпертеп аңлау иҗтимагый-фәлсәфи фикер үсешен турайтылган калыпларга гына салып күзаллауга китерде. Фактта исә иҗтимагый тормыш каршылыклы һәм анда бер-берсен кире кага торган тенденцияләр үзара үрелеп үсәләр. Шуның белән бергә иҗтимагый үсешнең төрле юнәлеш алуы да мөмкин. Бу каршылыклы тенденцияләрнең берберенә бәйләнеп үсүе, иҗтимагый үсештәге вариантларның төрлелеге иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер тарихына да кагыла. Бу тарихны да ниндидер бер монолит рәвешендә, каршылыксыз һәм һәркайчан үз-үзенә тәңгәл итеп күз алдына китерергә ярамый. Иҗтимагый тормышның башка якларындагы кебек үк иҗтимагый-фәлсәфи фикер үсешендә дә төрле тенденцияләр янәшә, бер-беренә бәйләнгән рәвештә, бер-беренә үтеп кергән рәвештә үсәләр. Шулай булгач, бу үсешне фикер каршылыкларыннан башка, прогрессив һәм консерватив идеяләрнең үзара бәрелешләреннән башка, яхшылык белән яманлыкның, дөреслек белән ялганның, гуманизм белән кешелексезлекнең каршылыгыннан башка күз алдына китерергә мөмкин түгел.

Шушыннан иҗтимагый-фәлсәфи фикердәге прогрессив агымнар белән беррәттән консерватив агымнарны да өйрәнү зарурияте туа. Соңгы елларда бездә мәгърифәтчеләр белән революцион-демократларның мирасын өйрәнүдә нәрсәдер эшләнде. Әмма шул ук вакытта аларга каршы якны өйрәнүдә әле бернинди дә адым ясалмаган. Әмма бу якның эшчәнлеге белән бәйләнгән мирасны, аның тарафдарлары алга сөргән идеяләрне өйрәнми торып, мәгърифәтчеләр белән революцион демократларның иҗтимагый фикер тарихында тоткан урынын анык кына итеп бәяләү мөмкин түгел. Соңгы вакытта Ш.Мәрҗанинең фәлсәфи һәм социал-сәяси карашларын, аның мәгърифәтчелек хәрәкәтенә керткән өлешен өйрәнүдә күпмедер эшләнде. Әмма әлегә «Җаруда» авторларның методологик позицияләре һәм алар күтәргән идеяләрнең эчтәлеге өйрәнелмәгән. Моннан башка исә безнең Ш.Мәрҗани турында белгәннәребез дә тулылыктан ерак һәм берьяклырак булып калалар.

Болгар-татар иҗтимагый-фәлсәфи фикере тарихының үсү этапларын аныклау мәсьәләсендә дә уйланырга вакыт. Бу мәсьәләгә кагылышлы хезмәтләрдә бу тарих өч этапка бүленеп киленде: 1. Борынгы дәверләрдән алып XVIII йөзнең ахырына

кадәр араны алган этап; 2. Татар халкының милләт булып формалашу чоры (XIX йөз); 3. XX йөзнең башы, ягъни татар иҗтимагый фикеренең марксизмга борылган һәм анда революцион-демократик фикерләүләр формалашу чоры. 2 һәм 3 этаплар турында сүз барганда мондый бүленеш, мөгаен, үзен аклый да булыр. Ә менә беренче этап шикләнүләр уята. Бу озын гасырларны бер этап итеп карау марксизмның иҗтимагый-икътисади формацияләр турындагы теориясенә бәйләп алынган. Әмма бу очракта бик зур тарихи чор турында сүз бара. Бу чор дәвамында безнең халкыбыз социаль яктан да, этник яктан да зур катаклизмнар, басып алулар, дәүләтчелекнең оешуын һәм җимерелүен кичерә. Бу тирән үзгәрешләр аның социаль-экономик тормышына, иҗтимагый аңына, сәяси һәм рухи тормышына, мәдәниятына тәэсир итми калмадылар. Бу этап халкыбыз һәм дәүләтебез тарихының монгол яуларына кадәрге чорын да, борынгы болгар җирләренең Алтын Урда дәүләте составында булуы чорын да, Казан ханлыгы чорын да һәм, ниһаять, урыс самодержавиесе табаны астында яшәү чорын да ала.

Бу чорлар мәдәният һәм иҗтимагый фикер үсеше тарихын өйрәнгәндә феодализм дәвере дип билгеләнә. Монда ирексездән бу озак гасырлар дәвамында халыкның тормышы, фикерләве һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләре бер үк төрле булып кала алдылар микән соң дигән сорау туа. Әгәр инде бу озак гасырлар дәвамында феодаль мөнәсәбәтләр сакланган булса, алар бер үк төрдәге феодаль мөнәсәбәтләр булганмы соң? Бәлки халыкның тормышын, социаль һәм идеологик мөнәсәбәтләрне характерлау өчен бу очракта башкачарак характердагы төшенчәләр кулланыргадыр? Бәлки Азиячә җитештерү ысулы төшенчәсе бу очракта кулайрак булыр? Бу эзләнүләрдә, мөгаен, социаль-экономик төзелештә купукладлылык яшәве мөмкинлеген дә истән чыгарырга ярамас. Бу мәсьәләләрне ачыкламый торып, төрле чорларда иҗтимагый-фәлсәфи фикернең эчтәлеген һәм структурасының нинди булганлыгын тәңгәл (адекват) рәвештә ачып салу, мөгаен, мөмкин булмаячактыр. Моннан безнең алдыбызда тарихның төрле дәверләрендә борынгы бабаларыбыз эш иткән социаль-экономик мөнәсәбәтләрнең характерын, һәрьяклап өйрәнү зарурәте килеп баса. Бу исә иҗтимагый-фәлсәфи фикер тарихын, аның үсешенең төп тенденцияләрен һәм төсмерләрен билгеләүче факторларны фәнни тикшеренүләрдә тәңгәл чагылдыру мөмкинлеге тудырачак.

Үзгәртеп кору һәм яңарыш шартларында үзебезнең иҗтимагый-фәлсәфи фикеребез мирасын өйрәнүгә, тарихыбызның төрле чорларында фәлсәфи һәм иҗтимагый мәсьәләләрне хәл итүдә андагы үзенчәлекләрне ачыклаганда да бик тирәнтен уйлап эш итәргә кирәклеге ачык күренә. Безнең иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер өлкәсендә тикшеренү алып баручы галимнәребез милли мирасны өйрәнүгә үзләренең фәлсәфә буенча тупланган белемнәренә таянып керешәләр. Ә аларның бу белемнәре Европа тәҗрибәсен үзләштерү нигезендә тупланган. Фәлсәфи принципларны, закон вә төшенчәләрне (категорияләрне) булачак галим-фәләсиф югары уку йортларында һәм аспирантурада шушы тәҗрибәне өйрәнү юлы белән үзләштерә. Безнең элгәрләребезнең фәлсәфи фикерләүләре исә мөселман дөньясы тәҗрибәсенә таянган иде. Шуңа күрә татар иҗтимагый-фәлсәфи фикере тарихын өйрәнүче галимебез әгәр ул фәнни эзләнүләрендә югары уку йортында һәм аспирантурада уку процессында тупланган фәлсәфи гыйлемнәргә генә таянып эш итсә, фәлсәфи мирасыбызның тирән эчтәлеген дә, аның үзенчәлекләрен дә аңлый алмаячак. Мөселман дөньясында озак гасырлар дәвамында, мәсәлән, вөҗүд (яшәеш), гадәм (юклык, юк булу), ваҗибелвөҗүд (зарури яшәеш), мөмкин вөҗүд (булуы мөмкин булган яшәеш), хөдус замани (заманда барлыкка килү) кебек төшенчәләр (категорияләр) фәлсәфи фикерләүдә мөһим роль уйнадылар. Бу төшенчәләр безнең элгәрләребезнең фәлсәфи аңнарына үтеп керде һәм аларга дөньяны һәм андагы процессларны танып белүдә һәм аңлатуда мөһим роль уйнады.

Бу уңайдан болгар-татар иҗтимагый фикере тарихында исламның хәлиткеч ролен дә онытырга ярамый. Үзгәртеп кору һәм яңарыш шартларында иҗтимагый фикер дингә карата 20—30 елларда урнашкан стереотиплардан акрынлап арына бара. Әле күптән түгел генә Русьның христиан динен кабул итүе тантаналы шартларда билгеләп үтелде. Бу тарихи дата уңаеннан үткәрелгән чараларда һәм матбугатта чыккан хезмәтләрдә христианлыкның рус дәүләтчелеге тарихында, рус халкын туплауда, аның рухи тормышында һәм мәдәнияты үсешендә мөһим роль уйнаганлыгы күрсәтеп үтелде. Христианлык рус иҗтимагый һәм фәлсәфи фикере үсешендә дә үзенең эзен калдырды. Шундый ук рольне Идел-Чулман болгарлары һәм аларның варислары — хәзерге татарлар тарихында ислам уйнады.

Беренче чиратта ул Идел-Чулман болгарларының һәм аларга кардәш кабиләләрнең бердәм кавем-милләт булып оешуының алшарты булды. Ислам шулай ук болгарларның дәүләте — Идел Болгарстаны оешуның да нигезендә ятты. XVI—XIX йөзләрдә болгарларның варислары — татарлар коточкыч социаль, экономик, сәяси һәм хокукый эзәрлекләүләргә карамастан, шашып христианлаштыруга һәм урыслаштыруга каршы тора алдылар һәм үзләрен халык буларак саклап калдылар. Бу очракта да ислам аларның рухи таянычы булды.

Ислам җирле халык тормышының бөтен якларына үтеп керде, аның рухи тормышының һәм дөньяны тануының нигезендә ятты, хокукый һәм әхлакый мөнәсәбәтләрнең характерын билгеләде. Хәзерге ислам турында тикшеренүләр алып баручы галимнәр билгеләп үткәнчә, аңа динилек тә, дөньявилык та хас. «Ислам, — дип язалар М.Т.Иовчук һәм Ш.Ф.Мамедов, — ул дин генә түгел. Бер үк вакытта ул бик үзенчәлекле дөньяга караш системасы да, үзенә дин мәсьәләләре белән беррәттән һәм аңа бәйле рәвештә формалашкан фәлсәфи карашларны да, социаль һәм әхлакый концепцияләрне дә сыйдырган үзенчәлекле идеология системасы да» (Иовчук М.Т., Мамедов Ш.Ф. Проблемы исследования истории философской и общественно-политической мысли в Средней Азии и Казахстане. Вопросы философии, 1978, №11, с. 115). Исламның бу үзенчәлеге болгар-татарларның рухи тормышында да үзенең эзен салды. Мөселман дөньясының башка төбәкләрендәге кебек үк, иҗтимагый-сәяси, әхлакый, фәлсәфи мәсьәләләрдә фикерләүләр биредә дә башлыча ислам калыпларында алып барылды. Татар иҗтимагый һәм фәлсәфи фикере тарихын торгызу, шушы үзенчәлекле мирасны тиешенчә өйрәнми һәм фәнни әйләнешкә кертми торып, мөмкин булмаячак. Ә моның өчен мөселман дөньясы халыкларының фәлсәфәсен, кәлямне һәм ислам тәгълимате буенча Идел буенда таралган чыганакларны тирәнтен белү зарур.

Яңарыш һәм үзгәртеп коруның мөһим аспектларыннан берсе — кеше факторы. Бу фактор икътисад өлкәсенә дә, социаль мөнәсәбәтләргә дә, сәясәткә дә кагыла. Һәм ул фәлсәфә мәсьәләсен дә читләтеп үтә алмый. Соңгы берничә дистә еллар дәвамында исә безнең илдә бу мәсьәләдә бик үзенчәлекле гайре табигый (парадоксаль) хәл туды. Бу хәлнең төп үзенчәлеге — фәлсәфи мәсьәләләрне кешедән аерып карау. Ә

асылда исә фәләсифнең төп бурычы — кешенең яшәешен һәм табигатьтәге урынын тикшерү һәм бәян итү. Кеше мәсьәләсе үзенең асыл мәгънәсе белән һәртөрле фәлсәфи фикерләүләрнең үзәгендә торырга тиеш. Фикер үсеше тарихында, шул хисаптан болгар-татар иҗтимагый һәм фәлсәфи фикерендә дә, ул шулай була килде.

Болгар-татар иҗтимагый-фәлсәфи фикере үсешенең урта гасырлардагы дәверендә, мәсәлән, төп проблемалардан булып әхлак-мораль мәсьәләләре калкып торды. Бу безнең мәдәниятыбызның «Кыйссаи Йосыф» (Кол Гали. XIII йөз), «Нәсихәт әс-Салихин», «Нәһҗ әл-Фәрадис» (XIV йөз), Мөхәммәдъяр әсәрләре (XVI йөз) һәм башка җәүһәрләре аша кызыл җептәй сузылып бара. Ә әхлак-мораль мәсьәләсе — ул үзенең асылы белән кеше мәсьәләсе, аның рухи дөньясы, аның табигате, аның яратылышның югары җимеше буларак кыйммәте мәсьәләсе. Шуның белән бергә, бу әсәрләрдә кешене аңлауда антропологик һәм космик тенденцияләрнең үзара бәйләнештә үсеше дә күзәтелә һәм бу бигрәк тә Котб иҗатында ачык чагыла. Кешегә кагылышлы фәлсәфи проблемалар шулай ук суфи шагыйрьләр иҗатының да асылын билгеле һәм бу Мәүлә Колый белән Г.Утыз-Имәни (әл-Болгари) иҗатында бигрәк тә ачык чагыла.

XIX гасыр мәгърифәтчеләре иҗатында, бигрәк тә Ш.Мәрҗани һәм Ш.Күлтәси иҗатында дөньяга фәлсәфи караш проблемалары калкыбрак тора. Бу проблемалар буенча эзләнүләр һәм аларны чишү алар иҗатында кешегә юнәлдерелгән, кеше акылын уртагасырчылык ятьмәләреннән арындыруга омтылыш рухы белән сөрелгән. XX гасыр башында иҗат иткән революцион-демократик рухтагы мөтәфәккирләребез иҗатында алгы планга социаль-сәяси проблематика чыгып тора. Һәм бу очракта да әйтелгән проблемаларны тикшерү һәм чишү шулай ук кешегә юнәлдерелгән, кешегә социаль һәм сәяси ирек идеясе яулау идеясе белән сугарылган. Димәк ки, безнең бүгенге иҗтимагый-фәлсәфи фикер тарихын өйрәнүче галимнәребез кайсы гына чордан калган мирас өстендә эшләсәләр дә игътибарлары үзәгенә кеше проблемасын күз алдында тотып эш итәргә тиешләр. Һәм шул чагында гына иҗтимагый фикергә кагылышлы иң мөһим мәсьәләләр тикшеренүченең игътибарыннан читтә калмаслар.

Хәзерге шартларда, милләтнең киләчәге мәсьәләсе бөтен кискенлеге белән куелган хәлдә, киләчәктә дә үзебезне кавем-милләт булып саклап кала алырбызмы-юкмы дип борчылган бермәлдә тарихи-фәлсәфи һәм иҗтимагый-сәяси эзләнүләрнең мөһим аспекты рәвешендә безнең алга халкыбызның рухын бөтен тирәнлеге белән ачу, милли хәзинәләребезнең иң тирән катламнарына үтеп керү, милли холкыбызның үзенчәлекләрен үзебез өчен, үзебез бу турыда төптән уйлый алыр өчен, бөтен тулылыгы белән күз алдына китерү мәсьәләсе килеп баса. Менә шундый гади генә күренгән, әмма алай бик үк гади булмаган бер мәсьәлә: ничек итеп безнең бабаларыбыз коточарлык эзәрлекләүләргә, патша самодержавиесенең һәм православие миссионерларының басымына, дүрт гасырдан артык үткәрелеп килгән чукындыру һәм урыслаштыру сәясәтенең бөтен ачысын татуларына карамастан, милли үзенчәлекләребезне саклап кала алганнар, ә менә соңгы 50—60 ел дәвамында яшәгән буын бу үзенчәлекләрнең күбесен югалтты, милләт эчендә үз халкының тарихын һәм мәдәниятын, аның рухи хәзинәләрен, хәтта телен дә белмәүче һәм белергә дә теләмәүче манкортлар үсеп чыкты? Нәрсә, нинди югалтулар безне мондый фаҗигале язмышка дучар итте? Халкыбызның рухи яктан зәгыйфьләнүенең, үткәнебез һәм киләчәгебез, телебезнең һәм мәдәниятыбызның бүгенге халәтенә битарафлык тамыр җәюенең сәбәпләре кайда? Шуның өстенә мондый халәт халкыбызның белем дәрәҗәсе яхшы ук күтәрелү шартларында туды. Бу халәттән котылу, халкыбызны упкыннан коткаруның юллары нинди?

Халкыбызның бөтен рухи байлыкларын, рухи мирасыбызны тирәнтен өйрәнү, бу байлык белән халкыбызның бүгенге тормышын нурландыру, аның аңына рухи мирасны һәм фикери байлыкларны иңдерү, мөгаен, бу сорауларга җавап эзләү юлларын һәм алар белән бәйләнгән проблемаларны чишү юлларын ачыклауга ярдәм итәр. Тарихчы галимнәр һәм җәмгыять тормышы белгечләре бу мөһим проблемаларны хәл итүдә һәм халкыбызны бик хәтәр милли авырудан — тарихи, мәдәни һәм рухи мирастан аерылудан коткаруда үзләренең өлешләрен кертә алалар һәм кертергә тиешләр.

Үзгәртеп кору, яңача фикерләү, яңарыш халкыбызның интеллектуаль, рухи потенциалын активлаштыру, моңа бөтен зыялыларыбызны тарту белән бик нык бәйләнгән. Үзгәртеп кору

шартларында административ-бюрократик идарә хакимлек иткән чорларда йокымсырап яткан рухи көчләр хәрәкәткә килә. Шәхес культы идеологиясе җәмәгатьчелек аңында «җайлы патша»га, бөтенесен дә булдыра ала торган үзәккә ышану, тормышта туган тискәре күренешләрне югарыдан кемдер килеп төзәтүен көтеп яту кебек зарарлы карашлар тәрбияләде. Хәзер ватандашларыбыз акрынлап, әмма бик кыенлык белән, үткәннең бу авыр йөгеннән арына баралар. Тормышыбызның бөтен якларында да диярлек демократияләү күренешләре күзәтелә, җәмәгатьчелек фикере уяна. Иҗтимагый фәннәр, шул хисаптан иҗтимагый-фәлсәфи фикер дә, үзләренең игелекле тикшеренүләре белән бу процесска ярдәм кулы сузарга тиешләр. Моның өчен бу фәннәрне вульгар социология ятьмәләреннән арындырырга кирәк. Ә бу социология кешеләрнең аңына нык сеңгән һәм үзенең позицияләрен һич кенә дә кулдан ычкындырырга теләми. Әмма фәнни тикшеренүләрдә чын иҗади рух җәелсен өчен безгә чын фәнни методологиягә, аек акылга һәм гомумкешелек принципларына таянып бу богаулардан тәмам арынырга кирәк. Бары шушы шартларда гына без татар иҗтимагый-фәлсәфи фикерен — милли мәдәниятыбызның бу мөһим өлешен — шәхес культы тантана иткән елларда һәм торгынлык заманында чорналган катламнардан арындыруга үзебезнең өлешебезне кертә алырбыз.

[1] Бу китап бары 1990 елда, әчтәлеге инде бик искергәч кенә дөнья күрә алды.

1988 ел.

ИСЛАМ БЕЗНЕҢ ТАРИХЫБЫЗДА ҺӘМ МӘДӘНИЯТЫБЫЗДА

Дистәләгән еллар дәвамында безнең тормышыбызда атеистик идеология хакимлек итте. Һәм ул халкыбызның аңыннан ислам динен куу өчен бөтен тырышлыгын куйды. Шушы максатларда официаль пропаганда ислам диненең кануннарын бозып күрсәтергә тырышты, аңа пычрак атылды, аның барлыкка килүе, тарихы һәм җәмгыять тормышындагы роле фальсификацияләнде. Бу пропаганданың асыл максаты ничек кенә булса да исламны җәмгыять тормышында һичнинди позитив роль уйнамаган

реакцион күренеш итеп күрсәтүгә кайтып кала иде. Бу пычрак пропаганда исламны, аның тарафдарларын сәяси эзәрлекләүләр белән беркетелде һәм көчәйтелде.

80 еллар азагында илдә җәелгән процесс дингә, шул хисаптан исламга карата да яңача карау мөмкинлеге тудырды. Ислам безнең тарихыбызга бик борынгыдан кергән һәм халкыбызның тормышында зур роль уйнаган идеологик юнәлеш. Бу мәкалә шушы тарихны һәм исламның мәдәни үсешебездә уйнаган ролен ачыклауга багышлана.

922 елда Идел буена Багдад хәлифәлегенең илчелеге килә һәм шушы уңайдан үткәрелгән тантаналар вакытында ислам Европаның көнчыгышында формалашып килә торган яңа дәүләтнең — Идел-Кама Болгарстанының официаль дине дип игълан ителә. Бу акт безнең бабаларыбыз — болгарларның исламга күчү процессының йомгагы иде. Ә процесс үзе күп элек башланды. Ш.Мәрҗани үзенең «Мөстәфад әл-әхбар фи ахвали Казан вә Болгар» дигән хезмәтендә болгарларның исламга бу акттан күп элек тартыла башлаулары турында сөйләүче ышанычлы дәлилләр китерә һәм алар арасында дәвалаучылар кыяфәтендә дингә өндәүчеләр йөргәнлеген әйтеп үтә. Ул болгарларның гарәпләр белән аралашулары гарәп-хәзәр сугышлары вакытында ук башлану мөмкинлегенә ишарә ясый. Шушы характердагы фактларны һәрьяклап тикшергәннән соң, ул болгарларның исламга күчә башлаулары Һарун әр-Рәшид һәм Мәэмүн хәлифәләр идарә иткән чорларга туры килә дигән фикерне әйтә.[1] Бу хәлифәләрнең беренчесе 786—809 елларда, ә икенчесе 813—833 елларда идарә иткән булалар. Димәк, болгарлар исламга VIII гасырның азагында һәм IX гасырның башында ук күчә башлыйлар. IX гасырда болгарлар арасында ислам йолаларының яхшы ук киң таралуы турында археологик тикшеренүләр дә сөйли. Һәм, ниһаять, фарс географы Ибн Рустәнең болгар авылларында мәчет-мәктәпләр булуы турында язып калдырган хәбәре. Бу хәбәр дә IX йөзнең ахырына карый.

Әлбәттә, инде IX гасырда ук бөтен болгар халкы мөселман була, дип әйтергә ярамас. IX йөздәге болгар зиратларында әле мөселманнар белән мәҗүсиләрнең каберләре аралашып яталар. Бу турында Е.А.Халикова үзенең «Мусульманские некрологи Волжской Булгарии», дигән хезмәтендә ачык дәлилләр китерә (Казань, 1986). Ш.Мәрҗани китергән һәм болгарларның ислам-

га Һарун әр-Рәшит һәм Мәэмүн хәлифәләр заманында күчүләре турында сөйләүче чыганаклар, мөгаен, болгарларның аерым төркемнәрен күздә тота булыр.

Русьның христианлыкны кабул итүенә багышлап чыгарылган бер мәкалә «Выбор князя Владимира» дип исемләнгән иде. Русьтан аермалы буларак, болгарларның исламны кабул итүе аларның патшасының шушы динне башлап сайлавы нәтиҗәсе түгел иде. Алар халык буларак үзләре акрынлап шушы дингә тартылдылар. Башта аларның бер группалары, соңыннан башкалары үзләре шушы динне кабул итте. Алмуш ханның исламны формалашып килә торган дәүләтнең официаль дине дип игълан итүе шушы тарихи агышның табигый йомгагы булды.

Болгарларның исламны кабул итүенә алардагы социал-экономик һәм рухи үсеш китерде. Шуның белән аларның нәкъ менә исламны кабул итүләрендә алар арасында мәҗүсилек заманында таралган ышанулар да үз ролен уйнадылар. Башка төрки халыклардагы кебек үк, болгарлар арасында да тәңре идеясе киң таралган иде. Шушы идеологиянең үсеше, әйтергә кирәк, болгарларны бер алла идеясен кабул итүгә турыдан-туры китерде дә. Ә бер алла идеясе ислам догматикасының асылын тәшкил итә. Әле хәзер дә татарлар арасында тәңре төшенчәсенең ходай төшенчәсе белән беррәттән Алланың синонимы булып кала бирүе шуңа күрә очраклы хәл түгел.

Әйтелгәннәр болгарларның нәкъ менә исламны кабул итүенең эчке сәбәпләреннән. Әмма моның тышкы сәбәпләре дә бар. Болгарларның якын күршеләре славяннар һәм угыр-фин кабиләләре бу вакытта мәҗүсилектә иделәр. Христианлашкан Европада грек-рим чоры мирасы онытылган, ә кешеләрнең аңында схолостика сөреме киң таралган иде. Ә гарәп-мөселман дөньясы исә IX—XI гасырларда үзенең чәчәк ату чорын кичерде. Бу чорда анда бик интенсив рәвештә антик дөнья калдырган мирасны үзләштерү процессы бара иде. Антик чорның Сократ, Платон, Аристотель, Плотин, Пифагор, Эвклид, Гиппократ кебек зур акыл ияләренең әсәрләре гарәп теленә тәрҗемә ителә. Фәлсәфә буенча зур-зур трактатлар, фәнни хезмәтләр языла, әдәбият һәм эстетик фикер үсә, шәһәр тормышы кайный. Гарәпләрнең бу казанышлары бабаларыбызның игътибарын үзенә җәлеп итми калмады һәм исламны кабул итү өчен билгеле бер алшарт тудырды.

Ислам болгарлар тормышында һәм аларның варислары Идел буе татарларның тарихи язмышында әһәмиятле һәм күпьяклы роль уйнады. Бу турыда сүз алып барганда беренче чиратта идеологик система буларак исламның үзенчәлекләрен күз алдына китерү зарур. Ислам — дөньякүләм таралган диннәрнең берсе. Башка диннәр кебек үк аңа үзенең догматикасы, кагыйдәләре һәм символикасы хас. Әмма башка диннәрдән аермалы буларак, исламның эчтәлеге бу догматика, норма һәм символлар белән чикләнми. Исламның башка ягы да бар. Ул киң планлы һәм күпкырлы мәдәни-идеологик система, дөньяга карашның тулы бер формасы. Үзенчәлекле идеологик система буларак ул үзенә дини карашлар белән беррәттән фәлсәфи төшенчәләр системасын да, социаль һәм этик концепцияләрне дә берләштерә. Ислам шулай ук җәмгыятьнең тормышын, кешеләрнең көндәлек эш-гамәлдә үзләрен тотышларын, аларның үзара мөнәсәбәтләрен билгеләүче кодекс та. Мөселман дөньясында иҗтимагый-политик һәм фәлсәфи мәсьәләләрне хәл итү, аларның таралышы ислам билгеләгән тышчаларда барды.

Фикһе гыйлемен алып карыйк. Фикһе гыйлеме гадәттә исламның хокук тәгълиматы рәвешендә характерлана. Әмма фикһе чынлыкта бер хокук мәсьәләләре белән генә чикләнми. Ул үзендә җәмгыять теориясенә кагылышлы бик күп проблемаларны берләштерә. Хокук мәсьәләләре белән беррәттән ул шулай ук фәлсәфәне дә, илаһи тәгълиматны да, сәясәтне дә, әхлак мәсьәләләрен дә, мантыйкны да, тел гыйлемен дә тикшерә. Шәригать белән дә эш шулай тора. Гадәттә соңгысын хокукый һәм әхлакый нормалар җыентыгы сыманрак күз алдына китерәләр. Әмма киң планда алганда шәригать үз алдына кеше яшәешенең бөтен якларын да яхшылык-яманлык күзлегеннән чыгып классификацияләү бурычын куя. Шуның белән бергә ул үз алдына кеше яшәешенең иң төп сәбәпләрен ачу, аның универсум белән бәйләнешен һәм табигатен өйрәнү вазыйфаларын да куя. Димәк фикһе гыйлеме дә, шәригать тә иҗтимагый, фәлсәфи, хокукый һәм әхлакый проблемаларның барысы белән дә кызыксыналар һәм аларга җавап бирергә тырышалар. Исламның болгар-татар тарихында тоткан урыны аның шушы киң масштаблы мәдәни-идеологик система булуы белән билгеләнде дә.

Хәзер болгарларның исламны кабул итүләренең әһәмиятен күрсәтүче кайбер факторларга тукталыйк:

1. Болгарларның Урта Иделдә ныклап тамыр җәюе Идел-Кама регионында Болгар дәүләтенең формалашуы белән янәшә бара һәм ислам бу дәүләтнең идеологик һәм хокукый нигезләре вазыйфасын үти. Болгарларның исламны кабул итүенең әһәмияте беренче чиратта шушының белән билгеләнә дә. Дәүләт дине дип игълан ителгәч, ул аерым кабиләләрнең мәҗүсилек белән бәйләнгән йолаларына каршы көрәшне уңышлырак башкара башлый һәм бу кабиләләрне бердәм дәүләт власте тирәсенә туплауга ярдәм итә.

2. Ислам шулай ук болгарларның, аларга якын башка төрки һәм төрки булмаган кабиләләрнең бердәм кавем-милләт булып берләшүенә идеологик алшарт булды һәм болгарларның бу динне кабул итүенең икенче зур әһәмияте шунда. Болгарларның элеккеге мәҗүсилек диннәре аларны берләштерү юлында ныклы терәк була алмады. Моның өчен аның идеологик нигезләре дә, оешмасы да юк иде. Ислам исә, идеологик яктан да, оешу ягыннан да нык үскән дин буларак, болгарларда бердәм мәдәният формалашуга нигез ташлары сала һәм алар арасында барлыкка килгән милли үзаңның аерылгысыз компонентына әйләнә. Ул формалашып килүче бу халыкны идеологик яктан берләштерә, болгар җәмгыяте әгъзаларын берберсенә өзелмәслек җепләр белән бәйли һәм бу милләткә дәүләтләре юкка чыкканнан соң да, башка исем астында булса да, үзен саклау мөмкинлеген ача.

3. Исламны кабул итү болгар җәмәгатьчелеген ул вакытта дөньякүләм алдынгы позициядә торган гарәп-мөселман мәдәниятына якынайта. Болгарларның бу мәдәният белән танышлыгы әле исламның Урта Иделдә официаль дин итеп игълан ителүенә кадәр үк, болгарлар арасына ислам үтеп керүнең беренче адымнарыннан ук башлана. Гарәп чыганакларында сакланып калган бер хәбәр шул турыда сөйли. Бу хәбәрне язып калдырган автор гарәп-мөселман мәдәниятының күренекле вәкиле әл-Җаһизны үзенең 200 биттән торган һәм болгар ханына адресланган хатында Алланың Китабы турында бер сүз дә әйтмәүдә гаепли. Бу факт болгарларның инде IX гасырның беренче яртысында ук (әл-Җаһиз шул чорда иҗат итә) гарәп дөньясы белән дини бәйләнешләр белән генә калмыйча, мәдәният мәсьәләләре буенча да күпкырлы бәйләнешләргә кергән булулары турында сөйли. Ислам дәүләтнең официаль дине итеп игълан ителгәч, болгарлар белән Багдад хәлифәлеге арасында

икътисад һәм сәүдә өлкәсендә дә, сәясәт һәм идеология өлкәсендә дә ныклы элемтәләр урнаша. Нәтиҗәдә, Идел буена ул заманда гарәп дөньясында үсеш алган фәнни-фәлсәфи идеяләр һәм әдәби әсәрләр үтеп керә.

Ислам кабул ителгәч, моңа кадәр болгарлар арасында таралган чөй (рун) язуы гарәп язуы белән алыштырыла. Һәм болгар язма әдәбиятының нигез ташлары салына. Гарәп телен һәм язуын белү Идел-Чулман буйларыннан чыккан төркиләргә гарәп телендә иҗат ителгән бай әдәби мирас белән танышу мөмкинлеге ача. Ә бу, үз нәүбәтендә, болгарларда фәнни-фәлсәфи фикер тууында, болгар мәдәниятының вә мәгрифәтенең үсүендә, әдәбият ядкарьләре иҗат итүдә мөһим роль уйнады. Тарих безгә шәйх Әхмәд ал-Болгари, Әбу ибн Идрис әл-Болгари, Борһанетдин Ибраһим бин Йосыф әл-Болгари, Әбу Мөхәммәд Садыр ибн Галәутдин әл-Болгари, Хуҗа Хәсән әл-Болгари кебек олы галим вә фәләсифләрнең исемнәрен китереп җиткерде.[2] Бу мөтәфәккирләрнең хезмәтләре Болгарстанның үзендә дә, шулай ук аннан читтә дә киң таралган була.

Ягъкуб ибн Ногман әл-Болгариның әле XI гасырда язылган «Тәварихи Болгария» исемле китабы турында, мәсәлән, гарәп сәяхәтчесе һәм укымышлысы Әбу Хәмид әл-Гарнати һәм киң диапазонлы галим Зәкәрия Казвини бик җылы сүзләр язып калдыралар. Фәлсәфә, илаһият гыйльме (богословие), тарих, медицина һәм фармокологиядән тыш болгар галимнәре астрономия һ.б. бик күп фәннәр белән дә шөгыльләнәләр. Әл-Гарнати калдырган мәгълүматларга караганда, болгар галимнәре күк җисемнәре турында тикшерүләр алып бару максатында төньякка бик еракларга барып җитә торган булалар. Әле монгол яуларына кадәр үк болгар әдәбиятының Кол Гали язган «Кыйссаи Йосыф» кебек гүзәл әсәрләре иҗат ителә.

Мәдәниятның мөһим өлешләреннән берсе — мәгърифәт. Ислам канаты астына тартылу болгар-татар мәдәниятының бу мөһим өлешенең нигез ташларын салуга да мөмкинлек тудырды. Исламны кабул иткәч үк болгарлар арасында уку-укыту эшендә билгеле бер система туа. Мәчетләр каршында яшәп килгән мәктәп-мәдрәсәләрдә дин сабаклары белән беррәттән дөньяви гыйлемнәр укытуга да әһәмият бирелә. Әл-Гарнатиның ерак Андалусиядән үзенең улын Болгарга укытырга алып килүе үзе генә дә бу илдә уку-укыту эшләренең яхшы ук югарылыкта торганлыгы турында сөйли.

Уку-укыту эшләрендә Болгар чорында урнашкан бу традиция Алтын Урда дәверендә дә, Казан ханлыгында да дәвам итә. Ш.Мәрҗани ул вакытта Казанда зур мәдрәсә эшләгәнлеге турында яза. Бу мәдрәсә шәкертләренең ул замандагы гыйлемнәрнең тулы комплексын өйрәнергә мөмкинлекләре була. Әле болгар чорында урнашкан традиция буенча һәр мәчет каршында мәктәп эшли. Уку йортлары Казан ханлыгының авылларында да күзәтелә. М.Худяков язуына караганда, ул вакытта Адай авылы мәдрәсәсе бик данлыклы була. 35 ел дәвамында аның мөдәррисе булып Иш-Мөхәммәд бин Туг-Мөхәммәд эшли. Бу мәдрәсә озак еллар яши һәм үзенә бик күп укучылар тарта.[3]

4. Ислам мәдәнияты — үзенең асылы белән шәһәр мәдәнияты. Ислам мәдәниятының бу үзенчәлеге Идел-Чулман Болгарстанында да үзен сиздерә. Биредә дә күп кенә шәһәрләр барлыкка килә һәм үсә. Бу шәһәрләр материаль һәм рухи мәдәният учакларына әйләнәләр. Идел-Чулман Болгарстаны территориясендә археологлар тарафыннан 150 дән артык шәһәр калдыклары табылган.[4] Бер-бер артлы Болгар дәүләтенең башкалалары булып торган Болгар һәм Биләр шәһәрләре бигрәк тә нык үсәләр. Соңгысы, мәсәлән, үзендә яшәгән халыкның саны һәм территориясе буенча ул заманның иң эре шәһәрләреннән саналган Киев, Париж һәм Владимирны үзып китә. Идел-Чулман Болгарстанының шәһәрләрендә мәһабәт архитектура корылмалары калкып чыга, сарайлар, мәчетләр, үзәк җылыту системасы булган таш пулатлар салына. Шәһәрләр үсеше исә рухи тормышның да үсүенә китерә.

Шәһәрләр үсеше белән шулай ук җитештерү көчләренең, кәсәбәчелекнең, һөнәрчелекнең, сәүдәнең үсүе дә бәйләнгән. Болгарстанда кара металлургия туа һәм камилләшә, чүлмәкчелек һәм күн эшкәртү һөнәре үзенең үсешендә яңа адымнар ясый, тимерчелек осталыгы яңа баскычлар яулый. Болгарлар инде XIV гасырда ук, Ауропада беренче булып, чуен кайната башлыйлар.

5. Ислам кабул итүнең болгар сурәтләү сәнгате өчен нәтиҗәләре үзенчәлекле һәм каршылыклы булды. Ислам, билгеле булганча, кеше вә хәйваннарның сурәтләрен ясауны хупламый. Шуңлыктан, исламны кабул иткән болгарлар арасында кеше һәм хайван образларын сынлы сәнгать чаралары белән гәүдәләндерү туктый. Ә мондый сәнгать аларда ислам кабул иткәнче яхшы ук үскән була. Шул ук вакытта сәнгать-

нең гамәли төрләре, мәсәлән, ювелирлык сәнгате, күнгә һәм тукымага чигү, бизәү сәнгате яңа үсеш ала. Кулъязма китаплар тарату бизәү сәнгатенең яңа төрләре, аерым әйткәндә, китап бизәү һәм каллиграфия язмалары туугa һәм үсүгә китерә. Гарәп-мөселман дөньясы белән алыш-биреш итү архитектура үсүенә дә яңа этәргеч ясый. Сәнгать иҗатының яңа төре — кабер ташларын бизәү барлыкка килә һәм зур үсеш ала. Төрки халыкларда таш һәм башка төрле билгеләр кую күптән килгән традиция. Орхон-Енисей һәйкәлләре һәм кыпчак далаларында очрый торган балбаллар шул турыда сөйлиләр. Болгарларда бу традиция каберләр өстенә матур итеп бизәлгән ташлар кую рәвешендә үстерелә. Бу ташларда болгар бабаларыбызның яшәеш проблемасы тирәсендә кичергән әхлакый һәм эстетик фикерләре үзләренең чагылышларын табалар.

6. Мәсьәләнең тагын бер аспекты — исламны кабул иткән болгарларның җәмгыять тормышының әхлакый нигезләренә булган карашларында үзгәрешләр. Диннәрдә теге яки бу рәвештә гомумкешелек әхлак нормалары үзләренең чагылышын табалар. Алар гаделлек, мәрхәмәт, шәфкать, мәхәббәт, инсанилык (гуманизм), әхлакый камиллелек идеалларын алга сөрәләр. Бу исламга да кагыла. Болгарлар арасында тарала башлау белән ислам иҗтимагый яшәеш мәсьәләсендә мәҗүсилек дәверендә урнашкан карашларга каршы эзлекле көрәш алып бара, кыргыйлыкны, шәфкатьсезлек һәм көчләү күренешләрен гаепли, яңа әхлакый принциплар таралуы өчен тырыша. Бу болгар-татарларның тормышына күпкырлы тәэсир ясый, аларны әхлакый үсештә яңа баскычларга күтәрә, тарихларына һәм тормыш-көнкүрешләренә яңа эз сала.

7. Һәм, ниһаять, ислам кабул итүнең халыкның алдагы язмышында, үзен этник бердәмлек буларак саклый алуында уйнаган роле. XIII гасырдан башлап Идел-Чулман буйларына кабат-кабат биниһая авыр җәбер-золым ябырыла, ил өстеннән давыл-өермәләр үтә, халык коточкыч тетрәнүләр кичерүгә дучар ителә. Мондый дәһшәтләрнең беренчесен монгол яулары китерә. Бату хан гаскәрләре Болгарстан җирендә җимерелгән шәһәрләр, яндырылган авыллар, тапталган кырлар калдыралар, иксез-чиксез кеше каны коела. Шулай да Идел-Чулман Болгарстаны халкы үзен саклап кала ала. Соңыннан да Чыңгызхан токымнары Болгар җиренә кабат-кабат ябырылалар. Бу

урыс князьләренең һәм Түбән Новгород ушкуйникларының — юлбасарларның һөҗүмнәре белән чиратлашып бара. Шушы һөҗүмнәр нәтиҗәсендә Болгар тәмам җимерелгәннән соң да, бу халык Чулманның төньягында яңа җир эшкәртү һәм һөнәрчелек үзәкләре тудырды, үзенең традицион мәдәниятын үстерде. Бу шартларда ислам халыкны берләштереп тотучы, аның этник бөтенлеген һәм үзенчәлеген саклауда хәлиткеч роль уйнаучы куәтле бер көч булды.

Ислам мәдәнияты вәкилләре буларак, болгарлар, Хорезм белән бергә, Алтын Урда мәдәниятының формалашуында да, ул биләгән киң далаларда яңа һөнәр һәм сәүдә үзәкләре барлыкка килүдә дә хәлиткеч роль уйнадылар. Ахыр чиктә бу далада яшәгән мәҗүси кабиләләр нәкъ менә Болгар һәм Хорезм тәэсирендә ислам кабул итәләр дә.

Казанның Иван Мөдһиш тарафыннан яулап алынуы борынгы болгарлар токымы — инде рус чыганакларында татарлар дип атала башлаган халыкка яңа авыр сынаулар китерде. Рус тарихчысы М.Худяков бу яулап алу вакытында Казан халкы өстенә биниһая җәбер-золымнар төшүен, күп халыкның кырылуын, монда туган материаль һәм рухи мәдәният ядкарьләренең юкка чыгарылуын күрсәтеп үтә. «Чудовищное избиение жителей взятой Казан, — дип язды ул, — составляет одну из самых тяжелых страниц русской истории... Колосальнюю гекатомбою человеческих жертв закончился «крестовый поход» христолюбивого воинства против казанцев... Кроме огромного количества человеческих жизней, насильственно унесенных в могилу, кроме бесчисленных слез, страданий и горя, пережитых казанским народом, печальный день 2 октября (день покорения Иваном IV Казани в 1552 г. — Я.А.) знаменовал собою гибель материального благосостояния, накопленного целыми поколениями и утрату культурно-бытовых ценностей, которые теперь были — безжалостно извлечены из укромных уголков, где они бережно сохранялись, без сожаления были изломаны, изуродованы, потеряны, уничтожены.»[5] Икенче бер рус тарихчысы, Казан университеты профессоры Н.Н.Фирсов басып алынган халыкка карата патша самодержавиясенең сәясәтен тасвирлап болай дип язды: «С внедрением в Казанский край дворянства и монастырей начались систематические религиозные гонения. Эти гонения начал сам завоеватель Иван IV,

находившийся под сильным влиянием православного духовенства, он разрушил татарские мечети и запретил их возобновлять, Московское духовенство выступила здесь настойчивой миссионерской ролью, стремясь увеличить количество пасомых — базы, эксплаутации.»[6]

Нигезе Иван Мөдһиш тарафыннан салынган бу милли кысу һәм эзәрлекләүләр патша хөкүмәте тарафыннан татарларга карата гасырлар буена үткәрелгән сәясәтнең үзәгендә ятты. КПССның X съезды үзенең резолюциясендә «политика царизма, политика помещиков и буржуазии к нерусским народам состояла в том, чтобы убить среди них зачатки всякой государственности, калечить их культуру, стеснить язык, держать их в невежестве, и наконец, по возможности русифицировать их», — дип күрсәтеп үтте.[7]

Бу сәясәт Казан җирендә тулы чагылышын тапты. Үзенең асылы белән ул ачыктан-ачык шовинистик характерда булды һәм болгарларның токымы булган татарларны мөстәкыйль халык буларак юкка чыгаруга юнәлдерелгән иде. Бу максатта җирле халыкның теленә, диненә, мәдәниятына һәм гореф-гадәтләренә каршы көчле эзәрлекләү политикасы үткәрелде. Патша хөкүмәте һәм аның урындагы сатраплары татар халкына карата социаль, экономик, сәяси һәм хокукый басым режимы урнаштырдылар. Халык барысын да татыды: нагайкасын да, төрмәсен дә, сөрген-себерләрен дә. Татарларга каршы хәрби командалар өстерелеп торылды, аларның җилкәсендә казак камчылары җитәрлек уйнады, гыйбәдәтханәләр һәм изге урыннар җимерелде, милли хисләр һәм традицияләр мәсхәрәләнде.

«Религиозные гонения, закрытие мечетей (один лишь епископ Казанской Лука Кашаневич в 1738—1755 гг. разрушил в Татарии 418 мечетей из 536) сопровождалось насильственным отбиранием детей мусульман в духовно-приходские школы.»[8] Татарларның зиратларыннан кабер ташлары алынып, чиркәү һәм монастырьларның нигезенә салынды, китапханәләр яндырылды, башка мәдәният учаклары һәм истәлекләре юкка чыгарылды. Шундый чаралар ярдәмендә патша самодержавиесе татарларның милли үзаңын юкка чыгарырга тырышты, аларның үз тарихларын, мәдәниятын, гореф-гадәтләрен онытуларына ирешергә теләде.

Шундый җәбер-золымнарга карамастан, татар халкы үзен, үзенең милли үзенчәлекләрен, мәдәниятын, гореф-гадәтләрен, традицияләрен саклап кала алды. Бу очракта да без тулы

ышаныч белән, халыкның милли аңының состав өлешенә әйләнгән ислам хәлиткеч роль уйнады, дип әйтә алабыз. Халыкның милли мөстәкыйльлеген саклауда нәкъ менә ислам идеологик терәк вазыйфасын үтәде. Патша самодержавиесе һәм миссионерлар көчләп христианлык таккан бер чорда татарлар исламда үзләрен милләт буларак саклауда сыену урыны таптылар, анда үзләренең этник, рухи һәм мәдәни бердәмлекләрен саклау чарасын күрделәр.

Татарларның милли үзенчәлекләрен саклауда мөселман мәктәпләре дә зур роль уйнадылар. Идел буе татарлары, көчле эзәрлекләүләргә карамастан, уку-укыту мәсьәләләрендә әле Болгар чорында урнашкан традициягә турылыклы булып калдылар, үзләренең барлы-юклы средстволары хакына мәктәпләр тоттылар. Бу, үз чиратында, халыкта билгеле бер күләмдә укымышлылык тәэмин итте. Моны миссионерлар да танырга мәҗбүр булдылар. «Православный благовестник» дигән журналда миссионерлардан берәү «сильно же магометанство прежде всего очень распространенной в магометанском населении грамотностью. Казанские татары — магометаны, почти все, за редькими исключениями, грамотны, очень ценят образование и заботятся о нем». Ахырда мәкаләнең авторы, шушының аркасында татарлар христианлаштырылуга бирелмиләр, дип зарлана.

Әйтелгәннәр исламның болгар-татар тарихында, самодержавиенең һәм миссионерларның басымына карамастан, этник бердәмлекләрен саклауда позитив роль уйнавы турында сөйлиләр. Әмма тормыш каршылыклы, иҗтимагый күренешләр дә күпкырлы. Тарихи агышның билгеле бер чорында берьяклы идеологик ориентация татар тормышында үзенең негатив якларын да күрсәтә башлый. Монда да патша хөкүмәтенең татарларга карата үткәрелгән сәясәте үзенең ролен уйный, бу политика татарлар арасында патриархаль мөнәсәбәтләрне консервацияләүгә, халыкны замана фәненнән һәм мәдәниятыннан ераклашуга этәрә, кешеләрне милли бөтенлекне саклау өчен тормышның инде артка калган формаларына һәм традицияләренә ябышып ятарга мәҗбүр итә, массалар арасында дин әһелләренең үткәнгә ябышып ятучы консерватив катламының тәэсирен көчәйтә.

Хәлне мөселман дөньясында соңгы гасырларда тамыр җәйгән күренешләр дә катлауландыра. Кайчандыр фән һәм мәдәният үсешенең алгы сызыгында торган бу дөнья тора-бара үзенең

2 з-473

позицияләрен жуя. Кешеләрнең аңын тәкълидчелек сөреме биләп ала, үткән заманның бөекләре әйткәннәргә сукырларча ышану тамыр җәя, тәнкыйди фикер йөртү эзәрлекләнә башлый һәм хәзерге заман кешеләренең мөстәкыйль фикер йөртү мөмкинлекләре кире кагыла. Моңа фәнни-фәлсәфи эзләнүләрне тәкфирдә гаепләү өстәлә, догматизм, схоластика, фанатизм тамыр җәя. Бу күренешләр татарлар арасына да үтеп керәләр.

Акрынлап мөселманнарның үз араларыннан бу торгынлык һәм туңлык чиреннән арынуга, иҗтимагый янарышка өндәүче көчләр үсеп чыга. Бу көчләрнең алдынгы сафында татар халкының уллары булдылар. Габденнасыр Курсави (1776—1812) шуларның беренчеләреннән иде. Ул ныклы дәлилләр белән тәкълидчеләргә каршы чыкты. Һәркемнең аек фикер йөртергә, иҗади эзләнүләргә хокукы барлыгын яклады. Г.Курсави эшен күренекле мәгърифәтчебез, тарихчы-галим һәм фәләсиф Шиһабетдин Мәрҗани (1818—1889) дәвам иттерде, тәкълид белән тәкфирне көчле тәнкыйть уты астында алды, кеше гакылына ирек даулады. Ш.Мәрҗанинең тәнкыйди методы халыкның тормыш юлында үткәннән калган киртәләргә каршы, аңа прогресска юл ачуга, аны фән, мәдәният, промышленность казанышларына якынайтуга юнәлдерелгән иде. Шул ук вакытта искәртеп үтәргә кирәк, Курсави да, Мәрҗани дә бу чыгышлары белән һич тә исламнан аерылмадылар, халык алдында туган проблемаларны дини позициядә торып анализладылар, үзләренең дәлилләрендә изге китапларга таяндылар.

Курсави белән Мәрҗани эшчәнлеге татар халкы тарихында тирән эз калдырды, үз халкы турында борчылучыларга, аның барыр юлларын ачыкларга тырышучыларга маяк вазыйфасын үтәде.

Үткәннән калган рухи мирасны яңадан бәяләүдә яңа адым җәдитчеләр тарафыннан ясалды. Бу хәрәкәт безнең төбәктә узган гасырның соңгы чирегендә тамыр җәйде һәм аның асылы Исмәгыйль бей Гаспралы, Риза казый Фәхретдинов, Фатих Кәрими, Һади Максуди, Шәмсетдин Күлтәси, Рәшит казый Ибраһимов, Галимҗан Баруди, Муса Бигиев, Хәсән-Гата казый Габәши, Һади Атласи һ.б. эшчәнлегендә һәм иҗатында үзенең ачык чагылышын тапты. Җәдитчеләр арасыннан татар революцион-демократиясенең Галиәсгар Камал һәм Гаяз Исхакый кебек вәкилләре, татар демократик мәдәниятының күренекле эшлеклеләре чыкты.

Җәдитчелек асылда бик катлаулы иҗтимагый хәрәкәт булды. Ул үзенә төрле тенденцияләрне һәм төсмерләрне туплаган иде. Җәдитчелекнең эчтәлеге, аның вәкилләренең эшчәнлеге, алар үз алдына куйган бурычлар бу хәрәкәт үсешенең барлык баскычларында да бертөрле булып калмадылар. Илдәге хәл үзгәрү белән бергә җәдитчеләр эшчәнлегенең эчтәлеге дә үзгәрә барды. Беренче адымнарында җәдитчеләр бары мөселман мәктәбенә һәм анда уку-укыту эшләренә үзгәрешләр кертү идеясе белән чыктылар. Җәдитчелек үзенең исемен дә мәктәптә яңа метод (ысулы җәдит) белән укытудан алды. Тора-бара җәдитчеләр иҗтимагый тормышның башка якларын үзгәртергә кирәклеген дә аңлый башлыйлар. Җәдитчелек үсешенең соңгы этабы инде чорның бөтен социаль һәм идеологик проблемаларын, шул хисаптан дини һәм илаһи тәгълимат мәсьәләләрен дә колачлый иде.

Җәдитчеләр эшчәнлеге нәтиҗәсендә татарлар арасында дини әдәбият белән беррәттән фәнни әдәбиятның номенклатурасы киң артты, татар телендә арифметика, география, физика, биология, гигиена, тарих һ.б. фәннәр буенча китаплар тарала башлады. Җәдитчелек хәрәкәте белән яңа, реалистик әдәбиятның беренче адымнары да, сәнгати фикердә тәнкыйди агым формалашу да, хатын-кызлар арасында эмансипация хәрәкәте дә нык бәйләнгән.

Шулай да җәдитчеләр алдында торган проблемаларның иң мөһиме мәктәп мәсьәләсе, яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсе булды. Җәдитчеләр бу очракта милләтнең язмышы, аның киләчәге яшьләр кулында икәнлеген аңлап, яшь буынны ничек итеп тәрбияләүгә бәйләнгәнлеген күз алдында тотып эш иттеләр. «Тәрәккыять заманыбызның иң зиядә дикъкать ителәчәк вә иң бөек гыйбрәт алыначак җәһәте дә, — дип язды Ш.Күлтәси, — ысул тегълим вә тәдрис җәһәтедер... Шул ысул тегълим вә тәдрисләрне җиңеләйтү аркасында хәзерге заманның алга киткән мәмләкәтләре меңнәрчә галим-голяма вә әдипләр, хакимнәр вә табибләр, йөзләрчә инженер вә астрономнар, географлар вә тарихчылар, химия белгечләре һәм диңгезчеләр, сәясәтчеләр һәм яхшы хәзерлекле хәрбиләр, игенчелек һәм сәнагать белгечләре житештерделәр.»[9]

Мәктәп мәсьәләсендә җәдитчеләр белән кадимчеләр арасында бик кискен көрәш җәелде. Бу көрәш үз тирәсендә киң җәмәгатьчелек игътибарын да җәлеп итте. Кадимчеләр уку-укыту мәсьәләсендә иске тәртипләрне саклау тарафдарлары буларак чыктылар, ә бу эштә яңалык кертүне ислам канунна-

рыннан тайпылу дип санадылар. Җәдитчеләр исә мәктәп эшендә реформа үткәрүне алга сөрделәр. Алар мәктәпләр эшенең мөселманлык таләпләренә нигезләнгән булырга тиешлегеннән һич кенә дә баш тартмадылар. Әмма мөселманлыкны саклау белән бергә алар мәктәпне заман гыйлемен, фән казанышларын тарату учагына әйләндерү кирәклеген дә алга сөрделәр. Җәдит мәктәпләрендә дин сабаклары белән беррәттән татар һәм урыс телләре дә, математика да, тарих та, география дә, башка дөньяви фәннәр дә укытылды. Шулай итеп җәдитчеләр мөселманлыкка тугрылыкны саклаган хәлдә татарлар алдында хәзерге заман фәнен һәм мәдәниятын үзләштерү юлын да ачтылар.

Җәдиди мәктәпләрдә дөньяви фәннәр белән бергә дини дәресләр дә керүе революциягә кадәр татарлар арасында уку-укыту мәсьәләләре яктыртылган хезмәтләрдә, җәдитчелек бу өлкәдә бернәрсә дә бирмәде, җәдит мәктәпләре кадими мәктәпләрдән берни белән дә аерылмадылар, дигән уйдырма таратылуга бер сылтау булды. Әмма мондый хезмәтләрнең авторлары җәдит мәктәпләреннән татарның Г.Тукай, Ф.Әмирхан, С.Рәмиев, Һ.Такташ кебек зур әдипләре, культура эшлеклеләре чыгуны, бу мәктәпләрнең гади халык балаларына җиңел ысул белән укырга-язарга өйрәнүгә, табигать һәм иҗтимагый фәннәр нигезләре белән танышуга мөмкинлек ачуын читләтеп үттеләр. Аннары шул типтагы мәдрәсәләрнең берсеннән зур язучыбыз һәм күпкырлы галимебез Г.Ибраһимов та чыккан иде бит. Галим һәм язучы Нәкый Исәнбәт тә, халкыбызның вөҗданы Хәсән Туфан да — шул ук типтагы мәдрәсә шәкертләре.

Болгар-татарлар тарихында исламның тоткан роленә бирелгән бу кыскача характеристика, аны халкыбыз тарихыннан җиңел кул белән генә аерып алу һич ни белән дә аклана алмый торган бернәрсә, дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Ул, күренүенчә, безнең милләт булып формалашуыбызда һәм үсешебездә хәлиткеч роль уйнады, мәдәниятыбызның нигезендә ятты. Халкыбыз өстенә төшкән һәм озакка сузылган җәбер-золым елларында, кан коюлар, мыскыллаулар белән бәйләнгән христианлаштыру шартларында аңа үз-үзен саклауда рухи таяныч булды һәм бүген дә, әгәр киләчәккә үзебезне милләт буларак сакларга теләсәк, без аны күңелләребездә йөртергә, өйрәнергә, аның әхлакый идеалларын үзебезгә маяк итеп алырга тиешбез. Милләт буларак безнең киләчәгебез шуңа бәйләнгән.

[1] Кара: Мәрҗани Ш. «Мөстәфад әл-әхбар», т.1, Казан, 1897, 52—57 бб.
[2] Кара: Мәрҗани Ш. Мөстәфад ал-әхбар... т.1. Казан, 1897, 78—83 бб.
[3] Кара: Худяков М. «Очерки по истории Казанского ханства», Казань, 1923, стр.162.
[4] Кара: Р.Г.Фахрутдинов. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. Казань, 1975, с.190—191.
[5] Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. Казань, 1923. Стр. 153—154.
[6] Фирсов Н.Н. Прошлое Татарии. Казань, 1926, с.26—27.
[7] КПСС в резолюциях и решениях съездов, конференций и пленумов ЦК, часть 1, изд. 7-ое, Госполитиздат, 1953, с.558—559.
[8] История гражданской войны в СССР, т.1, М.1935, с.42.
[9] Күлтәси Ш. Һәйяте җәдидә. Казан, 1896, 5 б.

1989 ел

ИСЛАМНЫҢ БАШКА ДИННӘРГӘ МӨНӘСӘБӘТЕНӘ КАРАТА

Коммунистик-атеистик идеология хакимлек иткән чорда кешеләрнең аңына, ислам дөнья халыкларын икегә бүлә: мөселманнарга һәм дөрес диндә булмаучыларга, соңгыларына карата дошманлык позициясендә тора, дигән фикер сендерелде. Моны раслау өчен адым саен Карл Маркcның «Сугыш игълан итү. Шәрекъ мәсьәләсе тууының тарихы» дигән мәкаләсендәге түбәндәге сүзләре кабатлана киленде: «Коран и основанное на него мусульманское законодательство сводят географию и этнографию различных народов к простой и удобной форме деления их на две страны и на две нации: правоверных и неверных, неверные — это харби (т.е. военные), враг. Ислам ставит неверных вне закона и создает состояние непрерывной вражды между мусульманами и неверными».[1]

Ислам белән башка диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне болай характерлауда берьяклы, баштан ук исламны кире кагу, аңа карата Аурупага гына багланганлык (евроцентрик) позициясендә торып фикер йөртү, шәрекъне гарбкә каршы кую, аны дөнья мәдәниятыннан бер якта торучы регион дип күрсәтергә тырышу тенденциясе күзгә чалына. Бу тенденциянең чыганакларын ачып, күренекле фәләсиф-шәрекъ белгече А.Сагадаев болай дип язды: «Как в индивидуальном сознании человека его представление о себе складывается через соотношение «я» и «он», так и в массовом сознании образ данной этнической

общности или цивилизации вырабатывается у ее представителей посредством сопоставления «мы» и «они». Причем в последнем случае подобное сопоставление часто под влиянием политических и идеологических факторов превращается в противопоставление собирательного «я», характеризуемого положительными качествами, некоей «чужой» общности, наделяемой по контрасту соответствующими качествами с отрицательным знаком. Коллективный эгоцентризм европейцев нашел воплощение в дихтомии «Восток-Запад», возникший еще в эпоху античности и в течение многих столетий обраставшей разнообразными предрассудками относительно нравов, политических институтов, культуры, мировоззрения и психологического склада азиатских народов».[2]

К.Маркс шушы Аурупага багланганлык (евроцентризм) тенденциясе хакимлек иткән мохиттә формалашты һәм шунда яшәде. Аның исламга, мөселман кануннарына кискен кире каршы чыгуы шушының белән аңлатыла да. Аурупага багланганлык, шәрекъка тенденциоз караш аңа шәрекъның көчле мәдәнияты — идеологик факторларыннан булган исламга ачык күз белән карарга комачаулады һәм хаклыктан ерак торган бәяләмәләргә китерде.

Чынлыкта исә бу бәяләмә дөреслеккә туры килми. Ислам үзенең барлыкка килгән вакытында ук башка халыкларга һәм диннәргә карата түземлелек идеясе күтәреп чыкты һәм дини мәсьәләләрдә һәртөрле көчләүләрне кире какты. Бу Корьән Кәримдә дә үзенең чагылышын тапты. «Диндә көчләүгә урын юк» дип игълан ителә Бәкара сүрәсенең 256 аятендә. Исламның нигезенә салынган һәм Корьәндә үзенең чагылышын тапкан бу түземлелек идеясе аның тарихында да расланды. Мөселман диненең әле беренче гасырларында ук, аның үзәге Багдад хәлифәлегендә исламнан башка диннәр вәкилләре дә — яһудиләр һәм нәсарилар (христианнар) яшәде. Алар ирекле рәвештә җитештерү һәм сәүдә эше белән шөгыльләнә алдылар, үзләренең дини йолаларын үтәделәр. Аурупаның көньяк-көнбатыш почмагына урнашкан Картава (Кордово) хәлифәлегендә дә яһудиләр һәм нәсарилар шулай ук ирекле рәвештә яшиләр һәм үзләренең дини йолаларын үтиләр. Дөрес, ул вакытта мөселман илләрендә яшәгән башка дин кешеләренең тормышы билгеле бер рамкага куелган була. Алар, мәсәлән, дәүләт казнасына

жан башыннан налог-харaж түләргә тиеш булалар. Әмма моны һич кенә дә хәрби дошманлык һәм кысулар белән тәңгәлләштерергә ярамый. Хараждан башка яһудиләргә дә, нәсариларга да һичнинди җәбер-золым төшмәде, алар һәр җәһәттән ирекле, үзләренчә яшәргә хаклы иделәр. Киресенчә, шул ук Кардово җирләренә христиан хакимдарлары килеп утыргач, мөселманнар анда ут һәм кылыч ярдәмендә юкка чыгарылдылар.

К.Маркстан китерелгән өзектәге бәяләмә, шул ук мәкаләдәге нәсариларның Төркия мәмләкәтендәге хәлен характерлаучы фактларга да каршы килә. Мәкаләдә К.Маркс үзе үк Төркия дәүләтендә 13730 мең грек-православный, 2400 мең әрмән һәм 900 мең католик яшәгәнлеген күрсәтеп үтә. Алар барысы да, әлбәттә, харaж түлиләр. Әмма шул ук вакытта аларның йортларына, милкенә һичкем кул тидерә алмый; нәсариларның чиркәүләре, аларда булган милек кагылгысыз дип санала; нәсарилар аларда үзләренең гыйбадәтләрен бернинди чикләүләрсез башкара алалар. Шуның өстенә Константинополь патриархы, православныйларның башлыгы буларак, аларның сәяси җитәкчесе һәм югары хөкемдары да булып санала. Һәм мөселман дәүләте моны гарантияли.

Әмма фәнни һәм пропагандистик хезмәтләрдә К.Маркстан әлеге өзекне китергәндә бу фактлар читләтеп үтелде — һәм ул өзек исламны кара буяуларга манып күрсәтү максатында файдаланылды. Әмма К.Маркс мәкаләсенең үзендә китерелгән тарихи фактлар да, бөтен ачыклыгы белән, исламны башка диннәргә һәм аларны тотучыларга түземсезлек позициясендә тора, дигән уйдырманың баштанаяк ялган булуын күрсәтәләр.

Исламның Идел буенда башка диннәргә мөнәсәбәте дә шул турыда сөйли. Билгеле булганча, VII йөздә Иделнең түбән өлешендә Хазар каганаты барлыкка килә. Бу дәүләт составына Түбән Иделгә якын башка районнар да керә. Анда мөселманнар, яһудиләр, мәҗүсиләр үзара тынычлыкта яшиләр. Күп кенә чыганаклар Хазар каганатында шулай ук нәсарилар берләшмәсе булганлыгы турында да сөйлиләр.

X гасырда Урта Иделдә яңа төрки дәүләт — Идел Болгарстаны формалашуы тәмамлана. 922 елда ислам бу дәүләтнең рәсми дине дип игълан ителә. Бу дәүләттә дә, Хазардагы кебек үк, башка диннәргә карата түзә алмаучылык күренешләре күзәтелми. Монда яшәүче, исламны кабул итмәгән кабиләләр

үзләренең мәҗүсилек йолаларын үтәүне дәвам итәләр. Анда даими рәвештә руслар һәм византияле сәүдәгәрләр һәм кәсәбәчеләр яши. Алар ирекле рәвештә үзләренең православие диннәрен тоталар, аның йолаларын үтиләр. Тарихи документларда болгар җирендә шулай ук нәсари әрмәннәрнең яшәгәнлеге дә теркәлгән. Җитмешенче елларда Биләргә баргач, күренекле археолог профессор А.Х.Халиков миңа Балтыйк дингезе буеннан килгән кәсәбәченең торак урынын күрсәтте. Аннан чыккан табылдыклар бу кешенең янтарь эшкәртү белән шөгылләнгәнлеге, үзенең динен тотканлыгы, үз халкының гореф-гадәтләрен үтәгәнлеге турында сөйли иделәр.

Болгарлар арасында ислам дине таралуының үзенчәлекләре үк аның башка диннәргә карата мөнәсәбатенең характерын билгеләде. Ислам болгарлар арасына кылыч ярдәмендә үтеп кермәде. Ул Болгарстанда ниндидер хөкемдар әмере белән дә урнаштырылмады. Русьта христианлык кабул итүнең мең еллыгына багышланган бер мәкалә «Выбор князя Владимира» дип аталган иде. Русьтан үзгә буларак, болгарлар исламга үзләренең ханнары сайлавы нәтиҗәсендә тартылмадылар. 922 елны Алмуш ханның исламны Болгар дәүләтенең рәсми дине дип игълан итүе бу дәүләт халкының мөселман диненә күчүенең башы түгел иде. Болгарлар ислам диненә бу вакыйгадан күп элек тартыла башлыйлар. Ш.Мәрҗани китергән мәгълүматларга караганда, болгарлар арасында исламга Һарун әр-Рәшид һәм Мәэмүн хәлифәләр заманында ук тартыла башлыйлар. Ә бу хәлифәләр IX гасырның башында хакимлек итәләр. Ш.Мәрҗани шул гасырларда ук болгарлар арасында дәвалаучылар кыяфәтендә дингә (исламга) өндәүчеләр йөргәнлеген искәртә һәм аларның вәгазьләре инде шул вакытта ук күп кенә болгарларның мөселманлыкка тартылуына китерә. Болгарлар арасында исламның IX гасырда ук таралуын археологик казылмалар да раслый. Е.А.Халикованың «Мусульманские некрологи Волжской Булгарии X — начала XIII вв.» (Казань, 1986) дигән хезмәтендә бу турыда ышанычлы дәлилләр китерелә. Һәм, ниһаять, фарс географы һәм тарихчысы Ибн Рустәнең IX йөздәге вакыйгалар чагылыш тапкан хезмәтендә дә IX йөздә Болгар авылларында мәчетләр барлыгы, алар каршындагы мәктәпләрдә мулла-мәзиннәрнең балаларга ислам сабагы бирүләре хәбәр ителә.

Димәк ки, болгарлар арасына ислам инде IX йөздә үк, бәлки иртәрәктер дә, үтеп керә. Алар аңа һичнинди көчләүсез тартылалар. Исламны аларның башта бер төркемнәре, аннары икенчеләре үз ирекләре белән кабул итәләр. Алмуш ханның 922 елда исламны Болгар дәүләтенең рәсми дине дип игълан итүе исә шушы процессның йомгагы булды.

Исламның болгарлар арасында тыныч юл белән таралуы үзе үк алар арасында башка диннәргә карата түземлелек атмосферасы урнашуның мөһим алшарты булды.

XIII гасырда Көнчыгыш Аурупа һәм Көнбатыш Азия киңлекләрендә яңа зур төрки дәүләт — Алтын Урда барлыкка килә. Анда яшәгән халыкларның зур күпчелеге әле мәҗүсилек кануннары нигезендә яши. Әмма мөстәкыйльлекләре өчен барган авыр көрәштән соң бу дәүләт составына ике мөселман дәүләте — Болгар һәм Хорезм җирләре дә кушыла. Дәүләт башында яулап алучы монголлар тора. Алар мәҗүсиләр. Бу дәүләт эчендә калган башка халыкларның да зур күпчелеге мәҗүсиләр. Әмма борынгы мөселман үзәкләре — Болгар һәм Хорезм тәэсирендә Алтын Урданың мәҗүси халкы акрынлап мөселманлыкка тартыла башлый, ә Үзбәк хан идарә иткән дәвердә ислам үзеннән-үзе Алтын Урдада дәүләт диненә әйләнә. Үзеннән-үзе, бернинди көчләүләрсез. Көчләү аппараты башта, киресенчә, мәҗүсиләр кулында була. Ислам дәүләт диненә әверелгәч тә Алтын Урдада, Хазардагы һәм Болгардагы кебек үк, дини түземлелек саклана, нәсарилар ирекле рәвештә үз диннәрен тоталар, ә православие епископы, инде әйтелгәнчә, зур хокуклардан файдалана.

Башка диннәргә карата гасырлар буена дәвам иткән бу түземлелек мөселман дәүләте булган Казан ханлыгында да, башка татар ханлыкларында да саклана. Казан ханлыгында, мәсәлән, даими рәвештә урыс сәүдәгәрләре һәм кәсәбәчеләре яши. Казанда, Болгар ханлыгындагы кебек үк, әрмән-нәсари җәмгыяте дә эш итә. Тегеләре дә, болары да ирекле рәвештә үзләренең дини йолаларын үтиләр.

Казанлылар, үзләренең элгәрләре болгарлар кебек үк, мәҗүси күршеләре арасында миссионерлык эше дә алып бардылар. Әмма бу эш һичнинди көчләүләрсез, тыныч юл белән алып барылды, корал һәм камчы ярдәмендә түгел. Казан ханлыгы тарихы буенча бик күркәм хезмәт калдырган урыс тарихчысы М.Худяков Идел буенда мөселман руханиларының миссионер-

лык эшчәнлегенең бары тыныч юл белән барганлыгын аеруча басым ясап күрсәтеп үтә. Биредә мөселман руханилары хөтбә-вәгазьләрен, дип яза ул, кулларына кылыч түгел, ә таяк тотып укыталар, ә таяк исә дини тәгълиматны бары тыныч юл белән, дини вәгазьләр аша тарату символы. Тыныч юл белән иңдерелгән бу вәгазьләр тирә-юндәге фин-угор һәм төрки кабиләләр арасына үтеп керәләр һәм шул юл белән аларны мөселманлаштыру процессы бара. «Мөстәфадел-әхбар...» исемле хезмәтендә Ш.Мәрҗани бер гарәп чыганагының башкортларның исламны болгарлардан алуы турындагы расламасын китерә.

Идел буендагы төрки-татар мәмләкәтләрендә исламның башка диннәр белән гасырлар буе дәвам иткән тыныч мөнәсәбәтләрдә яшәеше Иван мөдһиш Казанны яулап алганнан соң челпәрәмә килә. Дини эзәрлекләүләр башлана. Ислам тарафыннан түгел, аңа каршы. Патша хөкүмәте һәм православие чиркәве яулап алынган җирләрдә мөселманнарга карата аяусыз изү режимы урнаштыралар; дини һәм милли эзәрлекләүләр башлана. Бу бердәнбер максатны — җиңелгән халыкны православие диненә тартып урыслаштыру максатын күз алдында тотып эшләнә. Шушы максатка ирешү өчен мөселманнарга карата иктисади, сәяси, хокукый эзәрлекләүләр җәелдерелә, көчләп чукындырулар башлана. Халыкара мөнәсәбәтләргә, ил эчендәге вәзгыятькә бәйле рәвештә бу сәясәтне үткәрү юллары үзгәрә тора. Ә максат үзгәрешсез саклана — татарларны милләт буларак бетерү, аларны чукындыру, исламны дин буларак бу төбәктә юкка чыгару.

Октябрь революциясе җиңеп, илдә совет хакимияте урнашкач, дингә карата бөтенләй яңа сәясәт үткәрелә башлый. Совет хөкүмәте диннең дәүләттән аерылганлыгын игълан итә һәм шул ук вакытта коммунистик идеологиягә каршы көч санап, дингә һәм дини оешмаларга каршы киң планлы һөҗүм җәелдерә. Бу шартларда православие дә, ислам да бертигез җәбер-золымга дучар ителәләр, мәчетләр дә, чиркәүләр дә ябыла, дини уку йортлары яшәүдән туктый, православие руханилары да, мөселман руханилары да хокукый эзәрлекләүләргә дучар ителәләр. Православиегә каршы да, исламга каршы да коммунистик атеистик пропаганда ябырыла.

Күренүенчә, башка диннәргә карата сугышчан түземсезлек һич кенә дә ислам тарафыннан күрсәтелмәде. Киресенчә, христиан хөкемдарлар тарафыннан уздырылган мондый түземсез-

лекне мөселманнар татыды. Шуның өстенә, коммунистик хакимият чорында бу түземсезлек режимы бөтен диннәргә карата да җәелдерелгән иде — христианнарга каршы да, мөселманнарга каршы да, башка диннәргә каршы да.

[1] Маркс и Энгельс, т.10, стр. 167.

[2] Сагдеев А. Наследие ислама: история и современность. Предисловие к книге Монтгомеры Уоот «Влияние ислама в Средневековую Европу», М., 1976, с.4.

1996, июнь

ҖӘДИТЧЕЛЕК ҺӘМ ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН

XIX гасырдан XX гасырга күчкән чорда татар дөньясы социаль-иктисади һәм мәдәни-идеологик мөнәсәбәтләр өлкәсендә тирән үзгәрешләр кичерә. Иҗтимагый аңда үткән юлга һәм җәмгыятьнең тормышына карата яңача фикерләүләр укмаша, яңа кыйблалар эзләнә. Шушы эзләнүләр барышында соңыннан җәдитчелек дигән исем алган киң иҗтимагый хәрәкәт барлыкка килә. Бу хәрәкәт татарлар арасында гына түгел, башка төрки халыклар арасында да үзенең зур яңгырашын тапты.

Җәдитчелек хәрәкәте XIX йөзнең 80-нче елларында формалашты һәм аның байрагын шул вакыттагы социаль тәртипләр белән килешә алмаган татар зыялылары күтәреп чыктылар. Тора-бара бу хәрәкәт зур көчкә әйләнде һәм тарихыбызда тирән эз калдырды.

Революциягә кадәр дә, аннан соң да татар җәмәгатьчелеге арасында җәдитчелек хәрәкәте прогрессив роль уйнаган уңай күренеш дип бәяләнеп киленде. Әмма Солтангалеевчылыкка каршы көрәш җәелгәч, татар иҗтимагый фикере тарихын югарыдан төшерелгән күрсәтмәләр нигезендә бәяләү урнаша, нәтиҗәдә, башка иҗтимагый хәрәкәтләр белән беррәттән, җәдитчелеккә карата да реакцион күренеш дигән уйдырма тудырыла. Моның азагы аяныч булды — җәдитчелек озак еллар буена объектив нигезләрдә өйрәнелмәде, берниндн дәлилсез типкәләнеп йөртелде.

Бу уйдырманың баштанаяк нигезсез булуы минем 1979 елны чыккан «Джадидизм, его социальная природа и эволюция» дигән хезмәтемдә төпле дәлилләр белән исбатланган

иде.[1] Шушы ук хезмәтемдә, ә аннары 1990 елда дөнья күргән «Буржуазно-демократическое движение рубежа XIX—XX вв. и его идеологическое выражение — джадидизм»[2] дигән язмамда җәдитчелек хәрәкәтенең социаль асылы һәм тарихтагы урыны, ул күтәргән проблемаларның эчтәлеге дә ачып салынды. Җәдитчелек хәрәкәте һәм аның тарихтагы урыны турында вакытлы матбугатта чыккан кайбер мәкаләләремдә дә сүз барды. Шуңа күрә бу язмамда сөземтә рәвештә җәдитчелеккә хас кайбер төсмерләр турында гына сүз алып барам.

Беренче чиратта җәдитчелекнең үзенең социаль табигате, алдына куйган максатларының эчтәлеге һәм характеры белән мәгърифәтчелек тибындагы хәрәкәт булганлыгын күрсәтеп үтәргә кирәк. Мәгърифәтчелеккә хас рәвештә бу хәрәкәт үзенең һөҗүмен артталыкка, катып калганлык күренешләренә каршы юнәлдерде, тәрәкъкыят һәм иҗтимагый яңарыш байрагын күтәрде. Җәдитчеләр күтәргән яңарыш таләпләре социаль-икътисади мөнәсәбәтләр өлкәсен дә, гаилә-көнкүреш мөнәсәбәтләре өлкәсен дә, мәдәният-идеология өлкәсен дә колачладылар. Алар хатын-кызга ирек һәм тигезлек даулыдылар, мәдәни-агарту учакларының киңәйтелүе кирәгенә басым ясадылар, газета-журналлар тарату, милли матбугат һәм сәнгать үсеше зарурлыгын алга сөрделәр, халыкның икътисади хәлен төптән үзгәртү һәм көнкүрешне урта гасырчылык рамкаларыннан азат итү кирәклеген күрсәтеп үттеләр. Алар ислам позициясендә торып фикер йөрттеләр. Шул ук вакытта алар дини тәгълиматның һәм йолаларның кайбер катып калган якларын тәнкыйтьләп тә чыктылар, мөселман руханиларның эшчәнлеген яңабаштан коруны таләп иттеләр, шәригатьнең кайбер төшенчәләренә яңача якын килү кирәклеген күрсәттеләр.

Җәдитчеләрнең игътибар үзәгендә яшь буынны укыту-тәрбия мәсьәләсе торды. Схоластикага корылган иске уку-укыту системасының чикләнгәнлеген һәм аның заман таләпләренә җавап бирердәй милли кадрлар хәзерли алмаганлыгын күреп, алар мәктәп-мәдрәсәләр эшчәнлегенә тирән реформа үткәрү өчен тырыштылар, алардагы укыту программаларына, дини дәресләр белән беррәттән, дөньяви фәннәр дә, татар һәм рус телләре дә укыту кирәклеген алга сөрделәр. Җәдитчеләр мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту эшләрен яңа педагогика нигезендә алып бару тарафдарлары иделәр, алар Европаның фән-техника казанышларын киң рәвештә файдалану зарурлыгына басым ясадылар.

Әйтелгәннәр җәдитчелекнең үзенең асылы белән мәгърифәтчелек тибындагы хәрәкәт булганлыгын ачык күрсәтәләр. Шул ук вакытта җәдитчелекне гомумән татар мәгърифәтчелеге белән тәңгәлләштерүнең урынсыз булуын да күрсәтеп үтәргә кирәк. Ә тәңгәлләштерүгә омтылышлар очрый. Әмма бу урынсыз. Чөнки, билгеле булганча, татарлар арасында мәгърифәтчелек хәрәкәте инде XVIII гасыр азакларында ук формалаша башлый, ә XIX гасыр урталарында ул үзенең җитлегү чорын кичерә. Аның күренекле вәкилләре сыйфатында без Г.Курсави (1776—1812), Г.Утыз-Имәни әл-Болгари (1754—1834), И.Хәлфин (1778—1829), Ш.Мәрҗани (1818—1889), К.Насыйри (1825—1902), Х.Фәезханов (1828—1866) исемнәрен атыйбыз. Җәдитчелек исә, инде әйтеп үтелгәнчә, XIX гасырның 80-нче елларында формалаша. Аның тарафдарлары тарихи аренага мәгърифәтчеләрнең элекке буыны башлаган эшне дәвам иттерүчеләр буларак аяк бастылар. Шуңа күрә Галимҗан Ибраһимов җәдитчелекне татар мәгърифәтчелеге үсешенең яңа баскычы итеп карый. Аның фикеренчә, җәдитчеләр Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Х.Фәйзханов башлаган эшне дәвам иттерделәр.

Татар мәгърифәтчелегенең яңа, җәдитчелек этабының үзенчәлекләре турында сүз алып барганда түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин: беренчедән, мәгърифәтчелек программасын тормышка ашыруда практик эш җәелдерү һәм, икенчедән, хәрәкәткә татар зыялыларының киң катламы тартылу. Татар мәгърифәтчелегенең тәүге этабында мәгърифәтчелек идеяләрен тарату эшен бары аерым шәхесләр генә алып бардылар. Җәдитчелек хәрәкәтендә исә мәгърифәтчелек байрагы астына татар зыялыларының киң катламы тупланды. Җәдитчеләр үзләренең сафларына мөселман руханиларының прогрессив рухтагы өлешен дә, мөгаллимнәрне дә, шәкертләрне дә, прогрессив милли интеллигенциянең башка катламнарын да берләштереп эш иттеләр.

Киң пландагы милли хәрәкәт буларак, җәдитчелек үз байрагы астына татар зыялыларының төрле караштагы вәкилләрен берләштерде. Җәдитчеләр арасында беренче чиратта мөселман реформаторлыгы агымы күзгә ташлана. Бу агым тарафдарлары, җәдитчелеккә хас булганча, иҗтимагый үзгәрешләрнең зарурлыгын, рухи хәзинәләрне яңадан карап чыгу кирәклеген күреп эш иттеләр. Шул хисаптан алар исламның кайбер нормаларын заман таләпләре күзлегеннән карап чыгарга, аларны хәзерге

иҗтимагый практика күзлегеннән карап яңача бәяләргә кирәклеген таныдылар. Бу юнәлештә иң актив эш алып барган шәхесләр арасыннан Г.Баруди, М.Бигиев, Р.Ибраһимов, К.Тәрҗемани, З.Кадыйри, Җ.Абызгильдин һәм Х-Г.Габәши исемнәрен атарга кирәк.

Җәдитчеләр арасындагы икенче агым — мәгърифәтчел реформаторлык. Бу агым тарафдарлары үзләренең игътибарларын тарих, мәдәният, мәгариф мәсьәләләренә юнәлттеләр һәм иҗтимагый тормышны үзләренең элгәрләре әйтеп калдырган программа нигезендә кору максатын күз алдында тотып эш иттеләр. Болар арасында иң мәшһүрләре Р.Фәхретдинов, Ф.Кәрими, Һ.Максуди, Ш.Күлтәси, З.Камали, Г.Гафуров-Чыгтай һәм Г.Буби булдылар. Дөрес, әйтелгән бүленеш бик шартлы. Икенче агым тарафдарлары, беренчесенеке кебек үк, ислам позициясендә торып эш иттеләр. Әмма аларның мирасында, беренче агым тарафдарлары мирасы белән чагыштырганда, билгеле бер күләмдә дөньявилек өстенлек итә иде.

Җәдитчеләр арасыннан Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Исхакый, Г.Камал, М.Гафури, Ф.Туктаров кебек татар милли хәрәкәтенең һәм мәдәниятының күренекле вәкилләре дә чыкты һәм алар практикада җәдитчеләрнең мәгърифәтчелек программаларын тормышка ашыруны күз алдында тотып эш иттеләр.

Җәдитчеләр эшчәнлеге бер яктан татар җәмәгатьчелегенең консерватив даирәләрнең, икенче яктан хөкүмәт органнарының нык каршылыгына очрады. Боларның беренчеләре үз сафларында тәгассыблык белән агуланган мөселман руханиларын һәм искелектән аерыла алмаган татар байларын берләштерделәр. Бу феодал-уртагасырчылык агымы иде. Алар кадимчеләр дип аталдылар (кадим-иске, борынгы). Болар арасында үзләренең сугышчанлыгы белән Ш.Мөхәммәдиев, Г.Мөхетдинов һәм И.Динмөхәммәтов аерылып тордылар. Татар иҗтимагый фикеренең бу консерватив даирәләре җәдитчеләрне исламның нигезләрен җимерүдә гаепләп чыктылар, аларны фетнәчеләр һәм дин дошманнары дип санадылар. «Бу дөньяда, — дип язды Г.Мөхетдинов, — ирек бирергә ярамый торган өч нәрсә бар: дошман, ут һәм авыру һәм боларга каршы кичекмәстән корал, су, дару кулланырга кирәк, юкса кеше һәлак булачак: дошман — яңа тәртипләр һәм алар арасында иң беренчесе — яңача укыту, ут — аларның тәгълиматы һәм авыру — аларның укытуы нәтиҗәсе». Ә.И.Динмөхә-

мматов исә җәдитчеләрне иблис иярченнәре дип санады, аларны шәригатьне бозуда гаепләде һәм ислам тарафдарларын аларга каршы аяусыз көрәш алып барырга чакырды.

Патша хөкүмәте һәм аның җирле органнары җәдитчеләргә каршы көрәштә кадимчеләрнең союзниклары буларак чыктылар. Алар җәдитчеләр эшчәнлегендә патша самодержавиесе өчен зур куркыныч күрделәр һәм бу яңалык тарафдарлары белән көрәштә кадимче муллаларны файдаланырга тырыштылар. Моның шулай икәнлеген эчке эшләр министры Маклаковның хаты ачык күрсәтә. «Движение в пользу новометодных школ, — дип язды ул, — встретило противодействие в лице консервативных представителей мусульманского духовенства... Будучи движимы побуждениями чисто религиозными, такие лица в сущности того не сознавая, является союзниками властей в борьбе с нежелательной с государственной точки зрения национализацией мусульманской школы». Алга таба Маклаков җирле органнарны бу союзникларга игътибар итәргә һәм аларга ярдәм күрсәтергә чакыра.

Җәдитчеләрнең эшчәнлеге искелекне яклаучы шушы кадими көчләргә каршы көрәш рәвешендә җәелдерелде. Бу эшчәнлек халыкның рухи потенциалын арттыруда, кешеләрне феодал идеология сөременнән арындыруга үзенең зур өлешен кертте. Җәдитчеләрнең эшчәнлеге җәелгән чорда татарлар арасында христиан динен тарату максатында православие миссионерлары киң колачлы эш алып бара иделәр. Җәдитчеләрнең эшчәнлеге миссионерларның бу тырышлыгын нейтральләштерүгә һәм халыкта ата-бабалар традицияләренә, аларның иманына тугрылыкны саклап калуда үзенең өлешен кертте.

Җәдитчелек таралуның, аның халык тормышына үтеп керүенең татар мәдәнияты үсешендә дә тәэсире зур булды. Җәдитчеләр эшчәнлеге нәтиҗәсендә туган телдә фәнни китап бастыру яңа үсеш алды, арифметика, география, физика, гигиена, тарих һ.б. фәннәрдән китап таралу киң колач алды. Җәдитчеләр эшчәнлегенең зур нәтиҗәсе — мәктәп-мәдрәсәләр челтәре киңәю һәм аларда укучылар санының күзгә күренеп артуы. Бу уңайдан 1895 елдан алып 1912 елга кадәр Казан губернасында татар мәктәпләре санының 647 дән 1088 гә кадәр, аларда укучылар санының 33 меңнән 83 меңгә кадәр үсүен күрсәтү дә җитә. Ә бу үз чиратында татарлар арасында белем дәрәҗәсенең яхшы ук күтәрелүенә китерде.

Җәдитчеләр эшчәнлеге белән яңа, реалистик әдәбият таралу да, матур әдәбиятка тәнкыйди рухның үтеп керүе дә, татар вакытлы матбугатының тууы һәм үсеше дә турыдан-туры бәйләнгән. Җәдитчеләр эшчәнлеге татар театрының, татар профессиональ музыкасының һәм сынлы сәнгатенең тууына да мәдәни-идеологик җирлек хәзерләде.

Җәдитчелек хәрәкәтенең таралуы татарларның үзләренең милли мәнфәгатьләрен яхшырак күзаллый башлауларын, үзләренең тарихы булган милләт буларак таный башлауларын күрсәтүче фактор булды. Җәдитчеләр эшчәнлеге татар иҗтимагый фикере үсешенең, иҗтимагый аң үсешенең мөһим бер этабы булды. Бу турыдан-туры халыкның рухи потенциалы үсүгә илтте, иске богаулардан арыну өчен массаларны яңа идеяләр белән баету мөмкинлеге ачты.

Җәдитчелек хәрәкәтенең бу сабаклары халкыбызның бүгенге хәле һәм аның киләчәге турында фикерләүләр өчен дә билгеле бер җирлек булып тора. Беренче чиратта, милли тарихыбызның бу дәверен тирәнтен өйрәнү, ул вакытта татарлар арасында яңгыраш тапкан азатлык идеяләрен барлау, җәдитчеләрнең милләт мәнфәгатьләрен күз алдында тотып актив көрәшкә тартылуларын күзаллау, мөгаен, халкыбыз алдында бүген торган проблемаларны чишү юлларын эзләгәндә үзенең ролен, әйтергә кирәк, мөһим ролен уйнар.

Икенче мөһим момент — инде әйтеп киткәнчә, җәдитчеләр мәктәп-мәсдрәсәләр эшчәнлегендә зур үзгәрешләргә ирештеләр, аларны дөньявиләштерүдә, табигать гыйлемнәрен һәм гуманитар фәннәрне укытуда, аларның челтәрен киңәйтүдә алга зур адым ясадылар. Мәктәп-мәдрәсәләрнең эшчәнлегендә бу үзгәрешләр милли нигездә барды: зур яңарышлар кичерсәләрдә, аларда гасырлардан килгән традицияләр сакланды. Мәктәп-мәдрәсәләребез эшчәнлегенең үзәгендә милли тәрбия мәсьәләсе торды. Бу исә милли рухның яңа баскычка күтәрелүендә үзенең ролен уйнады.

Октябрь революциясеннән соң мәктәп эше халыкның үз кулыннан алынды, алардагы укыту-тәрбия эшендәге миллилекне чикләү өчен бөтенесе дә эшләнде, мәктәп эшенә интернационализм идеологиясе сеңдерелде. Нәтиҗәдә, мәктәп милли ихтыяҗларны канәгатьләндерүдән читләштерелде, ахырда милли йөзен бөтенләй югалтты һәм урыслаштырылды. Хәзер безнең алга милләтне торгызу, янадан аякка бастыру проблемасы килеп

басты. Бу проблеманы чишүдә җәдитчеләр тәҗрибәсен өйрәнү һәм куллану үзенең ролен уйнаячак. Бу тәҗрибә мәктәпләр эшчәнлеген милли нигездә коруның зарурлыгы турында сөйли. Моның өчен урыс мәктәпләрендә татар сыйныфлары ачу һәм русча укытыла торган сыйныфларга атнасына 2—3 сәгать татар теле дәресләре кертү генә җитми. Моның өчен мәктәп эшчәнлеге тамырдан үзгәртелеп корылырга, бөтен укыту-тәрбия эшләре милли рухта алып барылырга тиеш. Бу укыту программаларын тамырдан үзгәртүне таләп итә. Рус теле татар мәктәбендә, әлбәттә, укытылачак, әмма татар телен укыту да рус теле укытудан ким дәрәҗәдә булырга тиеш түгел. Әдәбият укыту программасы да М.Гафуриның «Кара йөзләр» һәм Һ.Такташның «Гасырлар һәм минутлар»ы кебек интернациональ һәм коммунистик тәрбия бирү максатында кертелгән әсәрләреннән азат ителергә тиеш. Ә менә Г.Исхакыйның милли рух, милли әхлак аңкып торган «Сөннәтче бабай»ы, «Остабикә»се кебек әсәрләр әдәбият дәреслегендә үзләренең лаеклы урынын алырга тиешләр.

Хәзерге мәктәптә халкыбызның тарихы бозып укытыла, анда кулланыла торган дәреслекләр уйдырмалар белән тулган. Бу дәреслекләр милли хис тәрбияләүгә ярдәм итмиләр генә түгел, киресенчә, халкыбызның үткәненә карата җирәнгеч хисләр генә уята алалар. Шуның өчен мәктәптә тарих укыту тамырыннан үзгәртелергә, тарих укыту милли хис тәрбияләрдәй, халыкның үткәнен дөрес яктырткан дәреслекләр нигезендә алып барылырга тиеш.

Милли мәктәп, әлбәттә, табигать гыйлемнәренең дә, иҗтимагый фәннәрнең дә, җәдит мәктәпләрендәге кебек, татар телендә укытылуын күз алдында тота.

Татар мәгърифәтчеләре, шул хисаптан җәдитчеләр, педагогика фәне буенча олы мирас калдырдылар. Бу җәһәттән бигрәк тә К.Насыйри, Р.Фәхретдинов, Һ.Максуди һ.б. хезмәтләрен күрсәтеп үтәргә кирәк. Бу хезмәтләр татар халкының укыту-тәрбия эшендәге күпгасырлык бай мирасын өйрәнү нигезендә язылганнар. Милли мәктәптә бу мирас та үзенең лаеклы урынын алырга тиеш.

Өченче момент — милли мәдәният мәсьәләсе. Җәдитчеләр аның үсешенә дә мөһим өлеш керттеләр. Бу үсешнең кайбер контурлары турында инде әйтеп үттек. Иң мөһиме — бу

үсешнең җәдитчеләр алга сөргән төп тенденцияләре шулай ук милли рухта иделәр. Совет чорындагы интернациональләштерү шаукымы бу җәһәттән дә үзенең өлешен кертте, мәдәниятны милли нигездән аеру өчен бөтенесе эшләнде, көнбатыштан килгән һәм халкыбыз әһаңына чит булган стереотиплар тагылды. Шуңа күрә мәдәниятыбыз үсешен җәдитчеләр сызып калдырган милли буразналарга кайтару өчен дә эзлекле эш җәелдерәсе бар.

Һәм, ниһаять, дини мирас мәсьәләсе. 1100 елдан артык безнең халкыбыз ислам канунннары нигезендә яшәде. Мөселманлык безнең милли рухыбызның нигезен тәшкил итеп килде һәм этник аңыбыз белән тыгыз бәйләнгән иде. Күп гасырлар дәвамында безнең мәдәниятыбыз, әхлакый карашларыбыз ислам белән тыгыз бәйләнештә үсте. Большевиклар хакимияте безнең халкыбызны бу мирастан, бу тарихтан аеру өчен бөтенесен эшләде. Бу исә безне зур әхлакый югалтуларга китерде, рухи яктан зәгыйфьләндерде. Эчкечелек, җенси тыйнаксызлык, яшьләр арасында тәртипсезлекләр, буыннар арасында, ир-хатын арасында аңлашылмаулар моның аерым мисаллары. Халык тормышын әхлакый сафландыру динне торгызу белән аерылгысыз бәйләнгән. Моны халкыбыз йөрәге белән сизә, дингә тартыла. Без бүген зур дини күтәрелешнең шаһитләре. Ләкин бу җәһәттән бик мөһим бер проблема туа — халкыбыз дингә ни рәвештә кайтыр?

Инде әйткәнемчә, XIX һәм XX гасыр арасында дини үсештә ике юнәлеш билгеләнде — кадимчеләр һәм җәдитчеләр. Җәдитчеләр алга карап эш иттеләр, динне заман күзлегеннән карап аңларга тырыштылар; кадимчеләр исә үткән көнгә ябышып яттылар. Дин нинди рәвештә безгә кире кайтыр, кадимчеләр күзаллаганчамы, әллә җәдитчеләрме? Хәзер күп кенә мөселман илләрендә фундаментализм дигән агым барлыкка килде. Бу агым, бездәге кадимчеләр кебек үк, мөселман дөньясының бары үткәндәге бөеклеген генә күрә, мөселман халыклары алдында яңа заман тудырган проблемалардан йөз чөерә. Дингә йөз белән борылу шартларында милләттәшләребез арасыннан да кайберәүләрдә шушындый тенденцияләр күзгә ташлана. Әмма мондый тенденцияләр бары тупикка гына илтә алалар, халыкны дөнья цивилизациясеннән, тәрәккыяттән башка якка өстериләр. Җәдитчеләр моны күрә алдылар һәм дини яңарышны, динне заман таләпләреннән чыгып аңлауны алга сөреп кадимчеләргә каршы көрәш алып бардылар. Хәзер, дини яңарыш кичергәндә шушы җәдитчеләр башлаган эшне дәвам иттерәсе,

динне иҗтимагый, сәнагати һәм мәдәни тәрәккыятнең байрагына әйләндерәсе иде. Бу юнәлештә Риза Фәхретдинов, Муса Бигиев, Галимҗан Баруди, Рәшит Ибраһимов, Һади Максуди, Габдулла Буби, Зия Камали кебек күренекле җәдитчеләрнең мирасын тирәнтен өйрәнеп халкыбызның һәм дини, һәм әхлакый, һәм мәдәни яңарышы максатында файдалану үзенең игелекле ролен үтәр иде.

Шулай итеп, җәдитчеләр мирасында милләт алдында бүген барлыкка килгән проблемалар яссылыгыннан караганда бик бай һәм әһәмиятле хәзинә бар. Бу хәзинә халкыбыз алдына заман куйган таләпләрне чишүдә үзенең файдаланышын табарга тиеш.

[1] Кара: «Из истории татарской общественной мысли», Казань, 1979 г.
[2] Кара: «Общественная и философская мысль в Татарии начало XX в.», Москва, Наука, 1990 г.

1991 ел.

ИСЛАМ. ТАРИХ. ЗАМАН.

Ислам, башка диннәр кебек үк, үзенә хас догматикасы, символлары һәм кагыйдәләре булган һәм дөньякүләм таралган диннәрнең берсе. Әмма аның асылы моның белән генә чикләнми. Ул бер үк вакытта бик үзенчәлекле дөньяга караш һәм идеологик фикерләүләр системасы да. Бу система дингә бәйләнешле рәвештә үзендә фәлсәфи принципларны да, социаль һәм әхлакый концепцияләрне дә берләштерә. Ислам шул ук вакытта җәмгыятьнең тормышын тәртипкә салучы, кешеләрнең тормышта үзләренең тотышларын һәм үзара мөнәсәбәтләрен билгеләүче кагыйдәләр тупланмасы да булып тора. Мөселман дөньясында иҗтимагый-сәяси, әхлакый һәм фәлсәфи мәсьәләләрнең үсеше һәркайчан ислам кануннары нигезендә булды. Халкыбызның тарихында һәм мәдәниятында ислам алып торган урын аның шушы киң планлы мәдәни һәм идеологик система булуы белән билгеләнде дә.

Дини, фәлсәфи, идеологик, хокукый һәм әхлакый система буларак ислам халкыбыз тарихында мөһим роль уйнады. Бу роль халкыбыз тарихында ислам уйнаган функцияләрдә үзенең ачык чагылышын тапты. Бу функцияләр түбәндәгеләргә кайтып кала:

1. **Халкыбызны бергә туплау, берләштерү** (интегративная функция). Бер Алланы тануга нигезләнгән идеологик система буларак, ул безнең бабаларыбыз — болгарларның дәүләт булып оешуы нигезендә ятты һәм бу дәүләтнең идеологик әсасын тәшкил итте. Болгар дәүләте формалашканда аның составына болгарлар белән бергә алар белән кардәш башка төрки кабиләләр һәм угор-фин кабиләләренең аерым төркемнәре керде. Ислам бер дәүләт эчендә яшәгән бу кабиләләрне берләштерде, аларның бергә яши алуларына кирәкле рухи һәм әхлакый җирлек тудырды, үзара мөнәсәсбәтләрен изгеләштерде һәм ныгытты, кабиләләр арасындагы аерымлыкларны йомшартты, аларның психик якынаюына юл ачты һәм нәтиҗәдә бу кабиләләр болгар исеме астында бер кавем-милләт булып оештылар. Шәмсетдин әд-Димәшки язып калдырган хәбәргә караганда, Идел буеннан чыгып хаҗга баручылардан, сез кемнәр дип сорагач, «без — болгарлар» дип җавап бирәләр. Моннан күренүенчә, болгарларда ныклы милли үзаң — болгарлык формалашкан була. Ә болгарлар кемнәр, дип сорагач, алар: «Төрек белән сәкалибә арасында туган халык», дип җавап бирәләр. Димәк, болгарлар үзләренең нинди халык булуын гына түгел, этник тамырларын да яхшы белеп фикер йөрткәннәр. Бусы да аларда милли узаңның никадәр тирән үтеп керүе турында сөйли һәм бу милли узаң формалашуда ислам мөһим алшарт булды.

2. **Халыкның яшәешен билгеле бер тәртипкә, җайга салу** (регулятивная функция). Исламның хокукый асылын тәшкил иткән шәригать гасырлар буенча болгар-татарлар арасында социаль-экономик, сәяси, хокукый мөнәсәбәтләрне ныклы бер тәртипкә салды, җәмгыятьнең нормаль яшәешен, тормышның билгеле бер тәртиптә агышын тәэмин итте.

3. **Үзара бәйләныш, аралашу, фикер алмашу** (коммуникативная функция). Башка мөселман халыкларындагы кебек үк, болгар-татарларда да исламның бу функциясе мәчетләр эшчәнлегендә үзенең ачык чагылышын тапты. Намаз укудан тыш, мәчетләр борын-борыннан фикер алышу, җәмәгать эшләрен хәл итү урыны булып хезмәт иттеләр, аларда галим-голямә җыелып, дини һәм дөньяви мәсьәләләр турында бәхәс алып барды. Мәчетләрдә мәхәллә халкы җыелгач, аның тормышына кагылышлы мөһим карарлар да кабул ителә килде. Исламның бу

функциясе, күренүенчә, аның халыкны бергә туплау һәм аның яшәешен билгеле бер тәртипкә салу функцияләре белән бәйләнгән һәм аларны тулыландыра.

4. **Дөньяга, тирәлеккә карашны формалаштыруда да ислам мөһим роль уйнады** (мировоззренческая функция). Бу уңайдан фикһе гыйлеменә күз салыйк. Аны, гадәттә, исламның хокук тәгълиматы рәвешендә күзаллыйлар. Әмма ул моның белән генә чикләнми. Ул үзендә җәмгыять теориясенә кагылышлы бик күп проблемаларны берләштерә. Хокук мәсьәләләре белән беррәттән ул фәлсәфәне дә, илаһи тәгълиматны да, сәясәтне дә, әхлак мәсьәләләрен дә, мантыйкны да, тел гыйлемен дә тикшерә. Шәригать белән дә эш шулай тора. Гадәттә аны хокукый һәм әхлакый нормалар җыентыгы дип күз алдына китерәләр. Әмма киң планда алганда ул үз алдына кеше яшәешенең бөтен якларын да яхшылык-яманлык күзлегеннән чыгып классификацияләү бурычы куя. Шуның белән бергә, ул үзенең алдына кеше яшәешенең иң төп сәбәпләрен ачу, аның универсум белән бәйләнешен һәм табигатен өйрәнү вазыйфасын да йөкли. Димәк, фикһе гыйлеме дә, шәригать тә иҗтимагый, фәлсәфи, хокукый, әхлакый проблемаларның барысы белән дә кызыксыналар һәм аларга җавап бирергә тырышалар.

5. **Кешеләрнең рухи һәм әхлакый ихтыяҗларын канәгатьләндерү функциясе.** Бу, беренче чиратта, үзенең чагылышын кешене турыдан-туры Алла белән бәйләүдә тапты. Бу бәйләнештә кеше үзенә рухи таяныч һәм күңел тынычлыгы күрде. Мөселман дөньясында, шул хисаптан болгар-татарларда да, кешеләрнең тормышы һәр даим ислам рухы белән өретелеп килде һәм шәригать кануннары белән билгеләнде. Ислам, билгеле булганча, гаделлек, мәрхәмәт, шәфкать, мәхәббәт, инсанилык (гуманизм), әхлакый камиллек идеалларын алга сөрә. Бу идеаллар халкыбызның әхлакый тормышының нигезендә яттылар, кешеләрнең уй-фикерләрен, омтылышларын изгеләштерделәр. Бу исә аларны яман адымнар ясаудан саклап килде.

6. **Ислам — безнең мәдәниятыбызның нигез ташы да булды** (культурологическая функция). Исламны кабул иткәч, безнең бабаларыбыз — болгарлар ул вакытта дөньякүләм алдынгы позициядә торган гарәп-мөселман мәдәнияты тәэсире астына керәләр. Ислам белән бергә алар гарәп язуын да кабул итәләр һәм бу безнең язма әдәбиятыбыз барлыкка

килүенең һәм үсешенең алшарты булды. Гарәп мәдәнияты белән танышу болгарларда фәнни-фәлсәфи фикер үсүендә дә зур роль уйнады.

Мәдәниятның мөһим өлеше — мәгърифәт. Ислам канаты астына тартылу болгар-татар мәдәниятының бу өлешенең нигез ташларын салуга да мөмкинлек тудырды. Исламны кабул иткәч үк болгарлар арасында уку-укыту эше билгеле бер системага салынды, мәктәп-мәдрәсәләр барлыкка килде. Болгар чорында урнашкан бу традиция Алтын Урда дәверендә дә, Казан ханлыгында да дәвам итә. Колониаль изү чорында да татар халкы бу традицияне эзлекле рәвештә дәвам иттерде һәм бу халкыбызда яхшы ук югары белем дәрәҗәсе сакларга мөмкинлек бирде.

Ислам мәдәнияты кысаларында болгар-татарларда төзелеш, архитектура, бизәү сәнгате үсә, нәфис сәнгатьнең үзенчәлекле алымнары туа, эстетик карашлар формалаша, китапчылык тамыр җәя.

7. Һәм, ниһаять, исламның **халкыбызның кавем-милләт булып сакланып калуында роле** (охранительная функция). Халкыбыз болгар чорыннан алып соңгы гасырларга кадәр авыр, катлаулы юл үтте, басып алуларга, икътисади, сәяси-хокукый изүләргә дучар ителде. Аның милли хисләре, дине мәсхәрәләнде, теле, мәдәнияты эзәрлекләнде. Аны диннән, милли тамырларыннан аеру өчен бөтенесе дә эшләнде — көчләп чукындыру да, һәр төрле җәберләүләр дә, мыскыллаулар да калмады. Әмма халкыбыз үзен этник берәмлек буларак саклап кала алды һәм монда исламның роле хәлиткеч булды. Авыр басым шартларында ул аңа рухи таяныч вә терәк булды, миссионерларның һөҗүмнәреннән сакланганда калкан вазыйфасын үтәде.

Әйтелгәннәр исламның халкыбызның тарихында ифрат әһәмиятле роль уйнавы, аның кавем-милләт булып формалашуының һәм саклануының, мәдәнияты үсешенең алшарты булуы, рухи вә әхлакый тормышының нигезендә ятуы турында сөйли.

Большевистик хакимият, марксистик идеологиягә бирелгән өстенлек халкыбыз тормышында исламның бу позициясен бик нык какшатты. Админстратив басым, кешеләрнең аңына коммунистик-атеистик идеология сеңдерү халкыбызны исламның әхлакый кануннарыннан аеруга, рухи бушлык тамыр җәюенә, мораль тотрыксызлык, эчүчелек таралуына китерде, гаилә мөнәсәбәтләренә һәм балалар тәрбияләүнең эчтәлегенә үзенең яман тәэсирен

ясады. Милли интеллигенциягә һәм мөселман руханиларына карата үткәрелгән сәяси эзәрлекләүләр милләтне рухи житәкчесез калдырды. Гыйбадәтханәләрне һәм мәдрәсәләрне жимерү халыкка дини-әхлакый тәрбия бирү юлларын кисте. Рухи җепләрнең өзелүе милли таркаулыкка китерде, милли битарафлык орлыклары чәчелде. Нәтиҗәдә, милли үзенчәлекләребездән тәмам аерылу һәм милләт буларак юкка чыгу куркынычы туды.

Бу шартларда заманның халкыбыз алдына куйган иң зур таләбе — үзебезне милләт буларак саклап калу чаралары күрү, милли асылыбызга кайту. Моның хәлиткеч шарты, беренчедән, халкыбызның улларында һәм кызларында милли аң уяту, милли битарафлыкны җиңү, милли горурлык хисе тәрбияләү, ә, икенчедән, халкыбыз арасында исламның гасырлар дәвамында яшәгән позициясен яңадан торгызу һәм ныгыту. Исламның позициясен элекке хәленә кайтармый торып, милләт улларының һәм кызларының ислам кануннарын һәм әхлакый принципларын тирән үзләштерүен тәэмин итми торып, милли асылыбызга кайту турында сүз дә алып барырга мөмкин түгел. Җәмгыять тормышын сафландыруда, аны рухи чатаклыклардан арындыруда мөселманлыкның рухи һәм әхлакый традицияләре гадәттән тыш зур әһәмияткә ия.

Моңа ирешүнең хәлиткеч шарты — дини тәрбиянең, ислам нигезләрен, аның әхлакый принципларын, халкыбыз тарихында тоткан урынын пропагандалауның төпле, уйланылган һәм фәнни нигезләнгән программасын булдыру, бу программаны тормышка ашыру буенча эзлекле эш алып бару. Бу программа үз эченә гаилә тәрбиясен дә, балалар бакчаларында эшләү формаларын да, мәктәп яшендәге балалар, егетләр-кызлар белән эшләү ысулларын да, дингә олыларны тарту юлларын да алырга тиеш. Дини-тәрбияви эшнең юлларын билгеләгәндә, әлбәттә, матбугат органнары һәм радио-телевидениенең эшчәнлеге дә, дини әдәбият басып чыгару һәм тарту мәсьәләләре дә күз алдында тотылырга тиеш.

Дини-тәрбияви эш алып барганда түбәндәгеләрне күз алдында тоту зарури:

1. **Заманның характеры, тормышыбызда шуңа бәйле рәвештә туган үзенчәлекләр, халкыбызның мәдәни-идеологик хәләте.** Революциягә кадәрге чор белән чагыштырганда хәзерге татарларның белем дәрәҗәсе һәм дөньяны аңлавы үзенең тирәнлеге белән дә, диапозоны белән дә бик нык

аерыла. Шуның өстенә 70 елга сузылган атеистик пропаганда да эзсез калмады, халыкның аңына нык тәэсир итте. Дини тәрбия эше бу вәзгыятьне искә алып борылса гына максатына ирешәячәк. Ул хәзерге шартларда түземле рәвештә үткәрелергә, тирән эчтәлекле һәм эзлекле булырга тиеш. Бу хәлдә дини вәгазьләрдә ара-тирә күренә торган кычкыру-җикерену яки куркыту тиешле нәтиҗә бирми генә түгел, киресенчә, зарар да итә. Хәзерге дини пропаганда халкыбызның теге яки бу катламында диннең тәэсире ни дәрәҗәдә булуын да, инсани төркемнәрнең психик халәтен дә истә тотып эш итәргә тиеш. Атеистик идеология тарафыннан калдырылган җимергеч тәэсирне тәмам җиңү өчен халыкның аңына җитәрдәй формалар кулланып, ислам, аның тарихыбызда, мәдәниятыбызда һәм рухи тормышыбызда уйнаган роле турында объектив информация җиткерү чарасы күрү бик мөһим.

2. **Милли һәм дини мөнәсәбәтләр ягыннан республиканың үзенчәлеге, анда төрле диннәрдәге кешеләрнең үзара бәйләнештә яшәве.** Бу бәйләнешләр исламның позициясенә дә тәэсир итми калмады. Шуның өстенә, инде әйтеп үтелгәнчә, 70 елга сузылган атеистик пропаганданың аяныч нәтиҗәләре, аның күбәүләрне динсезлек баткаклыгына этәрүе, ә икенчеләрдә дини битарафлык тәрбияләве. Бу исә халкыбызның күп кенә катламнарында идеологик бушлык (вакуум) тууына китерде. Хәзер бу бушлыкны христиан диненең төрле секталары, шул хисаптан евангелист-баптистлар, протестант-харезматиклар, кришнаитлар, баһаитлар тутырырга тырышалар, татар яшьләре һәм кызлары арасында миссионерлык эше җәелдерәләр. Бу да ислам әһелләреннән бик акыллы, эзлекле эш алып баруны таләп итә. Бу эш миссионерлар коткысына бирелүчән тәҗрибәсез яшьләребез һәм кызларыбызның күңелләренә үтеп керердәй, аларның аңына исламның рухи һәм әхлакый өстенлекләрен сеңдерә алырдай булсын иде. Шуның белән бергә төрле исем астында эш итүче миссионерларга каршы көрәш бөтен җәмәгатчелекнең дә, беренче чиратта милли оешмаларның һәм яшьләр берләшмәләренең дә игътибары үзәгендә торырга тиеш.

3. Дини-идеологик система буларак **исламның үзенчәлекләре.** Мөселман руханиларының вәгазьләрендә үзенең чагылышын тапкан ислам пропагандасы хәзер башлыча мөселман йолалары үтәүгә чакыруга кайтып кала. Мондый вәгазьләр

һичшиксез кешеләрнең дини ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә мөһим роль уйныйлар. Шул ук вакытта бу характердагы эшчәнлекнең чикләнгәнлеген дә күрсәтеп үтү зарур. Инде әйтеп үтелгәнчә, ислам дини йолалар үтәүгә генә кайтып калмый. Ул үз эченә рухи-әхлакый тәгълиматны да ала. Шуңа күрә дини тәрбиянең үзәгендә рухи-әхлакый тәрбия, кешеләрнең аңына мәрхәмәт, шәфкать, мәхәббәт, туганлык, үзара дуслык һәм ярдәмчеллек, әхлакый камиллек идеяләре сеңдерү мәсьәләсе торырга тиеш.

Хәзерге алып барыла торган тәрбия, руханиларыбызның вәгазьләре кешеләрнең хисләренә юнәлдерелгән, аларда дини хис тәрбияләүне максат итеп куялар. Әмма хәзерге шартларда, кешеләрнең белем дәрәҗәләре югары булу, аларның башка дин кешеләре белән һәркөн аралашуы һәм, ниһаять, атеистик идеологиянең яхшы ук таралуы шартларында бу һич кенә дә җитәрлек түгел. Исламның позициясен ныгыту өчен ул кешеләрнең хисенә генә түгел, аңына да үтеп керергә тиеш, аның кануннары аларның акылын да яулап алырга тиеш. Киң планлы идеологик-фәлсәфи система буларак исламның моңа мөмкинлекләре зур. Аның ислам дөньясында фәнне, фәлсәфәне үстерүдә кайчандыр булган казанышлары шуның белән аңлатыла да. Дини пропаганданың исламның бу үзенчәлегенә игътибары аның тәэсир итү көчен арттырачак, мөселман динен хисләр белән генә түгел, гакыл белән дә кабул итәргә ярдәм итәчәк.

Исламны шулай тирән аңлауга ирешүгә юнәлдерелгән эшчәнлек тә, сектант-миссионерлар һәм башка дини агымнар белән уңышлы көрәшү ихтыяҗы да һәм, ниһаять, заманыбызның үзенчәлекләре дә руханилардан күпкырлы хәзерлек, ислам тарихын һәм мәдәниятын тирән белү, фәлсәфә һәм илаһият тәгълиматы өлкәсендә яхшы хәзерлек, фән өлкәсендә хәбәрдарлык, фән казанышларын корьән өйрәтмәләре белән чагыштыра һәм аңлата алырлык хәзерлек таләп итә.

Кызганычка каршы, руханиларыбызның күпчелегендә бу җитенкерәми. Шуңа күрә аларның дини, фәлсәфи һәм гомуммәдәни хәзерлеген күтәрү чаралары турында уйларга вакыт. Руханиларның дини һәм фәлсәфи хәзерлеген күтәрү, алар тарафыннан хәзерге иҗтимагый процессны өйрәнү һәм фәнни казанышлар белән танышу системасы тудырылса, максатка ярашлы булыр иде. Бу мәсьәләдә татар зыялылары да читтә торырга тиеш

түгелләр. Мөгаен, зыялылар белән руханилар арасында диалог башларга да вакыт җиткәндер. Бу һәр икесенең игътибарының милли ихтыяҗларга йөз белән борылуына ярдәм итәр иде.

Без бүген — зур дини күтәрелешнең шаһитләре. Ләкин бу җәһәттән бик мөһим бер проблема туа — халкыбыз дингә ни рәвештә кайтыр. Безнең максат — хәзерге заман исламына, фәнни казанышлар һәм иҗтимагый практика белән янәшә атлый торган исламга кайту. Билгеле булганча, XIX гасырда татар мәгърифәтчеләре Г.Курсави һәм Ш.Мәрҗани мөселман дөньясында беренчеләрдән булып реформаторлык идеяләре күтәреп чыктылар һәм алар күтәргән идеяләр зур яңгыраш тапты. XIX һәм XX гасыр арасында бу идеяләрне җәдитчеләр яңа баскычка күтәрделәр. Тегеләр дә, болар да алга карап эш иттеләр, исламны заман күзлегеннән чыгып аңларга тырыштылар. Шул елларда мәйданга чыккан һәм кадимчеләр исеме белән дан алган икенче агым тарафдарлары исә үткән көнгә ябышып яттылар. Хәзер күп кенә мөселман илләрендә фундаментализм дигән агым барлыкка килде. Бу агым тарафдарлары, бездәге кадимчеләр кебек, мөселман дөньясының бары үткәндәге бөекләген генә күрәләр, мөселман халыклары алдында яңа заман куйган проблема вә таләпләрдән йөз чөерәләр. Дингә йөз белән борылу шартларында милләттәшләребез арасыннан да кайберәүләрдә шундый тенденцияләр күзгә ташлана. Әмма бу тенденцияләр бары тупикка гына илтә алалар, халыкны дөнья цивилизациясеннән, тәрәккъыят юлыннан башка якка өстериләр. Р.Фәхретдинов, Г.Баруди, Р.Ибраһимов, М.Бигиев, З.Кадыйри, З.Камали, Г.Буби кебек җәдитчеләр моны күрә алдылар һәм дини яңарышны, динне заман таләпләреннән чыгып аңлауны алга сөреп, кадимчеләргә каршы аяусыз көрәш алып бардылар. Хәзер дини яңарыш кичергәндә шушы җәдитчеләр башлаган эшне дәвам иттерәсе, исламны иҗтимагый, сәнагати һәм мәдәни тәрәккъыятнең байрагына әйләндерәсе иде.

Озын-озак тарих дәвамында халкыбызны милләт буларак саклап калуда, дин белән бергә, мәктәп хәлиткеч роль уйнады. Аның эшчәнлеге баштанаяк ислам рухы белән өретелгән иде һәм гасырлар буена яшь буынны мөселманлык рухында, шуның белән бергә милли рухта тәрбияли килде. Җәдитчеләр мәктәп эшен үзгәртеп кору, аны заман таләпләренә яраклаштыру идеясен күтәреп чыктылар. Бу идеяне тормышка ашыру белән

бергә, алар мәктәпнең миллилеген дә саклап калдылар. Җәдитчеләр мәктәпкә дөньяви фәнне укытуны керттеләр. Шул ук вакытта татар мәктәбе, аларның тырышлыгы белән, үзенең дини вә милли рухын да саклап калды.

Большевиклар хакимияте урнашкач идарәче даирәләр бөтен көчләрен татар мәктәбен ислам рухыннан һәм миллилектән арындыру эшенә җәлеп иттеләр. Элек яшь буынны укыту-тәрбия эшләрен татар халкы үз кулында тотты. Совет власте елларында исә мәктәп эше большевистик хакимият ихтыярына буйсындырылды һәм аларның программаларына интернационализм һәм атеизм сеңдерелде. Бу исә инде берничә буынны милли рухтан, милли мәдәнияттән, милли традицияләрдән аеруга китерде, халыкның тормышыннан милли тел акрынлап кысрыклап чыгарыла барды. Атеистик тәрбия гасырлар буена исламга нигезләнгән әхлак принципларыннан аерылуга сәбәп булды, мораль тотрыксызлык нормага әйләнде. Халкыбыз үзенең милли йөзен югалта барды, инкыйраз упкыны алдына килеп басты.

Ислам дөньясының олы шәхесе мөтәфәккир Әбул Әгълә Әл-Мәүдүди (1903—1979. Пакистан), «халыкларның җир йөзеннән эзсез югалулары кеше саны яки женесләренең кимүеннән түгел, ә бары тик милли асылларының югалуыннан килә», дип язды. Милләтебезне бу язмыштан саклап калуның мөһим шарты — хәзер мәктәп эшен, укыту-тәрбия эшен яңадан халкыбызның үз кулына алу, аңа милли рух сеңдерү, балаларга уйдырмалардан арындырылган хакыйкый тарих, милли мәдәниятыбыз нигезләрен, милли әдәбият укыту, аларның милли телне камил белүләренә ирешү, кыскасы, алдагы буыннарның милли асылыбызга кайтуына ирешү.

Безнең асылыбыз исә исламнан аерылгысыз. Шуңа күрә яшь буынның милләт вәкилләре булып формалашуы, аның ислам рухына гаиләдә дә чумуы, ислам нигезләрен, аның әхлакый кануннарын тирән үзләштерүе белән бәйләнгән. Моңа балаларга ясле-бакчаларда да, мәктәпләрдә дә, балалар учреждениеләрендә дә дини тәрбия бирелсә генә ирешергә мөмкин. Моның өчен милли балалар бакчалары ачу һәм аларда мөселманлыкның әхлак һәм гигиена нигезләрен өйрәнү зарур. Татар мәктәбенең дөньявилыгын саклаган хәлдә, аларда балаларга ислам нигезләре турында мәгълүмат бирү формасы турында

уйлау да — кичектергесез бурыч. Ислам тарихы вә мәдәнияты, әлбәттә, татар мәктәбендә ныклап өйрәнелергә тиеш. Яшь буынга ислам, аның кагыйдәләре вә йолалары турында тиешле мәгълүмат бирү өчен мәчетләр һәм мәдрәсәләр каршында, мәдәни-агарту учреждениеләрендә якшәмбе яки җомга мәктәпләре оештырылу да, әлбәттә, максатка ярашлы булыр иде. Урыс мәктәпләрендә укучы татар балаларына исламның рухи-әхлакый асылын һәм гигиеник таләпләрен өйрәтү чаралары турында да уйланырга вакыттыр.

Болар һәркайсы милли асылыбызга кайтуда мөһим роль уйнаячак. Ислам гомер-гомергә милләтебезнең рухи таянычы булып килде һәм бу таянычны халыкка кайтару — милләтне саклап калуның хәлиткеч чарасы.

1992 ел.

МИЛЛӘТ. МӘДӘНИЯТ. ИСЛАМИЯТ.

Узган ел азагында Татарстан Фәннәр академиясендә экология проблемаларын тикшерүгә багышланган конференция булып узды. Конференция әйләнә-тирә мохитне саклау һәм баету мәсьәләсенә һәрьяклап фәнни анализ бирде, бу юнәлештә алда торган гамәли бурычларны билгеләде. Конференция кысаларында этноэкология мәсьәләләре дә каралды, бүген яшәп килә торган этносларны, шул хисаптан татар халкын киләчәктә дә саклап калу юллары турында фикер алышынды.

Бу мәкалә милләт, мәдәният, исламият арасындагы диалектиканы анализлауга, татар халкының киләчәген тәэмин итүдә милли мәдәният белән исламиятнең ролен билгеләүгә багышланган. Әмма күтәрелгән проблема турында сүз алып бара башлаганчы, башта милләтнең нәрсә икәнлеген ачыклап китү кулай булыр. Бездә, билгеле булганча, милләтне Сталин биргән төшенчә ярдәмендә аңлатылып киленде. Бу аңлатмада милләтнең субстраты бер якка куелды һәм ул капитализм тантанасы белән бәйләнгән һәм социаль-экономик үсеш нәтиҗәсендә барлыкка килгән тарихи күренеш дип бәяләнде. Хәзер Сталинның бу өйрәтмәсенә турыдан-туры мөрәҗәгать итмиләр. Әмма татар милләте турында сүз барганда, аның шаукымы сизелеп тора. Бу татар милләтенең барлыкка килүен капиталистик мөнәсәбәтләр барлыкка килүе һәм үсүе белән бәйләүгә омтылышта ачык чагыла.

Әмма милләт капиталистик мөнәсәбәтләр яралуы белән генә бәйләнгән тарихи күренеш түгел, аның тууы һәм яшәеше ерак үткәннән килә. Бу төшенчә белән без Тәүратта ук очрашабыз. Аның Сифри-Тәквин китабының Х фасылында, Нух пәйгамбәр улларының исемлеге китерелгәннән соң, түбәндәге мәгънәдәге бер җөмлә күзгә ташлана: «Төрле төбәкләрдә үзләренең телләре, ыруглары, милләтләре буенча урнашкан кавемнәр боларның оныкларыдыр».

Шулай да нәрсә соң ул милләт?

Хәзерге әдәбиятта милләтне ике төрле аңлау күзгә ташлана. Аларның беренчесе, милләтне сәяси бердәмлек, гражданлык бердәмлеге белән тәңгәлләштерү. Мондый карашны Русия Фәннәр академиясенең этнология институты директоры В.Тишков алга сөрә. Аның фикеренчә, хәзерге дөньяда милләтне мәдәни бердәмлек дип аңлау үзенең урынын сәяси күренеш, бердәм гражданлык күренеше дип аңлауга бирә. Әйтергә кирәк, бу В.Тишков тарафыннан милләтләрне юкка чыгару, аларны бердәм Русия казанында тәмам эретеп бетерү сәясәтен аклау өчен эшләнә. Аның фикеренчә, элеккеге СССР территориясендә дәүләт төзү ихтыяҗлары шуңа этәрә. Үзенең фикерен дәвам итеп, ул ачыктан-ачык болай дип яза: «Оснований признать существование общероссийской гражданской общности, тем более предпринимать усилия по ее укреплению более чем достаточны».[1] В.Тишковның бу тырышлыгы аның күптән түгел Русиядә милләте күрсәтелмәгән паспортлар бирүне яклап чыккан мәкаләсендә дә үзенең чагылышын тапты. В.Тишков һәм аның кебекләр өчен: Русиядә бары россияннар гына яши һәм башка нинди дә булса милләтләр турында сүз алып бару да урынсыз.

Бу мәсьәләнең тарафдарлары Татарстан җирлегендә дә очрый. Шуларның берсе В.Беляев. «Бу дөньяда, — дип яза ул, — инде XVIII гасырдан бирле милләт дип теге яки бу кавем (татарлар, руслар, басклар) түгел, ә бөтен халык (бердәм гражданлык) атала».[2] Беляев фикеренчә, Русиядә татар да, чуаш та, башкорт та юк, бары россияннар гына яши.

Милләтнең асылын, аның килеп чыгышын аңларга ярдәм итәрдәй икенче караш яшәвен дәвам итә. Бу — аны мәдәни (этнокультурный) бердәмлек дип аңлау. Мондый караш соңгы вакытта Америка галиме Майкл Линдның «Либераль милләтчелекне яклап» дигән мәкаләсендә үзенең чагылышын тапты.

Аның өчен милләт — ул мәдәни бердәмлек. Шуның өстенә «Мәдәни-лингвистик бердәмлек буларак, милләт бүген һәркайда сәяси бердәмлекнең нигезен тәшкил итә».[3]

Әйтергә кирәк, Франция, Италия, Германия, Польша, Швеция кебек, бер генә милләт яшәгән дәүләтләр өчен бу бәхәснең актуальлеге дә юктыр. Әмма Русия бер милләтле дәүләт түгел. Анда күп милләтләр, шуның өстенә тамырлары шушы җирдә булган милләтләр яши. Һәм алар өчен «без кем» мәсьәләсе актуаль булып кала. Һәм бу мәсьәләне милләтне мәдәни-кавеми (этнокультурный) бердәмлек дип караганда гына чишәргә мөмкин. Моның өчен ачкычны без С.Максудиның «Миллият тойгысының социологик әсаслары» дигән хезмәтендә табабыз. Милләт мәсьәләсен тикшергәндә китапның авторы алгы планга конкрет халыкны, кавемне (этносны) куя. Аның өчен милләт билгеле бер кавем, ягъни этник бердәмлек тәшкил итүче халык үсешенең югары баскычы. Бу очракта ул кавем — милләт төшенчәсе куллана. «Кавем-милләт исемен, — дип яза галим, — без ыруг, кабиләләрнең бер дәүләт эчендә берләшүе нәтиҗәсендә туган этник бердәмлек рәвешендә күз алдыбызга китерәбез».[4] Кавем һәм милләт тәгъбирләре арасындагы мөнәсәбәтне ачыклап С.Максуди милләтнең ниндидер бер кавемнең үсеп җитүен күрсәтүче фактор икәнлегенә басым ясап үтә. «Тарихи вә сәяси үсеш нәтиҗәсендә формалашуы тәмамланган һәр кавем, — дип яза ул, — милләттер».[5]

Ахырда автор «Кавем-милләт билгеле бер өлкәдә (территориядә) яшәгән, этнологик яктан бер тамырдан чыккан оймак вә кабиләләрнең иң куәтлесе җитәкчелегендә дәүләт булып берләшүе нәтиҗәсендә туган, бер телдә сөйләшүче, бер үк гореф-гадәтләр тотучы, бер үк дингә иманучы, үзенә хас милли характеры булган, бер-беренә теләктәшлектә торучы вә охшаш кешеләрнең зур төркемедер»[6] дигән нәтиҗәгә килә. Күренүенчә кавем-милләт төшенчәсе бер яктан милләтнең асылын, аның ни нәрсә икәнлеген, ә икенче яктан тамырларын, килеп чыгышын ачып сала.

Бу бәяләмәдән күренгәнчә, милләт — кавеми-мәдәни бердәмлек. Ул билгеле бер кабилә яки кабиләләр җирлегендә формалаша. Аңа тел, гореф-гадәтләр берлеге хас. Милләтнең асылын билгеләүче әһәмиятле факторларның тагын берсе — уртак дин. Һәр милләткә шулай ук уртак милли холык та хас. Әйтергә кирәк, С.Максуди бу бәяләмәне дөнья фәненең казанышларына таянган төпле анализ нигезендә бирә. Бу уңайдан китапның

миллəт һəм аның барлыкка килүен яктыртуга багышланган бүлегендə төрле иллəрдə торып иҗат иткəн 20 дəн артык галимнең хезмəтлəренə таянуын күрсəтү дə җитə.

Миллəтнең яшəешен болай аңлату аңа бары тарихи күренеш кенə дигəн аңлатмалар тырнагыннан арынырга мөмкинлек бирə. Кавем-миллəтлəр тарихның билгеле бер этабы белəн генə бəйлəнмəгəннəр. Алар инде бик борынгы дəверлəрдə үк яшилəр һəм аларның формалашуы беренчел дəүлəтлəргə үк туры килə. Дəүлəт исə, дип дəвам итə С.Максуди, ул — борынгы гореф-гадəтлəр урынына индивидлар мəҗбүри рəвештə буйсынырга тиешле хокукый тəртиплəр урнаштырылу дигəн сүз. Мондый тəртиплəр исə кабилəчелектəн чыгу дəверендə урнаша. Димəк, дəүлəтнең яшəве, шуның белəн бергə миллəтнең дə формалашуы бик борынгы, тарихка кадəрге дəверлəргə барып тоташа. Миллəтлəрнең формалашуы инде беренчел дəүлəтлəрдə үк күзəтелə. Китапта кельт, герман, славян, төрек ыруклары турында сүз кузгатыла. С.Максуди аларны бик борынгы дəүлəтлəр эчендə аерым миллəт тəшкил иткəн массаларның таркалган өлешлəре дип саный.

***

С.Максудиның əйтелгəн фикерлəре безнең миллəтнең үткəне, бүгенгесе һəм килəчəге турында фикер йөрткəндə гаять зур əһəмияткə ия. Безнең бабайлар ерак үткəн дəверлəрдə үк Идел буенда кавем-миллəт булып оешалар дип санарга тулы нигез бар. «Панорама-форум» журналының 1996 елгы беренче санында археолог И.Измайловның «Этнологические аспекты самосознания булгар X—XIII в.в.» дигəн мəкалəсе урнаштырылган. Мəкалəдə автор Идел-Кама болгарларында С.Максуди кавем-миллəт формалашуы өчен зарури дип санаган бөтен төсмерлəрне таба һəм тəфсилле анализ бирə. Бу төсмерлəрнең барысына да тукталмастан, мин аларның бары иң мөһимнəренə генə игътибарымны юнəлтəм.

Башта ук шуны əйтергə кирəк, X гасырда болгарларның дəүлəте — Идел-Кама Болгарстаны барлыкка килə һəм бу болгарлар һəм аларга кардəш кабилəлəрнең якынаюына һəм берлəшүенə сəяси, икътисади һəм хокукый нигез тудыра. Шушы җирлектə болгар кавем-миллəте формалаша һəм аларда болгарлык милли үзаңы барлыкка килə. Ш.Мəрҗани үзенең «Мөстəфадел-əхбар» исемле китабында гарəп тарихчысы Ш.Əд-Дмəшкигə

таянып, шундый дәлил китерә: Идел буеннан чыккан һәм хажга баручы сәйярлардан сез кемнәр дип сорагач, алар, без — болгарлар, дип җавап бирәләр. Алардан тагы, болгарлар кемнәр, дип тә сорыйлар. Моңа алар, төрек белән сәклаб арасында туган халык, дип җавап кайтаралар.[7] Бу болгарларда инде формалашкан милли үзаң булуы һәм аларның үзләренең этник чыгышлары турында да фикер йөртүләре турында сөйли.

Аралашу чарасы буларак, болгарларның үз теле була, ул — төрки тел. Шул ук Мәрҗани аларның телләре турында, гарәп галимнәреннән Истархинның, Ибн-Хаукалның һәм Гарнатиның болгар теленең төрки тел булуы турында әйтеп калдырган хәбәрләрен китерә. Алар «болгар теле — хәзәр теле кебек» дип язалар, ә хәзәр теле, әлбәттә, — төрки тел, дип өсти Ш.Мәрҗани.[8] Урыс тарихчысы В.Н.Татищев язуына караганда, Владимир кнәзе Всеволодка кыпчаклар белән союзга кереп болгарларга каршы яу чабарга тәкъдим иткәч, ул, болгарларга яу чапканда кыпчакларга таянырга ярамый, чөнки аларның телләре — бер, дип җавап бирә.[9] Ә кыпчак теле, билгеле булганча, — төрки тел.

Болгарларның үз милли мәдәниятлары, гореф-гадәтләре һәм милли холыклары формалаша. Ә мәдәният, милли гореф-гадәтләр, милли холык, С.Максуди фикеренчә, — милләтне характерлаучы мөһим факторлар.

Һәм, ниһаять, болгарлар мөселман милләте буларак формалашалар. Исламият баштан ук болгарның милләт булып оешуы нигезендә ятты. Ул аларның кавем-милләт булып формалашуының рухи фундаментын тәшкил итте. Ислам, идея һәм оешу ягыннан җитлеккән дин буларак, таркау кабиләләрне бер Аллаһ идеясе тирәсенә туплады, берләштерде, аларның милләт буларак оешу процессына көчле идеологик йогынты ясады. Ислам нигезендә болгарларда яңа әхлак кануннары тамыр җәя, алар тормышына исламга хас изгелек, гаделлек, мәрхәмәт, шәфәгать, кешелеклелек, тигезлек, туганлык принциплары үтеп керә. Болар җәмгысы милләтне бердәм итеп туплауда мөһим роль уйный.

Ислам болгарларның милли мәдәниятлары формалашуының нигезендә дә ятты. Исламны кабул итү болгарларның гарәп язуын кабул итүенә китерде. Ә гарәп язуы аша болгарлар ул вакытта югары үсеш алган гарәп-мөселман мәдәнияты белән таныша алдылар. Шул нигездә аларда әдәб әдәбияты туа, фәлсәфи-дини фикерләүләр җәелә. Ислам мәдәнияты — шәһәр

мәдәнияты. Ислам мәдәниятының бу хасияте болгар җирлегендә дә үзенең чагылышын таба. Бу уңайдан Идел Болгарстаны территориясендә археологлар тарафыннан 150дән артык шәһәрчек табылуын күрсәтеп үтү дә җитә.[10] Шәһәрләр үсеше белән житештерү көчләренең үсүе, һөнәрчелек һәм сәүдә мөнәсәбәтләренең үсүе дә бәйләнгән. Ислам таралу белән параллель рәвештә болгарлар арасында сәнгатьнең үзенчәлекле төрләре дә туа, архитектура һәйкәлләре калкып чыга. Мәдәниятның мөһим тармагы — мәгариф, мәгърифәт тарату. Ислам канаты астында болгарларда мәдәниятның бу тармагы да үсеш ала, белем учагы буларак, мәктәп-мәдрәсәләр барлыкка килә.

Ислам кабул иткәч, болгарларның тәүге мәдәнияты да яңа, ислам мәдәниятының состав өлешенә әверелә. Бу мәдәният алып ташланмый, юкка чыгарылмый. Аның күп кенә элементлары изгеләштереләләр, мөселманлык төсмерләре белән баетылалар. Болгар мәдәнияты шулай итеп ислам мәдәнияты буларак формалаша һәм үсә. Бу мәдәният болгар кавем-милләтенең йөзен билгели, аның яшәешенең рухи нигезен тәшкил итә.

Унөченче йөздә Аурупаның көнчыгыш һәм Азиянең көнбатыш өлешендә яңа зур дәүләт — Алтын Урда барлыкка килә. Идел Болгарстаны аның состав өлешенә әйләнә. Алтын Урда зур һәм көчле дәүләт була. Аның составында җитештерү яңа үсеш ала. Мәдәният үсә. Әмма анда барган кавеми (этник) процесслар әле тиешенчә өйрәнелмәгән. Бу процессны ачыклау төпле эзләнүләр, яңа фикерләүләр көтә. Хәзергә бары шуны гына фаразлау мөмкин — бу дәүләтнең халкы, мөгаен, бердәм кавем-милләт булып оешып җитә алмаган. Чөнки беренче тетрәнүләр белән үк андагы халык нигезендә яңа этник төркемнәр укмаша башлый — үзбәкләр, казакълар, башкортлар, нугайлар һ.б.

Бу процесс Алтын Урданың состав өлеше — элеккеге Болгар җирендә дә бара. Аңа, болгарлар белән бергә, Идел буенда яшәүче башка төрки кабиләләр дә, фин-угыр халыкларының бабалары да катнаша. Милләт мәсьәләсе кан берлеге мәсьәләсе генә түгел, ул, беренче чиратта, — мәдәният берлеге мәсьәләсе. Һәм әйтелгән процесс инде формалашуы тәмамланган болгар мәдәнияты нигезендә бара. Ә бу мәдәният — ислам мәдәнияты. Алтын Урда халкы исә башта мәҗүсиләр булалар. Этник процесс Идел буенда яшәгән халыкның исламга күчүе, болгар-ислам мәдәнияты кысаларында туплануы белән янәшә бара. Һәм җирле халык үзен татарлыктан әле бер якка

куя. Казан ханлыгы чорында да үзен болгарлык яки казанлык дип атый. Алай гына да түгел, татар аның өчен — чит, ят халык. Билгеле булганча, һәркемнең үзен аңлавы «мин» белән «ул»ны бер-беренә каршы куюдан башлана. Шуңа хас рәвештә теге яки бу кавем кешеләренең аңында да төрле кавемнәргә карата «без» һәм «алар» дип карау күзәтелә. Шуның өстенә, «без» уңай сыйфатлар белән характерланса, «алар»га контраст рәвешендә кире сыйфатлар тагыла. Моны без Казан халкында да күрәбез. Моның ачык мисалы — Мөхәммәдъяр иҗаты. Шагыйрь Казан халкын турыдан-туры татарга каршы куя, соңгысы — кире сыйфатлар белән характерлы.

Аллаһ — мәзһәбен белмәүче татар син,
Бу дөньяда һәм эттән дә начар син.
Өстәп Хошнун: «И, шөкәтсез, ди, татар,
Асрама эт баласын — асылына тартар...»[11]

Шул ук вакытта халкыбыз арасына татар атамасы да үтеп керә башлый — әмма миллидән бигрәк, социаль атама буларак. Алтын Урдадагы ызгышлар аркасында аннан качып китеп Мәскәү хезмәтенә күчкән аксөякләр йомышлы татар (служилый татарин) исемен алалар. Тора-бара алар тулы бер социаль катлам тәшкил итәләр һәм аларга Казаннан качып китүчеләр дә өстәлә.

Мәскәү хөкүмәте Казанны яулап алганнан соң, милли яшәеш өчен түзә алмаслык шартлар тудырыла. Патша хөкүмәте җирле халыкка карата ачыктан-ачык шовинистик сәясәт үткәрә. Ул халыкны диненнән яздыру, милли тамырларыннан ваз кичтерү, ахыр чиктә христианлаштыру һәм урыслаштыру өчен эзәрлекләүләр башлана. Халкыбыз иктисади басымны да, сәяси басымны да, казак камчысын да, төрмә-сөргеннәрен дә татый. Аның милли хисләре мәсхәрәләнә, гыйбадәтханәләре яндырыла, кабер ташлары чиркәү-монастырьларның нигезенә түшәлә.

Шушы социаль-икътисади изүләргә, сәяси-хокукый эзәрлекләүләргә, милли мәсхәрәләүләргә карамастан, халкыбыз христианлаштыру сәясәтенә бирешми, үзенең милли үзенчәлекләрен һәм, хәленнән килгәнчә, мәдәниятын да саклый. Бу очракта хәлиткеч рольне исламият уйный. Көчләп чукындыру шартларында халкыбызның уллары һәм кызлары исламда рухи таяныч табалар. Шуның өстенә, Казанны алгач, милли зыялыларыбызның яшәү мөмкинлеге дә калмый, милли тормышның дөньяви-

лык җәһәте юкка чыгарыла. Бердәнбер таяныч булып ислам кала. Мөселманлык милләтнең бердәнбер күрсәткеченә әверелә, милләт мөселманлык белән тәңгәлләштерелә башлый.

Шулай да, болгарлык идеясе халыкның, бигрәк тә аның зыялы катламнарының, аңыннан тәмам юылмый. Танылган библиограф Зәйнәп Максудова «Болгари» ләкабы белән язган әдип, шагыйрь, галим, фәйләсуф һәм дин белгечләренең картотекасын төзеп калдырган. Хәзер бу картотека Дәүләт музеенда саклана. Анда болгар чорыннан алып, XX гасыр башына кадәр «Болгари» ләкабе белән язган меңнән артык шәхес теркәлгән. Әле XVIII йөздә дә җирле халыкның милләтен болгарлык белән тәңгәлләштерүе турында Америка галиме А.Франк та яза.[12]

Һәм, ниһаять, Ш.Мәрҗани фикерләре. Бу олуг галимебез зыялыларыбыз арасыннан, татар исеменнән качарга кирәкми, дип аваз салган беренче зат. Шул ук вакытта ул татарны болгардан да аермый. Хәзерге татарлар, аның фикеренчә, — борынгы болгарларның дәвамы. Бу халык, дип яза ул, «иң әүвәл кыпчак һәм хәзәр хаканнары хөкүмәте, соңыннан Болгар әмирләре хөкүмәте, аннан соң Татар ханнары хөкүмәте карамагында булып, хәзерге вакытта өч йөз елдан артык инде Русия хөкүмәте идарәсендә яши.[13]

Димәк, дәүләте җимерелеп, кавем-милләт булып оешуның күп кенә факторлары юкка чыккач та, хәтта исеме алышынса да, халкыбыз кавем-милләт булып яшәвен дәвам итә, милли мәдәниятын, гореф-гадәтләрен саклый. Бу ни белән аңлатыла соң? Бу сорауга җавапны Садри Максудиның инде телгә алынган хезмәтендә табабыз. «Формулашуы тәмамланган милләтнең, — дип яза ул, — миллияте өзлексез һәм ул киләчәктә дә милләт буларак сакяана ала».[14] Моңа мисал итеп ул яһүд милләтен китерә. Аның гасырлар буе милли туфрагы да, дәүләте дә булмады. Ул бөтен дөньяга таралган хәлдә, төрле дәүләтләрдә, төрле икътисади җирлектә булса да бер милләт буларак яшәде. Шул ук вакытта яһүдләр милләт буларак формалашкан чорда, Даут һәм Сөләйман исемле хөкемдарлар заманында аларның милли туфраклары да, дәүләтләре дә бар иде. Яһүдләр дөньяның төрле почмакларына инде милләт булып формалашканнан соң таралдылар. Көчле милли рух, милли дин аларны берләштереп торды. Безнең дә кавем-милләт булып саклана алуыбызда милли рухыбыз, миллият тойгысы, исламият хәлиткеч роль уйнады.

***

Октябрь инкыйлабыннан соң илдә урнашкан тоталитар иҗтимагый тәртипләр милләтебезнең яшәешен яңа сынаулар алдына куйды. Шушы тәртипләр һәм коммунистик идеологиянең басымы милли аңның йомшаруына китерде, милли яшәешнең тамырларына балта чабылды, милли битарафлык орлыклары чәчелде. Бу шартларда милләт язмышы мәсьәләсе, милләтебезнең сафларын ныгыту мәсьәләсе алдыбызга бөтен кискенлеге белән килеп басты. Бу уңайдан, беренче чиратта, алгы планга **миллият тойгысы** мәсьәләсе калкып чыга. Бу мәсьәләгә без әлегә игътибар биреп бетермибез, сөйләсәк, милли үзаң турында сөйлибез. Әмма миллият тойгысы милли үзаңнан тирәнрәк ята, бәндәләрнең эчке кичерешләреннән кайнап чыга һәм милли үзаңның формалашуында да мөһим роль уйный.

Миллият тойгысының ни нәрсә икәнлеген, аның чыганакларын аңлауда да без С.Максуди фикерләренә таяна алабыз. Милләтнең яшәешендә, көрәш мәйданында үзен саклап калуында, үзенең бөтенлеген тәэмин итүендә, дип хисаплый ул, миллият тойгысының хәлиткеч роле — бәхәссез. «Милләтләрнең милләт буларак яшәешен тәэмин итүче, башка милләтләр арасында эреп юкка чыгудан саклаучы, — дип ассызыклый галим, — нәкъ менә шушы куәтле тойгыдыр».[15] Бу тойгының чыганагы, аның фикеренчә, кабилә вә кавемнәрнең ерак үткәненә барып тоташа һәм ул аларны тәшкил иткән индивидлар арасында кеше рухына хас булган иҗтимагый омтылыш басымы астында барлыкка килә. Кеше тумышыннан ук үзе бәйләнгән төркем, кабилә, кавем яки милләт рухына багланган була. Чөнки аның хәяттагы урыны әйтелгән инсани төркемнең хәятына бәйләнгән. Бу төркем эчендә урнашкан теләктәшлек һәм бердәмлек атмосферасы аның иҗтимагый омтылыш вә һәвәслекләре ачылуга мөмкинлек, каршылыклы мәхәббәт, бербереңә ышаныч вә тынычлыкны саклый алырдай бер мохит тудыра. Шушы нигездә миллият тойгысы барлыкка килә дә. «Шулай итеп, дип яза С.Максуди, — миллият тойгысының чыганагы вә үзәге беренчел җәмгыятьләрдә дә, мәдәни җәмгыятьләрдә дә, аерым очракларда хәтта хайваннар дөньясында да күзәтелгән шушы гомуми социологик күренештер, ягъни индивидларның үзләренә хас тойгылары нәтиҗәсендә туган бербереңә бәйлелек хиседер».[16]

Бу тойгының эчтәлеген ачып, автор алга таба «Миллият тойгысы индивидларның үз милләтләренең үткәненә, киләчәгенә, теленә, мәдәниятына, өлкә вә туфрагына карата туган карашларының тирәнәюе, нәселдән күчүе белән бәйләнгән рухи бер халәттер.»[17] дип күрсәтеп үтә. Шуның өстенә, бу рухи халәт милләтне тәшкил итүче бөтен индивидларны колачлаганлыктан, шәхси булудан бигрәк, коллектив бер тойгы рәвешендә яши.

Индивидларда милләткә бәйлелек хисенең, миллият тойгысының тууы, көчәюе, тирәнәюе вә бөтен милләт эчендә таралуы, дип хисаплый С.Максуди, милләтнең формалашып мәйданга килүенең психологик нәтиҗәләреннән берсе. Бу тойгы нәселчәнлек кануннары нигезендә милләт эчендә туктаусыз куәтләнә бара. Һәм милләтнең милләт буларак яшәешен тәэмин итүдә, аны башка милләтләр арасында эреп юкка чыгудан саклауда хәлиткеч роль уйный. Нindидер сәбәпләр аркасында шәхесләрне милләт итеп берләштерә торган бу җепнең өзелүе милләтнең барлык мәйданыннан юклык мәйданына күчүенә китерә.

Миллият тойгысы беренче чиратта теге яки бу милләткә караган кешеләрнең үзләренең милли тарихларына, милләтнең үткәндәге уңышларына яки бәхетсезлекләренә мөкатдәс бер нәрсә итеп караулары рәвешендә күзгә ташлана. Милләтләрнең үз үткәннәренә бәгланганлыклары аларның үз милли мәдәниятларына, телләренә, диннәренә, милли аңнарына, милләтнең олы затларына вә каһарманнарына хөрмәт рәвешендә күренә.

Миллият тойгысы фәкать милләтнең үткәндәге язмышына бәйле рәвештә генә күзәтелми. Ул индивидларның милләтнең киләчәген күз алдында тотып кылган гамәлләрендә һәм фикерләрендә дә үзенең чагылышын таба. Миллият тойгысының болай киләчәккә булган юнәлеше сәяси яктан мөстәкыйль булган милләтләрдә киләчәктә дә мөстәкыйль булып яшәү теләгендә, ә бәйсезлекләрен югалткан милләтләрдә исә бәйсезлекне яңадан торгызуга булган эш-гамәлләрендә үзенең чагылышын таба. Бу ике халәттә булган милләт тә, дип саный С.Максуди, үз ватанында, үз телендә сөйләшеп, үз гореф-гадәтләренә таянып яшәүгә, мәдәният вә цивилизация җәһәтеннән алга бару теләге вә карашын даими үстерү өметендә булырлар. Миллият тойгысының ачылуы, үсүе вә камиллеккә ирешүе шушы киләчәккә омтылган теләк вә максат аркасындадыр.

Димәк, безнең дә киләчәктә дә милләт булып яши һәм үсә алуыбыз бездәге миллият тойгысының камилләшә, үткенләнә һәм үсә баруы белән турыдан-туры бәйләнгән. Без бары үткәнебездән сабак алып милләтебезнең ихтыяжларын тоеп, аның киләчәген кайгыртып һәм бөтен сәләтебезне шушы киләчәк өчен җиксәк кенә милләтебезнең башка халыклар белән бер сафта алга баруына ирешә алачакбыз.

Кызганычка каршы, совет-коммунистик идеология хакимлек итүе шартларында бу тойгы бездә бик нык йомшарды һәм милләт алдында аны торгызу, җанландыру бурычы калкып чыкты. Бу уңайдан икенче мәсьәлә дә бөтен актуальлеге белән алга килеп баса, ул — **милли мохит** мәсьәләсе. Саф һәм көчле миллият тойгысы формалашсын өчен татар баласы саф татар милли мохитендә тәрбияләнергә тиеш. Чөнки аның эчке дөньясы, уй-фикерләре, омтылыш-хыяллары, яшәү һәм хәрәкәт рәвеше билгеле бер социаль тирәлек кысаларында формалаша. Ә шәхеснең тойгылары чын мәгънәсендә милли булсын өчен бу тирәлек тә милли булырга тиеш. Хәзерге безнең яшәгән мохитебез исә миллилектән ерак тора. Мохит үз эченә адәм баласы яши, үсә торган җирләрне, ул формалаша торган ясле-бакчаларны, ул укый, белем ала һәм шәхес булып формалашу процессын үтә торган уку йортларын (башлангыч, урта һәм югары мәктәпләрне), хәзерге дөньяда кеше даими рәвештә тәэсирен тоеп яши торган информация кырын, газета-журналларны, радио-телевидение тапшыруларын, җәмгыяви бәйләнешләр сферасын һәм, ниһаять, кешенең җитештерү өлкәсендә катнашу сферасы — оешмалар, предприятиеләр, транспорт һ.б. ала. Октябрь инкыйлабына кадәр мохитның бу состав өлешләре миллилеген саклый алган иде. Ә Октябрьдән соң үткәрелгән интернациональләштерү сәясәте нәтиҗәсендә бу мохитнең барлык өлешләрендә дә миллилек я тәмам юкка чыкты, я бик йомшарды, саекты. Шуңа күрә милләтне торгызу өчен, миллият тойгысын аякка бастыру өчен милли мохитне торгызырга кирәк. Барысын да — гаиләдән башлап, милли университеткача, завод-фабрикаларгача.

Миллият тойгысын торгызу һәм ныгыту интереслары бездән татар халкын этник төркемнәргә, Казан, Себер, Әстерхан татарларына, мишәрләргә, типтәрләргә бүлгәләү белән мавыкмауны да таләп итә. Бу мәсьәләдә безгә урыслардан үрнәк алганда ярар иде. Алар составына төркиләр дә, угыр-фин халыклары да

яхшы ук өлеш керткән. Славяннар үзләре дә төрле кабиләләргә бүленгән була. Бу халыкның исемен дә норманнардан чыккан руслар бирә. Әмма этнологлар урысны этнографик яктан бүлгәләп тормыйлар, бердәм урыс милләте дип тикшерәләр. Һәм дөрес эшлиләр. Чөнки нинди генә этник төркемнәр кушылса да, урысның этник тарихы бер нигездә — урыс-славян мәдәни нигезендә барды. Безгә дә халкыбызның этник тарихын бер нигезгә салып, бер мәдәни-кавеми нигездә, бер кавем-милләт буларак өйрәнергә кирәк.

Аннары болгарлык яки татарлык дигән ике багана арасында адашып йөрүебездән дә арынырга вакыт. Бу тирәдә барган бәхәсләр миллият тойгысының ныгуына да, милли үзаң үсүенә дә ярдәм итми, киресенчә, милләттәшләребезнең зиһеннәрен чуалта. Безнең мәдәни-кавеми чишмә башыбыз, әлбәттә, болгардан башлана, ә Алтын Урда чорында шушы нигездә катлаулы этник һәм мәдәни үсеш кичерә. Ахырда аңа татар исеме тагыла. Тарих агымы барышы шуңа китерә. Хәзер бу турыда бәхәс куерту файдасыз, ул бары милли бердәмлекне генә йомшарта, милләтне таркатуга китерә. Шуңа күрә Ш.Мәрҗани тарих белән бәхәсләшмәскә, безгә тарихи үсеш процессында тагылган этноним белән килешергә чакырып чыга. Шуның өстенә ул, инде әйтелгәнчә, этник тамырларыбызның болгардан килгәнлеген дә яхшы аңлый. Безгә дә шушы Мәрҗани әйткән эздән бару хәерлерәк булыр. Шул ук вакытта — этник тамырларыбызның кайда икәнлеген аңлаган хәлдә, тарихи процессны да яхшы күз алдына китереп.

Һәм, ниһаять, **исламият мәсьәләсе.** Инде әйтеп үтелгәнчә, элгәрләребез кавем-милләт булып оешканда ислам аның рухи-идеологик нигезен тәшкил итте. Соңыннан да, шул хисаптан Алтын Урда дәверендә дә, этник процесс исламның рухи тәэсире астында барды. Коточкыч милли изү шартларында да, көчләп чукындыруларга да карамастан, халкыбыз исламга таянып үзен милли бердәмлек буларак саклап кала алды. Хәзерге шартларда да, милләтне сакларга теләсәк, исламны рухи тормышыбызның нигезенә салырга тиешбез. Коммунистик идеологиянең хакимлеге шартларында халкыбыз арасында, билгеле булганча, исламның позицияләре бик нык йомшарды. 70 елга сузылган атеистик пропаганда һәм дини эзәрлекләүләр үзләренең кара эшләрен башкардылар. Халкыбызның байтак өлеше хәзер дингә яки битарафлык саклый, яки бөтенләй кире

мөнәсәбәттә тора. Бу шулай дәвам иткән тәкъдирдә безнең киләчәктә дә милләт булып кала алуыбызга гаять зур куркыныч яный. Идеологик бушлык озак саклана алмый. Һәм хәзер менә шушы бушлыкка башка дини идеяләр, беренче чиратта баһаитлар, кришнаитлар һәм христиан чиркәвенең төрле секталары ыргылалар һәм милләтебезнең ориентирларын югалткан өлешен бик җиңел үз кармакларына эләктерәләр. Бу шулай дәвам итсә, милләтнең тәмам таркалуына китерәчәк.

Дөрес, соңгы елларда исламның позициясе халкыбыз арасында күпмедер киңәйде, күбәүләр аңа йөз белән борылдылар. Әмма динилек милләттәшләребез арасында әлегә дини хис рәвешендә генә күзәтелә һәм динне аңлау идеология дәрәҗәсенә күтәрелмәгән. Динне идеологик күренеш дип аңлау һәм аңлата алу дәрәҗәсенә әле руханиларыбыз үзләре дә хәзерлекле түгелләр. Имамлык вазыйфасын башкаручы бик күбәүләр динне аңлауда мәхәллә халкыннан әлләни аерылып тормыйлар. Руханилар арасында хәзер Р.Фәхретдинов, Г.Баруди, М.Бигиев, Р.Ибраһимов, Ә.-Һ.Максуди, З.Камали, К.Тәрҗемани, Х-Г.Габәши, З.Кадыйри, Ж.Абызгильдин кебек асыл затларыбыз юк. Андый затлар репрессия корбаннары булдылар, яисә эмиграциягә китеп, чит-ят җирдә дөнья куйдылар. Шулай итеп, илаһи тәгълиматны аңлау һәм аңлату белән бәйләнгән күп гасырлык традицияләр өзелде. Шуңа күрә хәзер динне идеология дәрәҗәсендә аңлый һәм аңлата алырдай руханилар тәрбияләү изге бурычлардандыр. Бу һичшиксез дини оешмаларның игътибары үзәгендә торырга тиеш. Зыялыларыбыз да бу мәсьәләдә дин әһелләренә ярдәм кулы сузарга тиешләр.

Бу очракта исламның коры дин генә булмавын да күз алдында тотып эш итәргә кирәк. Ислам — дөньякүләм тәэсире булган диннәрнең берсе. Әмма ул бер үк вакытта фәлсәфи һәм идеологик система да, мәдәният та, әхлакый кануннар һәм хокук нормалары системасы да. Исламны шулай итеп өйрәнү аның халкыбыз аңына тәэсир итү көчен һәм тормыштагы ролен арттырачак. Шуңа күрә исламның идеологик һәм фәлсәфи асылын, аның мәдәният тарихындагы, җәмгыятьнең рухи һәм әхлакый үсешендәге ролен тирән аңлауның милли аңны үзләштерүдә әһәмияте ифрат зур булачак.

Безнең ирекле милли үсешебез, милләтне, аның рухи бердәмлеген саклап кала алуыбыз **Русиядәге хәлгә дә** бәйләнгән. Андагы үсеш нинди юл белән барыр, чын мәгънәсендәге

демократиягә табамы, әллә империячел тәртипләрнең ныгуынамы? Күп милләтле дәүләтләрдә милләтләрнең яши һәм үсә алуы бары барлык милләтләрнең тигезлеге, аларның телләренең ирекле яшәве, мәдәниятлары үсешенә, гореф-гадәтләренең яшәешенә киртәләр салынмавы шартларында гына мөмкин. Ә мондый мөмкинлекләр бары демократия тантанасы шартларында гына туа.

Ә бүгенге Русия чын демократиядән ерак тора. Аның чәчәк атуына империячел көчләр, «бердәм һәм бүленмәс Русия» лозунгы астында шовинизмның тамыр җәюе, бөек державачылык идеяләренең киң таралуы комачаулый. Ә империячел тәртипләр сакланган тәкъдирдә һичнинди демократия дә, милләтләрнең ирекле үсеше дә, шул хисаптан, хаким милләтнең үзенең ирекле үсеше дә мөмкин түгел. Башка бер халыкны изеп торучы милләт үзе дә ирекле була алмый. Чөнки ул башка милләтләрне буйсындырып тору өчен үз иркен дә кысарга һәм үзенең язмышын нинди дә булса тиран яки авторитар хакимият карамагына тапшырырга мәҗбүр була.

Күп милләтле илләрдә демократик ирекләрнең саклануы бары **федератив тәртипләр** урнаштырылганда гына мөмкин. Садри Максуди инде телгә алынган хезмәтендә федерация демократия нигезендә чәчәк атсын өчен аның түбәндәге принципларга таянып оешуын шарт дип саный:

1. Федерациянең аны тәшкил иткән **субъектларның үз ирекләре белән оешуы.** Федерация нindидер үзәк ихтыяҗы белән оештырылса, бернинди дә ирекле, демократик федерация була алмый.

2. Федерациянең **демократик хокукый дәүләт принциплары нигезендә оештырылуы,** федерациягә керүче халыкларның демократик хокуклары саклануы.

3. Федерациягә берләшкән **милли дәүләтләр хокукларының, аларның демократик ирегенең кагылгысызлыгы.** Федераль үзәк милләтләр өстеннән хакимлек итәргә дәгъва итә алмый, ул бары федерация субъектлары исеменнән эш йөртүче дәүләт структурасы.

4. **Федерациянең асимметрик нигездә оешуы.** Федерациягә кергән һәр субъект федерациягә керү шартларын үзе билгели. Шуңа күрә аларның федерациягә тапшырган вәкаләтләре төрлечә булуы мөмкин. Бу вәкаләтләрнең күләме субъек-

тларның икътисади потенциаленнән, сәяси һәм мәдәни үсеше дәрәҗәсеннән һәм үз яшәешен тәэмин итә алуы белән бәйләнгән башка факторлардан чыгып билгеләнә.

5. **Федератив дәүләтнең вәкаләтләре аңа кергән милли дәүләтләр биргән вәкаләтләр нигезендә формалаша** һәм шул кысалардан чыкмый.

6. Федерациягә берләшкән милли дәүләтләрдә яшәгән **милли азчылыкларның һәм этник төркемнәрнең ирек һәм хокукларын гарантияләү.**

Бу принциплар С.Максуди тарафыннан 1955 елда бәян ителәләр. Соңрак, үзенең «Аурупа-Азия совет республикаларының Конституциясе проекты» дигән хезмәтендә А.Д.Сахаров та шундый ук нәтиҗәләргә килә һәм федерациягә берләшүче милләт һәм республикаларның үзбилгеләнү хокукына басым ясый.

Әмма Россия, федератив дәүләт дип игълан ителсә дә, бу принципларга нигезләнгән демократик федерациядән ерак тора. Ул ирекле милләтләрне һәм чын мәгънәсендә суверен республикаларны берләштергән федерация түгел. Аны милләтләр үз ирекләре белән оештырмадылар; алар Русия дәүләте составына көчләү юлы белән, басып алу юлы белән кертелделәр һәм шул көч ярдәмендә Русиягә бәйләп тотылалар да. Русия Конституциясе милләтләрнең үзбилгеләнү хокукын игълан итә, ләкин аны Русия рамкалары белән чикли. Әгәр дә ул ирекле рәвештә оешкан булса, бу хокукка һичнинди чикләүләр булырга тиеш түгел иде. Шуңа күрә Русиядә чын мәгънәсендә федерация булмады һәм юк. Русия Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы Сергей Алексеев хаклы рәвештә әйтеп үткәнчә, самодержавие вакытында да, советлар хакимиятендә дә Русия дәүләтчелеге «был властью державной, имперской, основанной на произволе и насилии».[18] Хәзер дә ул шулай булып кала.

Чын мәгънәсендәге федерация тантанасы өчен Русиядә кәгазь битенә генә теркәлгән демократия түгел, ә гамәли демократиянең тантанасы кирәк. Бары шунда гына милләтләрнең демократик тигезлеге, аларның ирекле үсеше мөмкинлеге тантана итәчәк.

[1] Тишков В. О нации и национализме. // Панорама-форум, 1996. №1. — С.9—10.

[2] «Советская Татария», 1992, 28 май.

[3] Линд Майкл. В защиту либерального национализма. // Панорама-форум. 1996, №1. — С.10

[4] Maksudi S. Milliyet duygusunun Sosyoiojik əsaslari. Istanbul, 1975 — S.66—67.

[5] Шунда ук, 66 б.

[6] Шунда ук, 67—68 б.б.

[7] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан, 1889, — 54 б.

[8] Шунда ук, 55, 62 бб.

[9] Кара: Татищев В.Н. История Российская, т.III. М.-Л., 1964. — С.128.

[10] Фахрутдинов Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. Казань, 1976. — С.190—191.

[11] Мөхәммәдъяр. Нуры содур. Казан, 1997. — 119 б.

[12] Панорама-форум, 1997, №1. — С.113.

[13] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар. Казан. 1889. 53 б.

[14] Maksudi S. Milliyet duygusunun... — S.77.

[15] Maksudi S. Milliyet duygusunun... — S.79.

[16] Шунда ук, 71 б.

[17] Шунда ук, 71 б.

[18] Известия, 1993, 9 июля.

МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ

Халкыбызның милли бәйрәмнәре күп төрле. Аларның берише динебез ислам белән бәйләнгән һәм тормышыбызга исламны кабул иткәч кереп киткән. Халкыбыз бу бәйрәмнәрне борын-борыннан бик олылап үткәреп килә. Аларның иң мәшһүрләре — ураза гаете һәм корбан гаеты. Болардан тыш, халкыбызның яшәеше, тормыш-көнкүреше һәм милли традицияләре нигезендә туган бәйрәмнәребез дә бар. Мондый бәйрәмнәребезнең күбесе инде онытылып та бара. Безнең көннәребездә бу бәйрәмнәрнең иң мөһиме — сабан туе. Ул елдан-ел бик олылап үткәрелеп килә. Соңгы елларда инде онытылып бетә язган нәүрүз бәйрәме дә яңадан уздырыла башлады. Ул — яз башы бәйрәме. Шуңадыр нәүрүз традицияләрен яңартучылар да яшьләр булдылар. Кыш уртасында, көннәр озыная башлагач, безнең халыкта тагы нардуган бәйрәме үткәрелә торган була. Керәшен кардәшләребездә ул хәзергәчә сакланып калган. Болгар чорларында бу бәйрәм бөтен халкыбыз өчен уртак була. Соңгы елларда җәйге кыр эшләрен тәмамлап еллык йомгак ясауны да бәйрәм төсендә үткәрү традициягә кереп бара. Һәм, ниһаять, безнең бабаларыбызның борын-борыннан алып шушы гасырның 20 елларында кадәр үткәрелеп килгән бәйрәмнәрнең тагы берсе — җыен.

Мин бу язмамда сүзне телгә алынган бәйрәмнәрнең милли яшәешебез һәм традицияләребез белән аерылгысыз рәвештә бәйләнгән, халкыбыз чал тарихтан бирле бик зурлап үткәреп килгән икесе — җыен һәм сабан туе турында алып барырга телим.

Хәзерге иң популяр милли бәйрәмебез — сабан туе. Ул бик борынгы заманнардан бирле үткәрелеп килә. Илебезнең аксакалы, күренекле рәссам һәм әдип Бакый ага Урманче «Сабантуй йолалары» («Социалистик Татарстан», 1989, 2 июнь») дигән мәкаләсендә аны VIII—IX гасырларда ук үткәрелә башлаган дип саный. Әмма халкыбызның тарихы тагын да борынгырак заманнарда, әле күчмә терлекчелек белән көн күргән дәверләрдә үк туган бәйрәмне дә белә. Ул — җыен. Аның формалашуы кабиләчелек тормышының җитлеккән чорына туры килә, дип фараз кыла алабыз. Бу чорда инде кабиләләр үрчиләр, зураялар, алардан яңа кабиләләр дә бүленеп чыга һәм алар таралып яши башлыйлар. Шулай да, бу кабиләләр арасында туганлык җепләре өзелеп бетми. Төрле тарафларга таралган тугандаш ыругларда ара-тирә җыелып уртак мәсьәләләрне бергәләп хәл итү ихтыяҗы туа. Менә шул бик борынгы заманнарда төркиләр тормышында җыеннар үткәрү традициясе туа да.

Герман кабиләләреннән булган франкларда кабиләчелек мөнәсәбәтләре җитлеккән чорда Марс кырларына елына бер мәртәбә бергә тупланып сөйләшү, уртак ихтыяҗлар турында фикер алышу һәм бергә җыелгач бәйрәм итеп алу традициясе була. Бу җыйналыш үткәрелү урынына бәйле рәвештә Марс кырлары дип атала. Бу көннәрдә франк кабиләләре шушы кырларга туплангач яшәешнең җитлеккән мәсьәләләрен уртага салып сөйләшәләр, фикер алышалар, киләчәккә планнар билгеләләр. Марс кырлары мондый көннәрдә шаулап-гөрләп тора, төрле бәйгеләр оештырыла: атларда узышу, куышу, көрәш һ.б. Яшьләр өчен төрле уеннар, бу уеннар вакытында алар берберсе белән танышалар, аралашалар. Бу көннәрдә кабиләдәшләр бер-берсенә кунакка йөрешәләр, туйларын да уздыралар.

Төрки халыкларда да җыен бик борынгы заманнардан уздырылып килә һәм франкларда Марс кырлары үтәгән функцияләрне үти. Ул заманнарда күчмә терлекчелек белән яшәгән төркиләр бу бәйрәмгә җәйнең күркәм бер вакытында, яшь елкы-куйлар

өлгергәч, кымызның да мул чагында җыйналалар. Бу кардәш-ыруг белән очрашу, кунакка йөрешү һәм сыйлашу өчен иң кулай вакыт. Кардәш кабиләләр һәм ыруглар җыйналган мәйданда казаннар асыла. Бер-берсенә кунакка йөрешү, сыйлашу китә. Һәр җәйне үткәрелә торган бу җыеннарда кабиләдәшләрнең уртак проблемалары турында фикер алышу, аларны тикшерү дә игътибар үзәгендә була. Җыен көннәрендә кабиләләр тормышына кагылышлы карарлар да кабул ителә, киләчәккә планнар да корыла. Кыз алып, кыз бирешләр дә, ярәшүләр дә булмый калмый. Уртак бәйрәм көннәрендә мәйданнар уен-көлкедән, җыр-музыка тавышларыннан гөрләп тора. Бәйрәм тантаналарының аерылгысыз өлеше — яшьләрнең җырлы-биюле уеннары. Марс кырларындагы кебек үк, аларда да төрле бәйгеләр: ат чабышлары, йөгереш, көрәш үзәк урынны алып тора. Бу традиция безнең төрки бабаларыбыз тормышында күп гасырларга сузыла.

Тарих бара тора. Борынгы бабаларыбыз — болгарлар акрынлап утрак тормышка күчә һәм игенчелек белән шөгыльләнә башлый. Игенчелеккә күчү тормыш-көнкүреш, яшәеш циклларына үзгәрешләр кертә. Игенчелек белән бәйләнгән болгарларда җәйләрен ерак араларга озаклап кунаклап кайтырга чыгып китү мөмкинлеге тарая. Җыен традицияләре трансформация кичерә башлый. Утрак игенчелек белән бәйләнгән традицияләр барлыкка килә һәм ныгый. Игенчеләр авылларда төпләнеп яши. Бер авылда яшәүчеләрнең уртак проблемалары да туа. Авыл халкы алдында ул проблемаларны оператив рәвештә уртага салып тикшерү һәм хәл итү зарурәте барлыкка килә. Шул нигездә борынгы кабиләдәшләрнең зур җыены урынына җәмәгать җыены үткәрү традициясе урнаша. Минем балалык елларым (20 еллар) авылда үтте. Ул вакыт Октябрь революциясенең дулкыннары авылның традицион тормышын җимереп бетермәгән иде. Халык нигездә искечә яши. Нинди дә булса мәсьәләне җәмәгать белән хәл итү ихтыяҗы туганда халык җыены үткәрелә. Ул каравыл өе янында уза. Чираты җиткән кеше кулына шалтыравык тотып, аны шакый-шакый «җыенга барыгыз, җыенга» дип кычкыра-кычкыра авылның бер башыннан икенчесенә кадәр үтеп чыга, аннары икенче урам... Кабатларга кирәкми. Шакылдавык бер мәртәбә үтү белән халык җыен үтә торган мәйданга, каравыл өе янына агыла башлый. Җыенда кайнар бәхәсләр дә була, әмма уртак фикер туа һәм халык бер-берсе белән аңлашып, тупланып яши.

Борынгы җыен йолаларының икенче бер өлеше — хәзерге тел белән әйтсәк, аларда үткәрелеп килгән спорт бәйгеләре һәм яшьләр уеннары халкыбызның яңа бер бәйрәменә — сабан туйларына нигез сала. Сабан туе турыдан туры игенчелек белән бәйләнгән бәйрәм. Ул үзенең башын болгар бабаларыбызның игенчелеккә күчеп, утрак тормышта яши башлауларыннан ала. Аның исеменә дә сабанның — җир эшкәртү коралының — җир белән кавышуы салынган. Егет белән кыз кавышканчы, егет кыз куенына кергәнче, безнең бабаларыбыз борын-борыннан туй үткәрә торган була. Шул рәвешчә, алар язгы җир эшләре башланганчы, сабан җир куенына кергәнче, сабан туе үткәреп алалар.

Мөгаен, төрле җирдә сабан туе төрлечәрәк үткәндер. Минем күз алдында үзебезнең авылда — Олы Кибәхуҗада (Теләче районы) үткәрелгән сабан туе. Бәйрәм гадәттә өч көнгә сузыла. Беренче көн — иртә таңнан без, балалар, өстебезгә яңа күлмәк-штаннар киеп, букчаларыбызны асып, авыл буйлап чыгып китәбез. Туган-тумачага, кардәшләргә, әти-әниләр дус булган авылдашларның өйләренә сугылабыз. Кайсы букчабызга буялган йомырка сала, кайсы бавырсак, җиләк-җимеш, чикләвек, конфет, пряник, 1—2 тиен акча. Кемнең хәле ничек, нәрсә бирә ала. Якынрак туганнардан кыйммәтлерәк бүләкләр дә эләгә. Өйгә кайтуыбызга — әнинең коймагы өлгереп тора.

Бу безнең авылда. Ә күрше авылда, Кече Кибәхуҗада, бу көн башкачарак башлана. Балалар монда да шулай ук өйдән-өйгә кереп йөри. Хуҗабикәләр аларга он, ярма, май, йомырка кебек азык-төлек чыгарып бирә, ә көн авышкач алар авыл башында инеш буена җыйналып карга боткасы пешерәләр.

Яңадан үзебезнең авылга кайтам. Көн уртасына табарак атларга атланып урамга яшьләр чыга. Алар сөлге-яулык җыя. Урамнар гөрләп тора, җырга-моңга күмелә. Яшьләр атларына атланган килеш капка төпләренә туктап гармонга кушылып җырлыйлар. Җырларының төрлесе була. Хуҗаларны, хуҗабикәләрне, яшь киленнәрне, кызларны мактый торганнары да, төрттереп-чәнчеп ала торганнары да. Кешесенә карап, чыгарып биргәк бүләккә карап. Һәркемнең капка төбенә тукталмыйлар. Кем бүләген бирергә тиеш — шуңа. Беренче чиратта хәллерәк кешеләргә. Кем өй өлгерткән шуңа. Кайсы йортта яшь килен бар шул капка төбенә. Кайсы йортта җиткән кызлар... Кем

нәрсә салырга тиеш, егетләр беләләр. Әгәр көткән әйберләр чыкмаса, тагын җырлыйлар, тагын, тагын... Тиешлесен алмый китмиләр. Алгач, хуҗаларга биргән бүләкләрен мактап җырлап та җибәрәләр. Хәтеремдә калганча, яшь киленнәр бүләк җыючыларның атына сөлге чыгарып тага, кызлар сөйгән егетенең атына я чигелгән кулъяулык, я аяк чолгавы тага, хуҗабикәләр ашъяулык, хәлле хуҗалар капка төбенә тәкәсен дә чыгарып бастыра. Ул соңыннан сабан туе мәйданына илтеп куела. Уен-көлке, җыр-бию белән сөлге-яулык җыю кичкә кадәр сузыла.

Икенче көнне көн авышкач мәчет янындагы мәйданда без — балалар өчен бәйге оештырыла. Картлар мәйданга тубал белән йомырка чыгарып куялар. Кәрзин тубалның тоткасына кулъяулыклар да бәйләнгән була. Сабан туе көрәшсез булмый. Безне дә көрәштерәләр. Аннары чүлмәк ватыш, аякларны капчыкка тыгып йөгереш, бүрәнә өстеннән капчык белән бәреп төшереш һ.б. Ахыр килеп, авылның инде чирәм белән каплана башлаган урамы буйлап йөгереш. Бәйгенең һәр төрендә дә җиңүчегә бүләк тапшырыла. Хәтердә калган, балалар өчен оештырылган бу сабан туе мәйданы белән ак сакаллы картлар җитәкчелек итә иде.

Һәм ниһаять, сабан туеның өченче көне. Бу бәйрәмнең кадагы. Бу көнне өйлә намазыннан соң халык мәйданга агыла. Ир-егетләр мәйдан тота: көрәш, ат чабышлары, йөгереш, чүлмәк ватыш, аркан тартыш, капчык киеп йөгереш һ.б. бәйгеләр. Җиңүчеләргә бәйрәмнең беренче көнендә җыйналган бүләкләр тапшырыла. Атларның ялларына сөлге-тастымаллар, яулыклар тагыла. Ә сабан туе батырының җилкәсенә тәкә салына.

Бәйрәм өч көн дәвам итә. Әмма эчү-исерү юк. Сүгенүәрепләшүләр дә күренми. Сабан туе мәйданындагы тәртипне дә ил картлары күзәтеп тора. Низаг-ризасызлыклар килеп чыкса да алар хәл итә. Аларның сүзе закон. Сабан туе көннәрендә үткәрелгән чараларның берсе дә югарыдан килгән фәрман белән билгеләнми. Монда команда белән эш итү юк. Гасырлардан килгән йола, гореф-гадәтләр һәркемгә билгеле, һәркем аның тәртибен белә һәм шул тәртип белән эш итә. Нинди дә булса проблема туса аксакаллар бар, алар җыйналып бу проблеманы хәл итәләр.

Сабан туе, әлбәттә, җыр-биюләрсез булмый. Безнең авылда сабан туеннан кызлар-яшьләр уеннары да башланып китә иде. Алар һәркөнне кичен авыл артындагы кечкенә генә болынга

Кәтри атавы итәгенә җыелалар. Тау битенә олылар да килеп утыра. Бер якта ирләр, икенче якта хатыннар. Болында кызлар-яшьләр уеннары, түгәрәк уен, көтүче, башка төрле җырлы-биюле уеннар. Бераз читтәрәк үсмерләр үзләренең түгәрәген оештырганнар. Без, балалар да, өлешсез калмыйбыз. Бер кырыйда безнең дә түгәрәк әйләнә. Бу уеннар сабан туеннан башлап һәр кичне уздырыла һәм уракка төшкәнче дәвам итә иде.

Сабан туе артыннан ук халык чәчүгә чыга. Хәтеремдә иртә таңнан торып утырып әти белән басуга китүем. Үз җиребезгә җиткәч әтинең орлыкны түбалга тутырып бисмилласын әйтеп чәчә башлавы, беренче орлыклар белән бергә буялган йомыркалар тәгәрәве, минем аларны җыеп йөрүем.

Колхозлашулар башланганчы җыен да үткәрелеп киленде. Җыеннар җәйнең матур чакларында уздырыла иде. Алар язгы кыр эшләре беткәч башланалар һәм бер авылда бер, икенче авылда икенче атнада үткәрелә һәм уракка төшкәнче дәвам итә иделәр. Аларның үткәрелү атнасына карап төрле якларда төрлечәрәк исемнәре була, кушкапка, сабыр, сулып һ.б. Безнең өчен җыен кайсы атнада кайсы авылда үтсә шул авыл җыены була иде. Җыеннарның инде кабиләчелек вакытындагы эчтәлеге югалган. Аларда борынгы җыеннарның бер вазыйфасы сакланган — туганнар очрашуы, кунакка йөрешү. Җыенның беренче көнендә ерак авыллардан туганнар килә. Безнең авылда кунаклар башлыча Җылыштан, Утардан, Җәнәйдән, Яңасаладан килә иделәр. Чөнки элек-электән авылыбыз халкы шушы авыллар белән кыз алып кыз бирешә торган була. Ерак авыллардан туганнар килгәч кунакка йөреш башлана. Өч көн буена авыл гөрләп тора. Гармун, җыр тавышлары. Мәҗлесләр. Аларда татарга хас сый-хөрмәт. Табында милли ашлар. Баздан сыра да чыгарыла. Мәҗлеснең азагына, хәзрәт һәм картлар киткәч, хуҗа балын да чыгарып утырта. Китә үзара сыйлашу, тыйнак кына җырлап, гәпләшеп утыру. Ләкин эш исереклек җанҗалларына җитми. Җыелгач уртак мәсьәләләр тирәсендә фикер алышулар да булмый калмый. Ә кичен кызлар-яшьләр уеннары.

Җәй көненең башка атналарында бу атнада үзе кунак сыйлаган хуҗа белән хуҗабикәнең бүтән авылларга чакырылуы мөмкин. Тарантасы яки арбасына печән җәеп ястык-юрганнарын түшәп, аларны юрган белән каплап, атын җигеп инде алар үзләре кунакка чыгып китәләр. Ә аларны туганна-

ры көтә. Безнең үзебезнең гаилә Җылыш белән ныграк бәйләнгән иде. Әти-әниләр анда кунакка бардылар, үзебезгә дә кунаклар шуннан килделәр.

Җылышка җыенга без малайлар да барабыз. Атта түгел, җәяүләп, ялан аяклап иртә таңнан, әле чык та кипмәгән була, авылдан чыгып китәбез. Казакларны үткәч бераздан Мишә буена килеп чыгабыз. Юлыбыз Комаровка, Караширмә, Карачтау (Кече Җөри), Мамалай авыллары аша бара. Менә Мишә буеның тау бите, анда урман, әрәмәлек. Шул әрәмәлектә без бара торган Ибраһим абзыйларның умарталыгы. Һәм, ниһаять, Җылыш. 20—25 чакрым юл үтелгән. Арып-талып туганнарга барып җитәбез. Анда бәйрәм, 2—3 көн буена сый-хөрмәт. Яңа очрашулар. Бәйрәм хозурлылын күзәтүләр, тирә-як белән танышу. Кичен уеннар.

Колхозлашу процессы башлангач бу традицияләр өзелде. Җәмәгать җыеннары халыкның үзидарәсе формасы буларак яшәүдән туктадылар. Алар урынына совет органнары үзләре халыкны җыеп җыелышлар уздыру тәртибе керттеләр. Әмма алар халыкның үзидарә органнары түгел иде инде, ә хакимиятнең халык белән идарә итү формасы.

Сабантуйларның да характеры үзгәрде. Колхозлашуның беренче елларында сабан туйларын да, җыеннарны да бәйрәм буларак үткәрү бөтенләй тукталды, халыкның хәле алар белән маташырлык түгел иде инде. Массаларның үзоешу формасы буларак алар хакимият органнарын да кызыксындырмадылар. Әмма тора-бара бу органнар да халыкның игътибарын ни белән дә булса җәлеп итәргә кирәклеген аңлый башладылар. Һәм утызынчы елларның урталарында Сабан туен «казып» чыгардылар. Әмма аның традицион эчтәлеген үзгәртеп, хәтта исеменә дә үзгәрешләр кертеп, акрынлап сабан туе урнына сабантуй дигән гыйбарә керде. Аның үткәрү вакыты да үзгәрде. Алар традицион үткәрелеп килгән вакытында, язгы чәчүгә керешкәнче түгел, ә язгы чәчүләр тәмамланганнан соң элек җыеннар үткәрелә торган вакытларда уздырыла башладылар. Вакыт үзгәреше, күренгәнчә, бу бәйрәмнең исемендә дә үзенчә чагылышын тапты. Сабан туе, сабантуй. Чөнки асыл мәгънәсендәге туйның инде вакыты үткән. Сабан туе, әйткәнемчә, сабан җир куенына кергәнче уздырыла. Ә хәзер сабантуй сабан җир куенына кергәннән соң 1,5—2 айдан соң уздырыла башлады. Тора-бара тагы да яңалык-

лар өстәлде. Аерым урыннарда җәй уртасында төнге сабантуйлар, кышкы сабантуйлар үткәрә башладылар. Нинди кышкы сабантуй, нинди төнге сабантуй. Нонсенес. Мәгънәсезлек. Сабан туе яз бәйрәме, табигатьнең яңаруы бәйрәме, кышкы йокымсыраудан соң кояшның үзенең нурларын киң колачлап сибә башлаган вакыт бәйрәме.

Бу тышкы үзгәрешләр сабан туеның эчтәлегендә дә үзенең чагылышын таптылар. Алар инде халыкның үзешчәнлеге нәтиҗәсе булудан туктадылар, административ бер чарага әйләнделәр. Шуның белән бергә, аның милли колориты да югала башлады, ул төссезләнеп тә киткәндәй булды. Миңа күптән түгел бер авылда сөлге-яулык җыю күренешен сөйләделәр. Бер төркем егетләр өйдән-өйгә кереп сөлге-яулык җыеп йөри. Җәяү. Һәр йорт бүләкне алар теләгәнчә бирә алмый. Әгәр биргән әйбер белән канәгатьләнмиләр, яки хуҗабикә берни дә чыгарып тоттырмаса, ишек алдына ук керәләр, хәтта өйгә дә үтәләр һәм, җыр белән түгел, сүз белән бүләк даулыйлар. Күз алдында 20 елларда атка атланган егетләрнең сөлге-яулык җыюлары. Нәүбәттәге капка төбенә килеп туктыйлар. Гармун сызгыра. Җыр. Атлар тыпырдаша. Бер читтәрәк хатын-кыз, бала-чага тамаша күзәтә. Бераз җырлагач, тиешле бүләк чыгарыла, теге яки бу атның ялына тагыла. Яшьләр бүләктән канәгать булсалар, атларын биетә-биетә икенче капкага юнәләләр. Бүләк канәгатьләндермәсә, яңадан җыр башлана. Төртмәле җырлар да була. Бу йортка лаек бүләкне алмыйча, яшьләр капка төбеннән кузгалмыйлар. Алалар, әмма сүзләр белән ялынып-ялварып түгел, ә җыр белән, моң белән.

Соңгы елларда сабантуйларына килеп кушылган тагын бер күңелсез күренеш — эчү, сабан туе мәйданы тирәсендә исерекләр аунап ятуы, аларның яшелле-зәңгәрле тавышлар чыгарып акырынулары, бакырулары, хәтта якалашулары, сүгенүләре дә. Минем Казандагы сабан туйларында да, район үзәкләрендә дә, авылларда да булганым бар. Һәркайда шушы күренеш. Болар барысы да татар халкына чит нәрсә иде. Бигрәк тә сабан туе көннәрендә. Бу милләтнең зәгыйфьләнүе күренеше. Ай, арынасы иде бу авырудан. Юкса, милләт буларак, безнең киләчәгебез — өметсез. Сабан туе — татар халкының милли бәйрәме. Ул борынгы заманнан килгән гадәт, йолалар буенча аек кешеләр өчен якты бәйрәм, күңелле ял булырга тиеш.

Аннан соң аларны, административ кысалардан коткарып, чын мәгънәсендә халыкчанлык рамкаларына кертәсе иде. Сабан туена үзешчәнлек хас, анда күзәтелә торган милли бизәкләр дә шул үзенчәлек белән бәйләнгән. Ул яз башында үткәрелә торган, табигать белән туганлашу бәйрәме. Сабан туйларының шушы хосусиятен, халыкчанлыгын яңадан торгызасы иде. Дөрес, дөнья бер рәвештә, үзгәрмичә тормый. Бу табигать кануны сабан туйларына да кагыла. Сабан туе традицияләренә яңа бизәкләр өстәлүе мөмкин. Әмма аларның төп асыла, аларга хас халыкчанлык бизәкләре сакланырга тиеш.

Соңгы елларда сабан туйларына интернациональләштерү шаукымы да үзенең тәэсирен бик нык сиздерә. Интернационализм бик гади, һичнинди гаепсез, милләтара дигән төшенчә. Халыклар бер җир йөзендә, бер-берсе белән янәшә, аралашып яшиләр, үзара мөнәсәбәтләргә керәләр. Хәзерге заманда бу гадәти күренеш. Әмма большевистик хакимият урнашкач, бу төшенчәгә сәяси төсмер өстәлде. Һәм бу халыкларның милли үзенчәлекләрен, аларның үзбилгеләнүен кысрыклау чарасына әйләнде. Һәм шушындый төсмер алган интернационализм идеясе сабан туйларына да үтеп керде. «Безнең Минзәлә шәһәрендә, — дип яза С.Миңлегәрәев, — Сабан туй хәзер интернациональ бәйрәмгә әйләнеп бара» дигән булып җитәкчеләребез бәйрәмне урысча сөйләп ачып җибәрәләр, алып баручыларның да күпчелеге урысча сөйли» (Ватаным Татарстан, 1995, 11 июль). Бу Минзәләгә генә хас күренеш түгел. Һәркайда сабан туйларын җансыз кысаларга кертеп, менә хәзер урысча, менә хәзер чуаш, мари җыры, украин, молдаван биюе дип интернациональләштерү процессы бара. Мин урыс, украин, мари, чуваш алдында сабан туе мәйданнарының капкаларын бикләп куярга өндәмим. Килсеннәр, карасыннар, хозурлансыннар, теләсәләр бәйгеләрдә дә катнашсыннар. Әмма сабан туйлары — татар халкының традицион милли бәйрәме. Аларның миллилеге, аларга хас милли төсмерләр һәр очракта сакланырга тиеш. Аларның баетылуы да милли нигездә булырга тиеш.

Хәзер сабан туйларында бүләкләрне дә мулдан яудыралар: җиңел машина, трактор, мотоцикл, телевизор, видеомагнитофон, суыткыч һ.б., һ.б. Элек тә мәйдан батырын буш кул белән калдырмыйлар иде. Тәкә, сөлге, ашъяулык, аяк чолгавы, чиккән яулык... Гади татар кешесенең гадел хезмәте җимешләре,

сәнгати әйберләр, индивидуаль иҗат җимешләре. Хәзерге мәйдан бүләкләре иҗтимагый казаннан алып өләшенә. Алар өләшүчеләрнең шәхси хезмәте нәтиҗәсе түгел. Гомуми хезмәт җимеше. Шуңа күрә бирүче түрә өчен кыйммәте дә юк. Гомуми байлыкка ул хуҗа, ала да бирә. Үз кесәләренә кагылмагач саранланып торуның кирәге юк. Һәм менә түрәләр һәм эшмәкәрләр арасында ярыш башлана — кем зуррак бүләк чыгарып сала. Әмма бер нәрсә искә алынмый — гомуми казаннан чыгарып салынсалар да, ул машиналар, тракторлар, мотоцикллар, телевизорлар теге яки бу колхоз, совхоз, предприятие коллективларының уртак хәзинәсеннән бүленеп алынган, шушы коллектив хезмәте җимеше. Гомуми байлык ничек файдаланыла — бу турыда һәркемгә яхшырак уйларга иде, түрәләргә дә, гади хезмәтчәннәргә дә.

Сабан туйларын кайчан уздыру һәм исеме турында да, мөгаен, уйланырга вакыттыр. Сабан туе әйткәнемчә яз бәйрәме, сабанның җир куенына керү бәйрәме. Озын тарихыбыз дәвамында ул табигатьнең җанлану вакытында — сабанга төшкәнче үткәрелеп килде. «Сабан туен, — дип язды рассамыбыз һәм әдибебез Бакый ага Урманче, — иртә яз, сабан аенда уздырырга кирәк. Ул бит табигатьнең терелүе, яшәү туе. Вакытында уздырылмаса аның тәме бетә» («Социалистик Татарстан», 1989, 2 июнь). Хак сүзләр. Мин хәзер, тотарга да сабан туйларын сабанга төшкәнче уздырырга күчәргә кирәк, дип катгый тәкъдим ясарга җөрьәт итмим. Бу — халык эше, җәмәгатьчелек эше. Шулай да хөрмәтле аксакалыбыз сүзләрендә җәмәгатьчелек өчен уйланырлык урын бар. Моннан берничә ел элек Теләче районының Шәтке авылы халкы бу бәйрәмне җыен дип үткәрә башлады. Чөнки сабан туе исеме белән бу бәйрәм хәзер элеккеге җыеннар вакытында уза. Шуның өстенә, инде күрсәтелгәнчә, сабан туе үзенең чыганагы белән борынгы җыеннарга да барып тоташа. Бу да уйланырга җирлек тудыра.

Милли йолаларыбызны кәкре юлларга борып җибәрмичә сакларга иде.

1995 ел.

ТАТАРНЫҢ ДИАСПОРАСЫ КАЙДА?

Шушы арада Казанда «Татарстан республикасында кавемара һәм динара мөнәсәбәтләре» дигән темага фәнни-практик конференция булып узды. Күтәрелгән проблемаларның күпьяклы булуы белән дә, тыңланылган докладларның эчтәлеге белән дә, күпсанлы күренекле галимнәрнең катнашуы белән дә бу конференция соңгы елларда үткәрелгән шуңа охшаш конференцияләрдән уңай якка аерылып торды. Шулай да бер нәрсә гаҗәпкә калдырды — конференциядә укылган докладларда да, танылган галимнәрнең чыгышларында да еш кына татар диаспорасы дигән тәгъбир яңгырады һәм ул Татарстаннан читтә яшәүче барлык татарларга карата да кулланылды.

Әмма, нәрсә соң ул диаспора? Бу грек сүзен теге яки бу халыкның үз ватаннарыннан читтә яшәүче аерым төркемнәренә карата кулланалар. Диаспора бу төркемнәрнең үз ватаннарыннан куылуы, яки көчләп күчерелүе, геноцид куркынычы янавы яки экономик һәм хокукый эзәрлекләүләр аркасында туган җирләрен ташлап чит-ят төбәкләргә барып урнашуы аркасында барлыкка килә. Башта диаспора тәгъбире яһудләрнең Палестинадан куылып Вавилонда яшәргә мәҗбүр булган төркемнәренә карата кулланыла. Бу диаспора безнең эрадан 6 гасыр элек барлыкка килде. Соңыннан яһуд диаспоралары барлыкка килүе безнең гасырның 1—2 йөзләрендә аларны римләннәрнең эзәрлекләве белән бәйләнгән. Тора-бара диаспора тәгъбире үз ватаннарыннан читтә яшәргә мәҗбүр булган башка кайбер халыкларга (әрмәннәр, ирландиялеләр, кытайлылар) һәм дини берләшмәләргә (беренче христианнар) карата да кулланыла башлады. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң икътисади хаҗәт Якын Көнчыгыш, Көньяк Азия һәм Африкадан күп кенә халыкларның вәкилләрен Көнбатыш Европа илләренә килеп эшкә урнашырга мәҗбүр итте. Нәтиҗәдә бу илләрдә төрек, алҗирлылар һ.б. халыкларның диаспоралары барлыкка килде.

Татар халкы тарихта зур михнәтләр, эзәрлекләүләр кичергән халык. Икътисади, сәяси һәм хокукый кысрыклаулар нәтиҗәсендә аның вәкилләре туган ватаннарыннан күтәрелеп чыгып китәргә мәҗбүр булдылар һәм чит-ят җирләрдә төпләнеп калдылар. Шулай итеп Финляндиядә, Америкада, Кытайда һ.б. илләрдә татар диаспоралары барлыкка килде.

Әмма милли һәм дини кысуларга, сәяси һәм хокукый эзәрлекләүләргә, икътисади басымга карамастан, татар халкының күпчелеге үзенең тарихи ватанынан аерылмаска тырышты. Аның бу ватаны — бөтен Идел буе, Көньяк һәм Урта Урал төбәге, шулай ук Көнбатыш Себер өлкәләре. Бу җирләр татарлар өчен диаспора түгел, ә Татарстан кебек үк, туган туфрак, гасырлар буе ата-бабалары яшәгән изге җир. Шуның өчен Башкортстан яисә Удмуртия, Пермь яки Чиләбе, Чувашстан яки Мордовия, Самара яки Түбән Новгород, Ульяновск яки Пенза, Саратов яки Волгоград, Көнбатыш Себер яки Әстерхан татарлары турында сүз алып барганда диаспора тәгъбирен куллану урынсыз, алар үзләренең тарихи ватаннарында көн күрәләр. Диаспора тәгъбирен бары Мәскәү һәм С.-Петербургта, Казахстан һәм Кыргызстанда, Үзбәкстан һәм Әзербәйҗанда, Украина яки Белорусиядә яшәүче татарларга карата куллану урынлы булыр.

Сүзне дөрес кулланмау, аның эчтәлеген аңлатуда төгәлсезлекләр, икътисади мөнәсәбәтләрне, сәяси бәйләнешләрне һәм мәдәни эшчәнлек юнәлешләрен билгеләгәндә хата юлга өстерәве мөмкин. Шуңа күрә диаспора тәгъбирен дә татар халкына карата зур төгәллек белән кулланасы иде.

1993 ел.

II

МӘРҖАНИ ШӘХЕСЕ ҺӘМ АНЫҢ ТАТАР ИҖТИМАГЫЙ ФИКЕРЕ ТАРИХЫНДА УРЫНЫ

Күп гасырларга сузылган бай тарихы дәвамында татар халкы үз арасыннан киң колачлы галимнәр, олы фикер ияләре, әдипләр һәм шагыйрьләр бирде. Без аларны ихтирам белән искә алабыз, мирасларын өйрәнәбез. Шундый бөек шәхесләрнең берсе Шиһабетдин Мәрҗани (1818—1889). Аның йөзендә безнең күз алдыбызга киң диапозонлы галим һәм мөтәфәккир (мыслитель) килеп баса. Ул төпле фикер йөртүче фәләсиф (философ), тарихчы һәм мәдәниятның төрле тармакларыннан хәбәрдар булган киң карашлы укымышлы. Фәлсәфә һәм тарихтан тыш аңа әдәбият һәм тел гыйлеме дә, археология дә, этнография дә, нумизматика да, математика да, география дә, медицина да, фармакология дә чит түгел. Ул аларның һәркайсы, хәтта музыка һәм сәнгатьнең башка төрләре буенча да теоретик бәхәсләр алып барырга хәзер.

Шул ук вакытта Ш.Мәрҗани татар мәгърифәтчелеге хәрәкәтенең күренекле вәкиле дә. Аның хезмәтләре һәм киң планлы эшчәнлеге халкыбызны урта гасыр туңлыкларыннан, катып калганлыктан арындыруда мөһим роль уйнады, аңа алгарышка (прогресска) юл ачты. Аның барлык әсәрләре, — дип язды Г.Ибраһимов, — фикердә хөррият рухы белән, киләчәккә якты карау һәм адәм акылына ихтирам белән сугарылган. Аның әсәрләре баштанаяк адәмнең акылы өстенә салынган богауларны өзү, фикернең искелеккә кол булуына каршы көрәшүдән гыйбарәт. (Кара: Аң, 1915, №1, 14 б.).

Хезмәтләре һәм эшчәнлеге белән генә түгел, Ш.Мәрҗани килеш-килбәте белән дә, үзен тотышы белән дә мәһәбәт зат була. Замандашларының әйтүенчә, ул үзен бик гади тота. Кеше белән аралашканда бик игътибарлы була, шул ук вакытта үз бәясен дә белә һәм дәрәҗәсенә берәрсе тел

тидерсә, аны күтәрә алмый. Ул сөйләгәндә ышандырырлык итеп дәлилләр белән сөйли, ләкин күпсүзле түгел. Солтанәт кыяфәте, үзен җитди тотуы, принципиальлеге, нык характерлы булуы аны башкалардан аерып тора.

Мәзкүр зат 1818 елның 16 гыйнварендә Казан артында урнашкан Ябынчы авылында киң белемле рухани гаиләсендә дөньяга килә. Тиздән аның әтисе Бәһаутдин хәзрәт Казан артындагы икенче бер авыл — Ташкичүгә имам итеп тәгаенләнә. Бәһаутдин хәзрәт бу авылда зур мәдрәсәгә нигез сала. Шиһабетдин мәхдүм шушы мәдрәсәдә фәннәр үзләштерүдә тәүге адымнарын атлый. Ә 1838 елда ул, инде җиткән егет, укуын дәвам итү өчен сәүдә кәрванына ияреп Бохарага китә. Биредә ул иң абруйлы мөдәррисләрдән дәресләр ала.

Ш.Мәрҗани бала чактан ук максатка омтылучанлыгы һәм эшчәнлеге белән аерылып тора. Әле авылда уку елларында ук ул мәдрәсәдә бирелгән дәресләрдән тыш башта әтисенең, аннан соң бабасының бай гына китапханәсендәге китапларны баштанаяк укып чыга. Бохара һәм Сәмәркандта укыган елларында да мәдрәсә стеналарында бикләнеп ятмый, вакытын андагы китапханәләрдә үткәрә, дини, фәлсәфи, тарихи, филологик әдәбият диңгезенә чума. Шул ук вакытта хөр фикерле мөдәррисләр һәм башка укымышлылар белән аралашырга тырыша, фәнни бәхәсләрдә катнаша.

Бохарада һәм Сәмәркандта тормышын алып бару өчен Шиһабетдинның нинди дә булса материаль чыганаклары булмый. Шуңа күрә аңа күп кенә вакытын тормышын материаль яктан тәэмин итүгә бирергә туры килә. Ул офтанмый, зарланмый. Шундагы балаларны укытуга яллана, китап күчерү белән шөгыльләнә, ә җәйләрен мөгаллимлек итү өчен авыл җирләренә чыгып китә. Соңыннан ул үзенең шәкертләренә, Бохарада булганда дәрескә өлгерү өчен һәр көнне иртән яланаякка башмак эләктереп 3—4 чакырым юл үтәргә туры килә иде, дип сөйли торган була (Кара: Мәрҗани, Казан, 1915, 44 б.).

Шушы шартларда ул эзлекле рәвештә белем туплый, зиһенен баета. Шуның белән бергә, ул бөтен мөмкинлекләрен файдаланып әдәбият җыя, шәрекънең күренекле галимнәренең әсәрләрен сатып ала, ә моңа акчасы булмаса күчереп яза. Шулай итеп Ш.Мәрҗани бай гына китапханә туплый, туган иленә берничә сандык китап һәм кулъязмалар төяп кайта.

Казанга кайтып урнашкач та, Ш.Мәрҗани шундый ук эзлеклелек, максатка омтылучанлык белән эшен дәвам итә, башыаягы белән фәнни эзләнүләргә һәм уку-укыту эшенә чума.

Ул гомере буе тикшеренүләр алып бара, шул максаттан еш кына авылларга чыгып йөри, кабер ташларындагы язмаларны һәм борынгы акчаларны тикшерә, иске китапларны һәм тарихи шәхесләрнең язмаларын өйрәнә. Зур түземлелек белән ул халыкта сакланган сөйләмнәрне, риваятьләрне, борынгы китапларның читләрендәге язмаларны һәм рәсми документларны туплый, аерым шәхесләрнең биографияләрен һәм халык авыз иҗаты ядкарьләрен өйрәнә.

Ул армый-талмый эшли, фәнни хезмәтләрен яза, тарихтан, фәлсәфәдән, илаһият тәгълиматыннан утыздан артык калын-калын китаплар иҗат итеп калдыра. Замандашларының истәлекләренә караганда, ул бик нык авырган хәлдә дә үзенең шәкертләре ярдәмендә «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» дигән хезмәтенә өстәмәләр кертә.

Ш.Мәрҗанинең эшчәнлеге күпкырлы була. Бүген ул безнең күз алдыбызга беренче чиратта Казан шәһәренең олы имамы, иң абруйлы имамнарның берсе булып килеп баса. Ш.Мәрҗанинең бу мәртәбәле урыны инде аның ватанына кайткач ясаган беренче адымнары белән үк билгеләнә. Ул Казанның беренче мәчетенә имам-мөдәррис итеп чакырыла. Бу урынга тәгаенләгәнче шәһәрнең мәшһүр байларыннан булган Ибраһим Юнусов зур бәхәс мәҗлесе уздыра. Анда күренекле имамнар, галим-голяма катнаша. Алар сораулар биреп Ш.Мәрҗанине бәхәскә тарталар. Бәхәс мөселман фәлсәфәсе, игътикад, илаһият тәгълиматының катлаулы мәсьәләләре тирәсендә бара. Яшь имам төпле дәлилләре, тирән фикерле җаваплары белән үзенең оппонентларын егып сала. Һәм шушы бәхәс киләчәктә дә Казанның галим-голямасы һәм имамнары арасында аның мәртәбәле урынын билгеләде. Үзенең үтемле сүзе, ачык фикере, төпле уйланулары, әхлакый пакълеге белән Ш.Мәрҗани мәхәллә халкы алдында да зур абруй казана.

Имамлык вазыйфаларын үтәү белән бер үк вакытта, ул мәчет каршындагы мәдрәсәнең мөдәррисе була. Ул килеп эшли башлагач, бу мәдрәсә Казанның иң абруйлы уку йортларының берсенә әйләнә, даны еракларга тарала. Ул түземлелек белән мәдрәсәнең эшен ныклы тәртипкә салу чараларына

керешә, сайлап куелган попечательләр булдырып, аның эшен тәкәббер байларның башбаштаклыгыннан коткарырга тырыша. Имам вә мөдәррис үзе биргән дәресләр исә тирән эчтәлекле, фәнни анализның нигезле булуы белән аерылып торалар. Дөнья куярына берничә көн калгач та, ул шәкертләрен өенә чакырып, дәрес бирүне дәвам итә.

Ш.Мәрҗанинең эшчәнлеге күбәүләргә ошамый. Дошманнары ике мәртәбә аның указы алынуга да ирешәләр. Әмма мәхәллә халкы бердәм рәвештә аның ягына баса, яклап чыга. 1853 елда указы алынгач, имамлыктан һәм мөдәррислектән читләштерелүенә ризасызлык белдереп, үзен кире эшкә кайтаруны сорап, мәхәллә халкы тарафыннан диния нәзаратына язылган хатларның берсендә: «Имам и мударрис мулла Шигабетдин Багаутдинов поистине достойный вечного уважения, усердный учитель и ревностный исполнитель своих обязанностей, имеет к тому же кроткую нравственность, к прихожанам приветлив и с учениками был весьма обходителен, любовь и уважение оных привлек к себе до такой степени, что вступлением его в должность имама и мударриса число учеников противу прежнего в училище, вдвое и того больше увеличилось, которые по устранению Его — муллы Багаутдинова от училища, оставили учение—одним словом сей мулла Шигабетдин Багаутдинов достойный и редкий учитель, и подобно ему в правилах законопреподаватель приход никогда не имел и иметь невозможно...». (Башкорстан АССР үзәк архивы. Оренбург Мөхәммәт дини мәҗлесе фонды, фонд И-295, опись 3, саклау берәмлеге 3499, 84 б.), дигән юллар характерлы.

Шуның өстенә, Ш.Мәрҗани, инде әйткәнчә, зур галим, фәләсиф (философ) һәм илаһият тәгълиматы (богословие) вәкиле дә. Бу яктан аның йөзе күпкырлы иҗатында үзенең ачык чагылышын тапты. Галимнең «Назурәтел-хак» (1870), «Әл-Хикмәтел-балига» (1888), «Хаккыл-мәгърифәт» (1880), «Әл-Бирак әл-Вәмид» (1888), «Әл-Газб ул-фурат» (кульязма) исемле гарәп телендә язылган әсәрләрендә фәлсәфәгә һәм илаһият тәгълиматына кагылышлы мәсьәләләр күтәрелә һәм аларга тәфсыйлле анализ ясала. Аларда мөтәфәккиребез (фикер иясе) мөтәкәллимнәрнең дөньяга карашы мәсьәләләренә кагылышлы фикерләренә тәнкыйди анализ ясый һәм чынбарлыктагы процессларны фәнни яктан яктыртуга юл яра.

Ш.Мәрҗани фәлсәфә тарихы буенча да төптән фикерләүче галим буларак чыгыш ясый. «Мөкаддимәте Вәфиятел-әсләф...» һәм «Вәфиятел-әсләф вә тәхиятел-әхләф» исемле фундаменталь хезмәтләрендә аның мөселман дөньясында иҗтимагый фикер үсеше дә, төрле идеологик юнәлешләр арасында барган көрәш тә, исламда төрле мәзһәбләр формалашуы тарихы һәм алар арасында урнашкан катлаулы мөнәсәбәтләр дә, ислам дөньясы фәлсәфи фикеренең үзенчәлекләре һәм аның илаһият тәгълиматына мөнәсәбәте дә, мөселман җәмәгатьчелегендә суфичылыкның урыны мәсьәләләре дә үзләренең ачык чагылышын табалар. Бу әсәрләрдә Әл-Фараби, Ибн Сина, Әл-Кинди, Әл-Газали, Ибн Рошд, ибн Халдун кебек ислам дөньясының олы мөтәфәккирләре һ.б. мәдәният эшлеклеләре турында да бик кыйммәтле мәгълүматлар саклана.

Фәлсәфә һәм илаһият тәгълиматы мәсьәләләрен яктыртканда да, фәнни проблемаларны тикшергәндә дә, фәлсәфә тарихы буенча сүз алып барганда да Ш.Мәрҗани, рационализм позициясендә тора һәм акылга таянып фикер йөртә. Фәләсиф-рационалист буларак, ул схоластик уйдырмаларны катгый рәвештә кире кага һәм хөр фикерлелекне яклап чыга. Ш.Мәрҗани, әлбәттә, ислам тарафдары һәм үзенең оппонентлары белән бәхәсләшкәндә Корьән һәм хәдисләргә таяна. Шул ук вакытта ул фанатизм белән мистицизмны да кире кага һәм бу очракта изге китапларны аларның позицияләрен какшату максатында файдалана.

Фәлсәфәдә рационализм позициясендә торган Ш.Мәрҗани тәкълидчелек белән дә килешә алмады. Тәкълидчелек идеясе ул заманнарда консерватив караштa торган дин әһелләренең һәртөрле яңалыкка, хөр фикерләүгә каршы көрәшү коралы вазыйфасын үтәде. Бу идея белән коралланган искелек тарафдарлары үз замандашларын борынгылар әйтеп калдырганнарга һични уйламыйча иярүне таләп итеп чыктылар, адәм баласының иҗади эзләнүләргә хакы барлыгын инкяр иттеләр. Алар фикеренчә, иҗади көчәнүләр һәм эзләнүләр заманы инде артта калды (иҗтиһад мөнкарыйз), мөҗтәһидләр (мөстәкыйль фикер йөртергә сәләтле шәхесләр) юкка чыкты. Борынгы заманнарда яшәгән мөҗтәһидләр дөнья тәртипләре турында бөтенесен әйтеп калдырганнар, хәзерге бәндәләр шул мөҗтәһидләр сүзенә уңга-сулга карамыйча ышанып эш итәргә тиешләр. Бу идеянең җәмәгатьчелек фикерен яулап алуы иҗади эзләнүләргә богау салды, уй-фикердә торгынлык тамыр җәюенә китерде.

Әле Ш.Мәрҗанинең элгәрләреннән булган Г.Курсави бу практикага каршы кискен протест белән чыкты, тәкълидчелекне иҗтимагый үсешне тоткарлый торган традиция буларак гаепләде. Әмма үткәннәргә сукырларча ияреү һәм догматизм күренешләренә каршы хәлиткеч һөҗүм Ш.Мәрҗани тарафыннан ясалды. Үзенең инде телгә алынган хезмәтләрендә ул тәкълидчелек һәм аңа бәйләнгән догматизм безнең арада һәртөрле тәгассыблыкның һәм катып калганлыкның терәгенә әйләнде, дигән фикер үткәрә. Тәкълидчелекне кире кагып, мәгърифәтче галим кешелек җәмгыятенең танып-белү куәсенә һәм актив иҗади эзләнүләргә һичнинди киртә булуы мөмкин түгел, дип күрсәтә. Кеше үзенең фикерләвендә дә, эш-гамәлләрендә дә һәркайчан ирекле булып кала.

Мәрҗани шулай ук ул заманнарда мөселман дөньясында нык тамыр җәйгән тәкфир практикасын, фәнни эзләнүләр белән шөгыльләнүче һәр кемсәне дәһрилектә гаепләү күренешләрен дә бөтен кискенлеге белән кире кага. Тәкълидчелек кебек үк, тәкъфир дә, аның фикеренчә, алгарыш юлында яткан коточкыч киртә булып тора.

Ш.Мәрҗанинең тәкълидчелек һәм тәкфир турында әйтелгән тәнкыйди сүзләре дини реформаторлык юнәлешендә иделәр. Әмма шуның белән бергә алар мәгърифәтчелек рухы белән дә сугарылган булдылар. Татар иҗтимагый фикерендә дини реформаторлык көнбатыштагы кебек мәгърифәтчелектән вакыт ягыннан аерылып тормады, алар XVIII гасыр азагыннан алып XX гасыр башына кадәр бер-берсенә бәйле рәвештә, үзара үрелеп үстеләр. Чөнки аларның реформаторлык идеяләре кешеләрнең аңына юнәлдерелгән иде, аларны тирә-юньгә, традицияләргә һәм иҗтимагый практикага аек акыл белән, тәнкыйть күзе аша карарга чакырып тордылар. Ә иҗтимагый практикага, традицияләргә тәнкыйди караш, аларны аек акыл күзлеге аша үткәрү, билгеле булганча, мәгърифәтчелек хәрәкәтенең мөһим үзенчәлеге булды.

Ш.Мәрҗани шул ук вакытта — күренекле тарихчы да. Аның иҗади мирасында бу фән буенча хезмәтләре төп урыннарның берсен алып тора. Ул безнең күз алдыбызга киң планлы тикшеренүче галим булып та, тарих фәненең тирәннән фикер йөртүче теоретигы да булып килеп баса. Үзенең хезмәтләрендә ул тарихның фәннәр системасындагы урынын нигезле бәяли, кешеләр тормышында, җәмгыятьнең үсешендә аның урынын тәгаенли һәм тарихи эзләнүләрнең методологик нигезләрен яктырта.

Ш.Мәрҗанинын тарих фәненә кагылышлы мирасының төп өлешен үз халкының үткәнен, аның мәдәниятын, күренекле шәхесләрнең эшчәнлеген яктырткан сәхифәләр били. Аның иҗади эшчәнлеге, билгеле булганча, татарлар арасында милли аңның уянуы һәм үсеше белән параллель рәвештә барды һәм бу аның мирасының эчтәлегендә үзенең чагылышын тапты. Милләт һәм үз халкының тарихи язмышы бу мирасның үзәк урыннарының берсен били. Милли аңның төшенкелеге, халыкның үзенең тарихи үткәнен һәм мәдәни мирасын белмәве, аның фикеренчә, социаль һәм милли алгарыш (прогресс) юлында җитди киртә булып торалар.

Шуңа күрә дә, тарихчы-галимнең игътибар үзәгендә үз халкының, ул яшәгән төбәкнең тарихы тора. Ш.Мәрҗани бик урынлы рәвештә татар халкының фәнни тарихына нигез салучылардан санала. Татар мәдәниятының күренекле вәкиле Җ.Вәлиди юкка гына аны «безнең Геродотыбыз» дип атамады. Дөрес, татарлар арасында тарих гыйлеме аңа кадәр дә яхшы ук тамыр җәйгән иде, халкыбызның хәтерендә тарихи үткәнебез турында киң генә мәгълүматлар сакланып киленде. Тарихка кагылышлы язма әсәрләр дә бар иде. Әмма аларда теркәлгән мәгълүматлар әле таркау һәм алар эзлекле бер системага китерелмәгән иделәр. Татар халкының тарихы үзенең системалаштырылган, эзлекле язылышын беренче мәртәбә Ш.Мәрҗани мирасында тапты. Аның «Мөстәфадел-әхбар...» һәм «Галялят аз-заман...» исемле әсәрләре турыдан-туры шушы мәсьәләгә багышланган. Татар халкының тарихи үткәне турында аның «Вафийәтел-әсляф вә тәхийәтел-әхләф» дигән әсәрендә дә бай гына мәгълүмат тупланган.

Үз халкының тарихын язганда Ш.Мәрҗани гарәп тарихчыларының хезмәтләренә таяна, шәрекъ илләреннән чыккан сәяхәтчеләрнең истәлекләренә һәм урыс чыганакларына мөрәҗәгать итә. Әмма аның фәнни тикшеренүләрендә үзәк урынны үзе эзләп тапкан мәгълүматлар алып тора. Тарихи дөреслекне торгызу өчен ул күп кенә беренчел чыганакларга — борынгы тәңкәләргә (акчаларга), ярлыкларга, телдән һәм язма рәвештә килеп ирешкән риваятьләргә, дәүләт эшлекләләренең һәм аерым шәхесләрнең язмаларына, кабер ташларында теркәлгән хәбәрләргә, борынгы китапларның кырларындагы язмаларга һ.б. таяна. Шул юл белән ул үз халкының тарихи үткәнен торгыза.

Татар халкы, дип саный ул, зур тарихи юл үтте һәм бик күркәм мәдәният ядкарьләре тудырды һәм бу фикерне ышанычлы дәлилләр китереп раслый.

Ш.Мәрҗани шәхесе турында сүз алып барганда аның йөзен билгели торган тагы бер сыйфат — принципиальлек. Аның күпкырлы фәнни-педагогик эшчәнлеге, урта гасырлардан калган схоластик фикерләүләргә һәм тәгассыблык күренешләренә каршы кискен чыгышлары, искелеккә каршы әйтелгән тәнкыйди сүзләре, әлбәттә, үткәннән калганнарга ябышып ятучы көчләрнең ачуын уята. Җәмгыять тормышындагы тискәре күренешләрне үз исеме белән атаган һәм искелекне саклауга каршы чыккан өчен аны каһәрлиләр, могътәзил (исламда акыл белән эш итүне яклап чыккан агым), хәтта диннән язучы дип гаеплиләр, эзәрлеклиләр, аңа каршы яла ягулар белән тулы хезмәтләр язалар. Дошманнары мәхәллә халкын да аңа каршы котырталар. Инде әйтелгәнчә, ялган әләк нигезендә аның ике мәртәбә указы да алына, мәдрәсәсе иң йогынтылы байларның ярдәменнән мәхрүм ителә. Эш хәтта аның мәдрәсәсен яндыруга кадәр җитә.

Шундый каршылыкларга карамастан, Ш.Мәрҗани чигенми, үзенең маягына тугрылыгын саклый. Ә бу маяк — иҗтимагый алгарыш, туган халкының киләчәге. Искелек тарафдарларына каршы көрәштә ул аяусыз була. Әсәрләрендә дә, голяма бәхәсләрендә дә ул үзенең оппонентларын логик нигезләнгән, кыска, әмма үткер сүзләр белән егып сала, аларның фикерләренең баштанаяк нигезсез икәнлеген күрсәтә. Фикерләрен дәлилләүдә Мәрҗанинең эзлекле булуына басым ясап, Р.Фәхретдинов аның әсәрләренә бер өстенлек хас, ул да булса сүз бара торган мәсьәләне ышанычлы итеп исбат итү, дип яза. Анда юкка-барга сүз озайту юк, сүз бара торган мәсьәләләрнең һәркайсы аның тарафыннан җентекләп тикшерелгән. «Гомерендә «Назурә»не күрмәгән ... бер гыйлем әһеленә, — дип дәвам итә ул, — бу әсәрдән зур гына кисәк укып бирәләр. Мәзкүр галим тыңлый да «моны язучы кеше үзенә каршы булу һәм һөҗүм итәргә маташучылар белән сөйләшеп торуны лязум күрми. Һәр берене берәр-берәр салган да еккан, салган да еккан, шуннан соң: «Барыгыз, инде кирәгегез булды!», — дигән» (СССР Фәннәр академиясенең Башкорстан филиалы архивы, фонд 7, саклау берәмлеге 12, 183 б.).

Ш.Мәрҗани өчен дөреслек бар нәрсәдән дә өстен була. Аны якыннарының фикере дә, тирә-юньдәге каргышлар да, үзе дөрес дип ышанган максатка ирешү өчен көрәштән туктата алмыйлар. Атасының, кешеләрдән аерылмаска һәм купчелекнең фикере белән санашырга кирәк, дип үгетләвенә каршы ул: «Суконныйларда да күпчелек бар. Күпчелектән бигрәк хакыйкать вә тугрылыкны алда тотарга кирәк», — дип җавап бирә («Мәрҗани» мәҗмугасы, Казан, 1915, 176 б.). Менә шушы инануы белән аның тормышта кылган эшләрен билгеләп, бәяләп була. Сүз дөреслек һәм кешелек дәрәҗәсе турында барганда ул, үз чорының иң бай, иң танылган кешеләре белән арасы өзелүдән дә курыкмый, моның авырлыкларга һәм югалтуларга дучар итүенә һәм эшендә зур күңелсезлекләргә китерүенә карамый, берни алдында да туктालып калмый, алга бара. Хөрлек сөюче, принципиаль галимне сайлаган юлыннан һични тайпылдырмый. Искелек көчләре оештырган һәртөрле киртәләргә карамастан, алдына куйган максатын тормышка ашыру өчен Ш.Мәрҗани үз-үзен аямыйча эшли, көрәшә.

Шулай итеп үзенең күпсанлы хезмәтләре аша Ш.Мәрҗани безнең күз алдыбызга зур галим-тарихчы, фәлсәфәче (мыслитель) һәм мәгърифәтче, армый-талмый халкыбызның киләчәге өчен көрәшкән затлы шәхес булып килеп баса. Ул үзенең бер әсәрен «Ал-бирак ал-вәмид фи ар-радди ал-бәгыйзи ал-мөсимми би-әнакыйс» дип атады. Кыскача гына итеп әйткәндә, бу, дошманнарны юк итүче яшен, дигән сүз. Чыннан да анын эшчәнлеге, ул язган әсәрләр үзләренең нурлары белән татар халкының караңгы тормышына яктылык салган яшенне хәтерләттеләр. Бу яшеннең яшьнәве тирә-юньдә бик көчле күкрәү авазы булып яңгырады һәм яктылыкның, аң-белемнең, прогрессның бөтен дошманнарын калтыратырга мәҗбүр итте.

Мәрҗани татар иҗтимагый фикере тарихында тәнкыйть сукмаклары салучыларның берсе булды. Аның искелекнең череп таркалган калдыкларын фаш итүче чыгышлары борынгыларга сукырларча табынудан азат булырга, фикер азатлыгы һәм үзлегеңнән хакыйкатьне эзләү юлына басарга ярдәм иттеләр. Бездә тәнкыйтьнең беренче адымы унтугызынчы гасырның башларында Курсавидан башланды. Беренче тәнкыйть утлары атучы ул булды. Аның тәнкыйте татарның фикер тунлыгына каршы юнәлдерелгән дини-фәлсәфи, усал һәм каты тәнкыйть

иде. Шул ук рухтагы тәнкыйтьне унтугызынчы йөз урталарыннан Мәрҗани дәвам иттереп алып китте. Бу галим-мөтәфәккирнең тәнкыйте тагын да ачы, тагын да каты һәм тагын да зәһәрлерәк булды.

Ш. Мәрҗанинең иҗади мирасы туган халкын феодаль-патриархаль мөнәсәбәтләр һәм уртагасырчылык идеологиясе капкыннарыннан коткаруга, аны дөнья мәдәнияты казанышларына бәйләүгә юнәлдерелгән иде. Аның әсәрләре, дип язды Г.Ибраһимов, «фикер азатлыгын яклау, киләчәккә якты ышаныч һәм кеше акылына хөрмәт белән сугарылган... Беренчел юллардан алып соңгысына кадәр, алар фикер коллыгына һәм аның үле традицияләр белән богаулануына каршы көрәшкә, кеше акылына салынган чылбырларны өзүгә, ватуга юнәлдерелгән идеяләр белән сугарылган» («Аң», Казан, 1915, №1, 14 б.). Ш.Мәрҗанинең иҗади мирасын һәм эшчәнлеген шулай ук татар мәдәниятының күренекле вәкилләре М.Акмулла, Г.Чокрый, Г.Тукай, М.Гафури, язучы-публицистлар Ф.Әмирхан, Н.Думави, галим-иҗтимагый эшлеклеләр Р.Фәхретдинов һәм Җ.Вәлидиләр дә югары бәялиләр. Үзенең «Шиһаб хәзрәт» исемле шигырендә Г.Тукай, мәсәлән, аны мәгърифәткә әүвәл башлап адым салган, милләт өчен бәһа җитмәс әйбәт хәзрәт, дип атады.

Ш.Мәрҗанинең фәнни эшчәнлеге урысның укымышлы даирәләрендә дә югары бәя алды. Күренекле шәрекъ белгече академик В.В.Бартольд, мәсәлән, аны «татарлар арасында прогрессив агымга нигез салучылардан», дип атады. Ә Казан университеты профессоры Н.Ф.Катанов тарихчы галимнең «Мөстәфадел әхбары...» тарих һәм этнография ягыннан урыс теленә генә түгел, европадагы башка телләргә дә тәрҗемә итәргә лаек; монда автор Болгар һәм Казан патшалары турында төгәл һәм фәнни рәвештә яза» дип күрсәтеп үтә (Катанов Н.Ф. Известия общества археологии и истории... т.XIX, вып. 4, Казан, 1898, 47 б.).

Күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Садретдин Айни һәм таҗик профессоры Богоуддинов татар мәгърифәтче галименең Урта Азиядә иҗтимагый фикер үсешенә тәэсире зур булганлыгы турында да язалар. Аның шулай ук казакъ мәдәниятының күренекле вәкилләреннән булган Ахан-сере, Кунанбаев һәм М.Сералиннарның фикери үсешенә дә йогынтысы

бәхәссез. Соңгысы Ш.Мәрҗанины «халыкка хезмәт иткән олы шәхес» (Сералин М.Мәрҗани. «Айкап», 1915, №2.) дип характерлады. Мөхтәр Әуэзов Абай Кунанбаев әсәрләре җыентыгына кереш сүзендә, бу казакъ язучысы «беренче татар мәгърифәтчесе — яңалык кертүчесе булган Шиһабетдин Мәрҗанине яхшы белгән» (Кунанбаев Абай. Лирика и поэмы, М.1940, с.26) дип күрсәтеп үтте.

Ш.Мәрҗани үзен Россиядә генә танытмады. Көнчыгыш илләрендә дә һәм Көнбатышта да аны белә иделәр. Һәм аның турында һаман кызыксынып тордылар. London Publishina Kompany, мәсәлән, 1874 елның 30 мартында аңа энциклопедия өчен тәрҗемәи хәлен һәм фотосын җибәрүен сорап хат белән мөрәҗәгать итә. Аның белән Төркия, Тунис, Каһирә, Мәдинә, Һиндстан галимнәре дә кызыксынып торалар.

Ш.Мәрҗани кешенең гакылын һәртөрле рухи богаулардан коткару кирәклеген аңлап эш итте. Ул бөтен гомерен алгарыш (прогресс) идеаллары өчен көрәшкә, кешеләрнең дөньяны аңлавын киңәйтүгә һә рухи нурланышына багышлады. Ул милләттәшләре аңының ачылуы һәм янарышы турында хыялланды һәм бөтен көчен, иҗади сәләтен шушы хыялын тормышка ашыруга бирде. Шуңа күрә дә татар иҗтимагый фикере һәм мәдәнияты тарихында ул күренекле урын алып тора.

1997 ел.

РИЗА ФӘХРЕТДИНОВ — ГАЛИМ, ДИН БЕЛГЕЧЕ, МӘГЪРИФӘТЧЕ[1]

Риза Фәхретдинов — XIX йөз ахырында һәм XX йөз башында яшәгән күренекле тарихчы, журналист, педагог һәм әдип. Ул 1859 елның 4 январендә элекке Самара губернасының Бөгелмә өязе Кичучат авылында (хәзер Татарстанның Әлмәт районы) рухани гаиләсендә туа. Мәдрәсәне тәмамлагач берничә ел укытучылык итә, аннан мулла була.

1889 елда Диния нәзарәтенә казый булып сайлана. 1905 елгы революциядән соң үзен тулысы белән иҗат эшенә багышлый. 1906 елда Диния нәзарәтендә казый булып эшләүдән баш тартып, Оренбургка күчеп килә һәм «Вакыт» газетасында эшли башлый. 1908—1918 елларда, тәгәл ун ел, иҗтимагый-политик

4 3-473

һәм әдәби-нәфис «Шура» журналының җаваплы редакторы була. Аның педагогика, әдәби тәнкыйть һәм тарихка караган күпчелек мәкаләләре шул журнал битләрендә дөнья күрә.

Р.Фәхретдинов редакторлыгында чыккан «Шура» журналы үз вакытында татар-башкорт зыялылары арасында зур популярлык казана, ул шулай ук Урта Азия һәм Казахстан якларында да шактый киң тарала. «Шура» үз укучыларын алдынгы рус һәм дөнья культурасы казанышлары белән таныштырып бара. Журнал битләрендә М.В.Ломоносовның 200 еллыгы, Н.В.Гогольнең 100 еллыгы билгеләп үтелә. А.С.Пушкин, Л.Н.Толстой, А.П.Чехов һәм А.М.Горький турында мәкаләләр, Некрасов шигырьләре, шәрекъ культурасының әл-Фәраби, Ибне Сина, әл-Мәгарри, Сәгъди, Хәйям, Рабиндранат Тагор кебек вәкилләре турында материаллар басылып тора. Татар-башкорт укучылары журналдагы материаллар аша Аристотель, Сократ, Бэкон, Спиноза, Руссо кебек философларның фәнни карашлары белән дә танышалар. «Шура» журналында системалы төстә үсемлекләр һәм кеше организмының физиологиясе турында, Дарвин, Сеченов, Луи Пастер, Дж.Пристли, У.Гарвей, Ньютон, Торричелли кебек атаклы галимнәр хакында фәнни-популяр мәкаләләр һәм очерклар чыгып тора. Анда шул заман татар әдәбиятының Г.Тукай, М.Гафури, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, Ш.Бабич кебек күренекле вәкилләре языша.

Р.Фәхретдинов иҗтимагый аренага мәгърифәтчелек традицияләрен алга таба дәвам иттерүче бер зыялы булып күтәрелә. Бу аның 1889 елда язып, бастырып чыгарырга рөхсәт сорап Петербургка цензура комитетына җибәргән беренче фәнни хезмәтендә үк ачык күренә. Тик хезмәт, дөнья күрмичә, цензура архивында тоткарланып кала. Аңарда автор халыкның культурасына, милли уку йортларын үстерүгә, аларның эшен тәртипкә салу, яңа типтагы дәреслекләр булдыру, дөньяви фәннәр һәм матур әдәбият укытуга кагылышлы мәсьәләләрне кузгата. Кулъязмада шулай ук китапханәләр оештыру һәм газеталар чыгару мәсьәләсе карала. «Милләтне мәсгут итмәк исә, — ди ул, — аларга җиңел укытмак вә гүзәл кәсеп итеп байлык тапмак юлларыны күрсәтмәк илә, һөнәр вә сәнәгать илә улыр. Русча яхшы белмәгәндә боларны мәйданга куймак мөмкин дәгел идеге шөбһәсездер». Үзенең әсәрләрендә ул шәригатьнең консерватив нормаларын, караңгылык, томаналык, наданлык, схо-

ластика һәм фанатизм кебек күренешләрне кискен тәнкыйтьләп, хатын-кызларга тигез хокук таләп итеп, халык арасында фәнни белемнәрне һәм мәгариф эшен таратуны яклап чыга.

Дөрес, Р.Фәхретдинов буржуаз демократик лозунгларыннан югары күтәрелә алмый, «мөселманлык» бердәмлеген яклый, милләтнең үз эчендәге «партия талашларына» каршы була. Ул ярлы халыкның авыр тормышы хакында яза, шул чор тормышындагы әхлаксызлык күренешләренә каршы чыга.Әмма шул ук вакытта һич тә гамәлдәге капиталистик системаны гаепләми, ә бәлки, гуманист буларак, халыкның авыр язмышын кызгану белән чикләнә. Аның социаль карашларының чикләнгәнлеге илдә революцион үзгәрешләр барган көннәрдәге позициясендә дә, аерым алганда, совет власте дошманнарына исеме һәм абруе белән файдаланырга вакыт-вакыт кул куюында да күренә. Шул ук вакытта ул ак гвардиячеләр һәм контрреволюцион ак эмигрантлар лагерына кушылмый, халыктан аерылмый.

Р.Фәхретдинов дөньяга идеалистик караш йогынтысыннан арынып җитә алмый, вакыт-вакыт дингә мөрәҗәгать итә. Шул ук вакытта ул тормыш күренешләренә аек акыл белән карауны таләп итеп чыга, хорафатларга һәм ырымнарга ышануны тәнкыйть итә. Рационализм котылгысыз төстә аның дөньяга карашында стихиячел-материалистик һәм стихиячел диалектик тенденцияләрнең үзара үрелеп баруына китерә. Ул ислам дине тарафдары була, шул ук вакытта дини сабырлыкны һәм читләр фикеренә хөрмәт белән карауны алга сөрә.

1922 елда Р.Фәхретдинов Диния нәзарәтенең башлыгы — мөфти булып сайлана. Формаль төстә шул постны биләп торса да, ул төп вакытын фәнни эшләренә багышлый. Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген гомеренең соңгы көннәренә хәтле туктатмый. 1935 елда, үләренә күп тә калмый, ул: «Гомерне язу һәм язганны төзәтү өстендә уздырам», — ди. Ул совет учреждениеләре белән даими бәйләнештә тора. Аның 1925 елда тарихи һәм мәдәни истәлекләрне саклау хакында тәфсилле һәм нигезле төстә язылган хат белән Башкортстан хөкүмәтенә мөрәҗәгать итүе мәгълүм. 1925 елда Р.Фәхретдинов СССР Фәннәр академиясенең 200 еллык юбилеена багышлап Ленинградта уздырылган рәсми тантанага чакырыла. Анда баргач, академик Крачковский һәм башка галимнәр белән очрашып сөйләшә.

Аның танылган тюрколог А.Н.Самойлович белән хат алышып яшәве игътибарга лаек факт. Шул хактагы материаллар хәзер Салтыков-Щедрин исемендәге дәүләт китапханәсенең кулъязмалар бүлегендә саклана. 1930 елда А.Н.Самойлович аңа үз карамагындагы архив материалларын СССР Фәннәр академиясенә тапшыруын үтенеп хат белән мөрәҗәгать итә. Күренекле галимнең үтенечен искә алып, Р.Фәхретдинов Академиягә фундаменталь хезмәте булган «Асарь»ның чираттагы томнары өчен җыйган материалларын һәм архивында җыелган хатларын җибәрә. Хәзер ул кулъязмалар СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты Ленинград бүлегенең фәнни архивында саклана.

Тынгысыз галим Р.Фәхретдинов бик бай фәнни, әдәби һәм публицистик мирас калдыра. Аның күпчелек публицистик хезмәтләре «Вакыт» газетасында һәм «Шура» журналында басылган. Казан университетының фәнни китапханәсендә галимнең 46 китабы теркәлгән, әмма бу әле һич тә тулы исемлек түгел.

Р.Фәхретдиновның басылган әсәрләре арасыннан «Асарь» исемле библиографик хезмәте аеруча аерылып тора. 1900—1907 еллар арасында әлеге күптомлы хезмәтнең 14 кисәктән торган ике томы чыгып өлгерә. Әлеге фундаменталь хезмәтендә Р.Фәхретдинов мөһим тарихи вакыйгалар, күренекле мәдәният вәкилләренең тормыш юлы һәм иҗаты турында сөйли, культурагарту учакларына, әдәби һәм мәдәни истәлекләргә бәя бирә. Бу төп хезмәте буенча без аны галим итеп тә, тарих, әдәбият һәм мәдәният өлкәләрендәге тәнкыйтьче итеп тә күрәбез. Дөрес. китапта динне идеаллаштыру бераз сизелеп китә, әмма шул ук вакытта ул бик тә рәтен белеп наданлыкны, схоластиканы, суфичылыкны һәм ишанлыкны гаепләп чыга. Хезмәтнең төп кыйммәте — чыганакларга бай булуында. Аңарда татар һәм башка халыкларга караган тарихи, этнографик һәм әдәби материал зур пөхтәлек белән җыелып, ныклы тәртипкә салынган.

Р.Фәхретдиновның «Ислам динен тотучылар турында хөкүмәт карарлары» дигән зур хезмәте патша хөкүмәтенең татарларга һәм Россиядәге башка мөселман халыкларына карата уздырган политикасын өйрәнү өчен бүген дә бай чыганак булып тора. «Мәшһүр ирләр» һәм «Мәшһүр хатыннар» дигән хезмәтләрендә ул тарихта тирән эз калдырган мәдәният әһелләре, галимнәр, дәүләт эшлеклеләре хакында бай мәгълүмат туплап бирә.

«Мәшһүр хатыннар» дигән хезмәте җәмәгатьчелек фикерен хатын-кыз азатлыгы проблемасына юнәлтү ноктасыннан да мөһим роль уйный. Китапта хатын-кыз мәсьәләсе, дини мәсьәлә булудан бигрәк, социаль-экономик мәсьәлә дигән фикер уздырыла.

Гарәп галимнәре һәм сәяхәтчеләр Ибне Гарәбшаһ, Ибне Батутта, Ибне Халдун турындагы хезмәтләре Р.Фәхретдиновның бик тә кызыклы һәм үзенчәлекле ориенталист булы хакында сөйлиләр. Шунысы игътибарга лаек, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри һәм М.Акмуллаларның иҗади мирасы һәм эшчәнлекләре турында да беренче булып ул яза башлый.

Фәхретдинов калдырган кульязма фонд җитди игътибарга лаек. Салтыков-Щедрин исемендәге дәүләт китапханәсеннән һәм СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтының Ленинград бүлегенең фәнни архивыннан тыш, галимнең кульязмалары СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институты архивында тупланган. Уфадагы кульязмалар үзләре генә дә 40 томнан артык. Аларда татар халкының культурасы һәм атаклы мәдәният әһелләренә караган зур байлык тупланган.

Р.Фәхретдиновның редакторлык һәм нәширлек эшен дә билгеләп узмый булмый. Ул Ш.Мәрҗанинең сәяхәт материалларын («Рәхләтел әл-Мәрҗани» — 1898 ел) һәм «Исмәгыйль Бикмөхәммәтовның Һиндстанга сәяхәте»н аерым китаплар итеп әзерли һәм бастырып чыгара. Соңгысы 1967 елда Р.Фәхретдинов хәзерләп калдырган рәвештә рус теленә тәрҗемә итеп тә басылды.

Р.Фәхретдинов шактый бай әдәби мирас калдыра. Аның «Сәлимә» (1899) һәм «Әсма...» (1903) дигән повестьлары яна әдәбиятыбыз үсешендә мәгълүм бер эз калдыра, алар хәзер дә әдәбият дәреслекләрендә һәм хрестоматияләрдә үзләренә лаек урынны алып киләләр. Аның әдәби эшчәнлегенә бәя биреп Г.Тукай: «Ул (Риза казый — Я.А.) «Әсма», «Сәлимә» кеби китаплары белән куәм тәхририя вә хәтта шигъриясен күрсәткән вә гомуми ирадәсе ачык, язу тарызы садә вә гүзәл бер язучыдыр», ди. Р.Фәхретдиновның әдәби һәм журналистик эшчәнлеге белән М.Горький кызыксына. 1911 елда пролетариат язучысының инициативасы белән «Татар әдәбияты» дигән китап басмага хәзерләнә башлый. Бер татар язучысына җибәргән хатында М.Горький әлеге китапка Р.Фәхретдиновның тормыш һәм иҗат юлы турында материал кертергә тәкъдим итә.

Риза Фәхретдинов 1936 елда Уфада вафат була.

Р.Фәхретдинов фәнни эшчәнлегендә дә, әдәби иҗатында да сыйнфый чикләнгәнлек кысаларын ахыргача атлап чыга алмый. Ул дөньяга дини-идеалистик караштан да котыла алмый, методологик яктан исә, объективизм позицияләрендә кала. Шуңа да карамастан, Риза Фәхретдинов татар культурасы тарихында мөһим урын биләп тора. Татар халкының тарихын, культурасын һәм әдәбиятын өйрәнгәндә аның фактик материалга бай иҗат мирасын читләтеп узу мөмкин түгел.

1980 ел.

[1] 1979 елда З.А.Ишмөхәммәтовның «Социальная роль и эволюция ислама в Татарии» исемле китабы басылып чыкты. Автор китабында милли хәрәкәткә катнашкан дип дип әһелләрен, шул хисаптан Риза Фәхретдиновны да буржуаз милләтчелектә гаепләде, аларның иҗатларына һәм эшчәнлекләренә реакционлык мөһере сукты. Мондый бәяләмә хакыйкый тарихны белүчеләр, шул хисаптан Риза Фәхретдиновның туганнары арасында, зур ризасызлык уятты. Соңгылары З.А.Ишмөхәммәтовның уйдырмаларына протест белдереп партия үзәк комитетына хат яздылар. Хатта китапны чыгарган нәшриятка да, моңа юл куйган партия өлкә комитетына да гаепләү ташланган иде. Партия үзәк комитеты хатны мәсьәләне ачыкларга һәм җавап бирергә дип партия өлкә комитетына җибәрде. Өлкә комитетының ул вакытта идеология бүлеге мөдире Ю.Воронин мине чакырып китапта Риза Фәхретдиновка бирелгән бәяләмәгә карата белешмә хәзерләргә кушты. Мин хәзерләгән документта Риза Фәхретдиновның зур галим һәм мәгърифәтче булганлыгын, аның эшчәнлегенә һәм иҗатына берьяклы килергә ярамаганлыгын күрсәтеп үттем. Әмма мондый бәяләмә партия өлкә комитетындагы түрәне канәгатьләндермәде. Әңгәмә вакытында мин өлкә комитетына китапны аклый, ә Р.Фәхретдиновка тискәре бәя бирелгән белешмә кирәклегенә төшендем. Белешмә яңадан язарга дип миңа кайтарылды. Мин беренче вариантта әйтелгән фикерләремне яхшылабрак дәлилләп, яңа белешмә хәзерләп илттем. Ю.Воронинга бусы да ошамады. Мин белешмәне тагы да тулыландырып, яңадан да (инде өченче мәртәбә) Ю.Воронинга илтеп тапшырдым. Өлкә комитетында башка бу турыда минем белән сүз булмады.

Әйтелгән белешмәне мәкалә рәвешендә хәзерләп 1987 елда чыккан «Мәгърифәт нуры ачар...» дигән китабыма кертергә тырышып карадым. Әмма рецензентлар аны бу басмада урнаштыруны кулай күрмәделәр. Мәкалә әле торгынлык заманнарында ук мирасыбызны объектив рәвештә өйрәнүгә һәм бәяләргә омтылыш яшәгәнлеген күрсәтә. Бу басмага урнаштыру кулай күрелде.

ҺАДИ АТЛАСИ — ГАЛИМ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ[1]

Мең тугыз йөз бишенче елгы буржуаз-демократик революция Россия империясендәге халыкларның барлык катламнарын да дулкынландырып, кузгатып җибәрде, аларның социаль һәм милли аңнары үсүгә гаять зур этәргеч булды. Шул зур хәрәкәт дулкынында татар җирлегендә дә җәмәгать эшлеклеләренең, әдипләрнең, галимнәрнең, халык мәгарифе һәм культурасы эшлеклеләренең яңа буыны мәйданга чыкты. Чорында матбугатта исеме киң мәгълүм булган Һади Атласи — Һади Мифтахетдин улы Атласов (1876—1938) — әнә шул буынның бер вәкиле иде.

Мәгълүм җәмәгать эшлеклесе, тарихчы галим һәм халык мәгарифе хезмәткәре Һади Атласи 1876 елда Сембер губернасы Буа өязе Чәке авылында (Татарстанның хәзерге Чүпрәле районы) дөньяга килә. Башлангыч белемне туган авылында әтисеннән алгач, Һади укуын, ул вакытларда шактый билгеле булган Буа мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Кадим мәдрәсәдә бирелгән гыйлемнәр белән канәгать булмаган егет үзлегеннән белемен үстерү чараларын күрә: төрле фән нигезләрен үзләштерә, бик тырышып, рус һәм немец телләрен өйрәнә. Культура һәм фән казанышларын үзләштерүдә аңа Оренбург янындагы Сәгыйть бистәсендә (Каргалы авылы) укытучылар хәзерләү өчен оештырылган өчьеллык курсларда уку да мәгълүм күләмдә уңай йогынты ясый. Нәтиҗәдә Һ.Атласи татар укымышлыларының үз заманы өчен шактый киң карашлы, белемле вәкиле булып җитлегә. Төрле фән нигезләрен үзләштерү белән бергә ул, туган теленнән тыш, рус, немец, гарәп, фарсы һәм төрек телләрен дә яхшы белгән.

1898 елда Һади Атласи Буа мәдрәсәсенә мөгаллим-укытучы булып кайта һәм җиң сызганып уку-укыту эшләрен заман таләпләре югарылыгына күтәрү чараларына керешә. Моның белән ул уку-укытуның иске ысулларын яклаган хәлфәләрнең кискен ризасызлыгын тудыра. Озак та үтми, ул фән нигезләрен пропагандалау өлкәсендә дә беренче адымнарын ясый: «Гыйльме һәйәт» («Астрономия фәне») һәм «Тарихе табигый» («Табигать гыйлеме тарихы») кебек хезмәтләрен язып бастыра.

1903 елда Һ.Атласи Бөгелмә өязенең Әлмәт авылына имам һәм мөдәррис итеп чакырыла. Имамлык вазифасын үтәгән хәлдә ул иҗат һәм уку-укыту эшләре белән шөгыльләнүен,

публицистик әсәрләр язуын ташламый. Озакламый аның «Ахыр заман ишаны», «Идел буе», «Мәктәп һәм мулла» кебек әсәрләре дөнья күрә. Мәдрәсәдә ир балалар укыту белән бергә, ул кызлар өчен дә мәктәп ача.

Россиядә революцион хәрәкәтнең күтәрелеш елларында Һади Атласиның иҗтимагый-политик эшчәнлеге сизелерлек дәрәҗәдә активлаша. 1907 елда ул II Дәүләт думасына депутат булып сайлана һәм «Мөселман депутатларының зәхмәттәш фиркасе» — мөселман хезмәт фракциясе эшендә актив катнаша. Аның турыдан-туры катнашында Петербургта татарча «Дума» исемле газета чыга башлый. Бу газета агымдагы политик хәлләрне трудовиклар позициясеннән чыгып яктырта. Барысы алты саны дөнья күргән газета хөкүмәт тарафыннан ябыла.

1905 елның маенда хөкүмәт тарафыннан Россиянең Көнчыгыш өлкәләрендә яшәүче рус булмаган халыкларда мәгариф эшләренең торышы мәсьәләләре буенча махсус киңәшмә җыела. Киңәшмә карарлары нигезендә, мәктәптә укыту процессында рус булмаган халыкларның милли узаны уянуы һәм үсүне булдырмау, тоткарлау максатыннан чыгып, кагыйдәләр төзелә. Кагыйдәләр 1906 елның 31 мартында Мәгариф министрлыгы тарафыннан раслана. Атласи 1908 елда шул кагыйдәләрне тәнкыйть иткән «Яңа низам вә голямаларымыз» исемле әсәрен дөньяга чыгара. Кискен политик рухта язылган бу китап царизм һәм кадимче мөселман руханиларының халык мәгарифе өлкәсендәге политикасына каршы юнәтелгән иде. Шушы китабы өчен Һ.Атласи 1909 елда политик җавапка тартыла. Һәм өч айга төрмәгә хөкем ителә, шулай ук ул указлы мулла һәм башка рухани дәрәҗәләрдән мәхрүм ителә. Төрмәдән чыккач, полиция аны даими күзәтү астына ала. Аның тарафыннан оештырылган кызлар мәктәбе дә ябыла.

Нинди дә булса рәсми вазыйфалар башкару мөмкинлегеннән мәхрүм ителгән Һади Атласи үзен гыйльми, әдәби-публицистик һәм мәдәни-агарту эшләренә багышлый: фәнни хезмәтләр яза, «Йолдыз», «Вакыт», «Шура» кебек газета-журнал битләрендә публицистик мәкаләләр бастыра. Бераздан ул Әлмәттә яңа мәктәп ачып, җәдитчә, ягъни яңа ысул белән укыту эшләрен башлап җибәрә. 1921 елны Әлмәттәге совет власте вәкилләре тарафыннан бирелгән белешмәдә дөрес күрсәтелгәнчә, бу мәктәпне тәмамлаган укучыларның күпчелеге соңыннан совет мәктәбе

хезмәткәрләре, партия эшлеклеләре булдылар. Мәктәп житәкчесе буларак, Һади Атласи үзенең укучыларында халык арасында культура таратуга омтылыш тәрбияләде.[2]

Егерменче йөзнең унынчы елларында Һади Атласи үзен күренекле тарихчы итеп таныткан хезмәтләр яза. Мәсәлән, 1912 ел башында галимнең «Себер тарихы», ә 1913 елда Казанның соңгы ханбикәсе турында «Сөембикә. Тарихи хикәя» исемле очеркы басылып чыга. Гыйльми җәмәгатьчелек каршында үзен төпле, җитди тарихчы итеп таныта алган Атласи 1913 елда Казан университеты каршындагы «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте»нең хәкыйкый әгъзасы итеп сайлана. 1914 елда галимнең төп фәнни хезмәте булган «Казан ханлыгы» исемле зур китабы басылып чыга. Бу хезмәтенең фәнни әһәмияте хакында аның Совет чорында яңадан ике тапкыр (1920 һәм 1924 елларда) нәшер ителүе үк күпне сөйли булса кирәк. Һ.Атласиның тарихи хезмәтләре максат һәм концепция ягыннан оешкан, ә эчтәлеге җәһәтеннән исә бай булулары белән аерылып торалар. Тарихи тикшеренүләрендә автор татар, рус, гарәп, фарсы һәм төрек телләрендә язылган беренче кул тарихи чыганаклардан җыелган фактик материалларга таянып гамәл кыла. Бу уңайдан аның В.Н.Татищев, С.М.Соловьев һ.б. рус тарихчылары хезмәтләрен һәм шулай ук рус елъязмаларын яхшы белгәнлеге ачык күренә. Асылда ул — татар тарихчылары арасында XV—XVI йөз русча тарихи истәлекләрдән алынган күпсанлы материалларны беренчеләрдән булып фәнни хәрәкәткә кертеп җибәргән галим. Шуның белән беррәттән Һ.Атласи — аңа кадәр галимнәргә билгеле булмаган кыйммәтле татарча тарихи чыганакларны да фәнгә кертүдә зур тырышлык күрсәткән галим. Мисал рәвешендә, 1523 елны Сәхиб Гәрәй хан тарафыннан бирелгән тарханлык ярлыгын беренче тапкыр (1914 елда) матбугатта чыгару, Казан шәһәренең беренче рәсми исеме «Яңа Болгар» булуы хакында хәбәр итүче мөһим факт теркәлгән «татар елъязмасы»ның фарсы телендәге версиясен табу, тикшерү, шулай ук беренче булып «Ханәкә солтан» исемле тарихи бәетне бастырып чыгару һ.б. фактларны күрсәтергә мөмкин.

Тарихчының бу хезмәтләре үз вакытында ук көнчыгышны өйрәнүче рус галимнәренең дә игътибарын җәлеп иткән иде. Мәсәлән, күренекле ориенталист галим академик В.В.Бартольд

Һади Атласиның «Себер тарихы» һәм «Казан ханлыгы» дигән китапларына язган рецензиясендә, әлеге китапларда очраган кайбер текстологик кимчелекләрне һәм ялгышларны күрсәтү белән бергә аларның бәхәссез уңай сыйфатларын да билгеләп уза.[3] Һ.Атласиның бу китапларны «татар патриоты» позициясеннән торып язуын әдәпле рәвештә махсус искәртеп узгач, гадел хөкем йөртүче В.В.Бартольд, рецензияләнә торган хезмәтләрнең авторы XV—XVI йөз рус дәүләт эшлеклеләрен дә тиешле дәрәҗәдә объектив бәяләгән дип күрсәтә.

Бер үк вакытта шуны да әйтеп үтәргә кирәк: Һ.Атласи методологик яктан әле җитлекмәгән тикшеренүче буларак, татар ханлыкларының җимерелү сәбәпләрен социаль-экономик шартлардан түгел, бәлки аерым татар хөкемдарларының «бәла-казаларының» башын аларның алдан күрә алмаучанлыкларында, үзара ызгыш-талашларга батуларында һ.б. күрә. Әлбәттә, болары да булган һәм андый фактлар хакында рус һәм совет тарихчылары аз язмадылар инде. Ләкин болар асылында Казан ханлыгын җимерүче төп сәбәпләрнең үзләре булмыйча, дәүләтне шул һәлакәткә китергән социаль-экономик мөнәсәбәтләрнең нәтиҗәләре генә иде. Нәкъ менә шушы үзенчәлекле социаль-экономик мөнәсәбәтләр өлкәсендәге буталчыклыкның, таркалышның нәтиҗәсе буларак әлеге үзара ызгыш-талашлар, гауга-тартышлар илдә тамыр җәйгән, киң таралган иде. Вак буржуаз тарихчы буларак, Һ.Атласи әнә шул тирәндә яткан беренчел процессларга игътибар итмәде диярлек. Дәүләтләр, илләр тарихын ул бары тик политик тарих — ханлыклар, династияләр яки аерым дәүләт башлыклары тарихы рәвешендә генә бәян итә. Шунысы белән ул үз чорының башка буржуаз тарихчылары дәрәҗәсендә иде.

Һ.Атласи иҗатының характерлы тагын бер үзенчәлеген билгеләп үтәргә кирәк: беренче әсәрләрен ул гади татар укучысына авыр аңлашыла торган һәм шул вакыттагы кайбер әдипләр, галимнәр карашында «могтәбәр» саналган корама телдә язган, соңрак Һ.Атласи хезмәтләренең теле сөйләм теленә якыная төшә, ягъни күзгә күренеп халыкլаша. Әгәр Атласига мондый характердагы җитешсезлекләрдән котылу чагыштырмача җиңел бирелгән булса, вак буржуаз авторларга хас кайбер идеологик буталчыклардан котылу аңар, кызганычка каршы, гомумән, насыйп булмый диярлек.

Һ.Атласи энергияле һәм нәтиҗәле иҗатчы булу белән бергә татарлардагы вак буржуаз тарихи фикернең идеологик җәһәттән эзлексез һәм каршылыклы вәкиле иде. Аның эзлексезлеге фәнни иҗатында да, публицистикасында да чагылыш тапкан. Тарихчының хезмәтләренә методологик җитлекмәганлек, тикшерелә торган күренешләрнең объектив нигезен ачып бирә белмәү хас. Аның дөньяга карашында методологик яктан идеалистик күрсәтмәләр өстенлек итә, ә бу исә үз чиратында тарихи вакыйгалар турында фикер йөртүдә субъективлыкка китерә. Автор үз хезмәтләрендә бик тәмләп, тәфсилләп дигәндәй интим характердагы фактлар турында сөйли. Һәртөрле вак имеш-мимешләргә артык күп урын бирә. Тарихи чыганакчылык белеме күзлегеннән караганда, Һ.Атласи хезмәтләре өчен бер төр чыганакларның хәбәрләрен тәнкыйтьсез генә кабул итү, ә икенчеләренә исә, киресенчә, нигезсез рәвештә шикләнеп карау, ышанмау хас. Дөрес, бу өлкәдә ул бернинди дә үзгәреш, үсеш кичермәде дип әйтеп булмый. Соңрак язылган хезмәтләрендә Һ.Атласи, гомумән алганда үз чорының буржуаз тарихи чыганакчылык белеме дәрәҗәсенә күтәрелә яза. Көндәлек матбугат битләрендә аның хезмәтләренә карата бирелгән бәяләр нәкъ менә шул хакта сөйлиләр. Үз чоры өчен традицион, мәгълүм истәлекләрдән тыш, күптөрле яңа чыганакларны (хан ярлыкларын, тарихи риваятьләрне һ.б.) фәнни хәрәкәткә кертеп җибәрүдә галим биргән яңалыклар турында сөйләгәндә шуны да истә тотарга кирәк: Һади Атласи хезмәтләрен тарихи чыганакчылык күзлегеннән карап бәяләү — ул әле киләчәктә махсус тикшеренүне сорый торган мөстәкыйль мәсьәлә.

Һади Атласиның политик эшчәнлеге дә махсус тикшерүгә, бәяләүгә лаек. Аның политик эшчәнлеге һәм фәнни иҗаты арасында үзара бәйләнеш һәм тәэсир итешүне инкарь итмәгән очракта да, аларның бер-берсенә тәңгәл килеп бетмәүләрен дә истә тотарга кирәк. Һ.Атласи вак буржуаз политик эшлекле һәм вак буржуаз тарихчы иде. Тарихчы буларак ул эре буржуазия позициясенә якынрак торса, җәмәгать эшлеклесе хәлендә халык массаларына тартымрак иде. Мәсәлән, Һ.Атласи җәмәгать эшлеклесе сыйфатында кыска вакыт эчендә суллаша барган булса, тарихчы Атласи исә ике арада, урталыкта кала бирде дип әйтерлек.

Һ.Атласиның вак буржуаз эшлекләренә хас эзлексезлеге һәм каршылыклы шәхес булуы аның иҗтимагый-политик эшчәнлегендә аеруча ачык чагыла. Иҗтимагый-политик көрәш мәйданында ул крестьяннар мәнфәгатен чагылдыручы көрәшче буларак чыгыш ясый, әмма крестьян массаларының сыйнфый бүленешен исәпкә алмыйча, «гомум крестьяннар» мәнфәгатеннән чыгып эш итәргә тырыша. II Дәүләт думасына ул крестьяннар куриясе буенча сайланган иде. Дәүләт думасында да, трудовиклар рухында чыгыш ясый, үзен татар халкының вак буржуаз катламнары мәнфәгатьләрен яклаучы итеп таныта. Һ.Атласи патша хөкүмәте политикасын мөселман хезмәт ияләре исеменнән тәнкыйтьләде һәм бу мәсьәләдә трудовикларга теләктәшлек күрсәтте. Ул монархия һәм полиция режимының килешмәс дошманы булды. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач ул, аңа каршы чыгып, сугышны хезмәт халкы өчен бәлаказа дип бәяләде. Шул ук вакытта Һ.Атласи бу тенденцияне эзлекле рәвештә үстереп, аны буржуазия һәм алпавытлар строена каршы юнәлгән революцион көрәшне тану югарылыгына җиткерә алмады. Һади Атласи социалист-революционерлар партиясе члены иде. Дөрес, «сугыш һәм революция һәм буржуазия белән килешү» мәсьәләләрендә эсерлар политикасы белән килешмичә, ул соңыннан бу партиядән аерылды. Бер ук вакытта Һ.Атласи «РКП(б) программасының кайбер пунктларына» теләктәшлек белдерде. Шулай да ул тулысынча пролетариат партиялелеге позициясенә дә күчә алмады. Үзенең әйтүе буенча, ул эсерлар һәм большевиклар арасында бәргәләнде. Бер яктан ул «большевикларны, ә икенче яктан эсерларны яклый, ягъни һәр ике партия программаларының кайбер пунктлары белән килешсә дә, кайберләрен кире кага, икенче төрле әйткәндә, бу партияләр арасында урта линияне тотарга тырыша» (80, 131 битләр).

Һади Атласиның бу вак буржуаз эзлексезлеге, принципиаль линияне сайлый белмәве, буржуазия һәм алпавытлар строе белән хәлиткеч көрәш чорында — Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында үзен бигрәк тә ачык сиздерде. Бу вакытта ул тотрыксыз культура эшлекләренә хас позициядә торды. Февраль революциясеннән соң Һ.Атласи Бөгелмә өязенең Земство идарәсе һәм мөселман оешмалары составына керде, «Анда хезмәт ияләре ягында торып ачыктан-ачык буржу-

аз элементларга каршы чыгыш ясады» (29 б.). Ул Земство идарәсенең халык мәгариф бүлегенә җитәкчелек итте. Октябрь революциясе җиңгәч һәм совет власте урнашкач, Һ.Атласи Бөгелмә өязе советы составына кереп, аның башкарма комитеты члены булып сайланды, совет мәктәпләре өчен кадрлар хәзерләүне юлга салуда актив катнашып, яңа оештырылган дүртьеллык укытучылар семинариясендә укытты. Ләкин озак та үтми, контрреволюция баш калкыта, чехословаклар корпусы фетнә күтәрә. Совет органнары һәм хезмәткәрләре Бөгелмәне ташлап китәргә мәҗбүр булалар. Ләкин Һ.Атласи алар белән бергә китми, фетнәчеләр власте урнашкач, яңадан эшли башлаган Земство идарәсенә эшкә урнаша. Чехословаклар шәһәрдән киткәндә дә ул Земство идарәсенең башка членнары кебек Бөгелмәне ташлап чыкмый, бәлки шәһәргә кергән Кызыл Армия частьләрен каршылый һәм яңадан совет мәктәпләрен оештыру эшендә катнаша, укытучылар семинариясендәге эшен дәвам иттерә. Озак та үтми Бөгелмә өстендә яңадан болытлар куера, шәһәргә Колчак армияләре якынлаша. Кызыл Армия частьләре һәм совет хезмәткәрләре шәһәрне калдырып чыгалар. Ләкин, бу юлы да Һ.Атласи алар белән китми, бәлки Колчакны «иң рәхимсез рәвештә халык восстаниесен бастырган иң зарарлы элемент» дип санаса да, шәһәрдә кала бирә. Аклар аңа Земство идарәсенең эшен яңадан торгызырга тәкъдим итәләр. Һ.Атласи тәкъдимнән баш тарта. Әмма соңыннан, хәрби комендатура һәм гарнизон начальнигы басымы астында, ул Земство идарәсе җитәкчесе урынбасары булып эшләргә ризалык бирә, хәтта Россиянең «Гали идарәчесе»нә котлау телеграммасы да җибәрә, аклар шәһәрдән чигенгәндә ул да, алар белән китә. Ләкин беренче мөмкинлек туугач ул ак армия обозын ташлап кача. Чиләбедә аңа аклар армиясе контрразведкасында үзенең большевистик характердагы эшчәнлеге хакында материаллар тупланувы турында хәбәрләр ишетелә. Шуннан соң Һ.Атласи ашыгыч рәвештә хәрәкәт маршрутын көнчыгыштан көнбатышка таба үзгәртә һәм Троицк аркылы Бакуга килә. Баку советы Мәгариф комиссариаты нәшриятының төрки бүлегендә эшли башлый (81, 89 бб.). Һ.Атласиның бу аумакайлыгы, кыска гына, ләкин бик давыллы чордагы эшчәнлегенең зигзаглары аның вак буржуаз интеллигенция вәкиленә хас эзлексез һәм тотрыксыз позициясенең ачык үрнәге булып тора.

Әлбәттә, Һ.Атласиның ул вакытларда үз-үзен тотышын берьяклы гына бәяләп булмый, һәм ул хәзер зарури да түгел. Андый позиция революциядә «өченче юл» эзләүче күпләгән вак буржуаз демократлар өчен тупик күренеш иде. Мондый омтылышларның хыялый һәм политик яктан зарарлы булын тарих үзе исбат итте. «Кем белән барырга?» дигән сорауга өздереп җавап бирергә кирәк булганда бик күп вак буржуаз эшлекләләр, бигрәк тә аларның сул өлеше, һаман да әле революция һәм контрреволюция арасында бәргәләнүен дәвам итте. Әмма, аларның күпчелеге ахыр чиктә дөрес позицияне сайлый алдылар. Һ.Атласи да шулай ук төрле хаталар һәм икеләнүләр аша революциягә таба якынлашты, әмма, кызганычка каршы, ахырына кадәр аны дөрес аңлау дәрәҗәсенә барып җитә алмады.

Соңгы елларда дөнья күргән кайбер хезмәтләрдә Һ.Атласига Бөгелмә өязе Колчак гаскәрләре кулында калган чорда совет хезмәткәрләрен һәм укытучыларын эзәрлекләүдә катнашу кебек гаепләр тагылды. Әмма бу гаепләүләр нигезсез, чөнки алар тарихи документлар белән расланмыйлар. Киресенчә, архив документлары Һ.Атласиның ак чехлар фетнәсе һәм Бөгелмәдә Колчак гаскәрләре хуҗа булган вакытта, үзенең эш урынынан файдаланып, мөмкин булган кадәре совет хезмәткәрләрен контрреволюция тырнагыннан саклап калу өчен тырышуы хакында сөйлиләр. Мәсәлән, Һ.Атласи үлем вагонына ябылган РКП(б) члены, Бөгелмә өязе башкарма комитеты председателе Закир Исхаковны акларның контрразведкасы кулыннан коткарып кала һәм качарга булыша (39, 81, 82, 86 бб.). Өяз комитетының агитация-пропаганда бүлеге мөдире, РКП(б) члены С.Рахманкулов, халык мәгарифе бүлеге инспекторы С.Уразмановлар да аклар контрразведкасы тырнагыннан шул ук Һ.Атласи ярдәмендә коткарылалар (23, 37, 40, 82, 86 бб.). Бөгелмә шәһәренең ятимнәрне тәрбияләү эшләре комиссары, ә өяздә беренче совет газетасы булган «Бөгелмә мөхбире»н оештыручыларның берсе, РКП(б) члены З.Гыймазетдинов аклар контрразведкасыннан Һ.Атласи өендә яшеренеп ята (43, 44, 81, 82 бб.). Һ.Атласи татарлар арасындагы контрреволюцион хәрәкәтнең идеологы, хәтта аның җитәкчеләренең берсе булган дигән кайбер раслауларның да нигезсез икәнлеген архив материаллары ачык дәлилллиләр.

20—30 елларда Һади Атласи актив рәвештә совет мәктәпләрендә укытучылык эше белән шөгельләнде. 1921 елдан 1929 елга кадәр Бөгелмә шәһәрендәге икенче баскыч мәктәбендә тарих һәм немец теле, ә утызынчы елларда исә Казанда немец теле укытты. Замандашлары аның татар мәктәпләре өчен педагогик кадрлар хәзерләүгә керткән өлешен тәкъдир итәләр һәм бу өлкәдәге эшчәнлеген югары бәялиләр.

Күп еллар буе Һ.Атласи көнчыгыш халыклары һәм төрле илләр тарихы буенча төрле телләрдә язылган өч меңнән артык китапны, шул исәптән рус, татар, фарсы һәм гарәп әдәбиятлары классикларының әсәрләрен үз эченә алган уникаль китапханә туплый. 1925—1928 елларда Һ.Атласи фарсы әдәбияты җәүһәре — Сәгъдинең «Гөлстан»ын татарчага тәрҗемә итә.

Бу әйтелгәннәрдән без Һ.Атласиның актив иҗат иткән бай мирасы һәм бер үк вакытта татар вак буржуаз интеллигенциясенең үтә каршылыклы, эзлексез бер вәкиле булганлыгын ачык күрәбез. Әлбәттә, ул буржуаз милләтчелек идеологиясе йогынтысыннан да азат түгел иде. Шул ук вакытта аны, кайвакытлардагы кебек, контрреволюцион хәрәкәтнең әйдәп баручы идеологы яки җитәкчесе итеп күрсәтүнен дә кирәге юк. Киресенчә, фактлар мондый раслауны кире кагалар. Безнең каршыга ул үзенчә намуслы һәм үзенчә халыкка тугрыклы интеллигент буларак килеп баса. Һ.Атласи — халык мәгарифе һәм татар тарихи фикерен үстерүдә үзеннән билгеле күләмдә өлеш керткән галим һәм җәмәгать эшлеклесе. Шул ук вакытта аны тәмам калыплашып җиткән мәгърифәтче итеп сурәтләргә дә җитәрлек нигез юк. Һ.Атласи — Россия чынбарлыгының катлаулы революция алды һәм революция чорының татар җирлегенә хас вак буржуаз мохиты вәкиле булды һәм ахырга кадәр шулай булып кала да. Ул күп тапкырлар ялгышты, адашты, икеләнде, кискен тайпылышлар ясады, әмма ахыр чиктә, совет чынбарлыгына килде һәм калган көчен, сәләтен-тәҗрибәсен совет мәктәбен үстерүгә, яңа культура төзелешенә бирде.

[1] Мәкалә тарих фәннәре докторлары, профессорлар (хәзер академиклар) М.Г.Госманов һәм И.Р.Таһиров белән бергә язылды.

[2] ТАССР ҮДА, 779 ф. 3 тасв. 33 эш, 65 бит. (Алга таба бу эшнең бит саннары текстта җәяләр эчендә күрсәтеләчәк).

[3] Записки Восточного отделения Русского археологического общества, т.XXIII, вып.III—IV, 1916, 421—422 бб.

1985 ел.

Г.ТУКАЙ: ХАЛЫК ЯЗМЫШЫН КҮЗ АЛДЫНДА ТОТЫП

Прогрессив татар иҗтимагый фикере XX йөзгә мәгърифәтчелек идеаллары байрагы астында керде. Фикер ияләренең яңа буыны тулаем шул йогынты астында иде әле. Әмма XX гасыр башы социаль каршылыкларның чиктән тыш кискенләшүе белән характерлана. Империализм эпохасына керү сыйнфый изүне көчәйтүгә, хезмәт халкының хәерчелегенә илтә. Идел буе һәм Урал тирәләрендә — татар халкы тупланып урнашкан милли окраинада — социаль изү милли изүнең дә көчәюе белән бергә үрелде. Илдә революцион көрәш җәелә. Бу шартларда, бөтен Россиядәге шикелле үк, татарлар арасында да марксистик-ленинчыл идеяләр ныклы тамыр җибәрә, социал-демократик пропаганда җәелә. Россия социал-демократларының турыдан-туры йогынтысы астында татарлар арасында революцион-демократик идеология формалаша. Г.Тукай, Ф.Әмирхан, М.Гафури, Г.Камал, Ш.Мөхәммәдов, революциягә чаклы Г.Ибраһимов бу идеологиянең күренекле вәкилләре булалар. Н.Думави белән С.Рәмиев тә аларга якын тора.

XIX йөз мәгърифәтчеләрен Г.Ибраһимов насыйрилар дип атады. Алар арасында Г.Курсави, Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, Ш.Күлтәси шикелле зур фикер ияләре, яңа татар әдәбиятын башлап җибәрүчеләрдән М.Акъегет-задә, З.Бигиев, Г.Ильяси, Ф.Халиди була. Каюм Насыйри исә арада аерылып торганнарыннан санала. Аның эшчәнлегендә һәм иҗатында мәгърифәтчелек идеологиясенең эчтәлеге үсешенең характерлы тенденцияләре һәм социаль асылы шактый тулы һәм ачык чагылыш таба. Аның иҗаты — халык өметләренең, феодаль-патриархаль мөнәсәбәтләр тышауларыннан котылырга омтылуының чын гәүдәләнеше.

Г.Ибраһимовка ияреп, без XX гасыр башындагы прогрессив культура һәм иҗтимагый фикер эшлеклеләре плеядасын тукайчылар дип атый алабыз. Г.Тукай XX йөз башындагы прогрессив татар культурасының һәм революцион-демократик хәрәкәтнең иң күренекле вәкиле иде. Аның иҗатында хезмәт кешеләрен эксплуатациядән һәм изүдән коткарып, социаль гаделлек һәм тигезлек җәмгыятенә бару, кан кардәшләрен социаль изүдән коткару идеаллары бик калку гәүдәләнеш тапты.

Г.Тукай һәм аның фикердәшләре иҗатының аерымлыклы сыйфатларыннан берсе дикъкатьне социаль-политик проблемаларга туплау булды һәм аларның мирасы үзләреннән алдагы этапта иҗат ителгәннәрдән шуның белән аерылып тора. XIX йөздә, мәгърифәтчелек идеяләре таралу чорында, беренче планга философик проблематика чыга. Бу урта гасырдан калган дини тәгълиматларны аргументлы тәнкыйтьләү зарурлыгы һәм иҗтимагый прогресс юлына киртә булган дини идеологиянең катып калган формаларыннан арыну кирәклеге белән аңлатыла. Тукайчылар социаль каршылыкларның соңгы чиккә җитеп кискенләшкән һәм самодержавие-капиталистик стройга каршы революцион көрәш көчәйгән дәвердә иҗат итәләр. Социаль-политик проблематиканың беренче планга чыгарылуы шуның белән аңлатыла. Социаль тигезсезлек, сыйнфый катлаулану, байлыкның бер кулларга тупланып, икенчеләрнең хәерчеләнүе, хезмәт кешеләренең эксплуатацияләүгә каршы көчле протесты Г.Тукай һәм аның көрәштәш-фикердәшләре иҗаты аша кызыл җеп булып сузыла. Яшьлегендә язган «Шәкерт, яки бер очрашу» дигән шигырендә Г.Тукай болай ди:

«Бу дөнья, бел, ярлылык дөньясыдыр.
Вакытлы бер хурлык дөньясыдыр».

Тормышта өлешсезләргә теләктәшлек итү мотивы акрынлап хосусый милек хакимлек иткән дөнья каршылыкларын ачык аңлау дәрәҗәсенә үсә. 1911 елда язган «Көзге җилләр» шигырендә шагыйрь:

«Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил жылый:
Җил җыламый, ач үлемнең куркусыннан ил җылый.
— Иң сөекле эшче әүладым быел ач калды, — дип
Изге, шәфкатьле анабыз — мәрхәмәтле җир җылый.
Куйса монда корткалар төшкән тешен алтын белән,
Бер телем икмәк дип анда назлы нечкә бил җылый!»
— ди.

«Сафия» (1911) һәм «Толстой сүзләре» (1913) шигырьләрендә Г.Тукай мал-мөлкәтлеләрнең иминлеге изелгән ярлылар өлеше икәнен басым ясап әйтә:

«Тәмле булганга гаҗәпләнмә бу байлар ашлары,
Күп вакыт борчы, тозы — мискин гидайлар яшьләре».

Татар иҗтимагый фикере үсешенең үзеннән алда булган этабындагыга караганда Тукай иҗатында тагын бер яңалык шул: шагыйрь промышленность эшчеләренең аяныч тормышын һәм бихисап авыр хезмәтен күрсәтә. «Кярханәдә» (1909) шигырендә (кярханә — завод, фабрика мәгънәсендә) автор фабрика һәм заводларда эшләүчеләрнең хезмәтен тәмугка тиңли, ут һәм төтеннән тын алыр хәл юклыгын тасвирлый, эшчеләрнең йөзләре саргаеп, күзләре нурсызланып калганын яза. Әлеге мотив «Казан» шигырендә тагын да саллырак яңгыраш таба:

«Ут, төтен, фабрика-завод берлә һаман кайный Казан;
Имгәтеп ташлап савын, сау эшчеләр сайлый Казан».

Г.Тукай әсәрләрендә социаль мөнәсәбәтләрне тәнкыйтьләү өзлексез рәвештә политик тормыш проблемаларын яктырту белән үрелеп бара. Крепостнойлык һәм аннан соңгы чорда иҗат иткән мәгърифәтчеләр исә киң планда политик проблемаларны тикшерергә кыймыйлар иде. Алар, күп дигәндә, татарларның үзидарә органнарындагы кимчелекләр турында сүз алып баралар һәм чиновникларның чамадан чыккан гамәлләрен тәнкыйтьләп фикер йөртәләр иде. XX йөз башы татар культурасының прогрессив вәкилләре илдә революцион хәрәкәт җәелгән һәм самодержавие кризис кичергән шартларда киң даирә политик проблемалар күтәрәләр. Г.Тукай җирле үзидарә органнарының һәм үзәк властьның эшчәнлеген тәнкыйть күзлегеннән анализлый. Законсыз хәрәкәтләре һәм башбаштаклыклары белән халык массаларын интектергән патша бюрократиясе һәм чиновниклары аның аяусыз тәнкыйтенә дучар булалар. Фикер иясе булган шагыйрь дәүләт властенең сыйнфый ролен күз алдына яхшы китерә, байлар мәнфәгатен яклаган эчке һәм тышкы политиканың нечкәлекләренә төшенә. Бу җәһәттән ул тәрҗемә иткән «Мөхарәбә вә Государственная Дума» һәм «Петр бабайның хикәяте» дигән хезмәтләре мөһим, аларда социал-демократик идеяләр үткәрелә. Шагыйрь ул хезмәтләрдә патша администрациясенең бер төркем эшкуарларны баету өчен тырышуы, патша чиновникларының алпавытлар иминлеген саклап, ачка интеккән крестьяннарның гөнаһсыз зар авазларын да гаскәр һәм казаклар көче белән бастыруын фаш итә.

Г.Тукай публицистикасында Дәүләт думасына сайлаулар мәсьәләсе зур урын алган. «Фикер» газетасында һәм «Әлгасрел-җәдит» журналында басылган мәкаләләрендә баштарак думаның патша администрациясен тезгенләвенә беркадәр өмет сизелә, соңга таба исә Думада чын халык вәлилләре булмасына төшенүе, аның да бай сыйныфлар мәнфәгате сагына басачагын аңлавы күренә. Ә беренче Дәүләт думасын таратуга мөнәсәбәтен Г.Тукай «Государственная думага» дигән шигыре белән белдерә. Бу шигырь шагыйрьнең Дума турындагы иллюзияләренең челпәрәмә килүен раслый.

«Думаның хәле» дигән мәкаләсендә Г.Тукай икенче Дәүләт думасындагы «халык вәкилләре»нең һичнәрсә хәл итә алмауларын, патша властена ялагайлануларын әйтеп, аларның хәлен мәче тырнагына эләккән тычкан хәленә тиңли.

Г.Тукайның политик карашлары диапазонын аңлау өчен аның рус-япон сугышына, шулай ук Триполитан һәм Балкан сугышларына мөнәсәбәте бик характерлы. «Мөхарәбә вә Государственная Дума» дигән хезмәтендә ул империалистик державалар арасындагы каршылыкларны тикшерә, рус-япон сугышының шул каршылыклар нәтиҗәсе икәнен әйтә. Россиягә күз яше һәм кан, өзелгән гомерләр һәм гариплэнгән солдатлардан, толлар һәм ятимнәрдән башка һични бирмәгән, бары тик бер төркем капитал хуҗаларына миллионнар михнәтеннән байлык сыгу мөмкинлеге генә биргән сугышның асылын Г.Тукай ачык аңлый. Ул шулай ук Италиянең хезмәт халкына бәла-каза гына китергән Триполитан сугышын да гаепли. «Тегеннән-шуннан» мәкаләсендә Балкан сугышларының мәгънәсезлеген күрсәтә.

Заманының социаль-политик мәсьәләләрендә тоткан позициясе Тукай иҗатының революцион-демократик характерын дәлилли. Ул социаль тигезсезлекне һәм халыкны изүне, җәмгыятьнең политик системасын тәнкыйтьләп кенә калмый, халык җилкәсендә сорыкорт булып яшәүчеләргә, искелек көчләренә каршы революцион көрәш бурычын да куя. 1906 елда ук әле «Сорыкортларга» дигән шигырендә халыкны феодаль-патриархаль кысада тотарга тырышкан, яңалыкны яралгысында ук буып атарга омтылган көчләр белән исәп-хисапны өзәргә чакыра.

1905—1907 елгы революция социаль каршылыкларның бөтен тирәнлеген ачты, шуның нәтиҗәсендә Г.Тукайның да революцион көрәш зарурлыгы турында фикерләре ныгый барды. Аның 1907

елда язылган «Тартар кош сайрый», «Тавыш хакында», «Тормыш» шигырьләрендә азатлык хакына көрәшкә чакыру яңгырый. «Тавыш хакында» шигырендә, мәсәлән, мондый юллар бар:

«Эшче туган! Тартыш кирәк, кирәк тартыш,
Тартышмаган эшчеләргә бик батар теш;
Изге эштер тартышмаклык хокук өчен,
Тартыш, эшче! Тартыш, зинһар, тартыш, тартыш!»

Шагыйрьнең революцион демократизмы социалистик идеал белән өретелгән. «Сорыкортларга» шигырендә үк инде ул «минем чын мәсләгем — юлым бөтенләй социаллардай» дип язган иде. 1906 елда «Фикер» газетасында (17 декабрь) бастырган «Һәркимиң кәнничә вардыр ля мөхаль эндишәси» мәкаләсендә ул социализмның азаккы максат икәнен әйтә.

Г.Тукай һәм аның фикердәшләренең мирасындагы революцион идеяләренең үткенлеге, барыннан да битәр, феодаль-патриархаль искелеккә каршы юнәлтелгән иде. Әмма XX йөз башы Россиясе шартларында ул капиталистик мөнәсәбәтләргә каршы да юнәлтелә. Үз чорының гаделсезлекләренә төп сәбәп итеп алар буржуаз мөнәсәбәтләрне, куәтле капиталны һәм хосусый милекне саныйлар.

«Читен тормыш! — капиталга чукынмасаң,
Хәзрәтеңдә тезләр чүгеп укынмасаң;
Тор, рәхәтлән, кәп-кәкрене туры дисәң,
Истибдадның (деспотизм) намусына тукынмасаң»

(«Дөньяда торыйммы? — дип киңәшкән дустыма»).

1907 елда реакция һөҗүмгә күчә, революция кимүгә бара. Самодержавие революцион халык һәм аның авангарды — пролетариат тарафыннан яуланган хокук һәм азатлыкларны кире талый, прогрессив интеллигенцияне, демократик матбугатны эзәрлекли. 1905 елда гомуми энтузиазм дулкынында революциягә ияргән күп кенә буржуаз эшлекләләр көрәштән читләшәләр, үз эчләренә бикләнәләр, яисә контрреволюция лагерына күчәләр.

Тукай исә шул шартларда да социаль һәм милли тигезлек өчен көрәшүчеләрнең алгы сафында кала, үзе сайлаган юлдан кыю барасын белдерә. «Татар яшьләре» шигырендә ул революциянең киләчәгенә зур ышаныч һәм өмет белән каравын әйтә.

«Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары,
Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары».

Революцион-демократик идеологиянең тууы һәм үсүе татар иҗтимагый фикере үсешендә мәгърифәтчеләрнең социаль прогресс эволюциясе концепциясеннән революцион концепциягә сикереш иде. Революцион-демократик идеологиянең формалашуына китергән тирән процесслар марксизм-ленинизмның турыдан-туры йогынтысында барды һәм бу хәл татар революцион демократларының таләпләре эчтәлегендә чагылмый кала алмады, аларның социаль-политик программасының характерын билгеләде.

Г.Тукай һәм аның фикердәшләренең иҗатында һәм эшчәнлегендә аерымлыклы сыйфатларының берсе бик ачык чагылган антиклерикализм иде. Бу — яшисен, яшәп, җәмгыять аягына бәйләгән ташка әверелгән, социаль һәм милли прогресска киртә булган консерватив динчеләр һәм дини учреждениеләргә каршы көрәш зарурлыгын шарт иткән сыйфат. Антиклерикализмның мәгълүм элементлары мәгърифәтчеләр мирасында ук бар иде инде. Алар да консерватив карашлы мөселман дине башлыкларының җәмгыять тормышында яңага омтылуга чамадан тыш тупас каршы чыгуларын гаепләделәр. XX йөз башының прогрессив фикер ияләре бу башлангычны дәвам иттерделәр һәм яңа баскычка күтәрделәр. Аларның антиклерикализмы киң масштаблы булуы һәм реакцион динчеләргә каршы килешмәс көрәш белән аерылып тора.

Г.Тукай киң колачлы эшлекле иде. Хатларының берсендә ул С.Рәмиевка болай дип язды: «Мин бит синең шикелле саф, коеп куйган поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит». Талантының шундый күпкырлы булуы белән Тукай үз халкының культурасы һәм иҗтимагый фикере тарихында җуелмас эз калдырды.

1985 ел.

ДУМАВИНЫҢ ДӨНЬЯВИ УЙЛАРЫ

Татар әдәбияты тарихында егерменче гасырның башы аерым бер урын, үзенчәлекле урын алып тора. Бу хәл 1905—07 еллар революциясе тәэсире белән аңлатыла. Нәкъ менә шушы чорда татар халкының озак еллар дәвамында җыйнала,

туплана килгән куәтле рухи энергиясе тышка бәреп чыгу мөмкинлеге ала. Нәкъ менә шушы елларда татар халкының иҗтимагый аңында, фәлсәфи һәм социаль-политик карашларында, әхлакый-этик, эстетик фикерләрендә тирән сыйфат үзгәрешләре барлыкка килә. Күп санлы татарча газет-журналлар пәйда була, татар китабының саны һәм тиражы нык арта. Мәктәп-мәдрәсәләр тормышында да зур үзгәрешләр күренә, программаларга дөньяви фәннәр кертү буенча яңа адымнар ясала, әдәбият, татар һәм рус телләрен укытуда яңалыклар була. Милләтнең күп санлы прогрессив культура эшлеклеләре, журналистлар, педагоглар пәйдә булу һәм милли театрның барлыкка килүе татар иҗтимагый тормышында гаять мөһим роль уйный.

Соңгы елларда бездә гасыр башы культура мирасын өйрәнү буенча шактый гына эшләр эшләнә башлады. Ул чорның тарихи вакыйгаларын һәм әдәби процессын яктыртучы, күренекле шәхесләрнең тормышына, эшчәнлегенә һәм алар калдырган мираска багышланган мөһим монографияләр басылып чыкты. Шулай ук Г.Тукай биш томлыгының, Г.Ибраһимов сигез томлыгының, Ф.Әмирхан һәм М.Гафури дүрт томлыкларының, Г.Камал өч томлыгының басылып чыгуы да гасыр башындагы культура үрнәкләрен пропагандалау өчен мөһим күренеш булды. Дәрдмәнд белән С.Рәмиев әсәрләренең дөнья күрүен җәмәгатьчелек шулай ук җылы кабул итте. Ниһаять, без кулыбызга Нәҗип Думавиның сайланма әсәрләрен дә алдык. (Думави Нәҗип. Тормыш сәхифәләре. Шигъри әсәрләр һәм проза. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1985. Төзүчеләре Зөфәр Рәмиев һәм Резеда Ганиева).

Н.Думави әсәрләренең сирәк басылуын без инде беләбез. Алар сугыштан соң беренче мәртәбә 1960 елда дөнья күргән булса, бусы — икенче шундый вакыйга. Яңа басмага тегесендә булмаган 50 шигырь кертелү белән бергә проза әсәрләре дә тәкъдим ителгән. Шуңа күрә безнең алда Н.Думавиның дөньяга карашларын һәм әдәби-эстетик фикерләү рәвешен аңлау өчен материал күбрәк. Алар Н.Думавиның татар әдәбияты тарихындагы ролен ачыграк аңларга булышалар.

Егерменче гасыр башы татар әдәбиятында Н.Думави бик тә үзенчәлекле фигура. Аның иҗат юлы вакыт ягыннан алганда әлләни күп елны колачламаса да, ул юлда мөһим борылышлар

һәм көтелмәгән үзгәрешләр шактый күп. Иҗатында нинди генә яңа тенденцияләр чагылса да, барыбер халык, милләт һәм аның киләчәге турында уйлану шагыйрь өчен иң төп мотивлардан булып кала. Әдипнең андый уйлары иң калку булып «Замана хәле шулай» исемле шигырьдә чагыла:

Адәмнең кирәкләре хәддин ашкан,
Мәшәкать (нужа) илә тулып ташкан;
Сугышкач табигатьле гадәләтсез,
Золымлык гадәләтне бөгеп баскан.
Күрә алмый хәкаикьны ачык итеп.
Хакыйкать аның өчен ерак качкан.
Никадәр күрмәсә дә гаҗәп түгел,
Өйрәнгәч караңгыга кече яшьтән.
Шулкадәр авыр хәзер — гомер итү
Уңаймас төзәтмичә яңабаштан.

1905—07 еллар революциясен Н.Думави шатланып каршылый. Бу чорда ул изелгән хезмәт кешесен яклап, патша самодержавиесенә каршы күп кенә шигыйрьләр яза. Шагыйрьнең яна китабын ачып җибәргән «Революция заманы» шигырендә ул болай яза:

Дулкынланды океаннар бу көннәрдә,
Болганадыр күңелләр һәм бу көйләрдә;
Талпыналар мәмләкәтнең кораблары, —
Сизенмәсәң, батып китәр бөтенләй дә.
Үзлегеннән күтәрелде ачы җилләр,
Атып бәрә корабларны ничә милләр.

Алга таба китсәк, «Без дә файдаланыйк» дигән шигырь белән очрашырбыз. Анда шагыйрь үзенең милләттәшләренә мөрәҗәгать итә, аларны башка халыклардан калышмаска өнди, беренче революция биргән мөмкинлекләрдән файдаланып калырга чакыра, гомум кешелек хокукларыннан файдалану кирәклеген искәртә. «Яз. Күзне ачып карыйк әле» дигән шигыйрьнең идея эчтәлеге дә әнә шундый.

Революцион вакыйгалар куера башлаган елларда шагыйрь, Чистайдагы мөгаллимлеген калдырып, Урал ягына китә. Ләкин изге эшен биредә дә ташламый, шахтерларның балаларын укыта. Яңа мохит шагыйрьнең үзенә дә нык тәэсир ясый, аның социаль яктан өлгерүенә булыша. Тормыш тәҗрибәсе арту ачык чагылган шигырьләрнең берсе — «Җир күмере казучылар».

Ничә сажин җир астында пәриләр күк бәреп-ватып,
Казыймыз ташкүмер, руда, чүгеп һәм түш илә ятып...
Белеп булмый: бу базларны казыймыз без бәхеткәме,
Яхуд үз гәүдәмез өчен чыгалмаслык ләхеткәме?...
Атнаның алты көнендә күренми безгә көн йөзе,
Керәмез таң илә бергә, чыгамыз кич кышын-көзе...

Әнә шундый төгәл тасвирланган социаль күренешләр шагыйрьнең башка әсәрләрендә дә еш очрый башлый. Мисал өчен «Бер бай», «Заман хәлен...» дигән әсәрләрне атап күрсәтергә мөмкин.

Гуманист шагыйрь буларак, Н.Думави авыр хәлдәге хезмәт кешесен чын күңелдән кызгана. Ләкин ул моның белән генә дә канәгатьләнеп кала алмый. Үз әсәрләрендә шагыйрь катгый килешмәүчәнлеген дә белдерә. «Эч поша, күңел болгана», «Замана хәле шулай», «Җәй дә бетте, көз дә җитте» әнә шундыйлардан.

«Гарьлек» дип аталган шигырьдә ярлы кешенең тормышы, язмышы психологик яктан бик төгәл табылган сүзләр аша укучыга җиткерелә. Искиткеч түбәнлеккә төшкән хезмәт кешесен кызгану шигъри әсәрләрдә генә түгел, чәчмә әсәрләрдә дә төп тема булып бара. «Габдулла» һәм «Ике мәхәббәт» дигән хикәяләр әнә шундыйлар.

Ул чор тормышын чагылдырырга теләп, Н.Думавиның тоткынлык темасына, тоткын образына мөрәҗәгать итүе бер дә юкка түгел. Яңа китапта дистәдән артык әсәр менә шушы гайре табигый хәлне төрле яклап ачуга, күрсәтүгә багышланган. Чөнки В.И.Ленин тарафыннан «халыклар төрмәсе» дип йөртелгән Россиядә тоткынлык, коллык тойгысы бик күп халыкларга хас иде. Н.Думавиның шигырьләре бу хисне бик ачык гәүдәләндерә:

Давыл, кар, боз, суык-салкын һавасы,
Ябык, хур, кайгылы һәрбер баласы.
Хәбес (төрмә), богаулар һәм богаулар,
Кылыч, мылтык, револьверлы кагаулар.
Караңгы, һәр кеше монда бәхетсез,
Бәхетсезлек малик монда тәхетсез.

Ул чордагы татар әдәбияты һәм сәнгате эшлеклеләре арасында Россиядәге политик стройны, патша властенең деспотизмын, дәүләт думасының көчсезлеген, аның хезмәтчел халык өчен нәрсә дә булса эшли алуы мөмкин түгеллеген

Н.Думави сыман ачы итеп тәнкыйтьләүчеләр күп булмый. Бу яктан бигрәк тә шагыйрьнең «Государственная думага хитап» дигән шигыре һәм «Безләр нишлибез?» исемле публицистик мәкаләсе аерылып тора. Шулай ук «Үтте, үтте...», «Тавыш» һ.б. шигырьләрдә дә политик мотивлар өстенлек итә, хезмәт халкын һәртөрле җәберләүләр өчен, меңләгән кешеләрне каторгага сөрүләр өчен, гаепсезгә коелган кан өчен, гөнаһсызларның күз яшьләре өчен патша хакимиятенең гаепле икәнлеге раслана.

Ләкин шагыйрь монда патшаның үзен генә гаепләп калмый. Ул капиталны гаепләүгә кадәр барып җитә. «Эч поша, күнел болгана» шигырендә әлеге фикер мондый юллар аша белдерелә:

Кая баксаң, жулап ага
Фәкыйрь кардәшләрем каны,
Атылмышлар, киселмешләр, —
Һаман бер туктамый шул хәл;
Исең китәр хисапласаң.
Ниһаятьсез моның саны.
Түгел бер патшада бу хәл.
Бөтен дөнья тулып Дәжжал;
Икенче сүз илә: ошбу —
Капитал дәүренең жае.

Гади кешеләрнең тырышып һәм намус белән хезмәт итеп тә, гаять авыр хәлдә яшәүләре өчен капиталның һәм патша властеның гаепле икәнлеге әсәрдә бик ачык әйтелгән. Ә инде «Мәхәббәтме, рәхәт, шатлыкмы кирәк?» дигән икенче бер шигырьдә автор шул фикерен тагын да ныграк үстерә: капитал һәм акча хакимияте кеше тормышының кадерен киметә, аның тәнен һәм җанын сату-сатылу объекты итә, дип белдерә. Патша Россиясенең политик строен һәм капиталистик мөнәсәбәтләрне гаепләгән әсәрләр Н.Думавиның бу китабында һәм, гомумән, иҗатында шактый урын били. Шагыйрь иҗтимагый стройны тулаем гаепләү белән генә канәгатьләнми, аның максаты — үз халкын, татар милләтен бәхетле итеп күрү, Европаның алдынгы халыклары кебек үсештә итеп күрү. Ә моның өчен иң беренче чиратта актив эшчәнлек һәм көрәш соралганын яхшы белә шагыйрь. «Иҗтиһад», «Тырышмак», «Ник йоклыйсың син, агай» һ.б. байтак шигырьләрнең эчтәлеге әнә шул хакта сөйли.

Ул чорда үсешне тоткарлаучы иҗтимагый тәртипләр Г.Тукай белән Ф.Әмирхан һәм башка алдынгы фикерле иҗатчылар әсәрләрендә дә тәнкыйть ителә. Искелеккә каршы көрәш кирәклеге дә актив рәвештә раслана. Н.Думавиның да күп кенә әсәрләре алар фикеренә аваздаш. Биредә бигрәк тә «Иделгә» һәм «Күңел белән бәдән» шигырьләрен күрсәтергә була. Ләкин, яшәп килүче җәмгыятькә карата байтак кына тәнкыйть фикерләре булса да, иҗтимагый үзгәреп кору мәсьәләсенә килгәндә шагыйрь әле мәгърифәтчелек карашларында тора. Милләт алдындагы мөһим мәсьәләләрне хәл итү юлларын эзләгәндә исә XIX гасырда яшәгән мәгърифәтче галим Шиһабетдин Мәрҗани образы аның өчен юл күрсәтүче маяк булып хезмәт итә. Рухи остазына багышлап, шагыйрь «Шиһабетдин Мәрҗани кабере янында» дигән шигырь дә яза.

Бүтән мәгърифәтчеләр кебек ук, Н.Думави да кешенең акылына һәм белеменә дан җырлый. Укыган кеше җәмгыятьнең кысан шартларында да үзен иректә сизә алачак, азатлык идеалларыннан үзенә көч табачак. Иң куркыныч төрмә — таш капчык түгел, ә наданлык, караңгылык. Халыкның начар хәле турында борчылмау, уйланмау — шулай ук коллык галәмәте. Бу хакта шагыйрь «Гафильнең» дип аталган шигырендә җитди сүз алып бара. Биредә татар халкын изеп торучы деспотлык һәм караңгылык кискен гаепләнә.

Караңгылыктан һәм артталыктан чыгу юллары турында уйлану шагыйрьне кабат-кабат шуңа алып килә: моның өчен татар халкының заман культурасына һәм заманча белемгә ия булуы сорала. «Бер вәлидәнең балаларга нәсихәте», «Карлыгачның балаларга әйткән сүзләре» дигән әсәрләр укучыга нәкъ әнә шул фикерне сеңдерә. Ләкин биредә дә, аң-белем кирәклеге турында сүз алып барганда, шагыйрь тормыш чынбарлыгыннан аерылмый. Ул чорның мәктәп-мәдрәсәләрендәге реаль хәлне дөрес аңлый. Кадими мәдрәсәләрне «Кемнәр ничек», «Иске мәдрәсә җимеше», «Мулла булам, мулла булам», «Сихерле тамчылар» әсәрләрендә тәнкыйть утына тота. Кайбер әсәрләрендә исә шагыйрь татарның белем бирү системасын камилләштерү, аны тормышка ныграк якынайту турында уйлана. Чорның, милләтнең рухи һәм гамәли ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә мәктәп һәм мәдрәсәләрне мөһим бер баскыч итеп саный. Дөнья культурасының алдынгы сафлары белән тигезләнү юлында шагыйрь милләт улларына берләшү кирәклеген дә искәртә.

Н.Думави иҗатын бәяләүдә төрле тенденцияләр яши һәм бер-берсенә каршы килүче фикерләр әйтелә. Ә элеккерәк елларда исә бу иҗат тулысынча кара төстә генә яктыртыла иде. Кайбер тикшеренүчеләр шагыйрь язганнарны халыкка каршы эш дип тә күрсәтергә тырыштылар.

Әлбәттә, Н.Думави иҗатының үзендә дә каршылыклы урыннар бар. Бу аның дөньяга карашы шундый булуы белән һәм шагыйрьнең шәхси язмышының борылышлары белән аңлатыла. Чөнки 1905—07 еллар революциясен зур өметләр һәм куаныч белән каршылаган Н.Думави реакция чорын бик авыр кичерә, еш кына күңел төшенкелегенә бирелә. Аның бу чорда язылган әсәрләрендә ышаныч югалу һәм өметсезлек авазлары да мул яңгырый. 1908—10 елларда язылган әсәрләрдән, мәсәлән, «Яз үтеп, җәйнең дә башы...», «Дөньяга ачы хат», «Мәхбус. Дөньяда төннәр узып...», «Себер төрмәсендә тәрәзә рәшәткәсенә кунган кошны күреп...» «Юану», «Бу да бер киңәш»ләрдә андый мотив көчле чагыла. Хәтта әле мондый күңел төшенкелеге соңрак язылган шигырьләрдә дә күренә («Караңгы, кап-кара болыт» — 1908 ел, «Мотлак фарыз, мотлак фарыз» — 1912 ел, «Үтә яшьлек» — 1913 ел, һ.б.). Әсәрләрнең кайберләрендә чынбарлыктан качарга тырышу мотивлары да чагыла.

Ләкин шагыйрь үз күңелен биләп алган мондый халәттән котылырга тырыша, тирән рухи эзләнүләр белән яши. Шул чорда марксистик әдәбият һәм Ленин хезмәтләре белән танышу аңа терәлештән чыгу юлларын табарга булыша. 1911 елда төрмәдә утырган чагында ул К.Маркснын экономик теориясе белән таныша һәм Г.В.Плеханов хезмәтләрен укый. Ләкин вак буржуаз даирәсеннән чыккан шагыйрь бу тәгълиматны барыбер тулысынча кабул итә алмый.Үзенә рухи маяк эзләп, шагыйрь дөнья әдәбияты классиклары һәм рус язучылары әсәрләрен укый, көнбатыш илләрен биләгән фәлсәфи агымнар белән мавыга. Аның әсәрләрендә еш кына очраган Н.Гоголь, А.Пушкин, М.Лермонтов, Ф.Достоевский, А.Чехов, Л.Андреев һәм башкаларның исемнәре әнә шул хакта сөйли. Шулай ук аңа Л.Толстой белән М.Горькийның да билгеле бер тәэсире була. «Дөнья кайчан ислах булыр?» һ.б. әсәрләре шуңа мисал. Үткән чорлар фикер ияләреннән шагыйрьгә Сократ, Бэкон, Локк, Декрат, Руссо, Кант, Дарвин өйрәтмәләре дә якын һәм таныш була. Дөрес юл эзләп, ул Шопенгауэр

белән Ницше фәлсәфәләренә дә мөрәҗәгать итә. Ләкин шагыйрь боларның берсеннән генә дә үзенең рухын канәгатьләндерерлек тулы җаваплар таба алмый. Ул икеләнү һәм шик тулы эзләнүләрен давам итә. Бу китапта урын алган «Серле тамчылар» хикәясе сыман әсәрләр шундый рухи эзләнүләр нәтиҗәсе булып тора.

Иҗатының башлангыч чорында Н.Думави да, замандашлары Г.Тукай һәм Ф.Әмирхан кебек, кадими рухтагы мөселман руханияларын кискен рәвештә тәнкыйтьләп чыга. Аларның дин турында кайгыртмауларын, ә үз мәнфәгатьләрен генә алга сөрүләрен камчылый. Биредә сүз бара торган китапта әнә шундый эчтәлектәге «Вөждан», «Хөррият булмаса», «Ишан» һ.б. шигырьләр бар. Ләкин шунысы игътибарга лаек: беренче рус революциясе җиңелеп, илдә реакция чоры башлангач, шагыйрь иҗатында шактый сизелерлек борылыш була. Ул элекке позицияләреннән китеп, Алла һәм кеше тәкъдире, язмыш хакында дини уйлануларга якыная. «Мәэюскә», «Корьән», «Үзгәрү», «Сәҗдә» һәм «Җир кортлары» дигән шигырьләрне әнә шулар рәтенә кертергә мөмкин. Шул ук вакытта шагыйрь андый уйлар кысасыннан чыгу кирәклеге хакында да шактый нык уйлана. 1912 елда язылган «Газраил яки оҗмах көткәндә» шикелле әсәрләрендә инде ул үзенең элеккеге антиклерикаль идеяләренә кайтып төшә диярлек була. «Хәзерге заман» белән «Газраил»дә бу тенденция тагын да көчлерәк.

Н.Думавиның иҗади мирасында кеше проблемасы төп урыннарның берсен алып тора. Ләкин әлеге проблеманың иң мөһим өлеше — кеше белән җәмгыять арасындагы мөнәсәбәт мәсьәләсе шагыйрь иҗатында үзенә дөрес чишелеш таба алмый. Н.Думави өчен кеше шәхесе үзе генә, ялгызы гына яши. Иҗтимагый тормышның стихияле көчләренә каршы кеше бер ялгызы гына каршы тора. Кешене адым саен явызлык, гаделсезлек сагалый. Ләкин алар барысы да иҗтимагый мөнәсәбәтләр җимеше итеп түгел, аерым-аерым кешеләрнең аерым эш-хәрәкәтләре итеп карала. Мисал өчен 1912 елда язылган «Кем гаепле?» хикәясен алыйк. Әсәрнең төп образы итеп тасвирланган Нәгыймә — көчле рухлы һәм тормыш, яшәү турында ныклы үз фикере булган кеше. Ләкин әхлакый бозык бер кеше тарафыннан аңа карата ясалган әшәкелек Нәгыймәнең бөтен тормышын боза. Әле тагын шунысы бик мөһим: үзенә килгән бәла белән

Нәгыймә бер ялгызы кала. Тора-бара үз язмышын бозган кешедән үч алырга карар кыла. Ул аңа күңеленнән үлем карары чыгара. Һәм үзе үк моны чынга да ашыра.

Зур тормыш күренешләре арасында кешене ялгыз итеп тасвирлау «Мортый илә Мукай» хикәясендә дә күзгә бәрелә. Бу инде индивидуализм фәлсәфәсен алга сөрү. «Яшь күңелгә» шигыре андый нәтиҗәне тагын бер кат раслый. «Җир йөзендәге тәртипләрне кешелеклерәк итү турында хыяллану — буш хыял» — ди төсле безгә шагыйрь. Кеше бары тик үзенең холкын, табигатен үзгәртү турында гына уйлый ала. Сүз уңаеннан әйтеп үтик: шагыйрьнең моңа охшаш фикерләре элеккерәк еллар иҗатында да күзгә ташлана иде. Мәсәлән, 1906 елда язылган «Вөждан» шигырендә шагыйрь шундыйрак фикер үткәрә — кеше иҗтимагый тормыш кануннары буенча яшәргә тиеш түгел, аңа үз вөжданы юнәлеш күрсәтергә тиеш.

Н.Думавиның нык ышануынча вөждан — кешенең бердәнбер хакиме һәм юл күрсәтүчесе, рухи юлдашы. Менә мондый уйлары шагыйрьне тора-бара Лев Толстой идеяләренә алып килә. Ягъни, дөньяны камилләштерү өчен иң элек кешенең үзен яхшыртырга кирәк, дигән фикергә. Думавиның андый уйлары 1912 елда язылган «Дөнья кайчан ислах булыр?» исемле шигырьдә ачык чагыла.

Унынчы еллардагы Н.Думави иҗатына күз салсак, без анда романтизм агымының нык кына көчәеп китүен күрәбез. Бу чорда шагыйрьнең «Юкка үлде», «Алла тигезли»« «Болгар кызы Тойгы туташ» дигән романтик рухтагы шигырьләре языла. Ул елларның байтак кына хикәяләре дә шул рухта иҗат ителгәннәр. Шагыйрь ул чорда үз халкының үткәнен дә күбрәк романтик буяулар аша, романтик төстә күрә. Шәрекъның идеалистик фәлсәфәсендә ул юл күрсәткеч маяк булдырдай көч күрә, көнчыгыш халыкларының Чыңгыз хан шикелле шәхесләрен зурлый. Шундый омтылыштагы әсәрләрдән шагыйрьнең «Бер мөляхәзә», «Шәрекътан Гарепкә мөнәсәбәте белән» һәм «Шәрекъ даһие» дигән шигырьләрен күрсәтергә мөмкин. Н.Думавиның бу шигырендә алга сөрелгән андый идеяләр үз вакытында Җамал Вәлиди тарафыннан хаклы рәвештә тәнкыйть ителделәр.

Шагыйрьнең дөньяга карашлары системасында кешенең табигать белән мөнәсәбәте аерым урын алып тора. Н.Думави җәмгыятьне камилләштерү, аны яхшы якка үзгәртү ысуллары

хакында сүз барганда сыйнфый көрәштә һәм революциядә әллә ни өмет күрми. Халык алдына килеп баскан проблемаларны хәл итү юлларын ул табигатьтә һәм аның кануннарын үзләштерүдә күрә. Ә җәмгыятьтәге тигезсезлекне ничек бетерергә? Шагыйрь уйлавынча, табигать моңа бик яхшы җавап бирә — анда гармония, камиллек. Менә шушындый идеяне раслаучы шигырьләр дип түбәндәгеләрне күрсәтергә була: «Акчарлак» (1913), «Бездә җәйге таң», «Җәйге айлы төн», «Айлы төн» (1914), «Чишмә», «Җәйге төндә» (1915), «Җәйге таң» (1916). Чәчмә әсәрләрдән «Юкка үлде» һәм «Дөнья китабы» хикәяләрендә дә Н.Думави табигатьтәге камиллекне кешелек җәмгыятендәге начарлыкларга каршы куя, ә «Хәрибә» дигән әсәрендә исә гомумән дә кешелек җәмгыятен вакытлы гына бер күренеш дип саный, аннан үзгә буларак, табигатьтәге мәңгелек гүзәллеккә дан җырлый. Кеше табигать кануннарын аңларга һәм шуларны истә тотып эш итәргә тиеш, дигән фәлсәфәне тагын да ныгыта.

Үз иҗатында кеше проблемасын язганда Н.Думави антропологик фәлсәфәгә тартым фикерләр үткәрә. Әлбәттә, табигать матурлыгын гына алга сөргәндә, аңа гына табынып яшәгәндә моның шулай буласы алдан ук билгеле иде. Үзенең байтак кына әсәрләрендә шагыйрь табигый мәхәббәт тойгысын бик югары күтәрә, аны кешеләргә яктылык һәм яшәү чыганагы бирүче буларак данлый, мәхәббәтне тормыш пычрагыннан азат булган илаһи бер башлангыч итеп күрә. 1914—16 елларда язылган «Мәхәббәт», «Син кая, әй, син кая...» һәм «Шәркыям» әсәрләре әнә шуның гүзәл үрнәкләре.

Табигый гармониягә һәм кешедәге табигый башлангычларга, әлбәттә, татар демократик культурасының башка әһелләре дә зур әһәмият бирәләр иде. Ләкин Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов һәм М.Гафури кебек әдипләр, шагыйрьләр бу мөнәсәбәттә ары таба китеп, үзләренең карашларын социаль күренешләргә таба юнәлтәләр һәм революцион-демократик нәтиҗәләргә киләләр.

Н.Думави исә еш кына очракларда көчле шәхесне данлауга, индивидуализмга һәм иррационализмга килеп чыга. Бу яктан караганда аның «Хакыйкать эзләгәндә» исемле хикәясе кызыклы (Әлеге хикәя инглиз язучысының әсәре нигезендә иҗат ителгән). Әсәр герое итеп алынган егет танышлары белән конфликтка керә дә, алар тарафыннан эзәрлекләнә башлагач,

гаиләсе белән бергә джунглига кача, шунда яши башлый. Ул кыргый шартларда яшәп, табигый гармониягә ирешеп, үз күңеленә канәгатьләнү һәм тынычлык таба. Н.Думави уйлавынча да шулай: табигать белән дус һәм тату яшәү — кеше өчен иң зур бәхет. Һәр хакыйкатьне дә бары тик табигатьтән генә эзләргә кирәк. Кешеләр арасында дөреслек юк. Анда берәүләр икенчеләр өстеннән хакимлек итә, кеше һәм бөтен нәрсә сатыла. Анда уйлап чыгарылган абруйларга сукырларча ышану яши һәм бүтән төрле җитешсезлекләр күп. Шуның өчен тормыш дөреслегенә бары тик табигатьтән генә өйрәнергә мөмкин. Ләкин табигать серенә акыл белән дә, хисләр аша да ирешеп булмый. Хисләр безне алдый, ә акылга субъектив хаталанулар хас. Һәр кеше үзенә ошаган әйберне генә дөрес дип санарга күнеккән... Шулай итеп, Н.Думави иррационализм яссылыгына килеп чыга. Кеше үзенең әйләнә-тирәсен интуитив рәвештә генә тоярга мөмкин, дигән фикергә килә. Аның уйлавынча, кеше аңына һәм акылына буйсынмый торган көчләр генә хакыйкатькә таба алып бара ала, биредә кешенең пычранмаган эчке дөньясы, тойгылары гына ярдәм итә ала. «Алла тигезли» дигән хикәясендә Н.Думави иррациональ көчләрне явызлык тудыруда төп гаепле итеп аңлата. Янәсе, кешеләргә бәхетсезлекне алар алып килә... Шундый карашлар әдипнең мәкаләләрендә дә алга сөрелә.

Н.Думави иҗатын шушы кыска гына мәкалә аша күзалларга тырышканда да аның, катлаулы һәм каршылыклы иҗат юлы, эзләнүләрендәге фәлсәфи һәм эстетик борылышлар ачык гәүдәләнә. Аның карашларына тотрыклык һәм эзлеклелек җитми. Бу Н.Думавиның вак буржуаз демократка хас карашларыннан килеп чыга. Ләкин, шул ук вакытта, мондый хәл татар милләтенең үзенең ул чактагы халәте белән дә аңлатыла иде. Беренче революция нәтиҗәсендә әле генә уянган халык массалары арасында рухи һәм фәлсәфи эзләнүләр юлында булучыларның күплеге гаҗәп түгел. Н.Думави әнә шундый эзләнүчеләрнең берсе иде.

Ләкин, иҗади юлы ничек кенә катлаулы һәм каршылыклы булмасын, Н.Думави халкы белән һәрчак бергә атлады, үз әсәрләрендә аның уйларын һәм хис-кичерешләрен чагылдырды. Н.Думави әсәрләрендә без авыр хәлдә яшәүче хезмәт кешесенең аһ-зарлы авазын да, яшәп килгән тәртипләрне кире

кагуны да, караңгылыкка һәм артталыкка каршы чыгуны да күрәбез. Икенче төрле итеп әйткәндә, аның иҗади эзләнүләре һәм рухи омтылышлары татар халкының социаль һәм милли изүдән котылырга теләү һәм омтылышлары белән тәңгәл килә иде. Бу — халыкның һәм аның бер улының алдынгы халыклар, культура ягыннан югары үскән милләтләр белән тигезләшергә теләве иде. Экономикада, фәндә һәм культурада алар белән бер сафка басарга теләү иде бу.

Н.Думави үз халкының бәхетле киләчәгенә ышанып иҗат итә. Аның бу ышанычы 1906 елда язылган «Замана хәле шулай» һәм «Китәчәк иске дөньяга яңа дөньяның сүзләре» шигырьләрендә генә түгел, ә аннан соңгы елларда язылган, хәтта күңел төшенкелеге чорында язылган әсәрләрендә дә чагыла. 1915 елда иҗат ителгән «Әкрен-әкрен сүнә кичке шәфәкъ» шигырендә ул мәсьәлән болай ди:

Купкә бармас тарлык, сабыр ит, җан!
Ләгънәт орма, бизмә дөньядан!
Уйнар күктә матур энҗе-мәрҗән,
Калкып чыгар матур тулган ай!
Шунда инде менә бетте коллык
Күзе ачык һәрбер җаннарга;
Әтраф ачык, чиксез киң бер тынлык —
Ник очмыйсың әллә кайларга!

1915 һәм 1916 елларда басылып чыккан «Җәйге айлы таң» шигырендә дә шуңа тартым оптимистик аһәңнәр яңгырый.

Әйе, Н.Думавиның иҗат юлы сикәлтәле була. Ләкин бернинди сикәлтә дә, текә борылыш та аны кешегә ышанудан, аның рухи көченә ышанудан ваз кичтерә алмый. Үзенең иҗади юлы башында ул кешегә һәм аның көченә дан җырлаудан, аның мөмкинлекләренә сокланудан башлаган булса, бу ышанычын ул гомер ахырына кадәр саклап калды. Хәтта шагыйрь өчен иң авыр булган 1914 һәм 1915 елларда иҗат ителгән «Тормыш һәм мәхәббәт» белән «Бир яшен — тел, әй фәләк!» шигырьләрендә дә шагыйрь һаман да кешегә ышана, аның бетмәс-төкәнмәс көч чыганагына ия булуын әйтә. 1916 елда Н.Думави хәтта турыдан-туры «Син кеше» дип исемләнгән шигырь дә иҗат итә.

Бирмә серне, бул гали — типсен йөрәк зурлык белән!

Булма мәхзун — сынма төшенкелек белән, хурлык белән!
Бирмә тезгенне кара көчләргә — булма кол кеше!
Бул — батыр! Бул — нык кеше! Бул — ир кеше!
Бул — хөр кеше!
Син беләмсең синдә күпме көч барын, куәт барын?
Тип, очыр бу дөньяның барлык кара куәтләрен!
Син — бөек! Салган ходай күктән сиңа үз орлыгын.
Бул — гали! Таптама зинһар шул «ходайлык» зурлыгын!

Үзе дә рус-япон сугышында һәм империалистик сугышта катнашкан Н.Думави андый явызлык күренешләрен җаны-тәне белән кӱралмый, сугышны кара көчләр ихтыяры дип саный. 1908 елда язылган «Сугыш» шигырендә шагыйрь сугышны — халык өчен кан һәм үлем, ә армиядәге түрәләр өчен дан һәм дәрәҗә алу чарасы дип карый. Шул ук вакытта Н.Думави сугышны Алла һәм дин исеме белән акларга теләгән поплар һәм муллалардан ачы көлә. Кешелекнең бер өлешен юк итәргә чакыручы «фәнни» теорияләргә дә гуманист шагыйрь каршы чыга. 1916 елда язылган «Агач аяк» хикәясе кешене рухи һәм физик гарипләндерүче, юк итүче сугышка көчле нәфрәт белән сугарылган. Шул ук елны язылган «Сугыш тәэссораты» шигырендә исә яу кырында ныклыкка, кыюлыкка чакыручы юллар да бар. Бер ук вакытта әсәрдә сугышларның мәгънәсез кан кою икәнлеге дә ачык һәм тәэсирле итеп әйтеп бирелә. Чөнки анда бер гаепсез кешеләрнең җаны кырыла, каны коела.

Кычкырмачы, карга баш янымда,
Китче, зинһар, миннән арырак!
Күрмисеңме канны як-ягымда,
Куллар мәҗрух, тездән юк аяк!

Н.Думави иҗаты яңа чор татар әдәби телен үстерүдә дә зур роль уйный. Билгеле булганча, бу эшкә узган XIX гасырда Габделҗаббар Кандалый мөһим өлеш керткән иде. Һәркем аңлый ала торган телдә язылган шигъри әсәрләр ул чорда татар шигъриятен чынбарлыкка якынайттылар. Аннан соңгы чорда әлеге тенденция К.Насыйри, Г.Ильяси, Ф.Халиди иҗатлары аша тагын да үстерелде. Ә инде XX гасыр башында халык шагыйре Габдулла Тукай иҗаты белән бу юлда яңа һәм зур адым ясала. Аның чордашлары Г.Камал,

5 3-473

М.Гафури, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимовларның да әлеге процесстагы өлеше әйтеп бетергесез зур. Биредә С.Рәмиев, Ш.Камал, Ш.Мөхәммәдев исемнәрен дә онытa алмыйбыз.

Хәзер без тикшерә торган шагыйрь дә үз иҗаты белән татар әдәби телен формалаштыруда, аны халыкның тормышчан сөйләм чынбарлыгына якынайтуда зур эш башкарды. Әлбәттә, Н.Думави әсәрләрендә кайчак җирле сөйләш үрнәкләре очрый, ләкин тулаем алганда алар XX гасыр башында әдәби норма буларак кабул ителгән һәм хәзер дә кулланышта булган телдә язылганнар.

Үзенең иҗат юлындагы һәм язмышындагы күп төрле борылмалар аша булса да, Н.Думави үзенең милләте, аның ирекe һәм киләчәге турында уйлап яшәде һәм иҗат итте. Иҗатының бөтен тамырлары аша гади халык белән нык бәйләнештә яшәгән һәм язган шагыйрь язмышы, әлбәттә, бүтәнчә була да алмый иде.

1987 ел.

Г.ИБРАҺИМОВ: ФИКЕРИ ҺӘМ ИҖАДИ ЭВОЛЮЦИЯСЕ

Галимҗан Ибраһимов (1887—1938) иҗади эшчәнлегенең беренче адымнарыннан ук үзен олы язучы һәм тирәннән уйланучы галим-мөтәфәккир итеп күрсәтте. Әле 1909 елда ук яңа гына иҗади эзләнүләр юлына баскан Галимҗан «Борынгы ислам мәдәнияты» исеме белән үзенең беренче фәнни хезмәтен бастырып чыгара. Аның бу хезмәте бай мәгълүмат туплануы һәм куелган проблемаларның чишелеше ягыннан Европада бу мәсьәлә буенча соңрак чыккан күп, кенә хезмәтләр белән янәшә тора. Милләт балаларын ана теле буенча укытуның хәле, фәннилек дәрәҗәсендә торган дәреслекләрнең булмавы уңаеннан борчылган яшь галим татар теленең грамматикасы буенча китаплар яза. Үзенең «Әдәбият мәсьәләләре» (1910 ел), «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (1911 ел) һәм башка хезмәтләре белән ул үзен тирәнтен фикер йөртүче әдәбият белгече итеп тә таныта. Ә «Без татармыз» (1911 ел), «Без кем бәхәсе» (1912 ел), «Яңа әсәр» (1911 ел) дигән хезмәтләре яшь Г.Ибраһимовның тарихи мәсьәләләр белән дә кызыксынуы һәм аның йөзендә бу өлкәдә тирән эзләнүләр

алып барырдай галим формалашуы турында сөйлиләр. «Галлей киткәннән соң» (1910 ел) дип исемләнгән мәкалә аның киң планлы укымышлы буларак формалаша баруын, фән тарихын һәм аның хәзерге проблемаларын яхшы белеп фикер йөртүен күрсәтә.

Бу чордагы иҗатында Г.Ибраһимов әле мәгърифәтчелек позицияләрендә торып фикер йөртә. Бу бәяләмә аның фәнни хезмәтләренә дә, публицистик әсәрләренә дә, әдәби иҗатына да кагыла. Аның ул вакыттагы иҗади эшчәнлегенең нигезендә рационализм фәлсәфәсе, ягъни кеше акылын фәнни фикерләүнең хәлиткеч чыганагы дип бәяләү ятты. Бу уңайдан Г.Ибраһимовның «Аурупа философы Декарт һәм аның нотыгы» (1909 ел) дигән хезмәте игътибарга лаек. Яшь галимнең бу әсәрендә француз философының «Метод турында уйланулар» дигән хезмәтенә анализ бирелә. Моны фәлсәфи фикерләүләр юлына баскан Г.Ибраһимовның үзенең эзләнүләрендә XVII гасырның фәлсәфәдә рационализм юлы тоткан олы философына якын позициядә торганлыгын күрсәтүче дәлил, дип аңларга кирәк.

Шулай да иҗтимагый үсешне мәгърифәтчеләр позициясендә торып аңлау һәм аңлату, бу позициянең фәлсәфи нигезе булган рационализм кысалары яшь галимне тора-бара канәгатьләндерми башлый. Ул яңа кыйблалар, яңа фәлсәфи-методологик адымнар эзли башлый. Мөтәфәккир буларак та, җәмәгать эшлеклесе буларак та Г.Ибраһимовның позициясендә эволюция күзәтелә башлый. Иҗтимагый-сәяси җәһәттән алганда бу эволюция революцион-демократизмга, ә фәлсәфи яктан тирәлеккә, аның объектив хасиятеннән карап фикерләүгә юнәлдерелгән иде. Яшь Ибраһимовның фикери эзләнүләренең эволюциясенә этәргеч ролен илдә социаль каршылыкларның кискенләшүе һәм революцион хәрәкәтнең күтәрелүе, шул хисаптан татар җәмәгатьчелеге кысаларында социаль антагонизмнарның торган саен ачыграк яңгыраш алуы үтәде. Бу очракта Г.Ибраһимовның рус культурасы, В.Г.Белинский, Н.Г.Чернышевский, Д.П.Писарев кебек рус революцион демократларының фикери мирасы белән танышуы да үзенең ролен уйнады. Һәм, ниһаять, Г.Ибраһимовның революцион хәрәкәткә тартылуы, патша самодеражавиесе зинданының ачысын татуы да, ул үзе соңыннан әйтеп үткәнчә, аңа «байтак тәэсир кылды.»[1]

Демократизм идеяләренә һәм революцион хәрәкәткә тартылу, әлбәттә, Г.Ибраһимовның милли мәсьәләләрне хәл итүдә мәгърифәтчелек традицияләре белән араны өзүе түгел иде. Аның иҗатында мәгърифәтчелек тенденциясенең саклануы «Шәрекъ клубы»нда татарча театр» (1915 ел), «Тәрбиядә хөррият вә шәхсият нигезләре» (1914 ел), «Хатын язмышы» (1913 ел) һ.б. әсәрләрендә әле бик ачык сиземләнә. Шул ук вакытта мәгърифәтчелек идеяләре аның иҗатында социаль һәм сәяси мәсьәләләр, җәмгыятьне революцион юл белән үзгәртү идеяләре белән елдан-ел ныграк үрелә баралар.

Г.Ибраһимовның мәгърифәтчелектән революцион демократизмга таба эволюциясе аның халык массаларының аянычлы язмышын бәяләүгә яңача килүендә үзенең ачык чагылышын тапты. «Хәзерге капитал, — ди ул, — үзенең бер кулга җыелуы сәбәпле, күпме җаннар гомергә бер телем икмәк өчен газап чигәргә мәҗбүр булмыйлар да, кемнәр, нинди фәрештәләр, шул каһәрнең золымы сәбәпле, фәхиш этләрнең астында изелергә, соңра ачлыктан үлмәс өчен күпер башларында, урам буйларында үзләренең тәннәрен һәрбер очраган адәмгә сатып йөрү газабына төшмиләр»[2] Бу өзек Г.Ибраһимовның 1913 елда язылган «Татар шагыйрьләре» исемле әсәреннән алынды. Социаль күренешләрне шушы рәвештә тасвирлау язучының «Яңа китап мөнәсәбәтилә», «Зур романнар» (1912 ел), «Мәдрәсә чуалышлары» (1913 ел) һәм башка мәкаләләрендә дә күзәтелә.

Г.Ибраһимов халкының кызганыч тормышы уңаеннан үзенең протестын белдерү белән генә чикләнми. Бер ук вакыт ул халыкны караңгылыкка, кыргыйлыкка һәм фәкыйрьлек баткаклыгына этәрүче көчләрне алып ату, тормышының алга баруына юл ачу мәсьәләсен дә күтәрә. «Адәм хаяте туктаусыз ага, үзгәрә, — дип яза ул, — Гасырлар буенча бер халыкның йөрәгенә кан булып, каты таш булып каткан иске фанатизм хаятьнең бу үзгәрүе, бу такаддеме (прогрессы) юлында иң көчле манигълардандыр. Бер халыкның яңа хаятькә керүе өчен шул гасырлар буенча оешып катып калган иске фанатизмны җимермәк, шул иске фанатизмны халык йөрәгеннән төбетамыры илә суырып ташламак бу, шөбһәсез, яңа хаять юлы ачу димәктер, шөбһәсез, яңа куәтләргә хаятьне үзләре эстәгән рәвешенә кертү өчен зәмин хәзерләү димәктер.»[3]

Үзенең фәлсәфи-иҗади эзләнүләрендә Г.Ибраһимов бик катлаулы юл үтте. Акрынлап аны кешене, аның табигатен һәм тормышының мәгънәсен аңлауда ортодоксаль дини өйрәтмәләр белән бәйләнгән төшенчәләр канәгатьләндерми башлый. Кеше яшәешенең мәгънәсен ул тормышының үзендә, яшәеш күренешләрендә эзли башлый. Бу аның игътибарын табигатьтәге нәфислеккә һәм максатчанлыкка, аның аһәңнәренә, андагы үзара ятышканлыкка һәм ахыр чиктә кешенең табигый асылына юнәлтә. Аның фәлсәфи эзләнүләрендә антропологик тенденцияләр сиземләнә башлый. Кешенең табигый асылына мөрәҗәгать итү, аны табигытьнең аерылгысыз өлеше рәвешендә күз алдына китерү, табигый гармониягә дан җырлау үзенең чагылышын бигрәк тә аның «Яз башы» (1910 ел), «Сөю — сәгадәт», «Яшь йөрәкләр» (1912 ел) һәм «Табигать балалары» (1914 ел) дигән әсәрләрендә тапты.

Фәнни-концептуаль рәвештә антропологизм принципы Г.Ибраһимовның «Яңа әсәр» (1911 ел) дигән хезмәтендә нигезләнә. «Ул (кеше — Я.А.), — дип яза мөтәфәккиребез анда, — бөтен табигый куәтләр, кыенлыклар каршында үзенең ялангач гәүдәсеннән башка һичбер нәрсәгә малик түгел, ул бернәрсәсез, тик кул белән башы бар да, үзенә дә сизелмәгән рәвештә хәят сөю хисе, ничек кенә булса да яшәргә теләү табигате бар. Ул үзе боларны белми, болар анда **табигый, җибилли** (тумыштан) булган сыйфатлар. Боларның тәэсире илә аңарда үләсе килмәү — шунлыктан үзенең хәятен һәрбер кыенлыклардан мөдафәга (саклау) итү заруры хисе туа. Шуннан аның кулы, бераздан башы да эшкә мәҗбүр була. Аны зарурәт көчли. Тәҗрибә ярдәм итә. Аның, хәятны мөдафәга юлындагы хәрәкәте тәэсире илә, өстен өртергә, ут, тимер табарга, хәтта уйларга да белә башлый. Шуннан килеп чыга мәдәниятның беренче орлыклары».[4] Күренүенчә, Г.Ибраһимов өчен кеше үзенең асылы, көчлелеге-көчсезлеге, хисләре, теләк-омтылышлары белән табигать баласы. Аның бөтен барлыгының һәм тәрәккыятенең нигезендә шушы табигый асылы ята. Алга таба автор кешегә хас табигый фактларга бәйле рәвештә мәдәният үсешен дә, кешелек цивилизациясенең югары баскычларга күтәрелешен дә аңлатырга тырыша.

Үзенең әдәбият мәсьәләләренә багышланган тикшеренүләрендә дә Г.Ибраһимов антрополгизм принципларына таяна. Менә аның 1913 елда язылган «Татар шагыйрьләре» исемле

хезмәте. Бу әсәр дөнья күргәч, татар җәмәгатьчелеге арасында зур бәхәсләр туды. Әле хәзер дә бу бәхәсләрнең тәмам тынганы юк. Әмма аның бу хезмәтендә татар шагыйрьләренә карата бирелгән бәяләмәләрдә һич кенә дә гаҗәпләнерлек нәрсә юк. Г.Ибраһимовның үзенең замандашларына карата бирелгән бу бәяләмәләре аның ул вакыттагы фәлсәфи инанууларының нәтиҗәсе булып торалар. Ә бу фәлсәфи инанулар нигезендә антропологизм идеяләре, кешене баштанаяк табигать баласы дип кузаллау ята. Чын мәгънәсендә рәссам яки шагыйрь булган кеше, дип саный ул, табигать тарафыннан салынган кутәренке рух күренеше һәм ул табигать белән бердәмлектә һәм аңа таянып иҗат итә. Ул тудырган әсәрләрдә табигать таләбе үзенең чагылышын таба. «Кеше үзе теләп кенә шагыйрь була алмый, аны табигать ясый.»[5] Шуның өстенә шигъри иҗат процессында, акыл, фикерләү куәте һичничек тә катнашмый. Шагыйрь тулысынча хисләр коллыгында яши. Ә хис — ул табигать бүләге. Шулай булгач, «шигырьдә бөтен вә баш хасият — шагыйрьнең аны ясамавы, теләсә генә ничек булса да, үзе хис кылган рәвештә чыгуыдыр.»[6] Димәк шагыйрь сүзләр аша үзенең хиссиятенә табигать тарафыннан салынган кичерешләрне генә бирә. Г.Ибраһимовның 1915 елны чыккан «Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз» дигән әсәренә дә шушыңа охшашлы фикерләүләр хас иде.

Г.Ибраһимовның дөньяга карашында антропологизмга хас тенденцияләрнең тууы, аның фәлсәфи эзләнүләренең илаһилыктан кешенең җирдәге яшәешенә, тормышының үзенә борылуын күрсәтүче фактор булды. Моның шулай икәнлеген аның инде телгә алынган әдәби-тәнкыйди әсәрләре ук күрсәтеп торалар. Г.Ибраһимов аларда кешенең табигый асылын күз алдында тотып фикер йөртә.

Г.Ибраһимов алга таба акрынлап антропологизм тәэсиреннән дә арына башлый һәм бу очракта да аның актив җәмәгать эшчәнлеге һәм иҗтимагый хәрәкәтләрдә катнашуы үзенең ролен уйнаган булыр. Аның бу вакыттагы фәлсәфи карашларында реаль тормышка таянып фикер йөртү тагы да куерак төс ала һәм материализмга тартым идеяләр яңгырый башлыйлар. Бу җәһәттән аның 1916 елда язылган «Телләре башка булса да, рухлары бер» дигән хезмәте игътибарга лаек. Бу хезмәтендә галим телләрнең функциясе һәм үсеше мәсьәләсен

теге яки бу халыкның иҗтимагый ихтыяҗыннан чыгып аңлата. «Һичбер халыкның авызына, һичбер вакытта, — дип яза ул, — аның табигый телен тартып алып, үзең теләгән яңа бер тел куяр хәл юк. Әдәби тел һичбер вакыт ясалмый. Ул халыкның үз рухындагы мәгънәне нинди тел белән әйтергә теләвеннән килеп чыга.»[7] Кайчандыр, бик борынгы дәверләрдә, дип дәвам итә ул, иҗтимагый тормышның объектив таләпләренә бинаән төрки халыклар бер әдәби тел тәэсире астында яшиләр. Ә соңыннан тарихи, җәгърәфи, икътисади, сәяси һәм мәдәни-идеологик факторлар тәэсирендә алар таркалып яши башлыйлар. Бу шартларда госманлы төрекләренең, әзербәйҗанлыларның, үзбәкләрнең, татарларның — һәркайсының үзенең әдәби теле формалаша. Шулай булгач, бу халыкларны бердәм тел традицияләренә буйсындырырга тырышу яки аларның кайсының да булса берсенә икенчесенең телен тагу мәгънәсезлек, тормыш кануннарын белмәү нәтиҗәсе. Чөнки, «Хәят безнең теләвебез буенча йөрми. Аерым бер груһның фикере вә хезмәте һичбер вакыт хәят агымын туктата алмыйлар. Мәсьәләгә болай карау — диңгез агымын ишкәк белән туктатырга тырышу кабиленнән бер эштер.»[8]

Г.Ибраһимовның 1917 елгы революцияләр алдыннан язылган хезмәтләрен күзәтү аның фәлсәфи карашларында диалектик тенденцияләрнең сиземләнә башлавын да күрсәтә. Бу беренче чиратта аның тормышны, аның күренешләрен хәрәкәттә һәм үзгәрештә итеп каравында чагыла. «Хәят, — дип яза ул, — ике килми, табигый барышыннан да туктамый. Зәвалга (бетү, юкка чыгу) йөз тоткан нурын, һич булмаса, әүвәлге хәлендә калдырырга да чара юк. Ни генә кыйлма ул үз юлында».[9] Чынбарлык үзе дә, кешенең аңы да туктаусыз тәрәккыйләшә баралар. Ә «тәрәккый димәк, — хәятның иске рәвешләрен җимереп, яңа ихтыяҗларга җавап бирерлек яңа шәкелләр тудырмак димәктер. Тарихта кайбер ирләр фәкать җимергәннәр. Һәм шуның белән күп файда китергәннәр. Чөнки искене җимерү белән мәйдан бушый, хәят эченнән чыгачак яңа куәтләргә юл ачылган була.»[10] Шуның өстенә, Г.Ибраһимов фикеренчә, үсеш һәм үзгәреш — объектив процесс, ул кеше ихтыярына бәйләнмәгән. Шунысы характерлы, ул үсеш идеясеннән, яңаның искегә каршы көрәше идеясеннән, искенең яңага алыштырылагачыгының котылгысыз булганлыгыннан радикаль нәтиҗәләр чыгара, туып килүче көчләр тарафыннан

искелектән калган тәртипләрне тәвәкәллек белән җимерү кирәклегенә басым ясый. Шулай итеп, Г.Ибраһимовның үсеш һәм үзгәреш идеясен искелекнең җимерелүе һәм яңаның тантанасы рәвешендә күзаллавы аңа иҗтимагый яңарышның революцион демократик концепциясен нигезләү мөмкинлеге тудыра.

Г.Ибраһимовның чынбарлыкны диалектик рәвештә күзаллавының бик мөһим бер чагылышы — аның күренешләрне каршылыклы итеп каравы һәм тирәлектә капма-каршы көчләрнең көрәшен тануы. Аның фикеренчә, табигатьтә дә, иҗтимагый тормышта да нәфислек һәм шөкәтсезлек бер-беренә бәйләнгәннәр һәм бер-берсен фараз кылалар. Җылылык һәм салкынлык, искелек-яңалык, шатлык һәм хәсрәт, бер-берсе белән аерылгысыз җепләр белән тоташканнар. Шушы каршылыклы тенденцияләрнең көрәше һәм шул ук вакытта бердәмлеге тормышның нигезендә ята.

Дөрес, бу диалектик идеяләргә әле стихиялелек хас һәм алар чынбарлыкның диалектикасын фәнни өйрәнүгә нигезләнмәгәннәр. Бу диалектик идеяләр арасында үзара бәйләнеш тә юк һәм шуңа күрә алар бердәм һәм төптән уйланылган концепцияне тәшкил итмәделәр. Капма-каршылыклар һәм үсеш идеясе турында сүз алып барганда, Г.Ибраһимов аларны берберсенә бәйләп карамады. Шуның белән бергә, ул каршылыкларны хәрәкәт һәм үсешнең универсал чыганагы итеп тә күз алдына китерми. Шушы эзлексезлекләргә һәм стихиялелеккә карамастан, Г.Ибраһимов иҗатында ныклы урын алган бу диалектик идеяләр, аның фикер сөрешенә керә башлаган материалистик тенденцияләр белән бергә, мөтәфәккиребезнең фикери үсешенең бик мөһим нәтиҗәләре булдылар. Алар аның алдагы фикери үсеше өчен мөһим баскыч ролен үтәделәр, ә бу үсеш исә 1917 елгы революцион вакыйгалар һәм илдә колач җәйгән социаль үзгәрешләр тәэсирендә барды.

Давыллы, 1917 елны Г.Ибраһимов инде җитлеккән революцион демократ буларак каршылый һәм актив революцион эшчәнлеккә алына. Үзенең революцион демократик характерда булган карашларын ул үзе редакцияләгән «Ирек» газетасында (Уфа) пропагандалый. Күпсанлы халык массаларын туплаган митингларда чыгышлар ясый, революцион оештыру эшләре белән шөгыльләнә, хезмәт ияләрен җәбер-золымнан коткару өчен, җир өчен, сугыштан чыгу өчен көрәшкә туплауга күп көч

куя. Ул 1917 елда Мәскәүдә, Казанда һәм Уфада узган мөселман съездларының эшләрендә дә актив катнаша һәм аларда милли мәсьәләне демократик рухта хәл итү юнәлешендә эш алып бара.

Октябрь социалистик революциясе күтәргән шигарьләрне дә Г.Ибраһимов кире какмый һәм революцион көрәштә катнашуын дәвам итә. Бөтен көче белән ул актив җәмәгать эшчәнлегенә чума, мөһим дәүләти вазыйфалар үти, советлар төзелешендә катнаша һәм бөтен көчен контрреволюциянең һөҗүмен кире кайтару өчен көрәшкә бирә.

Бу көрәштә һәм совет дәүләте төзелешендә актив катнашу Г.Ибраһимовны акрынлап Коммунистлар партиясе белән якынайта һәм ахыр чиктә аның гамәли һәм нәзари фәлсәфәсен кабул итүгә китерә. Г.Ибраһимовның фикери эволюциясендәге бу үзгәрешләргә аның моңа кадәрге үсешендә инде нигез салынган була. Бу нигез аның карашларында инде әйтеп үтелгән материализмга тартым идеяләрнең һәм диалектик күзаллауларның урын ала башлауларында күренде. Ахыр чиктә бу тенденцияләрнең үсеше аны марксистик фәлсәфәне — диалектик материализмны кабул итүгә китерде.

Хакимияткә килгән коммунистлар белән якынаю һәм бердәм эшләү нәтҗәсендә Г.Ибраһимов Маркс, Энгельс һәм Ленинның фәлсәфи хезмәтләре белән таныша башлый һәм тора-бара аларның нигезендә яткан идеяләр аның үзенең хезмәтләрендә дә яңгыраш таба баралар. Мәсәлән, аның 1920 елда язылган «Сарайларга — сугыш, фәкыйрь өйләргә — туганлык» дигән хезмәтендә Ф.Энгельснең «Анти-Дюринг», «Гаилә, хосуси милек һәм дәүләтнең килеп чыгышы», шулай ук Маркс һәм Ленин әсәрләренең тәэсире сизелеп тора. Аның «Бөек октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» дигән хезмәте дә «Коммунистлар партиясе манифесты»н, Маркcның «Готт программасына тәнкыйть», «Франциядә сыйнфыйлар көрәше», шулай ук Ленинның дәүләт һәм пролетариат диктатурасына кагылышлы әсәрләрен өйрәнү нигезендә язылганнар.

Г.Ибраһимовның 1919—20 елларга караган хезмәтләрендә марксизмның, иҗтимагый-сәяси идеяләр үсешендә җәмгыятьнең материаль тормышы шартлары хәлиткеч роль уйный, дигән положениесен кабул итеп фикер йөрткәнлеге үзен сиздереп тора. Дөрес, Г.Ибраһимов шушы елларда ук фәлсәфәдә инде

эзлекле марксистик позициягә басты, дип әйтергә ярамас. Бу әсәрләрендә ул җәмгыять тормышының материаль нигезләрен әле берьяклырак аңлый һәм бу нигезләрне турыдан-туры экономик үсешкә кайтарып калдыра.

«Фикерләр, — дип яза ул 1920 елда, — тормыштан туа, тормыш теләгән калыпка коелалар. Икътисади мөнәсәбәтләр һәрнәрсәнең нигезе, тамыры. Башка әйберләр — бу тамырдан чыккан үсемлекләр, гөлләр, җимешләр.»[11] Җәмгыять тормышының базисын экономик мөнәсәбәтләргә кайтарып калдырып, ул, әлбәттә, аның материаль җирлеген беркадәр чикләнгәнрәк рәвештә күз алдына китерә. Монда, мөгаен, Г.Ибраһимовка экономик материализм идеяләренә таянган һәм ул вакытта бик популяр булган Покровский мәктәбенең тәэсире сизелә булыр.

Марксизмның методологик принципларын тирәнрәк үзләштерә барып, Г.Ибраһимов торган саен әлеге экономик материализм тәэсиреннән арына бара. Инде «Берничә сүз» (1921 ел) һәм «Өч җавап» (1922 ел) дигән хезмәтләрендә ул, җәмгыятьнең материаль тормышының өскорма өчен нигез булуы турында сүз алып барганда, экономик мөнәсәбәтләр белән бергә социаль мөнәсәбәтләр мәсьәләсен дә күтәрә. «Әдипләр, шагыйрьләр, — дип яза ул, — күктә яшәми, талантлар күктән рухланмый — болар мәгълүм дәвернең, мәгълүм иҗтимагый (ягъни социаль)-икътисади зәминнәрнең җимешләре булганга, шуңа карап, аларның безгә ача торган дөньялары, тормышлары, җанлы картиналары төрлечә була.»[12]

Һәм, ниһаять, Г.Ибраһимовның «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» дигән хезмәте (1922 ел). Бу хезмәт әдипнең марксизмның методологик нигезләрен инде ныклап үзләштергәнлеген күрсәтеп тора. «Әдәбиятлар, фәлсәфәләр, гыйльми ысуллар, диннәр, әхлаклар, — дип язды ул бу хезмәтендә, — кыскасы бөтен идеология хәрәкәтләренең һичбере күктән яумаган кебек, нинди дә булса бер даһиның тик үз башыннан уйлап чыгаруы белән дөньяга килмиләр. Боларның фикерләре, рухлары, мөндәриҗәләре — һәммәсе тарихның мәгълүм дәверендәге мәгълүм бер мадди, иҗтимагый катлаулар тупрагында үсеп чыга торган чәчәкләр генәдер... Шуңа күрә әдәбиятлар, фәлсәфәләр, гыйльми ысулларны тикшерүдә, аеруда бердәнбер дөрес юл — боларны җитештергән иҗтимагый-икътисади нигезләр буенча язу һәм шул нигез мизаны белән бәһа, кыйммәт куюдыр.»[13]

Китерелгән берничә мисал Г.Ибраһимовның марксизмның материалистик фәлсәфәсен адым саен тирәнрәк үзләштерә барганлыгы турында сөйли. Шуның белән бергә, ул үзенең тарих, әдәбият һәм тел гыйлеме, иҗтимагый фикер тарихын тикшерүгә багышланган хезмәтләрендә бу фәлсәфәгә бәйле методологик ысулларны киңрәк куллана бара. Мәсәлән, «татар әдәбиятын өйрәнү юлында» (1923 ел) һәм «Пролетариат әдәбияты турында» (1924 ел) дип исемләнгән хезмәтләрендә Г.Ибраһимов татар әдәбиятының тарихын һәм әдәбият гыйлеменең заманга кагылышлы проблемаларын марксистик методологиягә таянып анализлый. «Без, — дип яза ул «Пролетариат әдәбияты турында» дигән хезмәтендә, — шигырьнең, сәнгатьнең, әдәбиятның ничек тууларын, үзгәрешләрен, кичкән баскычларын аңларга теләсәк, һәрнәрсәдән элек боларны җитештергән иҗтимагый тупракка, тормышның икътисади-сәяси моментларына карарга, тамырны шуннан эзләргә тиешле булабыз... Әсәрләрдәге төп уйларны, материалларны гына түгел, телне, стильне (өслубне) һәм боларның төрле кешедә, төрле заманда төрлечә булуларының сәбәпләрен дә шул нигезләрдән табачакбыз. Бу гына түгел, әдәбият тарихының кайбер баскычларында «талантлар»ның күп чыгулары, күп кыйммәтле нәрсәләр бирүе, кайбер дәверләрдә «илһам»ның тукталуы кебек хәлләрнең дә шул иҗтимагый-икътисади эшләрнең тудырган психологиясендә күрәбез.»[14] Әдәби процессны бу рәвештә социаль-экономик үсеш белән бәйләп аңлату Г.Ибраһимовның бу елларда язган башка хезмәтләрендә дә күзәтелә.

Фикери эволюциясе процессында Г.Ибраһимов марксизм фәлсәфәсен бербөтен тәгълимат буларак кабул итә. Ә бу фәлсәфәнең мөһим ягы, билгеле булганча, — диалектик фикерләү. Һәм әдипнең фикери эволюциясендә дә материалистик һәм диалектик карашлар бер-беренә бәйләнеп үсәләр һәм бердәм тәгълимат булып формалашалар. «Дөньяда, — дип яза Г.Ибраһимов борынгы юнан фәләсифы Гераклитның әйткәннәренә таянып, — һәммә нәрсә ага, һәммә нәрсә үзгәрә... Гыйльми социализмның нигез ташларыннан берсе булган диалектика ысулы безгә «моны» үз тормышыбызга каратып ачып бирде; дөньяның бертуктаусыз үзгәреп торуын техниканың алмашынуына карап, адәмнәрнең тормышы, оешулары, көн итешләре, фикерләре, карашлары яңадан-яңа рәвешкә керә барганын исбат итте.»[15] Үзгәреп торучан бу дөнья, дип хисаплый әдип,

үзенең үсешендә төрле этаплар үтте. Иҗтимагый тормышка нисбәтән бу этапларның башында борынгы җәмгыять торды. Аннан соң колбиләүчелек, феодализм һәм капитализм дәверләре бер-берсен алыштыра бардылар. Иҗтимагый-икътисади формацияләрнең бу алмашуы капма-каршы социаль көчләрнең кискен көрәше шартларында барды.

Үсеш, аның төрле этапларының бер-берсенә бәйләнеше, капма-каршы көчләрнең берлеге, үзара йогынтысы һәм көрәше турындагы диалектик тәгълиматны галим иҗтимагый хәрәкәтләрне, иҗтимагый фикер тарихын, әдәбиятның барышын, тел проблемаларын тикшергәндә методологик алым буларак киң куллана. Татар иҗтимагый фикере үсешен тикшергәндә ул, мәсәлән, болай дип яза: феодаль мөнәсәбәтләрнең таркалуы һәм капиталистик мөнәсәбәтләрнең тамыр җәюе шартларында капма-каршы социаль көчләрнең үзара көрәше аша гасырлардан калган кадими идеологиягә алмашка Г.Курсави, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, М.Акмулла, М.Акъегет-Задә һ.б. йөзендә мөтәфәккирләрнең яңа буыны үсеп чыга. Бу татар иҗтимагый фикере үсешенең яңа баскычы иде. Әмма идеологик тормыш бу чорда да бер урында таптанып тормады; иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең үзгәрүе тәэсирендә ул да үсешенең яңа баскычларын яулады, яңа эчтәлек белән тулыландырылды. «Орлыктан сабак, яфрак чыгып үскән кебек, тамчылар белән башланган чишмәләр зураеп елгага әйләнгән кебек, ул икенче дәвер хәрәкәте дә бер ноктада тукталып калмады — баскыч-баскыч күтәрелде, үсте, киңәйде, барлыгы бер кыйблага — Европа мәдәниятын, гыйлемен алуга карап юнәлүдә дәвам итте.»[16]

Икътисади мөнәсәбәтләр үсеше, социаль антогонизмнарның кискенләшүе һәм илдә революцион хәрәкәтнең үсүе, — дип хисаплый Г.Ибраһимов, — яңа идеяләр тудырды. Татар иҗтимагый фикере үсешенең бу яңа адымын ул өченче этап дип атый. Татар иҗтимагый фикере үсешенең бу этабы Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал, М.Гафури кебек революцион демократлар иҗаты, һәм Х.Ямашев һәм Г.Сәйфетдинов кебек марксистлар эшчәнлеге белән бәйле. Шул ук вакытта татар иҗтимагый фикере үсешенең бу этаплары бер-берсеннән аерылмаганнар да, киресенчә, алар бер-берсе белән үрелгәннәр, бер-берсенә үтеп керәләр. «Һичбер дәвер, — дип яза ул, — бөтен көенчә ясалып күктән төшми, алдагы дәверләр эчендә азмы-күпме матдәләр ясала; болар азмы-күпме хәрәкәт итеп куялар.»[17]

Г.Ибраһимовның марксизмга таба эволюциясе аның социаль карашларында да үзенең ачык чагылышын тапты. Бу беренче чиратта аның иҗтимагый күренешләрне тикшергәндә һәм бәяләгәндә сыйнфыйлык позициясенә күчә баруында һәм пролетар партиялелек принцибына таянып эш итү юлына басуында күренде. Ярлылар һәм байлар арасындагы аермалыклар турында ул инде революциягә кадәр язылган әсәрләрендә дә сүз алып бара. «Карт ялчы» һәм «Көтүчеләр» дигән әсәрләрендә, мәсәлән, ул хезмәт кешесенең ачы язмышы турында зур кызгану хисе белән яза. Яшь Г.Ибраһимовның күп кенә публицистик һәм әдәби-тәнкыйди әсәрләре дә шушы ук рух белән сугарылган иделәр. Әмма революциягә кадәрге иҗатында ул әле үзләренең махсус мәнфәгатьләре булган сыйныфлар турында сүз алып бармады һәм сыйныфларга бүленүнең сәбәпләренә дә кагылмады. Февраль революциясеннән соң чыккан беренче хезмәтләрендә дә («Куәт — халыкта», «Халык — падишаһ», «Безнең юл» дигән мәкаләләр) ул әле гомумән халык турында яза. «Безнең иманыбыз, — дип ассызыклый ул, — халыкта, халыкның аңлавында, халыкның үз теләкләрен белдерер өчен аң белән вә каһарманлык белән көрәшергә, җанын, канын аямыйча, үз теләгенә барырга хәзер булуындадыр.»[18]

Әдипнең 1918 елда чыккан хезмәтләрендә исә иҗтимагый хәрәкәтләр һәм оешмаларның эш-гамәлләрен бәяләгәндә сыйнфыйлык позициясендә торып фикер йөрткәнлеге инде ачыктан-ачык күренеп тора. «Мәркәздә һәм урыннарда мөселман комиссариатлары» дип исемләнгән мәкаләдә инде ул аларның сыйнфый характерда булуын басым ясап күрсәтә. «Мөселман комиссариатлары, — дип яза Г.Ибраһимов, — саф милли бер теләк өчен тумадылар. Болар — сыйнфый оешмалар, болар Шуралар (советлар) хакимияте аппаратының бер кисәге, болар октябрь революциясенең җаныннан, каныннан туган мөәссәсләр.».[19] Ә «Мәркәз мөселман комиссариатының мәрхүм милли идарә эшләре хакындагы хисабы мөнәсәбәте илә берничә сүз» дигән язмада Г.Ибраһимов бу идарәне татар буржуазиясенең милли мәнфәгатьләрне яклау сылтавы белән эшче һәм крестьяннар хакимиятенә каршы алып барган сыйнфый оешмасы дип бәяли. Ә 1920 елда язылган «Сарайларга — сугыш, фәкыйрь өйләргә — туганлык» дигән әсәре аның сыйныфлар һәм сыйнфый көрәш мәсьәләсендә тулысынча марксизм позициясенә күчкәнлеген күрсәтә.

Сыйнфыйлык принцибын ул үзенең революция һәм дәүләт хакимияте мәсьәләләрен яктырткан хезмәтләрендә эзлекле рәвештә куллана. Аның фикеренчә, фәлсәфә, әдәбият, сәнгать кебек өскорма күренешләре дә сыйнфыйлык рухы белән сугарылганнар. «Әдәбиятның, фәлсәфәнең, сәнаигы нәфисәнең сыйнфый көрәштә битарафлыгы, сафлыгы хакындагы сүзләргә һич урын юк; мондый сүзләрне «аңламау яки аңлап та эшче-крестьянның эшен томалау өчен генә әйтелгәнлеге» ачыктыр.[20]

Әйтергә кирәк, башка күп кенә әдипләр һәм галимнәр кебек үк, Г.Ибраһимовны да сыйнфыйлык, партиялелек белән мавыгу берьяклылыкка китерде. Бу берьяклылык аның милли оешмаларга мөнәсәбәтендә үзенең бигрәк тә ачык чагылышын тапты. Миллилек, милли мәнфәгатьләрне яклау күренешләре, ул елларда язган бик күбәүләр кебек үк, Г.Ибраһимов тарафыннан да, — хезмәт халкы интересларына, советлар хакимиятенә каршы юнәлдерелгән буржуаз милләтчелек, һич булмаса милли чикләнгәнлек күренеше дип бәяләнде. Инде 1919 елда язылган «Социаль революция һәм татар зыялылары» дигән хезмәтендә үк ул татар мәдәнияты эшлеклеләренә ачы тәнкыйть утлары чәчте, аларны революцион көрәш күтәрелеше шартларында сыйнфый битарафлык позициясенә басуда гаепләде. Бу әсәрендә ул сүзен, милли мәнфәгатьләрне яклыйбыз дигән булып алар асылда халыкка каршы көрәш алып баручылар ягында калдылар, дип тәмамлады.

Сыйнфыйлык белән миллилекне бер-берсенә каршы кую Г.Ибраһимонның «Кара маяклар һәм ак әдәбиятлар» дигән әсәрендә бигрәк тә нык яңгырады. Бу әсәрендә ул татар иҗтимагый фикеренең төрле агымнары турында сүз кузгата һәм аларга сыйнфыйлык позициясендә торып бәя бирә һәм чит илгә китеп большевизм элмәгеннән котыла алган татар зыялыларын контрреволюцион эшчәнлектә гаепли. Әйтергә кирәк, соңрак Г.Ибраһимовның бу әсәрләре милли хәрәкәт эшлеклеләрен гаепләп язылган бик күп хезмәтләрнең авторларына таяныч ролен үтәделәр.

Шулай да, Г.Ибраһимов сыйнфыйлык һәм партиялелек принципларына һәркайчан сукырларча ияреп иҗат итмәде. Бу уңайдан, беренче чиратта, аның «Татар әдәбияты нинди юл белән барачак» дигән әсәрен күрсәтеп үтү урынлы булыр. Бу әсәр 1927 елда язылган һәм милли мәдәниятның киләчәгенә

нигилистик карашларга каршы юнәлдерелгән. Шул еллардагы башка хезмәтләрендәге кебек үк, ул бу әсәрендә дә сыйнфыйлык идеясен таный, әмма шул ук вакытта социализм шартларында да милли мәдәният һәръяклап үсәргә тиеш дигән фикер үткәрә һәм шуны яклый. Әдип совет хакимиятенең җитәкче даирәләрендә әле патша самодержавиесеннән калган урыслаштыру тенденциясенең сүнмәгәнлеген, киресенчә, аны һәртөрле юллар белән җанландыру чаралары күрелгәнлеген күрсәтеп үтә дә, фикерен, идарә аппараты — халкыннан, аның мәдәниятыннан ераклашкан чиновниклар кулында түгел, бәлки аның телен, әдәбиятын, гореф-гадәтләрен, тарихын-тормышын белгән хезмәтчәннәр кулында булырга, ә республикада үткәрелә торган сәясәт шушыңа буйсындырылырга тиеш, дип тәмамлый.

Дөрес, Г.Ибраһимов пролетар революциясенең, пролетариат диктатурасының һәм интернационализмның Сталин биргән юнәлешенең асылын аңлап бетерми. Ул, пролетариат революциясе дә, пролетариат диктатурасы да чынбарлыкка ашкан күренешләр һәм без шушы кысаларда милли мәдәниятны үстерү өстендә эзлекле эш алып бара алабыз һәм алып барырга тиешбез, аларның тегесе дә, бусы да милли мәдәният үсешенә комачауламый, киресенчә, моңа киң мөмкинлекләр ача, дип ышана.

Г.Ибраһимов социализм төзелеше шартларында милли мәдәниятлар үсешенең кысаларын да билгеләргә тырыша. «Халыклар, — дип яза ул, — үзләренең телләре, гореф-гадәтләре, тормышлары, тарихи язмышлары буенча бер-берләреннән тышкы калыпларда байтак аерылалар. Шуңа карап аларның һәрберсенең мәдәнияты, мәдәни хәрәкәте дә тышкы төстә үзенә башка аерым рәвештә гәүдәләнәләр. Мәсәлән, мәктәп, сәнгать, гыйлем, әдәбият — болар һәммәсе милләтнең үз телендә булырлар. Үз телендә киңәеп, тирәнәеп үсәрләр, үз зәүкына, үз хаҗәтләренә карашып туарлар, үзләренә уңай, аңлаешлы калыпларга салынырлар, үз тормышы белән сугарылып, үзләренең аерым тарихи моментлары, тудырган мәсьәләләре юлында эшләрләр... Шушы калыпларда һәр халыкның мәдәнияты үзенең милли нигезендә, үз ана телендә, үз тормышының аерым хасиятләре белән сугарылыр, аерым рәвешләнер».[21]

Г.Ибраһимов телне мәдәниятның чишмә башы һәм аның асылын билгеләүче фактор дип саный. Шуңа бинаән ул бу хезмәтендә тел мәсьәләсенә кабат-кабат әйләнеп кайта һәм

милли мәдәниятның үсешен тәэмин итү максатында һәр татар баласын башлангыч мәктәптән алып югары уку йортына кадәр ана телендә укыту зарурлыгын, татар телен белүче инженерлар, агрономнар, врачлар хәзерләү кирәклеген басым ясап күрсәтә. Милли мәдәниятны үтсерүнең мөһим тармагы рәвешендә ул администрацияне милләләштерү мәсьәләсен дә күтәрә, милли телне үстерү юлларын билгели, татар өчен китапларның татар телендә басылырга тиешлеген ассызыклый. «Татар халкы, — дип яза Г.Ибраһимов сүзен йомгаклап, — башка милләтләргә йотылу юлы белән түгел, үз теле нигезендә, үз мәдәниятын үстерү юлы белән барачак. Ассимиляция һәм урыслашу перспективалары татарның киләчәк көннәренең мөндәриҗәсеннән алып ташланырга, йотылу яки урыслашу хәрәкәтләрен аерым бер агым итеп мәйданга куюэшенә каршы каты көрәшергә, моны революция принципларын аңламаучылык итеп каралырга, татар хезмәт массасының революция эчендәге хәрәкәтенә зарарлы реакциячелек саналырга тиешле... Бу шартлар эчендә урыс мәдәниятының татар мәдәниятыннан югарылыгы, шуңар күрә татарлар өчен зәгыйфь мәдәнияттан югары мәдәниятка күчү тиешлеге турындагы сөйләнүләр — великоруслык милләтенең элекке өстенлеген саклар өчен чыгарылган караш кынадыр. Татар арасында мондый карашларның булуы — иске замандагы русификаторлык сәясәтенең татар зиһенендә калдырган күләгәсе, үзенә түбән, ышанычсыз карарга өйрәнүенең хата нәтиҗәсе генәдер.»[22]

Г.Ибраһимовның бу һәм башка хезмәтләрендә яңгыраган шушыңа охшаган карашлары (әйе, Г.Ибраһимовның моңа охшаш карашлары башка хезмәтләрендә дә яңгырап тордылар) ул вакытта партия өлкә комитетында утырган түрәләргә дә, татарларның инде үз араларында яхшы ук тамыр җәйгән сул радикалларына да ошамады. Тегеләре дә, болары да аңа ул вакыт өчен бик хәтәр булган гаепләүләр белән ябырылдылар. Милли мәдәният мәсьәләләре һәм бу турыда татар җәмәгатьчелеге арасында куерган фикерләр 1927 елның 14 июнендә партия өлкә комитетының пленумына куеп тикшерелде. Пленум карарында әдип әйтелгән хезмәтендә милли мәдәниятның мөстәкыйльлеген зурайтып күрсәтүдә һәм аны идеаллаштыруда, татар милли мәдәниятының үсешендә пролетариатның ролен кечерәйтүдә һәм милли интеллигенциянең ролен зурайтуда

гаепләнде. Әдипнең иҗатына карата ул вакытта идеология фронтын тулысынча үз кулында тоткан партия Өлкә комитеты тарафыннан бирелгән мондый бәя, әлбәттә, аның өчен эзсез калмады, иҗади мөмкинлекләрен дә чикләде.

Г.Ибраһимов авыр, сикәлтәле тормыш юлын үтте. Җәмгыять тормышында туып торган яңадан-яңа борылышлар аны фикери эзләнүләрендә төрле якка ташлады. Шулай да әдипнең тормыш һәм иҗат юлында һәркайчан якты маяк балкып торды — ул туган халкы, аның киләчәге. Һәм, шушы киләчәк турында уйланып, ул туктаусыз эзләнде. Шуның өстенә, ул олы талант иясе дә иде. Шушы таланты, туган халкына бирелгәнлеге, аның киләчәген күз алдында тотып фикер йөртүе, олы әдибебезгә тормышының соңгы елларында да, марксистик методологиянең катгый таләпләре басымына да карамастан, әдәби иҗатында да, фәнни иҗатында да тормышның беренче адымнарында ук билгеләнгән кыйбладан тайпылмаска көч бирде.

Г.Ибраһимов олы әдәби һәм фәнни мирас калдырды. Бу мираста публицистика да зур урын алып тора. Әдипнең публицистикага игътибары бигрәк тә 1917 елгы революцион күтәрелеш вакытында арта. Бу, мөгаен, революция дулкыннары белән өскә калкып чыккан проблемаларга бик тиз җавап бирергә кирәклеге белән аңлатыла булыр. Октябрь революциясеннән соң да Г.Ибраһимовның публицистикага игътибары сүнми. Әмма, шуның белән бергә, фәнни характерда булган олы-олы хезмәтләр дә күбрәк күренә башлый. Бу, мөгаен, патша самодержавиесе җимерелгәннән соңгы беренче елларда татар мәдәнияты өстенә салынган богауларның берникадәр йомшаруы, аз гына булса да халкыбызның үткәнен һәм мәдәниятын өйрәнү мөмкинлекләре ачылу белән аңлатыла булыр. Г.Ибраһимов бу мөмкинлекләрдән файдаланып калырга ашыга һәм халкыбыз вә мәдәниятыбыз тарихы, тел вә әдәбият гыйлеме буенча фәнни тикшеренүләрен җәелдерә.

Г.Ибраһимовның игътибарын җәмгыять тормышының, тарихи үсешенең һәм мәдәният төзелешенең бик күп проблемалары үзенә җәлеп итә. Ул революцион көрәш тарихын һәрьяклап өйрәнә. Әйтергә кирәк, Г.Ибраһимов бу өлкәдә күп кенә фундаменталь хезмәтләр язып бастыра. Алар арасыннан аның «1905 елгы революциядә татарлар», «Татарлар арасында революцион хәрәкәт», «Мулланур Вахитов» исемле әсәрләрен әйтеп

үтәргә кирәк. Аларда революцион хәрәкәтләр белән беррәттән автор татарның гомуми тарихы, бигрәк тә аның соңгы тарихы мәсьәләләрен дә күтәрә.

Г.Ибраһимовның иҗади мирасында татар иҗтимагый фикере тарихына кагылышлы хезмәтләре күренекле урын билиләр. Бу җәһәттән аның «Насыйриларның тарихи урыннары» дигән хезмәтен аерып алып күрсәтергә кирәк. Бу хезмәттә аның татар мәгърифәтчеләренә биргән бәясе әле хәзер дә үзенең әһәмиятен югалтмаган. Татар иҗтимагый тарихының мөһим мәсьәләләре аның шулай ук «Татар халкының яңа тарихында өч дәвер», «Урал һәм уралчылар» һәм башка хезмәтләрендә дә бик тәфсилле итеп яктыртылалар.

Әдипнең фәнни мирасын бәяләгәндә, әлбәттә, аның тел һәм әдәбият гыйлеменә кагылышлы фундаменталь хезмәтләрен күрсәтми булмый. Бу хезмәтләр мәдәниятыбызның алтын фондына керделәр һәм әле хәзер дә күп кенә очракларда бу өлкәләрдә алып барылучы фәнни эзләнүләрнең методологик нигезен тәшкил итәләр. Һәм, ниһаять, Г.Ибраһимовның әдәби иҗатының да һич кенә дә сүлпәнләнмәгәнлеген әйтеп үтәргә кирәк. Аның фундаменталь әдәби әсәрләренең байтагы шушы елларда язылды.

Г.Ибраһимовның иҗаты һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге татар халкының рухи тормышында һәм иҗтимагый фикер үсешендә мөһим эз калдырды. Фәнни һәм әдәби иҗат белән беррәттән ул татар мәдәнияты, аның сәнгате һәм эстетик фикере үсешенә дә зур өлеш кертте. Аның гомере туган халкының киләчәге өчен көрәштә үтте. Аның иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге шушы көрәшнең чагылышы булды. Аның әдәби әсәрләреннән дә, гыйльми хезмәтләреннән дә, публицистикасыннан да көрәш рухы аңкып тора. «Беренче әсәрләремнән хәзергәчә мөндәриҗәләрендә, — дип язды ул 1927 елда, — төп характерлар һаман-һаман көрәш вакыйгалары, халыкның хезмәт процесслары тирәсендә, шулар белән сугарылды. Хезмәт авылда, шәһәрдә төрлечә тасвирга алынган кебек, көрәш тә үзенең тәфсилен үзгәртте генә түгел, бәлки ык тирәнәйтте.»[23]

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр, 8 томда. 6 т. Казан, 1986, 472 б.
[2] Шунда ук, 5 т. Казан, 1978, 140 б.
[3] Ибраһимов Г. Мәдрәсәи Галия вакыйгәсе хакында берничә сүз. «Аң», 1915, 20 сан, 359 б.
[4] Ибраһимов Г. Әсәрләр, 8 томда, 6 т. Казан, 1986, 75—76 бб.

[5] Ибраһимов, Әсәрләр, 8 томда, 5 т. Казан, 1978, 80 б.
[6] Шунда ук, 90 б.
[7] Ибраһимов Г. Әсәрләр, 8 томда, 5 т. Казан, 1978, 228 б.
[8] Шунда ук, 230 б.
[9] Ибраһимов Г. Әсәрләр, 8 томда, 5 т. Казан. 1978, 154 б.
[10] Ибраһимов Г. Мәдрәсәи Галия вакыйгәсе хакында берничә сүз. «Аң», 1915, 20 сан, 358 б.
[11] Ибраһимов Г. Әсәрләр, 8 томда, 5 т. Казан, 1978, 241 б.
[12] Шунда ук, 311 б.
[13] Шунда ук, 336—337 б.
[14] Ибраһимов Г. Әсәрләр, 8 томда, 5 т. Казан, 1978, 183 б.
[15] Ибраһимов Г. Әсәрләр, 8 томда, 7 т. Казан. 1984, 341 б.
[16] Ибраһимов Г. Әсәрләр, 8 томда, 5 т. Казан, 1978, 341 б.
[17] Шунда ук, 348 б.
[18] Ибраһимов Г. Әсәрләр, 8 томда, 6 т. Казан, 1986, 116 б.
[19] Ибраһимов Г. Әсәрләр, 8 томда, 6 т. Казан, 1986, 176 б.
[20] Ибраһимов Г. Әсәрләр, 8 томда, 5 т. Казан, 1978, 243 б.
[21] Ибраһимов Г. Татар мәдәнияты нинди юлдан барачак. «Казан утлары», 1992, №3, 166—167 бб.
[22] Шунда ук, 175 б.
[23] Ибраһимов Г. Әсәрләр, 8 томда, 6 т. Казан, 1986, 472 б.

1987—1993.

ГАЯЗ ИСХАКЫЙ: ФИКЕРИ ЭЗЛӘНҮЛӘР ЮЛЫНДА

Гаяз Исхакый (1878—1954) халкыбызның рухи тормышында һәм мәдәнияты тарихында тирән эз калдырган олы шәхес. Ул җәмәгать эшлеклесе дә, халкыбызның киләчәге турында уйлап иҗат иткән әдип тә, милли азатлык хәрәкәтенә үзенең зур өлешен керткән көрәшче дә. Аның иҗаты һәм киң планлы эшчәнлеге иҗтимагый фикеребез тарихында мөһим роль уйнады. Халкыбызның мәнфәгатьләрен күз алдында тоткан хәлдә ул туктаусыз эзләнде һәм бу эзләнүләр аның фәлсәфи карашлары үсешендә үзләренең чагылышларын таптылар.

Әйтелгән үсешне өч этапка бүлеп карарга мөмкин: беренчесе — мәгърифәтчелек идеалларына йөз тотып иҗат итү, икенчесе — революцион һәм сыйнфый позициядә торып фикер йөртү, ниһаять, өченчесе — иҗатын һәм бөтен эшчәнлеген милли идеаллар белән бәйләү. Бу этаплар, әлбәттә, берсеннән берсе кискен рәвештә аерылып тормыйлар. Исхакый иҗатындагы бу катламнарның берсе алдан, икенчесе соңыннанрак барлыкка килә, әмма алар берсенә берсе үрелеп, берсен берсе

тулыландырып үсәләр. Мәгърифәтчелеккә хас тенденцияләр аның иҗатының беренче этабында барлыкка килә, әмма алар икенче этапта да, өченче этапта да күзәтелә. Революцион көрәшкә йөз тоту 1905—1907 еллардагы революция чорында формалаша. Милли позициядә торып фикер йөртү Исхакый эволюциясенең соңгы этабына хас күренеш. Әмма аның чаткылары инде иҗатының беренче баскычларында ук күзгә ташлана.

Г.Исхакый иҗат мәйданына 19 гасырның азагында килеп керә. Бу елларда татар иҗтимагый фикеренең прогрессив тенденцияләре мәгърифәтчелек фәлсәфәсе белән бәйләнгән була һәм шушы фәлсәфә яшь әдипнең иҗади эшчәнлегенең эчтәлеген били иде дә. Рационализм һәм мәгърифәт идеясе — бу фәлсәфәнең төп принципларыннан. Без моны Г.Исхакый иҗатында да ачык күрәбез. Нәрсә турында гына сүз алып бармасын, нинди генә проблема күтәрмәсен, ул аларны рационализм һәм мәгърифәтчелек калыбына кидертеп анализлый, аларга шушы позициядән чыгып бәя бирә.

Г.Исхакый бөтен уй-фикерләре белән туган халкына аерылгысыз бәйләнгән әдип. Ул аның бүгенге хәле һәм киләчәге турында уйланып иҗат итә. Аны кайчандыр тарихи казанышларга ирешкән татар халкының торгынлыкка төшүе, киләчәге билгесез булуы һәм тәрәккыять юлына аяк баса алмавы борчый; ул мәгърифәтчеләргә хас рационализм принцибына таянып бу артталыкның сәбәпләрен ачарга тырыша. Бу эзләнүләр Г.Исхакыйның 1905 елгы революциягә кадәр иҗат иткән күп кенә әсәрләрендә үзләренең чагылышларын таптылар. Ә «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле фәлсәфи-публицистик хезмәтендә исә ул тәнәззелгә дучар ителүнең, түбәнгә төшүнең, тәрәккыять юлына аяк баса алмауның сәбәпләренә, гомумиләштереп, тәнкыйди анализ ясый.

Безнең арада мәгърифәтчелекне гадәти уку-укыту, әхлак төзәтү һәм дидактизм дип күзаллау яшәп килә. Хакыйкый мәгърифәтчелек исә тәнкыйди адым. Аның тарафдарлары урта гасырчылык күренешләрен һәрьяклап тәнкыйтьләп чыктылар. Бу Г.Исхакый иҗатына да хас. Ул халыкның аяныч хәлен, тәрәкъкыять юлындагы киртәләрне ачыклау максатында иҗтимагый тормышны һәрьяклап тәнкыйть күзлеге аша үткәрә. Бу анализ аны тәрәкъкыять юлында биш киртә бар, дигән фикергә китерә.

Бу киртәләрнең (манигы тәрәкъкый) беренчесе — халык тормышына тәгассыблык сазлыгына баткан, искелеккә ябышып ятучы руханилар төркеменең тәэсире. «... Милләтнең тәрәкъкыйга манигъларын эзләгәндә, — дип яза ул, — кайсы яктан карагандa да шул «голяма» сыйныфның иң алда кылычын тотып «җәһаләтне» саклавын» күрәсең.[1] Дөрес, ул руханилар арасында тәрәкъкыять тарафдарлары барлыгын да искәртә. Ләкин шул ук вакытта караңгылык сагында торучы тискәре руханиларның өстенлек итүенә басым ясый.

Халыкны тәрәкъкыять юлыннан читләштерүче сәбәпләрнең икенчесе — заман таләпләренә җавап бирердәй, җәмгыять тормышына, аның алга баруына файда китерерлек гыйлем эстәргә мөмкин булган мәктәп-мәдрәсәләрнең булмавы, ә булганнарында урта гасырдан калган тәртипләрнең һәм схоластиканың саклануы, шәкертләрнең гыйлем эстәү урынына вакытларын буш мөнәзарәләр белән уткәрүе.

Тәрәкъкыять юлындагы киртәләрнең өченчесе — милләт хадимнәренең дәрәҗәсе һәм мәгыйшәте түбән булу. Бу сәбәпкә үз вакытында Ш.Мәрҗани дә игътибар иткән иде. Аның юлыннан барып, Г.Исхакый милли мәсьәләләрне аңлаган, милләткә хезмәт итәрдәй кешеләрнең ярлы булып, милләт файдасына эш-гамәл кылу урынына, көнлекче хәленә калып, тамак туйдырырга мәҗбүр булулары тәрәкъкыять юлында зур киртә дип күрсәтә. «Хәзерге күзгә күренгән әрбабе каләмнең, — дип яза ул, — һичберсе юк ки мөстәкыйлән хәрәкәт итә алсын, һәммәсе үз тамагын туйдырыр өчен, үзләренең башмакчысы булырга ярамаган кешеләрнең кулларында уенчык булып йөриләр.» Нәтиҗәдә, «милләтнең алдан бара торган кешеләре һәм халыкка караңгы юлда ут күрсәтә торган затлары, үзләренең утларын сукырларның күзләренә зарар итмәс өчен, я бөтенләй күрсәтмәенчә халыкны караңгылыкта калдыралар, яисә тычкан уты төсле генә якты биреп, халыкны караңгы төндә адаштыралардыр.»[2]

Манигы тәрәкъкыйның дүртенчесе, Г.Исхакый фикеренчә, рус мәктәпләреннән йөз чөерү, алардан шикләнеп карау, балаларны аларда укытырга теләмәү. Руслар соңгы вакытларда мәктәпләр эшчәнлегенә зур үзгәрешләр керттеләр, уку-укытуны заман таләпләренә муафик рәвештә кордылар, җәмгыятьнең нормаль яшәеше өчен файдалы гыйлемнәр өйрәнә башладылар. Ә без

боларны күрмәмешкә салыштык, уку-укытуда русларда барган бу файдалы үзгәрешләрне кабул итәргә теләмәдек һәм нәтиҗәдә тәрәккыять юлыннан читләштек.

Манигы тәрәкъкыйның бишенчесе — алга карап, ахырын уйлап эш итә белмәү, эшләгән эшләребезнең төпсез, әсассыз (нигезсез) булуы, эш-гамәлдә эзлеклелек булмау, башлаган эшне ахырына кадәр җиткермичә ярты юлда калдыру, җәмгыятькә, халкыбызга файда китерердәй эш белән шөгыльләнү урынына, вакытны буш гамәлгә сарыф итү.

Менә шушы сәбәпләр, Г.Исхакый фикеренчә, милләтнең чабуыннан тартып тора, артка өстери, туңлыкка, катып калганлыкка китерә һәм ахырда бөтенләй юкка чыгуга, инкыйразга илтүе мөмкин.

Халкыбызны бу һәлакәттән коткару өчен ни эшләргә кирәк соң? Г.Исхакый бу сорауга мәгърифәтчелек позицияләрендә торып җавап бирә. Аның фикеренчә, тәрәкъкыять аерылгысыз рәвештә мәгърифәткә бәйләнгән. Шулай булгач, артталыктан, туңлык богауларыннан котылу, караңгылыктан арыну өчен халыкны агартырга, мәгърифәт нурлары белән нурландырырга кирәк. Әле беренче язма әсәре «Тәгаллемдә сәгадәт» (1897) тә үк Г.Исхакый гыйлем — ул бәхет чыганагы, бары гыйлемнәрне үзләштергәндә генә тормышны бизәргә мөмкин, дигән идея уздыра. «Дөньяга килүдән мәсгуд, — дип яза ул, — дөньяда ничек җитте шулай көн уздыру түгел, бәлки дөньяда үзебез рәхәт яшәп вә башка мөселман кардәшләребезнең дә рәхәт гомер кичерүләренә тырышып вә гайрәт кылып ахирәт көнендә әдәби мәсгудияткә ирешмәктер. Болар исә тәхсил гыйлемнән башка бер нәрсә белән хасил була торган түгел.»

Халыкны мәгърифәт белән нурландыруда иң нәтиҗәле юл — уку-укыту. Ә моңа заман таләпләренә җавап бирердәй уку йортлары аша гына ирешергә мөмкин. Бездә исә хәзергә мондый уку йортлары юк. Булганнарында да шәкертләр вакытларын заяга уздыралар. Һәм тормышка файда китерердәй гыйлем ала алмыйлар. Милләтнең тәрәкъкыяте өчен безгә Аурупа илләрендәге һәм руслардагы кебек эштә-тормышта файда китерердәй фәнни һәм гамәли гыйлем бирә алырдай уку йортлары кирәк. Моның өчен булган мәктәп-мәдрәсәләребезне ислах кылырга, аларны тәртипкә салырга, фәнни һәм гамәли гыйлемнәр укыта башларга кирәк. Г.Исхакый җәдит

мәктәпләре таралуына уңай карый һәм аларда шул яңа тип, фәнни һәм гамәли белемнәр бирердәй уку йортларының башлангычын күрә.

Фән һәм гыйлем өлкәсендә заман белән бергә атларга кирәклегенә Г.Исхакый аеруча басым ясап күрсәтә. «Бу гасырда халыклар гакыллар ышанмаслык машиналар иҗат кылганда, безнең димагыбыз (миебез) уйлый алмас дәрәҗәдә фәннәрне тәрәкъкый иткәндә безгә дә, — дип яза ул, — башкалар белән бер булырга, башкалар кебек эшләргә кирәктер.»[3] Моның өчен безгә һөнәр һәм сәүдә мәктәпләренә керергә, башкалар кебек үк эш-гамәл кылырга өйрәнергә кирәк. Шул ук вакытта безгә хөкүмәт мәктәпләреннән дә, рус уку йортларыннан да, университеталардан да читләшмәскә, аларга кереп укып үзебезгә файдалы гыйлемнәр алырга кирәк.

Мәгърифәт казанышларын үзләштерү өчен шулай ук халыкны уятырдай фәнни һәм әдәби әсәрләр тарату да зур әһәмияткә ия. Шуңа күрә безгә яңа әдәбият тудырырга, милләтебез тормышын яктырткан рисаләләр язарга, эшебез-гамәлебезгә файда китерердәй китаплар иҗат итәргә, ә укымышлыларыбызның авылларга китеп агарту эшләре җәелдерүе кирәк. Бу уңайдан әдип «Тәрҗеман» газетасы алып барган эшне югары бәяләп үтә.

Торгынлыктан, инкыйразга тәгәрәүдән котылу өчен мөһим шартларның берсе бердәм актив эш-гамәл юлына басу. Әгәр милләтнең киләчәге имин булуын телибез икән, курчак уены белән мавыгуны туктатырга, бөтен көчне һәм сәләтне җәмгыять өчен файдалы шөгыльгә җигәргә, максатка яраклы эш алып барырга кирәк. «Әгәр дә тәрәкъкый итик дисәк, — дип яза Г.Исхакый, — һәммәбез милләтнең иң кирәкле эшләренә тотыныйк һәм шундый кешеләргә ярдәм итешик. Барыбыз бергә бер юл белән хәрәкәт итик, һәммәбезнең теләгәнебез бер, эстәгәнебез бер булсын. Тырышыйк, авырлыкларны күтәрик, бер нәрсәбезне кызганмыйк, менә шуннан соң милләт милләт төсле булыр».[4] Ул И.Гаспралы эшчәнлеген милләт өчен, аның киләчәге өчен сарыф ителгән изге хезмәт дип бәяли һәм аның үрнәгендә эш итәргә чакыра.

Иҗтимагый тормышның нигезе — кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең югары әхлак нормаларына нигезләнгән булуы. Әхлакый бозыклыклар таралу җәмгыятьне һәлакәткә илтә. Бу уңайдан Г.Исхакый «Ике йөз елдан соң инкыйраз»да Казан халкы арасында күренә башлаган әхлакый бозыклыкларны

тәнкыйть уты астына ала. Аерым бәндәләр, — дип яза ул, — «бөтенләй этлеккә салынган... Көндезләрен вак-төяк сату иткән булып маташалар да, кичләрен гостиницалар, пивной вә фәхеш урыннарында үткәрәләр... Исереклек, зина, фәхеш таралган, бу хәтта хатын-кызлар арасына да үтеп кергән».[5]

Иҗтимагый тормышны мондый әхлакый бозыклардан арындыру, әхлакый сафлык — җәмгыятьнең нормаль яшәешенең мөһим шарты, халкыбызны торгынлык баткаклыгыннан һәм инкыйраз куркынычлыгыннан коткару юлына хәлиткеч чара. Шушы фәлсәфәгә бәйле рәвештә Г.Исхакый иҗатының беренче елларында язылган әсәрләрендә кешеләр арасында татулыкка, дуслыкка, ярдәмчелеккә дан җырлый, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек һәм фидакарьлек идеалларын күтәрә. Бу җәһәттән аның «Остазбикә» повесты бигрәк тә аерылып тора. Шул ук вакытта «Кияү» дигән повестында әдип әхлакый сукырлыкны гаепләп чыга, шөһрәт артыннан куунын нинди түбәнлеккә китерүе мөмкинлеге турында кисәтә.

Мәгърифәтчеләргә хас рәвештә Г.Исхакый иҗатының бу чорында тәрбия мәсьәләсе мөһим урын алып тора. Кешенең әхлакый йөзе, аның фикеренчә, тәрбиядән бәйле. Бала күңеле язылмаган такта. Бу тактага нәрсә языла — анысы тирәлектән, бала кемнәр белән аралашып, кем тәрбиясендә үсә — шуннан бәйле. Тирәлек әхлак ягыннан саф булса бала да чын кеше булып формалаша, ә бозык кешеләр арасында әхлакый яктан бозык шәхес тәрбияләнә. Менә әдипнең «бай углы» дигән әсәре. Бай кешеләрнең бердәнбер баласы Кәрим туган көненнән үк бозык атмосферага эләгә. Аның әнисе баласы дигәндә бернинди дә әхлак принциплары белән исәпләшми. Тәрбиясенең беренче адымнарында аның тормышында иске фикерле Сәхилә карчыкның роле зур була. Кәримне тәрбияләргә дип әтисе әхлакый яктан бик түбән, диннең нәрсә икәнен белмәгән, надан Фәхрине хезмәткә ала. Бусы балага үрнәк булырлык зат түгел, киресенчә, ул аны акрынлап алдашырга, угрылыкка, тәмәке тартырга, эчәргә өйрәтә, мәйханәләргә, фәхешханәләргә тарта. Нәтиҗәдә Кәрим бер эшкә яраксыз һәм бозык шәхес булып формалаша, ахырдан әтисен бөлгенлеккә китерә һәм үзе дә һәлак була.

Тәрбиядә таза тирәлек белән бергә уку-укыту, гыйлем үзләштерү дә мөһим роль уйный. Кәрим болардан да мәхрүм булып үсә. Аның әтисе-әнисе иске фикерле кешеләр, алар

баштанаяк кадими карашларга буйсынганнар һәм балаларын заманча итеп укытырга теләмиләр. Нәтиҗәдә бала мәгърифәттән читтә кала, бернинди белем алмый, китап белми. Бу да аны әхлакый баткаклык һәм бозыклык сазлыгына батыруда үз ролен уйный. Димәк тулы канлы, җәмгыятькә, тирәлегенә файдалы кеше үссен дисәк, кечкенәдән ук баланы тәрбияләүгә зур әһәмият бирергә, әхлакый яктан аңа таза тирәлек тудырырга, аның гыйлемнәр үзләштерүенә һәм күңелен сафландыруга ирешергә кирәк.

Үзенең әсәрләрендә Г.Исхакый хатын-кыз шәхесе, аның азатлыгы һәм тәрбиясе мәсьәләләренә бик зур урын бирә, моны милләт тәрәккыятенең мөһим шарты итеп карый. «Һәр милләтнең, — дип яза ул, — яртысы хатын-кызлар, һәр милләтнең рухын саклаучылар — хатыннар, һәр милләтнең теленең хосусый тәләффызларын, шивәсен саклаучылар хатыннар, киләчәктә ата булачак ирләрне, ана булачак кызларны тәрбия кылучылар — хатыннар идеке һәркемгә мәгълүм бер нәрсә».[6] Бәс шулай икән, ана тәрбияләү, әхлакый яктан саф, намуслы, укыган, дөньяны белә торган ана тәрбияләү җәмгыятьнең нормаль яшәеше өчен зарури шарт. Ана баланың иң якын кешесе. Югары әхлаклы, киң күңелле, белемле ана янында бала да әхлак ягыннан саф булып тәрбияләнә. Ә бозык ана янында бала бозык булып үсә. Әгәр ана тәрбияле булса, баласын ашату-эчертү белән генә канәгатьләнеп калмас, аның холкы яхшы булуы, сәламәтлеге, мәгълүматының артуы, «күзенең ачылуы» турында да кайгыртыр. Мондый «аналар милләт вә дин ноктаи нәзарыннан һәм җәмгыяте бәшәрия ноктаи нәзарыннан бик мокаддәс затлар булачаклардыр».[7] Әмма укымаган, тәрбия алмаган хатыннардан балалары өчен дә, ирләре өчен дә, җәмгыять бәшәрия өчен дә бернинди дә файда көтәргә мөмкин түгел. Димәк, кыз балаларны саф күңелле, югары әхлаклы, дини, һәрьяктан мәгълүматлы итеп тәрбияләү җәмгыятьнең мөһим вазыйфасыдыр.

Г.Исхакый үз әсәрләрендә хатын-кызның ирекле булуы, ирләр белән тигезлеге мәсьәләсен дә күтәрә. Бу да, аның фикеренчә, җәмгыятьнең нормаль яшәеше өчен мөһим шарт. Гаилә тормышы, дип хисаплый ул, ир белән хатынның дуслыгы, бер-берсен аңлап эш итүеннән бәйле. Шунда гына гаилә бәхетле була. Моның өчен егет белән кыз бер-берсен күреп-белеп, мәхәббәт

булганда гына гаилә корырга тиешләр. Г.Исхакый егет белән кызны әти-әниләренең бер-берсен күрмәгән килеш өйләндерү күренешләрен кискен рәвештә кире кага. Авторның «Тәгаллемдә сәгадәт» дигән әсәрендә өйләнешкәндә егет белән кызның үз теләкләре, үзара мәхәббәтләре алга сөрелә. Шундый кавышу — килешүчән, үзара ихтирамга нигезләнгән гаилә тормышының алшарты.

«Ике йөз елдан соң инкыйбраз» дигән әсәрендә Г.Исхакый татар тормышының ачы якларын ачып салды, аны артка этәрүче сәбәпләргә һәрьяклап анализ бирде. Шулай да ул киләчәккә өмет белән карый: аның ул еллардагы әсәрләреннән оптимизм рухы балкып тора. Ул, халкы, торгынлыктан котылып, тәрәкъкыять юлына басар дип ышана. Моның өчен халыкка, үзенең ачы язмышын күреп, инкыйразга илтүче сәбәпләрне ачык күзаллап, киләчәккә өмет белән, мәгърифәткә таянып, актив эшчәнлек юлына басарга кирәк. Шулай иткәндә киләчәгебез якты булыр. Шушы фәлсәфә — аның бу чордагы иҗатының нигезен тәшкил итә.

1905—1907 еллардагы революция Г.Исхакый иҗатына зур үзгәрешләр китерде. Революциянең беренче көннәреннән үк ул актив көрәш юлына баса. Ә монда аның элеккеге хәзерлеге, татар укытучылар мәктәбендә укуы, революцион партияләрнең программалары белән танышуы, революцион карашлы шәхесләр белән аралашуы, хезмәт кешесенең аяныч хәленә ачык күз белән, аек акыл белән карый алуы үзенең ролен уйнады. Болар барысы да Г.Исхакыйның иҗатында үзләренең чагылышларын таптылар. Аның революцион күтәрелеш башланганнан соң язган әсәрләрендә инде ачыктан-ачык революцион демократиягә хас идеяләр үзләрен сиздереп тордылар. 1906 елда Казанда Г.Исхакыйның идея җитәкчелегендә «Таң йолдызы» газетасы, ә ул ябылгач, «Таң мәҗмугасы» чыгарыла. Боларның һәр икесендә дә илдә бара торган вакыйгалар эсерлар позициясендә торып яктыртылалар.

Г.Исхакыйның фикери үсешендәге бу икенче этапның кайбер үзенчәлекләренә күз салып үтик. Бу үзенчәлекләрнең иң мөһимнәреннән берсе — иҗтимагый тормыш күренешләрен, анда бара торган процессларны сыйнфый позициядән чыгып карау һәм бәяләү. Җәмгыять, дип хисаплый әдип, ике капма-каршы сыйныфларга бүленгән. Бер якта халыкның 96 процен-

тын тәшкил итүче авыл хезмәтчәннәре белән 3 процентны тәшкил итүче эшчеләр һәм приказчиклар, ә икенче якта калган бер процентын тәшкил итүче зур корсаклы байлар һәм алпавытлар. «Россиянең мөселманнары, — дип яза әдип, — дин җәһәтеннән вә хәтта мәзһәб ягыннан да бер диндә булсалар да алар үзләренең тормышлары ягыннан бер-берсенә тәмам башка ике сыйныфка аерылалар».[8] Байлар ягында тагын бер сыйныф — бюрократия, дәүләт чиновниклары тора.

Бу сыйныфларның һәркайсының үзенә хас мәнфәгатьләре бар. Әйтик, байлар үзләренең хезмәтчеләренең озаграк та, күбрәк тә эшләүләрен, эш көненең озынрак, эш хакының исә кимрәк булуын телиләр. Эшче халык исә, үз өстенә төшкән авырлыклардан котылырга, хезмәтен җиңеләйтергә, тормышын яхшыртырга, күбрәк эш хакы алырга тырыша. Шушы нигездә сыйныфлар арасында каршылыклар туа. Бу каршылыкларны тасвирлаганда һәм эшчеләр белән авыл халкының авыр тормышы турында сүз алып барганда Г.Исхакый хезмәт кешесенең кайгысын кайгыртып фикер йөртә, эшче-приказчикларның хуҗаларының кесәләре калынаюы өчен көне-төне тир түгүләре һәм бил бөгүләре, ә авыл халкының җирсезлектән интегүе, иртәдән кичкә кадәр эшләп тә, ачлы-туклы яшәве турында сүз алып бара.

Шушы сыйнфый позициядә торып Г.Исхакый дәүләт органнарының, шул хисаптан дәүләт думасының эшчәнлеген һәм үзе бюрократия дип атаган катламны тәнкыйтьли, аларны байлар мәнфәгатен яклауда, халыкка карата башбаштаклыкта гаепли. Боларның, дип яза ул Чистай төрмәсендәге тәртипләр һәм андагы чиновникларның башбаштаклыклары турында сөйләгәндә, кыланышлары, боларның йөрешләре миңа Испаниядәге инквизиция мәхкәмәләрен хәтеремә төшерде. Мондагы һәрнәрсәдән әллә нинди золым исе тоелган кебек, ят тавыш ишетелгән кебек иде. Мондагы һәрнәрсә бюрократия золымының әллә ничә елгы шаһиты булганга «бюрократия золымының, вөҗдансызлыгының кораллары булганга, болар һәммәсе миңа җирәнгеч, сасы, кабәхәт күренәләр иде. Мондагы кешеләрдә хайвания хисеннән башка бернәрсә булмаган кебек, мондагы әйберләрдә дә матурлык-фәлән кебек нәрсә юк иде».[9] Һәм мондагы тәртипләр, мондагы тупаслык, мондагы җәберләүләр барысы да хезмәт кешесен буйсындырып тору максатында эшләнә.

Милли мөнәсәбәтләрне дә Г.Исхакый сыйнфый күзлектән чыгып бәяли. Менә аның «Таң йолдызы»ның 1906 ел, 29 маенда «Безнең мәсләгебез һәм милләт» дигән мәкаләсе. Без, татарлар, дип яза ул анда, бюрократия җәберләрен Россиянең башка халыклары кебек гражданское право ягыннан гына түгел, ә бәлки татар булган өчен дә, мөселман булган өчен дә татыйбыз. Безнең телебез кысылган, динебез кысылган. Без социалистлар һәр шәхескә хөрлек теләгән кебек, милләтчеләргә дә хөрлек телибез. Шул ук вакытта без һичбер вакытта, милләт буявына буяп, эшче һәм авыл халкын үзенең милләттәш байлары, алпавытлары файдасы өчен генә корбан булып, үзләренең икенче кавемнән булган сыйныфташлары белән дошманлыгына риза булмыйбыз. Шуның өчен без милли автономия идеясе «эшче һәм авыл халкының күзен дин, милләт буявына буяп, икенче милләтләрнең эшчеләре һәм авыл халкыннан аерыр өчен генә булса, безгә, туксан тугыз проценты эшче һәм авыл халкы булган татарларга, андый автономия кирәкми».[10] Күренүенчә, Г.Исхакый бу очракта милли мәнфәгатьләрне сыйнфый мәнфәгатьләргә буйсындырып карый, сыйнфый мәнфәгатьләрнең өстенлеген алга сөрә.

Сыйнфый каршылыкларны ничек хәл итәргә, хезмәт халкын сыйнфый изүдән ничек коткарырга соң? Моның юлы бер генә, дип җавап бирә Г.Исхакый, — көрәш, эшчеләрнең, авыл халкының үз азатлыклары өчен тартыш юлына басуы. «Тартышуда гына табарсыз сез үз хакыгызны» дип күрсәтелә «Таң йолдызы» 1906 елның 18 маенда басылган кереш мәкаләсендә. Г.Исхакый әсәрләрендә сыйнфый көрәшнең, тартышуның максатлары ачык итеп күрсәтелә. Бу максатны характерлап «Таң йолдызы»ның 1906 елның 18 маенда басылган редакцион мәкаләдә «Таң»ның лозунгысы: авыл халкы өчен җир һәм ирек, эшчеләр өчен аларның хакын хаклый торган законнар, эш сәгатен 8 сәгатькә калдыру, эш бәһасен арттыру» дип язды. Г.Исхакыйның «Таң йолдызы»нда басылган башка мәкаләләрендә бу таләпләр тагы да киңәйтелә һәм үстерелә. Алар арасында, мәсәлән, завод-фабрикаларны эшчеләр кулына тапшыру, җирне алпавытлар кулыннан алып, крестьяннарга бирү, забастовкалар ясарга һәм профессиональ берлекләргә оешу мөмкинлеге кебекләре дә бар. Максатның иң зурысы — хезмәт халкына ирек һәм социализм яулау.

Г.Исхакый үзенең әсәрләрендә байлар һәм бюрократия золымнарыннан котылу һәм ирекле тормыш яулау өчен көрәшнең юнәлешләрен дә билгели. Алар арасында беренче чиратта яңалык тарафдарлары булган яшьләрнең искелек ягында торган картларга каршы көрәше күзгә ташлана. Бу көрәш 20 гасыр башында иҗат иткән күп кенә әдипләребезнең игътибар үзәгендә тордылар. Бу характердагы әсәрләр арасында безгә Ф.Әмирханның «Яшьләр»е яхшы билгеле. Бу проблема Г.Исхакыйны да читләтеп үтмәде. Без моны аның иҗатының башлангыч адымнарында ук күрәбез. Ә 1907 елда язылган «Алдым-бирдем» драмасы исә гомумән шушы проблеманы ачуга буйсындырылган. Драманың героинясе заманчарак тәрбия алган Галия ачынып «бер яктан тегесе кыса, бер яктан болары кыса, менә юлын тап инде, гәзитә әйткәнчә менә болар белән тартыш инде! Әмма тартышам! Актыгына кадәр тартышам», ди.[11]

Дөрес, бу әсәрдә яңалык белән искелекнең көрәше әле яшьләрнең шәхси бәхетләре өчен көрәше рәвешендә гәүдәләндерелә, ул искелекнең гәүдәләнеше булган «аксак хатыннар» дөньясының җиңелүе һәм мәхәббәтнең тантанасы белән тәмамлана. Ә «Тартышу» дигән драма әсәрендә исә искелек белән яңалыкның көрәше киңрәк планда алына, татар тормышын һәрьяклап колачлый, халыкның ихтыярын басып торган караңгылык, тәгассыблык күренешләренә каршы юнәлдерелә. «Без, — дип белдерә драма геройларының берсе, — рус шәкертләре кебек мәктәп балалары гына түгел, без иске гадәт, иске тормыш белән тартышучылар, иске дөнья белән сугышучылар, безнең укуыбыз, безнең киләчәк хезмәткә хәзерләнүебез — һәммәсе иске тормышны ватар өчен, бетерер өчен, без үзебезнең һәрбер адымыбыз, һәрбер хәрәкәтебез белән иске тормышның нигезен җимерәбез... Без — яңа тормышның алдагы гаскәре. Безгә һәр минутта, һәр секундта иске тормыш белән сугышырга туры килми хәл юк».[12]

Г.Исхакый үзенең әсәрләрендә алга сөргән көрәш юлларының иң әһәмиятлесе һәм хәлиткече — иске, бюрократик идарә системасы белән көрәш, илдәге социаль-экономик һәм сәяси тәртипләрне тамырыннан үзгәртеп кору өчен социаль-политик көрәш. «Ике елдан бирле революция пожары» дәвамында, дип язды «Таң йолдызы» үзенең 1906 елның 29 маенда басылган мәкаләсендә, бюрократия Россия халкының күп канын койды.

«Бу бәладән котылуны, бу бетмәгән, төкәнмәгән бюрократия золымыннан азат булуны думадан көтү үз-үзеңне алдау гына булачак, бу авырлыклардан ватанны коткару өчен һәр кеше берләшеп, бергәләшеп бөтен мәмләкәтнең идарәсен халыкның үз кулына тапшырылуы өчен тартышырга кирәктер. Шуннан соң гына халык азат булыр, шуннан соң бөтен халыкның гражданский праволары кайтыр».

Г.Исхакыйның «Тартышу» дигән драмасында да татар җәмгыятен тамырдан үзгәртеп кору бөтен Россия күләмендәге революция аша гына, илдә гадел, демократик тәртипләр урнаштыру нәтиҗәсендә генә мөмкин булыр дигән фикер үткәрелә. «Вакыт, иптәшләр, вакыт, — ди әсәрнең герое Закир, — бу сасы куй маеннан аерылырга, күзебезне зуррак ачарга, киләчәкне ачыграк күрергә вакыт! Без моңарчы анда бер җәмгыяте хәйрия ачылуына, монда бер мәктәп салынуына әллә нинди бер зур эш дип карый идек. Ул хата. Нигез черек булганда ул мәктәптән генә, ул җәмгыяте хәйриядән генә берни чыкмый... Безгә нигезне тазартырга кирәк».[13] «Таң йолдызы»ның 1906 ел, 31 август санында басылган «Мөселман иттифакы»на безнең карашыбыз» дип исемләнгән мәкаләсендә Г.Исхакый җәмгыятьтә экономик интереслары капма-каршы булган сыйныфлар яшәгәндә революцион көрәшнең тукталмаячагын басым ясап күрсәтеп үтә.

Революцион көрәшнең өченче юнәлеше — массалар арасында революцион агарту эше алып бару, аларны тартышка хәзерләү. «Таң йолдызы» газетасын Г.Исхакый шушы максатны үтәүдә мөһим чара итеп карый, аның битләрендә патша хөкүмәте үткәргән реформалар сәясәтенең ялган асылын ачып сала, дәүләт думасының халык мәнфәгатен яклап берни эшли алмаячагын күрсәтә, хакимият диарәләренең погромнар оештырып халык массаларының революцион энергиясен милләтара ызгышларга юнәлтергә тырышканлыгын фаш итә. Ул халык арасында, бигрәк тә авыл хезмәтчәннәре арасында революцион агитация алып баруда турыдан-туры үзе дә катнаша. Ә «Зиндан» дигән әсәрендә әдип югалган ат эзләү сылтавы белән гади крестьян картының авылдан авылга йөреп крестьяннар арасында халыкка бюрократиянең ерткычлыгы турында сөйләве, бюрократияне фаш итеп җыеннарда чыгышлар ясавы, «Җир һәм ирек өчен көрәш» идеясен пропагандалавы, газета-журналлар һәм китаплар таратуы турында яза. Әдип револю-

цион идеяләр таратуга бюрократиянең дә үз өлешен кертүен күрсәтеп үтә. Аның җәбер-золымы, дип хисаплый ул, халыкның ачуын кабарта, үзенә каршы актив көрәшкә туплый.

1908 елда язылган «Тартышу» драмасының соңгы пәрдәсендә Г.Исхакый 1905—1907 еллардагы революцион эшчәнлеккә йомгак ясый һәм революция җиңелгәч илдә урнашкан тәртипләргә, реакция золымына бәя бирә. «Һәммәсе бетте, һәммәсе, — ди әсәрнең геройларыннан берсе ачынып, — Бер ел эчендә никадәр үзгәрү, бер ел эчендә никадәр артка китү! Кайда карама анда катылык. Газеталар тагы баллар хакында, генералларның чин алулары хакында яза башлады... Тагы 902 ел кайтты, әдәбият тагы кысылды, тагы изелде... Җәмгыятьләр тагы юк хөкеменә китерелде. Кайда карама — анда тентү, кайда карама — анда арестлар, кайда карама — анда суд, төрмә, ссылка, каторга, үлем!.. Бөтен Русия эскәнҗәгә кысылды!...[14] Ләкин революция җиңелсә дә, нәтиҗәсез булмады. Ул татар халкының уянуында үзенең ролен уйнады, хөр, якты дөньяга юл күрсәтте. Революция яңадан күтәрелер, чәчкән орлык чыкмый калмас, тагы җылы көннәр килер, тагы яңгыр явар, революция чәчкән орлыклардан чыккан үсентеләр ямь-яшел булып җирне каплар. Алда яңа көрәш, яңа тартышлар тора. Шулай итеп автор Россиядә урнашкан реакциягә үзенең бәһасен бирә, ул китергән авырлыкларны ачып сала һәм шул ук вакытта киләчәккә өмет белән карый, яңа революцион көрәшкә өнди.

1905—1907 еллардагы революция җиңелгәннән соң, Г.Исхакый иҗатының яңа этабы — милли позициягә күчү чоры башлана. Дөрес, бу күчеш кинәт кенә булмый. Әдипнең 1908—1911 елларда иҗат ителгән «Мулла бабай» романында, «Тормышмы бу?» дигән әсәрдә, «Сөннәтче бабай» һәм «Кияү» исемле повестьларда, «Шәкерт абый» дигән хикәядә, «Җәмгыять» һәм «Кыямәт» дигән комедияләрдә социаль-политик мотивлар инде күзгә ташланмыйлар. Аларда, И.Нуруллин әйтеп үткәнчә, гадәттә татар тормышы, төрле катлау кешеләренең хәл-әхвәлләре, теләк-омтылышлары, шатлык-куанычлары, кайгы-хәсрәтләре, татарларга хас гореф-гадәтләр тасвирлана. Мәгърифәтчелек идеологиясенә бәйле рәвештә Г.Исхакыйның бу чорда иҗат ителгән әсәрләрендә гуманизм тенденцияләре, саф әхлак тәрбияләү һәм мәгариф тарату мәсьәләләре дә яхшы ук чагылыш табалар.

Ә 1911 елда тәмамланган «Зөләйха» драмасында исә әдипнең милли идеягә йөз белән борылып иҗат иткәнлеге инде ачыктан-ачык күренеп тора. Л.Гайнанова һәм Һ.Мәхмүтов әйтеп киткәнчә, Г.Исхакый бу әсәрендә «Ничә йөз еллар изелеп яшәп тә, телен, динен, гореф-гадәтләрен, милли йөзен саклап кала алган татар халкының аяныч хәлен һәм берүк вакытта рухи батырлыгын күз алдына китереп бастыра».[15] Шушы миллилек позициясенә басуы Г.Исхакыйның 1912 елның 13 июнендә Ф.Әмирханга язган хатында да ачык күренә. Бу хатта сүз татар шагыйрьләренең мәҗмугасын хәзерләү һәм аңа Тукай шигырьләрен дә кертү турында бара. Г.Исхакый фикеренчә, бу шигырьләрдә «татар тормышы аңкып торырга тиеш».[16]

Г.Исхакыйның иҗади кыйбласының болай үзгәрүен ни белән аңлатырга соң? Монда, мөгаен, 1905—1907 еллардагы революция җиңелгәннән соң илдә тантана иткән реакция, патша хөкүмәтенең рус булмаган милләтләргә карата үткәргән ачыктан-ачык шовинистик сәясәте, аларның теленә, диненә, мәдәниятына каршы һөҗүмнәр үзенең ролен уйнаган булыр. Патша хөкүмәтенең Балкан сугышы вакытында үткәргән сәясәте дә бу җәһәттән эзсез калмады. Хөкүмәт тарафыннан татар мәктәпләренә карата алып барылган сәясәт, Буби мәдрәсәсенең таркатылуы да татар зыялыларының игътибарын социаль-политик мәсьәләләрдән милли мәсьәләләргә этәрде. Сөргендә вакытта милли-азатлык хәрәкәтендә актив эш алып барган затлар белән аралашу да Г.Исхакыйның милли проблемаларга йөзе белән борылуында үзенең ролен уйнаган булыр.

Милли позициягә күчү өчен Г.Исхакый иҗатының элгәреге этапларында да билгеле бер җирлек хәзерләнгән иде. Менә аның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» дигән әсәре. Бу әсәр, инде әйтелгәнчә, 1902—1903 елларда мәгърифәтчелек позициясендә торып иҗат ителгән. Әсәрнең башыннан ахрына кадәр авторның милләт кайгысын кайгыртып фикер йөрткәнлеге күзгә бәрелеп тора. Әдип үзенең сыйнфыйлык рухы белән сугарылган «Безнең мәсләгебез һәм милләт» исемле мәкаләсендә («Таң йолдызы», 1906, 29 май) милли таләпләрнең эчтәлеген ачып, «безнең татарлар үзләренең телләрен рус теле белән бер дәрәҗәгә килүен, безнең дә үзебезгә кирәкле нәрсәләргә правобыз булуын, мәктәпләрдә үзебезнең телдә укытуны, кирәкле законнарның татарга татарча язылуын телибез», дип яза. Ә «Таң йолдызы»

үзенең беренче санында (1906, 18 май) басылган баш мәкаләдә газета «татарларның милли вә дини эшләренең тәмам үз кулларына керүенә тырышачак, шуларны мәйданга чыгару өчен тартышачак», дип белдерә. Кабатлап әйтәм, «Таң йолдызы»нда бу таләпләр әле сыйныфлар күзлегеннән чыгып яктыртылалар. Революцион демократик позициядә торып язылган «Тартышу» драмасында (1908 ел) шулай ук милләт идеясе, аның уянуы өчен көрәш идеясе күтәрелә. 1911 елдан соң иҗат иткән әсәрләрендә инде бу идея әдипнең иҗади кыйбласына әйләнә.

1913 елда Петербургта Г.Исхакый нәширлегендә һәм мөхәррирлегендә «Ил» исемендә татарча иҗтимагый-сәяси газета чыга башлый. Газетаның идея юнәлеше һәм эчтәлеге Г.Исхакый тарафыннан билгеләнә һәм миллият рухы белән аерылып тора. «Милли тойгы мәсъулиятен хис итү, — дип күрсәтелә «Ил»нең 1913 ел, 28 ноябрь санында, — безгә эшләргә, хәл итәргә куша, көчләп-көчләп куша, безне генә түгел, бөтен зыялыларыбызны куша». Газета битләрендә татар тормышының төрле яклары яктыртыла. Монда иҗтимагый тормыш мәсьәләләренә, сәяси һәм икътисади мөнәсәбәтләргә, тормыш-көнкүреш мәсьәләләренә, уку-укыту, мәктәп-мәдрәсә, тәрбия мәсьәләләренә, татар театры эшчәнлегенә, китап басу, вакытлы матбугат тарату мәсьәләләренә, имамнар эшчәнлегенә һ.б. кагылышлы мәкаләләр очратасың. Газета нинди генә мәсьәлә күтәрмәсен һәркайсын бер позициядән — милләт ноктаи нәзарыннан, аның мәнфәгатьләре, бүгенге хәле һәм киләчәге күзлегеннән чыгып анализлый һәм бәя бирә.

«Ил» битләрендә Г.Исхакый милли идеал мәсьәләсен дә күтәрә. Бу турыда сүз йөртеп ул, мәсәлән: «Әдәбиятыбыз мәйданга чыгар-чыкмас аның беренче эше һәм дә уйлап, план белән түгел, үзеннән-үзе килеп чыгып эшләнгән эше, табигый бер хәрәкәтне әдәбиятыбызга максатка әйдәүче идеал тәгаен итү булды. Ул аны газеталар, журналларда үзен мөзәкарә, мөнәзарәләр соңында гакыл белән уйланып, мантыйк белән үлчәп, бу кирәк, бу кирәкми юллары белән түгел, тагы ук табигый юл белән, иң дөресе **милли йөрәк** белән генә хәл итте дә куйды. **Ул идеалда без бер халык, бер милләт**».[17]

Бу миллият позициясе, уй-фикерләрне милли идеалдан чыгып йөртү Г.Исхакыйның «Ил»дә басылган башка мәкаләләрендә, ул ябылгач, «Сүз» газетасында дөнья күргән язмаларында,

әдәби һәм публицистик әсәрләрендә тагы да үстерелә һәм нигезләнә. Аның 1917 елда Ф.Әмирхан рәислегендә үткәрелгән банкетта ясаган чыгышы бу үсешне йомгаклау рәвешендә әйтелгән сүзләр булып яңгырый. 1905 елгы революциядә, дип белдерә Г.Исхакый бу чыгышында, без сыйнфыйлык байрагы астында бардык, хәзер исә милли байрак астына басарга тиешбез. Ләкин бу безнең демократиягә хыянәт итеп буржуазиягә сатылуыбыз дип каралырга тиеш түгел. Чөнки хәл үзгәрде. Безне буып торган самодержавие җимерелде һәм безнең бурыч хәзер «шул хәрабәнең урынын чүпләрдән арчып, аның урынына милли мәдәният иҗат итү, милли рәфаһидәт (ирек) торгызудыр». «Шул иҗади эшнең нык фундаменты салынып өлгереп, сыйнфый көрәшкә тотыну вакыты җиткәч, без үзебезгә кайсы сыйныф тарафыннан торырга тиешлекне белербез».[18]

1905—1907 елгы революция җиңелгәннән соң акрынлап сыйнфый позициядән милли позициягә күчү, әйтергә кирәк, бер Г.Исхакыйга гына хас нәрсә булмады. Бу татар демократик интеллигенциясе вәкилләренә хас гомуми күренеш иде. Бер генә мисал. 1914 елда «Аң» журналында татар демократик интеллигенциясенең күренекле вәкиле Ф.Әмирхан «Олуг милләтче тугрысында кечкенә бер хатирә» дигән мәкалә бастырды. Анда сүз күренекле җәмәгать эшлеклесе И.Гаспралының 1906 елда Петербургта мөселман съездында ясаган бер чыгышы турында бара. Безнең арадан бер иптәшебез (сүз сыйнфый позициядән торган революцион рухлы татар яшьләре турында бара), дип яза Ф.Әмирхан үзенең мәкаләсендә, съездны әйдәп баручы милләт эшлеклеләрен гаепләп бик ачы сүзләр әйтте. Моңа каршы И.Гаспралы: «Угылым, — дип белдерде, — сез яшьсез, тәҗрибәсез сез. Шунлыктан кирәгеннән артык каты гыйбарәләр истигъмал итәсез... Сезнең кеби кызу рухлы яшьләребез милләткә хезмәт итеп, аның мәдәни дәрәҗәсен үстерсәләр ул вакытта без сыйнфый ихтиляфлар (каршылыклар) тугрысында сөйләшербез, фикер йөртербез. Мәдәнияты юк бер милләтнең промышленносте була алмый, шулай булгач әле сыйнфый низагларга да иртә. Безнең бу көнгә вазыйфабыз әле мәдәни үсүдән вә шуңар юллар хәзерләүдән гыйбарәт... Аннан соңгысын бездән соңгылар карарлар». [19] Бу — татар милләтчесенең позициясе. Ф.Әмирхан исә ул вакытта (1906 елда)

әле сыйнфыйлык һәм революцион көрәш позициясендә тора. Ә 1914 елда, бу мәкаләсен язганда, ул инде И.Гаспралының үзенә дә, аның бу карашларына да ихтирамын, аңа теләктәшлеген белдерә һәм үзенең дә шушы позициягә күчеп фикер йөртә башлавын күрсәтә.

Инде күргәнебезчә, Г.Исхакый да бу елларда шушындый ук фикери эволюция кичерә һәм милләт кайгысын кайгыртып яза башлый, милләтне, аның телен, мәдәниятын саклау идеясен күтәрә. Ул милли һәм дини изүне гаепләп чыга, патша чиновникларының, миссионерларның татар халкына карата үткәрелгәнерткычлыкларын фаш итә, милли колониаль изүнең, шуның бер күренеше булган көчләп чукындыруның фаҗигале нәтиҗәләрен ачып сала. Бу яктан аның «Зөләйха» исемле драмасы аерым урын алып тора. Менә әсәрдә патша чиновникларының мәрхәмәтсезлеге ничек тасвирлана. «Теге Әхмәди абзыйлар эше белән моннан Казанга кадәр богаулап алып бардылар, — ди әсәрнең герое Гыймади, — юл буе кыйный-кыйный киемебезне генә түгел, тәннәребезне тишкәләп бетерделәр. Мескен Мирсәяф чыдый алмады, үлде. Поп алдында «Алла» диеп, иман китереп үлде. Теләсә кая күмсеннәр, кыямәт көнне аллаһы тәгалә мөэминнәр груһыннан аермасын. Ул казаматтагы кыланышларны әйтмә дә инде! Карчык судка килгәч танымады».[20] Әмма бу кыерсытуларның, бу җәберләүләрнең иң авыры физик җәбер түгел, ә рухи җәбер, рухи богаулар. Зөләйха 25 ел төрмәләрдә утыра, каторгада була. Себерне дә күрә, андагы җәбер-озлым турында ачынып сөйли. «Бик күп нәрсә күрдем, — ди ул, — Ләкин иректә күргән начарлыкны төрмәдә күрмәдем. Ниләр булмады, ниләр баштан кичмәде. Кыйналдым, мыскыл ителдем, суктырылдым. Бөтен тән җәзаларын күрдем. Ләкин мондагы кебек, иректәге кебек күңелемә каравыл куймадылар. Теләгәнчә намазымны укыдым. Теләгәнчә рузамны тоттым».[21]

Бу әсәрдә Г.Исхакый шул ук вакыт милли-азатлык өчен көрәш идеясен дә күтәрә. Дөрес, бу очракта әйтелгән көрәшнең максаты ата-баба диненә тугрылыкны саклау өчен көрәш буларак күз алдына китерелә. Әсәрнең герое Гыймади карт әңгәмәдәшләрен дин өчен көрәш юлыннан тайпылмаска өнди. «Нинди көчләсәләр дә, — ди ул, — газиз динегездән, бабаларыбызның диненнән аерылмагыз. Дөнья дәүләтенә, дөнья ләззәтенә

алданмагыз! Ил гомере — бер көн. Үтә дә китә. Әхирәт мәңгелек. Әхирәтне югалтмагыз!»[22] Әсәрнең геройлары Сәлимҗан да, Зөләйха да, башкалар да бөтен эш-гамәлләрен шушы максатка буйсындырып яшиләр.

Г.Исхакыйның «Зөләйха»дан соң иҗат ителгән әсәрләрендә һәм публицистик язмаларында инде беренче планга турыдан-туры милләт язмышы, аның бүгенге хәле һәм киләчәге калкып чыга. «Халкыбызның өсте-башы бөтен, ашы-суы иркен, йөзе-күзе күркәм, көе-җыры көчле, йөреше-барышы тугры иттереп күрәсебез килү, — дип белдерелә «Ил»нең беренче санында, — безне зур мәсъулиятле «Ил» эшене җилкәбезгә алырга мәҗбүр итте... Милли тойгыбыз шул хәрәкәттә бергә булырга, тарих көпчәге әйләнгәндә аның (милләтнең — Я.А.) алга таба атлавы өчен тырышырга, тартышырга безне дә кушты».[23] Газетаның шушы ук санында басылган «Матбугат» исемле мәкаләдә Г.Исхакый татар матбугаты алдында торган бурычлар турында сүз алып бара. «Матбугат вазыйфасының иң авыр, иң изгесе, — дип яза ул анда, — милләт эшләре». Милләткә хезмәт итү, аның фикеренчә, матбугат эшчәнлеген бәяләүдә ин төп үлчәм булып тора. Мәктәп-мәдрәсә турындамы, мөгаллимнәр яисә имамнар эше турындамы сүз алып барса да, матбугат һәркайчан милләт мәнфәгатьләрен күз алдында тотып эш итәргә тиеш.

Милләтне саклауның мөһим шарты, Г.Исхакый фикеренчә, милли үзенчәлекләрне, милли мәдәниятыбызны саклау. Безнең халкыбыз, мәдәниятыбыз, дип яза ул «Ил»дә урнаштырылган «Элек һәм хәзер» дигән мәкаләсендә (1913 ел, 14 ноябрь), элек-электән фарсылык һәм гарәбилек басымын тоеп яшәде. Хәзер ул йөрәге белән «черегән фарсы, мөнкарыйз булган гарәп белән таза төрек, нык татар арасында уйда, фикердә, планда һичнинди бертөрлелек булмавын аңлап, үз юлына, үз төркилеге юлына басты һәм милләт буларак үзен саклап кала алды. Милли үзенчәлекләрне саклауда аңа милли тойгылар, милләт идеалы таяныч булды.

Хәзер безнең милли бөтенлегебезгә, милләтебезнең асылына Аурупадан килә торган яңа куркыныч яный. Бу Ауропаның әдәбияты, театры, фәлсәфәсе, музыкасы, фәне, сәнаигъ нәфисәсенә, техникасына, экономикасына ияреп килә торган агу — фәхешлек, рухи пычраклык, әхлаксызлык һәм һәрнәрсәне, шул

хисаптан кеше намусын да, сату-алу объектына әйләндерү. Болар безнең борынгыдан килә торган әхлакый ныклыгыбызны кырыеннан кимерәләр. Без моңа юл куймаска, әхлакый сафлыгыбызны, рухи бердәмлегебезне җимерергә ирек бирмәскә, милли үзенчәлекләребезне саклап калырга тиешбез. Әдип фикеренчә, татар халкы мондый көчкә ия һәм ул үзенең мәкаләсен «Идел буенда гарбтән агып килә торган икенче туфанда батмаслык көч бар», дип тәмамлый.[24]

Милләтнең бөтенлеге, башка милләтләр арасында хөрмәткә лаеклы булып яшәве мәсьәләсенә Г.Исхакый үзенең публицистикасында кат-кат әйләнеп кайта. «Без, — дип яза ул «Ил»нең 1914 ел, 5 февраль санында, — хәзер үзебезнең киләчәк өчен тырышырга, пакь мәдәни бер милләт булып яшәргә хакыбыз бармы-юкмылыгын тикшерә торган бер имтихан алдында торабыз. Без үзебезнең татар дөньясы алдында гына, мөселман голәмасының матбугаты алдында гына түгел, Россиянең эфкяр гомумиясе, Россиянең матур пакь интеллигенциясе алдында имтихан тотабыз». Әдип татар халкының бу имтиханны тота алуына, пакьне пычрактан аера алуына, сәяси тәрбиясенең югарылыгына, милли рухны саклый алуына ышанып фикер йөртә.

Шул ук вакытта халкыбыз арасында милли горурлык тәрбияләүнең мөһим икәненә дә басым ясап үтә һәм милли талымсызлыкны гаепләп чыга. «Без, — дип яза ул, — үзебезне үзебез тота белмибез, үз арабызда сөйләргә яраган һәр сүзне, ятлар арасында сөйләргә ярамаганны, үз арабызда яманларга, тәнкыйть итәргә мөмкин фикерләр-уйларны, ятлар арасында шулай итәргә кирәкмәгәнне, шулай итү безгә җиңелчә итеп карарга сәбәп булганын белмибез. Шуның белән руслар арасында үзебезне кимсетә торган эшләр эшлибез. Алар белән үзебезне яманлашабыз, үзебезне мыскыл итәбез».[25] Бу халкыбызның дәрәҗәсен төшерә, милли горурлыгы булган кеше моңа бармаска тиеш.

Г.Исхакый милли мәсьәләдә тотрыклылыкны, пакьлекны, сафлыкны һәм принципиальлелекне яклый. «Ул әле өйләнмәгән иде» исемле повестында әдип бу мәсьәләдә принципсызлык, чигенү һәм тайпылулар юлына басуның баткаклыкка илтүен, милли йөзеңне саклау юлында чишелә алмаслык төеннәр тудыруын күрсәтеп үтә.

Күргәнебезчә, Г.Исхакый милләт кайгысын кайгыртып, аның башка халыклар арасында дәрәҗәсе турында кайгыртып, татар халкының киләчәктә дә милләт буларак яши алуы, аның мәдәнияты үсеше турында кайгыртып фикер йөртә. Революцион 1917 елга ул шушы позициядә торып аяк басты, һәм татар халкының милли азатлыгы өчен көрәшүчеләрнең алгы сафында торып эш итте. Ул мөселман корылтайларының эшенә актив катнашты, аларның эшчәнлегенә идея юнәлеше бирүчеләрдән булды. Бу корылтайларда кабул ителгән карарларның күбесе аның кулы белән языла. Милли азатлык өчен көрәшкә басарга чакырып Г.Исхакый ялкынлы чыгышлар ясый, вакытлы матбугатта мәкаләләр бастыра. Ул башта татарлар арасында зур яңгыраш тапкан «милли мәдәни автономия» идеологиясенең тарафдары була һәм аның концепциясен хәзерләүдә актив катнаша. 1917 елның азагында «Милли мәҗлес» оеша. Г.Исхакый аның эшендә шулай ук актив катнаша. «Милли мәҗлес» рамкаларында милли-территориаль мохтәрият һәм «Идел-Урал штаты» идеясе калкып чыга. Г.Исхакый бераз икеләнүләрдән соң бу идеяне дә кабул итә һәм «Идел-Урал штаты» лозунгысы астында татар халкының милли үзбилгеләнүе өчен җәелдерелгән көрәшендә актив роль уйный.

Г.Исхакыйның бу эшчәнлеге милләтчелек дип бәяләнде һәм бу бәяләмә бер өрәк рәвешендә аның иҗатын һәм эшчәнлеген каһәрләү максатында кулланылды. Дөресен әйтергә кирәк, бу эшчәнлек, бу иҗат чыннан да милләтчелек рухында иде. Ләкин аны каһәрләргә урын юк. Милләтчелек ул үз милләте, аның киләчәге, теле һәм мәдәнияты турында кайгыртып эш итү. Бу Г.Исхакый эшчәнлегенә дә хас нәрсә булды.

Бездә милләтчелекне еш кына шовинизм белән тәңгәлләштерәләр. Әмма милләтчелек ул шовинизм түгел. Анда башка милләтләргә карата өстен карауның, башка милләтләр өстеннән хакимлек итүгә тырышуның мыскалы да юк. Г.Исхакый иҗатында да шовинизмга хас мондый сыйфатларның эзе дә күренми. Бөек әдипнең әсәрләрендә һичнинди милли чикләнгәнлек юк. Ул рус халкына да, аның мәдәниятына да ихтирам белән карый, руслар белән татарлар арасында мөнәсәбәтләрнең нормаль булуын канәгатьләнү хисе белән күрсәтеп үтә. «Дүрт йөз ел эчендә, — дип яза ул, — «Ил»нең 1914 ел, 10 гыйнвар санында, — күрше-күршечә яши торган

рус халкы белән татар халкы берсен-берсе тәмам танып бетте. Авыллары иген эшендә, шәһәрләрдә сату-алу эшендә алар кычкырышмаенча-талашмаенча тыныч тормыш кичерәләр». Шул ук вакытта илнең башка төбәкләрендә без милләтләр арасындагы ызгышлар турында белеп торабыз. Идел буенда исә мондый нәрсәнең күренгәне дә, ишетелгәне дә юк. «Катгыян иминбез һәм дә мондый нәрсәләр һичбер вакыт күреләчәк, ишетеләчәк түгелдер. Чөнки ике милләт тә бер-берсен таныды, бер-берсенең холкын, вазыйфасын аерды, кычкырышырлык, аңлашылмаслык нәрсә калмады».

Күренүенчә, Г.Исхакыйны милләтләр арасына чөй кагуда, татар халкына башка милләтләр арасында өстенлек даулауда гаепләү бары уйдырма гына. Гали Акыш үзенең истәлекләрендә күрсәткәнчә, ул коммунизмны җимерүне дә максат итеп куймады. Аның төп максаты «Идел-Урал халыкларының һәм, гомумән, рус булмаган халыкларның үзбилгеләнү хокукын яулап алудан гыйбарәт иде».[26]

Г.Исхакый милләтчелегенең асылында татар халкының милләт буларак яшәеше мәсьәләсе ятты. Ул үз халкының бөтенлеге, иминлеге, тормышын үзе теләгәнчә кору мөмкинлеге турында уйлап иҗат итте, шуның өчен көрәште. Ул милли телнең, милли мәдәниятның яшәеше турында кайгыртты, моның юлларын эзләде. «Мин, — дип язды ул соңыннан, — бөтен гомерем буена төрек-татар халкының бәхете, иркенлеге өчен көрәштем... Тәңре сезләргә ватаныбыз Идел-Урал азатлыгын күрергә насыйп итсен».[27] Ул бу көннең килүенә ышанып яшәде. Әле 1914 елда ул «Ил» газетасында (29 март) «Язгы суга каршы буа тоттырып булмаган кебек, уянган халыкка каршы да киртә салып булмыйдыр», дип язды.

Үз халкының бу азат киләчәгенә ышанычын Г.Исхакый 1933 елда эмиграциядә язылган «Идел-Урал» дигән хезмәтендә кабатлый. «Русские, — дип яза ул, — привыкшие в течение столетий властвовать над всеми национальностями бывшей России, до сих пор еще несмотря на тяжелые уроки истории, не могут отказываться от мысли быть господином над «инородцем». Но они жестоко ошибаются. Российская революция еще не закончена. Большевики в этой революции являются только одним из переходных этапов ее. Эта революция, имеющая в настоящее время своим основным содержанием именно нацио-

нальный вопрос, может быть закончена только радикальным разрешением национального вопроса в бывшей России и окончательным освобождением народов, борящихся за свою независимость. Если великая французская революция принесла национальное освобождение народам запада Европы, то Российская революция принесет освобождение народам востока Европы».[28]

Әдип бикерактан күрә белгән. Рус империясенең совет чорындагы гәүдәләнеше булган СССР инде таркалды һәм күп кенә халыклар үзләренең милли бәйсезлегенә ирештеләр. Әмма көрәш дәвам итә. Россия федерациясенең идарәче даирәләре кысылганрак рамкада булса да империяне саклап калырга тырышалар. Әмма көрәш, Г.Исхакый билгеләп үткәнчә, Аурупаның көнчыгышындагы барлык халыкларның милли бәйсезлеге яулап алынганчы дәвам итәчәк.

[1] «Казан утлары», 1990, №1, 110 б.
[2] Шунда ук, 112 б.
[3] «Казан утлары», 1990, №1, 145 б.
[4] «Казан утлары», 1990, №1, 113 б.
[5] «Казан утлары», 1990, №1, 123—124 бб.
[6] «Казан утлары», 1990, №1, 126 б.
[7] «Казан утлары», 1990, №1, 127 б.
[8] «Таң йолдызы», 1906, 31 август.
[9] Исхакый Г. «Зиндан», Казан, 1991, 26 б.
[10] «Таң йолдызы», 1906, 29 май.
[11] Г.Исхакый, «Зиндан», Казан, 1991, 388 б.
[12] Шунда ук, 440 б.
[13] Исхакый Г. «Зиндан», Казан, 1991, 448 б.
[14] Исхакый Г. «Зиндан», Казан, 1991, 471 б.
[15] Исхакый Г. «Зиндан», Казан, 1991, 646 б.
[16] «Казан утлары», 1991, №2, 183—184 бб.
[17] «Ил», 1913, 14 ноябрь.
[18] «Кояш», 1917, 13 апрель.
[19] Әдәби мирас, 1 китап, Казан, 1991, 23 б.
[20] Исхакый Г. «Зиндан», Казан, 1991, 518 б.
[21] Шунда ук, 564 б.
[22] Шунда ук, 526 б.
[23] «Ил», 1913, 22 октябрь.
[24] «Ил», 1913, 22 октябрь.
[25] «Ил», 1913, 22 ноябрь.
[26] Нуруллин И. Әдипнең соңгы көннәре. Шәһри Казан, 1992, 12 февраль.
[27] «Казан утлары», 1991, №5, 161 б.
[28] Исхаки А. «Идель-Урал», Париж, 1933, с.62.

1991 ел.

III

ЫШАНМАУЧАНЛЫК КИРТӘЛӘРЕ, ШИК-ШӨБҺӘЛӘР АША ҮТЕП[1]

Шушы елның февраль башларында (1988 ел) безгә, һәркайсыбызга аерым-аерым, АКШның Висконсин университетыннан һәм Үзәк Азияне өйрәнү Ассоциациясеннән халыкара фәнни конгресс эшендә катнашырга һәм докладлар белән чыгыш ясарга тәкъдим итеп хатлар килеп төште. Хатта конгрессның апрель азагында җыйналачагы һәм анда Үзәк Азия халыкларының, шулай ук аларга чиктәш булган башка төбәкләрдә яшәүче халыкларның теле, әдәбияты, тарихы һәм иҗтимагый фикере мәсьәләләре тикшереләчәге күрсәтелгән иде. Анда шулай ук оештыру комитетына Америка Кушма штатларыннан, Кытайдан, Көнбатыш Аурупа илләреннән күп кенә галимнәрнең катнашырга теләкләре барлыгы һәм инде докладларның тезислары да килгәнлеге кисәтелгән иде.

Хат безгә 1,5 ай чамасы килгән. Инде калган арада оештыру комитеты белән элемтәгә керә, илдән чыгып китү өчен тиешле документларны хәзерләп бетерә алырбызмы дигән шөбһә туды. Чөнки безне әйтелгән документларны хәзерләргә дүрт айга якын вакыт кирәк дип кисәтеп куйдылар. Шулай да без тәвәкәлләп карарга булдык һәм оештыру комитетына үзебезнең ризалыгыбызны белдереп һәм докладларыбызның темасын әйтеп хат юлладык. Бер үк вакытта докладларыбызны язарга керештек.

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты дирекциясе (без шунда җитәкче фәнни хезмәткәрләр булып эшлибез) безнең теләкне хуплады, ә республиканың тиешле даирәләре озакка сузмыйча безнең фәнни командировкабыз белән бәйләнешле мәсьәләләрне чиштеләр. Инде март аеның урталарында СССР Фәннәр академиясе Президиумы безнең чит илгә чыгу белән бәйләнгән фәнни командировкалар исем-

легенә кертелүебез турында хәбәр итте. Димәк, безнең өлгерүебез мөмкин! Мәсьәләнең болай тиз чишелешендә без ил тормышында һәм Америка-Совет мөнәсәбәтләрендә уңай якка борылышны сиземләдек.

Озакламый без Үзәк Азияне өйрәнү Ассоциациясе Президенты профессор Кемал Х.Карпаттан конгрессны оештыру комитетына җибәргән хатыбызга җавап та алдык. Бу хатта хөрмәтле профессор безнең докладларның конгрессның программасына кертелүе турында әйткән иде. Шул ук көннәрдә бу хәбәр Кемал Х.Карпаттан килгән телеграмма белән дә расланды. Хатта да, телеграммада да ул безгә Нью-Йорктан конгресс узачак Медисон шәһәренә ничек барырга һәм авиобилетларны кайда һәм нинди юл белән алырга кирәклеген, безнең Америкада яшәү шартларын бик тәфсыйлләп аңлаткан һәм безнең Америкада булган көннәрдә тотылачак чыгымнарны тулысынча Ассоциациянең үз өстенә алганлыгын күрсәткән иде (соңыннан безгә конгрессны уздыру өчен тотылган чыгымнарны каплауны Америка миллиардеры, танылган меценат Соросның үз өстенә алганлыгы билгеле булды). Яңа географик шартларга яраклашу, Медисон шәһәренең һәм Висконсин штатының истәлекле урыннары белән танышу һәм экскурсияләрдә катнашу өчен без Медисон шәһәренә 24 апрельдән дә соңга калмый килергә тиеш булып чыктык.

22 апрельдә без инде Мәскәүдә СССР Фәннәр академиясе Президиумының фәнни бәйләнешләр идарәсендә идек. Әмма монда безнең өчен көтелмәгән тоткарлык туды. Аэрофлот һәм «Пан-Американ» самолетларына билетлар Мәскәүдән 26 апрельгә кадәр сатылып беткән булып чыкты. Көнбатышның авиофирмалары ярдәмендә без 25 апрельдә Прагадан Нью-Йоркка Чехословакия Авиокомпаниясе самолеты очачагын белдек һәм шул самолетта үзебезгә урын калдыруга ирештек. Шулай итеп безгә башта Мәскәүдән Прагага очарга туры килде. Кемал Х.Карпатның киңәше белән без Нью-Йорктан Чикагога очуны планлаштырган идек. Чөнки аннан Медисонга очу кулайрак. Күрәсең вазгыять үзгәрде. Прагада утырып Нью-Йоркның Кеннеди исемендәге аэропортына без бик соң килеп җиттек. Шуның өстенә аэропортка бер үк вакытта берничә самолет килеп кунган булып чыкты. Аларның пассажирлары барысы да Америкага керергә рөхсәт алыр өчен иммиграция

агентлыгы янына җыйналды. Гомуми чиратта безгә өч сәгать көтәргә туры килде. Нәтиҗәдә без Чикагога очучы самолетка өлгермәдек. Безгә Нью-Йоркның Хилтон фирмасы кунакханәсендә бер төн кунарга туры килде.

Безнең делегация Мәскәүдә тарих фәннәре докторы С.Алеев (делегация җитәкчесе), Әзербәйҗан Фәннәр академиясенең тарих институты галимнәре Г.Гулиев, О.Эфендиев, А.Аббасов, Үзбәкстан Фәннәр академиясенең Икътисад институты директоры урынбасары Р.Ибадуллаева, Таҗикстан Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы А.Мохтаров әфәнделәрдән торды. Моннан тыш без Мәскәүдә конгресска Казагыстан язучылары союзы рәисе О.Сөләймановның, КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясеннән фәлсәфә фәннәре докторы Г.Керимовның һәм Карачай-Черкас автономияле өлкәсеннән шагыйрә А.Караеваның чакырылганлыгын белдек. Алар өчен билетлар СССР Язучылар берлеге аша алдан рәсмиләштерелгән булып чыкты һәм алар «Пан-Американ» самолетында бездән алда, 24 апрельдә үк Мәскәүдән Нью-Йоркка турыдан очып киттеләр.

Нью-Йоркта безне профессор Майкл Рывкин каршы алды. Бу шәһәрдә булган сәгатьләрдә без тулысынча аның карамагында булдык, һәрдаим аның ихтирамы һәм игътибары сизелеп торды. Иртәгесен ул безне Нью-Йоркның Ла Гардия дигән аэропортына озатып куйды. Аннан без Детройт аша Медисонга очтык. Профессор М.Рывкин үзе Медисонга иртәгесен килде. «Россия — СССРда социаль һәм мәдәни үзгәрешләр» дигән секциянең эше белән җитәкчелек итте, аның утырышларының берсендә доклад белән чыкты.

Медисон аэропортында безне Кемал Х.Карпат үзе, профессор-славист Алекс Ролих, аспирант-тюрколог Айшә-Денис каршы алдылар. Безне Ловелл Холлга урнаштырдылар. Бу университет шәһәрчегенең үзәгендә урнашкан 6 катлы зур гына бина. Аның күп өлешен кунакханә били, рестораны, почтасы, конференц-залы, ял итү һәм гәпләшеп утыру өчен бик яхшы җиһазландырылган холлары бар. Шул ук көнне безнең өчен автобуста Медисон буйлап экскурсия оештырылды. Кичен Конгресска килүчеләр ресторанга аш мәҗлесенә чакырылдылар. Анда Кемал Х.Карпат конгрессның бурычлары һәм эш тәртибе турында сөйләде, килгән делегатларны тәкъдим итте. Аннан соң университетның тарих факультеты деканы профессор

Е.Давид Кронен чыгыш ясады. Ахырда О.Сөләйманов совет делегациясе исеменнән чыгып конгрессны оештыручыларга рәхмәт сүзе әйтте һәм аның илләребез халыкларының үзара аңлаша алуына өлеш кертә алуына һәм югары фәнни дәрәҗәдә үтүенә ышаныч белдерде.

Конгресска күп кенә АКШ университетларыннан, Англиядән, Норвегиядән, Швециядән, Франциядән, Даниядән, Польшадан, Төркиядән, Кытайдан, Көнбатыш һәм Көнчыгыш Германиядән, Пакистаннан танылган галимнәр килгән иде. АКШ делегациясеннән кала иң күп санлы делегацияләр СССРдан һәм Төркиядән булды.

Медисон — Висконсин штатының башкаласы. Бу штат Бөек күлләр төркеменнән Мичиган һәм Югары дип исемләнгән күлләр кочагында урнашкан. Үзенең капитолие булган Медисонны студентлар шәһәре дип атарга мөмкин. 250 меңгә якын кеше яшәгән бу шәһәр университетында 50 мең студент укый. Алар арасында төрле илләрдән чыккан һәм төрле ырк (раса) вәкилләреннән торган егетләр һәм кызлар. Шәһәрнең хуҗалары да студентлар. Алар шәһәр тормышына кагылышлы барлык мәсьәләләрне, шул хисаптан торак, транспорт, урамнардагы тәртип мәсьәләләрен хәл иткәндә актив катнашалар. Студентлар, мәсәлән, шәһәрнең үзәк урамнарында машиналар йөрешен туктатуга ирешәләр. Шәһәрнең үзәге ял итү, очрашулар һәм митинглар үткәрү урыны итеп тәгаенләнгән. Медисон университеты студентлары беренчеләрдән булып АКШның Вьетнамдагы сугышта катнашуына каршы чыгалар. Аларның бу чыгышы соңыннан АКШның башка университетлары студентлары тарафыннан да хуплана. Шәһәрнең үзәк урамнары һәртөрле студент бәйрәмнәре үткәрү мәйданы дип хисаплана. Кояшлы көннәрдә монда газоннарны, урам-тротуарларны төрле кием кигән (араларында ярым шәрәләре дә була) яшьләр каплый: берәүләре укый, икенчеләре төрле уеннар белән мавыга, ә өченчеләре музыка белән ләззәтләнә... Әгәр дә инде башыгызны нindидер фикерләр биләп алса, күтәренке урыннарга куелган мөнбәрләр артына басып теләсә нинди темага чыгышлар да ясый аласыз. Бу чыгышлар тынычлыкны саклау турында да, шәһәрдәге тәртипсезлекләр турында да, секс турында да булырга мөмкин. Аларда шәһәр түрәләре һәм университет җитәкчеләре адресына тәнкыйть тә яңгырый. Беркемне беркем тыймый.

Телисең икән тыңлыйсың, теләмисең — узып китәсең. Без үзебез дә шундый чыгышларның берсенә тап булдык: кичерәк кенә мәйдан уртасына куелган мөнбәр артына баскан өлкәнрәк яшьтәге кырыс кына ханым нотык тота. Тирә-юньгә куелган скәмияләрдә, агач төпләрендә, чирәм өсләрендә яшьләр утырган, һәркайсы үз эше белән мәшгуль, ораторны тыңлаганнары абайланмый. Ә ханым сөйли...

Көндез генә түгел, төннәрен дә шәһәр — студентлар карамагында. Безгә студентларның инде якынлашып килүче җәйнең беренче җылы көнен ничек билгеләп үтүләренең шаһитләре булырга туры килде: төн буе музыка яңгырады, петардалар шартлады, тирә-юнь шау-шу, көлү-шыркылдаулар белән яңгырап торды. Иртә белән бөтен скверлар, урамнар, чирәмнәр төрле чүп-чар, кока-кола, пепси-кола банкалары, кәгазь стаканнар һәм кулсөрткечләр белән капланган иде... Ә иртән сәгать тугызларга бөтен урам-скверлар да бу чүп-чардан чистартылган, юдырылган, газоннар тәртипкә кертелгән булып чыкты... Һәм моны студентлар үзләре үк эшләде... Безгә университетның эчке тормышының күп кенә мәсьәләләре (кемгә һәм күпме стипендия түләргә, кемне университеттан куарга, кемгә материаль ярдәм күрсәтергә, китапханәнең акчасын нинди китаплар алу өчен тотарга һ.б.) студентларның үзләре тарафыннан хәл ителә, диделәр.

Матбугат та, укылган китаплар да, радио-телевидение дә безнең аңыбызга Америка шәһәрләре, бигрәк тә аларның зурраклары урамнарына кояш төшми торган биек йортлардан тора, ә шәһәр һава белән катнашкан төтен пәрдәсе (смог) белән капланган кебегрәк фикер сеңдерелде. Медисон исә моңа һичкенә ошамаган. Ул шәһәр-курортка тартым. Биек йортлар башлыча аның үзәгенә урнашкан. Алар күп түгел һәм шәһәргә басынкылык итмиләр. Ә шәһәрнең калган өлеше 2—3 катлы йортлардан тора. Аларның күбесе газон-чирәмнәр, бакчалар, уен мәйданчыклары белән чолганган. Бу бер Медисонга гына хас күренеш түгел. Бу илдә булу көннәрендә ике этажлы Американы без Медисонда гына түгел, Нью-Йоркта да, Нью-Аркта да күрдек. Үзенең музейлары, көнбатыш яктан шәһәр читенә ук килеп терәлгән зур һәм матур күле (бу күлдә балык та күп, төрле киек кошлар да, шул хисаптан инде югалып бара торганнары да, яхшы гына үрчи диделәр), төз

урамнары, мәһабәт архитектуралы корылмалары белән Медисон, әлбәттә, һәр килгән кешедә җуелмастай күңелле хатирәләр калдыра.

Конгресс үзенең эшен башлаганчы безнең өчен тагы бер экскурсия оештырылды. Монысы Миссисипи елгасына. Без автобусларда бардык һәм тәрәзәләрдән Американың авыл җиренә хас пейзажын күзәтә алдык. Юлның ике ягында да җиренә җиткереп эшкәртелгән басу-кырлар. Анда-санда урман-куаклыклар. Басу-кырлар уртасында фермерларның торак йортлары. Алардан бераз читтәрәк терлек азыгы саклау өчен салынган башня-каланчалар, хуҗалык биналары һәм абзарлар. Бөтенесе бергә укмаштырып корылган. Алар тирәсендәге җирнең һәр адымы эшкәртелгән. Безгә XVII йөздән калган, Төньяк Американы беренче үзләштерүчеләр яшәгән йортларны күрсәттеләр. Юлыбыз яхшы ук билгеле булган Додтвилл, Монфорт, Фенимор, Мускадту Фрабор де Чейн шәһәрләре аша узды... Соңгысы Миссисипигә барып җитәрәк Висконсин штатында соңгы шәһәр. Хәзерге америкалыларның бабалары тарафыннан кыргый көнбатышны колонизацияләү — ак тәнлеләр тарафыннан җирле индеецларның җирләрен басып алу — шушыннан башланган. Миссисипи аша салынган күперне үтеп без Айова штатына чыгабыз. Биредә, торак пунктлардан еракта Миссисипи буенда индеецлар мәдәниятына кагылышлы музей урнашкан. Аның белән танышабыз. Музейдан ерак түгел, Миссисипи ярыннан күтәрелгән биек тауны каплаган урманда борынгы индеецлар каберлеге. Бу урыннар хәзер милли парк-музей дип игълан ителгәннәр.

Кире әйләнеп штатка исем биргән Висконсин елгасының төньягы буйлап сузылган юл буйлап кайттык. Монда инде башкачарак мөнәзара. Барып-кайту юлы барлыгы 500 км. тәшкил итте. Аруга карамастан, без Ловелл Холлга кайткач кара төнгәчә фикерләр алышып утырдык, башка илләрдән килгән делегатлар белән таныштык. Төн үтүгә безне бик киеренке хезмәт көне көтә иде.

28 апрельдә иртән бөтен делегатлар Висконсин тарих җәмгыятенең конференцияләр залына җыйналды. Конгрессны Кемал Х.Карпат ачты. Беренче булып котлау сүзе белән университет канцлеры Донна Шалала чыкты. Конгрессның пленар утырышы профессор Кемал Х.Карпат доклады белән

башланды. Ул Медисон университетының Үзәк Азияне өйрәнү буенча башкарган эшләре белән таныштырды. Икенче булып Техас университеты профессоры Андре Ф.Шерберг «Тарихи үсеш күзлегеннән караганда Үзәк Азия төрки халыкларының мәдәниятында охшашлык һәм телләренең структурасы» дигән темага доклад укыды. Өченче докладка аерым тукталасы килә. Бу доклад белән Германия Федератив Республикасыннан килгән галим Иоганн Штраус чыкты. Бу доклад «Татар телендә яңарыш һәм хәзерге төрки телләр» дигән темага иде. Әле конгресс үзенең эшен башлаганчы ук доктор Штраус безнең Татарстаннан икәнлегебезне белеп яныбызга килде һәм чыгышының тексты белән танышырга тәкъдим итте. Доклад безне авторның киң эрудицияле галим икәнлегенә, аның хәзерге һәм революциягә кадәрге татар тел галимнәренең хезмәтләре белән яхшы таныш булганлыгына инандырды. Конгресста укылган һәм татар теленең үсеше, аның төрки телләр системасындагы урынын тикшерүгә багышланган докладында галим мәсьәләне профессор М.З.Зәкиевкә якын позициядә торып яктыртты. И.Штраус үзе татар телен һәм төрки рун язмаларның тарихын яхшы белә.

Көндезге аштан соң конгресс секцияләргә бүленеп эшли башлады. Конгресс нинди мәсьәләләрне колачлаганын ачык күз алдына китерү өчен бу секцияләрнең исемнәрен күреп үтү дә җитә: «Дин һәм җәмгыять», «Антик чорда Үзәк Азия», «Үзәк Азия тарихының төп этаплары», «Көнчыгыш Төркстанның халыклары һәм сәнгате: хинганнар», «Сәясәт һәм элита», «Традицияләр һәм дин», «Ислам, җәмгыять һәм дин», «Милли хәрәкәт», «Икътисад һәм җәмгыять»...

Конгрессның 30 апрельгә билгеләнгән утырышлары тулысынча совет фәненә багышланган булып чыкты. Бу көнне «Үзәк Азиягә кагылышлы историография», «Әзербәйҗанда кавем (этнос) һәм традицияләр мәсьәләсе», «СССР — Россиядә социаль-мәдәни үзгәрешләр», «Тел һәм мәдәният» дигән секцияләр эшләде. Өченче секциядә профессор Я.Г.Абдуллин «Идел-Урал татарлары арасында мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм аның Урта Азиядә иҗтимагый фикер үсешенә тәэсире», ә дүртенче секциядә филология фәннәре докторы Ә.Г.Кәримуллин «Американың кайбер җирле кавемнәре (индеецлар) телләренең Алтай телләренә якынлыгы мәсьәләсенә карата» дигән темаларга докладлар

сөйләделәр. Докладларыбызны без рус телендә укыдык, ә инглиз теленә аларны гомерен татар халкының тарихын, мәдәниятын, матбугатын, күренекле шәхесләрнең тормышын һәм эшчәнлеген өйрәнүгә багышлаган, тикшерү нәтиҗәләрен калын-калын китапларда яктырткан күренекле француз галиме А.Беннегсенның кызлары Мари Броуксап һәм Фанни Брайан тәрҗемә иттеләр. Олҗас Сөләймановның конгресста ясаган чыгышы турында аерым әйтеп китәргә кирәк. Бу чыгышта беренче чиратта совет әдәбияты, шул хисаптан казакъ әдәбияты үсешенә, аның хәзерге хәленә, илдә бара торган үзгәрешләрнең тәэсире мәсьәләләре үзләренең чагылышларын таптылар. Үзенең чыгышында ул шулай ук хәзерге Монголия территориясендә урнашкан борынгы төрки рун язулы кабер ташларының аяныч хәле мәсьәләсен дә күтәрде. Халыкара фәнни конгресс, О.Сөләйманов тәкъдиме белән, бу кыйммәтле мәдәният ядкарьләренең сакланышын тәэмин итүгә кагышлы кичектергесез чаралар күрү кирәклеге мәсьәләсен күтәрде һәм бу турыда ЮНЕСКОга мөрәҗәгать кабул итте.

Шушы ук көнне (30 апрельдә) Үзәк Азиягә багышланган халыкара фәнни конгресс эшен тәмамлады. Үзенең йомгаклау чыгышында Кемал Х.Карпат, конгресс фәнни югарылыкта, төрле сәяси системаларга караган илләрдә иҗат итүче галимнәрнең үзара аңлашучанлыгы һәм дуслыгы шартларында үтте, дип белдерде. Бу инде биредә Үзәк Азия проблемаларына багышланган өченче конгресс иде. Кемал Х.Карпат конгресс кунакларына аның киләчәк утырышларында да катнашырга чакырып мөрәҗәгать итте. Бу күренекле галимнең Румыния татарларыннан булуын һәм күңелендә татар халкына зур ихтирам йөртүен күрсәтеп үтәргә кирәк.

Конгресста яңгыраган бөтен чыгышлар да диярлек катнашучыларда зур кызыксыну уятты. Шундый хәл хәтердә уелып калды. Огайя университеты (АКШ) профессоры Берт Бейнинның «Совет төрки республикаларында милли идеология коралы буларак библиография» дип исемләнгән докладында Татарстанда библиографиянең торышы читләтеп үтелде. Ә.Г.Кәримуллин үзенең чыгышында моны күрсәтеп үтте һәм конкрет фактлар китереп, Татарстанда библиографиянең торышы һәм уңышларын яктыртты. Үзенең җавабында Бейнин татар телендәге күрсәткечләрнең аңа ирешмәвен сылтау итеп акланырга тырышты. Ул шулай ук, докладымда мин бары саннары миллион һәм аннан

артык булган төрки халыкларда библиографиянең торышын яктыртырга кирәк таптым, дип әйтеп ташлады. Бу безне бөтенләй аптырашта калдырды. Шушы уңайдан Я.Абдуллин үзенең докладында саны 7 миллионга җиткән татар милләтенең этник чыгышы һәм тарихы мәсьәләсен дә күтәрде. Соңыннан профессор Бейнин безнең янга килеп докладында күзәтелгән төгәлсезлекләр өчен гафу үтенде.

Официаль очрашулар һәм фәнни дискуссияләрдән тыш та кичләрен конгресска килүчеләр урнашкан Ловелл Холлда фикер алышулар дәвам итте, аерым тарихи вакыйгаларга карата карашлар ачыкланды, шәхси бәйләнешләр урнаштырылды.

Конгресс иҗтимагый тәртипләрдәге аерымлыкларга карамастан төрле илләрдә яшәүче һәм иҗат итүче галимнәрнең берберсенә үзләренең сәяси карашларын такмыйча нәтиҗәле итеп эшли алуларын күрсәтте. Без моны да ике ил арасындагы мөнәсәбәтләрне каплап торган боз катламнарының соңгы вакытларда эри башлавы нәтиҗәсе дип карыйбыз.

Исеме инде телгә алынган профессор Майкл Рывкин совет делегациясе членнарына Карабахта бара торган вакыйгаларны тулырак аңлатуны сорап мөрәҗәгать итте. Моңа җавап рәвешендә мәсьәләне тарихи җәһәттән анализлап һәм статистик мәгълүматлар китереп С.Алеев, О.Эфендиев, А.Аббасов, Г.Гулиев чыктылар.

Шулай итеп 30 апрельдә халыкара фәнни конгресс үзенең эшен тәмамлады. Шул ук көнне О.Сөләйманов, Г.Керимов һәм А.Караева илгә очтылар. Алар өчен кире кайту билетлары турында СССР Язучылар берлеге әле Мәскәүдә ук кайгырткан булып чыкты. Ә безнең кайту билетлары 6 майга тәгаенләнгәнлеге ачыкланды. Шуннан алдан безгә берни дә тәкъдим итә алмадылар.

1 майда без Нью-Йоркка очтык. Кемал Х.Карпатның кайгыртуы һәм М.Рывкинның катнашы белән без анда тору өчен Манхэттенның үзәгендә урнашкан «Менсфельд» кунакханәсендә урын алдык. Кунакханә дан казанган Бродвейдан 150—200 метрларда гына булып чыкты. Сәрмая кысан булу аркасында без барыбыз бергә иң арзан номерга урнаштык. Әмма аның да бәясе кеше башына 20 доллар булып чыкты. Әмма аның Манхэттенның үзәгендә булуы безгә шәһәр белән танышу өчен бик кулай булып чыкты. Без көндезен дә, кичләрен дә

аның үзәк урамнарын кат-кат әйләндек, паркларында да, кибетләрендә дә булдык. Машинага утырып Манхэттен аша аркылыга да, буйлыга да уздык. Бруклинда да булдык, Тетайненда да, Квинсны да, Бронксны да күреп уздык.

Безнең беребезгә (Я.Г.Абдуллинга) шәһәрнең 107 катлы иң бөек бинасының түбәсенә менеп шәһәр панорамасын күзәтергә дә насыйп булды. Гаҗәеп күренеш! Алда, зур булмаган утрауда мәһабәт сын — Ирек статуясы басып тора. Янәшәдә генә Гудзон аркылы салынган ике яруслы асылма күпернең мәһабәт панорамасы. Аның астыннан океан лайнерлары узып тора. Сул якта Нью-Йоркның Бруклин дигән өлеше, ә артта үзенең күккә ашкан бинаQлары белән Манхэттен.

Нью-Йоркны шулай тамаша кылып йөрүдән бүленеп Ә.Г.Кәримуллин профессор Ричард Фрей чакыруы буенча данлыклы Гарвард университетына да (Бостон-Кембридж) барып кайтты. Ул анда университетның күренекле урыннары белән танышты, профессорлары һәм аспирантлары алдында татар халкының этник чыгышы һәм мәдәнияты турында лекция укыды.

Безнең матбугатта Америка турында күп язылды. Радиотелевидение аша да күп гәпләр корылды. Америкада булып кайткач, бер иптәшебезнең газета битләрендә безгә җиткергән коточкыч хәлләр әле дә күз албыдызда — үтереш, талау, төнлә урамга чыгарга ярамый... Болар да була булыр... Шулай да... Менә бер кичне кунакханәдән чыгып шәһәр урамнарын гизеп кайтырга булдык. Төрле җирләрдә булдык. Шул хисаптан Бродвейда да. Сәгать төнге бердә генә әйләнеп кайттык. Безгә төркем-төркем яшьләр дә, шул хисаптан негрлар да, азиялеләр дә очрады. Әмма безнең матбугатта тасвирланган коточкыч хәлләрнең берсенә дә тап булмадык. Үзебезне үзебез өркетеп яшәмәдекме икән?!

Полиция дә безнең күзгә әллә ни ташланмады. Ничә көн торып Медисонда безгә бары бер мәртәбә узып баручы полиция машинасы күрсәттеләр. Нью-Йоркта да бер кичне урам чатында җыйналган зур булмаган төркем янында атка атланган полицейскийне күрдек. Без үзебез аралашкан американлыларга бу турыда сорау да бирдек. Алар борчылмагыз, тәртипсезлек эшләсәң минуты белән килеп җитәрләр, хәтта машинада тизлекне арттырып баруыңны да күрерләр һәм озак көттермичә яшәгән урыныгызга күпме штраф түләргә икәнлеге турында хәбәр дә килеп ирешер, диделәр.

Америкага килеп төшү белән диярлек без анда яши торган милләттәшләребезнең игътибарын тоя башладык. Нью-Йорктан Медисонга очканда безгә Детройтта икенче самолетка күчеп утырырга туры килде. Аэровокзал — түгәрәкләнеп килгән ифрат озын бина. Самолетыбыз аның бер башына килеп кунды. Анда безне үзенең ире кырымлы Осман белән милләттәшебез Рафика ханым каршы алды һәм зур тизлек белән бинаның икенче башына алып килеп (15 минут чамасы бардык) самолетка утыртып җибәрде. Медисонга килеп урнашкач, озак та үтми яныбызга университет студенткасы Сюзан килеп житте (ул Осман әфәнде белән Рафика ханымның кызы булып чыкты). Медисонда булу көннәребездә бу туташ Я.Г.Абдуллин янына Пакистаннан килеп укучы бер аспирантны да алып килде. Бу әфәнде татар мәгърифәтчелеген, шул хисаптан җәдитчелекне өйрәнә булып чыкты. Үзен кызыксындырган мәсьәләләрдә консультация алырга тели икән. Аның белән бу проблемага кагылышлы мәсьәләләр буенча озак кына әңгәмә алып барылды. Аспирантның кулында Я.Г.Абдуллинның «Татарская просветительская мысль» дигән китабының ксерокста алынган күчермәсе күзгә ташланды. Кызыксына башладык һәм Америка китапханәләренә безнең хезмәтләрнең килепирешкәнлеген белдек.

Медисонда очрашкан милләтләшләребез бер Сюзан гына булып чыкмады. Килүебезнең беренче көннәрендә ук кунакханәдәге бүлмәбезгә Нью-Йорктан килгән профессор Рифат Таби килеп чыкты. Таныштык, хәл-әхвәлләрне, белештек, Нью-Йорктагы татар диаспорасы турында беренче белешмәләрне алдык. Килүебезнең икенче көнендә кунакханә холлының бер башында кәнәфидә утырабыз. Холлның икенче башыннан безгә таба җил-җил атлап берәү килә. Бусы милләттәшебез, Төркиядән килгән галим Надир Дәүләт булып чыкты. Тагы — Америка университетларының берсендә эшләүче татар тарихчысы Юлай Шамилоглу. Бу әфәнделәр белән икеләнмичә (ул вакытта илдәге кебек), як-якка карамыйча, фикерләребезне ачыктан-ачык җәеп салып халкыбызның үткәне, хәзерге хәле һәм киләчәге турында күп гәпләр кордык.

Конгресста төрекләр күп иде. Һәр көнне алар белән кунакханә холлына җыелып уртак мәнфәгатьләр турында сүз куерттык. Бу әңгәмәләр вакытында да, башка очрашуларда да

төрекләр белән без үзебезне бер гаиләдәй хис иттек. Һәм шулай ук уртак мәсьәләләр турында эчкерсез бәхәсләр алып бардык.

Нью-Йоркка килгәч, профессор Рифат Таби безне тулысынча үз карамагына алды. Һәм без аның кайгыртучанлыгын һәрдаим сизеп тордык. Нью-Йоркта нәрсәләр күрә алуыбыз һәм кайларда була алуыбыз турында югарыда инде язып үттек. Болар барысы да Рифат әфәнде тырышлыгы белән эшләнде. Бу эштә аның апасы Шәфика һәм яшьлек дусты кырым татары Сераж әфәнде вә аның җәмәгате Лейлә дә зур өлешләрен керттеләр.

Без Рифат әфәнденең Нью-Йорктан читтәрәк океан буендагы паркта урнашкан вилласында кунакта да булдык, Гаиләсе белән таныштык. Мәҗлескә хуҗаның дус-ишләре һәм туганнары җыйналган иде. Аларның һәркайсының тормыш юлы, монда килеп төпләнүе, эше, яшәп китүе — үзе бер повесть. Гәпләшеп утырганда Нью-Йоркта йөзләп татар гаиләсе яшәгәнлеге ачыкланды. Алар монда «Татар мәдәни җәмгыяте» булып берләшкәннәр. Еш кына татар клубында очрашалар, дини бәйрәмнәрне бергәләп үткәрәләр. Ара-тирә татарча спектакльләр куялар, Тукай көннәре уздыралар, ә язын балалар өчен сабантуй кебегрәк нәрсә оештыралар. «Казан утлары», «Азат хатын» журналларын алдыралар. Хәзерге татар җырларын, бигрәк тә Р.Яхин әсәрләрен яратып тыңлыйлар. Туристик путевкалар белән Советлар Союзында, кайберләре Казанда да булганнар. Әби-бабалары чыккан җирне сагынып һәм СССРда бара торган үзгәрешләр бәйләнешләрне киңәйтергә мөмкинлек ачар, дигән ышаныч белән яшиләр. Мәҗлестә озак, кара төнгәчә утырдык һәм Рифат әфәденең вилласында кунып та калдык. Иртәгесен ул безне Нью-Йоркка кунакханәбезгә кадәр озатып куйды һәм тиздән Сераж әфәнде килеп безне үз машинасында шәһәр гизәргә алып чыгып китте.

Нью-Йорктан китәр алдыннан безне тагы Рифатның абыйсы Әнвәр әфәнде үзенә кунакка алды. Бруклинда урнашкан зур гына йортта иркен генә фатир. Кунаклар арасында Рифат әфәндедә танышкан миләттәшләребез дә бар иде, яңалары да байтак булды. Бу мәҗлестә дә Рифат вилласында башланган әңгәмә дәвам итте. Мәҗлес бик кунелле үтте. Күңелдә уелып калырдай бер мизгел булып алды: Сания ханым пианинода

уйнап, моңа кадәр безгә ишетелмәгән бер җыр җырлады. Милли көй, җыры да татарның үзеннән өзелеп төшкән. Әйтүләренә караганда, бу җырны Манчжуриядә яшәгәндә бер милләттәшебез ватанны бик сагынганда бик өздереп җырлый торган булган. Мөгаен, туган яклардан алып килгәндер, ә үзебездә инде онытылган. Тагы бер очрашу турында әйтеп китү урынлы булыр. Бусы инде кат-кат телгә алынган, Нью-Йоркка килеп төшүебез белән ук безнең турыда кайгырта башлаган профессор Майкл Рывкин фатирында. Профессор үзенә совет делегациясенең әле Америкадан китеп өлгерә алмаган членнарын чакырды. Манхэттенда мәһабат кенә йорт. Профессор М.Рывкин анда зур гына фатир били. Киң холлда (залда) утырабыз. Каршыда — Гудзон елгасы. Елга аръягында һәм тәрәзәдән сул яктарак Гудзонның бу ягында да парк. Ә булмәдә экзотик гөлләр һәм куаклар. Тәрәзәнең теге ягындагы паркның дәвамы диярсең. Шул гөлләр-куаклар арасында куелган кәнәфиләргә утырып та, табын артында да гәп корабыз. Сүзебез Америка җиренә аяк басу белән башланган тема — Америка-Совет мөнәсәбәтләре, фәнни бәйләнешләр, фәнни тикшеренүләрдә дөреслекне яктырту мөмкинлекләре тирәсендә. Башыма бер уй килә: профессор М.Рывкин да, мәҗлестә катнашучы икенче бер америкалы профессор да, тагы бик күп америкалы галимнәр дә гомерләре буе Советлар Союзын, анда яшәүче халыкларның тарихын, мәдәниятын, телен өйрәнгәннәр, калын-калын китаплар язып бастырганнар. Без аларга советологлар, антисоветчылар дип кара мөһер суга килдек, язганнарын укып-нитеп тормастан, кире кага бардык. Конгресс көннәрендә шушы советологлар никадәр докладлар укыдылар. Барысы да безнең илне өйрәнү нигезендә, фактик материалларга таянып язылганнар, үзләреннән хаклык аңкып тора. Без, совет галимнәре эшлисе эшне алар эшли, без, укып та тормастан, аларны кире кагабыз...

Безнең Америкада булу көннәребез төгәлләнде. Без бу илнең кунакчыллыгын татып илгә кайту юлына борылабыз. Әлбәттә, монда да төрлесе бар. Барысы да ал да гөл дисәк, хаклыкка туры килмәс. Күпкырлы ил, аны һәрьяклап белү өчен вакыт һәм кешеләре белән күбрәк аралашу кирәк. Безнең монда булуыбызның үзебез өчен төп нәтиҗәсе: күңелебездә америкалыларның безнең кебек үк тынычлыкны яклауларына, сугышны сөймәгәннәренә, безнең ил һәм башка халыклар белән

дуслык мөнәсәбәтләре урнаштыруга омтылышларына тулы ышаныч тууы. Аларның безнең илдә бара торган процессларны зур кызыксыну белән күзәтеп торулары сизелеп тора. Безнең бу фикеребез Америка галимнәре һәм гади кешеләре белән бәйләнешләр вакытында алган тәэсирләребезгә нигезләнә. Зур нәтиҗәләр ясар өчен бу тәэсирләр, бәлки, аздыр. Шулай да, булган кадәресе инде әйтелгән ныклы фикергә китерде.

[1] Мәкалә филолгия фәннәре докторы (хәзер Татарстан Фәннәр академиясе академигы) Ә.Г.Кәримуллин белән бергә язылды.

1988 ел.

КЫЙТГАЛАРНЫ ТОТАШТЫРГАН ШӘҺӘРДӘ[1]

Истанбул. Үзенең тар урамнары, шау-шулы базарлары, остаханәләре, мәһабәт һәм зиннәтле сарайлары, мәчетләренең гөмбәзләре һәм күккә ашкан манаралары, Босфор дулкыннарында чайкалып торучы көймә һәм корабльләре белән ул борын-борыннан халкыбыз күңеленә бер маҗаралы шәһәр булып кергән. Хаж юлында да якташларыбыз бу шәһәргә сугылып үткәннәр, аратирә болгар җиренә халкыбызның бу шәһәр мәктәп-мәдрәсәләрендә белем алган уллары кайтканнар. Идел-Урал буйларыннан солтан җиренә сәүдәгәрләр дә барып йөри, бәхет эзләүчеләр дә барып чыга. Аларның бу сәяхәттән алып кайткан тәэсирләре дә Истанбулның сихри образын сурәтләүгә үзенең өлешен керткән.

Идел-Урал буйлары белән Босфор арасындагы бәйләнешләр әдәбият, мәдәният ягыннан да шактый киң булган. Бу якта иҗат ителгән «Мөхәммәдия», «Алты бармак», «Кыйсаи әнбия» әсәрләре халкыбыз арасында популяр әсәрләргә әйләнә. «Кәлилә вә Димнә», «Кыйссаи Әбүгалисина», «Кырык вәзир» кебек классик көнчыгыш әсәрләре дә безгә Төркия аша кергән. «Җиһаннамә», «Кәшфел-зөнун», «Сәяхатель Кедра», «Хаятель-хәйван» кебек әсәрләр дә зыялыларыбыз арасында кулдан-кулга йөри, хаттатларыбыз тарафыннан күчерелеп таратыла. Басма китап барлыкка килгәч, Истанбулда басылган китаплар бездә киң тарала, үз чиратында Казан татар китаплары да бу якта үзен тиз таныта. Узган гасырның урталарыннан башлап Төркиядә чыга башлаган газеталар безнең якларда яхшы таныш була, төрек китаплары аша безгә Европа мәгърифәтчелеге

фикере үтеп керә башлый. Шушы вакытларда Казанда Намык Кәмал, Әхмәд Мидхәд кебек алдынгы фикерле төрек әдипләренең әсәрләре басыла башлый. Халкыбыз күңеленә Истанбул образын тудыруда безнең әдип һәм галимнәрнең сәяхәтнамәләре дә өлеш керткән. Шиһап Мәрҗанинең «Рихләтель Мәрҗани» һәм Фатыйх Кәриминең «Истанбул мәктүпләре»ндә дә Истанбул образы укучы күз алдында шактый тулы сурәтләнгән.

Без, Г.Ибраһимов исемендәге институтның ике җитәкче фәнни хезмәткәре, Ататөрек исемендәге аэропортта ТУ-154 самолетыннан төшеп шушы шәһәрнең туфрагына бастык. Бирегә без Истанбул шәһәренең Мәрмәрә университеты каршындагы фәнни өйрәнүләр үзәге чакыруы буенча Төркиянең социаль һәм экономик тарихына багышланган V халыкара фәнни конгресс эшенә катнашу өчен килдек. Конгресс 5 көн — 21 августтан 25 августка кадәр дәвам итте. Аның эшендә, Төркиянең үзеннән тыш, Америкадан, Англиядән, Франциядән, Көнбатыш Германиядән, Румыниядән, Австриядән, Польшадан, Венгриядән, Мисырдан, Япониядән, Израильдән, Малайзиядән һәм башка илләрдән 150 ләп галим катнашты. Конгресска Советлар Союзыннан 10 делегат килгән иде: без икебез, 3 мәскәүле, һәм 5 азербайҗанлы. Конгресс Мәрмәрә университетының доктор Ибраһим Узунчы исемендәге культура үзәгендә барды. Ул университет хоры башкаруында Истикълял маршы белән ачылды һәм беренче пленар утырышны университетның ректоры профессор Орһан Огуз алып барды. Төркия җәмәгатьчелегенең, конгрессны оештыручыларның, университетның мөгътәбәр профессорларының тәбрикләү сүзеннән соң, доклад белән Кушма штатларның Чикаго университеты профессоры Хәлил Иналҗик чыкты. Чыгышы белән татар булган бу галим фән дөньясында танылган кеше һәм конгресста катнашучыларның аңа ихтирамы күзгә бәрелеп тора. Аның эчтәлекле доклады төрек телендә укылды.

Бу көннең икенче яртысында һәм алдагы көннәрдә конгресс үзенең эшен секцияләрдә дәвам итте. Конгресс эшенең икенче көнендә 1нче секциянең программасына безнең докладлар да кертелгән иде. Ә.Г.Кәримуллин үзенең чыгышын Ольга Сергеевна Лебедеваның (Гөлнар ханым) Төркиядәге эшчәнлеген анализлауга багышлады. Ә Я.Г.Абдуллин «Тәнзыймәт һәм татар мәгърифәтчелеге: типологик аспект» дигән теманы яктыртты. Докладлар татар телендә укылса да, игътибар белән тыңлады-

лар һәм докладтан соң сораулар бирелде. Ә.Г.Кәримуллинга докладтан соң ук бер төркияле ханым Гөлнар ханымның эшчәнлеген өйрәнергә теләге барлыгын белдерде һәм докладчыдан тиешле консультацияләр алды.

Безнең күп кенә фәнни конференцияләрдә катнашканыбыз бар. Үзебезгә дә фәнни конференцияләрне оештыручы вазыйфасын үтәргә туры килгәләде. Алар гадәттә 1—2 көн дәвам итәләр. Докладлар өчен 20 минут вакыт бирелә. Ораторлар регламент рамкаларына сыймый. Нәтиҗәдә, соңгы докладларның вакыты 10—15 минутка кадәр кыскартыла. Докладлар буенча чын мәгънәсендә фикер алышулар өчен дә вакыт калмый. Бу конгресста исә көндезге тәнәфескә кадәр дә, аннан соң да секцияләрдә икешәр утырыш билгеләнгән иде. Аның беренчесендә 45 минутлык утырышка юнәлеш бирүне максат итеп куйган төп доклад. Бу докладтан соң фикер алышулар уздырыла. Аннан тәнәфескә кадәр 20 минутлык бер һәм тәнәфестән соң 3—4 доклад. Ә ахырдан — фикер алышулар. Фикер алышулар тәнәфес вакытында да дәвам итә. Шушы тәртип конгрессның соңгы утырышына кадәр сакланды. Фәнни симпозиумнарны болай оештыру, безнең фикеребезчә, куелган мәсьәләләрне һәрьяклап тикшерү һәм төрле илләрдән һәм төбәкләрдән килгән галимнәрнең аралашуы өчен зур мөмкинлекләр ача.

Конгресс дүрт телдә алып барылды: төрек, инглиз, француз һәм немец телләрендә. Әмма докладларны бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү ихтыяҗы күренмәде. Чөнки анда катнашучы галимнәр һәркайсы берничә тел, шул хисаптан төрек телен дә беләләр һәм бик иркен сөйләшәләр, фикер алышалар. Хәзер без дә дөньякүләм аралашу, шул хисаптан фәнни аралашу юлына басабыз, бу илебез үсешенең, аның киләчәккә атлавының мөһим шарты. Ә бу аралашулар өчен чит телләр белү зарури шарт. Бу исә фән юлына басучы һәркемгә бер генә түгел, берничә, беренче чиратта инглиз телен белүне зарур итеп куя. Чөнки фәнни конференцияләр дә башлыча шушы телдә алып барыла, фән һәм теника казанышлары да күпчелек очракта шушы телдә яктыртыла.

Конгресс дәвамында алынган тагы бер сабак — фәнни проблемаларны өйрәнгәндә, шул хисаптан үзебезнең илебезгә кагылышлы проблемаларны өйрәнүдә дә чит ил галимнәре белән кулга-кул тотышып эшләү. Моңа кадәр без чит илләрдә

илебезнең тарихын, экономикасын, социаль проблемаларын өйрәнүче галимнәрне негатив төсмер биреп, советологлар дип атап килдек һәм аларның хезмәтләренең барысын да, укып тормас борын, кире кага бардык. Ә алар арасында объектив позициядә торып, бездә бара торган процессларның асылын ачып салу максатыннан чыгып язылганнары да бар иде бит. Бу характердагы хезмәтләр белән танышу, аларның авторлары белән элемтәдә торып эшләү безгә ил эчендә барлыкка килгән проблемаларны аңлауда һәм чишүдә ярдәм генә итәр иде. Сүз бара торган конгресс төрек галимнәренең үз тарихларын өйрәнүдә һәм анда торган проблемаларны тикшерүдә һәм чишүдә чит ил галимнәреннән нинди киң планда файдаланганлыкларын ачык күрсәтте. Мөгаен, бу галимнәр арасында Төркиягә теләктәшлек позициясендә торучылар белән бергә тискәре фикердә торганнары да булыр. Әмма алар барысы да каршылыклы тарихи процессны өйрәнүдә актив катнашалар. Шулар арасында Мәскәү галиме В.Данилов та бар иде. Ул Төркиянең хәзерге тарихы буенча күп кенә хезмәтләр авторы һәм конгресста да төрек телендә кызыклы гына доклад белән чыкты. Моннан безгә дә үрнәк алырга, чит илләрдәге фәнни учреждениеләр белән элемтә урнаштырырга, үзебезнең тарихыбызны һәм мәдәниятыбызны өйрәнүдә андагы галимнәр белән кулга-кул тотышып эшләргә, алар кулында сакланган чыганаклардан киң рәвештә файдаланырга кирәк.

Фәнни конгресс үзенең эшен 25 августта тәмамлады. Ә безгә илгә әйләнеп кайту өчен авиобилетны самолет рейслары булмау сәбәпле Мәскәүдә үк 30 августка оформить иткәннәр иде. Бу исә Истанбул белән яхшырак танышу өчен өстәмә мөмкинлекләр тудырды. Дөрес, бу танышу Ататөрек аэропортында самолеттан төшүгә башланды. Бу аэропорт Истанбулның көнбатыш кырыенда Мәрмәр диңгез буенда урнашкан. Анда безне конгрессны оештыру комитетыннан Һарун әфәнде каршылады һәм машинасына утыртып Истанбулның үзәгенә бара торган юл белән алып китте. Киң, төзек асфальт юл. Аның уң ягында Мәрмәр диңгез, сул ягында үзенең борынгы стеналары, торак йортлары, мәһабәт сарайлары, мәчетләре һәм аларның манаралары белән чал тарихлы Истанбул. Галата күперенә җиткәндә машинабыз тоткарлана. Монда да хәзерге заманның зур калаларына хас күренеш — чиксез машиналар агымы. Ә

шәһәрнең бу иске өлешендә юлларны ике-өч дәрәҗәдә кисештереп үткәрү мөмкин түгел. Шунлыктан тоткарлыклар хасил була. Ниһаять, Галата күперен кичеп иске Истанбулның артык киң булмаган урамнарына килеп керәбез. Машиналар таулыклы юлларны бер менеп, бер төшеп акрын гына алга баралар. Без дә шулар арасында.

Ниһаять, Босфорның биек ярына килеп чыгабыз. Алдыбызда бугазның бер ярыннан икенче ярына ташланган асылмалы күпер. Мәһабәт корылма. Бу күпер моннан 20—25 еллар чамасы элек салына һәм ун ел эчендә үзенә тотылган чыгымнарны каплый. Шул ук вакытта транспорт ихтыяжларын канәгатьләндерми дә башлый. Һәм тиздән Истанбулның Кара диңгезгә якынрак өлешендә икенче күпер салына. Беренче күпернең озынлыгы 1,7 км, икенчесе — аннан да озынрак. Ике күпер аша да транспорт агылып тора.

Без Истанбулның Азия өлешендә Мәрмәр диңгез буенда салынган Саудия кунакханәсенә килеп урнашабыз. Конгресс барган бина да Истанбулның шушы өлешендә. Шунлыктан Төркиядәге беренче көннәребездә шәһәрнең Азиядәге районнары белән таныша алдык. Бу районнар башлыча соңгы елларда төзелгән. Күбрәк, заманча итеп, бөтен уңайлыклары белән салынган йортлар. Әмма архитектура ягыннан бер-берсенә тәңгәл түгелләр, төзүчеләр аермалык бирергә тырышканнар. Киң чиста урамнар, яшеллек, транспорт көчле урыннарда юл киселешләре ике, хәтта өч дәрәҗәдә.

23 августта көндезге аштан соң конгресста катнашучылар өчен Босфор буйлап экскурсия оештырылды. Босфорның Мәрмәр диңгезгә чыккан җирендә Өскедар пристанендә теплоходка (төрекләр беренчесен искелис, икенчесен вапур диләр) утырдык. Юлыбыз Кара диңгез тарафына. Уң якта — Истанбулның Азия өлеше, сулда — Европа өлеше. Ике якта да елгалар һәм ерганаклар белән бүлгәләнгән тау битләре. Тау битләренә салынган торак йортлар, офислар, мәчетләр, аларның гөмбәзләре һәм озын манаралары. Йортлар күп очракта яшеллек белән күмелгән. Зур массивлы яшеллекләр дә күренә. Матур, күркәм күренеш. Янәшәдә генә франциялe профессор Меликофф утыра (ул Баку нефтепромышленнигы Меликовның кызы. Әнисе рус булган. Революциядән соң Франциягә китәләр. Кыз шунда үсә, зур галим-тюрколог булып формалаша, Төркия тарихы

белән шөгыльләнә). Аның сүзе: «Аһ, бу дөньяда бердәнбер кабатланмас шәһәр», — ди. Без, — «ә Париж, ә Ницца», — дибез. «Юк, Истанбул бөтенләй башка, аны Париж белән дә, Ницца белән дә чагыштырырга мөмкин түгел», дип җавап бирә. Кара диңгезгә җиткәч кайту юлына борылабыз. Ике ягыбызда да шул ук мөнәзара, инде кичке Истанбул.

Тагын бер экскурсия. Анысын безнең икебез өчен 24 августта Истанбул университеты доценты доктор Осман Серткая оештырды. Бу экскурсиядән максат — Истанбул университеты каршындагы Төркият институтында саклана торган Катанов фонды белән танышу.

Конгресс бара торган бинадан машинада Мәрмәр диңгезе буендагы Кадекәй искелисенә китерделәр, вапурга утырып Галата күпере янына чыктык. Анда безне Осман Серткая каршы алды. Осман Серткая киң эрудицияле тел белгече — тюрколог. Барлык төрки халыкларның тел белеме проблемалары турында хәбәрдар. Монголия далаларында гизгән, борынгы төрки рун язмаларын укыган. Урта Азиядә үткәрелгән тюркология конгрессында катнашкан, СССРдагы күп кенә тел галимнәре белән таныш. Матур, образлы итеп сөйли. Ярдәмчел, кешелекле кеше. Ул безне борынгы Истанбулның тар урамнары, базарлары аша Истанбул университеты тарафына алып китте.

Ниһаять, без Төркият институты урнашкан бинада. Алдыбызда Катанов фонды. Казан университеты профессоры Н.Ф.Катановның бай китапханәсе һәм кульязмалар фонды 1913 елны Россиягә килгәч Казанга да сугылган Гыйльми паша тарафыннан сатып алына һәм Истанбул китапханәсенә тапшырыла. Күренекле язучыбыз һәм мәгърифәтчебез М.Акъегет-Задә 1914 елны шушы китапханәгә эшкә чакырыла һәм әйтелгән фондны фәнни эшкәртү, картотекаларын төзү өстендә эшли. Хәзер бу фонд Төркият институты карамагында. Биек озын стенд. Китаплар тәртипле итеп тезелгән. Бу фондтагы китаплар һәм кульязмаларның тулы картотекасы да бар. Фондта борынгы кульязмалар да, XIX гасырда һәм XX гасыр башында Казанда һәм Россиянең башка шәһәрләрендә чыккан татарча һәм русча китаплар да бар. Мондагы хәзинәне тулысынча күзаллау өчен берничә ай утырырга кирәк. Без өстән-өстән генә таныша алдык.

Төркия галимнәре безгә татар халкының тарихына һәм мәдәниятына кагылышлы хезмәтләрнең Сөләймания, Милләт һәм Ататөрек китапханәләрендә, Айя-Софиядә саклана торган

архив фондларында да барлыгын әйттеләр. Ә Ислам тарихы, мәдәнияты һәм сәнгате мәркәзе китапханәсендә Казанда басылган китапларны һәм аларның ксерокопияләрен үз күзләребез белән күрдек. Боларга өстәп Әнкарада Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Әхмәд-Зәки Вәлиди, Рәшид Рәхмәти-Арат архивлары саклануын да әйтергә кирәк. Бу тарихыбызны һәм мәдәниятыбызны өйрәнгәндә әйтелгән хәзинәләргә игътибарыбызны җәлеп итү зарурлыгы турында сөйли.

Төркият институтыннан Осман Серткая безне Истанбул университетының фән-әдәбият факультетына алып китте. Зур, мәһабәт бина. Лифтта 4нче катка менәбез. 5—6 метр биеклектәге киң коридорлар. Ниһаять, без «профессор Рәшит Рәхмәти-Арат бүлмәсе» дип язылган ишек янына килеп туктыйбыз. Эчкә узабыз. Стенада әдәбият кафедрасында эшләгән профессорларның рәсемнәре. Уртада — Рәшит Рәхмәти-Арат портреты. Бу шәхес Казан артыннан чыккан. Төркиядә, Германиядә укыган. Зур галим — тюрколог булып формалашкан. Күп көчен борынгы төрки әдәбият ядкаре булган Йосыф Баласагунның «Кутадгу белек» дигән хезмәтен тикшерүгә багышлаган. Һәм тикшеренүләренең нәтиҗәсен калын-калын өч томнан торган хезмәттә яктырткан. Без университетның берничә профессоры белән очраштык, аларның һәркайсы Рәшит Рәхмәти-Аратның исемен зур ихтирам белән искә алдылар. Хәзер аның бүлмәсендә, ул башлаган эшләрне Осман Серткая дәвам иттерә.

Конгресс беткәч, 26 августа без Истанбулның Европа өлешенә чыгып урнаштык. Биредә урамнар инде таррак. Ә алардагы йортларның һәркайсы архитектура ядкарьләре буларак игътибарга лаек. Менә Истикълял җаддысы. Бу сүзне безнең кулланышта булган проспект дип тәрҗемә итәргә мөмкин булыр иде. Истанбулның Азия өлешендә җаддылар чыннан да бездәге проспектлар кебек киң. Ә Истикълял алай киң түгел, шулай да кара-каршы икешәр машина үтәрлек. Әмма йортлары һәркайсы үзенә күрә бер архитектура ядкаре, аларның күбесендә чит илләрнең консуллыклары урнашкан. Безнең урам дигән сүзгә төрекчә саккы дигән сүз туры килә. Аларда инде кара-каршы килгән ике машина көчкә-көчкә генә узарлык. Шунын өстенә бу урамнар тау битләреннән борыла-сарыла баралар, менәләр, төшәләр. Бу урамнарда йөрү шофердан зур осталык таләп итә. Шәһәрнең шушы өлешендә моннан 100 ел

элек дөньяда беренче булып салынган метро. Буе 1000 метр. Аңа да утырдык. Истанбулда трамвай да, троллейбус та юк. Халык, үз машинасы булмаса, автобусларда йөри.

Шәһәр, аның истәлекле урыннары белән танышабыз. Менә Яңа җами (без җамигъ мәчет дияр идек), Солтан Фатих җамые, Сөләймания җамые, Солтан Баязит җамые. Болар болай гына күз йөрткәндә бер-берсенә охшаш кебек. Һәркайсының гөмбәзләре калкып тора, күккә ашкан манаралары. Әмма якынрак карасаң һәркайсы үзенә бер архитектура ядкаре. Ә эчке бизәлешләре инде тулысынча аерылалар, һәркайсының үзенә бер төрле.

Алдыбызда Айя-София. Бу мәһабәт бинаны гадәттә Византия чорыннан калган диләр. Әмма бу Айя-Софиянең бер өлеше генә. Аңа кушылып озын-озын манаралар, өсләре ябык, ян-яклары ачык зур-зур колонналы заллар салынган. Мәһабәт биналар. Болары инде солтанлык чоры һәйкәлләре. Айя-Софиянең үзәк өлешендә ремонт бара, шуңа күрә анда керә алмадык, ә кушылып салынган мәһабәт корылмалары астында йөрдек.

Ниһаять, Төп-капе. Бу зур комплекс — сарай-парк. Парк бик гүзәл итеп планлаштырылган. Сарай зур, мәһабәт бина. Залдан залга кереп бирелдә урнаштырылган хәзинәләр белән танышып йөрибез. Алар арасында сәнгать әсәрләре, сугыш кораллары, сәнгати савыт-саба, алтын-көмеш җиһазлары, асылташлар, солтаннар һәм аларның якыннары өстендә йөргән кием-салым. Төрле илләрдән килгән, төрле кием кигән туристлар бихисап.

Төп-капе XVI—XVIII йөзләрдә төрек солтаннарының сарае була. Босфордан ерак түгел Мәрмәр диңгез буена урнашкан. Хәзер ул музейга әйләнгән. Төркиянең иң бай һәм гүзәл музее. 1958—1978 елларда бу музейның баш хранителе булып якташыбыз профессор Хәлид Зөбәер Кошай (1897—1979) эшли.

Без Истанбул университетында булдык. Бу Европада иң карт университетларның берсе. Аның нигезе 1453 елда салынган. Хәзерге Истанбул университеты төрле гасырларда төзелгән мәһабәт биналар комплексы. Аларның һәркайсы бер архитектура һәйкәле. Истанбул университеты шәһәрнең генә түгел, бөтен Төркиянең югары уку йортларының иң могътәбәрләреннән һәм иң зурларыннан. Анда 80 мең тәлабә (студент) белем ала, күпсанлы тикшеренү учреждениеләре эшли. Истанбулда моннан тыш тагы 5 университет бар, шулар арасында Истанбул технологик университеты, Мәрмәрә, Богаз-Эчи, Йолдыз университетлары.

Истанбулны хәзерге Төркиянең көзгесе дип атарга мөмкин. 8 миллион кеше яшәгән бу шәһәрдә илнең казанышлары да, каршылыклары да үзләренең чагылышын таба. Без Истанбулда чакта «Известия» газетасында «Төркиядә бөтенесе дә бар» («Известия», 1989, 26 август) исеме астында күләмле генә мәкалә басыла. Мәкаләгә икенче исем дә өстәлгән — «Без бөтенләй белмәгән экономик сикереш». Чыннан да Төркия һәм анда барган үзгәрешләр турында безнең матбугатта берни дә яктыртылмады дияргә була. Булган кадәресе дә Төркия тормышын негатив пландарак яктыртып килде. Бактын исә Төркия зур үзгәрешләр кичерә, зур адымнар белән экономик үсеш юлыннан атлый. 80нче елларда уртача еллык үсеш 8—10 процент тәшкил итә, аннан да югарырак булгалый. Производствоның барлык тармаклары да диярлек бик интенсив рәвештә фәнни-техник прогрессның яңа казанышларын үзләштерә, промышленностьның яңа тармаклары үсеп чыга. Соңгы елларда гына барлыкка килгән автомобиль промышленносте инде экспортка да эшли. Ә күптән түгел генә Төркиянең экспортын бары чимал (хром) һәм текстиль тәшкил итә иде. Электроприборлар җитештерү, электроника үсә, компьютеризация процессы бара. Дөньяда үзен-үзе туйдыра торган 13 дәүләтнең берсе — Төркия. Шуның өстенә, азык-төлекне (шул исәптән бодайны) Төркия чит илләргә чыгара.

«Известия»дә язылганча, Төркиядә бөтенесе дә бар. Истанбулның Азия өлешендәге озын киң урам буйлап без берничә мәртәбә автобуска утырып та, җәяүләп тә уздык (кунакханәдән конгресс узган бинага барыр юлыбыз шушы урам аша уза иде). Урамның ике ягы буйлап кибетләр тезелгән — автомобиль һәм транспорт җиһазлары кибетләре. Күпчелегендә — җиңел машиналар. Йөк машиналары да очрый. Шәһәрнең башка районнарында да автомобиль сата торган кибетләр күзгә чагылды. Гомумән, Истанбул кибетләренең күп булуы белән күзгә бәрелеп тора. Азык-төлек кибетләре дә, кием-салым да, тормыш кирәк-яраклары да, радиоэлектроника товарлары да — барысының да киштәләре тулы. Безгә зур кибетләр очрамады. Берничә кеше эшли торган кибетләр. Бусагадан атлап керүгә аларда эшләүчеләр каршыңа килеп баса, товарның әле берсен, әле икенчесен алып күрсәтә, акчаң булса, сатып ал.

Истанбулда Капалы чарши исемле зур ябык базар бар. Аның секцияләрендә дә вак-вак кибетләр. Галата күперен чыгуга Әминенү дигән район башлана. Капалы Чаршига менеп җиткәнче бу районның тар урамнарында да базар. Җаның ни тели — шуны табып була.

Тагын бер игътибарны җәлеп итәрлек нәрсә — халыкка хезмәт күрсәтүнең куелышы. Шәһәрнең һәр почмагында ихтыяҗыңны үтәрдәй мастерскойлар яки мастерлар табасың. Туклану предприятиеләренең эше игътибарга лаек. Шәһәрдә рестораннар күп. Кайбер урыннарда адым саен диярлек. Бигрәк тә кичке сәгатьләрдә алар буш тормый. Төрекләр аларга дусишләре белән дә, гаиләләре белән дә йөриләр. Тәкъдим ителә торган ризык күп төрле. Өстәл артына утыруың белән официантлар килеп җитә һәм сораган ризыкларны китерә башлый. Ресторанга бездә эчү урыны диебрәк карыйлар. Әмма бирердә ресторанда исереп утырган яки исереп чыгып киткән кешене безгә күрергә туры килмәде. Өстәлләрдә ак яки кызыл виноград шәрабләре күрдек. Әмма берничә кешегә бер шешә. Шул ук вакытта өстәл уртасына самовар куеп чәй эчеп утыручыларны да күрдек. Әйрән, пепси-кола, чишмә суы атлаган саен сатып торалар.

Әйтелгәннәрдән укучы авторлар Төркияне бигрәк идиллик картиналарда характерлыйлар дип уйламасын. Берничә мәртәбә безне әңгәмәдәшләребез сез Төркиянең, Истанбулның да муллыкта яши торган өлешендәсез, бөтен җирдә хәл болай түгел, кубәүләрнең хезмәт хаклары бик түбән, тормышларын авырлык белән алып баралар, дип әйттеләр. Бу, әлбәттә, шулайдыр. Инде әйтеп үткәнчә, Төркия бик тиз үсү чоры кичерә. Ә мондый темплар үзләре ук социаль тигезсезлек тудыра. Шул ук вакытта әңгәмәдәшләребезнең берсе басым ясап, Төркиядә һәркем тук, кем генә булса да ашарына-эчәренә, өс-башына җитәрлек средство таба ала, диде. Һәм, әгәр үз йорты булмаса хәле мөшкелрәк, квартир хакы кыйммәт, хезмәт хакының яртысына җитә, дип өстәп куйды. Дөрес, шул ук Истанбулда зур төзелеш бара, без яңа төзелә торган, күпкатлы йортларны да, инде төзелгән һәм «сатлык» дип язылган игълан эленеп торган йортларны да күп күрдек. Әмма ул йортлардагы квартираларны сатып алырга теләсә кемнең хәленнән килми.

Төрекләрне борчыган нәрсә — инфляция һәм тышкы бурыч. Мәскәүдән килгән профессор Данилов, моннан 20—25 ел элек монда мин бик мул көндезге ашка 1 лира түли идем, дип сөйләде. Ә хәзер тулы күләмле көндезге ашны ашап чыгу өчен ресторанда 8—10 мең лира калдырырга кирәк. Илнең тышкы бурычы исә хәзер 39 млрд. доллар тәшкил итә. Шулай да, халыкара аренада төрек лирасының позициясе ныгый булыр. Әле күптән түгел генә лираның конвертировать ителә торган валютага әйләндерелүе шул турыда сөйли булса кирәк.

Төркия өчен тагын бер авыр мәсьәлә — эшсезлек. Хәзер эшсезләр саны 3 миллионнан артып киткән. Бу кыенлыкның бер сәбәбе — крестьян яшьләренең авылны ташлап шәһәргә килүе. Күрәсең, бу процесс бездә генә түгел, башка илләрдә дә, шул хисаптан, капиталистик дөньяда да бара. Авылдан килгән яшьләрнең квалификацияләре юк һәм алар эшсезләр армиясен тулыландыралар. Бу исә илнең экономикасына зур йөк өсти, социаль каршылыклар тудыра.

Әйтелгәнгә охшаш кыенлыкларга карамастан, Төркия алга карап атлый, фән-техника казанышларының яңа үрләрен яуларга тырыша. Әңгәмәдәшләребезнең берсе илнең көньяк-көнчыгыш өлешендә тормышка ашырыла торган грандиоз бер проект турында сөйләде. Бу проект нигезендә гидроэлектростанцияләр, сугару системалары, сусаклагычлар төзелә, яңа җирләр үзләштерелә. Бу проектны тормышка ашыру азык-төлек җитештерүне 3 мәртәбә арттырырга мөмкинлек бирәчәк. Инде хәзер дә үз-үзен туйдыра ала торган ил өчен бу, әлбәттә, дөньякүләм әһәмиятле сикереш булачак. Дөрес, проектны тормышка ашыру акрын һәм авырлык белән бара, финанс җитми, моңа комачаулык итәргә тырышучылар да бар. Димәк, Төркия өчен алга баруның ышанычлы юлы — үз көчеңә ышану, үз ресурсларынны максатка ярашлы итеп файдалана белү һәм иң мөһиме — халыкның үзенең бердәм эшчәнлеге.

Истанбулга килгәнче, без Төркиядә милләттәшләребез яшәгәнлеген белә идек. Алар ничек яши, эш-көнкүрешләре ничек — бу да безне кызыксындырды. Узган ел Америкада булганда без Нью-Йоркта күпсанлы булмаган татарларның укмашып яшәгәннәрен күреп, бергәләп милли бәйрәмнәр, Тукай кичәләре үткәрүләрен, балаларына милли тәрбия бирергә торышуларын белеп кайткан идек. Әмма Истанбулдагы татарлар үзләренчәрәк

яшиләр. Дөрес, алар үзара аралашалар, әмма бербөтен булып, укмашып яшәүләрен сизмәдек. Элегрәк аларның милли җәмгыятьләре булган, әмма 1979 елгы хәрби путчтан соң политик партияләр таратылгач бу җәмгыять тә таркалган. Хәзер Төркиядә политик партияләр яңадан эшли, әмма татар милли җәмгыяте торгызылмаган. Шулай булса да, андагы татарлар безнең илдә бара торган үзгәрешләр, татар халкының хәле, мәдәниятыбызның торышы белән кызыксынып яшиләр.

Без очрашкан шәхесләр барысы да актив эш алып баралар. Менә Мәрмәрә университетының фән-әдәбият факультеты доценты фәннәр докторы Надир Дәүләт. Ул Маньчжуриядә туган. Ятимлектә үскән, үз тырышлыгы белән фәнгә юл салган. Берничә китап авторы, Фәнни хезмәтләре арасында татар халкына, аның үткәненә кагылганнары да бар. Төрек теленнән тыш татар, рус, инглиз, немец, француз телләрен яхшы белә. Ул без катнашкан фәнни конгрессны оештыру комитетының фәнни секретаре иде. Күрүебезчә, конференцияне оештыру һәм алып бару аның җилкәсенә төште һәм ул бу вазыйфаны менә дигән итеп башкарып чыга алды. Конгресс-ның соңгы пленар утырышы да аның рәислегендә узды.

Безнең Истанбулда икәнлегебезне ишетеп Әнкарадан Мәхмүт Таһир әфәнде килеп төште. Ул да Маньчжуриядә туган, инде олы яшьтә, әмма бик актив, эшлекле кеше. Специальносте һәм хезмәте буенча инженер-гидроэлектрик. Шул ук вакытта тарих һәм әдәбият проблемалары өстендә эшли. Татар халкының тарихын һәм мәдәниятын яхшы белә, шуларга кагылышлы хезмәтләр яза, аларны төрле илләрдә бастырып тарата. Ул безнең янда ике көн булды һәм үзен энциклопедик мәгълүматлы, киң эрудицияле, татар халкы турында янып-көеп яшәүче кеше буларак танытты.

Бер компаниядә утырганда яныбызга безне эзләп ике кеше килеп керде. Аларның берсе психолог Рәхми Оруч Гюнеч булып чыкты. Ул Истанбул университетының хастаханәсендә психолог булып эшли, авыруларны музыка белән дәвалый. Төрекчә сөйләшә. Әмма чыгышы белән татарлардан. Аның бабалары узган гасырның 90нчы елларында перепись вакытында бу чукындыру өчен эшләнә, дип куркып Төркиягә күчеп киткәннәр. Бөгелмә өязенең Әби авылыннан чыкканнар дип сөйләде. Алар барысы 3000 кеше җыйналып Иске Шәһәр

7 1-471

янында авыл булып утырганнар. Бәлки шул авылда яшәп килгән традицияләр, яңгыраган көй-моңнар Рәхмине татар культурасы, бигрәк тә музыкасы белән кызыксынуга этәргәндер дә.

1976 елда Истанбул университетында төрки халыклар музыкасын өйрәнү һәм пропагандалау группасы — Тумата җәмгыяте төзелә һәм аның җитәкчесе итеп Рәхми Оруч билгеләнә. Җәмгыять үзенең эшен төрки халыкларның уен-музыка коралларын, җыр-моңнарын, аларның текстларын барлаудан башлый, бу өлкәгә караган китапханә туплый. Моның белән чикләнмичә, Рәхми Оруч төрки халыкларның җыр-музыкасы һәм биюләре белән тамашачыны таныштыру турында да уйлана башлый. Шул максаттан чыгып, Тумата җәмгыяте каршында һәвәскәр җырчы, биюче, музыкантлар туплый һәм үзешчән труппа оештыра. Труппаның репертуарында татар халык җырлары һәм татар композиторларының әсәрләре зур урын ала. Труппа Төркиянең зур шәһәрләрендә һәм ерак районнарында концертлар куя. Труппаның даны тиз тарала, аны чит илләргә чакыра башлыйлар. Труппа Испания, Франция, Австрия, Кипр, Америка Кушма Штатларында гастрольләр үткәрә һәм һәркайда җылы каршылана. Хәзер Рәхми Оруч труппаның репертуарына татар мөнәҗәтләрен кертү буенча эш алып бара. Составының күпчелеген татарлар тәшкил итә. Алар арасыннан Гөлтан Ураллы, Хәнәфи Кыргыз, Яшәр Гюнечны әйтеп үтәргә кирәк. Солист Гөлтан Ураллының төп репертуары — татар халык җырлары. Шул ук вакытта ул — оста биюче дә. Профессиясе буенча ул — инженер. Рәхми Оруч үзенең труппасы белән хәзер Казанга килү хыялы белән яши һәм шуңа хәзерләнә.

Башка очрашулар да булды. Менә доктор Сәет Акчура. Истанбул университеты хастаханәсендә эшли. Нейрохирург. Фабрикант Фәрит Бичури — 40—45 яшьләрдә. Предприятие хуҗасы. Экономик проблемаларны, илнең хәләтен, хезмәт һәм капитал мөнәсәбәтләрен яхшы аңлап сүз алып бара. Зур гына автоҗиһазлар һәм детальләр кибете хуҗасы — Мәхмүт Ураллы. Боларның һәркайсы, безнеңчәрәк итеп әйтсәк, актив тормыш позициясендә торалар, үзләренең туган халкына җылы хисләр саклыйлар, аның киләчәге турында уйлыйлар, мәдәнияты белән кызыксыналар.

Истанбулга барырга чыкканда без үзебезнең алдыбызга халкыбызның күренекле улы, галим-мәгърифәтче Габденнасыйр Курсави каберенә зиярат кылу бурычы да куйган идек. Мәгълүм

булганча, ул 1812 елда хаҗ сәфәренә барышлый Истанбулда чума белән авырып китә һәм дөнья куя. Безгә мәгълүм булган хәбәрләргә караганда, ул Босфорның Истанбулга каршы ярында урнашкан Өскөдарда Солтан Хәмит мәчете янындагы каберлеккә җирләнгән булырга тиеш иде. Истанбулга аяк басу белән без бу каберлек турында белешә-сораша башладык. Әмма Өскөдарда андый мәчет булмавы, Истанбулда Солтан Хәмитнең бары төрбәсе генә булуы ачыкланды. Биредә яшәгән татарлардан да, үткәннән хәбәрдар булган төрекләрдән дә Курсавиның күмелүе мөмкин булган башка каберлекләр турында да сораштырып карадык. Әмма белүче булмады.

Янибызга Әнкарадан Мәхмүт Таһир әфәнде килгәч кенә мәсьәлә бераз ачыклана төште. Бу игелекле бәндә Г.Курсави белән инде күптәннән шөгыльләнә икән. Үзенең фикердәшләре белән бергәләп дүрт ел дәвамында ул мәгърифәтче-галимнең каберен дә эзләгән, аның күмелүе мөмкин булган бөтен каберлекләрне йөреп чыккан. Аның өчен бу максатта игътибарга иң лаеклы каберлек Өскөдардагы Солтан җәмигъ мәчете янындагы Карача Әхмәт каберлеге була. Бу зур һәм иске каберлек. Башка төрки халыклардагы кебек үк төрекләрдә дә каберлекләргә ихтирам зур. Әмма дөньядагы һәрнәрсә кебек каберлекләр дә картаялар, еллар аларның өслеген дә, алар турындагы хәтерне дә тигезли бара. Үзебезнең Казаныбызда да күп кенә каберлекләр өстендә хәзер шәһәр мәхәлләләре (кварталлары) утыра. Карача Әхмәт каберлеге дә шундыйрак язмышка дучар була.

Истанбул үзенең борынгы чикләреннән үтеп Босфор бугазының һәм Мәрмәр диңгезенең көньягына чыккан, Өскөдарны да, аны узып башка киң мәйданнарны да колачлаган һәм бу киң мәйданда төзелешләр җәелгән. Мәһабәт корылмалар барлыкка килгән, юллар сузылган. Инде телгә алынган каберлек өстеннән дә шәһәрнең яңа районнарын тоташтыручы юл салына. Нәтиҗәдә каберлек өч кисәккә бүленеп кала. Мәхмүт Таһир һәм аның дуслары борынгы зиратның бу кисәкчәләрен бик җентекләп йөреп чыгалар, әмма Г.Курсавиның каберен таба алмыйлар. Ш.Мәрҗани исә узган гасырның 70 елларында үзенең хаҗ сәфәре вакытында бу кабер янында була, аның өстенә таш куелганлыгы һәм язуының яхшы сакланганлыгы турында да язып калдыра. Моннан соң инде 100 елдан артык гомер узган.

Мәрҗани күргән каберне еллар җир белән тигезләгәнме, әллә башка бик күп каберләр өстеннән узган кебек, Г.Курсави кабере өстеннән дә соңгы елларда салынган юлларның берәрсе узганмы?! Тәәссефкә каршы, белә алмадык; бары юлдан узышлый ул каберлекләргә моңсу карашларыбызны ташлап китә алдык.

Истанбул дөньяда ике кыйтгага урнашкан бердәнбер шәһәр. Босфор аны икегә аера. Әмма Истанбулның Аурупа өлеше дә, Азия өлеше дә бер шәһәр булып яши, бердәм сулый. Босфор шәһәрне икегә аерса да шәһәр үзе ике кыйтганы бергә тоташтыра, бәйли. Босфор аша салынган күперләр Истанбулның ике өлешен генә тоташтырмыйлар, алар Төркиянең Аурупа өлеше белән Азия өлешен бер-берсе белән ныклы җепләр белән бәйлиләр. Бу күперләр шулай ук ике кыйтганың — Аурупа белән Азиянең экономик бәйләнешендә мөһим роль уйныйлар. Алар аша төрле илләрдән чыккан һәм төрле малларын төягән күптоннажлы машиналар туктаусыз узып тора. Истанбулның диңгез портында Аурупа дәүләтләренең флаглары күтәрелгән корабльләр дә, Азия дәүләтләренең флаглары күтәрелгән корабльләр дә рейдта торалар.

Истанбулда булган көннәрдә без Аурупа-Азия арасындагы экономик мөнәсәбәтләр белән беррәттән рухи бәйләнешләрне дә, мәдәни багланышларны да күрдек. Истанбулның төзелешендә. аны бизәп торган биналарда шәрекъка һәм гаребка хас архитектура үрнәкләре кулга-кул тотышып торалар. Хәзерге Истанбул европалашкан шәһәр. Ататөрек җитәкчелегендә узган революция Төркиягә зур үзгәрешләр китерде, аның йөзен үзгәртте. Истанбул — бу үзгәрешләрнең ачык чагылышы. Ул хәзерге Төркиянең зур экономик, мәдәни һәм политик үзәге. Анда хәзерге заман промышленность предприятиеләре эшли. Истанбулның мәктәпләрендә һәм югары уку йортларында заман фәннәре укытыла. Аның кешеләре дә заманча, европадагыча итеп киенәләр. Шул ук вакытта гади генә итеп киенгән, көннәр эссе булса да өсләрендә җәйге пальто булган, башларына өчпочмаклап яулык салган хатыннар да очрады. Базарларда да, хәтта шәһәрнең истәлекле урыннарында йөргәндә дә, мәшһүр архитектура һәйкәлләре янында басып торганда да башларыннан аякларына кадәр өсләренә кара кием салган, авыз-борын өсләреннән ак тасма уздырган, бары күзләре генә ялтырап торган хатынкызлар да очрады. Боларны, гарәп хатыннары, диделәр.

Истанбул телевидениесе берничә каналда эшли. Аларда хәзерге Төркиянең популяр артистлары, җырчылары, биючеләре чыгыш ясый (радио да шулай). Төркиянең үзендә, Аурупа, Азия, Америкада эшләнгән фильмнар күрсәтелә. Ә намаз вакыты җиткәч, Истанбулның күпсанлы мәчетләре манараларына куелган репродукторлардан мөәзиннәрнең азаннары яңгырый.

Шулай итеп, Истанбулда хәзерге Аурупа тормышы белән Азия традицияләре очраша, бәхәскә керә, бер-берсен аңларга тырыша. Истанбул, бөтен Төркия кебек үк, ике тенденцияне берләштерергә тырыша, эзләнә, өйрәнә, киләчәккә эз сала. Без аңа хәерле юллар телибез.

[1] Мәкалә филология фәннәре докторы Ә.Г.Кәримуллин белән бергә язылды.

1989 ел.

ХИҖҖАЗГА СӘЯХӘТ

Хиҗҗаз Согуд Гарәбстанының көнбатыш өлешендә Кызыл диңгез буенда урнашкан өлкәсе. Бу борынгы тарихи төбәк. Бирегә безнең бабаларыбыз элек-электән хаҗ кылырга йөргәннәр, сәүдәгәрләребез дә барып чыккан. Гарәпләр бу тирәләрдә безнең эрага кадәр күп гасырлар элек яши башлаганнар. Аерым пәйгамбәрләрнең тормышларын чагылдырган риваятьләр шушы төбәк белән бәйләнгән. Мөхәммәт галәйһеәссәләмнең эшчәнлеге дә беренче булып шушында җәелә, шушында ислам дине формалаша, ислам мәдәнияты тарихы белән нык бәйләнгән Мәккә, Мәдинә, Җиддә һәм Таиф шәһәрләре дә шушында урнашканнар.

Без монда Бөтендөнья Мөселман лигасы тарафыннан Согуд Гарәбстанының мәдәнияты үзәкләре һәм анда бара торган үсеш тенденцияләре белән якыннан танышу өчен чакырылдык. Юлдашларым Үзбәкстаннан СССР халык депутаты, Үзбәкстан Язучылар берлеге рәисе Адиль Якупов, Үзбәкстан халык шагыйре, Үзбәкстан президенты советы әгъзасы Шөкерулла Йусупов, Үзбәкстан халык шагыйре, «Ватан» җәмгыяте рәисе Рәмз Бабахан, үзбәк-уйгур язучысы, тәрҗемәче Әмин Усман, язучы һәм тәрҗемәче Җамал Камал. Соңгы иптәшебез турында аерым әйтергә кирәк. Ул инглиз телен белә. Кайда гына булсак та, кем белән генә очрашсак та, безнең терәгебез булды. Үзе кешеләр белән элемтәгә бик тиз керә, җайлы, ярдәмчел, кешелекле зат.

Рабита (Бөтендөнья мөселманнар лигасы) безгә билетны Австрия һава юллары аша рәсмиләштергән булып чыкты. Шунлыктан без Шереметьево аэропортыннан Венага юл алдык. Мондый сәяхәтләр вакытында һәр күргән нәрсәгә игътибар итәсең, үзебездәге шуңа охшаш хәлләр белән чагыштырасың. Бу очракта да мин күзәтеп-чагыштырып барам. Самолетыбыз билгеләнгән вакыттан бер минут та кичекмичә очып китте. Киң, биек, салон, һәрнәрсә җайлы. Стюардессалар мөләемнәр, ихтирамлылар һәм игътибарлылар, мөрәҗәгатеңә шунда ук җавап бирергә хәзерләр. Ирексездән үзебездә очрый торган дорфалык күренешләре белән чагыштырырга мәҗбүрсең. Самолет урыныннан кузгалуга алар эшкә керештеләр. Башта пассажирларның путалары бәйләнгәнлеген карап чыктылар, аннары газета-журналлар тараттылар, озак та үтми азык өләшә башладылар. 2,5 сәгать очканнан соң, без Вена аэропортына килеп кундык. Бездә, гадәттә, самолет җиргә утыргач, озак кына көттереп трап бирәләр, аннары очучылар төшә, ә пассажирларга бу вакытта зарыгып көтәргә кала. Ә биредә самолет килеп кунуга трап та бирделәр, пассажирларны төшерә дә башладылар.

Вена аэровокзалына үтәбез, зур, киң заллар, анда идеаль тәртип, чисталык, пөхтәлек күзгә ташлана. Хезмәткәрләр вазыйфаларын тиз һәм төгәл башкаралар. Бернинди этеш-төртеш юк. Вокзал эче зур универмагны хәтерләтә. Анда барысын да табарга мөмкин, азык-төлеген дә, промышленность товарларын да. Без тиз генә тиешле формальностьлар һәм тикшерүләрне үтеп аэровокзалдан чыгабыз. Әйберләребезне алганда, Әмин Усманның бер төргәге юклыгы беленде. Таможня хезмәткәрләренә бу турыда әйткәч, иртәгә кадәр ачыкларбыз, диделәр. Чыннан да иртәгесен төргәкнең Дюсселдорфка киткәнлеге беленде. Һәм ул тиздән Венага кайтып та төште. Бу вакыйга, ирексездән, узган ел Бакуда Төркиядән фәнни конференциягә килгән бер галим белән туган маҗараларны искә төшерде. Бакуга ул «Аэрофлот» самолетында Әнкарадан очып килә. Очар алдыннан чемоданнарын тапшыра, әмма аларның берсе нигәдер Бакуда юкка чыга. Без дүрт көннән кайтып киттек, әмма чит илдән килгән кунагыбызның чемоданы әле табылмаган иде.

Безнең самолетыбыз Венадан Җиддәгә бер тәүлектән соң гына очачак. Шуңа күрә аэропорт янындагы «Новотел» кунакханәсенә урнашабыз. Монда да бернинди ыгы-зыгы, шау-шу юк.

Кунакханә зәвык белән җиһазландырылган. Иркен бүлмәләр, холлар, аларда чәчәкләр-гөлләр, утыру өчен кәнәфиләр, кресло-лар. Йокы бүлмәләрендә дә комфорт югары дәрәҗәдә. Кичен ресторанга ашарга төшәбез. Бу очракта да чагыштырмыйча булмый. Бездә ресторанга керсәң көттереп кенә меню китерәләр. Шулай ук көттереп кенә заказ алалар. Тагы да көттереп аш алды ашлары, беренчесен, икенчесен, чәен китерәләр. Ә монда кереп утыруыбызга официантлар килеп тә җиттеләр, ашамлыкларны бер-бер артлы китерә дә башладылар. Официантларның пөхтә итеп эшләүләре, ягымлылыгы, игътибарлылыгы күзгә бәрелеп тора.

Тагы бер нәрсә күзгә ташлана: самолетта да, аэровокзалда да, кунакханәдә дә, ресторанда да кемгә генә мөрәҗәгать итсәк тә инглиз телен беләләр. Ирексездән, бездә тел мәсьәләсендә никадәр берьяклылык, катып калганлык яшәп килде, халык бары бер телгә генә, урыс теленә генә бәйләп куелды, дип уйлыйсың.

Икенче көнне без кичке сәгать 4 кә кадәр буш. Тирә-юньне карап керим, дип чыгып киттем. Кунакханә һәм аэровокзал тирәсе яшеллеккә күмелгән, декоратив агачлар үсеп утыра, газоннар-чирәмлекләр, кай тарафка юнәлсәң дә, аларны икегә ярып тар гына асфальтланган сукмаклар сузыла, бездәге кебек газоннарны таптап теләсә кайда сукмак салмаганнар. Аэровокзал бинасы буйлап креслолар тезеп куелган. Берсе дә ватылмаган да, сызгаланмаган да, куйган урыннарында тора бирәләр. Утыр, ял ит, һичкайда чуп-чар күрмәссең, идеаль тәртип. Бөтенесе кеше өчен, аңа җайлы булсын дип эшләнгән. Аэровокзал ишегенә якынлашасың, ул үзеннән-үзе ике якка ачылып, сиңа юл бирә. Кунакханәгә кергәндә-чыкканда да шундый ук хәл.

Без яңадан да самолетта. Бусында да инде әйтелгән тәэсирләр. Самолетыбыз кичке сәгать сигезенче яртыда Кипрның Лорнак аэропортында тукталыш ясый. Аңа диңгез ягыннан якынлашабыз. Алдыбызда диңгез яры буйлап киң генә җәелгән шәһәрнең утлары ялтырый (көньяк киңлекләрдә иртәрәк караңгы төшә.) Лорнак аэропортында 1,5 сәгать тордык. Әмма самолеттан чыгармадылар. Без яңадан юлда. Самолетыбыз кузгалып китүгә кичке аш китерделәр. Бу юлы да моңа кадәрге аш вакытларындагы кебек пөхтә генә итеп төрелгән май бирделәр. Кичә дә уйлаган идем, бүген дә. Моның тәме бит татар хатыннары гомер-гомергә язган май тәмен хәтерләтә.

Бездә тормыш никадәр стандартлаштырылды, дип куясың. Әмма яхшы якка түгел. Кайчандыр бөтен тирә-якта даны таралган татар маен без хәзер күрмибез. Аның урынына безгә талон белән сыйфаты бик шөбһәле булган крестьян яки бутерброд мае бирәләр. Без хәзер әниләребез пешергән татар икмәген дә күрмибез. Озак еллар татар икмәге урынына безгә «орловский», «московский», «городской» икмәкләрен ашаттылар, ә хәзер икмәк дип, бүген алгач иртәгә искереп ката торган, ниндидер суррогат саталар.

Очабыз. Алдымда бер яшь кенә кеше урынында утырган килеш намаз укый. Ә бераз арырак гарәп егете һәм кызы чөкердәшеп утыралар. Мин шулай Гарәбстан белән таныша башлыйм.

26 май, төнге сәгать унбер. Ниһаять, без Хиҗҗаз җирендә. Венада һава салкынча иде. Самолетта конденционерлар тиешле температура режимын сакладылар. Ә биредә, самолеттан чыгып асфальтка аяк басуга, кайнар мичтән бәргән кебек эсселек килеп бәрелде. Һава температурасы 35 градус, диделәр. Без бу җирдә төгәл бер атна тордык, машинада шәһәрдән шәһәргә йөрдек. Бу безгә Хиҗҗаз белән, Согуд Гарәбстанындагы тормыш белән, аның мәдәнияты, халкының гореф-гадәтләре, мөселманнарның изге урыннары белән азмы-күпме танышырга мөмкинлек бирде.

Хиҗҗаз вади дип атала торган коры елгалар бүлгәләгән таулыклар белән капланган төбәк. Тау битләре җил, кояш кыздыруы, кышын гына була торган әз-мәз яңгыр сулары белән шомартылган ташлар белән түшәлгән. Шундый ук ташлар белән түшәлгән иңкүлекләр дә очрый. Мондый иңкүлекләр ерактан яңа гына сөрелгән кара туфраклы җир кебек күренәләр. Мәккәдән Мәдинәгә бару юлында тауларның кызгылт-сарыларына да тап булдык. Бер шәһәрдән икенчесенә барганда без тау-таш арасыннан үткән юллардан да, чүлне ярып сузылган юллар буйлап та үттек. Хәтта бер урында ком буранының нәрсә икәнен татырга да туры килде. Сәгатьләр буена барасың, ара-тирә генә көйгән тау битләрендә чемченеп йөргән сарыккәҗә, ә чүлләрдә дөя көтүләре очрый. Сирәк кенә яшеллеккә күмелгән бакчаларга да тап буласың.

Бу төбәкнең тормыш күзгә бәрелеп кайнап торган урыннары — шәһәрләр. Иң беренче итеп якыннан без Мәккә белән таныштык. Бу шәһәр тау-таш арасына утырган. Тау битлә-

реннән борыла-сарыла, әйләнә-тулгана урамнар сузыла. Шәһәрнең архитектурасы шәркый типта. Йортлар, җәмәгать биналары зәвык белән салынганнар. Аларның һичбере икенчесенә охшамый, һәркайсы үзенә бер үзенчәлекле архитектура әсәре. Шәһәрнең үзәгендә башлыча 2—3 катлы йортлар. Алар тау битләренә берсе өстенә икенчесе салынгандай тоела. Тик таулар чигенгән урыннарда гына күп катлы йортлар очрый. Тау-таш арасыннан узган тар урамнарда яшеллек күп түгел. Шул ук вакытта шәһәрнең читләрендә, таулар бераз чигенгән урыннарда, йортлар, ишек аллары яшеллеккә күмелеп утыралар. Мәккәнең үрмәкүч пәрәвезен хәтерләткән юллары хәтергә сеңеп кала. Алар тау араларыннан уңга да, сулга да, тауга менеп тә, төшеп тә үтәләр, тау тишекләренә кереп тә китәләр, берсе өстеннән берсе дә сузылалар. Ара-тирә якында йортлар күренми дә, ә юллар сузыла. Димәк, каядыр тау арасында шәһәрнең ниндидер бистәсе урнашкан. Без булган көннәрдә һавалар эссе торды. Температурасы 45 градус, диделәр. Тау-таш кыза. Әмма һава коры. Шунлыктан эсселек бөтенләй үк түзеп булмастай тоелмый.

Мәккәдән аермалы буларак, Мәдинә киң иңкүлеккә урнашкан, таулар аның яныннан чигенебрәк торалар. Монда яшеллек тә Мәккә белән чагыштырганда күбрәк. Бөтенләй яшеллеккә күмелгән киң туры урамнар да аз түгел, киң-киң бакчалар да үстерелгән, парклар да салынган, мәйданнарда фонтаннар да атылып тора, берничә урында хәтта тау бите буйлап агып торган фонтаннарны да күрдек. Шәһәр төз, архитектурасы Мәккәнеке кебек үк шәркый. Әмма гарби стиль белән аралашкан. Монда күпкатлы йортлар инде күбрәк очрый. Мәккәдәге кебек үк монда да бер йорт икенчесенә охшатып салынмаган. Һәркайсы үзенчәлекле бер архитектура әсәре. Һичнинди стандартлаштыру юк. Күрәсең, архитектура фикере үсүгә Хиҗҗазда тулы ирек бирелгән.

Мәккәдә торганда без бер генә көнгә Таифка барып кайттык. Зур булмаган шәһәр. Согуд Гарәбстаны мәлигенең җәйге резиденциясе. Мәккәдән 70 километр гына ераклыкта булуына карамастан, монда һава температурасы андагына караганда 5-6 градуска түбәнрәк. Таулар шәһәрдән чигенебрәк торалар. Киң урамнары туры сузылган. Күп очракта алар яшеллеккә күмелгән, лимон, хөрмә агачлары үсеп утыра. Шәһәрнең архитектурасы

башлыча шулай ук шәркый. Шул ук вакытта монда да йортларны салуда гарби алымнар яхшы ук кулланылганнар, заманча итеп салынган коттеджлар да, биек йортлар да очрый.

Җиддә хәзерге Хиҗҗазның иң зур шәһәрләреннән. Инде әйтелгән калалардан аермалы буларак, бу шәһәр таулардан ераграк, Кызыл диңгез буендагы киң далага урнашкан. Җиддә — Хиҗҗазның һава капкасы, аның янында зур халыкара аэропорт салынган. Анда дөньяның төрле почмакларыннан очкычлар килеп куна. Без килгән мәлдә монда бер тәүлек, кайтышлый тагы бер тәүлек булдык һәм анда яшәүче үзбәкләр ярдәмендә шәһәр белән яхшы гына таныша алдык. Шәһәрнең борынгы өлешендә урамнар тар, йортлар да артык биек түгелләр. Соңгы елларда шәһәр нык үскән. Аның яңа районнарында урамнар киңнәр. Аларда күп катлы мәһабәт биналар да, яшеллеккә күмелеп утыра торган һәм зәвык белән салынган шәхси сарайлар да очрый. Бу шәһәрнең архитектурасында да шәркыйлек үзен нык кына сиздереп тора. Әмма монда ул Хиҗҗазның башка шәһәрләре белән чагыштырганда гарби стиль белән ныграк үрелеп үскән. Биредә без шәрә урамнарга да очрадык, шулай да шәһәр яхшы ук яшелләндерелгән. Бу бигрәк тә Кызыл диңгезгә якынрак районнарга кагыла. Бу районнарның берсендә без зур мәйданны биләгән һәм үзенчәлекле итеп бизәлгән паркта булдык һәм аның гүзәллегенә сокланып туя алмадык. Шәһәрдә үзенчә итеп салынган сәнгати һәйкәлләр дә, фонтаннар да еш очрый.

Кайсы шәһәрдә генә булмыйк, безгә кибетләрнең күплеге күзгә ташланды, алар тар урамнарның ике ягына тезелеп киткәннәр, ишекләре кибетләрнең бөтен киңлегенә ачып куелганнар, киштәләре малдан сыгылып тора, кер, ни теләсәң шуны сайлап ал, акчаң гына булсын. Вак кибетләр белән беррәттән бу шәһәрләрнең һәркайсында күпкатлы мәһабәт биналарны биләгән супермаркетлар да калкып тора. Болары бер бина эченә сыйдырылган зур базар һәм аларда дөньяның төрле почмакларында җитештерелгән товарларны табарга мөмкин, һәм азык-төлегеннән, һәм промышленность-һөнәрчелек товарларыннан.

Хиҗҗазда шәһәрләр генә түгел, андагы юл буйларында да күзгә ташланган тагын бер нәрсә — мәчетләрнең күплеге. Һәрбер автозаправка станциясе янында мәчет салынып куелган. Шәһәрләрдә зур-зур гыйбадәтханәләр белән рәттән адым саен

диярлек гади генә итеп салынган мәчетләр очрый. Алар һәркайсы зәвык белән бизәлгән, идәннәрендә келәмнәр, паласлар, радиолаштырылганнар, намаз вакыты җитү белән алардан корьән сүрәләре, догалар яңгырый башлый. Намаз вакыты җитте исә, кеше, юлын бүлдереп, якындагы мәчеткә кереп намазын укый һәм моңа бары берничә минут сарыф итеплә.

Без булган урыннар ислам тарихы белән тыгыз бәйләнгән, шушында ислам мәдәниятының нигез ташлары салынган, шушыннан бөтен дөньяга мөселман идеяләре таралган. Мәккәдә һәм Мәдинәдә безгә мөселманнар өчен изге саналган урыннарда булырга, ислам тарафдарларының күңелләре төбәлгән мәгърур гыйбадәтханәләргә керергә, аларның күркәм диварларын күрергә, ул диварларга кагылырга насыйп булды. Боларның иң әһәмиятлесе, иң күркәме Мәккәдәге Мәсҗеде харам. Бу берничә бинаны берләштерүче зур комплекс. Аның залларында берьюлы берничә йөз мең кеше намаз укый ала. Мәсҗеде харамның уртасында һәр мөселманның күңел түренә урнашкан Кәгъбәтулла. Намаз укыганда ислам тарафдарлары шуңа төбәләләр. Кәгъбәтулладан бер яктарак мөселман легендаларына кергән һәм изге саналган Сафа һәм Мәрвә тауларын бер түбә астына алган озын, киң колонналы биек зал. Кәгъбәтулладан икенче якта Мәсҗеде харамның астына төшеп бер аз баргач, зәмзәм чишмәсе. Мәсҗедә харам зәвык белән салынган мәһабәт архитектура корылмасы. Хәзер аңа кушып шундый ук зурлыкта һәм аның үрнәгендә яңа бина салына.

Мәккәгә килүебез белән без, тәһарәтләр алып, Мәсҗеде харамга юнәлдек һәм анда гомрә (кече хаҗ) йолаларын үтәдек. Кәгъбәтулла тирәли тиешле догаларны укып җиде кат әйләндек, изге ташны үбеп киттек. Кәгъбәтуллага каршы утырып намаз укыдык. Аннары күрше залга кереп җиде тапкыр Сафа һәм Мәрвә таулары арасында йөгереп уздык. Ахырда зәмзәм чишмәсе янына төшеп суын эчтек, бит-кулларыбызны юдык.

Мәккәдән без Гарәфәт тавына да бардык. Бу шулай ук мөселманнар өчен изге урын. Ул киң вадида калкып тора. Бу вадида агачлар үстерелгән һәм ул зур яшел паркны хәтерләтә. Шул паркта Гарәфәт тавына каршы күп меңләгән кеше сыйдырышлы берничә манаралы бинийһая зур мәчет бинасы. Бу тау ерактан күренеп торган башка таулар белән чагыштырганда кечерәк. Аның башына мендек. Моның өчен баскыч

корылган. Ә тау үзе зур-зур ташларны өеп кую нәтиҗәсендә туган калкулыкны хәтерләтә. Бу тау турында гарәпләр арасында төрле легендалар сакланган. Аларның беренчесенә караганда, Адәм галәйһеәссаләм белән Һава, җәннәттән сөрелгәч, икесе ике якка ташлана. Алар бик озак бер-берсен эзлиләр һәм шушы тау янында очрашалар. Тау, димәк, табышу, кавышу урыны. Икенче легендага караганда, Ибраһим галәйһеәссаләм улы Исмәгыйль белән Кәгъбәтулланы төзекләндергәндә тирәюньдәге һәрбер таудан берәр таш алалар, ә Гарәфәткә тимиләр, аны Аллага багышлыйлар.

Хаҗ вакытында бөтен дөньядан килгән мөселманнар шушы тау янындагы иңкүлеккә тупланалар һәм бер тәүлек буена вакытларын гыйбадәт кылып үткәрәләр. Шуннан Мәккәгә хаҗ йолаларын үтәргә юнәләләр.

Мәккәдән Гарәфәт тавына барганда без хәзрәте Хәдичә күмелгән урын һәм Җәбәләте Нур тавы яныннан уздык. Шушы таудагы Һира куышында Мөхәммәткә беренче вәхи килгән, Корьән аятьләре иңгән дип исәпләнә.

Мәдинә шәһәрендә мөселманнар өчен изге урын — Мәсҗеде Рәсүлулла. Бу шулай ук мәһабәт архитектура комплексы. Аның зур залларында да берьюлы берничә йөз мең кеше намаз укый ала. Бу комплекс үз эченә Мөхәммәт галәйһеәссаләмнең төрбәсен дә ала. Соңгысы төрле асылташлар белән бизәлгән ике катлы йорт биеклегендәге күркәм бина. Хәзрәте Гайшә йорты урынына корылган бу мәһабәт бинага пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһеәссәләмнән тыш беренче хәлифәләрнең җисми калдыклары да урнаштырылган. Мәсҗеде Рәсүлулла, белән янәшә үк беренче сәхәбәләр күмелгән каберлек урнашкан.

Мәдинәдә без шулай ук мөселман дине тарихы белән нык бәйләнгән Уһуддә тавы янында, мәсҗеде Итте-кыйбла һәм Коба мәчетләрендә булдык. Уһуддә тавы янында Мөхәммәт пәйгамбәрнең кяферләр белән зур бәрелеше була һәм бу бәрелеш ислам тарихында, аның позицияләре ныгуда мөһим урын алып тора. Бу урында хәзер зур мәчет салынган.

Мөселманнар намазны башта Бәйтел мәкаддәскә (Иерусалимгә) карап укый торган булганнар. Бервакыт Мәдинә янында намаз укыганда Мөхәммәткә намазны Кәгъбәтуллага карап укырга дигән вәхи килә. Мөхәммәт шул урында мәчет салдыра һәм аны Итте-кыйбла мәсҗеде дип атый. Гарәбстанның хәзер-

ге хөкүмәте аның урынына дүрт манаралы зур мәһабәт бина салдырган. Аның аскы катында хатын-кызлар, өске катында ирләр намаз укыйлар. Мөхәммәт галәйһеәссаләм Мәдинәгә күчеп килгәч Коба дигән җирдә мәчет салдыра. Бу аның тарафыннан салдырылган беренче мәчет була. Хәзер бу урын шәһәр эчендә һәм искесе урынына зур мәһабәт бина корылган. Бу мәчет Мәсҗеде Коба дип атала. Аның түбәсе иртән күтәрелә, ә кичен ябыла. Бу исә көн дәвамында мәчеттә бер төрлерәк һава сакларга мөмкинлек бирә. Әйтелгән ике мәчеттә дә, Уһудда тавы янында да, мәсҗеде Рәсүлулла һәм пәйгамбәребез төрбәсе янындагы кебек үк, һәрдаим халык кайнап тора. Без бу мәсҗедләрнең һәркайсына кереп намаз укып чыктык.

Хиҗҗазда булу көннәрендә без Согуд Гарәбстанының җәмәгать һәм мәдәният эшлеклеләре, галимнәре, язучылары һәм эшмәкәрләре белән очраштык. Бу җиргә аяк басуыбызның икенче көнендә үк Җиддә шәһәрендә безне илнең күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, элек Гарәбстанның мәдәният һәм информация министры булган доктор Ямани үзенең йортына кабул итү мәҗлесенә чакырды. Мәҗлестә Гарәбстанның үзеннән, шулай ук башка илләрдән килгән галим-голәмә катнашты. Мәккәгә килгәннең икенче көнендә без Бөтендөнья Мөселман лигасында (Рабитада) булдык. Бу ислам үзәге Мәккәнең бер читендә таулар арасында урнашкан һәм яшеллеккә күмелгән шәһәр бистәсендә зур һәм мәһабәт сарайны били. Лига ислам дөньясында бара торган процессларны өйрәнә, мөселман илләре белән элемтәләр урнаштыру өстендә эшли. Аның составында фәнни-тикшеренү үзәкләре оештырылган, дөньяви һәм дини әдәбиятны туплаган бай китапханәсе бар. Бу китапханәдә 20дән артык телдә чыккан китаплар тупланган. Лига комплексына мәчет тә керә. Безне Рабитаның генеральный секретаренең беренче урынбасары доктор Мөхәммәд Наср Аббуди кабул итте. Ул өлкән яшьтәге мәһабәт кенә бер адәм, 70 китап авторы. Әңгәмә вакытында без — татарлар турында да китап язганлыгын һәм аның тиздән чыгачагын әйтте. Ул мөселман дөньясы турында сөйләде. Ахырда мин дә чыгыш ясадым, үзебезнең ислам дөньясының иң төньягында урнашкан төрки халык булуыбыз, Идел болгарлары токымыннан икәнлегебез турында сөйләдем, халкыбызның ислам динен кабул итүе тарихын, бу вакыйгаларның 1100 еллыгына багышланган танта-

наларга тукталдым. Аннан халкыбызның соңгы язмышы, Россия тарафыннан буйсындырылгач туган хәл турында сүз алып бардым. Чыгышымда шулай ук соңгы 70 ел эчендә халкыбыз кичергәннәрне, хәзер бара торган процессларны һәм алдагы бурычларны яктырттым. Ахырда Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбарын», Мәрҗани турындагы җыентыкны һәм үземнең кайбер хезмәтләремне бүләк иттем. Безне Рабита составындагы «Корьән һәм гыйлем» дигән бүлеккә алып керделәр. Бу югары хәзерлекле тикшеренүчеләр тупланган зур фәнни үзәк, анда Корьән белән төрле фәннәр арасында булган аваздашлыкны өйрәнәләр һәм игътибарга лаек ачышлар ясыйлар. Гомумән, Рабита фән белән динне берләштерү өстендә эшли дигән фикер калды. Рабитаның генераль секретаре Абдулла бин Омар Нассер үзе дә зур галим, геология фәннәре докторы.

Без Мәккә университетында да булдык. Бу зур уку йорты. Дин, әдәбият, гарәп теле, тарих, психология, библиография, табигать белеме факультетларыннан тыш, аның составында махсус фәнни-тикшерену институтлары эшли. Һәр факультетның һәм институтның үз бинасы бар, алар зур бер кварталны билиләр һәм яшеллеккә күмелеп утыралар. Университетта 16 мең таләбә (студент) укый. Анда хатын-кызлар өчен аерым бүлем бар. Уку срогы 5 ел. Университетның китапханәсендә 400 мең китап һәм бик күп борынгы кульъязмалар тупланган. Китапханә-библиография факультеты китапханәсендә тагы 27 мең том китап саклана. Без тел факультетында булдык, андагы укыту процессы белән таныштык, укыту процессының компьютерлаштырылганын, телевизион аппаратлар, оригиналь күргәзмә әсбаплар киң кулланылганын күрдек. Безне университет ректоры кабул итте һәм университетның эшчәнлеге белән таныштырды.

Бу изге шәһәрдә без Мәккә Язучылар клубында да булдык, андагы әдипләр һәм шагыйрьләр белән әңгәмәдәш булдык. Бу клуб берничә бинаны берләштергән комплекс тәшкил итә, заллары һәм бүлмәләре зәвык белән җиһазландырылган. Комплекс үз эченә бай гына китапханәне, кабул итү һәм эш бүлмәләрен, ял итүгә җайлаштырылган холларны ала.

Мәдинәгә килгәч, безне андагы университет проректоры кабул итте. Бу университет башлыча гуманитар характерда, андагы укыту процессында төп урынны дини тәгълимат һәм ислам тарихы алып тора. Мәккә һәм Мәдинә университетла-

рында һәм Язучылар клубында очрашулар вакытында да мин үз халкыбыз, аның тарихы һәм мәдәнияты турында сөйләдем, алып барган китапларымны биреп калдырдым.

Хиҗҗазда булу безгә хәзер Согуд Гарәбстанында бара торган процесслар, андагы экономик үсеш, социаль үзгәрешләр белән дә азмы-күпме танышырга мөмкинлек бирде. Инде алда әйтеп үтелгәнчә, Согуд Гарәбстанының табигате бай түгел, ул таулар һәм чүлләр белән капланган ил. Анда мул сулы елгалар да юк, яңгырлар да бары кышын гына һәм аз гына явалар. Кояш кыздыра һәм бөтенесен көйдерә. Илнең төп байлыгы нефть һәм ул илнең экономик үсеше нигезен тәшкил итә. 40нчы еллардан башлап безнең Татарстаныбыз да бик күп нефть чыгарды. Аерым елларда нефть чыгару күләме 100әр миллион тоннага җитте. Әмма бу җөмһүриятебезгә, халкыбызга файда китермәде, чыгарылган нефть Союз казнасының төпсез мичкәсенә төшеп югала барды, ә җөмһүриятебездә экологик вәзгыятьне чиктән тыш начарлатты, иген басулары пычранды, нефть районнарындагы чишмә сулары катламына тозлы сулар үтеп керде һәм чишмәләрне файдаланмаслык хәлгә китерде, нефть чыккан төбәкләрдә һава газ белән агуланды.

Согуд Гарәбстанында нефть дәүләт кулында, аның белән хөкүмәт идарә итә һәм аннан килгән табыш илнең экономикасын үстерү өчен файдаланыла. Шуның хисабына завод-фабрикалар салына, промышленностьның төрле тармаклары барлыкка килә, мәһабәт сарайлар төзелә, җәмәгать биналары һәм торак йортлар торгызыла, шәһәрләр төзекләндерелә. Монда иң нык тәэсир иткәне бу илдәге юллар булды. 2,5 млр. тонна нефть чыгарып, без юлсызлыктан интегәбез. Ә Согуд Гарәбстаны менә дигән асфальт юллар белән капланган. Тау-таш арасы, чүлләр, торак пунктлар күренми дә, ә юллар үтә, хоккей бозы өсте кебек, күзгә кебек ялтырап торган төп-тигез юллар. Алар янәшә дә баралар, бер-берсе өстеннән берничә кат булып та кисешәләр. Чүлдә, тау араларында бу юллар буенда автозаправка станцияләре салынган. Аларның күбесенең янында кунакханәләр, рестораннар, юлчыларга гыйбадәт кылу өчен мәчетләр торгызылган. Мәдинәдән Җиддәгә барабыз, машинабыз 160 км тизлек белән элдертә. Мәскәүгә кайткач, Шереметьево аэропортыннан кузгалып китүгә таксиебыз кат-кат ямалган асфальт юлдан сикерә-сикерә бара башлады һәм мин ирексездән Хиж-

җаздагы юллар, аларның төзеклеге турында уйлап куйдым. Мондый югары категорияле юллар анда хәтта мөмкин булмастай күренгән тау-таш араларыннан да сузылганнар. Таифтан Мәккәгә кайтканда машинадан чыгып тау кырыена бастык, алдыбызда упкын, тау астында каядыр еракта хәрәкәттәге машина утлары ялтырый. Без алардан 1 километр биеклектә басып торабыз. Машинага кереп утырдык һәм тау бите буйлап сузылган юлдан төшә башладык. Юл борыла-борыла төшә һәм тау астына кадәр ул 20 километрга сузыла.

Нефть китергән табыш ярдәмендә Согуд Гарәбстанында артезиан коелары казыла, диңгез суы төчеләндерелә, шулай табылган су белән җирләр сугарыла, яңа җиләк-җимеш бакчалары, иген басулары барлыкка килә. Юлда барганда безгә берничә җирдә шундый бакчалар һәм иген кырлары очрады. Игене урылган, кырыйдан сөрелә дә башлаган, ә уртасында, камыл өстендә я дөя көтүе, я сарык көтүе чемченеп йөри. Хәзер Согуд Гарәбстаны үзендә игелгән бодай белән илнең азык-төлеккә булган ихтыяҗларының байтак өлешен каплый.

Исламның мөһим өйрәтмәсе — гыйлемне кая булса, шунда барып алырга кирәк. Гарәпләр бу өйрәтмәне тормышка ашыру өчен бөтенесен дә эшлиләр дигән тәэсир калды. Алар хәзерге дөньядагы фәнни гыйлемнәрне дә, гамәли гыйлемнәрне дә үзләштерәләр һәм киң кулланалар. Урамда 40—45 градус эсселек, ә йортка килеп керүеңә салкынча һава килеп бәрелә. Торак йортларда да, кунакханәләрдә дә, гыйбадәтханәләрдә дә, җәмәгать биналарында да, предприятиеләрдә дә, автомашиналарда да туктаусыз конденционерлар эшләп тора. Производство сферасына да, тормыш-көнкүрешкә дә компьютерлар үтеп кергән. Кунакханәгә барып керәсең, бер почмакта телевизор тора, төбендә микрокалькулятор. Шуның ярдәмендә теләгән каналда телевизорны җибәрәсең. Чүлдә, бәдәвиләр чатырларында да телевизорлар, радиоалгычлар тора, дип сөйләделәр.

Без промышленность предприятиеләрендә булдык. Менә Мәккәдәге туку фабрикасы. Монда бай орнаментлы, корьән аятьләре язылган нәфис тукымалар тукыла, алардагы бай рәсемнәр, корьән аятьләре компьютер ярдәмендә төшерелә. Мәдинәдә безне басмаханәгә алып бардылар. Һәркайда тынлык, пөхтәлек. Озын һәм киң залның бер башындагы калку урында басып торабыз. Залның икенче башы күренми дә. Машиналар

тезелеп киткән. Ләкин кеше күренми. Басмаханә компьютерлар белән идарә ителә. Монда һәр елны 9 миллион данә корьән басыла. Әмма басмаханәнең 27 миллионга кадәр корьән басып чыгарырга мөмкинлеге бар. Моңа кадәр 7 телдә корьәннең тәржемәсе дә басылган. Хәзер казакъча тәрҗемә басарга әзерләнә. Үзбәкләр дә инде корьәннең үзбәкчәгә тәрҗемәсе әзер булуын әйттеләр, аны шушы басмаханәдә чыгару мөмкинлеге турында сүз алып бардылар. Ә без, күпьеллык китап басу тарихы булган халык, әле һаман мондый тәрҗемә кирәкме, юкмы, дип сөйләнәбез. Бу предприятиедә без корьәннең магнитофон язмалары хәзерләнә торган цехта да булдык.

Һәм, ниһаять, Җиддәдә суны тоздан чистарту заводы. Ул электростанция белән бер комплекс тәшкил итә. Инде сүз алып барылган предприятиеләр кебек үк, ул да яшеллеккә күмелеп утыра. Монда да бөтен процесс компьютерлаштырылган. Электростанциядә дә, суны төчеләндерү цехларында да кешеләр берән-сәрән генә очрый. Бу — Согуд Гарәбстанында су чистарта торган иң зур предприятие. Ул Англиядә хәстәрләнгән проект нигезендә төзелгән. Әмма производство процессын гарәпләр үзләре камилләштергәннәр һәм югары нәтиҗәгә ирешкәннәр.

Урамнарда, тау араларындагы һәм чүлләрдәге юлларда машиналар агылып тора. Монда машиналарның нинди генә юк, дөньякүләм автомобиль күргәзмәсе диярсең. Япония машиналары да, Англия, Америка, Германия, Франция, Италия машиналары да — барысы да бар, тик совет машиналары гына күренми.

Нефть китергән табыш хисабына табигать һәм культура һәйкәлләре төз тотыла, аларны баету чаралары күрелә. Моның ачык мисалы Мәккә, Мәдинәдәге Мәсҗеде харам һәм мәсҗеде Расүлулладагы идеаль тәртип, алардагы пөхтәлек һәм төзлек. Хиҗҗаз тарихи һәм сәнгати һәйкәлләргә бай төбәк. Хәзер аларга яңалары өстәлә. Моның бер мисалы — Таиф янындагы табигать һәйкәлләре (тыюлыгы). Монда Гарәбстанга хас пейзаж, игътибарга лаек табигый объектлар, таулар, түбәләр, комлыташлы тигезлекләр сакланган, алар арасыннан асфальтланган аллеяләр сузылган, агачлар утыртылган. Һәркайда электр лампалары, прожекторлар гөлт итеп тора. Аның мәйданының күләмен әйтүче булмады. Моны күз алдына китерү өчен безгә заповедникның уртасыннан сузылган асфальтланган төз юлдан югары тизлектә 30 минутка якын баруыбызны әйтү дә җитә.

Согуд Гарәбстанында социаль проблемаларны хәл итүгә дә җитди игътибар бирелә һәм нефтьтән килгән табыш моңа яхшы нигез булып тора, дигән тәэсир калды. Кайбер генә мисаллар. Без булган туку фабрикасында 250 кеше эшли. Алар аена уртача 800 доллар хезмәт хакы алалар. Кайбер югары квалификацияле эшчеләрнең хезмәт хакы 1000—1200 долларга җитә. Бер доллар 4 риальгә (Согуд Гарәбстанындагы акча берәмлеге) тиң. Алган хезмәт хакының 400 риале юл расходларына, 350 риале ашау-эчүгә китә. Калган 2500—3000 риале хисабына эшче тормыштагы башка кирәк-яракларын ала.

Мәккәдә өйләнү кыйммәткә төшә — 100 мең риальгә кадәр акча тотарга кирәк. Ә андый акчасы булмаса егет ни эшли, дип сорадык. Елмаеп кына, кәләшне башка җиргә барып эзләргә туры килә, дип җавап бирделәр. Һәм өстәделәр: әгәр егет үзенең мохтаҗлыгын раслый алса, хөкүмәт аңа 35—45 мең риальгә кадәр ярдәм бирә. Хөкүмәт шулай ук йорт салучыларга 300 мең риальгә кадәр ссуда бирә. Ә ул 24 ел буе ссуданың билгеләнгән бер микъдарен һәр елны вакытында кайтарып барса, ссуданың 30 проценты кичерелә. Гомумән Согуд Гарәбстанында торак проблемасын хәл итүгә яхшы игътибар бирелә булса кирәк. Мәккәнең бер районыннан барганда без әле яңа гына төзелеп беткән коттеджлар шәһәрчегенә тап булдык. Барлыгы 5 мең коттедж, аларны шәһәр властьлары салдырган һәм тиздән үзләрендә яшәргә тиешле гаиләләрне кабул итәчәкләр. Без булган шәһәрләрнең барысында да урамнар буйлап барганда безгә менә хастаханә, менә бала тудыру йорты дип күрсәтә килделәр. Алар хөкүмәт тарафыннан салдырылганнар һәм аларда авырулар дәүләт хисабына дәваланалар. Җәддәдә кешенең һәр көн дәвамында файдаланылган суы 8 риальгә төшә, әмма судан файдаланучы аның 1,5 риален генә түли, калганын хөкүмәт каплый.

Мөселманнарның изге урыннарында булу безгә исламның тарту көчен бөтен тирәнлеге белән аңларга мөмкинлек бирде. Менә Мәсҗеде харам. Мәсҗеде харамда Кәгъбәтулла тирәсендәге ачык мәйданда берничә мең кеше зикер әйтә-әйтә әйләнә, тәкбир әйтә, догаларын укый. Кәгъбәтуллага борылып карый да ялвара, аминь әйтә, булдыра алса якынаеп аның ташының ачык калган җирен (таш бизәкле кара парча белән чолганган) үбә, кулы белән сыйпап китә. Болар арасында төрле кавем кешеләре — ак тәнлеләр дә, кара тәнлеләр дә, сары тәнлеләр дә,

ире-хатыны да, олысы-кечесе дә бар. Монда алар барысы да бертигез. Барысы алдында бер бөек зат — Алла. Бөтенесе уй-фикерләре, күңел-калбләре белән аңа төбәлгәннәр, барысы да изге уйда. Мәсҗеде харамның Кәгъбәтулладан як-якка сузылган киң, озын һәм биек залларына җәелгән келәмнәргә шыгрым тулы халык утырган. Намаз укыйлар. Алар арасында да агы да, карасы да бар. Хатын-кыз аерым залларда утыра. Сафа һәм Мәрвә тауларын тоташтырып салынган калонналы озын зал. Буе 6—7 йөз метр булыр. Анда әйтелгән ике тау арасында шулай ук зикер әйтеп төркем-төркем халык йөгерә. Мәккә янындагы Мина тавы каршындагы вадида шайтан ишарәсе төшкән дигән урын бар. Шуннан узганда хаҗ кылучылар (барганда да, кайтканда да) шайтанга таш атып китәләр. Моның мәгънәсе яманлыкка, бозыклыкка, хаксызлыкка, башка әхлаксызлык күренешләренә таш ату, алардан арыну. Мәсҗеде харамда инде әйтелгән күренешләрне карап торганда миндә бу халык яманлык, явызлык, азгынлык белән араны өзә, чистарына, монда килеп болай гыйбадәт кылган кеше нинди генә булса да әхлаксызлык юлына басмас, күңелендә изгелек кенә булыр дигән фикер туды. Бу фикер Гарәфәт тавы янында, Мәдинәдә мәсҗеде Рәсүлулла, Мөхәммәт галәйһеәссаләм төрбәсе, Уһуддә тавы, Иттекыйбла, Коба мәчетләренә килгән халыкның җаны-тәне белән бирелеп гыйбадәт кылуын күргәннән соң тагы да ныгый барды.

Без Хиҗҗазда булган көннәрдә анда хаҗга килүчеләр туплана башлады. Аларны без Мәккәдә дә, Мәдинәдә дә, Җиддәдә дә, юл буйларында салынган кунакханәләрдә дә күп очраттык. Төрле кавем кешеләре. Менә фарсылар, араларында аяксызлары да күп. Ирак белән булган сугышта гарипләнеп калганнар. Аяксызлар коляскаларда йөриләр. Иран хөкүмәте хаҗга аларны үз хисабына җибәргән. Иранннан килгән башка хаҗилар, күренеп тора, аларга зур ихтирам күрсәтәләр, ярдәм итәләр. Хаҗга килүчеләр арасында индонезиялеләр дә, малайзиялеләр дә, һиндстанлылар да, пактистанлылар да, Филиппиннан һәм Африкадан чыкканнары да очрады. Мәдинәдәге басмаханәдә Көньяк Африкадан килгән хаҗиларның зур бер төркеменә тап булдык. Болар үзләренең оешканлыклары, кигән киемнәренең пөхтәлеге белән аерылып торалар. Хаҗга килгән барлык делегацияләр составында да ире-хатыны, яше-карты бар. Бездә Төркиядән килүчеләр бигрәк тә матур тәэсир калдырды. Аларны 50—60 мең чамасы булачак диделәр. Үз автобусла-

рында килгәннәр, шуларда Хиҗҗаз шәһәрләрен һәм юлларын гизәләр. Без аларны кая барсак та очраттык. Тукталган кунакханәләрендә төрек флагы җилферди. Барысы да бер төсле киенгән. Ирләр өстендә соры тукымадан тегелгән костюм, хатын-кызларында шундый ук күлмәк. Һәркайсының күкрәгендә, автобусларының алгы пыяласында төрек эмблемасы.

Һәр елны хаҗга 2—3 миллион кеше килә. Бу да исламның тарту көченең ачык бер билгесе.

Хаҗга килүчеләр һәр елны 1 миллион чамасы корбан чалалар. Ите консерваланып яки туңдырылып, Сомали һәм Бангладеш кебек мохтаҗлыкта яшәүче мөселман илләренә озатыла. Бу исә ислам этикасының шәфкатьлелек, мәрхәмәт турындагы таләпләренең тормышка ашырылуының бер формасы.

Исламның мөһим таләпләренең берсе — пакьлек, чисталык. Хиҗҗазда булу көннәрендә без Гарәбстанда бу таләпнең дә ничек төгәл үтәлүен күрә алдык. Җиддә аэропортына килеп төшүемә күземә беренче булып тубыгына кадәр сузылган ак күлмәк кигән, башына ак япма салган кеше күренде. Урамнарда, җәмәгать урыннарында, йортларда кешеләр башлыча шушы киемнән. Бары производствода гына мин гадәти эш киеменнән булган кешеләрне очраттым. Мондагы эссе һавада ул ак күлмәк тиз керләнә булыр. Әмма кешеләрне кайда гына, кайчан гына күрсәң дә, аларның өсләрендә чип-чиста, яхшылап үтүкләнгән ак күлмәк. Безне бер атна буена йөрткән негр шоферыбыз (ул Нигерия мөселманнарыннан) да, кайсы гына шәһәргә барып чыксак та, шул чиста ак күлмәктән иде.

Шушындый пакьлек, чисталык һәм төгәллек кайда гына барсаң да саклана: өс-башны тотуда да, эштә-гамәлдә дә, тормыш-көнкүрештә дә. Юлларда һичкайда һичнинди чүп-чар күрмәссең. Алар идеаль тәртиптә тотыла, нинди дә булса чокыр-чакырлар очрамый. Юл буйларында теләсә кайда тимер-томырлар яки шин да аунап ятмый. Юл яңа каткан боз кебек төп-тигез. Йортларда, ишек алдында барып керүгә, яшеллеккә күмелгән идеаль чисталыкка тап буласың. Һәркайда тәртип, һәрнәрсә үз урынында. Өйгә узасың. Анда да шул ук хәл. Рестораннарда да, кунакханәләрдә дә шундый ук чисталык, пакьлек, пөхтәлек хакимлек итә. Һичнинди шау-шу, ыгы-зыгы юк. Тыныч кына сиңа тиешле хезмәтне күрсәтәләр һәм бу да пөхтә генә итеп башкарыла. Кунакханәләрдә һәркөн урын-җирне алыштыралар. Һәркайда шушы тәртип.

Бездә хатын-кызга карата исламның позициясенә тискәре караш яшәп килә. Бу очракта еш кына мисал итеп хатын-кызның капланып йөрүен китерәләр. Янәсе, ислам хатын-кызга кимсетеп карый, аңа йөзен ачарга да рөхсәт итми. Белмим, Корьәндә һәм хәдистә бу мәсьәләгә караган күрсәтмәләр ниндидер, бу миңа мәгълүм түгел. Шуңа күрә үзем күргәннәргә таянып сүз йөртәм. Гарәп хатын-кызлары карага киенгәннәр, башларына да кара бөркәнчек япканнар. Ник ирләр акка, ә хатын-кызлар карага киенгәннәр, дип сорадым. Хатын-кызның да күлмәге ирләрнеке кебек үк актан, әмма шуның өстеннән алар кара кием салалар, гадәт шулай, дип җавап бирделәр. Кара бөркәнчекләре белән йөзләрен каплаган хатын-кызларны да күрдем, күзләре генә ялтырап тора. Башларына кара бөркәнчек каплап, бит турына үтә күренмәле челтәр япкан хатын-кызлар да очрады. Битен бөтенләй капламаган гарәп хатын-кызларына да тап булдым. Ә башка илләрдән килгән мөселман хатын-кызлары исә үз киемнәрендә һәм ачык йөз белән йөриләр. Урамда да, Мәсҗеде харамда да, Кәгъбәтулла тирәли йөрүчеләр арасында да, Мәдинәдәге Рәсүлулла Мәсҗедендә дә, Мөхәммәт пәйгамбәр төрбәсе янында да, башка гыйбадәтханәләрдә дә шулай. Боларны күргәч, мин, хатын-кызның капланып йөрүе дини таләпләрдән бигрәк, халыкларның милли традицияләре белән бәйләнмәгәнме дип уйладым. Гарәпләрдә ул, мөгаен, милли традицияләрдән килә. Гарәбстан исламның үзәге һәм бу традицияне кайбер урыннарда ислам таләбе дип уйлап кабатлаганнар булыр.

Хиҗҗазда без төрле кавем кешеләрен күрдек. Африкадан чыкканнарны да, көньяк һәм көньяк-көнчыгыш Азиядән чыкканнарны да, европалыларны да. Хәзер Согуд Гарәбстанында 4—5 млн. чит ил кешесе даими рәвештә яши диделәр. Алар нефть промыселларында, промышленностьның төрле тармакларында, төзелештә, юллар салуда, хезмәт күрсәтү сферасында эшлиләр. Без йөргән беренче класслы юлларны башлыча төрекләр, пакистанлылар, һиндстанлылар, филиппинлылар, африкалылар салганнар. Җирле халык оешканлык, эшне җиренә җиткереп эшләү ягыннан бигрәк тә төрекләрне мактап искә ала.

Согуд Гарәбстанында үзбәкләр күп яши. Килгән көнебездән алып киткән көнебезгә чаклы без аларның даими кайгыртуын, игътибарын тоеп яшәдек. Болар Урта Азия совет власте

урнаштыру өчен барган көрәштә җиңелгәч, ватаннарын калдырып китәргә мәҗбүр булган кешеләрнең токымнары. Алар башта Әфганстанга чыкканнар, аннары бөтен мөселман дөньясына таралганнар. Мин аларны Америкада булганда да, төркиягә баргач та очраткан идем.

Ватаннарыннан куылган халык. Әмма чит-ят җирдә үз урыннарын тапканнар, тормыш корганнар, муллыкта яшиләр. Миңа алар арасында бизнесменнар да, инженерлар да, врачлар да, теш техниклары да очрады. Ватаннарын ташлап китәргә мәҗбүр булган үзбәкләр үзләре инде дөнья куйганнар. Хәзер монда 2—3нче буын вәкилләр яши. Ләкин ят тирәлектә үзләренең телләрен, гореф-гадәтләрен саклыйлар, асыл ватаннары турында уйлап яшиләр, үз халкының киләчәге турында борчылалар, кайгырталар. Танылган ватандашлары килү алар өчен зур вакыйга булды, ил-халык турында алардан күбрәк белергә тырышалар, аларны олыладылар, хөрмәт иттеләр. Миңа да алар оештырган мәҗлесләрдә катнашырга туры килде. Үзбәкчә яшиләр, табыннары да, аш-сулары да үзбәкчә, гомумән, миллилекне яхшы саклыйлар. Бу мәҗлесләр аралашу, фикер алышу, киңәшләшү чарасы вазыйфасын үти дигән тәэсир калдырды. Шунда алар милли проблемалар турында фикер алышалар, аларны чишү юлларын билгелиләр. Ватандагы хәлгә дә тәэсир итәргә тырышалар булып тоелды.

Мин моның барысын да соклану, көнләшү белән күзәттем. Һай, безнең халыкта да шундый бердәмлек, милләт турында шулай кайгыртып яшәү булсачы, дип уйладым. Әле килүебезнең беренче көнендә ук Җиддәдә каршы алган үзбәкләрнең берсеннән (ул мондагы үзбәк җәмгыятендә үзәк урынны били дигән тәэсир калдырды), монда татарлар бармы, дип сорадым. Бар иде, әмма олылар инде дөнья куйды, ә яшьләр гарәпләшеп беттеләр, диде. Мәдинәдә дә, Таифта да миңа ичмаса берәр татар күрсәтә алмадылар. Ә бу шәһәрләр татарларның борын-борыннан барып йөргән урыны. Безнең халык тирәлеккә бик җиңел яраклаша. Үзбәкләр дә яраклашканнар, әмма үзбәклекләрен саклап яраклашканнар. Ә безнекеләр исә милләтебез белән араны өзеп башка халыклар арасында бөтенләй эреп бетәләр. Мин моны Төркиядә булганда да төсмерләдем. Без бу тенденцияне Советлар Союзының төрле почмакларында да, хәтта үзебезнең Татарстанда да күзәтәбез.

Хәзер халкыбызның киләчәге өчен көрәшкә күтәрелдек. Һай, милли аңны ныклап сеңдерәсе иде аңа, ул аны кайда гына барса да саклап калырлык булсын иде. Безнең милли аңыбызның аерылгысыз өлеше — ислам, дибез. Күп гасырлар буе, ачыктан-ачык урыслаштыру, чукындыру сәясәте алып барылган заманнарда да ул, милли мәктәбебез белән бергә, милләтебезне саклап калуда хәлиткеч таяныч булды. Әмма миллилекнең башка яклары да бар. Яшь буынны тәрбияләүдә аларның берсенә дә тиешле әһәмият бирелмәде. Нәтиҗәдә, атеистик сәясәт тамыр җәйгәч, динебез зәгыйфьләнде, хәлсезләнде. Мәктәбебез дә миллилеген югалтты. Нәтиҗәдә милли битарафлык тамыр җәйде. Моннан берничә еллар элек трамвайда барганда бер татар карчыгының күршесе белән әңгәмәсе колагыма чалынган иде. Әбинең балалары тормышларын урыслар белән корганнар. «Кем белән генә яшәсәләр дә барыбер инде, дин бетте», дип нәтиҗәдә ясады әби. Димәк, миллилек тә калмады. Ә башка мөселман илләренә барып төпләнгән милләттәшләребез бик җиңел генә шундагы җирле халык арасында эреп бетә баралар... Бу исә милләттәшләребез арасында, алар кайда гына яшәсәләр дә, милләтне саклап калу өчен милли рухны сеңдерү зарурлыгын куя.

Тәэсирләргә бай сәяхәтебез тәмамланып килә. Бу сәяхәт көннәрендә безне Бөтендөнья Ислам лигасының генераль секретаре урынбасары, Лиганың Көнчыгыш Европа, Советлар берлеге һәм Кытай мөселманнары бүлеге җитәкчесе хаҗи Рәхмәтулла Төркестани озатып йөрде. Милләте белән уйгурлардан. Ил белән, шәһәрләр белән, ислам үзәкләре белән, халыкның көнкүреше, гореф-гадәтләре, илдә бара торган процесслар белән ул безне үзбәк телендә таныштырды. Аның түземлелеге, ягымлылыгы, һәрдаим кирәкле ярдәм итәргә хәзер торуы өчен без аңа чиксез рәхмәтлебез. Хиҗҗаздан китәребезгә берничә сәгать калгач, Бөтендөнья мөселман лигасының Җиддәдәге резиденциясендә безне лиганың генераль секретаре доктор Абдулла бин Омар Нассер кабул итте һәм изге теләкләре белән безне озатып калды.

Икенче июнь көнне кичке сәгать 11 дә, Хиҗҗазга килеп җитүебезгә нәкъ бер атна булган вакытта, без Җиддә аэропортына килдек һәм тиздән «Австрия һава юллары» самолетында Вена аша илгә юл алдык.

1991 ел.

IV

БЕРДӘМ МАКСАТ, БЕРДӘМ КӨРӘШ
(Татар Иҗтимагый үзәге корылтаеннан соң уйланулар)

Татар Иҗтимагый үзәгенең беренче нигез ташлары 1988 елның җәендә илдә яңача фикерләү, үзгәртеп кору һәм демократияләштерү идеяләренең җәелүе шартларында салынды. Июль аеның эссе кичләренең берсендә Казан дәүләт университетыннан һәм Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтыннан бер төркем фән кандидатлары, аспирантлар һәм студентлар җыелып татар милләтен, аның телен һәм мәдәниятын саклап калу юнәлешендә эш башлау фикеренә килделәр һәм инициатива группасы оештырдылар. Группа милләт алдында торган проблемалар тирәсенә халык фикерен туплау эшенә кереште һәм милләт вәкилләренең корылтаен хәзерли башлады. Шушы максатта 1988 елның көзендә һәм кыш башында киң җәмәгатьчелек катнашында очрашулар, киңәшмәләр үткәрелде. Татар иҗтимагый үзәгенең платформасы һәм уставы проектлары хәзерләнде.

Иҗтимагый үзәкнең беренче адымнары ук зур каршылыкларга очрады. Аерым даирәләрдә аңа милләтчелек рухындагы экстремистик оешма дигән мөһер сугылды. Шушындый урынсыз бәяләмә матбугат битләрендә дә, республика җитәкчеләре үткәргән киңәшмәләрдә һәм җыеннарда да яңгырады, хәтта җирле органнарга әлеге Үзәкнең эшчәнлегенә каршы эш җәелдерергә кирәклеге турында партия өлкә комитетыннан күрсәтмәләр дә бирелде. Татар җәмәгатьчелеге арасында да Үзәкнең эшенә шикләнеп карау тенденцияләре күренде. Өлкәнрәк галимнәр дә, язучылар да Үзәкнең эшчәнлеген читтәнрәк күзәтеп торуны мәгъкуль күрделәр.

Шушы шартларда 1989 елның февралендә Татар иҗтимагый үзәгенең I корылтае җыелды. Аның эшендә Татарстан һәм Союзның төрле төбәкләрендә сайланган делегатлар катнашты.

Корылтай Үзәкнең платформасын һәм уставын раслады, җитәкче органнарын сайлады. Иҗтимагый үзәкнең алгы эше шушы платформа һәм устав нигезендә җәелдерелде.

Хәзер бу эшчәнлекнең нәтиҗәләре күз алдыбызда. Бүгенгесе көндә Иҗтимагый үзәк халыкны туплаучы зур көчкә әйләнде. Ул алып барган эшнең нәтиҗәләреннән берсе һәм иң мөһиме халкыбыз арасында уяну процессы башлану, Татарстанның шәһәрләрендә, район үзәкләрендә, СССРның төрле төбәкләрендә Иҗтимагый үзәкнең бүлекләре оешу. Хәзер мондый бүлекләрнең саны 100дән артып китә һәм алар актив эш алып баралар. Иҗтимагый үзәкнең абруе үсүнең мөһим бер күрсәткече— хәзер аны республиканың җитәкче даирәләре дә танырга һәм аның белән хисаплашырга мәҗбүрләр. Иҗтимагый үзәк күтәргән күп кенә проблемалар партия һәм совет органнарының эш программаларына үтеп керде һәм алар еш кына Үзәк белән параллель юнәлештә эш иттеләр. Характерлы бер мисал: КПССның республика комитеты Иҗтимагый үзәкнең II корылтаена тәбрикләү сүзләре белән мөрәҗәгать итте. Ә беренче корылтайның йомгакларына карата ул вакыттагы партия өлкә комитетының карашы тискәре иде.

Тууының беренче көннәреннән үк Иҗтимагый үзәк Татарстанның статусын үзгәртү, автономияле республика кысаларыннан котылу юнәлешендә киң эш җәелдерде. Татарстанны союздаш республика статусына күчерү таләбе белән имзалар җыю оештырылды. 1990 елның җәенә бу таләпне яклап 300 меңнән артык кеше кул куйды. Киң җәмәгатьчелек катнашында җыелышлар, митинглар оештырылды. Бу таләпне яклау һәм популярлаштыру максатында концерт заллары, матбугат битләре файдаланылды. Акрынлап бу таләп киң җәмәгатьчелек аңына үтеп керде. 1990 елның җәй башында Татарстан язучылары съезды да аны яклап чыкты. Озакламый Язучылар союзы идарәсе инициативасы белән иҗат оешмаларының берләштерелгән пленумы булды һәм ул да республикабызның суверенитеты идеясен хуплавын белдерде. Халык арасында теләктәшлек тапкан бу идеягә республиканың җитәкче даирәләре дә колак салырга мәҗбүр булдылар. Шушы шартларда 1990 елның август азагында Татарстан Югары Советының сессиясе чакырылды. Сессия барган көннәрдә Ирек мәйданы гөрләп торды. Монда җыйналган халыкның таләбе бер — Татарстанның

дәүләт суверенитетын игълан итү иде. Нәтиҗәдә 30 август көнне Югары Совет үзенең шуңа багышланган декларациясен игълан итте. Бу зур җиңү булды һәм моңа Татар Иҗтимагый үзәгенең керткән өлеше бәхәссез.

Татар Иҗтимагый үзәгенең 1991 елның 15—16 февралендә Казанда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында үткәрелгән II корылтае 2 еллык эшкә йомгак ясады. Аның утырышларында Союзның төрле төбәкләреннән 650гә якын делегат катнашты.

I корылтай белән чагыштырганда II корылтай эшендә уңай якка зур үзгәреш күзгә чагылды. Корылтай эшлекле шартларда узды. Тикшерелә торган мәсьәләләр буенча 60тан артык делегат чыгыш ясады.

Корылтай барышында да, чыгышларда да халык язмышы турында борчылу, аның киләчәге турында уйлану сизелеп торды. Бу корылтай кабул иткән документларда да чагылыш тапты. Әйтелгән документлар I корылтай кабул иткән документлардан теоретик яктан да, куелган максатларының характеры белән дә һичшиксез югары торалар. Эчтәлекләре белән алар халкыбыз алдында торган проблемаларны киң планда колачлыйлар. Бу яктан II корылтайда кабул ителгән платформа игътибарга лаек. Анда милли хәрәкәт алдында торган мәсьәләләр киң планда яктыртылалар, фәнни яктан да, хокукый яктан да алар төпле итеп нигезләнәләр. Моңа кадәр Татар Иҗтимагый үзәге юридик яктан бер Татарстандагы оешма буларак яшәп килде. II корылтайда Бөтенсоюз Иҗтимагый үзәгенә нигез салынды, аның җитәкче органнары сайланды.

Корылтай, андагы чыгышлар Татар Иҗтимагый үзәге, гомумән зыялыларыбыз алдында торган бурычларның никадәр зур һәм катлаулы булуын бөтен тулылыгы белән ачып салды. Бу бурычларның иң олысы һәм иң мөһиме — милләтне саклап калу. Совет власте елларында алып барылган сәясәт халкыбызның милләт буларак яшәү нигезләрен какшатты, милли нигилизм тамыр җәйде, манкортлык таралды, милли тамырларын белмәгән һәм белергә теләмәгән бәндәләр барлыкка килде. 1989 елгы сан алуның йомгакларына караганда Союзда яшәүче 6648 мең татарның бер миллионнан артыгы туган телен белми. Корылтайда бу процесста башка фактлар белән беррәттән катнаш никахларның да зур роль уйнавына басым ясап әйтел-

де. Хәзер татар кызларының 42 проценты башка милләт кешеләре белән никахлаша. Татар егетләре белән дә хәл шулай тора. Моңа кадәр бу интернационализм күренеше дип макталып киленде. Асылда исә ул милләтнең тамыры йомшауга, акрынлап аның юкка чыгуына илтә торган күренешкә әйләнде. Күренекле совет этнографы академик Ю.В.Бромлейның раславынча, катнаш никахлар хәзерге шартларда ассимиляцияләштерүнең төп юнәлеше. Мондый никахлардан туган балаларның кайберләре әле үзен татар дип санаулары да мөмкин. Ләкин, кагыйдә буларак, алар татар телен, мәдәниятын, аның тарихын белмиләр. Болардан туган балаларда инде милли аңнын чаткысы да калмый. Әлбәттә, яшьләрнең мәхәббәт хисләре белән уйнарга ярамый. Монда нинди дә булса көчләүләр мөмкин түгел. Әмма аларга вакытында башка милләт вәкилләре белән кушылуның нәтиҗәсе нинди булачагын төшендерү хәерле булыр.

Милләтне саклап калуның иң мөһим бер өлеше рәвешендә корылтай милли мәктәп булдыру икәнлегенә басым ясап әйтте. Уку-укыту, мәктәп-мәдрәсә мәсьәләсе халкыбызның озын гасырларга сузылган тарихында иң мөһим проблемаларның берсе булып килде. Әле X гасыр башларында ук гарәп сәяхәтчесе Ибн Руста бабаларыбыз болгарларның авылларында мәчетләр булганлыгын, мәчетләр каршында мәктәпләр эшләвен һәм аларда мулла-мөэзиннәрнең балаларга дин-әхлак сабаклары бирүен, укырга-язарга өйрәтүен язып калдырган. Бу традиция татарлар арасында Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорында да, туган җиребез патша Россиясе тарафыннан басып алынгач та дәвам итте. Халкыбыз көчле эзәрлекләүләр шартларында, хөкүмәттән бер тиен акча алмыйча үзенең барлы-юклы сәрмаяләры хисабына һәрбер мәчетле авылда мәктәп-мәдрәсә тотты, балаларын милли традицияләрдә тәрбияләргә тырышты. Зур эзәрлекләүләр нәтиҗәсендә аерым авыллар тыштан христианлыкка күчәргә мәҗбүр булган очракта да, яшерен рәвештә булса да балаларга мөселман сабагы укыту дәвам иттерелде. Нәтиҗәдә мәктәп-мәдрәсә татар халкының милли рухын саклап калуда олы бер таянычка әйләнде. Моны христиан миссионерлары да танырга мәҗбүр булдылар. Һәм үзләренең уңышсызлыгын татарларның грамоталыгында һәм мәктәп-мәдрәсәләрнең эшендә күрделәр.

Шунлыктан да XIX гасыр азакларында патша хөкүмәте татар мәктәбенең эшенә һәртөрле киртәләр куя башлый, киң планда миссионерлар эше җәелдерелә. Шушы шартларда та-

тарлар арасында җәдитчелек дигән киң хәрәкәт барлыкка килә. Җәдитчеләр үзләренең эшчәнлеге белән татар халкы тормышының бөтен якларын колачладылар. Шулай да аларның игътибары үзәгендә мәктәп-мәдрәсә мәсьәләсе торды. Алар мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту эшенә киң реформа үткәреп, дини дәресләр белән рәттән дөньяви фәннәр дә кертеп, аларның эшчәнлеген заман таләпләренә якынайтырга тырыштылар. Һәртөрле кыенлыкларга, кадимчеләрнең дә, патша властьларының да, миссионерларның да каршылыкларына карамастан, алар милли мәктәпләр челтәренең киңәюенә, уку-укыту эшләренең яңа баскычка күтәрелүенә ирештеләр. Нәтиҗәдә 1917 елгы революцияләр чорына татарлар илдәге иң грамоталы, басма китап һәм матбугат иң күп таралган халыкларның берсенә әйләнделәр.

Революциядән соңгы елларда татар мәктәпләренең челтәре тагын да киңәйде, аларда укучылар саны да арта барды. Әмма тора-бара милләтләргә карата Сталин һәм аның иярченнәре үткәргән сәясәт нәтиҗәсендә татар мәктәбе акрынлап үзенең миллилеген җуйды, ата-аналарның күпчелеге балаларын укырга урыс мәктәбенә бирергә мәҗбүр булдылар. Татар Иҗтимагый үзәге үзенең беренче адымнарыннан ук татар балаларын татарча укыту мөмкинлекләрен тудыру мәсьәләсен күтәрде. Әмма соңгы елларда тамыр җәйгән традиция бу эшне тиешенчә җәелдерергә мөмкинлек бирми. Хәзерге татар балаларының бары 7% гына татарча белем ала. Милли хәрәкәтнең басымы астында соңгы вакытта урыс мәктәпләрендә татар теле дәресләре кертү турында сүз алып барыла башлады. Әмма бу да, балалар бакчаларында атнасына 1—2 мәртәбә 15 минутлык татар теле дәресләре үткәрү дә берни дә бирергә сәләтле түгел. Бу бары күз буяу гына. Балалар туган телне дә, милли мәдәниятыбызны да, тарихыбызны да, мең еллар дәвамында урнашкан әхлак нормаларын да яхшы белеп үсәргә тиешләр. Шунда гына милли рух сакланачак. Моның өчен балалар бакчасыннан башлап югары уку йортынача тәрбия, уку-укыту татар телендә, татар халкының милли традицияләре нигезендә, татар халкының милли педагогикасына таянып алып барылырга тиеш. Шунда гына милләтне саклап калу мөмкинлеге туачак.

Корылтайда милләтне саклап калуда халкыбызның тарихын, аның мәдәниятын милләттәшләребезнең аңына сеңдерү хәлиткеч чараларның берсе икәнлегенә басым ясап әйтелде. Хәзерге

милли мәдәниятыбызның бөтен байлыгы халкыбызга җиткерелми. Мәктәпләрдәге укыту программалары балаларга урыс һәм дөнья культурасын тирәнтен өйрәнү максатын куялар. Бу кирәк. Әмма шуның белән бергә аларга халкыбызның үз мәдәниятын да киң планда өйрәтергә мөмкинлек бирелергә тиеш. Соңгы елларда татар теле укытылмаган сыйныфларда туган як мәдәнияты дигән дәресләр кертү генә бу бурычны башкарып чыгару өчен һич тә җитәрлек түгел.

Үсә торган буынга халкыбызның тарихын тулы күләмдә яктыртуның никадәр мөһим икәнлеге һәркемгә ачык булса кирәк. Үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге дә юк. Соңгы 50—60 ел эчендә халкыбызны үзенең хакыйкый тарихыннан аеру, аны оныттыру өчен барысы да эшләнде.Без аны мөстәкыйль рәвештә тикшереп, үзебезчә язу хокукыннан мәхрүм ителгән идек. Тарихчыларыбыз халкыбызның үткәнен урыс галимнәре уйлап тапкан концепцияләр нигезендә, алар күзлегеннән чыгып яктыртырга мәҗбүр булдылар. Нәтиҗәдә, тарих бозылып күрсәтелде, күп очракларда без цивилизациядән бер яктарак торган кыргый халык рәвешендә сурәтләндек. Тарих фәне кешедә үзенең халкына карата горурлык хисе тәрбияләргә тиеш. Ә безнең китапханә киштәләренә менеп урнашкан һәм мәктәпләрдә дәреслек итеп кулланылган китаплар исә халкыбызның үткәне белән уңайсызлану тойгылары гына уята алдылар. Бу халкыбызны көчсезләндерде, милли дәртне сүндерде, аны инкыйразга этәрде. Хәзер бурыч тарихыбызны аның тирәсендә тудырылган уйдырмалардан арындыру, аны каплап торган кара пәрдәне алып ташлау. Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Әхмәров, М.Рәмзи-Мәккәи, Һ.Атласи, Г.Гобәйдуллин кебек галимнәребез һәм зыялыларыбыз башлаган традицияләр нигезендә аны яңабаштан язарга һәм халыкның аңына җиткерергә кирәк.

Инде I корылтайда ук милләт вәкилләре үзләренең чыгышларында бөтен кискенлеге белән ислам мәсьәләсен күтәргәннәр иде. II корылтайда да бу мәсьәлә бөтен тулылыгы белән яңгырады һәм бу очраклы хәл түгел. Ислам, мөселманлык озак гасырлар буе милли аңыбызның аерылгысыз өлеше булып килде. Ул әхлакый тормышыбызның нигезен тәшкил итте һәм тәрбия эшендә хәлиткеч роль уйнады. Хәзер без зур борчылу белән милли аңның сүнүе, гаилә мөнәсәбәтләренең йомшаруы, шәфкатьсезлек, мәрхәмәтсезлекнең җәелүе, эчүчелекнең нык

тамыр җәюе, балалар арасында таралган тыйнаксызлык турында сөйлибез. Боларның барысында да 50—60 ел дәвамында дингә карата үткәрелгән сәясәт үзенең ролен уйнады. Шуңа күрә дә корылтайда диннең җәмгыятьтәге ролен торгызу тормышыбызның әхлакый нигезләрен сафландыруда, кешеләрдә шәфкатьлелек, рәхимлелек тәрбияләүдә, милли аңны үстерүдә иң мөһим чараларның берсе буларак каралды. Бу мәсьәлә корылтай кабул иткән платформада да үзенең чагылышын тапты.

Корылтайда катнашучыларның игътибар үзәгендә республиканың суверенитеты, аны яклау һәм реальләштерү мәсьәләсе торды. Татарстан Югары Советының суверенитет турында декларация кабул итүенә ярты ел вакыт үтеп китте. Мәскәүнең хәзергә кадәр аны тану турында белдереп чыкканы юк. Киресенчә, РСФСР власть органнары Татарстанны Россия составындагы бер территориаль берәмлек итеп эш итәләр. Хәзер Союз килешүен хәзерләү буенча актив эш алып барыла. Шушы арада гына аны хәзерләүче группа утырышында РСФСР Югары Советы рәисе урынбасары Абдуллатипов Союз килешүенә республикалар һәм суверен дәүләтләр кул куялар, дигән тәкъдим кертте һәм бу тәкъдим кабул ителде. Союз килешүенә шушы формула кереп китсә, бу милләтләрне төрле сортларга бүлү, бер халыкны икенчесе өстенә кую сәясәтенең яшәве дәвам итәчәк, дигән сүз.

Республикабызда «демократлар» кабыгына төренеп эш итүче группалар исә суверенитетлык идеясенә пычрак атуны дәвам итәләр, аны реальләштерүгә булган һәр адымга аяк чалалар. «Согласие» группасының соңгы вакыттагы белдерүләре, фәннәр кандидаты А.Разиновның «Вечерняя Казань» газетасының 1991 елның 6 февралендә «Сайлаучылар мәнфәгатендә», Татарстан халыкларының демократик партиясе рәисе В.Курносовның шул ук газетаның 11 февраль санында урнаштырылган «Демократия—милләтчелек—диктатура» исемле мәкаләләре бу көчләрнең нинди актив эш алып барганлыгын күрсәтүче мисаллар булып торалар.

Бу шартларда Татар Иҗтимагый үзәгенең, халкыбызның бөтен актив көчләренең иң мөһим бурычы — суверенитетны тормышка ашыру юнәлешендә республикада да, Үзәктә дә эзлекле эш алып бару, моңа халкыбызның игътибарын юнәлтү, моның өчен аны актив эшкә тарту. Бу җиңел булмаячак. Халкыбыз арасында уяну процессы башланды. Әмма әлегә,

бөтен милләт уянып җитте, дип әйтә алмыйбыз. 4,5 гасыр буена башыбызны тукмап тору безнең аңыбызга коллык, буйсынучанлык психологиясен сеңдерде. Милләттәшләребезнең күпчелеге, безгә кирәкне Мәскәү бирер, дип көтәләр һәм шуңа ышанып яшиләр. Бу психологиядән никадәр тизрәк арына алсак, милләтебезнең киләчәге шулкадәр якты булачак. Шуңа күрә Иҗтимагый үзәк эшенең халкыбызның бөтен төркемнәре арасына үтеп керүенә ирешергә кирәк. Хәзергә бу Үзәкнең эше башлыча шәһәрләрдә һәм аерым район үзәкләрендә алып барыла. Әмма авылларга Иҗтимагый үзәкнең әлегә үтеп керә алганы юк. Соңгы вакытларда газеталарда Апаста, Әгерҗедә һәм башка кайбер төбәкләрдә Иҗтимагый үзәкнең бүлекчәләрен ачуга аяк чалулары турында хәбәрләр басылды. Шушындый ук хәл шәһәрләрдәге промышленность һәм төзелеш предприятиеләрендә дә күзәтелә. Бу каршылыкларны җиңми торып Иҗтимагый үзәк корылтае билгеләгән программаны үтәү мөмкин булмаячак.

Корылтай чын мәгънәсендә гомуми күтәренкелек шартларында узды. Аның документлары һәм карарлары зур күпчелекнең тавышы белән кабул ителде. Әмма күңелгә шик сала торган нәрсәләр дә күзәтелде. Аерым чыгышларда бер-беренә карата түземсезлек авазлары яңгырады, бер-береңнең фикеренә колак салырга теләмәүчелек күренде. Корылтайның көн тәртибенә куелган мәсьәләләрне тикшергәндә дә, аның документларын кабул иткәндә дә, Иҗтимагый үзәкнең җитәкче органнарын сайлаганда да фирка тәгассыблыгы чаткылары ялтыраштыргалады. Мондый күренешләр тамыр җәйсә, милли хәрәкәтебез бик кыен хәлгә куелачак. Алда авыр көрәш тора. Анда бары бердәмлек сакланганда гына җиңеп чыгарга мөмкин. Иҗтимагый үзәк моңа кадәр зур эшләр башкарды. Ул бердәм максатка бердәм көрәш нәтиҗәсендә мөмкин булды. Бу бердәмлек сакланырга тиеш.

1991 ел.

ИРЕК ҺӘМ БӘЙСЕЗЛЕК
(Академик Р.Шәкуровның бер мәкаләсе уңаеннан)

Һәр халыкның, һәр милләтнең үз язмышын үз кулына алырга хакы барлыгы көн кебек ачык нәрсә. Бу Берләшкән Милләтләр Оешмасы кабул иткән документларда да бик

аңлаешлы итеп әйтелгән. Моңа кадәр илебез тормышында хакимлек иткән идеологиядә дә бу игълан ителгән иде. Әмма тормышка гына ашырылмады. Илдә яңарту, үзгәртеп кору дулкыннары күтәрелгәч, татар халкы да үз язмышын үз кулына алу юлына басты. Бу көрәшнең мөһим бер нәтиҗәсе 1990 елның 30 августында Җөмһүриятебез Югары Советының Татарстанның суверенитеты турында декларация кабул итүе булды.

Декларация кабул ителде. Әмма ул әле кәгазьдә генә кала бирә. Реаль мөстәкыйльлеккә ирешүдән әле без бик ерак. Ә аның тирәсендә болытлар куерганнан-куера бара, көн кебек ачык нәрсә өстенә болганчык су бөркелә, ул каралтып күрсәтелә, пычратыла. Бу юнәлештә Татарстанда эш итүче урыс «демократлары» һәм үзәктәге кайбер информация үзәкләре зур активлык күрсәтәләр. Әйтелгән дулкынга татарлар арасыннан да кайберәүләр килеп кушыла. СССР Педагогия Академиясе академигы Р.Шәкуров шулар төркеменнән. Газета битләрендә аның сүз бара торган мәсьәләгә кагылышлы берничә язмасы басылып чыкты. Академикның соңгы мәкаләсе «Сәясәт—мөмкинлекләр сәнгате» («Политика — искусство возможного») дип исемләнгән («Вечерняя Казань», 1991 ел, 6 сентябрь). Элеккерәк дөнья күргән язмаларыннан аермалы буларак, Р.Шәкуров бу мәкаләсендә суверенитет идеясен инде турыдан-туры кире какмый, хәтта «мин республиканың суверенитетын, Татарстанның мөстәкыйль дәүләт булуын яклыйм» дип тә яза, әмма ашыкмаска, Россиянең ачуын кабартмаска өнди.

Авторны, Татарстанның мөстәкыйльлеккә чыгуы мәсьәләсе әле өлгермәгән, сәясәттә ашыкмаска, мөмкинлекләрдән чыгып эш итәргә, мөмкин булмаган нәрсәгә алынмаска кирәк, дип фикер йөртә, дияргә мөмкин. Боларны укыгач, тарихыбыз искә төшә. XVI гасыр уртасында Казан ханлыгы тирәсендә болытлар чиктән тыш куера, халыкта бердәмлек булмау, төрле төркемнәр арасында низагларның тирәнәюеннән файдаланып Мәскәүлеләр Казанга һаман һөҗүм итеп торалар, ханлыкта эчтән җимерү эше алып баралар. Казанны саклап калу мәсьәләсе бик мөшкелләнгәч, идарәче даирәләр ханбикәне урыслар кулына биреп шәһәргә мәскәүлеләрнең басымын йомшартырбыз дип исәплиләр. Алар, мөгаен, Р.Шәкуров күтәргән «Сәясәт—мөмкинлекләр сәнгате» дигән принципка таянган булырлар. Әмма Сөембикәне Иван IV карамагына тапшыру Казанга ты-

нычлык китерми. Бер ел үткә Иван IV зур гаскәр белән килеп шәһәрне һәрьяктан камап ала. Казанлылар өчен авыр көрәш көннәре башлана. Шәһәрнең сакчылары кырылып бетә, әмма дошманга бирелмиләр. Р.Шәкуровка ияреп фикер йөртсәк, аларны мөмкинлекләрне исәпкә алмауда гаепләргә мөмкин. Әмма мин гаепли алмыйм. Күренекле урыс тарихчысы М.Худяков та аларны гаепләми, киресенчә, мәдхия укый, сатылмаулары, актык каннарына кадәр көрәшкәннәре өчен мактый. Мин дә бу фидакарь бәндәләр алдында баш иям.

Мин һич тә хәзерге шартларда азатлык, мөстәкыйльлек өчен коралы көрәшкә өндәмим. Мондый көрәш безгә кыйммәткә төшәчәк. Әмма мин, мөстәкыйльлекне, ирекне безгә урыс «демократлары» шәфкатьлелек күрсәтеп, үз ихтыярлары белән китереп тоттырырлар, дип тә ышанмыйм. Моның өчен көрәшергә кирәк. Дөрес, бу көрәштә мөмкинлекләрдән чыгып эш итү кулай булыр. Хәзер безнең өчен бердән-бер мөмкин булган көрәш юлы — парламенттан киң файдалану, аңың аша милли мәнфәгатьләребезне яклый, җөмһүриятебезнең мөстәкыйльлеген ныгыта торган законнар үткәрү, халкыбызның сәяси аңын үстерү, аны суверенитетны яклау өчен актив көрәшкә тарту, массакүләм акцияләр үткәрү, җөмһүриятебездә яшәүче барлык милләтләргә, шул исәптән урысларга да, суверенитетның аларга каршы юнәлдерелмәгәнлеген, барлык халыкларның да уртак файдасына икәнлеген төшендерү.

Мәкаләнең авторы Россия белән мөнәсәбәтләрнең кискенләшүендә татар милли хәрәкәтен әйдәп баручыларны гаепләргә тырыша һәм аларны моңа бармаска өнди. Чыннан да Россия белән мөнәсәбәтләрнең кискенләшүе безнең файдага түгел. Әмма мөнәсәбәтләрнең кискенләшүендә беренче чиратта кем гаепле соң? Безнең халыкның таләбе бер генә — башка халыклар белән тигез булу, милли проблемаларны үзе мөстәкыйль рәвештә хәл итә алуы. Бу законлы теләк. «Демократ» исеменә төренгән бөекдержавачылык тарафдарларына бу ошамый, аларның төп максаты «бердәм һәм бүленмәс» империяне саклап калу, башка халыкларны аның тырнагыннан ычкындырмау. Шушы максатны алга сөреп урыс «демократлары» милли азатлыкка омтылыш күренешләренә каршы инсинуацияләргә баралар, бу омтылышны кара төскә манып күрсәтергә тырышалар, аңа яла ягалар. Димәк, мөнәсәбәтләрнең кискенләшүендә

төп сәбәп — бөекдержавачылык идеяләре белән агуланган, әмма «демократ» булып кыланган империячелек идеологиясе тарафдарлары. Академик Р.Шәкуров үзенең киңәшләрен шуларга адресласа бик урынлы булыр иде, һәм, бәлки, мөнәсәбәтләрне йомшарту юнәлешендә үзенең өлешен дә кертер иде. Ул моны эшләми, татар халык мәкалендә әйтелгән кебек, «ак эт бәласен кара эткә» аударып маташа.

Р.Шәкуров татарның милли-азатлык байрагын күтәргән демократик көчләрен җаваплылык хисе, югары интеллектуальлек белән, мораль нормаларны саклап эш итәргә чакыра. Моның белән дә килешергә мөмкин. Әмма милли мөнәсәбәтләр кискенләшкән шартларда бу сыйфатлар каршы яктан да, урыс «демократлары» ягыннан да таләп ителә. Әмма соңгыларының эш-гамәлләрендә бу сыйфатлар сизелми. Р.Шәкуров та алар алдында мондый таләп куймый. Шуңа күрә аның тикшерелә торган мәсьәләдә позициясен берьяклы дими, ни дисең?

Академикның татар халкына үзенең суверенитеты белән мавыкмаска кирәклеген күрсәтеп китерелгән аргументларының берсе — Татарстан Россия җирләре белән камап алынган, үзенең бердәм һәм бүленмәс ил икәнлеге турында кайгырткан бер генә дәүләт тә үз эчендә башка нинди дә булса дәүләт яшәве белән килешә алмый, дип белдерә. Әйтергә кирәк, бу очракта ул тарихи фактларны күрмәмешкә салыша. Һәм хәзерге дөньяда бара торган чын демократик процесслар алдында күз йома. Беренчедән, бер дәүләт белән чикләнгән хәлдә икенче дәүләтләр яшәгәнен тарих белә. Моның ачык мисалы хәзерге Көньяк Африка республикасы белән чолганган хәлдә, хәтта бу илдә расачылык режимы хакимлек иткән шартларда да, Лесото дигән дәүләтнең яшәве. Икенчедән, Р.Шәкуров демократия турында күп сөйләсә дә, хәзерге дөньядагы демократик процессларны һәм илебездәге хокукый дәүләтчелеккә омтылыш күренешләрен искә алмый булса кирәк. Ул баштанаяк узган чорларның тоталитар идарәчелек һәм бер халыкның икенчесенә буйсынып яшәве практикасыннан чыгып фикер йөртә. Ә Россиядә чын мәгънәсендә демократик режим һәм хокукый тәртипләр урнашса, әйтелгән бердәм яшәешкә тулы мөмкинлек туачак. Татар милли хәрәкәте демократик позицияләрдә тора, Россия белән заман рухында, цивилизацияле мөнәсәбәтләр урнашыр дип ышана.

Р.Шәкуров үзенең мәкаләсендә «без хәзер Россия белән бары конфедератив мөнәсәбәтләргә генә хисап тота алабыз» дип яза. Россия белән конфедератив килешүе төзелү мөмкинлеген кире кагарга ярамый, әлбәттә. Әмма конфедерация суверен дәүләтләрнең үзара ирекле килешүе нәтиҗәсе буларак кына укмаша ала. Шуңа күрә безгә беренче чиратта реаль суверенитетка ирешергә кирәк. Бу булмый торып конфедерация фикция генә булып калачак. Теге яки бу халыкка көчләп тагылган конфедерация була алмый, ул протекторат рәвешен ала, ә протекторат халыкара мөнәсәбәтләрдә инде үтелгән этап. Чын демократик мөнәсәбәтләр аның белән янәшә яши алмыйлар. Әгәр мондый нәрсә татар халкына тагыла калса, тынычлык булмаячак, татар халкы үзенең реаль бәйсезлегенә ирешкәнче көрәшне туктатмас, дип тулы ышаныч белән әйтергә мөмкин.

Россия «демократларының» күренекле вәкиле А.Собчак халык депутатларының соңгы съездында башта илдә демократик тәртипләр урнаштырырга кирәк, аннары суверенизация турында уйларга мөмкин булачак, дип белдерде. Мәкаләсеннән күренгәнчә, академик Р.Шәкуров та шушы позициядә тора. Әмма демократия нинди генә матур итеп төрелеп күрсәтелмәсен, теге яки бу халыкка читтән көчләп тагылса, демократия була алмый. Мондый «демократия» бары тоталитар тәртипләр урнашуга гына китерәчәк. Демократияне халыкларга көчләп такмыйлар, ул аларның табигый үсеше нәтиҗәсе буларак кына урнаша ала.

Мөстәкыйльлеккә, суверенлыкка, дип яза академик, бары демократияләштерү процессында гына ирешергә мөмкин. Мәсьәләне киресенчә дә куярга мөмкин. Демократиянең мөһим өлеше — халыклар иреге. Халыкларга ирек бирми торып, һичнинди демократия турында сүз алып барып булмый. Башка халыкларны изә торган халык үзе дә азат була алмый. Ә урыс «демократлары» әлегә демократия битлегенә төренеп империяне саклап калырга тырышалар. Ә бу бер халыкка да, шул хисаптан урысларның үзләренә дә һичнинди демократик ирекләр китермәячәк. Шуңа күрә демократияләштерү белән суверенлаштыру параллель рәвештә барырга тиешләр. Бары шул гына реаль демократия белән реаль суверенитетның тантанасына китерәчәк. Б.Н.Ельцин үзенең бер чыгышында, Россия империя булмаячак, дип белдерде. Бирсен Хода! Шулай булганда, демократия дә урнашыр. Россия составындагы халыклар да иркен суларлар.

Татар милли хәрәкәте демократияләштерү тарафдары һәм чын мәгънәсендә милли ирекқә бары демократиянең тантанасы шартларында гына ирешеп була дип эш итә. Шуңа күрә ул янаевлар белән полозковларга йөз тота алмый. Шул ук вакытта ул «демократия» исеменә төренеп империя идеясен алга сөрүче травкиннарга да йөз тотмый. Татар милли хәрәкәте бүгенге Россиядә А.Сахаров, Е.Боннэр кебек хакыйкый демократлар барлыгын да күрә һәм шуларга йөз тота. Татарстанның мөстәкыйльлеге һәм анда реаль демократик тәртипләр урнаштыру өчен көрәштә ул шушы көчләр белән кулга-кул тотышып бараячак. Бары шул гына безнең изге омтылышларыбызның тантанасына китерә ала. Бары шул гына безгә тоталитаризм калдыкларын ахырына чаклы себереп түгәргә, демократик ирекләр тантанасы шартларында халкыбызның мөстәкыйльлегенә ирешү мөмкинлеге тудырачак.

1991 ел.

ФАТЫЙХ МӘРДӘНОВ ЯКИ МИЛЛӘТЧЕЛЕК КАРАЧКЫСЫ

Ике ел инде матбугат битләрендә, радиода һәм телевидениедә Татарстанның дәүләт статусы мәсьәләсе буенча бәхәсләр бара. Вакыт-вакыт аларга үзәк матбугат органнары да килеп кушыла. Менә «Вечерняя Казань» газетасында 1991 елның 23 январендә басылган «Суверенитетмы яки милләтчелекме?» дигән мәкалә (авторы Ф.Мәрдәнов). Ул үзенең әдәпсезлеге һәм татар халкы мәнфәгатьләрен түбәнсетеп каравы белән аерылып тора.

Мәкалә «Фатыйх Мәрдәнов» имзасы белән басылган. Укып чыккач, мин аны моннан элегрәк Рәшит Гарипов имзасы белән басылган мәкаләгә охшаттым. Татар кешесенең үз халкының өмет-ниятләре һәм мәнфәгатьләре турында шул дәрәҗәдә оятсызларча сүз алып баруына шаккаттым. Мин В.И.Ленинның шовинизм позициясенә баскан һәм үз «тырышлыклары»нда үтә явыз шовинистны да күп тапкырлар узып китәргә сәләтле милләтчеләргә биргән бәясен исемә төшердем. Кызганычка каршы, безнең арада да мондый манкортлар күп әле.

Автор Татарстанның дәүләт суверенитеты игълан ителүне күңеле белән кабул итә алмый һәм республиканы һаман да «Татария» дип кенә атый. Суверенитет дип исәпли ул, бары

тик республиканың житәкче даирәләре тарафыннан гына, халык ихтыярын исәпкә алмыйча игълан ителде. Ләкин, автор моны танырга телиме-юкмы, бу акт республиканың күпчелек халкы сайлаган халык депутатларының бердәм карары белән кабул ителде. Моннан тыш, Татар Иҗтимагый үзәге Татарстанны союздаш республика дип игълан итү турындагы таләпкә имзалар җыю үткәрде. 1990 елның 30 августына кадәр, ягъни республика Югары Советы Татарстанның дәүләт статусы турындагы мәсьәләне карауга керешкәнче аңа 300 мең кеше кул куйды. Татарлар да, руслар да. Бу документ күп кенә производство коллективлары җыелышларында һәм хезмәт иялэре хатларында да яклау тапты. Суверенитетны игълан итү алдыннан, ягъни узган елның август көннәрендә, җәмәгатьчелекнең моңарчы күрелмәгән активлыгында чагылды бу.

Милли проблемаларны хәл итүдә төрлечә омтылып карауларны бастыру сәясәтен үткәргәндә, безне күп еллар буенча интернационализм лозунгысы белән алдап килделәр. Соңгы вакытта шушы максатларда Россия «демократлары» шәхес мәнфәгатьләре төшенчәсен киң кулланалар. Ф.Мәрдәнов та шулар эзеннән бара һәм «Республикада яшәүче гади кешегә суверенитет нәрсә бирә?» дигән сорауны куя. Мин моңа сорау белән җавап бирер идем: Татарстанның Союз һәм Россия Федерациясенең империя структурасында күп дистә еллар буена яшәве республиканың гади кешесенә нәрсә бирде соң? Республикабызның байлыгын үзәк тартып ала торды, ә үзебезнең социаль-экономик, торак-көнкүреш проблемаларыбызны хәл итү һәм халыкның мәдәни-рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен безгә берни дә диярлек калмады. Аннары, милли һәм шәхси мәнфәгатьләрне бер-берсенә каршы куеп та булмый бит. Алар бер-берсенә үрелеп бара һәм шәхес билгеле бер милләт вәкиле буларак формалаша. Шәхси мәнфәгатьләрне милли мәнфәгатьләрдән аеру бары тик империячел-шовинистик сәясәтне үткәрү өчен һәм милләтне үз мәнфәгатьләрен яклауда коралсызландыру өчен генә уңай ул. Кеше хокуклары турындагы гомуми декларациядә шәхес һәм милләт хокукларының аерылгысыз бердәмлектә каралуы очраклы түгел.

Мәкалә авторы шундый сорау куя: милләтара мөнәсәбәтләрнең ихтимал булган катлаулануы өчен кем җавап бирер, янәсе? Аның бу соравы урынсыз. Чөнки республиканың суверените-

тын игълан итү ни өчен милләтара мөнәсәбәтләрне катлауландырырга тиеш соң? Суверенитет турындагы Декларациядә бер генә милләтнең дә мәнфәгатьләре кысылмый, татар һәм рус телләре бердәй рәвештә дәүләт телләре дип игълан ителә, барлык милләтләрнең һәм алар сөйләшә торган телләрнең тигез хокуклыгы тәэмин ителә, аларның мәдәниятларын үстерү өчен тигез мөмкинлекләр гарантияләнә.

Биредә бер халыкны икенчесеннән өстен куярга һәм татар, башкорт яки чуаш халыкларына борын чөеп карарга күнеккән кешеләр генә шулай фикер йөртә ала. Ф.Мәрданов үз нәтиҗәләрен нигезләү өчен мисалга Молдова, Балтыйк буе республикаларын, Әрмәнстан һәм Грузияне китерә. Чынлап та, бу республикаларда аяныч тәҗрибә тупланды. Әлеге республикаларда милләтара мөнәсәбәтләрнең катлауландуында, һичшиксез, бу республиканың җитәкче структуралары ялгышлыгы үзенең ролен уйнады. Әмма биредә һәртөрле «интерхәрәкәтләр»нең дә роле булмады түгел. Чөнки аларның башлыклары империячел фикерләрдән һич тә арынырга теләмиләр һәм бу республикалар халыкларының милли өмет-ниятләре белән исәпләшәселәре килми.

Югарыда әйтеп кителгән республикалардагы хәл бездә дә кабатланмасын өчен республика җитәкчелеге дә, милли хәрәкәтләр дә, «Килешү» оешмасы, Россия «демократлары» дип аталган оешма вәкилләре дә Татарстан ССР Югары Советында ирешелгән консенсусның бозылуына юл куймаска тиешләр. Ә менә Россия «демократлары»ның һәм кайбер матбугат органнарының («Вечерняя Казань», «Литературная газета») күп кенә чыгышлары милләтара низаг тудыруы ихтимал. Шул исәптән «Суверенитетмы яки милләтчелекме?» дигән мәкаләгә дә кагыла бу. Мәкаләнең бөтен рухы шул хакта сөйли. Илдә бара торган үзгәрешләр нигезендә республиканың идарә структураларын үзгәртүдә, Фәннәр академиясен төзү турындагы мәсьәләне тикшерүдә, республика язучыларының үз мөстәкыйльлекләре турындагы карарында һәм аларны, янәсе, җитәкче урыннарны «милләтләштерү»не уйлап чыгаруларында авторның фетнә эзләвен башкача ничек аңлатасың?

«Суверенитетмы яки милләтчелекме» дигән мәкаләнең исеме генә дә авторның бүгенге көндә татар җәмәгатьчелеген борчый торган бөтен нәрсәне милләтчелек күренеше дип аңлатырга маташуы турында сөйли. Озак еллар буена милләә-

тчелек карачкысы милли мәнфәгатьләрне якларга омтылуларга каршы эзәрлекләү коралы булып хезмәт итте. Татар халкын тергезүне, аның теле һәм мәдәниятын үстерүне яклап чыккан өчен генә Югары Совет депутатларын хурлаучы автор нәкъ менә шундый позициядә тора.

Татарстан экономикасы бары тик Россия экономикасы белән бергә генә нәтиҗәле эшли ала, дип кисәтә автор. Бу — империячел фикерләү үрнәге. Автор республика экономикасын бары тик Россия экономикасының кушымтасы дип кенә карый. Хәзерге дөньяда бер генә дәүләт тә экономикасы аерымланган хәлдә яши алмый. Шулкадәр куәтле держава саналган Япония экономикасы мөстәкыйль яши аламыни? Юк, чөнки ул чимал чыганакларыннан мәхрүм ителгән. Татарстанның да экономикасы аерымланган хәлдә яшәмәячәк. Ул Россия белән дә, башка республикалар белән дә үзара файдалы договор нигезендә күпьяклы экономик элемтәләргә керәчәк.

Автор хәтта чит ил фирмалары белән элемтәләрне җайга салуны да мөмкин булмаган иреклелек, муенга богау салу дип аңлый (чөнки моны Татарстанның дәүләт органнары эшли). Ә ул Россия органнарының чит ил фирмалары белән 140 миллиард сумны 7 миллиард 756 миллион Америка долларына сату турындагы алыш-биреше турындагы хәбәргә ничек карый икән? Татарстан хөкүмәтенең чит ил фирмалары белән төзегән килешүләрендә дә эквивалентлы алмашу күздә тотыла бит.

Россия «демократлары»на ияреп, автор республиканың суверенитеты мәсьәләсе буенча референдум турында сүз кузгата. Дөрес, «демократлар»дан аермалы буларак, ул референдумны Татарстан Союз субъектымы яки РСФСР субъектымы дигән мәсьәлә белән бәйләми. Ул мәсьәлә болай куелырга тиеш дип саный: РСФСР белән союздамы яки СССР белән союздамы? Әмма суверенитет — эчке һәм тышкы сәясәттә дәүләт властеның бәйсезлеге ул. Аның субъекты булып әлеге дәүләт берләшмәсе һәм аның халкы тора. Бары тик шулай гына. Шунлыктан Татарстан Союз субъектымы яки РСФСР субъектымы, дигән сорауны кую дөрес түгел. Суверен дәүләт буларак, республика башка дәүләт берләшмәләре белән нинди мөнәсәбәтләргә керәчәк, договор буенча нинди вәкаләтләрне бирә алачак? Биредә сүз бары тик шул хакта барырга тиеш. Ф.Мәрданов ачык ишекне кага. Татарстан Югары Советы бу

мәсьәләне ачыктан-ачык хәл итте: СССР белән союзга Татарстан Союзны төзүче сыйфатында керәчәк һәм Союз договорына мөстәкыйль рәвештә кул куячак. Ул РСФСР белән дә договорга кул куячак.

«Вечерняя Казань»ның шул ук санында Таисия Лучкинаның «Русларның горурлыгын мин нәрсәдә күрәм» дигән хаты урнаштырылган. Әйбәт хат. Моның өчен рәхмәт аңа. Рус булмаган халыкларга карата нәкъ менә шундый хисләр рус интеллигенциясенең демократик даирәләренә хас иде. Нәкъ менә демократик даирәләренә, ә империячел шапырынучы «демократларга» түгел. Таисия Лучкинага һәм аның фикердәшләренә шуны гына әйтә алам: татар милли хәрәкәте республикада яшәүче кайсы да булса халыкның мәнфәгатьләрен түбәнсетү максатын куймый. Ул барлык халыклар һәм милләтләрнең тигез хокуклылыгы, республикада яшәүче барлык гражданнарның иминлеге һәм чәчәк атуы хакына бергәләп иҗади эшләү ягында тора.

1991 ел.

МИЛЛӘТ ҺӘМ МИЛЛӘТЧЕЛЕК

Россиядә революцион күтәрелеш татар халкы алдында торган милли, социаль, сәяси һәм хокукый проблемаларны, милләт язмышы мәсьәләсен бөтен кискенлеге белән ачып салды, милли хәрәкәтне бу проблемаларны чишү юлларын актив рәвештә эзләүгә этәрде. Бу эзләнүләр 1905—1907 һәм 1917 елларда үткәрелгән мөселман съездларында һәм милли корылтайларда үзләренең ачык чагылышын таптылар, милли мәҗлес җыюга, милли идарә һәм хәрби шура оештыруга җиткерделәр. Инде әйтелгән съезд-корылтайларда, милли мәҗлес утырышларында, милли идарә һәм хәрби шура эшчәнлегендә милли һәм сәяси азатлыкка, социаль һәм хокукый тигезлеккә ирешү өчен практик чаралар билгеләнде һәм бу чаралар тормышка ашырыла да башлады. Әмма озак та үтмәде, советлар хакимияте тарафыннан милли мәҗлеснең, милли идарә һәм хәрби шураның эшчәнлегенә чик куелды, аларга милләтчелек мөһере сугылды, милли хәрәкәтнең күренекле вәкилләре, милләтчелектә гаепләнеп, эзәрлекләнә башладылар.

Монда ирексездән нәрсә соң ул милләтчелек, ул җәмгыять үсешенә каршы килә торган тискәре күренешме, татар милли

хәрәкәте һәм милли мәҗлес эшчәнлегендә гайре табигый төсмерләр булдымы, дигән сорау туа. Бу сорауга җавап бирү өчен башта милләт төшенчәсенә күз салып үтик.

Сталин үз заманында милләткә карата «нация есть исторически сложившаяся устойчивая общность людей, возникшая на базе общности языка, территории, экономической жизни и психического склада, проявляющаяся в общности культуры» дигән төшенчә бирде. Сталин культы тәнкыйтьләнгәннән соң, бу бәяләмәне тәнкыйть күзлеге аша үткәрергә тырышып караучылар булды, әмма бу тырышлыклар реаль нәтиҗәгә китермәделәр, философик әдәбият милләт төшенчәсен билгеләгәндә һаман шул Сталин бәяләмәсе тирәсендә әйләнде, бары тик китерелгән төсмерләрнең язылыш тәртибе генә үзгәртелде. Бу Сталин төшенчәсенең большевистик идеологиясенең асылыннан чыккан, философлар ничек кенә тырышмасыннар, аны атлап уза алмадылар, дигән сүз.

Бу төшенчәдә иң мөһиме милләтне бары социаль күренешләр тупланмасына әверелдерү. Бәс шулай икән милләт белән һәртөрле манипуляцияләргә юл ачыла һәм коммунистлар партиясе шушындый юлга басты да. Милләт кешеләрнең билгеле бер тарихи шартларда барлыкка килгән социаль күренешләр һәм мөнәсәбәтләр тупланмасы икән, димәк, ул тарихи шартлар үзгәрүгә бәйле рәвештә үзгәрә һәм коммунизм төзелгәч, бөтенләй юкка чыгачак. Шулай итеп, Сталин әле 20 елларда ук милләтләрнең бөтенләй юкка чыгуы идеясен күтәреп чыкты. Бу максатка ирешү өчен җәмгыять үсешенең аерым этапларының үзенчәлекләренә бәйле рәвештә партия тарафыннан төрле лозунглар куелды. Алар арасында милләтләрнең якынаюы, бергә кушылуы идеясе бигрәк тә алга сөрелде. Бу сәясәтнең үткәрелүе Советлар илендә дистәләгән милләтләрнең юкка чыгуына китерде. Хрущев һәм Брежнев заманнарында яңа милли бердәмлек рәвешендә Совет халкы төшенчәсе калкып чыкты һәм аерым милләтләрнең мәдәниятына, аларның милли үзенчәлекләренә каршы актив һөҗүм алып бару максатында файдаланылды.

Коммунистик идеологиядә Сталин төшенчәсенең территория һәм экономикага кагылышлы ягына басым ясалды һәм милләтнең үзенчәлеге беренче чиратта шуларда чагыла дип бәяләнде. Әмма милләт проблемасына бу күзлектән карау милли бердәмлекнең тышчасын, формасын беренче планга куеп аның

субстратын, милләтнең кемнәрдән торганын бөтенләй читләтеп үтте. Бу да шулай ук милләтләр белән төрле манипуляцияләр ясау максатында файдаланылды.

Милләт төшенчәсен ничегрәк аңларга соң? Аның асылы нидән гыйбарәт? Мин бу очракта дефинацияләр белән шөгыльләнергә теләмим, бары милләтнең асылын чагылдыручы, аңа хас кайбер үзенчәлекләрне генә әйтеп үтәргә уйлыйм. Монда беренче чиратта алга Сталин билгеләмәсе читләтеп үткән, милләтнең субстраты мәсьәләсе килеп баса һәм бу субстратны мин милләтне тәшкил итүче халыкта күрәм. Ләкин халык бу очракта народонаселение яки народные массы рәвешендә алынмый, ә этник бердәмлек рәвешендә күзаллана. Теге яки бу милләтне тәшкил итүче халык — ул этник чыгышы һәм тарихи язмышы ягыннан аерылгысыз бәйләнгән кешеләрнең зур төркеме. Татар телендә кавем дигән төшенчә бар. Милләтне тәшкил итүче халык төркемен, минем карашымча, шушы төшенчә аша күзалларга мөмкин.

Этник берәмлек буларак милләткә хас тагы бер мөһим сыйфат — милли үзаңның формалашкан булуы. Һәм бу милли үзаң ахыр чиктә халыкның үзен ничек атавында (исемендә), милләтне тәшкил итүчеләрнең бер-беренә мөнәсәбәтендә, аларның бер-берсен аңлавында үзенең чагылышын таба. Милләтнең бу үзенчәлеге дә Сталин билгеләмәсендә читләтеп үтелгән иде.

Милләт төшенчәсе белән аерылгысыз бәйләнгән тагы бер сыйфат — милли тел. Милли телдә шушы милләт кешеләре бер-берсе белән аралашалар, шул тел ярдәмендә милли аң, милләт уллары вә кызларының дөньяны ничек аңлаулары, җәмгыять тормышы кануннары формалаша.

Милли бердәмлек шулай ук милли мәдәниятта да үзенең чагылышын таба. Милли хосусиятләр материаль мәдәниятта да, рухи мәдәниятта да шушы халыкка хас үзенчәлекләр белән беркетеләләр. Милләт төшенчәсенең аерылгысыз өлеше буларак милли рухны, милли гореф-гадәтләрне һәм традицияләрне дә күрсәтергә кирәк. Соңгы вакытта Бердяев һәм Достоевский иҗатын өйрәнүгә бәйле рәвештә милли идея турында да күп язалар. Милли рухның, милли үзаңның аерылгысыз өлеше буларак динне күрсәтергә кирәк. Безнең халкыбызда, мәсәлән, мөселманлык күп гасырлар буенча милләт төшенчәсе белән тәңгәлләштерелеп яшәде.

Милләт төшенчәсе турында сүз алып барганда, әлбәттә, без территория һәм экономика мәсьәләсен дә читләтеп үтә алмыйбыз. Тегесе дә, бусы да милләт яшәешенең мөһим шарты, милләтнең тышчасы. Милләт билгеле бер территориядә яши, аның вәкилләре үзара тыгыз экономик мөнәсәбәтләргә керәләр. Шушы территориаль һәм экономик бердәмлек булганда гына теге яки бу халыкның тулы канлы милләт булып яшәвенә мөмкинлек туа.

Әйтелгән фактлар милләт яшәешенең нигезе. Аларның кайсы гына юкка чыкса да, милләтнең нормаль яшәеше өчен кыенлыклар туа. Мәсәлән, үз халкыбыз. Тарихи язмыш аны хәзергә кадәр Советлар Берлеге дип атап йөртелгән илнең төрле почмакларына сибелергә мәҗбүр итте. Нәтиҗәдә территориаль бердәмлек юкка чыкты, милләт буларак халык бик кыен шартларга куелды, аның акрынлап таркалуына юл ачылды. Шөкер, халкыбыз әле милләт буларак яши, милләтне тәшкил итүче башка факторлар яшәгәнгә яши. Бу шартларда милләтне саклауда иң мөһим чара — бу факторларны саклап калу, ныгыту, үстерү, милли аралашуны киңәйтү, милли үзаңның, милли телнең, милли мәдәниятның инкыйразына юл куймау.

Әйдә хәзер милләтне аңлаудагы шушы яссылыктан чыгып 1917 елны булып узган милли корылтайларның, милли мәҗлеснең эшчәнлегенә кыскача гына күз йөртеп чыгыйк: бармы бу эшчәнлектә нинди дә булса хилафлык, җәмгыятьнең яшәешенә каршы килә торган ниндидер бер гамәл? Бу җәһәттән милли корылтайларда һәм милли мәҗлестә каралган мәсьәләләр әһәмиятле. 1917 елның 14—17 апрелендә Уфада губерния мөселман съезды булып уза һәм ул мөселман халыкларының милли-мәдәни автономиясе идеясен яклап чыга, татар теленең дәүләт учреждениеләрендә рәсми тел дип танылуы, мөселманнар яшәгән төбәкләрдә уку-укыту эшләренең ана телендә алып барылуын таләп иткән карарлар кабул итә. Шул ук елның 23—24 апрелендә Казанда да шундый ук съезд уза һәм татар халкының үзбилгеләнү идеясен күтәрә. 1917 елның 1 маенда Мәскәүдә Бөтенроссия мөселманнарының I съезды эшли башлый. Съездда Россиянең чик төбәкләрендә милли-территориаль автономияләр урнашуы мөмкин дип танылa, ә үзәк районнар өчен милли-мәдәни автономия кулай булыр дип табыла. Шул ук вакытта милли-мәдәни автономияне тормышка ашыру анда

яшәүче милләтләрнең үз эше, ул халыклар мөстәкыйль рәвештә үзләренең милли-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү чаралары күрергә хокуклы дип бәяләнә.

Съездда каралган мөһим мәсьәләләрнең берсе — мәгариф мәсьәләсе. Һәм моның да халыкның, милләтнең үз кулында булырга тиешлеге тәгаенләнә, уку-укыту эшләренең милли традицияләр нигезендә, милли рухта барырга тиешлеге күрсәтелә. Съездда кискен көрәш барган мәсьәләләрнең берсе — хатын-кызлар иреге, аларның ирләр белән тигезлеге мәсьәләсе. Хәрби мәсьәләне тикшергәндә съезд армиянең милли принциплардан чыгып төзелергә тиешлеген күрсәтә. Съездда шулай ук рухи тормыш, дин-әхлак мәсьәләләренә зур әһәмият бирелә. Съездның эшчеләр сыйныфы, җир-су мәсьәләләренә кагылышлы карарлары рус демократик хәрәкәтенә кергән партияләрнең программалары белән тәңгәл килә.

1917 елның җәендә Казанда Бөтенроссия мөселман халыкларының өч съезды булып узды: 1) гомуми мөселман съезды; 2) Бөтенроссия мөселман хәрби съезды; 3) руханилар съезды. Бу съездларда да сүз башлыча I Бөтенроссия мөселман съездында каралган мәсьәләләр тирәсендә барды һәм аларда кабул ителгән карарлар I мөселман съездында кабул ителгән карарларны алга таба үстерделәр. Бу карарларда милли-мәдәни автономия һәм территориаль автономия мәсьәләләре әле I съездда билгеләнгән яссылыкта карала, шул ук вакытта милли үзбилгеләнү идеясе алга таба үстерелә һәм ачыграк яңгыраш таба. 1917 елның 22 июнендә өч съездның берләштерелгән утырышы була һәм анда үзәк Россия һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни автономиясе рәсми рәвештә игълан ителә, аны тормышка ашыру өчен мөстәкыйль структуралар, материаль-финанс чыганаклары билгеләнә.

1917 елның 22 ноябрендә Уфада милли мәҗлес эшли башлый. Аның депутатлары милли-мәдәни автономияне реальләштерү өчен төзелгән комиссия тәртип иткән кагыйдәләр нигезендә 50 мең кешедән бер вәкил исәбеннән сайлана. Мәҗлестә милли-мәдәни автономияне реальләштерү өчен махсус идарәләр, шул хисаптан милли идарә (финанс, мәгариф мәсьәләләре), рухани мәсьәләләр идарәсе, хәрби шура оештырыла. Шуның белән бергә милли мәҗлестә милли үзбилгеләнү идеясе дә алга таба үстерелә, милли-территориаль автономия (мохтәрият) мәсьәләсе тикшерелә. Һәм «Идел-Урал штаты» оештыру турында карарлар кабул ителә.

Табигатьтә формалашкан биологик берәмлекләр кебек үк, җәмгыять үсеше процессында барлыкка килгән иҗтимагый берәмлекләр дә яшәү хокукына, бу яшәешне яклау хокукына ия. Мөселман съезд-корылтайларында, милли мәҗлестә кабул ителгән карарлар, күренүенчә, татар халкының милләт буларак яшәешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән иделәр. Югарыда милләт төшенчәсенең эчтәлегенә тукталып, милләтне социаль берәмлек буларак характерлый торган үзенчәлекләрне күрсәтеп үттек. Үзенең яшәешен тәэмин итү өчен һәр милләт шушы үзенчәлекләрен яклау һәм саклау чаралары күрергә хаклы. Бу аның табигый хокукы. Съезд-корылтайларда, милли мәҗлестә кабул ителгән карарлар бары шушы хакны хаклауга юнәлдерелгән, ә аларның эшчәнлегендә катнашучылар милләт кайгысын кайгыртып, милләтнең киләчәген тәэмин итү өчен көрәш юлына баскан милли каһарманнар иде. Һәм без аларны яхшы мәгънәдә, уңай мәгънәдә һич икеләнмичә милләтчеләр дип әйтә алабыз, һәм бу милләтчелек татар халкының милли ихтыяҗларын яклауга, аны милләт буларак саклап калу чараларын күрүгә юнәлдерелгән иде.

Димәк, милләтчелектә, милли мәнфәгатьләрне кайгырту юнәлешендәге эшчәнлектә һичнинди хилафлык юк. Бу милли мөнәсәбәтләр өлкәсендә нормаль күренеш. Бу кешелек дөньясының яшәеш законнарына тәңгәл килә һәм ул тарихта шулай каралды да. Бу тарихка да күз салып үтик.

Милли идея феодализмнан чыгу чорында феодаль таркаулыкка каршы көрәш процессында туа һәм хәзерге Европа дәүләтләренең формалашуында мөһим роль уйный. Миллилек, милләтчелек идеясе соңыннан да, бу дәүләтләр оешкач та, үзенең әһәмиятен югалтмады. Америка социологы Г.Кон «Европада 1789 елдан соң, ә 20 гасырда дөньяның барлык почмакларында да, милләтчелек тарихи үсешнең маягы булды» дип язды һәм бу чорны милләтчелек гасыры дип бәяләде. Ирландия халкы Бөекбританиянең хакимлегенә каршы көрәшкә күтәрелгәч, милләтчелек идеясе бу халыкның милли-азатлык өчен көрәше байрагына әйләнде һәм тора-бара милләтчелек төшенчәсе дөньяның башка почмакларында калкып чыккан милли-азатлык хәрәкәтләрен характерлауда да кулланыла башлады. Көнбатыш социал-демократларның XX гасыр башларында игълан ителгән программ документларында милләтчелек гомумдемократик антиимпериячел хәрәкәтнең аерылгысыз өлеше итеп карала.

Милли-азатлык хәрәкәте күтәрелү шартларында милләтчелек төшенчәсе татар иҗтимагый фикеренә дә үтеп керә һәм милләт мәнфәгатьләрендә эш итү мәгънәсендә кулланыла. Татар милли-азатлык хәрәкәтенең М.Гафури, Г.Исхакый, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов кебек вәкилләре, мәсәлән, милләтчелекне үз халкыңа мәхәббәт, милли язмыш турында кайгырту, милләткә хезмәт итү дип уйлап эш иттеләр. Алар карашынча, милләтчелек ул шушы кавем кешеләренең табигый' хисе. Татар милли хәрәкәтенең күренекле вәкиле Җ.Вәлиди милләтнең киләчәге турында кайгыртуны, бөтен көчне милләтне саклауга сарыф итүне, шушы максатта аны уяту, гыйлемгә, фикери үсешкә, мәдәнияткә сәвыкъ (этәрү) итүне изге бурычлардан санады.[1]

Милләтчелеккә карата хәзер өстенлек итүче караш кайчан һәм ничек формалашты соң? Мондый караш башта татар милли хәрәкәте үсешенә реакция рәвешендә патша самодержавиесенең империячел рух белән сугарылган даирәләрендә калкып чыкты. Бу даирәләр башта татар милли хәрәкәтен чыбыркылау максатында панисламизм һәм пантюркизм карачкысын кулландылар һәм тора-бара аларның лексикасына милләтчелек төшенчәсе дә килеп керде. Шушы язманы хәзерләгәндә мин «Мусульманская печать России в 1910 году» дигән китапка тап булдым. Ул патша Россиясенең матбугат эшләре буенча баш идарәсе тарафыннан хәзерләнгән һәм аның беренче юлларында ук татар матбугатына тискәре төсмер белән милләтчелек мөһере сугыла. «Главной особенностью произведений печати на татарском языке, как прогрессивного, так и оппозиционного направлений, — дип күрсәтелә китапта, — является их сильно выраженный националистический характер: им отличается даже единственный в татарской печати умеренный орган еженедельник «Тарджиман». Шушы фикерне үстереп китап авторлары татар матбугатын Россиядән читләшүдә, халыкта милли рух тәрбияләүдә, мөселманлык идеясе таратуда, панисламизмда, Төркия белән якынлашуны яклауда гаеплиләр. Алар фикеренчә, милли мәктәпләрдә миллилекне саклау да, фәнни белемнәрне ана телендә өйрәтү дә гафу ителмәслек милләтчелек күренеше.

Революциядән соң Советлар илендә милләтчелеккә карата урнашкан караш патша самодержавиесе шартларында формалашкан шушы тенденциянең дәвамы булды һәм аның бөек

державачыл рухы тагын да үстерелде. Дөрес, большевиклар милләтләрнең үзбилгеләнү хокуклары турында да сүз алып бардылар. Әмма эштә алар бу хокукны билгеле бер рамкаларга куйдылар һәм бөтен көчләрен унитар дәүләт төзү максатына җиктеләр. Милләтчелек идеясе, шул исәптән татар милләтчелеге дә, бу максатны үткәрүдә комачаулык итте һәм алар кулларында тупланган властьтан файдаланып милли омтылышларга чик кую чарасына керештеләр. Һәм шушы максатта милләтчелек карачкысын үзләренә корал иттеләр. Бу очракта алар милләтчелеккә хас сыйфатларны фальсификацияләү юлына бастылар, аңа шовинизмга хас үзенчәлекләр тактылар. Зур совет энциклопедиясенең 17 томында (358 б.), мәсәлән, милләтчелек милли өстенлекне яклаучы идеология рәвешендә гәүдәләндерелә, аңа башка халыклар өстеннән хакимлек итүгә омтылыш һәм шушы милләткә генә хас сыйфатлар барлыгын алга сөрү тагыла.

Шовинизмга чыннан да милли өстенлекне, милли дошманлыкны, милли тәкәбберлекне, бер милләт мәнфәгатьләрен башкаларга каршы кую һәм милли изүне аклау хас. Әмма милләтчелек шовинизм түгел; милләтче бары үз халкы мәнфәгатьләрен генә кайгырта һәм аны башка милләтләрдән өстен кую, милли чикләнү юлына басмый. Моны без мөселман съездкорылтайлары һәм милли мәҗлес эшчәнлегендә дә ачык күрәбез. Кайбер генә мисаллар. Менә 1 Бөтенроссия мөселманнары съездының 1905 елның 15 августында кабул ителгән резолюциясе. Бу резолюциядә мөселман халыкларының бары башка халыклар белән бертигез хокуклардан файдалану өчен көрәшүе һәм мөселманнарның прогресс көчләренең алдынгы карашлы рус җәмәгатьчелеге позициясендә торуы ассызыклап күрсәтелә. Ә 1917 елны үткәрелгән Беренче Бөтенроссия мөселманнар съездында Россиянең иминлегенә кул сузуларга каршы тору азатлык өчен көрәшнең аерылгысыз өлеше дип бәяләнә. Бу съезд, инде әйткәнемчә, мәктәп-мәдрәсә эшләренә зур игътибар бирде. Аның карарларында, уку-укыту һәм тәрбия эшләрен милли рухта алып бару кирәклеге күрсәтелү белән бергә, балаларга рус телен өйрәнү кирәклеге ассызыклап әйтелә. 1917 елны узган өч мөселман съездының берләштерелгән утырышы исә бөтен мөселманнарны контрреволюция куркынычына каршы көрәштә Россиянең революцион-демокра-

тик көчләре белән берләшергә чакырды. Милли-мәдәни автономия идеясе дә бу съездларда Россия дәүләтчелегенә каршы куеп күтәрелмәде һәм аны Россия законнары нигезендә реальләштерү күздә тотылды. 1917 елның азагында милли мәҗлес милли-территориаль автономия игълан иткәндә исә Совет хөкүмәтенең 1917 елның 15 ноябрендә игълан иткән «Россия халыкларының хокуклары турындагы декларация»сенә таянып эш итте.

Күренә ки, татар милли хәрәкәтендә бернинди дә милли чикләнгәнлек, татар халкын башка халыкларга, шул хисаптан рус халкына каршы кую да күзәтелмәде. Аның вәкилләре бары милли тигезлек, татар халкының Россия шартларында үзенә лаеклы урын алуы, үз язмышына үзе хуҗа булуы, милләт хакын хаклый алуын күз алдында тотып эш иттеләр. Совет хөкүмәтенең һәм коммунистлар партиясенең шовинизм рухы белән агуланган даирәләренә бу ошамады һәм алар, милләтчелек төшенчәсенә шовинизмга хас сыйфатлар тагып, татар милли хәрәкәтен бастыруга ирештеләр. Соңыннан да милләтчелек мөһере милли аңны томалау, миллилекне саклауга юнәлдерелгән кечкенә генә омтылышны да бастыру коралы ролен үтәде. Шушы мөһерне тагып, Сталин һәм аның иярченнәре 20 елларда Солтангалиевне һәм аның яраннарын эзәрлекләделәр һәм ахырда бөтенләй юк иттеләр. 1929—1930 елларда, милләтчелек һәм солтангалиевчелектә гаепләнеп, татар зыялыларының зур төркеме юкка чыгарылды. Милләтчелек карачкысы 1936—1940 елларда җәелдерелгән репрессияләр вакытында да киң рәвештә кулланылды. 50—60 елларда милләтчелек мөһере халык аңына, бигрәк тә аның интеллектуаль катлауларына идеологик басым ясау өчен файдаланылды.

Халкыбызның тарихында шушылай яман роль уйнавына карамастан, милләтчелек төшенчәсенең шовинистик рухтагы интерпретациясе милләттәшләребез арасында да тамырын җәйде. Мин бу очракта марксистик әдәбият турында әйтеп тә тормыйм. Бу әдәбият гомумсоюз күләмендә тантана иткән интернационализм рухында язылды. Мин милләт кайгысын кайгыртып, миллилек рухында язылган хезмәтләрне күз алдында тотам. Менә Касыйм Фәсәховның «Миллилек, милләтчелек вә бәйнәлмиләлчелек» («Шәһри Казан», 1991, 10 апрель) дигән мәкаләсе. Автор милләт хакын хаклый, «демократларның» милли хәрәкәткә булган мөнәсәбәтенең шовинистик рухта икәнле-

ген ачып сала. Шул ук вакытта ул милләтчелек төшенчәсен аңлауда марксистик идеология рамкаларында урнашкан төсмерләрдән арына алмый һәм инде соңгы елларда илдә тантана иткән тенденцияләргә ияреп, милләтчелекне миллилектән аерырга, милли хәрәкәткә милләтчелек түгел, ә миллилек кенә хас дип расларга тырыша. Чынлыкта исә миллилек һәм милләтчелек төшенчәләре үзләренең мәгънәләре белән янәшә торалар, бер-берсенә үтеп керәләр. Милләтчелек ул миллилекнең бер аспекты, миллилекне практик яклауга һәм даулауга юнәлдерелгән аспекты. Милләтчелек милли аңның аерылгысыз өлеше һәм милләтчелек хисе халыкның аңыннан кудырылса, милләт яшәү көченнән мәхрүм ителә. Шовинистлар, нинди генә байрак астына басып эш итсәләр дә, коммунистлармы алар, «демократлармы», шушы максатны күз алларында тоталар.

Менә тагы Борис Антоновның «Милләтче Илдус» дигән мәкаләсе («Шәһри Казан», 1992, 3 январь). Бу мәкалә милләт хакын хаклап йөрүче Илдус Әмирханов турында. Автор аның эшчәнлегенә югары бәя бирә, аны яклый. Әмма авыз тутырып бу эшчәнлекне милләтчелек дип атарга базмый, «милләтче» сүзен куштырнаклар эченә ала. Бу очракта да милләтчелек төшенчәсенә бәйле рәвештә соңгы елларда урнашкан стереотиплар комачаулый.

Һәм, ниһаять, «Вечерняя Казань» газетасында басылган бер мәкалә (1991, 7 февраль). Мәкаләнең исеме «Может ли татарин быть нациналистом?» Авторы — Ә.Минһаҗов. Ул конкрет фактлар белән тоталитар режим шартларында татар мәдәниятының аяныч хәлдә калуын бик популяр рәвештә ачып сала. Һәм шуннан, татар кешесе милләтче була алмый, дигән нәтиҗә чыгара.

Әйтелгәннәрдән милләтчелек төшенчәсен урнашкан стереотиплардан арындыруның никадәр мөһим икәнлеген күз алдына китерергә мөмкин. Хәзергә бу өлкәдә фәлсәфә фәннәре кандидаты Р.Әмирхановның бер мәкаләсен искә алмаганда бернәрсә дә эшләнгәне юк дияргә мөмкин. Бу тирән эчтәлекле, милләтчелекнең нормаль күренеш икәнлеген ышанычлы дәлилләр китереп ачып салган бердәнбер мәкалә («Яңа аваз», 1991, №4) һәм Татар Иҗтимагый үзәге чыгарган «Республика» (1990, №2, 3) газеталарында дөнья күрде, әмма зур матбугатка үтеп керә алмады. Милли хәрәкәтнең нормаль агышы өчен «милләтчелек» төшенчәсенә кагылышлы уйдырмаларны ачып салу, бу

мәсьәләдәге стереотипларны җиңеп үтү күп теоретик хезмәт сорый. Моңа философлар да, тарихчылар да, башка гуманитар фәннәр вәкилләре дә үз өлешләрен кертергә бурычлылар.

Хәзер татар милли хәрәкәте яңа күтәрелеш чорына килеп керде. Аның вәкилләре халык өчен азатлык даулыйлар, аның башка халыклар белән тигез шартларга куелуын, милли телне, милли мәдәниятны үстерү мөмкинлекләре тудырылуын таләп итәләр. Бары шул гына. Империячел рух белән сугарылган хәзерге шовинистик даирәләр «демократия» кабыгына төренеп милләтчелек карачкысын, большевиклар кебек үк, милли хәрәкәтне тәпәчләү максатында файдаланалар. Милли хәрәкәтне пычрату өчен алар төрле уйдырмалар тудыралар. Билгеле булганча, милләтчелек коммунистик идеологиянең кан дошманы булып килде һәм милли үзаңны, милли омтылышларны бастыру өчен коммунистик идеология тарафдарлары һәртөрле пычрак алымнарга бардылар. Һәм менә хәзерге заманның «демократлары» милли хәрәкәткә «милли коммунизм» ярлыгы тагалар. Ә В.Беляев, И.Грачев һәм В. Лопатин кебек «демократлар» аны фашизм белән тәңгәлләштерергә маташалар. Фашизм, билгеле булганча, демократия һәм милли азатлыкның кан дошманы һәм демократик рухтагы милли хәрәкәтне аның белән янәшә куюны бу хәрәкәткә яла ягу дип бәяләмичә булмый.

Милли хәрәкәткә карата мондый инсинуацияләр соңгы вакытларда гомумән модага кереп китте. А.Собчак, мәсәлән, ТАСС хәбәрчесенә биргән интервьюсында, «на базе национальной идеи можно построить только фашистское государство», дип белдерде (Известия, 1991, 23 октябрь). Алда инде милләт идеясенең көнбатышта хәзерге демократик дәүләтләр формалашуына китерүен әйтеп үткән идек.Фашистик диктатурага бары милләт идеясенең гайри табигый формасы — шовинизм илтә. Без моны ике бөтендөнья сугышы арасында Германия мисалында күзәттек. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Азиядә, Африкада, Латин Америкасында милли-азатлык хәрәкәте җәелде. Бу хәрәкәтнең нигезендә милләтчелек идеясе ята иде. Милләтчелек байрагы астында барган бу көрәш күп кенә илләрдә демократик режимнар урнашуга китерде. (Индия, Мисыр, Тунис һ.б.). Кызганычка каршы, бу көрәш авторитар режимнар урнашу белән дә тәгәлләнде. (Сирия, Индонезия, Алжир). Ә аерым очракларда тоталитар режимнар урнашуга да китерде (Ливия, Ирак). Һәм, ниһаять, Эфиопиядә бу көрәшнен нәтиҗәсе

фашистик режим урнашу белән бетте. Әйтергә кирәк, мондый нәтиҗә власть башына килгән көчләрнең шовинизм рухы белән агуланган булуы белән бәйләнгән иде. Димәк, милләтчелек нормаль күренеш буларак һич тә фашизмга алып бармый. Әгәр милләтчелек шовинизм рухы белән сугарылган булса, тарихи агышның мондый нәтиҗәләргә дә китерүе мөмкин.

Соңгы вакытта милли хәрәкәтне, милләтчелекне экстремизмда гаепләү дә модага кереп китте. Милли хәрәкәттә катнашкан кайбер артык радикаль төркемнәр дә үзләренең эш-гамәлләре белән моңа азык бирәләр. Мондый эш-гамәлләрне империянең бөтенлеге сагында торучы шовинистик даирәләр бик оста файдаланалар. Шуңа күрә милли хәрәкәт төрле провокацияләргә юл куймас өчен сак эш итәргә, үз арасында экстремизм күренешләренә урын калдырмаска тиеш.

Шул ук вакытта милләт тормышы кысынкы шартларга куелган хәлдә милли хәрәкәттә радикаль тенденцияләрнең барлыкка килүенең котылгысыз икәнлеген дә әйтеп китәргә кирәк. Милли азатлык идеяләрен тормышка ашыру мөмкинлекләре чикләнгән очракларда милләтчелек еш кына хакимлек итүче милләткә карата куралмаучылык һәм дошманлык төсмерләренә дә манылa. Мондый төсмерләр хакимлек итүче милләтнең идарәче даирәләренең милли омтылышларны кысу сәясәтенә протест рәвешендә барлыкка киләләр. Бу сәбәпләр юкка чыкса, милли дошманлык сәбәпләре дә юкка чыгачак.

Соңгы вакытларда Россия Тышкы эшләр министры А.Козыревның җиңел кулы белән сәяси кулланышка «агрессив милләтчелек» дигән төшенчә кереп китте. Бу төшенчәнең асыл мәгънәсен А.Козыревның да, башкаларның да ачып салганнары юк. Ләкин бернәрсә — төшенчәнең милли-азатлык өчен көрәш алып баручыларга, шул хисаптан Россиянең әле теге, әле бу өлешендә милли-азатлык өчен кабынып китәргә торган көрәш учакларына каршы юнәлдерелгәне көн кебек ачык. Үзләренең милли азатлыклары өчен көрәш — бәйсезлекләрен югалткан халыкларның Алла биргән хокукы. Бу көрәшнең ысуллары да вәзгыятькә бәйле рәвештә төрлечә. Бездә, Татарстанда бу көрәш әлегә, шөкер, тыныч юл белән бара. Демократик тенденцияләр сакланганда, бу акланган юл. Әмма империячел көчләрнең агрессивлыгы көчәйгән тәкъдирдә, моңа адекват рәвештә җавап бирү зарурлыгы тууы мөмкинлеген дә әйтеп үтәргә кирәк. Милли бәйсезлеккә бару юлында — бу акланган чара.

Еш кына хәзерге Европада бара торган интеграция процессларына, милли дәүләтләрнең экономик һәм сәяси якынаюына бармак төртеп күрсәтәләр. Әмма 19 гасырда да, 20 гасырда да Европада булган канлы бәрелешләр безгә яхшы мәгълүм. Ә бу бәрелешләр нигезендә аерым дәүләтләрнең башкалары алдында үзләренең өстенлекләрен раслауга булган омтылышлары ятты. Бу илләрнең халыклары тарихи тәҗрибәдән сабак алып, негатив тенденцияләрне җиңүгә ирештеләр. Нәтиҗәдә, Европа халыклары алдында үзләренең миллилекләрен саклаган һәм милли мәнфәгатьләрне кайгырткан хәлдә үзара якынаю, һәм сәяси, һәм икътисади, һәм мәдәни хезмәттәшлек юлы ачылды.

Хәзер илдә бара торган процесслар иҗтимагый тормышны революцион үзгәртеп кору белән бәйләнгән. Бу үзгәрешнең төп юнәлеше—ил тормышын демократияләштерү. Әмма демократияләштерү процессы авыр бара, икътисади, социаль һәм сәяси мөнәсәбәтләргә демократизм рухы иңдерү зур кыенлыкларга очрый. Бу кыенлыкларның сәбәпләреннән берсе—илдәге милли мөнәсәбәтләрнең катлаулылыгы һәм кискенлеге. Империячел рух коллыгыннан аерыла алмаган «демократлар» милли азатлыкка булган омтылышларны демократиягә каршы куялар, милли суверенитетны яулау демократияне чикли, дип күрсәтергә тырышалар. Асылда исә милли-азатлык идеясенең демократия рухына каршы килүе мөмкин түгел. Үзенең асылы белән ул — демократик хәрәкәт, гомумдемократик антиимпериячел хәрәкәтнең аерылгысыз өлеше. Милли тигезсезлек сакланганда, бер халык үзенең ихтыярын башка халыкларга таккан тәкъдирдә демократиянең тантанасына ирешү мөмкин түгел. Хәзерге Россиядә демократияләштерү процессы кичерә торган кыенлыклар империячел тәртипләрне саклап калуга омтылыш белән турыдан-туры бәйләнгән. Демократия үзенең асылы белән милли азатлыкны да күздә тота. Шулай булгач, демократияләштерү белән милли хәрәкәтне бер-берсенә каршы куярга ярамый. Кулга-кул тотышып барганда гына аларның һәркайсы үзенең тантанасына ирешәчәк. Шикләнмичә әйтергә мөмкин: хәзерге Россия империясендә бара торган процесслар иртәме-соңмы, һәм демократиянең, һәм милли азатлык идеяләренең җиңүенә китерер.

[1] Вәлиди Җ. Милләт вә миллият. Оренбург, 1912, 37, 41 б.б.

1992 ел.

ДЕМОКРАТИЯ, ФЕДЕРАЛИЗМ, МИЛЛӘТ ҺӘМ КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ

Хәзер илебез җәмгыять тормышын демократияләштерүгә юнәлдерелгән тирән үзгәрешләр кичерә. Әмма социаль, экономик һәм сәяси-хокукый мөнәсәбәтләр сферасына демократик принципларның үтеп керүе бик авыр бара һәм биниһая күп каршылыкларга очрый. Бу процессның барышын катлауландыра торган сәбәпләрнең берсе — милли мөнәсәбәтләрнең кискенләшүе. Шовинистик идеология белән агуланган сәяси эшлеклеләр һәм публицистлар, демократик фразаларга төренеп, суверенитетка омтылыш демократик ирекләрне чикләүгә китерә, дип расларга тырышалар. Чынлыкта исә милли-азатлык һич кенә дә демократик ирекләргә каршы килми, киресенчә, аларны күз алдында тота. Милли-азатлык һәм демократия бер-берсенә аерылгысыз рәвештә бәйләнгәннәр һәм күпмилләтле дәүләтләрдә аларның берсенең булмавы икенчесенең дә юкка чыгуына китерә.

Милли хәрәкәт үзенең асылы белән демократик характерда, империализмга каршы юнәлдерелгән гомумдемократик хәрәкәтнең состав өлеше. II Интернационалның әле 20 гасыр башларында кабул ителгән документларында ук ул шулай дип бәяләнә дә. Ленин да милли хәрәкәттә демократик эчтәлек барлыгына басым ясап күрсәтеп үтте. Милли хәрәкәт, кагыйдә буларак, хаким милләтнең басымыннан арынуга, икътисади, сәяси, хокукый һәм мәдәни-идеологик мөнәсәбәтләр өлкәсендә тигезлеккә ирешүгә, милли телнең, мәдәниятның һәм гореф-гадәтләрнең үсешенә тигез мөмкинлекләр яулауга юнәлдерелгән. Бу омтылышларның демократик характерда булуы күзгә ташланып тора. Бер халыкның теләк-омтылышлары икенчесе тарафыннан богауланган тәкъдирдә һәм милли тигезсезлек сакланганда демократик хокуклар һәм ирек турында сүзнең дә булы мөмкин түгел.

Теге яки бу халыкка демократиянең бары милли ирек сакланганда гына бәһасе һәм әһәмияте бар. Милли ирек булмаганда демократия дә була алмый. Шуңа күрә дә хәзерге дөнья җәмәгатьчелеге фикерендә халыкларның суверенитеты, тигезлеге һәм азатлыгы идеясе кешелек җәмгыяте яшәешенең оптималь шарты һәм халыкара мөнәсәбәтләрнең нигез ташы рәвешендә кабул ителгән. Бу Берләшкән Милләтләр Оешмасының күп кенә документларында да үзенең чагылышын тапты. «Колониаль илләргә һәм халыкларга бәйсезлек бирү турындагы

декларация»дә, мәсәлән, «бөтен халыклар да милли үзбилгеләнүгә хокуклы һәм шуңа бәйле рәвештә алар үзләренең сәяси статусларын, икътисади, социаль һәм мәдәни үсеш юнәлешләрен ирекле рәвештә билгелиләр», дип күрсәтелә. Халыкларның суверен үсешкә булган бу хокукы Берләшкән Милләтләр Оешмасының «Халыкларның үсешкә хокукы декларациясе»ндә һәм башка документларда да демократиянең тантанасы өчен мөһим шарт буларак теркәлгән.

XX гасыр — милли-азатлык хәрәкәтенең киң таралган чоры, бу хәрәкәт үзенең асыл максаты белән империалистик дәүләтләрнең үз хакларын хаклау өчен көрәшүче халыкларны басып тору сәясәтенә каршы юнәлдерелгән. Бу көрәш нәтиҗәсендә Азиядә, Африкада, Латин Америкасында бик күп илләр үзләренең милли азатлыкларына һәм иҗтимагый тормышның бик мөһим бер сферасында — милли мөнәсәбәтләр өлкәсендә демократик принципларның тантанасына ирештеләр.

Милли-азатлык хәрәкәтенең нәтиҗәсе буларак, күп кенә колониаль империяләр җимерелде. 80 елларның азагына бу дулкын Аурупа һәм Азиянең зур киңлекләрен биләгән соңгы империягә дә килеп житте — СССР исеме астында яшәп килгән империя яшәүдән туктады, әмма бу әйтелгән империя инде тәмам юкка чыкты дигән сүз түгел. Хәзер аның җимерекләре өстендә, беркадәр кысылган рамкаларда булса да, Россия Федерациясе исеме астында, демократия пәрдәсе белән каплап империяне яңадан торгызу процессы бара. Бу әйтелгән империя кысаларында азатлыкка омтылучы халыкларга яңа богау салуга омтылыш дигән сүз.

Әмма демократия һәм империя антиподлар. Империя сакланган тәкъдирдә демократик яңарышлар көтү бары буш хыял гына. Хәзерге Россиядә демократияләштерү процессында туган кыенлыклар «демократлар»ның империяне саклап калуга булган омтылышлары белән аңлатыла да. Буйсындырылган халыкларның иреккә булган омтылышларын бастыру котылгысыз рәвештә хаким милләтнең үз азатлыгын югалтуга китерә. Марксистик фикернең күренекле әһелләреннән берсе үз вакытында, башка халыкларны изүче халык үзе дә ирекле була алмый, дип язган иде. Хак фикер. Буйсындырылган халыкларны богауда тотучы халык киләчәктә дә шушы хәлне саклап калу өчен үзенең азатлыгын да чикләргә һәм язмышын нинди дә булса тиран яки авторитар хаким кулына тапшырырга мәҗбүр.

Россиянең аерым сәяси эшлеклеләре үзләрен никадәр демократлар итеп күрсәтергә тырышмасыннар, аларның демократия белән һичнинди уртаклыгы булмаган империячел амбицияләре күзгә ташланып тора. Хәзерге Россия тарихи күренекле бер демократны белә — ул А.Д.Сахаров. Бу олы шәхес үзенең «Аурупа һәм Азия совет республикалары союзы конституциясе» проектында «Милли үзбилгеләнүгә хокук — һәр милләтнең һәм республиканың беренчел һәм нигезле хокукы» дип язып калдырды. Шуның өстенә А.Д.Сахаровның проектында бу хокукны барлык зур һәм кечкенә милләтләргә— Союз һәм автономияле республикалар, автономияле өлкәләр һәм округларга бирү каралган иде. Бу проектта әйтелгән дәүләт берәмлекләренең барысының да хокукый тигезлеге һәм суверенлыгы гарантияләнә дип күрсәтелә. Әмма үзләрен демократик үзгәрешләр тарафдарлары итеп курсәтергә тырышучы ялган демократлар А.Д.Сахаровның бу чыннан да демократик рух белән сугарылган идеяләрен читләтеп уздылар һәм аның дәүләт төзелешенә кагылышлы демократик принципларыннан ваз кичтеләр.

Коммунистик идеологиянең хакимлеге шартларында милли азатлык һәм тигезлек идеяләренә интернационализм каршы куелды һәм алар халыклар дуслыгына хилаф нәрсә дип каһәрләнеп киленде. Хәзер исә Россия «демократлары» милли суверенитет принцибына кеше хокуклары мәсьәләсен каршы куялар һәм халыкларның милли бәйсезлеге һәм суверен үсеше гражданнар иреген һәм шәхес хокукларын чикләүгә китерә дип расларга тырышалар. Икътисад өлкәсендә демократик үзгәрешләр тарафдары, күренекле экономист, профессор Н.Шмелев үзенең «Котылу өмете» дип исемләнгән мәкаләсендә («Известия». 1991 ел, №№ 249, 251—253), мәсәлән, без «милли суверенитет түгел, ә бәлки хәзерге дөньяда мөһим булган бердәнбер суверенитет — кеше суверенитеты турында уйларга тиешбез», дип расларга тырыша. Кеше хокукларын милләтләр хокукына шулай каршы кую аерым бер күрнеш кенә түгел. Шуңа аваздаш расламалар газета-журнал битләрендә дә, фәнни хезмәтләрдә дә еш очрый. Алар шулай ук парламент мөнбәрләреннән дә яңгырыйлар.

1993 елның маенда, мәсәлән, Мәскәүдә, Испания илчелегендә федерализмга кагылышлы мәсьәләләр буенча түгәрәк өстәл артында сөйләшү булды. Очрашуда Мәскәүдән, Екатеринбургтан,

Воронеждан бер төркем галимнәр һәм политологлар катнашты. Россия Федерациясенең ул вакытта Югары Советы каршында төзелгән Конституция комиссиясенең члены, хокук фәннәре белгече Н.В.Бутусова (Воронеж) түгәрәк өстәл утырышларының берсендә бик тырышып, милли хокуклар белән чагыштырганда кеше хокукларының өстенлеге идеясен яклады.

Әмма кеше һәм милләт хокукларын бу рәвештә бер-берсенә каршы кую нигезсез. Мәгълүм булганча, кеше хокуклары, кайбер «демократлар» раслаганча, кешенең материаль ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә генә кайтып калмыйлар, һәр кеше нинди дә булса милләт белән билгеле бер мөнәсәбәттә тора. Ә бу милләтнең үзенең махсус теле, мәдәнияты, традицияләре, гореф-гадәтләре була һәм кеше шәхесен алардан аерып карау мәгънәсез. Демократик җәмгыятьтә кеше үзенең материаль ихтыяҗларын да, рухи ихтыяҗларын да, шул хисаптан теге яки бу милләт вәкиле буларак туган ихтыяҗларын да канәгатьләндерергә хокуклы. Кешедә милли яклар да, шәхси яклар да бердәмдер, аларны бер-берсеннән аерырга ярамый. Әгәр кеше туган телендә сөйләшә алмый, үз милләтенең мәдәнияты җәүһәрләреннән файдалана алмый икән, аның кешелек хокуклары саклануы турында да сүз алып бару мөмкин түгел. Милли азатлык кеше хокукларын реальләштерүнең алшарты булып тора.

Милләтләрнең ирекле үсешкә булган хокуклары белән шәхес хокукларының бердәмлеге һәм аерылгысыз бәйләнеше хәзерге халыкара нормаларның нигез ташын тәшкил итә. Бу, мәсәлән, Берләшкән Милләтләр Оешмасы Генераль ассамблеясенең 1952 елның 16 декабрендә кабул ителгән һәм 637 А (VII) номеры белән теркәлгән резоляциясендә ачык чагыла. «Халыкларның һәм милләтләрнең үзбилгеләнүгә хокукы, — дип күрсәтелә бу резолюциядә, — кеше хокукларын тулысынча реальләштерүнең алшарты булып тора». Кеше хокуклары белән милләтләрнең хокукларының аерылгысыз бердәмлеге идеясе Берләшкән Милләтләр Оешмасының башка документларында да кызыл җеп булып сузылып бара. Конкрет әйткәндә, бу идея «Колониаль илләргә һәм халыкларга бәйсезлек бирү турындагы декларация»дә, «Үсеш хокуклары турындагы декларация»дә, «Гражданлык һәм сәяси хокуклар турындагы пакт»та, «Икътисади, социаль һәм мәдәни хокуклар турындагы декларация»дә үзенең ачык чагылышын тапты. «Үсешкә хокук турындагы декларация»нең 1 маддәсендә,

мәсәлән, «Кеше шәхесенең үсешкә хокукы халыкларның үзбилгеләнүгә булган хокукын тулысынча тормышка ашыруны да күз алдында тота» дип белдерелә.

Күпмилләтле илләрдә дәүләт төзелешенең бер формасы буларак, федерация кулланыла. Федерация субъектларының милли үзенчәлекләре һәм хокуклары сакланган тәкъдирдә бу форма иҗтимагый тормышта демократик тәртипләрне сакларга мөмкинлек бирә. Швецария моның ачык мисал. Россия дә күпмилләтле дәүләт буларак, сүздә генә булса да бу форма белән хисаплашырга мәҗбүр. Ләкин бу илдә чын мәгънәсендәге федерациянең булганы юк. Россия Фәннәр академиясенең мөхбирәгъзасы Сергей Алексеев хаклы рәвештә әйтеп киткәнчә, Россия самодержавиесе хакимияте дә, советлар хакимияте дә «были властью державной, империей, основанной на произволе и насилии» («Известия», 1993, 9 июль).

Дөрес, СССР федератив дәүләт дип игълан ителгән иде. Әмма коммунистик диктатура шартларында унитар тәртипләр сакланды. Россиянең хәзерге идарәче даирәләре дә федерация турында сүз алып барырга мәҗбүрләр. Әмма федератив договорда да, Россия Конституциясендә дә хакыйкый федерализм тормышка ашырылмый, киресенчә, республикаларны үзәк ихтыярына буйсындыру күз алдында тотыла, димәк, идарәдә унитарлык сакланып кала. Бу Россия Конституциясенең буеннан буена кызыл җеп булып сузылып бара.

Теоретик эзләнүләрдә федерализмны алга таба «үстерү» турында да сүз алып барыла, әмма бу эзләнүләр милли мәсьәләне чишүдән ерак торалар. Бу җәһәттән, юридик фәннәр кандидаты Г.Никеровның «Известия»нең 1991 елгы, 7 декабрь санында басылган һәм «Федерация халыклар өчен түгел, бәлки кешеләр өчен» дип исемләнгән мәкаләсе характерлы. Мәкаләнең исеменнән үк күренгәнчә, аның авторы федерация идеясен кеше хокукларына каршы куя. Кеше хокукларын болай итеп милләт хокукларына каршы куюның нигезсезлеге турында инде күрсәтелде. Күпмилләтле дәүләтләрдә исә федерация нәкъ менә аларның хокукларын реальләштерүгә хезмәт итә. Әмма бу — мәкалә авторына чит нәрсә. Ул, киресенчә, федерация идеясен милли мәсьәләне хәл итүдән бер якка алып китәргә тырыша; федерациянең субъектлары милли республикалар түгел, ә бәлки идарәләр, территорияләр, ягъни губерналар булырга тиеш дип белдерә.

Бу очракта Г.Никеров, башка күп кенә урыс авторлары кебек, Америка Кушма Штатларын күз алдында тотып фикер йөртә. Анда чыннан да Федерациянең субъектлары булып милли төсләре булмаган территориаль берәмлекләр — штатлар тора. Америка штатларында бу форма чыннан да гражданнарның бер өлешенә демократик хокуклардан файдаланырга мөмкинлек бирә. Әмма Америка Кушма Штатлары — башка кыйтгалардан килгән эмигрантлар иле. Ә Россиядә яшәүче халыклар исә килмешәкләр түгел. Алар үзләренең тарихи ватаннарында яшиләр. Биредә алар халык, милләт булып формалаштылар, биредә аларның мәдәниятләре туды һәм аларның табигый теләге — шушы туган җирдә үзләренең язмышларына үзләре хуҗа булып яшәү. Шуңа күрә федерациянең Америка үрнәге алар өчен кулай түгел. Әйтергә кирәк, ул американлылар өчен дә тулы канлы демократиядән ерак тора. Чөнки Америка демократиясеннән континентның җирле халкы — индеецлар бер читтә кала бирә.

Күп очракта федерация төшенчәсе халыкларның аңын буташтыру, аларның уй-фикерләрен чын федерализмнан бер якка юнәлдерү максатында файдаланыла. Россия тарихында ул гомумән шулай була килде һәм хәзер дә шулай булып кала бирә. Федерация дип сүз куертыла, ә эштә Мәскәү сәясәтчеләре бөтен көчләрен реаль федерализмны юкка чыгару өчен тырышалар. Бу тенденция Татарстанда «народовластие» һәм «согласие» исеме астында чыгучы «демократлар»ның эш-гамәлләрендә дә ачык чагыла. Соңгы вакытта алар үзләрен хәтта федералистлар дип тә атый башладылар. Әмма бөтен максатлары — Татарстанны Россия империясе составында саклап калу. Грачевлар, Штаниннар ничек кенә үзләрен федералистлар дип күрсәтергә тырышмасыннар, аларның төп максаты — бердәм һәм бүленмәс Россия, ягъни империя. Реаль федерация бары мастәкыйль республикаларның ирекле берләшүе нәтиҗәсендә генә барлыкка килә ала. Ә Россиядә федератив шартнамә милли республикаларга өстән, демократиядән ерак торган басым ясау юлы белән тагыла һәм монда ирекле берләшүнең эзе дә юк. Аннан чын федерация барлыкка килсен өчен рус республикасы да булырга һәм ул башка республикалар белән тигез нигездә берләшергә тиеш. Әмма андый республиканың булганы юк. «Демократлар» тарафыннан бердәмлеген һәм бүленмәслеген сакларга тырышылган Россия бар. Аның провинцияләре бар һәм алар республикалар, өлкәләр, крайлар дип аталалар. Бу — империягә хас күренеш.

Теге яки бу халыкның иркле рәвештә үсешен тәэмин итәрдәй форма — ул да булса милли суверенитет; ул халыкның үз дәүләтен оештыруга, нинди дә булса тышкы сәясәтен билгеләүгә һәм үткәрүгә юл ача. Шунлыктан да кеше һәм халык хокукларының мөнәсәбәте турындагы бәхәсләр еш кына милли суверенитет мәсьәләсенә кайтарылып калдырылалар. Россия «демократлары»ның кеше хокуклары турындагы бәхәсне бу илдәге халыкларның милли суверенитетка ирешү өчен көрәшкә күтәрелгәч куертулары очраклы хәл түгел. Әммә ялган демократларның бу мәсьәлә тирәсендәге шау-шулары кеше хокуклары турында борчылулардан тумады. Бу шау-шулар бары империяне тәмам җимерелүдән коткарып калуга булган омтылышның чагылышы. Әмма империяне саклап калу беркемгә дә, шул хисаптан урыс халкының үзенә дә ирек китермәячәк. Империягә хас тенденция — бар халыкларны да, шул хисаптан хакимлек итүче милләтнең үзен дә бер калыпка салып тигезләү, бар халыкларны да үзенең ихтыярына буйсындырып, карусыз колларга әйләндерү. Димәк, империяне саклау — ул демократик институтлардан һәм ирекләрдән баш тарту дигән сүз.

Россия «демократлары» зур пафос белән Россиянең суверенитетын игълан иттеләр һәм моны дөнья җәмәгатьчелеге алдында гаделлек тантанасы итеп күрсәтергә тырыштылар. Рус халкы, әлбәттә, үзенең суверенитетын яклауга хокуклы. Әмма «демократлар» нигәдер суверенитетка урыс халкының гына хокукын таныйлар, үз республикаларының суверенитетын игълан иткән башка халыкларның мондый хокукын күрмәмешкә салышалар. 1993 елның 2 мартында референдумда Татарстан халкының зур күпчелеге республиканың суверенитетын яклап тавыш бирде. Кайбер рус «демократ»лары моның белән һич тә килешергә теләмиләр, һәм референдум йомгакларын азчылыкта калган рус телләләрнең хокукларын кысу дип күрсәтергә маташалар. Ю.Феофанов үзенең «Татарстандагы референдумга карата өченче караш» дигән мәкаләсендә («Известия». 1992, 28 март), мәсәлән, Татарстан халкының күпчелегенең референдум вакытында ачык итеп белдерелгән ихтыярын мәсьәләне демократик булмаган юл белән хәл итү дип расларга маташа. Чөнки бу очракта, аның фикеренчә, референдумда каршы тавыш биргән азчылыкның фикере искә алынмый. Гаҗәеп хәл туа: Россиянең суверенитеты мәсьәләсе парламенттагы күпче-

лек депутатларның тавышы белән хәл ителде һәм урыс «демократлары» фикеренчә, бу демократик юл. Әмма Татарстан халкының күпчелек тавыш белән суверенитетны яклавы демократиядән тайпылу булып чыга, имеш бу очракта рус телле азчылыкның фикере санга сугылмый. Әмма сорау туа: Россия суверенитеты мәсьәләсен хәл иткәндә милли республикалар, өлкәләр һәм округлар халыкларының фикерен белергә тырышу булдымы икән? Юк. Шулай урыс халкына бер, башка халыкларга икенче үлчәм тагыла.

Һәм, ниһаять, Ю.Феофанов мәсьәләнең асылын да бозып күрсәтә. Татарстанның суверенитетын игълан итү дә, референдум да республикада яшәүче халыкларның хокукларын чикләми. Киресенчә, Татарстанның суверенитеты турындагы декларациядә дә, республиканың суверенитеты игълан ителгәч чыгарылган башка дәүләт актларында да, милләте нинди булуга карамастан, бөтен гражданнарның тигезлеге, аларның милли мәдәниятларын үстерүгә тулы хокуклыгы раслана, ә төп ике халыкның телләре — татар теле һәм урыс теле тигез нигездә дәүләт теле дип игълан ителә.

Татарстанның суверенитетына каршы чыкканда урыс «демократлары» аны Россия территориясе эчендә утыра, шуңа күрә суверенитет турында сүз дә булырга мөмкин түгел, дип расларга тырышалар. Әмма аерым суверен дәүләтләрнең башка дәүләтләр белән чолганган хәлдә яшәве бу аргументның урынсыз булуын күрсәтә. Расачыл Көньяк Африка республикасы эчендә, мәсәлән, суверен Лесото дәүләте тыныч кына яши бирә. Европада исә ике ил — Швецария һәм Австрия дәүләтләре белән чолганган хәлдә Лихтенштейн шулай ук тыныч кына яшәп ята. Азиядә Непал корольлеге шундый ук хәлдә яши — ул Кытай һәм Индия чикләре белән кысылган. Татарстанга килгәндә исә, ул үзенең тарихи территориясендә урнашкан һәм урыс «демократлары» әйткәнчә Россия җирендә түгел. Аннан Татарстан бер Россия белән генә чиктәш түгел, аның чикләрендә Россиядән тыш суверен Башкортстан, Чувашстан, Мари-Эл, Удмуртия республикалары урнашкан.

Татарстанның фактта суверенлыкка ирешүенең мөһим шарты — чиктәш республикаларда, беренче чиратта Россиянең үзендә демократик көчләрнең җиңүе. Хәзерге Россия, мәгълүм булганча, хокукый дәүләт төзүгә һәм демократик тәртипләр урнаштыруга йөз тота. Россиядә бу юнәлеш җиңеп чыкса, демократик

Татарстан Россия белән демократик хокукый институтлар нигезендә дәүләтара мөнәсәбәтләр урнаштырып үзенең фактик суверенитетына ирешә алачак. Әмма Россиядә дәүләтне хокукый нигездә коруга һәм демократик тәртипләр урнаштыруга көрәш бик авырлык белән бара. Бу үсешнең тоткарлануы, Россиянең эчке үсеше авторитар режим урнашуга һәм хакимияткә ачыктан-ачык шовинистик көчләрнең килүенә китерергә мөмкин. Бу очракта чынында Татарстанның тулы суверенитетына ирешүе зур кыенлыкларга очраячак.

«Демократлар»ның суверенитетка каршы сүз алып барганда тагы бер аргументы — алар хәзерге дөньяда интеграция процесслары күзәтелә, мөстәкыйль дәүләтләр бер-берсенә якынаю юлларын эзлиләр, аларны моңа экономик зарурлык этәрә, ә сез инде яши торган бердәмлекне какшатасыз, дип расларга тырышалар. Хәзерге заманда чыннан да интеграция күренешләре, дәүләтләрнең экономиканы үстерү өчен бер-берсенә якынаюы күзәтелә. Көнбатыш Европа моның ачык мисалы. Көньяк-Көнчыгыш Азия һәм башка регионнарда да бу тенденция нык тамыр җәйде. Әмма бу процесска инде үз мөстәкыйльлекләрен яулаган илләр — халыклар тартылалар һәм алар моңа кемнең дә булса көчләве белән түгел, ә ирекле рәвештә баралар. Хәзерге дөньяда илләр — халыклар бер-берсеннән тулы бәйсез була алмыйлар. Алар бер-берсе белән экономик һәм мәдәни бәйләнешләргә керергә, экономик һәм рухи үсеш өчен көчләрен берләштерергә мәҗбүрләр. Моңа кадәр коммунистик идарәче даирәләрнең басымы астында берләштерелгән республикалар да, әлбәттә, бер-берсеннән бөтенләй аерылышып яши алмаячаклар. Алар да экономик һәм рухи прогресс хакына берләшергә мәҗбүр булачаклар. Әмма аларга үзләренең ихтыяры белән берләшү өчен башта иреккә ирешергә һәм үз ихтыярларын ирекле рәвештә белдерү мөмкинлеген яулап алырга кирәк.

Халыкларның аңыннан милли идеяне куып чыгару, милли телләр һәм мәдәниятларны кысрыклау, соңгы чиктә халыкларны хаким милләт рамкаларында эретеп бетерү максатында коммунистик идарәчеләр төрле юллар белән кешеләрнең аңына интернационализм идеясе сеңдерергә тырыштылар. Хәзерге шартларда шушы ук максатларда Россия «демократлары» кеше хокуклары мәсьәләсен җикмәкчеләр. Әмма алар, элекке коммунистик идарәчеләр кебек үк, кеше хокукларын милләт хокукларына каршы кую юлы белән кеше хокукларын милли

җирлектән аерырга, урыс булмаган милләт вәкилләренең аңын томалауга һәм коралсызландырырга һәм соңгы чиктә шул ук яманаты чыккан интернационализм казанында эретеп бөекдержавачыл идеягә буйсындырырга тырышалар.

Табигый үсеш дәвамында барлыкка килгән биологик төрләр кебек үк тарихи үсеш процессында формалашкан социаль организмнар да (ә милләт шундый организмнарның берсе) яшәүгә хокуклы. Тарихи шартлар татар халкының бу хокукын бик нык чикләүгә китерделәр һәм аның киләчәген куркыныч астына куйдылар. Милләт, теле һәм мәдәнияты үскәндә генә, яши ала. Россия империясе, ә соңыннан коммунистик диктатура шартларында татар халкының милли теле һәм мәдәнияты нормаль эшләү һәм үсү мөмкинлегеннән мәхрүм ителделәр. Аларның куллану сферасы тарайды. Татар мәктәпләрен тормыштан куып чыгару киң колач белән алып барылды. Калган татар мәктәпләре дә үзләренең миллилеген югалттылар. Хәзер 1 миллион 130 мең татар кешесе үзенең туган телен белми. 1988 елгы мәгълүматларга караганда, 40,9 процент татар егетләре һәм 42,2 процент татар кызлары башка милләт кешеләре белән никахка керә. Мондый гаиләләрдә үскән балалар, кагыйдә буларак, татар телен һәм мәдәниятын белмиләр, ә алардан туган балалар исә татар милләте белән араны бөтенләй өзәләр. Бу процессның киләчәктә дә дәвам итүе милләтнең инкыйразына — бөтенләй юкка чыгуына илтәчәк. Шуңа күрә халкыбызның мондый перспективаны күрә алган уллары һәм кызлары милләтнең киләчәге турында уйларга чакырып чаң сугалар.

Биологик төрләр кебек үк, социаль-тарихи берлек булган милләтләр дә үзләренең киләчәге өчен актив көрәш алып барырга хаклылар. Татар халкының да үзенең тарихтагы урыны өчен актив көрәш алып барырга тулы хакы бар. Язучы Ркаил Зәйдулла үзенең «Ил» дигән мәкаләсендә («Шәһри Казан», 1992, 3 сентябрь) «Татарстанның азат дәүләт булу-булмавы турыдантуры Рәсәйгә, анда нинди көчләрнең җиңеп чыгуына бәйле» дип яза. Бу, әлбәттә, шулай. Әмма безнең киләчәгебез, безнең азатлыгыбыз соңгы чиктә үзебезгә бәйле, азатлыгыбыз, Татарстанның суверенлыгы өчен көрәшне ничек алып баруыбызга бәйле. Россиянең хаким даирәләреннән рәхим-шәфкать һәм мәрхәмәт көтү, анда нинди көчләр өстенлек итсәләр дә, безгә берни дә бирәчәк түгел. Азатлык көрәштә яулана.

1992 ел.

МИЛЛИ БИТАРАФЛЫК КАЯН КИЛӘ?

Милли хәрәкәткә кагылышлы бәхәсләрдә аны йомшаклыкта гаепләүләр, киң халык массалары аңа тартылмый дигән раслаулар белән очрашырга туры килә. Әмма моның белән бөтенләй үк килешеп булмый. Соңгы елларда җөмһүриятебез үзенең суверенитетын игълан итте, шушы елның 21 мартындагы референдумда халкыбызның зур күпчелеге суверенитетны яклап тавыш бирде һәм, ниһаять, Югары Советта Конституция кабул ителде. Болар барысы да милли күтәрелеш җимешләре. Милли мөстәкыйльлек хакына халык күтәрелмәгән булса, моңа ирешү мөмкин булмас иде. Бу күтәрелешнең гүзәл сәхифәләре буларак, 1990 һәм 1991 елларның җәй айларында күп меңләгән халык катнашында үткәрелгән сәяси акцияләрне һәм Татарстанда РСФСР президентын сайлауның өзелүен күрсәтү җитә. Референдумда Татарстанның мөстәкыйльлеген яклап бердәм тавыш бирү дә халык аңына милли мөстәкыйльлек идеясенең ныклап үтүе турында сөйли.

Шул ук вакытта милли-азатлык хәрәкәтенең эзлекле адымнар белән бармавын да күрсәтеп үтәргә туры килә. Ул әлегә дулкын-дулкын рәвешендәрәк бара, бер күтәрелә, бер төшә. Теге яки бу рубеж яулангач, милли хәрәкәттә сүлпәнләнү, аның массовый базасы тараю күренешләре күзгә ташлана. Җөмһүриятнең суверенитеты игълан ителде, референдумда җиңдек һәм бу күбәүләр тарафыннан мөстәкыйльлеккә тәмам ирешү рәвешендәрәк аңланды һәм тынычлану башланды. Суверенитет турындагы декларацияне кабул итү мөһим сәяси акт иде, шулай да ул реаль мөстәкыйльлек яулау дигән сүз түгел. Аның әлегә халыкара договорларда беркетелгәне юк һәм чит мәмләкәтләрнең безнең мөстәкыйльлегебезне официаль рәвештә танулары дип бәяләрлек актлары да күренми. Хәзер Россия белән бу турыда сөйләшүләр бара, әмма күзгә ташланырлык нәтиҗәләр шулай ук юк.

Бу сөйләшүләрдә бер урында таптану, әлбәттә, Россиянең идарәче даирәләренең Татарстанны империя тырнакларыннан ычкындырырга, аның экономик потенциалын һәм безнең үзебезне дә кулларыннан җибәрергә теләмәве белән аңлатыла. Әмма сөйләшүләрнең сүлпән баруының һәм бер урында таптануының сәбәпләрен безнең үзебездән дә эзләргә кирәк. Боларның күзгә иң ташланганы — җөмһүриятебезнең хакимият даирәләре сәя-

сәтендә һәм милли азатлык хәрәкәтендә инде алда әйтеп үтелгән эзлеклелек һәм дәвамчылыкның житенкерәмәве, теге яки бу уңышка ирешкәннән соң тынычланып калу, декларацияләрне чынбарлык итеп кабул итү, милли-азатлык өчен көрәш алып баручылар сафларының сыеклыгы, бу көрәшкә әле халыкның киң катламнары тартылмаганлыгы. Көрәшкә әлегә халыкның бер өлеше, аның авангарды тартылган, ә киңрәк катламнар бер читтәрәк тора. 1992 елның 28 августында Г.Камал исемендәге театр каршындагы мәйданда милли оешмалар чакыруы белән җыелган һәм Татарстанның суверенитеты игълан ителүгә 2 ел тулуга багышланган митинг бара. Кайнар нотыклар сөйләнә, мөһим резолюцияләр кабул ителә. Әмма митингта катнашучыларның саны 7—8 йөздән артык түгел. Митинг башланыр алдыннан урамда бер танышымны очраттым. Ашыга, поездга соңга калам, бакчага барам, ди. Менә шулай. Милләт кайгысын кайгырткан бер төркем митингка җыелган, суверенитетны тормышка ашыру юлларын эзли, ә күбәүләр үзләренең бакчаларына китүне мәгъкульрәк күрәләр. Тагы шундый митингларның берсендә милли хәрәкәттә актив эш алып баручы ханым авылларда йөреп кайткач, аның көрәшкә чакырып ясаган чыгышларына тыңлаучыларның, бәрәңгебез, ипиебез бар, балаларыбыз имин, башыбызны катырып йөрмәгез әле, дип җавап бирүләре турында ачынып сөйләде. Халыкның зур катламы әле көрәштән читтәрәк тора, битарафлык саклый дисәк хата булмас. Ирексездән, кайдан килгән соң мондый чир безнең халыкка, дигән сорау туа, милли битарафлыкның тамырлары кайда ята?

Әйтергә кирәк, милли битарафлыкның сәбәпләре ерак тарихтан килә. Әмма, кайберәүләр уйлаганча, бу сәбәпләрнең нигезе халкыбызның милли үзенчәлегендә, аның характерында түгел. Халкыбызның асыл сыйфаты аның 1552 елда үзенең азатлыгы һәм мөстәкыйльлеге өчен аяусыз көрәшендә ачык чагылды. Бу көрәштә кан елга булып акты, күп фидаи җаннар дөньядан китте. Иван мәдһиш Казанны алгач та әле милли бәйсезлек өчен көрәш озак еллар дәвам итте. Әмма көчләр тигез түгел иде. Дошман өстенлек алды, исәннәр буйсындырылды һәм коточкыч милли изүгә дучар ителде. Милли битарафлыкның тамыры күп гасырларга сузылган шушы милли изү белән бәйләнгән дә.

Бу изү аяусыз булды һәм халык тормышының социаль-икътисади якларын да, сәяси-хокукый якларын да колачлады. Моңа милли гореф-гадәтләрне, традицияләрне, телне һәм әдәбият-

ны кысу, халыкның йолаларын рәнҗетү, көчләп чукындыру, дини һәм милли мыскыллаулар өстәлде. Татар халкы патша хөкүмәтенең бу сәясәтенә, әлбәттә, буйсынучанлык күрсәтмәде, дүрт йөз ел буена милли үзенчәлекләрен, традицияләрен, телен һәм мәдәниятын саклап калу өчен көрәште. Әмма озак гасырларга сузылган изү, рәнҗетү һәм мыскыллаулар эзсез дә калмады; алар акрынлап халыкның рухи көчен йомшарттылар, сизелмәстәй дигәндәй халыкка ярашучанлык хисе сеңдерелде, коллык психологиясе барлыкка килде. Аерым катламнарда куркаклык тенденцияләре җәелде. Актив эш алып бару урынына өстән әмер көтү тамыр җибәрде. Менә шушылар милли битарафлыкның барлыкка килүенә һәм үсүенә җирлек булдылар да.

Патша самодержавиесе дә, большевистик хакимият тә халкыбызны рухи тамырларыннан аеру өчен бөтенесен эшләделәр. Бу юнәлештә идеологик басым патша заманында ук коточкыч була килде, ә коммунистик диктатура шартларында исә ул тагы да үстерелде һәм көчәйтелде. Шулай да патша Россиясе шартларында татар халкы бик авырлык белән булса да билгеле бер күләмдә үзенең милли үзенчәлекләрен саклый алды һәм бу очракта хәлиткеч рольне ислам дине һәм милли мәктәбебез уйнады. Татарлар арасында борын-борыннан мәгърифәткә омтылыш көчле була. Әле Болгар чорында ук авыл һәм шәһәрләрдә мәктәп-мәдрәсәләр яши, аларда балалар дөньяви гыйлемнәр дә алалар, ислам кануннарын да үзләштерәләр. Мәктәп бусагасын атлап керүгә, балалар хәреф танырга, укырга-язарга, хисапларга өйрәнәләр. Бер үк вакытта алар ислам динен дә, аның асылында булган әхлак нормаларын да үзләштерәләр.

Бу традиция безнең халыкта Алтын Урда чорында да, Казан ханлыгында да, рус хакимияте астына төшеп гаять зур милли кысу шартларында да дәвам итә. Татарлар арасындагы гыйлемгә хиреслекне узган гасырларда яшәгән урыс галимнәре дә күрсәтеп үтә. Ә православие миссионерлары исә татарларны христианлаштыруның барып чыкмавын аларның грамоталары югары булу белән аңлаталар да. «Сильно же магометанство, — дип язды К. имзасы белән берәү миссионерлар журналында, — прежде всего очень распространенной в магометанском населении грамотностью. Казанские татары-магометаны, почти все за редкими исключениями, грамотны и очень ценят

образование и заботятся о нем» («Православный благовестник», М., 1893, №19). Алга таба автор, шуның аркасында татарлар христианлаштыруга бирелмиләр, дип күрсәтеп үтә.

Патша хөкүмәте, бөтен тырышлыгына карамастан, татар халкын үзенең рухи таянычы булган диненнән һәм милли мәктәбеннән аера алмады һәм бу аңа милләт буларак үзен саклау мөмкинлеген бирде. Большевиклар эш башына килүгә патша хөкүмәтенең бу «ялгышын» төзәтү һәм татар халкын рухи тамырларыннан аеру эшенә керештеләр. Беренче чиратта алар аяусыз рәвештә ислам диненең тамырына балта чаптылар, дин әһелләрен юкка чыгардылар, мәчетләрне җимерделәр, атеистик пропаганда җәелдерделәр. Бер үк вакытта милли тамырлардан аеру эше дә барды, анда милли рух бетерелде һәм бөтен уку-укыту процессы интернациональ һәм атеистик тәрбия бирү максатларына буйсындырылды.

Ике мәртәбә әлифба алыштыру, милли рухыбызга һәм телебезнең авазлар системасына ят булган кириллица тагылу исә халкыбызны мең елдан артык тарихы булган язма мирасыбыздан аеруга китерде. 20—30 елларда моңа тагы милли рух белән сугарылган зыялыларыбызның юкка чыгарылуы өстәлде. Ә зыялылар, билгеле булганча, халыкның рухи җитәкчесе вазыйфасын үтиләр. Әйтелгәннәр җәмгысы халкыбызны үзенең рухи тамырларыннан аеруда, аны рухи коралсызландыруда һәм ахыр чиктә аның аңына битарафлык чире индерүдә үзләренең рольләрен уйнадылар.

Тагы бер нәрсә — халыкны тарихыннан аеру. Безнең бабайларда борын-борыннан ныклы тарихи аң булган. Алар үзләренең кем, нинди халык булуларын, нәсел-нәсәпләрен белеп яшәгәннәр. XVIII йөздә сәяхәтче галим Г.Георги, мәсәлән, татарларның үзләренең тарихи үткәненә зур кызыксыну белән караулары турында яза. XIX йөздә бу фикерне урыс укымышлысы П.И.Пашино кабатлый. Үзенең «Волжские татары» дигән хезмәтендә ул, әгәр татар белән сөйләшә башласаң сине тарихтан төрле сораулар белән күмә, дип язып калдырган. Татар халкының үзенең тарихына битараф булмаганлыгын аерым гаиләләрдә гасырлар буена язып барылган күпсанлы шәҗәрәләр һәм тарихи вакыйгалар турында шәхси китаплар читенә теркәлгән язмалар да ачык күрсәтә. Болар татарлар арасында заманында тарихи анның зур үскән булуы турында сөйлиләр. Ә тарихи аң исә — ул милли аңның состав өлеше, милләтнең үзен саклауда зур таянычы. Үзенең тарихын белмәгән милләтнең киләчәге дә юк.

Шуңа күрә дә Россия империясенең идеологик аппараты татарларның тарихи аңын сындыруга һәм тарихларын бозып күрсәтүгә бөтен көчләрен куйдылар. Хакимияткә коммунистлар килгәч бу сәясәт моңа кадәр күрелмәгән киң колач алды, татар халкының тарихы бинимаяә фальсификацияләнде, бозып күрсәтелде, аңа пычрак атылды. Бу фальсификацияләр һәм бозык аңлатмалар мәктәп дәреслекләрендә нык урын алдылар, «фәнни» китапларга үтеп керделәр, вакытлы матбугатта, радио, телевидение тапшыруларында яңгырадылар. Нәтиҗәдә, совет власте елларында үскән буын тарихны кәкре көзге аша гына күрә алды, хакыйкый тарих исә бөтенләй томан белән капланып калды. Бу, үз чиратында, татар халкында тарихи аңның йомшаруына китерде, халыкның үткәне белән кызыксынуының тамырына балта чапты, Элек-электән татарлар арасында һәр кеше ичмаса җиденче буынга кадәр үзенең бабаларын белергә тиеш була. Хәзер исә мондый затларны очратуы бик кыен. Соңгы елларда, без татармы яки болгармы, дип барган бәхәс тә шушы тарихи җепләрнең өзелүе, халыкның аңында этник дәвамлылык идеясенең өзелүе нәтиҗәсе. Тарихи аңның бозылуы исә шулай ук милли битарафлык җәелүгә җирлек булып тора.

Бу хәлдә халкыбызда милли аңның торгызылуы никадәр зур әһәмияткә ия булганлыгы көн кебек ачык булса кирәк. Милли аң уянса һәм колач җәйсә, милли битарафлыкка да урын калмаячак. Милли аң исә аерылгысыз рәвештә милләт идеясе, үз милләтеңнең тамырларын, аның үткәнен һәм бүгенгесен, телен һәм мәдәниятын белү, аның киләчәген кайгырту белән бәйләнгән. Күп дистә еллар буена бездә милләт турында кайгыртуга милләтчелек дигән кара мөһер сугылып килендe. Еш кына хәзер дә шулай булып кала бирә. Бу аерым җитәкчеләрнең чыгышларында да, публицистик язмаларда да күзәтелә. Үземнең «Милли мәҗлес: үткәне һәм киләчәге» («Шәһри Казан». 1992, 1 февраль) һәм «Национализм и демократическое движение» («Суверенитет». 1992, №6) дигән мәкаләләремдә мин мондый тәңгәлләштерүнең урынсыз булуы турында язган идем. Шовинизмнан аермалы буларак, милләтчелектә бер милләтне икенчесенә каршы кую яки аның өстенлеген яклауның эзе дә юк. Милләтчелекнең асыл мәгънәсе бары үз милләтеңнең язмышы, аның бүгенгесе һәм киләчәге, теле һәм мәдәнияты турында кайгырту. Халыкта сәламәт

милли аң формалашсын өчен милләтчелек төшенчәсен аңа тагылган кара уйдырмалардан арындырырга, үз милләтеңне ярату хисе, аның бүгенгесе һәм киләчәге турында кайгырту хисе, миллипәрвәрлек тәрбияләргә кирәк.

Халыкның аңын милли проблемаларга бору һәм милли хис тәрбияләү өчен бөтен мөмкинлекләрдән файдалану мәслихәт булса кирәк. Бу бөек эштән газета-журналлар да, радио-телевидение дә бер читтә торырга тиеш түгелләр. Милли хәрәкәтләрдә халык белән эш иткәндә бертөрлелектән арына алсалар яхшы булыр иде. Хәзер моңа кадәр кулланылган чаралар — митинглар аз нәтиҗә бирә башлады. Эшнең яңа формаларын һәм халык күңелен җәлеп итәрдәй яңа шигарьләр табарга кирәк.

Милли аң тәрбияләүгә, милләт идеясен пропагандалауга юнәлдерелгән эш халыкның бөтен катламнарына үтеп керергә тиеш. Соңгы вакытта манкортлык турында ачы сүзләр әйтелде. Мондый сүзләр минем үземнең язмаларымда да очрый. Әмма бу мәсьәләдә безгә аек эш итәргә кирәктер. Совет власте елларында хакимлек иткән идеологиянең ачы җимеше — милләттән аерылган, аның хакыйкый тарихын, телен, мәдәниятын, гореф-гадәтен белми һәм белергә дә теләми торган катлам барлыкка килде. Шушы катламны без манкортлар дибез. Бу аяныч күренеш. Ә иң аянычы шунда, аларның бер өлеше милләтне белми генә түгел, миллилеккә, милләт кайгысын кайгыртып йөрүчеләргә каршы актив көрәш алып бара. Шул ук вакытта манкортлык чире аларның гаебе дә түгел, ә бәлки бәласе, дистәләгән еллар буена алып барылган сәясәт нәтиҗәсе. Бу төркем — халкыбызның бер өлеше һәм аларны халкыбыздан этәрмәскә, киресенчә милләткә, аның теленә, мәдәниятына якынайту өчен түземле һәм эзлекле эш алып бару турында уйларга иде. Аларга милли аң сеңдерү һәм милли гореф-гадәтләр даирәсенә тартуның милләтнең киләчәген күз алдында тотканда никадәр әһәмияткә ия икәнлеге ачык булса кирәк. Манкортлашуның сәбәпләре төрлечә. Манкортлык та төрле дәрәҗәдә. Шуңа күрә эш бу төркемнең төрле катламнарында һәркайсының үзенчәлекләрен искә алып барылса максатка яраклы булыр иде.

Милли тәрбиянең хәлиткеч тармагы — мәктәп. Шуңа күрә мәктәп мәсьәләсе борын-борыннан халкыбызның игътибары үзәгендә булып килде. Узган гасыр азакларында һәм бу

гасырның башында бездә җәдитчелек белән кадимчелек арасында көрәш җәелде һәм бу көрәшнең үзәгендә мәктәп, анда милли тәрбиянең рәвеше мәсьәләсе, яшь буынны ничек итеп тәрбияләү мәсьәләсе торды. Чөнки бу халкыбызның киләчәге белән бәйләнгән иде. Хәзер дә, әгәр киләчәктә дә милләт булып яшәргә теләсәк, мәктәпне милли максатларга буйсындырырга кирәк. Милли мәктәп булырга, анда тәрбия милли рухта, милли традицияләр нигезендә алып барылырга тиеш. Шунда гына ул милләтнең киләчәгенә хезмәт итә алачак.

Хәзер татар мәктәбен милли нигездә кору турында күп сөйләнелә, әмма укыту-тәрбия эшләрен берничә дистә еллар дәвамында канга сеңгән «интернационализм» идеологиясеннән арындыру акрын бара. Татар балаларының күпчелеге, бигрәк тә шәһәрләрдә, урыс мәктәпләрендә укуларын дәвам итәләр. Урыс мәктәпләрендә татар класслары ачу яки татар теле укыту гына милли тәрбия проблемасын хәл итми. Анда укучы балалар урыс мохитендә кала бирәләр һәм бу мохит аларга үзенең идеологик төшенчәләрен тага. Татар балалары баштан ахырынача — балалар бакчасыннан алып югары мәктәпкәчә милли педагогика нигезендә милли уку йортларында тәрбияләнгән очракта гына үсеп килүче буынны милли рухта тәрбияләү, аңа милли аң иңдерү турында сүз алып барып булачак.

Хәзер без исламга йөз белән борыла башладык. Бу милли асылыбызга кайту юлында мөһим алым. Гасырлар буенча ислам, мөселманлык милли аңыбызның мөһим өлеше булган икән, без бу юлны ахырына кадәр үтәргә, тормышыбызга соңгы елларда үтеп кергән һәм ислам өчен чит булган эчкечелек, әхлакый тотнаксызлык, милләт хакын белмәү кебек яман чирләрдән аерылырга тиешбез. Ныклы милли аң тәрбияләү турында сүз алып барабыз икән, яшь буынга ислам тарихы һәм мәдәнияты, ислам йолалары һәм әхлакый кануннары, татар халкының тарихында һәм мәдәниятында исламның тоткан урыны мәсьәләсен эченә алган белем нигезләрен бирү турында да уйланырга вакыт.

Халкыбыз империячел структуралар һәм тоталитар режим таккан идеологик баткаклыктан бик авырлык белән арына. Зыялыларыбызның изге бурычы — аңа бу чистарыну процессында ярдәм итү, халыкны уяту, аны милли проблемаларга бору. Бу мөстәкыйльлеккә ирешүнең хәлиткеч чарасы.

1992 ел.

ӘСӘРДӘ МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ
(Р.Мөхәммәдиевнең «Сират күпере»н укыгач)

Татарстан китап нәшрияты Р.Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» исемле романын бастырып чыгарды. Моны татар әдәбияты барышында һәм иҗтимагый тормышыбызда мөһим вакыйгалардан булды, дип санарга тулы нигез бар. Китапта тарихыбызның катлаулы этабы, иҗтимагый көчләр бәрелеше, халкыбыз язмышына караган мөһим вакыйгалар, сүз бара торган чорда җәмгыять тормышында актив катнашкан шәхесләрнең эш-гамәлләре, аларның кичерешләре һәм уй-фикерләре сурәтләнә. Әсәрнең үзәгендә халкыбызның каһарман улы, күренекле җәмәгать эшлеклесе, милли азатлыгыбыз өчен көрәшкә, шулай ук дөньякүләм милли-азатлык хәрәкәтенә, аның теоретик нигезләрен дәлилләүгә зур өлеш керткән Мирсәет Солтангалиев образы. Сәнгати чаралар ярдәмендә автор бу асыл затның тормыш юлын, күпкырлы эшчәнлеген, эчке кичерешләрен һәм фаҗигале язмышын бөтен тулылыгы белән ачып сала. Китап битләрендә М.Солтангалиев күз алдына кеше буларак та, көрәшче буларак та титаник шәхес рәвешендә килеп баса. Шул ук вакытта көрәштәшләре, туганнары да бик тулы канлы итеп гәүдәләндереләләр.

Романда М.Солтангалиев эшчәнлеге белән бәйле рәвештә бик күп тарихи шәхесләр турында сүз алып барыла. Алар арасында татар халкының күренекле уллары Муса Бигиев, Гаяз Исхакый, Йосыф Акчура, Фатих Кәрими, Галимҗан Ибраһимов һәм милли-азатлык хәрәкәтенә зур өлеш керткән Мулланур Вахитов, Ильяс Алкин, Ибраһим Әхтәмев, Әхмәтзәки Вәлиди, Турар Рыскулов, Исмәгыйль Фирдәвес, Дерен-Айырлы, Муллаян Халиков һәм башкаларның онытылмас образлары. М.Солтангаливнен тормышында аяныч роль уйнаган Ягода, Куйбышев, Сәхибгәрәй Сәетгалиев кебек шәхесләргә дә язучы объектив бәя бирә алган, аларның пычрак эш-гамәлләрен бик төгәл бәяләгән. Китапта М.Солтангалиевка Сталинның дәһшәтле образы каршы куелган һәм аңа хас кансызлык, мәкер, икейөзлелек кебек сыйфатлар бөтен тулылыгы белән ачып салынган. Троцкий, Каменев, Зиновьев һәм Бухаринның шәхси йөзен М.Солтангалиев белән янәшә куеп тасвирлауда бу фидаи затның бөеклеген бөтен тулылыгы белән ачып салуда үзенең өлешен керткән.

Роман беренчел чыганакларга—хәзергә кадәр КГБ архивларында җиде кат бик артында сакланган үтә яшерен докумен-

тларга таянып язылган. Бу исә автор сурәтләгән шәхесләр, вакыйгалар һәм сюжетларның объектив чынбарлыкка тәңгәллегенә тулы ышаныч белән карарга мөмкинлек бирә.

Авторның максаты М. Солтангалиев аша татарлар арасында милли-азатлык хәрәкәтенең үсүен күрсәтү, аның үзенең һәм официаль әдәбиятта хәзергә кадәр каһәрләнеп киленгән көрәштәшләренең якты истәлеген халык күңеленә кайтару, аларның фаҗигале язмышын ачып салу. Р.Мөхәммәдиев бу максатына ирешкән дип тулы ышаныч белән әйтергә мөмкин. Гыйлемдар Рамазановның «Ватаным Татарстан» газетасының шушы елның 14 август санында басылган һәм «Каһарман Мирсәет» дип исемләнгән рецензиясендә бу инде ныклы дәлилләр ярдәмендә бик ачык итеп күрсәтелә. Рецензент әсәрнең төп сюжеты М.Солтангалиев белән Сталин арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр, үзара көрәш, Сталинның мәкерле сәясәте һәм үзенең оппонентына карата астыртын эш иткәнлеген аеруча басым ясап күрсәтә. Моның белән килешмәскә мөмкин түгел. Әмма китапта тагы бер сюжет — татар халкының язмышы мәсьәләсе дә калкып тора. Сталинның М.Солтангалиевкә каршы үткәрелгән сәясәте татар халкына каршы да юнәлдерелгән иде. Ул М.Солтангалив һәм анын көрәштәшләрен үз юлыннан алып ташлап татар халкын көчсезләндерүне, аны аяктан егуны күз алдында тотып эш итте. Китапта бу яхшы төсмерләнә.

Сталин хакимияткә килү белән коммунистик идеологиягә төреп һәм СССР исеме астында Россия империясен яңадан торгызу юлына баса. Ә татарларның милли аңы, алар арасында җәелгән милли хәрәкәт аның бу сәясәтен үткәрү юлында җитди киртә булып тора. Милли-азатлык хәрәкәте татарлар арасында Казан ханлыгы рус хакимиятенә буйсындырылганнан бирле сүнеп тормый, ә 1905—1907 елларда ул тагы да көчәеп китә. 1917—1918 елларда исә яңа баскычка күтәрелә. Моның ачык дәлиле татарларның 1917 елгы революцион күтәрелештә актив катнашуы. Алар бу күтәрелешкә социаль-политик яктан да, рухи-идеологик яктан да яхшы хәзерләнгән иделәр. Бу җәһәттән җәдитчелек хәрәкәте дә мөһим роль уйнады. Җәдитчеләр эшчәнлеге нәтиҗәсендә татарларның белем дәрәҗәсе һәм иҗтимагый аңы яхшы ук күтәрелде. Халыкның киң катламына азатлык идеяләре үтеп керде. Нәтиҗәдә татар халкы революцияне үз хакын хакларга хәзерләнгән милләт буларак каршылады.

Революцион көрәш дулкынында милли хәрби формированиеләр барлыкка килә, татар батальоннары һәм полклары милли-азатлык хәрәкәтенең таянычына әвереләләр. Революцион көрәш һәм милли-азатлык хәрәкәте күтәрелүе нәтиҗәсе буларак, милли идарә оеша, милли һәм хәрби шуралар барлыкка килә. Казанда соңгысының кулында 50 меңлек гаскәр туплана. Татар-башкортлар арасында Идел-Урал штаты идеясе туа. Бу идеяне күтәреп чыгучылар сүз бара торган штатны Россиядән аеруны күз алдында тотмыйлар, аларның максаты татар-башкортларга Россия составында үзләренең мөстәкыйльлекләренә, үз язмышларын үзләре хәл итү мөмкинлегенә ирешү иде.

Россиянең шовинизм рухы белән агуланган даирәләре моның белән килешә алмадылар, аларга татар-башкортларны элеккечә империя табаны астында изаландыру кулайрак булды. Әмма шул ук вакытта алар революцион буталчыклык шартларында татарлар белән ачыктан-ачык конфронтациягә барырга ярамаганын да күрәләр һәм милли көчләрне таркату, аларны бер-берсенә каршы кую юнәлешендә эш җәелдерәләр. Милли хәрәкәттә бердәмлек булмау аларга бу юнәлештә нәтиҗәле эш алып бару мөмкинлеге тудыра һәм алар милли хәрәкәтнең авангарды булган милли идарәне, хәрби шураны һәм 1917 елның азагында барлыкка килгән милли мәҗлесне таркатуга ирешәләр. Кызганычка каршы, бу эштә аларга милли хәрәкәтнең кайбер катламнары үзләре үк ярдәм итәләр.

Татар милли хәрәкәтен үз якларына аудару өчен Ленин һәм Сталин татар-башкорт республикасы идеясен күтәреп чыгалар. Бу идея Идел һәм Урал буенда зур яңгыраш таба, татар-башкортлар гына түгел, чуашлар, марилар, удмуртлар да аңа кушылырга теләкләрен белдерәләр. Мулланур Вахитов һәлак булганнан соң, бу идеяне иң актив рәвештә алга сөрүче М.Солтангалиев булды. Ул Ленин һәм Сталинның вәгъдәләренә ышана һәм Татар-башкорт республикасы рамкаларында халкыбыз үзенең азатлыгына ирешер дип өмет итә. Шушы идеяне тормышка ашыру максатында ул армый-талмый эшли, тештырнаклары белән самодержавие чорында урнашкан тәртипләрне саклап калу өчен сугыш алып баручы акгвардиячеләргә каршы көрәшкә татар-башкорт массаларын туплый. Бу җәһәттән Колчакка каршы көрәш фронтларында катнашкан армияләрнең кайберләрендә 60—70 процентка кадәр гаскәриләр татар-башкортлардан торганлыгын әйтү дә җитә.

Нәтиҗәдә татар-башкортларның иң актив көчләре гаскәри берләшмәләр составында Көнчыгышка һәм Урта Азия тарафына җибәрелгән булып чыга, ә Урта Идел һәм Урал төбәгендә калган милли көчләрнең сафлары сыеклана. Бу хәлдә Ленин да, Сталин да татар-башкорт милли хәрәкәте белән хисаплашмаска мөмкин дигән фикергә киләләр һәм татар-башкорт республикасы идеясеннән баш тарталар. Сталин инициативасы белән бу төбәктә хәзер яманаты чыккан автономияләштерү процессы башлана.

М.Солтангалиев моның белән килешә алмый, милли мәсьәләләрне хәл итүдә үзенең позициясендә кала һәм шушы юнәлештә актив эш алып бара, ә татарларга автономияле республика статусы тагылгач, ул шушы автономия кысаларында гына булса да реаль мөстәкыйльлеккә ирешү өчен көрәшә. Гражданнар сугышы кырларында җиңүгә ирешкәч, Сталин моңа чик куярга вакыт җитте, дигән карарга килә һәм М.Солтангалиевне юлыннан алып ташлау эшенә керешә. Китапта моны Сталинның нинди мәкерле юллар белән тормышка ашырганлыгы бик ачык итеп тасвирланган.

Әмма Сталин үткәргән бу мәкерле сәясәтнең максаты бер М.Солтангалиев кенә түгел иде. Бу очракта Сталин һәм аның иярченнәре беренче чиратта татар халкын күз алдында тотып эш иттеләр. Аларның төп максаты бу халыкны көчсезләндерү, аны җитәкчесез, башсыз калдырып аяктан егу иде. Матбугатта Сталинның 1937 елны оештырган җәбер-золымнары, аның интеллектуаль көчләрне эзәрлекләве һәм юкка чыгаруы турында күп язылды. Әмма татар халкына карата бу сәясәт күп элек үткәрелә башлый. Әле 1922—1923 елларда ук Татарстанда, Кырым республикасында һәм Башкортстанда эш башында торган һәм Солтангалиев белән бәйләнештә булган күп кенә милли кадрлар хезмәт вазыйфаларыннан читләштереләләр һәм эзәрлекләнүгә дучар ителәләр. 20 елларның азагында исә Солтангалиевчелеккә каршы көрәш сылтавы белән татар интеллигенциясенең милли рухта фикер йөртүче катламы юкка чыгарыла, халыкның күренекле вәкилләре төрмәләргә утыртыла, Соловки утравына яисә Себергә сөрелә. Нәтиҗәдә, халык интеллектуаль һәм рухи җитәкчесез кала.

Сталин Солтангалиевка һәм аңа бәйләнгән милли көчләргә каршы инде патша самодержавиесенең күп гасырлар дәвамында сыналган ысулын кулланып эш итте. Тарихтан билгеле булганча,

Мәскәү хөкемдарлары оппозицион көчләргә, беренче чиратта мөстәкыйльлекләрен сакларга омтылучы боярларга каршы канлы көрәш алып баралар. Бу көрәшкә алар татарларны да тарталар, теге яки бу бояр фетнәсен бастырганда татар отрядларын файдаланалар. Җиңүнең икенче көнендә исә алар бу отрядларның сугышчыларын канга батырап юк итәләр. Бу сәясәтнең бер эпизодын күренекле тарихчы Газиз Гобәйдуллин болай тасвирлый: «Бу сыйныф татарлар үзләренең рус сыйныфташларына смута заманында шактый зур хезмәт иттеләр... Ләкин смута бетәрбетмәс Мәскәүнең хаким служилый сыйныфы һәм аның сәүдә капиталы үзләренең Идел буендагы конкурентлары һәм шәрыкка тәҗавезләре өчен комачаулау ихтималы булган татар морза вә йомышлылары өстенә ташландылар».[1] Совет хөкемдарлары да гражданнар сугышы елларында акларга каршы көрәштә татарларны, милли ирек вәгъдә итеп, хәрби көрәшкә күпләп җәлеп итә алдылар, ә җиңү яулагач, шушы көрәшкә актив катнашкан татарларга карата хыянәтчел һөҗүм башладылар, аларның иң күренеклеләрен физик яктан юк итү чарасын күрделәр.

Бу тарихи сабак. Бу сабактан безгә тиешле нәтиҗә ясарга вакыт. Тарихта безгә иң зур зарар китергән нәрсә — бердәмлек булмау һәм Мәскәү хөкемдарларының сүзенә сукырларча ышану, безнең өчен һичнинди файдасы булмаган, киресенчә, бары зарар гына китерердәй эш-гамәлләргә тартырга ирек бирүдә булды. Мөгаен, инде күзне ачарга һәм, халкыбызның киләчәген күз алдында тотып, актив көрәшкә тартылырга вакыттыр. Халкыбызның иң аңлы уллары һәм кызлары хәзер милләтнең киләчәге, аның мөстәкыйльлеге һәм бәйсезлеге, үз язмышын үз кулына алуы өчен көрәшчеләр сафына бастылар. Бу изге максатка бару юлында безгә эш-гамәлдә дә, уй-фикердә дә, сүздә дә бердәм булырга, арабызга таркаулык кертмәскә һәм көчебезне милләт өчен хилаф юлга юнәлдерергә бирмәскә кирәк. М.Солтангалиев язмышы безне шуңа чакыра.

[1] Г.Гобәйдуллин. Тарихи сәхифәләр ачылганда. Казан, 1989, 203 б.

1992 ел.

МИЛЛИ ИДЕОЛОГИЯ МӘСЬӘЛӘСЕ ҺӘМ САДРИ МАКСУДИ МИРАСЫ

Илебез хәзер юллар чатына килеп баскан һәм кай тарафка китәргә белми аптырап калган юлчыны хәтерләтә. Бу халәт моңа кадәр яшәп килгән социаль-икътисади һәм сәяси тәртипләрнең җимерелүе нәтиҗәсе. Шул ук вакытта мондый халәтнең туууында идеологик ориентирлар югалуының да роле хәлиткеч булды. 1917 елгы революцион тетрәнүләрдән соң илдә урнашкан социаль-икътисади һәм сәяси тәртипләр җәмгыять тормышының гуманистик идеалларыннан ерак иделәр. Шуңа да карамастан, алар 70 елдан артык хакимлек итә алдылар һәм күпмедер күләмдә икътисадның үсешенә, фән-техника прогрессына да юл ачтылар. Бу яшәештә һәм үсештә идеологик өскорма үзенең ролен уйнады, халыкның фикери куәтен билгеле бер максатларга туплый алды.

Сиксәненче еллар азагында җәелгән процесс ил тормышының социаль-икътисади һәм сәяси нигезләре белән беррәттән идеологик ориентирларның да җимерелүенә китерде, коммунистик идеология халык массаларының аңы өстеннән хакимлек итү көчен югалтты һәм илдә идеологик вакуум (бушлык) хасил булды. Физик вакуум кебек үк, идеологик бушлык та озак саклана алмый. Бу чынбарлык өчен гайре табигый хәл булыр иде һәм хәзер Россия күләмендә без бу бушлыкны тутыруга юнәлдерелгән көчәнешне күрәбез. Бу очракта бер яктан христиан руханилары зур тырышлык күрсәтәләр һәм әйтелгән вакуумны православие идеологиясе белән тутырырга тырышалар. Ә икенче яктан халыкның аңына бөекдержавачылык идеологиясе сеңдерелә. Бу идеологиянең нигезендә урыс милләтчелеге ята. Милләтчелек милләтчелек кенә булып калса, әлбәттә, нормаль күренеш булыр иде. Башка һәрбер халык кебек үк, урыс халкы да үзенең милли мәнфәгатьләре һәм мәдәнияты турында кайгыртырга хаклы. Әмма урыс державачылык идеологиясе моның белән генә чикләнми, ул шовинистик һәм империячел идеяләр белән үрелеп үсә, бердәм һәм бүленмәс Россия идеясе, башка халыкларны империя тәгәрмәченә бәйләп кую идеясе белән бәйләнгән. Шулай итеп, яңа терминнар ярдәмендә халык аңына узган гасырда самодержавие идеологиясенең асылташларыннан булган рәсми халыкчанлык (официальная народность) шигарьләре сеңдерелә.

Бу шартларда үзебезнең идеологик ориентирларыбызны билгеләмәсәк, урыс державачылык һәм православие идеологиясе безнең аңыбызны томалауга китерәчәк һәм киләчәктә дә безнең арада урыслаштыру сәясәте үткәрүгә җирлек сакланачак. Шуңа күрә безнең үзебезнең дә бу идеологик басымга каршы торырдай милли идеологиябез булырга тиеш. Хәзерге шартларда безнең милли идеологиябез түбәндәге факторларны күз алдында тотып корылырга тиеш:

1. Миллилек, этник аң, милли рух, миллият хисе һәм миллият тойгысы. Бу милли хәзинә милли идеологиянең хәлиткеч өлеше, нигез ташы. Милли идеологияне этник аңнан, милли рухтан, миллият тойгысыннан башка күз алдына китереп булмый. Тулы канлы милли идеология бары шушы асыл нигезендә генә формалаша ала.

2. Дини инанулар. Кешелек тарихында бер генә дә динсез милләт күзәтелми. Коммунистлар традицион диннәрне һәм дини инануларны кире кагып эш иттеләр. Әмма шул ук вакытта алар марксистик-атеистик идеологияне дин дәрәҗәсенә күтәреп халык аңына иңдерергә тырыштылар. Чөнки дини инанулары булмаган җәмгыять нормаль яши алмый. Тарих шуны күрсәтә. Дини инанулар милләтләрнең барлыкка килүендә дә, яшәешендә дә хәлиткеч роль уйныйлар.

3. Хәзерге чор — фән һәм техника үсеше чоры һәм бу шартларда бер генә халык та көнбатышның фән һәм техника казанышларына, аның мәдәниятына, икътисади һәм сәяси тәҗрибәсенә күңелен багламаса, заман белән бергә атлый алмый. Шуңа күрә без дә көнбатыш мәдәниятының, аның фән һәм техника өлкәсендәге һәм рухи үсештәге, сәламәт акыл кабул итәрдәй казанышларын милли идеологиябезнең ориентирларын билгеләгәндә игътибардан читтә калдыра алмыйбыз.

4. Без билгеле бер икътисади, сәяси һәм хокукый фәзада (пространствода) яшибез. Ул фәзада башка халыклар вә мәмләкәтләр белән, беренче чиратта урыс халкы һәм урыс мәмләкәте белән күпкырлы мөнәсәбәтләргә керергә мәҗбүрбез. Милли идеологиябезнең ориентирларын билгеләгәндә боларны истә тоту да гаять зур әһәмияткә ия.

Тулы канлы милли идеология бу факторларның барысын да күз алдында тотып эш иткәндә генә формалаша алачак. Шулай да, халкыбызның бүгенге халәтен искә алсак, бу дүрт фактор-

ның беренче икесенең хәзергесе көндә аерым әһәмияткә ия булганлыгын күрәбез. Шуның өчен алар турында аерым тукталу мәгъкуль булыр.

Билгеле булганча, дүрт гасыр дәвамында безнең милли идеологиябез вазыйфасын ислам үтәде. Самодержавиенең христианлаштыруга һәм урыслаштыруга юнәлдерелгән коточкыч басымына карамастан, безнең халкыбыз үзен милләт буларак саклап кала алды һәм бу очракта ислам аның таянычы булды. Ул чукынмаган өчен асу-кисүгә, һәртөрле җәбер-золымга, мыскыллауларга дучар ителде һәм шушы шартларда ислам канаты астында тупланырга тырышты. Ислам аның милли аңының аерылгысыз өлешенә әйләнде, хәтта еш кына мөселманлык милләт белән тәңгәлләштерелде.

Хәзерге шартларда да милләтне сакларга теләсәк, ислам милли идеологиябездә үзенең лаеклы урынын алырга тиеш. Шул ук вакытта коммунистик идеология хакимлек иткән чорда халкыбыз арасында исламның позицияләренең бик нык йомшарганын да истән чыгарырга тиеш түгелбез. 70 елга сузылган атеистик пропаганда һәм дини эзәрлекләүләр үзләренең кара эшләрен башкардылар. Халкыбызның байтак өлеше хәзер дингә яки битарафлык саклый, яки бөтенләй кире мөнәсәбәттә тора. Бу шулай дәвам иткән тәкъдирдә безнең киләчәктә дә бердәм милләт булып кала алуыбызга гаять зур куркыныч яный. Инде әйткәнемчә, идеологик бушлык озак саклана алмый һәм хәзер менә шушы бушлыкка башка дини идеяләр, беренче чиратта бахаитлар, кришнаитлар һәм христиан чиркәвенең төрле секталары (евангелистлар, баптистлар һ.б.) ыргылдылар һәм милләтебезнең ориентерларын югалткан өлешен бик җиңел үз кармакларына эләктерәләр. Бу шулай дәвам итсә, милләтнең тәмам таркалуына китерәчәк.

Дөрес, соңгы елларда исламның позициясе халкыбыз арасында күпмедер киңәйде, күбәүләр аңа йөз белән борылдылар. Әмма динилек милләттәшләребез арасында әлегә дини хис рәвешендә генә күзәтелә һәм динне аңлау идеология дәрәҗәсенә күтәрелмәгән. Динне идеологик күренеш дип аңлау һәм аңлата алу дәрәҗәсенә әле руханиларыбыз үзләре дә хәзерлекле түгелләр. Имамлык вазыйфасын башкаручы бик күбәүләр динне аңлауда мәхәллә халкыннан әллә ни аерылып тормыйлар. Руханилар арасында хәзер Р.Фахретдинов, Г.Баруди, М.Бигиев, Р.Ибраһимов, З.Камали, К.Тәрҗемани, Х-Г.Габәши, З.Кадыйри,

Җ.Абызгилдин кебек асыл затларыбыз юк. Андый затлар репрессия корбаннары булдылар, яисә эмиграциягә китеп читят җирдә дөнья куйдылар. Шулай итеп, илаһи тәгълиматны аңлау һәм аңлату белән бәйләнгән күп гасырлык традицияләр өзелде. Шуңа күрә хәзер динне идеология дәрәҗәсендә аңлый һәм аңлата алырдай руханилар тәрбияләү изге бурычлардандыр. Бу һичшиксез дини оешмаларның игътибар үзәгендә торырга тиеш. Зыялыларыбыз да бу мәсьәләдә дин әһелләренә ярдәм кулы сузарга тиешләр.

Бу очракта исламның коры дин генә булмавын да күз алдында тотып эш итәргә кирәк. Ислам — дөньякүләм тәэсире булган диннәрнең берсе. Әмма ул бер үк вакытта — фәлсәфи һәм идеологик система да, мәдәният та, әхлакый кануннар һәм хокук нормалары системасы да. Исламны шулай итеп өйрәнү аның халкыбыз аңына тәэсир итү көчен һәм тормыштагы ролен арттырачак. Шуңа күрә исламның идеологик һәм фәлсәфи асылын, аның мәдәният тарихындагы, җәмгыятьнең рухи һәм әхлакый үсешендәге ролен тирән үзләштерүнең милли идеологиябезне формалаштыруда һәм үстерүдә әһәмияте ифрат зур булачак.

Шушы уңайдан иҗтимагый фикеребез үсеше тарихында җәдитчелек калдырган мирасның әһәмиятен дә ассызыклап әйтеп үтәргә кирәк. Җәдитчеләр яңалык тарафдарлары иделәр, шул ук вакытта алар ислам кануннары кысаларында торып эш иттеләр. Алар һәртөрле катып калганлыкка, шул хисаптан динне аңлауда катып калганлыкка да, искегә ябышып ятуга, тәкълидчелеккә каршы чыктылар, тормышта, шул хисаптан дини кануннарны аңлауда һәм куллануда заман белән бергә атларга кирәклегенә басым ясадылар. Дини агарту эше алып барганда бу мирас һичшиксез файдаланырга тиеш.

Милли идеологиянең хәлиткеч өлеше, инде әйтеп үтелгәнчә, милләт һәм миллият мәсьәләсе, этник тамырларыбыз мәсьәләсе, милли язмыш, милли рухыбыз, милли аңыбыз, милли тойгыларыбыз мәсьәләсе. Коммунистик идеология безнең халкыбызны бу җәһәттән дә зур югалтуларга дучар итте. Интернационализмны берьяклы аңлау, милләтләрне юкка чыгаруга юнәлдерелгән сәясәт милләтнең үткәненә дә, бүгенгесенә дә, киләчәгенә дә битарафлык тәрбияләде, халыкның зур катламнары арасында этник аң ифрат дәрәҗәдә йомшады, милли мәдәниятның нигез ташлары җимерелде, милли тел акрынлап халыкның тормышыннан кыс-

рыклана барды. Тулы канлы милли идеология бары бу югалтуларны кире кайтару, милли аңны һәм милли мәдәниятны торгызу нигезендә генә формалаша һәм үсә алачак.

Милли идеологияне торгызуда милли мирасыбыз да олы бер көчкә ия. Бу мирасның халкыбызга иң мәгълүм өлеше — Г.Тукай, Ф.Әмирхан, М.Гафури, Г. Камал, Г.Ибраһимов кебек әдипләребезнең әсәрләре. Әмма бу әсәрләр озак еллар буенча марксистик методология нигезендә берьяклы өйрәнеп килгенделәр. Хәзер аларны яңабаштан милли позициядән чыгып укырга кирәк һәм шул чагында бу бөек затлар күз алдыбызга бөтенләй башка рәвештә килеп басаячаклар. Р.Фәхретдинов, Җ.Вәлиди, Һ.Максуди, Г.Буби, З.Камали кебек бер яктарак калып килгән әдипләребезнең мирасы да милли хәзинәбезгә бөтен тулылыгы белән кереп урнашырга тиешләр. Һәм, ниһаять, эмиграциягә китәргә мәҗбүр булган мөтәфәккирләребез һәм әдипләребез — Г.Исхакый, М.Бигиев, Г.Ибраһимов, Ф.Туктаров, Б. Баттал, Й.Акчура кебек бөек затлар һәм аларның әсәрләре. Тикшерелә торган мәсьәлә уңаеннан мин Садри Максудины аерым алып, аның турында тулырак сүз алып барырга телим.

Садри Максуди (1878—1957) — күренекле җәмагать эшлеклесе һәм галим — мәтәфәккир. Ташсу дигән авылда (Казан арты) мулла гаиләсендә туа. 1888—1895 елларда Казан мәдрәсәләренең берсендә, ә 1897—1901 елларда Казан татар укытучылар мәктәбендә укый. 1902 елдан башлап Сарбоннада (Париж) хокук фәннәре һәм филология гыйлемен өйрәнә. Ватанына әйләнеп кайткач, актив сәяси эшчәнлеккә тартыла, «Мөселман иттифакы» җитәкчеләренең берсе була. 1907 елда икенче, соңыннан өченче дәүләт думаларының депутаты итеп сайлана. Думаның мөселман фракциясе белән җитәкчелек итә. Бу елларда аның патша самодержавиесенең милли сәясәтен фаш итеп һәм урыс булмаган милләтләрнең хокукларын яклап дәүләт думасында ясаган чыгышлары зур яңгыраш табалар. Февраль революциясе алдыннан ул Казанда адвокатлык эше белән шөгыльләнә.

С.Максуди төрки халыкларның азатлыгы һәм бердәмлеге идеясе тарафдары була һәм февраль революциясеннән соң милли-азатлык хәрәкәтенең җитәкчеләреннән берсе буларак чыга. 1917 елда ул мөселман халыкларының милли-мәдәни автономиясе концепциясен нигезләүгә күп көч куя. 1917 елның маенда мөселман халыкларының Мәскәүдә узган 1 съездында ул Бөтенроссия үзәк милли шурасына сайлана. 1917

елны узган барлык мөселман съездларының эшендә актив катнаша. 1917 елның азагында «Милли мәҗлес» составына кертелә һәм аның актив җитәкчеләреннән берсе була.

Большевистик хакимият тарафыннан милли-азатлык хәрәкәте бастырылгач, С.Максуди чит илгә китәргә мәҗбүр була. 30 елдан артык гомерен Төркиядә уздыра. Төрек революциясе җитәкчесе К.Ататөрек белән якынлаша, 2 мәртәбә Төркия парламенты (мәҗлесе) депутаты итеп сайлана. Төркия делегациясе члены буларак, Милләтләр Лигасы эшендә дә катнаша. 1945 елдан ул — Истанбул университеты профессоры һәм актив фәнни-тикшеренү эшләре алып бара. Аның язган хезмәтләре хокук гыйлеме һәм лингвистика мәсьәләләренә карыйлар. С.Максудиның соңгы фәнни хезмәте «Миллият тойгысының социологик эсаслары» дип атала. Бу фәлсәфи характердагы хезмәт 1955 елда Истанбулда басыла. Анда милләт һәм милли мөнәсәбәтләр проблемасына тирән теоретик анализ ясала. С.Максудиның бу китапта төпле дәлилләр белән нигезләнеп бәян ителгән фикерләре милли мәсьәләләрне тикшергәндә, шул хисаптан милли идеологиянең ориентирларын билгеләгәндә методологик таяныч ролен үти алалар.

Милләтне һәм милли мөнәсәбәтләрне аңлауда да безгә берничә дистә еллар буенча Сталинның милләтләрне юкка чыгаруга юнәлдерелгән өйрәтмәләре тагылып киленде. Сталин үлгәннән соң, милләткә карата ул биргән төшенчәне атлап үтәргә омтылышлар ясалды, милләт проблемасына төрле яктан килергә тырышучылар да күзәтелде. Әмма бу төшенчә марксизмның асылыннан чыга иде, шуңа күрә дә әйтелгән тырышулар нәтиҗәсез тәмамландылар. Әле хәзер дә, хәтта милләт кайгысын кайгыртып эш итүче авторлар да, милләткә кагылышлы Сталин өйрәтмәләреннән арынып җитә алмыйлар. Бу мөһим һәм кирәкле адымны атлау өчен милли мөнәсәбәтләрне яктыртуда марксизм тәэсиренә бирешмәгән авторларның хезмәтләре белән танышу мөһим роль уйнаячак. Садри Максудиның әйтелгән хезмәте шундыйлардан.

Сталин милләтне, билгеле булганча, социаль-икътисади мөнәсәбәтләр үсеше нәтиҗәсендә туган ниндидер тарихи берлеккә кайтарып калдыра һәм теге яки бу милләтне хасил итүче халыкны, этносны бөтенләй читләтеп үтә. С.Максуди хезмәтендә исә милләт турында сүз барганда алгы планга нәкъ менә халык, этнос килеп баса. Аның өчен милләт билгеле бер кавем, ягъни этник берәмлек тәшкил итүче халык

үсешенең югары баскычы. Бу мәсьәләне тикшергәндә ул кавем-милләт төшенчәсе куллана. «Кавем-милләт исемен, — дип яза ул үзенең хезмәтендә, — без ыруг, кабиләләрнең бер дәүләт эчендә берләшүе нәтиҗәсендә туган этник бердәмлек рәвешендә күз алдыбызга китерәбез». Кавем һәм милләт тәгъбирләре арасындагы мөнәсәбәтне ачыклап, С.Максуди милләтнең ниндидер бер кавемнең үсеп җитүен күрсәтүче фактор икәнлегенә басым ясап үтә. «Тарихи вә сәяси үсеш нәтиҗәсендә формалашуы тәмамланган бер кавем, — дип яза ул, — милләттер».

Ахырда автор, «Кавем-милләт билгеле бер өлкәдә (территориядә) яшәгән, этнологик яктан бер тамырдан чыккан оймак вә кабиләләрнең иң куәтлесе җитәкчелегендә дәүләт булып берләшүе нәтиҗәсендә туган, бер телдә сөйләшүче, бер үк гореф-гадәтләр тотучы, бер үк дингә инанучы, үзенә хас милли характеры булган, бер-беренә теләктәшлектә торучы вә охшаш кешеләрнең зур төркемедер», дигән нәтиҗәгә килә. Күренүенчә, кавем-милләт төшенчәсе бер яктан милләтнең асылын, аның ни нәрсә икәнлеген, ә икенче яктан тамырларын, килеп чыгышын ачып сала.

С.Максуди үзенең китабында кавем-милләт төшенчәсенә һәрьяклап анализ ясый, милләтләрнең формалашу һәм яшәеше шартларына җентекләп тукталa. Җыеп кына әйткәндә, бу шартлар түбәндәгеләргә кайтып калалар:

1. Милләтне тәшкил иткән индивидларның (фәрдләрнең) бер дәүләт эчендә яшәве;
2. Халык (нәфус);
3. Географик урын (территория);
4. Бәйсезлек;
5. Тел берлеге;
6. Гореф-гадәтләр берлеге;
7. Гомуми дини инанулар;
8. Милли характер;
9. Милләтнең күпчелегенең бер ырктан, ягъни бер этник тамырдан булуы.

Бу шартларның җәмгысы милләт формалашуның нигезендә яталар, аның йөзен билгелиләр һәм милләт төшенчәсен ачык күзалларга мөмкинлек бирәләр. Милләтне болай аңлау безгә дистәләгән еллар буе тукып киленгән милләт төшенчәсе басымыннан котылырга ярдәм итә. Инде әйтелгәнчә, С.Максуди өчен милләт билгеле бер халык, этнос. Милләт була алсын өчен ул сан ягыннан билгеле бер күләмдә, үзен саклый

алырлык күләмдә булырга тиеш. Шуның өстенә милләт булып оешучы халык массасы бер ырктан, ягъни бер тамырдан чыккан булырга тиеш. Ырк төрек теленнән татар теленә раса, кавем, нәсел, токым, тамыр дип тәрҗемә ителә. Ә раса төшенчәсе безнең әдәбиятта, башлыча, кеше төркемнәренең бер-береннән тышкы кыяфәтләре (чәче һәм тән төсе, баш төзелеше, күзләре, буйлары һ.б.) ягыннан аерылуларының чагылышы рәвешендәрәк аңлатылып киленде. Бу — мәсьәләнең антропологик ягы. С.Максуди да үзенең китабында раса төшенчәсенә бу җәһәттән тирән анализ ясый. Шуның белән бергә, ул раса төшенчәсенә этнологик яктан да бик тирән анализ бирә. Милләт мәсьәләсен тикшергәндә автор ырк төшенчәсен нәкъ менә шушы этнологик мәгънәдә, ягъни кеше төркемнәренең этник тамырлары һәм нәсел-нәсебе ягыннан куллана. «Ырк, — дип яза ул, — билгеле бер нәсел үзлегенең чагылышыдыр». Милләтләрнең формалашуында менә шушы мәгънәдә кулланылган ыркның роле бәхәссез. Милләтләр гадәттә теге яки бу дәүләт эчендә күпчелекне тәшкил иткән ырктан (кавемнән, нәселдән, кабиләләр төркеменнән) укмашалар.

Милли мөнәсәбәтләр урнашуда Сталин теориясендә хәлиткеч рольне икътисади мөнәсәбәтләр уйный. С.Максуди исә бу җәһәттән беренче планга дәүләтне чыгара. Милләтнең барлыкка килүендә, дип саный ул, милләтне тәшкил итүче массаларның озак заманнар буе бер дәүләт, бер үк хокукый кагыйдәләргә буйсынып яшәве кирәк. Аның фикеренчә, милләтләрнең оешып яшәве һәркайда билгеле бер дәүләт эчендә бара. Ә дәүләт исә индивидлар мәҗбүри рәвештә буйсынырга тиешле хокукый тәртипләр урнаштырылу дигән сүз. Шушы хокукый тәртипләр теге яки бу дәүләт рамкаларында яшәгән массаларның бер милләт булып формалашуында хәлиткеч роль уйныйлар да.

Милләтнең формалашуы һәм яшәвенең мөһим шартларыннан берсе — тел берлеге. Кешелек җәмгыятенең кабилә дәверендә ыруг вә оймакларның аралашу чаралары әле камил түгел. Бу беренчел телләрдә сүзләр аз, грамматика башлангыч чорны кичерә; аның кагыйдәләре малик түгелләр. Шулай да бу заманда һәр оймакның инде аерым теле бар. Төрле оймакларга кергән кешеләр исә әле бер-берсен аңламыйлар. Уртак тел фәкать озак вакытлар дәвамында бер дәүләт эчендә яшәү, аралашу, бер үк нәрсә күп мәртәбәләр кабатлану нәтиҗәсе буларак барлыкка килә.

Озак вакытлар буе бер дәүләт эчендә яшәү шулай ук кавем-милләтләргә хас бердәм гореф-гадәтләр укмашуга да, милли характер һәм уртак милли рух барлыкка килүгәдә алып бара.

Күренүенчә, марксизмнан аермалы буларак, С.Максуди концепциясендә милләт барлыкка килүнең хәлиткеч шарты капиталистик мөнәсәбәтләр барлыкка килүе түгел, ә милләт булып оешуга тартылган массаларның озак заманнар буе бер дәүләт булып яшәүләре. Шушы дәүләт рамкаларында кабиләләр милләт булып оеша, милли тел барлыкка килә, бердәм милли гореф-гадәтләр формалаша, милли характер чарлана һәм милли рух туа. Шушы дәүләт рамкаларында, әлбәттә, социаль-икътисади мөнәсәбәтләр дә формалаша һәм үсә. Милләтнең яшәешен болай аңлату аны тарихи күренеш кенә дигән аңлатмалар тырнагыннан арынырга мөмкинлек бирә. Кавем-милләтләр тарихның билгеле бер этабы белән генә бәйләнмәгәннәр. Алар инде бик борынгы дәверләрдә яшиләр һәм аларның формалашуы беренчел дәүләтләргә туры килә. Ә дәүләтнең барлыкка килүе исә сыйныфлар барлыкка килүенә бәйләнмәгән һәм аны бары сыйнфый изү коралы гына дип аңлату урынсыз. Дәүләт ул борынгы гореф-гадәтләр урынына индивидлар мәҗбүри рәвештә, буйсынырга тиешле хокукый тәртипләр урнаштырылу дигән сүз. Мондый тәртипләр исә кабиләчелектән чыгу дәверендә урнаша. Димәк, дәүләтнең яшәве, шуның белән бергә милләтнең дә формалашуы бик борынгы, тарихка кадәрге дәверләргә барып тоташа. Милләтләрнең формалашуы инде беренчел дәүләтләрдә үк күзәтелә. Китапта кельт, герман, славян, төрек ыркылары турында сүз кузгатыла. С.Максуди аларны бик борынгы дәүләтләр эчендә аерым милләт тәшкил иткән массаларның таркалган өлешләре дип саный.

Милләтнең формалашуының һәм яшәешенең мөһим шартларыннан берсе — өлкә берлеге, ягъни ул урнашкан географик урын. Кавем-милләтләр һәркайчан билгеле бер урында укмашалар һәм яшиләр. Әмма бу гомуми кагыйдәгә сыймаган очраклар да күзәтелә. Яһуд милләтенең, мәсәлән, гасырлар буе үзенең милли туфрагы булмады. Ул бөтен дөньяга таралган хәлдә бер милләт буларак яши бирде. Шул ук вакыт яһудләр милләт булып формалашкан чакта, Давыт һәм Сөләйман исемле хөкемдарлар заманында, аларның дәүләтләре дә, милли туфраклары да бар иде. Яһудләр дөньяның төрле почмакларына инде милләт булып формалашканнан соң таралдылар. Бу анализга

йомгак ясап, С.Максуди: «Формалашуы тәмамланган милләтнең миллияте өзлексез һәм ул киләчәктә дә милләт буларак саклана ала», дип күрсәтеп үтә.

Бу күрсәтмә безнең милләтнең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында фикер йөрткәндә дә гаять зур әһәмияткә ия. Безнең бабайлар да ерак үткән дәверләрдә Болгар дәүләте рамкаларында кавем-милләт булып формалашалар, дип әйтергә тулы нигез бар. Бу милләт Алтын Урда чорында катлаулы үсеш дәвере кичерә. Ә Казан ханлыгында яңадан үз җирлегендә үсүен дәвам итә. Урыс хакимиятенә буйсындырылгач, ул коточкыч җәбер-золымнар татый, таркатыла. Хәзер Аурупа һәм Азиянең киң мәйданнарында таралып яши һәм төрле мәмләкәтләрдә урнашкан социаль-икътисади, хокукый һәм сәяси тәртипләргә буйсынырга мәҗбүр. Шулай да татар кайда гына булса да, шөкер, үзенең татарлыгын югалтмый, бөтен күңелен вә тойгыларын асыл ватанына бәйләп яши. Һәм бу — безнең кайчандыр бик борынгы заманнарда милләт булып формалаша алуыбыз һәм шул вакыттан килгән милли тойгыны күңелләребездә саклавыбыз нәтиҗәсе.

Милләт формалашуының һәм яшәешенең тагы бер мөһим үзенчәлеге — дини инанулар. Инде әйтеп кителгәнчә, кешелек тарихында динсез бер милләт тә күзәтелми. Шулай да милләтләрнең яшәешендә милли телнең барлыкка килүе белән дини инанулар барлыкка килү арасында аерма да күзәтелә. Милләтләрнең милли теле милли бер казаныш һәм ул милләт белән бергә барлыкка килә. Дини инанулар исә милли түгелләр. Алланың асылы, инсанның вә галәмнең барлыкка килүе һәм кешеләрнең җирдә башкарырга тиешле гамәлләре турындагы инануларның, ягъни диннәрнең бер милләттән икенче милләткә күчкәне күзәтелә. Милли дине, ягъни үз милләте эчендә генә зарур булган пәйгамбәрләр тарафыннан таратылган дине булган милләтләр сирәктер. Әмма милли булса да, башка милләттән алынган булса да дин милләтнең бер күрсәткече. Француз милләтенең барлыкка килүендә католик дине, бүгенге төрек милләтенең барлыкка килүендә исламият мөһим бер фактор булдылар.

Шул ук вакытта С.Максуди искәрмә рәвешендә теге яки бу милләтнең булуы өчен дин берлеге зарури түгелдер, дип тә күрсәтеп үтә. Бу уңайдан мисал рәвешендә шул ук французларны китерә. Милләтләре буенча алар, әлбәттә, французлар, әмма аларның бер өлеше католиклар, ә бер өлеше протестантлар. Әмма бу каршылык француз милләтенең нигезендә ятмый.

Чөнки протестантлык француз милләте оешканнан соң барлыкка килгән. Шуңа охшашлы хәл безнең үзебезгә дә хас. Безнең милләтебез исламияткә инанучы бер милләт буларак барлыкка килә. Болгар дәүләте чорында ук инде без ислам тарафдарлары булып формалашабыз. Исламга тугрылыкны безнең милләтебез Алтын Урда чорында да, Казан ханлыгы чорында да саклый. Хәзер безнең арада керәшеннәр бар. Бу катлам соңгы гасырлар күренеше, илебез урыс дәүләтенә буйсындырылгач хакимият тарафыннан үткәрелгән урыслаштыру сәясәте җимеше.

Һәм, ниһаять, милләтләр оешуның һәм үзләренең бөтенлекләрен саклый алуның тагы бер мөһим шарты — аларның бәйсезлеге, мөстәкыйль яши алулары. Милләт бәйсезлеген югалтса, аның бөтенлегенә дә зарар килә, ахыр чиктә инкыйразына да илтүе мөмкин. Безнең кебек мөстәкыйльлеген югалткан бер милләт өчен милләт яшәешенең бу факторы кисәтү буларак яңгырый. Моннан 440 ел элек милли бәйсезлегебезне югалту безне милләт буларак зур югалтуларга китерде. Әгәр киләчәктә дә үз язмышыбызны үз кулыбызга алмасак һәм империя арбасына тагылган дегет чиләге хәлендә кала бирсәк, милләт буларак безнең хәлебез бик аяныч булачак.

Кавемнең милләт дәрәҗәсенә ирешү һәм милләт буларак яшәү шартларын һәм гамәлләрен шулай һәрьяклап анализлап чыкканнан соң, С. Максуди милләт төшенчәсенә яңадан әйләнеп кайта. «Милләт, — дип яза ул үткәрелгән анализга йомгак ясап, — ерак үткәндә, күп очракта тарихтан элгәре дәвердә үк билгеле бер урында дәүләт корып, шушы дәүләт эчендә озак вакытлар мөстәкыйль булып яшәп, үз составына кергән өлешләре каршылыклы тәэсирләр тойган хәлдә бер-берсе белән аралашып, бердәм гореф-гадәтләргә тугрылыклы булып бер телдә сөйләшүче индивидлар вә гаиләләрдән оешкан бәшәри массадыр».

Кавем-милләтләрнең барлыкка килүе, яшәеше аларның йөзен билгеләүче факторларны С.Максуди шулай характерлый һәм аларны хакыйкый милләтләр дип атый. Кавем-милләтләр, ягъни хакыйкый милләтләр белән беррәттән, аның фикеренчә, кешелек җәмгыятендә тарихи милләтләр дә очрый. Хакыйкый милләтләр (кавем-милләтләр) белән тарихи милләтләр бер-берсеннән үзләрен барлыкка китергән сәбәпләр, милли бәйләнеш нигезендә яткан факторлар һәм үзләренең состав өлешләре белен аерылалар. Бер нәселдән булган ыруг вә кабиләләрнең бер кавем-милләт булып оешуы нигезендә ихтыяри омтылыш ята, алар үз

мәнфәгатьләрен яклау өчен үз ихтыярлары белән берләшәләр һәм бу ихтыяри омтылыш кавем-милләтләрнең формалашуына китерә. Тарихи милләтләр исә көч куллану, хаким төркемнәрнең башка кавемнәрдән булган төркемнәрне көч ярдәмендә буйсындыруы һәм йотуы нәтиҗәсендә барлыкка киләләр. Кавем-милләтләрдә кешеләр бер-берсе белән этник җепләр белән бәйләнгәннәр. Ә тарихи милләтләрдә аларны бер-берсенә бәйләүче фактор — көч. Кавем-милләтләр бер-берсенә якын торган оймак вә кабиләләрдән укмашалар. Тарихи милләтләргә исә мондый бер төрлелек зарури түгел. Алар составына хакимлек итүче кавем-милләт тарафыннан буйсындырылган төрле кавем-милләтләр керүе мөмкин.

Тарихи милләтләрнең мисалы итеп С.Максуди римлыларны китерә. Бу милләт, дип күрсәтеп үтә ул, римлы булмаган һәм рим телендә сөйләшмәгән күп кенә кавем вә милләтләрне буйсындыру нәтиҗәсендә барлыкка килде. Тарихи милләтләр башлыча империягә хас күренеш. Аларның барлыкка килүе вә яшәве чыннан да билгеле бер тарихи шартлар белән бәйле.

Соңгы вакытта матбугат битләрендә милләт мәсьәләсен этник асылыннан аерып шушы тарихи милләтләргә хас төшенчәләргә таянып аңлатырга омтылыш күзәтелә. Менә «Согласие» төркеменең теоретигы В.Беляевның бу мәсьәләгә кагылышлы фикере «В мире с XVIII века, — дип яза ул, — нацией называется не этнос (татары, русские, баски), а все население (согражданство)» («Советская Татария», 1992, 28 май). Мондый фәлсәфә бары империалистик сәясәтнең, милләтләрне өстенлек итүче бер милләткә буйсындыру, аның казанында эретеп бетерүгә булган омтылышның чагылышы. В.Беляев теориясен милли мөнәсәбәтләрнең нигезе итеп алган тәкъдирдә Россия Федерациясендә, мәсәлән, татар да, чуаш та, башкорт та юк һәм була да алмый. Монда бары бер Россия милләте генә, россияннар генә яши. «Согласие» дип аталамы, «народовластие» дип аталамы, Татарстан җирендә эш итүче «демократларның» асыл максаты шушы. «Молодежь Татарстана» газетасының 1992 ел, 34 санында басылган мәкаләсендә В.Беляев Татарстанның бәйсезлеген дә анда яши торган милләтләрнең юкка чыгуы һәм бөтен халыкларның уртак берәмлеккә укмашуы белән бәйли. Күренүенчә, милләтләрнең тигезлектә бер-берсен аңлап бер дәүләттә янәшә яши алулары «демократ» өчен гайре табигый хәл.

Тарихи милләтләр кешелекнең нормаль үсешеннән тайпылыш буларак күзәтеләләр. Кешелекнең нормаль үсеш процессы исә кавем-милләтләр формалашуга китерә. Болар хакыйкый милләтләр. Алар ыруг, оймак, кабиләләрнең үсеше процессында барлыкка киләләр һәм кавем-милләт буларак яшиләр.

Милли идеологиянең эчтәлеге турында уйлаганда, С.Максудиның миллият тойгысына кагылышлы фикерләре дә гаять зур әһәмияткә ия. Миллият тойгысының чыганагы, С.Максуди фикеренчә, ыруг, кабилә вә кавемнәрнең ерак үткәненә барып тоташа һәм ул аларны тәшкил иткән индивидлар арасында кеше рухына хас булган иҗтимагый омтылыш басымы астында барыкка килә. Кеше тумыштан ук үзе бәйләнгән төркемкабилә, кавем яки милләт рухына багланган була. Чөнки аның хәяттагы урыны әйтелгән инсани төркемнең хәятына бәйләнгән. Бу төркем эчендә урнашкан теләктәшлек һәм бердәмлек атмосферасы аның иҗтимагый омтылыш вә һәвәслекләре ачылуга мөмкинлек, каршылыклы мәхәббәт, бер-берәңә ышаныч вә тынычлыкны саклый алырдай бер мохит тудыра. Шушы нигездә миллият тойгысы барлыкка килә дә. «Шулай итеп, — дип яза С.Максуди, — миллият тойгысының чыганагы вә үзәге беренчел җәмгыятьләрдә дә, мәдәни җәмгыятьләрдә дә, аерым очракларда хәтта хайваннар дөньясында да күзәтелгән шушы гомуми социологик күренештер, ягъни индивидларның үзләренә хас тойгылары нәтиҗәсендә туган бер-берәңә бәйлелек хиседер».

Бу тойгының эчтәлеген ачып автор алга таба, «миллият тойгысы индивидларның үз милләтләренең үткәненә, киләчәгенә, теленә, мәдәниятына, өлкә вә туфрагына карата туган карашларның тирәнәюе, нәселдән нәселгә күчүе белән бәйләнгән рухи бер халәттер», дип күрсәтеп уза. Шуның өстенә бу рухи халәт милләтне тәшкил итүче бөтен индивидларны колачлаганлыктан, шәхси булудан бигрәк, коллектив бер тойгы рәвешендә яши.

Индивидларда милләткә бәйлелек хисенең, миллият тойгысының тууы, көчәюе, тирәнәюе вә бөтен милләт эчендә таралуы, дип хисаплый С.Максуди, милләтнең формалашып мәйданга килүенең психологик нәтиҗәләреннән берсе. Бу тойгы нәселчәнлек кануннары нигезендә милләт эчендә туктаусыз куәтләнә бара. Һәм милләтнең милләт буларак яшәешен тәэмин итүдә, аны башка милләтләр арасында эреп юкка чыгудан саклауда

хәлиткеч роль уйный. Ниндидер сәбәпләр аркасында шәхесләрне милләт итеп берләштерә торган бу җепнең өзелүе милләтнең барлык мәйданыннан юклык мәйданына күчүенә китерә.

Миллият тойгысы беренче чиратта теге яки бу милләткә караган кешеләрнең үзләренең милли тарихларына, милләтнең үткәндәге уңышларына яки бәхетсезлекләренә мөкатдәс бер нәрсә итеп караулары рәвешендә күзгә ташлана. Милләтче инсан милләтнең тарихта ялтыраган дәверләрен, уңыш китергән заманнарын горурлык вә зур канәгатьләнү хисе белән искә алса, караңгылык чорлары, бәхетсезлек вә газап кичергән заманнар исә анда кайгы хисе уята. Милләтләрнең үз үткәннәренә бағланганлыклары аларның үз милли мәдәниятларына, телләренә, диннәренә, милли аңнарына, милләтнең олы затларына вә каһарманнарына хөрмәт рәвешендә күренә.

Шулай да миллият тойгысы фәкать милләтнең үткәндәге язмышына бәйле рәвештә генә күзәтелми. Ул индивидларның милләтнең киләчәген күз алдында тотып кылган гамәлләрендә һәм фикерләрендә дә үзенең чагылышын таба. Миллият хисенең болай киләчәккә булган юнәлеше сәяси яктан мөстәкыйль булган милләтләрдә киләчәктә дә мөстәкыйль булып яшәү теләгендә, ә бәйсезлекләрен югалткан милләтләрдә исә бәйсезлекне яңадан торгызуга булган эш-гамәлләрендә үзенең чагылышын таба. Бу ике халәттә булган милләт тә, дип саный С.Максуди, үз ватанында үз телендә сөйләшеп, үз гореф-гадәтләренә таянып яшәүгә, мәдәният вә цивилизация җәһәтеннән алга бару теләге вә карашын даими үстерү өметендә булырлар. Миллият тойгысының ачылуы вә камиллеккә ирешүе шушы киләчәккә омтылган теләк вә максат аркасындадыр.

Димәк, безнең дә киләчәктә дә милләт булып яши һәм үсә алуыбыз бездәге миллият тойгысының камилләшә, үткенләнә һәм үсә баруы белән турыдан-туры бәйләнгән. Без бары үзебез үткәнебездән сабак алып, милләтебезнең ихтыяҗларын тоеп, аның киләчәген кайгыртып һәм бөтен сәләтебезне шушы киләчәкне күз алдында тотып эш итсәк кенә милләтебезнең башка халыклар белән бер сафта баруына ирешә алачакбыз.

Милли тойгы белән бәйле рәвештә, С.Максуди миллиятчелек турында да сүз алып бара. Соңгы бернечә дистә ел дәвамында безнең әдәбиятта хакимлек итүче коммунистик идеология басымы астында милләтчелеккә (С.Максуди аны миллиятчелек дип

атый) кара мөһер сугылып килендә. Ул шовинизм белән тәңгәлләштерелде һәм антигуманистик характерда булган бер идеологик юнәлеш рәвешендә тасвирланды. С.Максуди китабыннан күренгәнчә, миллиятчелек шовинизм кебек идеологик юнәлешләрдән ерак тора. Ул милләтнең яшәешеннән туган гадәти бер күренеш, милли тойгының гамәли чагылышы. «Милләтләрнең яшәүгә омтылышы вә ихтыяры, — дип яза С.Максуди, — «миллият тойгысы» яки «миллиятчелек» дип атала».

Миллиятчелек башка милләтләрне буйсындыру яки җәберләүне һич кенә дә күз алдында тотмый. Аның асылы бары үз милләтеңнең кайгысын, аның киләчәген кайгырту, аның теле, мәдәнияты турында уйлап эш итү, аның киләчәге өчен тырышлык күрсәтү, үз милләтеңнең киләчәктә дә милләт буларак яшәешен тәэмин итү, аны башка милләтләр арасында эреп юкка чыгудан саклау. «Миллиятче инсан, — дип басым ясап күрсәтә автор, — милләтенең тарихта ялтыраган дәверләрен, уңыш китергән заманнарын горурлык вә зур канәгатьләнү хисе белән искә алыр. Караңгылык чорлары, бәхетсезлек вә газап күргән заманнар исә анда кайгы уятыр».

Милләтчелекнең нигезендә кайбер авторлар раслаганча башка милләтләрне буйсындыруга һәм җәберләүгә юнәлдерелгән шовинистик омтылыш ятмый. Киресенчә, дип яза С.Максуди, миллиятчелек хисе милли җәбер-золымга каршы протест рәвешендә үсә вә ныгый. Теге яки бу милләт тарихта никадәр еш кайгы вә газаплы дәверләр кичергән булса, башка милләтләрнең һөҗүменә, золымына вә изүенә никадәр күп дучар ителсә, шул нисбәттә үк аның уллары вә кызлары үз милләтенә бәгланган булырлар, шул нисбәттә үк миллиятче булырлар. Милләтләрнең тарихта кичергән фәлакәтьләре, алар өстенә төшкән җәбер, золым вә хаксызлыклар, аларның үз бәйсезлекләре өчен алып барган көрәшләре вә фидакарьлекләре милли хисләре үсүгә этәргеч вазыйфасы үтәгәннәр.

Бу факторларны С.Максуди милли хисне куәтләндергән бөек гамәлләр дип атый һәм мисал рәвешендә полякларны һәм яһүдләрне китерә. Бу ике милләт поляк һәм яһүд булган өчен генә гасырлар буе бик күп җәбер вә золымнар татыдылар. Бу үз чиратында аларның милли хисләрен чарлады һәм нәтиҗәдә поляклар һәм яһүдләр хәзерге дөньяда иң миллиятче милләтләрдән саналалар.

С.Максуди милләтчелекнең хөррият, демократия һәм либерализм идеяләре белән бәйләнгәнлеген, анда тәгассыблык яки чикләнгәнлекнең әсәре дә булмавын басым ясап күрсәтеп үтә. «Бүгенге миллиятче, — дип яза ул сүзен йомгаклап, — милли намус вә абруй, милли дәрәҗә вә милли мәнфәгатьләр мәсьәләсендә гадәттән тыш нәзакәтле булу белән бергә шовинизмнан ерак торган, әмма шул ук вакыт рациональ, төпле һәм аек акылга нигезләнгән милли хиснә бирелгән инсандыр». Миллиятчелек күренеше милләтләрнең тарихында бөек роль уйнаган, зур тәэсирле вә динамик бер мәгънәви куәттер. Шушы мәгънәдәге милләтчелек безнең милли идеологиябезнең аерылгысыз өлеше булырга тиеш.

1993 ел.

МИЛЛИ ХӘРӘКӘТКӘ НИ БУЛДЫ?

1988 ел. Июнь аеның җылы бер кичe. Казан университеты аудиторияләренең берсендә шәһәрнең югары уку йортларыннан һәм фәнни оешмаларыннан, башлыча университетның үзеннән һәм Тел, әдәбият һәм тарих институтыннан килгән яшь галимнәрнең җыелышы бара. Җыелган төркем әле зур түгел, әмма анда олы мәсьәлә — милләт язмышы мәсьәләсе тикшерелә. Фикер алышуларның йомгагы буларак, татар халкының киләчәге кайгыртып эш итәрдәй иҗтимагый хәрәкәткә нигез салу турында карар кабул ителә. Озак та үтми, әйтелгән хәрәкәтнең инициаторлары университетның зуррак залларының берсендә бер-бер артлы ике җыелыш уздыруга ирешәләр. Бу җыелышларда инде олырак яшьтәге галимнәр дә, халкыбызның башка катламнары вәкилләре дә катнаша. 1988 елның көзендә милли хәрәкәтнең конференциясе дә булып үтте. Шулай итеп, соңыннан Татар иҗтимагый үзәге (ТИҮ) исемен алган һәм халкыбыз тормышында зур яңгыраш тапкан мәшһүр оешманың нигез ташлары салынды.

1989 елның февралендә Татар иҗтимагый үзәгенең беренче оештыру корылтае да үткәрелде. Корылтайда Үзәкнең платформасы расланды һәм уставы кабул ителде. Бу документларда ТИҮ нең алдагы көрәш маяклары билгеләнде. Тора-бара милли хәрәкәт үзенең колачын киңәйтә барды. ТИҮ дән тыш «Суверенитет» комитеты барлыкка килде, «Иттифак» милли бәйсезлек фиркасы, яшьләрнең «Азатлык» берләшмәсе, «Мәрҗани» җәмгыяте оешты, ахыр килеп, татар халкының милли мәҗлесе сайланды.

Милли хәрәкәт күтәргән шигарьләр, аларның иң мөһиме — милли мөстәкыйльлек яулау идеясе халкыбызның аңына үтеп керделәр һәм аның билгеле бер өлешен актив көрәшкә күтәрә алдылар. 1990—92 елларда еш кына шәһәрләребез мәйданнары гөрләп торды, милли оешмалар үткәргән митинглар үзләренә дистәләрчә мең милләттәшләребезне җәлеп иттеләр. Җөмһүриятебезнең Югары Советы утырышлары узган көннәрдә депутатлар утырышлар залына Ирек мәйданында пикетта торучыларның калын кордоны аша үтәргә мәҗбүр булдылар. Бу пикетларда торучы милләттәшләребез депутатларга халык таләпләрен җиткерә тордылар. Милләт байрагын күтәргән депутатлар Югары Совет утырышларында халкыбыз хакын хаклап авыр көрәш алып бардылар.

Бу көрәшнең нәтиҗәләре дә күркәм булды. Алар арасында: 1990 елның 30 августында Югары Советта Татарстанның суверенитеты турында декларация кабул ителү, 1991 елда мөстәкыйльлегебез символы — Татарстанның Президентын сайлау, 1992 елның язында Татарстанның суверенитеты буенча үткәрелгән референдумда сайлаучыларның зур күпчелегенең республиканың мөстәкыйльлеген яклап тавыш бирүе, шушы ук елның көзендә Татарстанның Конституциясе кабул ителү. Шул ук вакытта Русия үткәргән референдумнар Татарстанда өзелделәр, җөмһүриятебез халкы Русия Президентын сайлауларда да катнашмады.

Болар халкыбызның милли азатлыкка бару юлындагы олы җиңүләре иде. Әмма бу җиңүләрдән соң милли хәрәкәт акрынлап үзенең позицияләрен югалта башлады, сүлпәнләнде, яңа шартларда халыкны яңа көрәшкә туплардай яңа шигарьләр күтәрә алмады, ә 1995 елны 17 декабрендә уздырылган Русия сайлауларына инде бөтенләй кыйбласын югалтып килде. Бер яктан милли хәрәкәткә мөнәсәбәте булган оешмалар бу сайлауларга бойкот игълан иттеләр, ә икенче яктан милли хәрәкәтнең аерым вәкилләре, үзләрен «Нур» мөселман җәмгыяте исемлегенә кертеп, думага үтү өчен актив көрәш алып бардылар. Милли хәрәкәтнең мондый каршылыклы адымнары сайлаучыларны аптырашка салмый калмады.

Милли хәрәкәтнең мондый хәлгә төшүенең сәбәпләре кайда соң?

1. Бу сәбәпләр арасында, беренче чиратта, милли хәрәкәтнең үзендәге таркаулык, аның төрле төркемнәре арасында бердәмлек булмау, ә лидерлары арасында үзара каршылыклар, амби-

циячелек, һәркайсының үз позициясен абсолютлаштыруы, бер-берсен тыңлый белмәве һәм тыңларга теләмәве күзгә ташлана. Шушындый сәбәпләр милли хәрәкәтне эчтән кимерделәр дә.

Югыйсә, безнең күз алдыбызда тарихыбызның ачы сабаклары да ярылып ята иде. Билгеле булганча, без дәүләте булган халык. Безнең бабаларыбыз инде X гасырда ук үз дәүләтләрен — Идел Болгарстанын төзиләр һәм бу дәүләт икътисади, сәяси, рухи-мәдәни үсеше белән тарихта үзенә лаеклы урын алып тора. Соңыннан Ауропаның көнчыгышында оешкан Алтын Урда дәүләтен төзүдә һәм аның үсешендә дә безнең халкыбыз үз өлешен кертте. Ахыр килеп, Ш.Мәрҗани әйткәнчә, борынгы Болгар дәүләтенең варисы буларак, Казан ханлыгы барлыкка килде. Ул да заманында чәчәк аткан дәүләтләрдән иде.

Әмма халкыбыз үз дәүләтен саклый алмады, урыс илбасарлары белән озын, озак елларга сузылган көрәштә җиңелде, 1552 елны үзенең мөстәкыйльлеген югалтты. Бу җиңелүнең төп сәбәбе — эчке таркаулык, бердәмлек булмау. Кабиләдәшләребезнең бер өлеше турыдан-туры урыс гаскәрләре сафларында булып, Казан өстенә ябырылдылар, ә икенчеләре эчтән җимерү эше алып бардылар. Нәтиҗәдә, халкыбызның фидакарь затлары авыр көрәштә үзләренең башларын салды. Казан егылды.

1917—18 революция елларында да халкыбыз үзенең мөстәкыйльлеген яулауга бик якын килгән иде. Бу очракта да шул ук таркаулык, үзара аңлашып, кулга-кул тотынышып эш итә белмәү үзенең эшен эшләде. Шуның аркасында бу көрәштә дә халкыбызның бик күп асыл уллары егылып калды, ә үзебез Русиянең идарәче даирәләре вәгъдә иткән алдавыч — һичнинди реаль эчтәлеге булмаган өтек автономия белән канәгатьләнеп калдык.

Хәзер дә шул кабатлана. Тарихның ачы сабакларын онытабыз. Аз гына җиңү чаткылары күренү белән, бу очракта да милли хәрәкәт лидерлары арасында ыгы-зыгы башланды. Һәркайсы үзенең көрәштәшләрен бер якка тибеп, өскә калкып чыгарга, үзенең карашларын башкаларга тагарга тырыша башлады. Бер-беренә хөрмәт кирәклеге онытылды. Менә халкыбызның милли бәйсезлеге өчен аяусыз көрәшкә ташланган фидая бер кызы. Ул көрәшнең алгы сафында булды һәм аның төрле юлларын кулланды: митингларда, парламент трибуналарында, вакытлы матбугат битләрендә халкыбыз хакын хаклап ясаган кайнар чыгышлар. Ирек мәйданында ике атна дәвамында ач торулар моның кайбер мисаллары гына. Ул бу эшкә саф йөрәктән

барды. Аның өстенә кара көчләр ябырылды. «Вечерняя Казань» битләреннән аңа бер-бер артлы пычрак атылды, ялалар ягылды. Аны төрле яктан, төрле юллар белән мәсхәрәләделәр. Ә милли хәрәкәттә ул үзенә яклау таба алмады. Аның өстенә ташланган пычракның урынсыз икәнлеген әйтеп беркем авызын ачмады. Киресенчә, милли хәрәкәттә катнашучылар арасыннан әзмәвердәй 3—4 ир-егет, булмаган гаепләр табып, аңа ябырылдылар. Мин әйтелгән ханымны тулысынча акларга теләмим. Ул да хатадан хали түгел. Аның эш-гамәлләрендә һәм чыгышларында да артык кискенлек, килешмәүчәнлек күзәтелә. Әмма халкыбыз хакын хаклап ясаган чыгышларында һәм гамәлләрендә аның эчкерсезлеген, барысына да ихлас күңелдән баруын күрергә мөмкин иде.

Бу бер генә мисал. Ә моңа охшаш мисаллар соңгы елларда байтак күзәтелде. Менә шулар татар милли хәрәкәтен бүгенге авыр хәлгә куйдылар да.

2. Милли хәрәкәтнең йомшаруына китергән сәбәпләрнең икенчесе — милли-азатлык өчен көрәшкә тартылган көчләрнең сыек булуы. 1990—92 елларда милли хәрәкәт кысаларында үткәрелгән митингларга һәм башка гамәлләргә 50—60 меңнәргә кадәр милләттәшләребез катнашуы очраклары күзәтелде. Әмма бу халыкның өске катламы гына иде. Аның тирәнрәк катламнары милли хәрәкәт үткәргән акцияләрдән читтәрәк торды. 400дән артык елларга сузылган милли-колониаль изү бездә милли аңны бик нык зәгыйфьләндерде. Халык ничек итеп көн күрү, балаларын киендерү-туендыру уе белән яшәргә дучар ителде. Милли тормышның тирәнрәк нигезләре турында уйларга аның вакыты да, мөмкинлеге дә калмады. Күбәүләрдә милли үзенчәлекләр мәсьәләсе бары сиземләү рәвешендә генә сакланып калды. Күп гасырларга сузылган милли изүгә һәм чукындыру сәясәтенә карамастан, халкыбыз үзен саклап кала алды. Монда хәлиткеч рольне ислам, телебез, үзенчәлекле аһәңле моң-җырларыбыз уйнады. Аның аңыннан этник тамырлары һәм тарихы, бай мәдәни мирасы, милли рухи-әхлакый кыйммәтләре һәртөрле юллар белән кысрыкланды. Шуңа да карамастан, милли моң, милли тел аны күренмәстәй җепләр белән бәйләп торды, ә ислам бу бәйләнешне ныгытты.

Вафирә Гыйззәтуллинаның авылларда гастрольләрдә йөреп кайтканнан соң бер митингта ачынып сөйләгән чыгышы хәтердә калган. Милләт җанлы бу зат үзенең җырларын сәяси

чакырулар белән катнаштырып алып бара. Шул чак тамашачылар аңа безнең, шөкер, тамагыбыз тук, балаларыбыз исәнимин, өсләре бөтен, сәясәт белән башны катырып йөрмәгез, без монда концерт тыңларга килдек, дип дәгъва белдерәләр. Бу очракта күбәүләрнөң милләт проблемасын нинди сай аңлаулары ачык чагыла. Алар үзләренең яшәешләре белән канәгать, милли моң-җырлар аларның рухи ихтыяҗларын да канәгатьләндерә. Аларның милләтне, аның ихтыяҗларын аңлау шуннан узмаган: халыкның милләт буларак яшәеше, язмышы һәм киләчәге аларны әлегә борчуга салмый.

Аннары суверенлык игълан ителү. Конституция кабул ителү, Татарстанның мөстәкыйльлеге мәсьәләсе референдумда уңай хәл ителү дә күбәүләр тарафыннан максатка ирешү дип кабул ителде. Бусы да халыкның милли яшәеш проблемаларын бөтен тирәнлеге белән аңлап бетермәве белән бәйләнгән иде. Шуның өстенә милли хәрәкәт үз сафларына татар зыялыларының да киң катламнарын тарта алмады.

Әйтелгәннәр, билгеле, милли хәрәкәтнең көч җыюына комачауламый калмадылар.

3. Милли хәрәкәтнең сүнүенә, йомшаруына хакимият тә үзенең өлешен кертте. Мәгълүм булганча, Чаллылар милли күтәрелешнең алгы сафында бардылар. Казанда милли бәйсезлекне яклау акцияләре уздырылганда, алар автомашиналарга төялеп, башкалага юл тоталар иде. Әмма юк-бар сәбәпләр табып, юлда алар милиция тарафыннан тоткарланалар һәм үткәрелә торган акциягә вакытында килеп җитә алмыйлар. Бөтендөнья татар конгрессы башлануга әзерлек көннәре. Башлыча яшьләрдән торган «Намус» фиркасы әгъзалары, ачлык игълан итеп, Ирек мәйданында палаткаларга урнашалар. Академия театрында тантаналы җыелыш бара. Нәкъ шул вакыт милиция отряды килеп, ачлык игълан иткән яшьләрне чолгап ала һәм көчләп үз идарәләренә алып китә, ә анда тоткарланучылар белән тиешле эш үткәрелә. Милли хәрәкәтнең бер төркем активистлары Әлмәттә үткәрелгән бер акциядән соң машиналарда Казанга кайтып киләләр һәм Сорочие Горы кичүендә аларны кыйнау оештырыла. Көтмәгәндә Татар иҗтимагый үзәгенең рәисе Әһлиуллин кулга алына һәм төрмәгә ябып куела. Тикшерүләр. Суд. Соңыннан Әһлиуллин төрмәдән чыгарыла. Шулай да хакимият максатына ирешә: Татар иҗтимагый

үзәге сафларына таркаулык индерелә. Болар милли хәрәкәтнең ничек тукмаклануын күрсәтүче кайбер мисаллар гына. Ә аларга охшаш хәлләр күп күзәтелә һәм алар милли хәрәкәтне зәгыйфьләндерүдә, аның сафларына апатия индерүдә һәм таркаулык тенденцияләре сеңүдә һичшиксез үз рольләрен үтәделәр.

4. Милли хәрәкәт вәкилләре белән сөйләшкәндә алар дүртенче сәбәпне дә күрсәтәләр — монысы мәгълүм органнарның тыкшынуы, астыртын җимерү эше алып баруы. Урыс империясенең бу яктан зур тәҗрибәсе бар. Ул «бүлгәлә дә хакимлек ит» дигән илбасарлык принцибын гасырлар дәвамында бик уңышлы куллана килде. Казан ханлыгына каршы көрәштә дә илбасарлар бу ысулга бик актив мөрәҗәгать иттеләр. Мөдһиш Иван дәүләтебезгә каршы соңгы походына чыкканчы, аның шымчылары Казанда киң фронтлы җимерү эше алып бардылар, дәүләтебезне эчтән таркату чарасын күрделәр, милли көчләрнең аерым төркемнәрен бер-берсенә каршы куя алдылар һәм бу урыс патшасына максатына ирешүне җиңелләштерде. Моңа охшаш мисалларны хәзерге заман тарихы да җитәрлек бирә. Менә 1968 елгы Чехословакия вакыйгалары. Бу илгә турыдан-туры гаскәр керткәнче советлар Русиясенең идарәче даирәләре аның эчендә дәвамлы һәм эзлекле таркату эше алып бардылар һәм шул юл белән танк колоннанарына юл әрчеделәр. Үз вакытында газеталарда шуңа охшашлы акцияләрнең Балтыйк буе республикаларында үткәрелүе турында да җитәрлек язылды. Һәм, ниһаять, Чечня. Бу ил халкына каршы эш иткәндә сатлык җан Авторхановлар, Хадҗиевлар Русия җитәкчелеге кулында курчак ролен үтәделәр һәм пычрак сәясәт коралы булдылар. Шушы бәндәләр һәм аларның иярченнәре ярдәмендә Русиянең иминлек органнары Ичкерияне эчтән таркатырга тырыштылар һәм тырышалар.

Мондый эшчәнлек Татарстанга карата да үткәрелмәде, дип без әйтә алмыйбыз. Ләкин мин монда мәсьәләнең икенче ягына да — үзебезгә дә игътибарны юнәлтер идем. Әгәр арабызга шымчылар үтеп кереп таркаулык орлыклары чәчә алганнар икән, димәк, милли хәрәкәтнең сафларында уяулык җитмәгән, аның лидерлары коткыга җиңел бирелгәннәр, каршы көчләрнең арабызга үтеп керүенә киртә сала алмаганнар. Бу исә милли хәрәкәт сафларында таркаулык тенденцияләре җәелүдә һичшиксез үзенең ролен уйнады.

Шушы сәбәпләрнең җәмгысы милли хәрәкәтнең көчсезләнүенә, кабынып китеп тә тиз генә сүнүе һәм сүлпәнләнүенә үзләренең өлешләрен кертми калмадылар.

Милли хәрәкәтнең мондый хәлдә калуы аяныч күренеш. Халкыбыз милли хәрәкәт күтәрелгәч калкып чыккан проблемаларны ахырынача чишүдән әле бик ерак тора. Үзебезнең суверенлыгыбыз турында декларация кабул итсәк тә, без әлегә реаль суверенитетка, реаль мөстәкыйльлеккә ирешә алганыбыз юк. Бу юнәлештә бары аерым адымнар гына ясый алдык. Җөмһүриятебезнең суверенитетын реализацияләү империячел көчләрнең зур каршылыгына очрый. «Бердәм һәм бүленмәс Русия» һәм «держава» идеяләрен маяк итеп алып, алар кайчандыр Русия империясе үзенә буйсындырган халыкларны киләчәктә дә үз табаннары астында калдыру өчен бөтенесенә дә, шул хисаптан Чечнядәге кебек канкоешларга һәм җимерүләргә дә барырга әзерләр.

Безнең суверенитет юлына басуыбыз, билгеле булганча, СССРның таркалуы тудырган тенденцияләрнең Русиягә үтеп керүе шартларында барды. Империя идеясе тарафдары булган Свердловок өлкәсе губернаторы Э.Россель моңа юл куюны Русия житәкчелегенең зур хатасы дип саный. Аның фикеренчә, 1993 елны Мәскәүдәге Ак йортка пушкалардан атканда, милли республикалар белән дә араны өзеп, губерналар системасына күчәргә кирәк иде. Әмма бу уңай вакыт кулдан ычкындырылды. Хәзер инде икенче шундый моментны көтәргә кирәк. Андый момент киләчәк һәм аңа кадәр максатны тормышка ашырырга юнәлдерелгән яңа вариант дежурда торырга тиеш. Ә максат — милли республикаларны бетереп губерналар системасына күчү («Аргументы и факты», 1995, №42).

Бу белдерүдә державачыл көчләрнең стратегиясе ачык чагыла. Бердәм һәм бүленмәс Рәсәй тарафдарлары, нинди генә битлек кимәсеннәр, шушы максатны күз алдында тотып эш иттеләр. Менә урыс милли хәрәкәте лидеры А.П.Баркашовның «Азбука русского националиста» дигән хезмәте. Анда ачыктан-ачык урыс бөтен дөньяда хакимлек итәргә, ә башка милләтләр аның табаны астында яшәргә тиеш, дигән идея үткәрелә. Яки менә В.Жириновскийның «Известия»дә басылган (1994 ел, 23 апреле) «Русиянең жыю роле һәм яшь бүреләр турында» дигән мәкаләсе. Анынча, төп максат — Русияне 1900 елгы чикләрендә торгызу һәм ахыр чиктә Һинд океанына чыгу. Моның өчен Русия хакимияте 6 ыргылыш ясарга тиеш. Бу

ыргылышларның дүртенчесе — автономияләрне бетерү һәм илне губерналарга бүлү. Бу язмалар урыс шовинизмының асыл максатын ачыктан-ачык күрсәтеп торалар.

Бүгенге Русиядә бу рәвештә фикер йөртүче көчләр житәрлек. Әле 1991 елда ук илдә «Рус гвардиясе», «Рус милли партиясе», «Рус хәбәрләре партиясе», «Рус партиясе», «Русия милли җыелышы», «Яшь Русия», «Рус империясе союзы» кебек шовинистик рух белән сугарылган берләшмәләр һәм фиркаләр пәйдә булды һәм алар барысы да империяне элеккечә итеп торгызу юнәлешендә актив эш җәелдерделәр. Аларның маягы — «держава». Һәм бу идеягә тугрылык саклап, алар бөтенесен дә таптап китәргә әзерләр. Бер генә мисал. Дәүләт Думасының элекке рәисе И.Рыбкин «Вести»гә биргән интервьюсендә, мәсәлән, Чечня вариантының Татарстан белән Башкортстанга карата да кулланылуы мөмкинлеген ачыктан-ачык әйтеп салды.

Империячел идеология тарафдарлары еш кына максатларын турыдан-туры бәян итмичә, демократия битлеге киеп эш итәләр. Әмма боларның да эш-гамәлләре һәм шигарьләре «Бердәм һәм бүленмәс Русия» идеясе тирәсендә әйләнә.

Менә безнең кайбер күренекле лидерларыбыз якынаерга теләгән «Рус общиналары конгрессы» җитәкчеләреннән берсе генерал Лебедь. Ул Русия хакимиятенең Чечнядәге сәясәтен гаепли, әмма чечен халкына яудырылган җәбер-золымы өчен түгел, ә сәясәтне үткәрә белмәгән өчен. 1995 елның 22 декабрендә «Вести»гә биргән интервьюсендә ул «чеченнар белән операцияне болай сузарга ярамый, бары тик ике генә мәртәбә бәрергә кирәк иде: беренче мәртәбә — башларына, ә икенчесендә — табутларына», — дип белдерде. Ә «демократ» битлеге кигән Б.Федоров Казан өстенә Русия флагын элү турында хыяллана. Боларның һәркайсы Э.Россель әйткән уңайлы вакытны көтеп кенә тора. Андый ситуация туу белән, алар милли республикалар белән ахырынача хисаплашырга әзерләр.

Инде хәзер үк милли республикаларның суверенитетына каршы киң планлы һөҗүм алып барыла (дөрес, бу һөҗүмнең суверенлашу процессы башланганнан бирле тынып торганы юк). Әйтелгән һөҗүмне хәзергә беркадәр урау юллар аша җәелдерү тактикасы кулланыла. Бу урау юлларының берсе — республикаларны өлкә, крайлар белән тигез хәлгә кую. Вакытлы матбугат битләрендә, радио-телевидениедә яңгыраган чы-

10 3-473

гышларда бу идея һаман-һаман кабатланып тора. Менә Федерация Советының яңа гына сайланган рәисе Е. Строев. Ул үзенең өстәле артына утырып та өлгермәде, Россиянең барлык субъектлары да — республикалар да, өлкәләр дә, крайлар да бертигез булырга тиешләр, дип оран салды. Моңа хас белдерүләр газета битләрендә, радио-телевидениедә еш яңгырыйлар. Суверенлашу процессында республикалар яулаган хокукларга каршы һөҗүмгә Русия Президенты аппараты да кушылды. Матбугатта яңгыраган мәгълүматларга караганда, бу аппарат кабинетларында субъектларның Конституцияләрендә Русия Конституциясенә булган каршылыкларны бетерү буенча комиссия төзелгән. Бу очракта да сүз милли республикаларның суверенлык хокукларын чикләү, аларның исемнәрен үзгәртмичә генә, өлкә-крайлар белән тигез хәлгә кую турында бара.

Өлкә-крайларны республикалар белән тигезләү кирәклеген дәлилләгәндә гадәттә икътисад проблемасы алгы планга чыгарыла. Ә шул ук вакытта милли республикаларның икътисадтан тыш әле милли яшәеш нигезендә туган интереслары да барлыгы бөтенләй читләтеп үтелә.

Суверен республикаларның хокукларын чикләүгә юнәлдерелгән чыгышларга яңа билгеләнгән чит ил эшләре министры Е.Примаков та кушылды. Шушы елның 23 гыйнварында телевизордагы чыгышында ул тышкы сәясәтне үзәкләштерү, аны чит ил эшләре министрлыгы аша гына үткәрү кирәклегенә басым ясады. Соңгы вакытларда безнең җитәкчеләребез, тышкы дөньяга мөстәкыйль рәвештә чыгабыз, дип күкрәк кагалар Ә менә Е.Примаков әфәнде фикеренчә, Русия субъектының чит илләр белән мөстәкыйль рәвештә мөнәсәбәткә керүләре Русияне таркатуга илтәчәк. Шуңа күрә дә мондый башбаштаклыкка юл куярга ярамый.

Бу шартларда милләт позициясендә торган көчләр алдына 1990 елның 30 августында билгеләнгән юлдан һичнинди тайпылышсыз алга бару, суверенитетыбызны ныгыту, аны реальләштерү чараларын күрү, мөстәкыйльлегебезне реаль эчтәлек белән тулыландыру өстендә туктаусыз эш алып бару бөтен кискенлеге белән килеп баса. Бу, үз чиратында, милли хәрәкәттән тарих биргән ачы сабакларны истә тотып үз сафларын ныгытуны, бердәмлекне тәэмин итү юнәлешендә түземле эш алып баруны, халкыбызның киләчәге турында уйлаучыларның барысын да бердәм көрәшкә туплауны таләп итә. Милли

хәрәкәттә катнашучылар арасында фикери аерымлыклар булуы мөмкин. Аларның һәркайсының үз тормышы тәҗрибәсе нигезендә формалашкан шәхси позициясе булуы да табигый хәл. Әмма монда бер нәрсәне онытмаска кирәк: милләт язмышы мәсьәләсе, аның киләчәге мәсьәләсе мондый шәхси позицияләрдән өстен тора. Сәяси көрәштә компромисс дигән нәрсә бар. Халкыбызның азатлыгы өчен көрәш юлына баскан көчләр, әгәр алар бу юлга чыннан да милләт язмышын күз алдында тотып баскан булсалар, шәхси позицияләрендә нинди генә аерымлыклар булмасын, бердәм эш итү өчен бер-берсенә каршы адымнар, якынаю адымнары ясарга һәм азатлыкка илтүче бердәм юл эзләргә тиешләр. Кызганычка каршы, татар милли хәрәкәтендә әлегә мондый омтылыш күзәтелми һәм бердәм эш итә алмау аны хәзерге авыр хәлгә куйды да.

Хәзерге милли хәрәкәт башлыча ике үзәк тирәсендә туплана. Бөтентатар иҗтимагый үзәге һәм «милли мәҗлес» белән «Иттифак» партиясе. Шушы ике үзәкнең бер-берсенә якынаюы — милли хәрәкәтнең бердәмлегенә ирешүдә хәлиткеч юл. Моның өчен идеологик нигез дә бар. Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең соңгы V корылтае милли хәрәкәтнең асыл максаты рәвешендә милли дәүләтчелекне торгызу идеясен күтәреп чыкты. Бу идея «милли мәҗлес»нең дә, «Иттифак» фиркасының да программ документлары нигезендә ята. Димәк, бу идея милли хәрәкәтнең төрле тармакларын берләштерүнең принципиаль нигезе дә була ала. Бары милли хәрәкәтнең лидерларына бер-берсенә кул сузасы гына кала. Моның өчен амбициячелектән арынырга гына, милләтнең глобаль интересларыннан чыгып эш итәргә генә кирәк.

Милли хәрәкәтнең ныклап тернәкләнеп китә һәм бердәм тупланып, дәвамлы көрәшкә тартыла алмавында аның сафларында үзенең биосоциаль һәм психологик сыйфатлары, акылыфигыле, интеллекты белән массаларны үзенә тартып торырдай харизматик куәсе булган лидерның үсеп чыга алмавы да үзенең ролен уйнады. Шундый лидер тәрбияләү милли хәрәкәтнең мөһим бурычларыннан берсе. Ул үсеп чыксын өчен хәзерге милли хәрәкәтнең башында торучыларның бер-берсенә аерата игътибарлы һәм ихтирамлы булулары, бер-берсенең үсешенә комачауламаулары лазем. Кызганычка каршы, хәзерге милли хәрәкәттә үсеп килүче лидерны артык алга китмәсен өчен итәгеннән тартып тору күренешләре күзәтелә.

Безгә тарих биргән ачы сабакны идарәче даирәләрнең дә истән чыгармавы хәерле булыр иде. Милли хәрәкәт, әгәр ул үзенең бердәмлеген һәм оешканлыгын тәэмин итә алса, империя тарафдарларына каршы торырдай зур көч. Җөмһүриятебезнең идарәче даирәләре, әгәр алар аның бөтенлеген, иминлеген һәм мөстәкыйль киләчәген күз алдында тотып эш итәргә телиләр икән, империя тарафдарларына, держава идеясен алга сөргән шовинистларга каршы эш иткәндә бары шушы көчләргә генә таяна алалар. Моның шулай икәнлеген әле күптән түгел булып үткән вакыйгалар да ачык күрсәтә. 1991 елның август көннәрендә безнең хакимият, шул хисаптан Президентыбыз да, икеләнеп калды, ГКЧПга карата икеле-микеле белдерүләр ясады. Әмма ГКЧП җиңелде. Ил башына «демократлар» килде, һәм алар Президент М.Шәймиевне эзәрлекләү юлына бастылар. Мәскәүнең эмиссарлары аны кулга алып, Мәскәүгә озату нияте белән Казанга да килдедер. Әмма милли көчләр бердәм рәвештә аны яклап чыктылар һәм изоляцияләүгә юл куймадылар. Нәтиҗәдә, Мәскәү эмиссарлары Казаннан буш кул белән китәргә мәҗбүр булдылар.

Халкыбызның, җөмһүриятебезнең иминлеге, ирекле яшәеше һәм үсеше, империячел көчләрнең басымына каршы тора алуы өчен, хакимият белән милли хәрәкәтнең бер-берсенә таба җитди адымнар ясавы кирәк. Демократик җәмгыятьләрдә хакимияткә оппозиция булуы нормаль күренеш, аның хакимият тарафыннан кысрыклаусыз эш итә алуы чын демократизмның чагылышы. Оппозиция ирекле рәвештә эш итә алмаса, демократия дә була алмый. Әгәр Татарстаныбызны демократик дәүләт, хокукый дәүләт итеп күрергә телибез икән, хакимият оппозициянең формалашуына комачауламаска, киресенчә, бу процесска һәрьяклап ярдәм күрсәтергә тиеш.

Үз чиратында, оппозициянең дә конструктив булуы хәерле. Әгәр оппозиция бөтенесен кире кагу юлына басса, ул үзен хакимиятнең эш юнәлешенә тәэсир итә алудан да буш калдырачак. Дәүләтнең нормаль яши алуы һәм үсеше өчен хакимият белән оппозициянең диалогы һәм үзара компромисслар юлына басуы кирәк. Ә оппозициянең хакимият белән чын мәгънәсендә конструктив эш итә алуы өчен милли көчләрнең бердәмлеге зарури. Бу бердәмлек булмаса, хакимият милли хәрәкәтне санга сукмаячак.

Тагы бернәрсә ачык — халкыбызда милли аң үсми торып милли хәрәкәт тә тиешле колач җәя алмаячак, милли мөстәкыйльлеккә бару юлындагы асыл максатларыбызга да ирешә алмаячакбыз. Бер акыл иясе «үзенең ихтыяри ирегеН югалткан халык бер-бер артлы өч халәт кичерә: ачу-ярсу, курку һәм апатия-сүлпәнлөк. Апатия-сүлпәнлек никадәр озак дәвам итсә, ул шулкадәр үк халыкның рухын да тирәнрәк яралый һәм кимерә», дип әйтеп калдырган. Озакка сузылган коллык, милли изү, телне, динне, гореф-гадәтләрне кысу халкыбызны тирән апатиягә, рухи сүлпәнлеккә китереп ташлады. Шуның өчен милли хәрәкәтнең асыл бурычы, милли бәйсезлеккә бару максатын күздән төшермәгән хәлдә, беренче чиратта халыкны апатия баткаклыгыннан, рухи сүлпәнлектән, коллык психологиясеннән коткару. Шунсыз бәйсезлек даулаулар буш шау-шу гына булып калачак. Чөнки рухы сүнгән, үзенең милли асылын җуйган халык бәйсезлекне яулап ала да алмый. Яулаган тәкъдирдә дә аны саклап кала алмый. Рухи яктан изү — ул колониализмның иң нечкә күренеше. Шуңа күрә милли хәрәкәтнең асыл бурычы — халыкның милли аңын уяту, аңа тарихы булган, дәүләте булган милләт икәнлеген, теле, дине, гореф-гадәтләре һәм мәдәнияты булган милләт икәнлеген тирән төшендерү, аның уй-фикерләрен милләтнең мөстәкыйль киләчәге өчен көрәшкә юнәлдерү.

450 ел буе урыс коллыгында яшәү безнең фикери юнәлешебезне Мәскәүгә баглады. Без бөтенесен — яхшысын да, яманын да шуннан көтеп яшәргә өйрәндек. Соңгы елларда да, милли хәрәкәт күтәрелгәч тә, милли мөстәкыйльлекне Мәскәү үзе бирер дип көтүләр күзәтелде. Күбәүләр Ельцинның демократ булып кылануына ышандылар, башларыннан алып, аңа түбәтәйләрен дә кидерттеләр. Буш хыял. Моның шулай икәнен Русия хөкүмәтенең соңгы еллардагы сәясәте, бигрәк тә Чечня вакыйгалары ачык күрсәтте.

Мәскәүнең алдау-юлдауларыннан тәмам арыну, халыкның күзен тәмам ачу өчен безгә аның аңына милләт идеясен иңдерү зур әһәмияткә ия. Бу уңайдан безнең алга бөтен кискенлеге белән милли идеология мәсьәләсе килеп баса. Соңгы елларда матбугатта бу мәсьәләгә кагылышлы язмалар күренгәләп тора, аның төп контурлары да ачыклана бара. Татар милли идеологиясенең асыл сызыклары милләт идеясе, исламчылык һәм заманчылык төшенчәләре аша сузыла. Бу сызыклар инде билгеләнгән. Шулай да әле һәрьяктан нигезләнгән милли идеология форма-

лашып житмәгән. Моның өчен галимнәрнең — тел, тарих, мәдәният һәм әдәбият белгечләренең, философларның, әдипләрнең уртак тырышлыгы кирәк. Шуны аңларга кирәк ки, милли мәсләге булмаган халык, милләт идеясе белән коралланмаган халык, үзенең бәйсезлеген яулый алмый. Безнең күз алдыбызда тарихи мисаллар да бар: поляклар һәм финнар. Алар милли идеяне беренче планга куеп эш иттеләр һәм урыс империясенең тырнакларыннан ычкына алдылар.

Безнең халкыбыз таркалып урнашкан. Урыс колонизациясе процессында татарларның тарихи ватаннарына — Идел-Урал буйларына һәм көнбатыш Себергә урыслар һ.б. халыклар килеп утырды, ә татарлар үзләре алар арасында сибелеп-чәчелеп калдылар. Шуның белән бергә, алар милли кысрыклаулар аркасында үзләре дә ана-ватаннарын ташлап, Русиянең башка төбәкләренә һәм хәзерге БДБ илләренә дә барып төпләнделәр.

Милли хәрәкәт алдында, милләт идеясен алгы планга куеп, сибелгән-чәчелгән халкыбызны берләштерү, ул яши торган барлык төбәкләрдә дә милли аңны уяту, милли телне, милли мәдәниятны, динебезне торгызу һәм саклау бурычы тора. Ә бердәм һәм бүленмәс Русия тарафдарлары моңа теш-тырнаклары белән каршылар. Менә Русия Фәннәр академиясенең Этнография институты чыгарган «Этнография» исемле җыентык. «Необходимо обратить особое внимание на агитационнуо деятельность национальных партий Татарстана в среде татарской диаспоры в России и предпринять условия к ее прекращению», дип күрсәтелә бу документта. Моны Русия хөкүмәтенең официаль позициясе дип аңларга кирәк. Чөнки әйтелгән документның авторы Этнография институтының директоры В.Тишков. Ул озак кына еллар Русия хөкүмәтенең милли мәсьәләләр буенча Дәүләт комитеты рәисе булып та торды.Күренүенчә, Россиянең төрле почмакларына сибелеп яшәүче милләттәшләребез белән эшләү авыр булачак. Әмма ул безнең өчен аеруча әһәмиятле һәм зарури бер эш.

Шуның белән бергә, татар халкының тарихта тоткан урыны, ул яшәгән географик киңлек аның милли хәрәкәтенә Идел-Урал төбәгендә урнашкан барлык халыкларны бергә берләштерү юнәлешендә эш алып бару бурычын да йөкли. Колониализмга каршы көрәштә моның никадәр мөһим икәнлеген, соңга калып булса да, М.Солтангалиев тә аңлый алган иде. Аның изелгән халыкларны берләштерү өчен Колониаль Интернацио-

нал төзү юлында кылган эш-гамәлләре шул турыда сөйли. Ләкин ул бу эшне башлаганда инде вакыт узган иде. Ныгып өлгергән совет хакимияте һәм коммунистлар партиясе аның бу юнәлештәге эшчәнлегенә чик куйдылар. Бу ачы тәҗрибә истә тотылырга тиеш. Чөнки бәйсезлекне Русия империясенең тырнакларына эләккән барлык халыкларның да бердәм көрәше юлында гына яулап булачак.

Безнең максат — милли мөстәкыйльлеккә ирешү. Милләтләрнең мөстәкыйльлек алуы беркемгә дә янамый, һәр милләтнең үзенең милли тормышын үзенчә оештырырга тырышуы — аның табигый хокукы. Алла биргән хокукы. Милли мөстәкыйльлек үзенең эченә, беренче чиратта, тормышны үзең теләгәнчә коруны, милли яшәешне тәэмин итү мөмкинлеген ала. Ә милли яшәеш, үз чиратында, туган телдә аралашу, аны саклау һәм үстерү мөмкинлеген, үз динеңә инану мөмкинлеген, гореф-гадәтләрне саклау мөмкинлеген, милли мәдәниятны үстерү, ана телендә уку-укытуны, фән һәм техника казанышларын милли нигездә үзләштерү һәм үстерү мөмкинлеген күз алдында тота. Без бу максатка бердәм булсак кына, милли көчләребезне һәрдаим тулыландырып торсак кына ирешә алачакбыз.

1996 ел.

МИЛЛИ МОХИТ ҺӘМ МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ

Октябрьнең башында «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясендә милләт язмышына кагылышлы зур сөйләшү булды. Алда — XXI гасыр. Татар халкы аңа ни рәвешле аяк басар, анда аны нинди язмыш көтә? Бер төркем зыялыларыбыз түгәрәк өстәл әйләнәсенә урнашып шушы турыда сүз алып бардылар, бәхәс кордылар. Бәхәстә сүз башлыча татар теле, милли рухыбыз, милли аңны үстерү, татар милли идеясе тирәсендә барды һәм милләтне саклауда аларның югары роленә басым ясап күрсәтелде. Шул ук вакытта борчулы фикерләр дә әйтелде. Ә борчылырлык урын бар. Моны раслаучы фактлар әңгәмәдә катнашучыларның чыгышларында да яңгырады. Соңгы елларда татар егетләре-кызларының 40—42 процентны катнаш никахларга керә. Мондый никахка керүчеләрнең күпчелеген милләт өчен югалган дип санарга кала. Чөнки аларның балалары татар телен белми үсә, аларга милли аң иңдерелми, алар милли мәдәнияттан ерак торалар, халкыбызның гореф-гадәтлә-

реннән хәбәрсез, мәгълуматсыз булып үсәләр. Балалар гына түгел, олыларның да күпчелеге инде татар телендә начар сөйләшә, яки бөтенләй сөйләшми. Мәскәүдә яшәүче зыялы милләттәшебез Вахит Юныс үзенең бер мәкаләсендә мәскәүле татарларның 93 проценты туган телдә сөйләшә һәм укый белми, дип ачынып язды. Милли хәрәкәттә милли битарафлык күренешләренең киң таралуы, милләт ихтыяжларына игътибар җитмәү уңаеннан да борчылу авазлары яңгырап тора.

Әйтелгәннәр — кайбер фактлар гына, ә мондый фактларны күпләп китерергә мөмкин булыр иде. Шунысы ачык, алар җәмгысы татарның сафларын сыекландыра, аны акрынлап башка халыкларның казанында, башлыча урыс казанында, эретә бара.

Әйтелгән сөйләшүдә татарны бу афәттән коткару, милләтне инкыйраздан саклап калу юллары турында да сүз барды. Бу язмамда мин боларның сөйләшүдә телгә алынмаганы — милли мохит турындагы фикерләрем белән уртаклашырга телим. Заманының бөек мәгърифәтчеләре, «Кеше үзе яшәгән тирәлекнең җимеше», дигән канатлы сүз әйтеп калдырганнар. Үзебезнең күренекле мәгърифәтчебез К.Насыйри да кеше тәрбияләүдә ул яшәгән мохитның хәлиткеч роль уйнавын күз алдында тотып фикер йөртте. Татар кешесе, үзе үскән һәм яшәгән мохите милли булса гына, чын мәгънәсендә үз милләтенең вәкиле булып формалаша һәм яши ала. Аның милли йөзен милли мохит билгели. Дөрес, кеше Аллаһның мәхлугы. Әмма Аллаһ адәми затны яратканда аның асылына бетмәс-төкәнмәс мөмкинлекләр салган. Бу мөмкинлекләрнең кайсы реаль төс ала — бусы адәм баласының кемнәр тарафыннан ничек тәрбияләнүенә, ул үзе яшәгән тирәлектән алган тәэсирләренә бәйле. Шуңа күрә, милләтебез XXI гасырга үзенең киләчәгенә ышаныч белән керүен теләсәк, бүген милли мохитебез, аның татар баласын чын мәгънәсендә милләтпәрвәр итеп формалаштыра алырдай булуы турында кайгыртырга тиешбез.

Безнең бүгенге милли мохитебез моңа җавап бирәме соң? Бу сорауга җавап эзләгәндә милли мохитнең структурасын күз алдыннан үткәреп үтү максатка ярашлы булыр.

Адәм баласы яши, үсә, формалаша торган мохитнең иң беренче һәм иң мөһим катламы — гаилә. Гаиләдә баланың аңына беренче әхлакый төшенчәләр иңә, шунда аның дөньяга карашы формалаша башлый, шунда ул яхшыны яманнан аерырга өйрәнә, шунда аның күңеленә изгелек орлыклары чәчелә,

шунда ул изгелекне яманнан аерырга өйрәнә. Гаиләдә шәхеснең рухи йөзе формалаша башлый һәм шунда формалашкан төшенчәләр аның гомерлек юлдашына әйләнә. Туганлык-кардәшлек, кавем-милләт идеяләре дә аның аңына гаиләдә салына. Кызганыч ки, хәзерге татар гаиләсе баласының аңына милләт идеясе, аңа бирелгәнлек рухы иңдерә алудан әлегә ерак тора.

Элек-электән татар гаиләсе милли һәм дини нигездә формалашып яшәде. Анда балалар да дини һәм милли рухта тәрбияләнделәр. Ә соңгы 70—80 ел эчендәге интернациональләштерү процессы татар гаиләләрендәге милли һәм дини рухны астан да, өстән дә, эчтән дә кимерде. Гаилә миллилеген дә югалтты. Шуның белән бергә аның милләтебез өчен чит булган тенденцияләргә каршы торырдай иммунитеты да югалды. Нәтиҗәдә, татар егетләре һәм кызлары бик җиңел генә урыс-марҗа белән гаилә кору юлына бастылар, татар өчен чит булган эчүчелек таралды, зина кылу күренешләренә битарафлык атмосферасы тамыр җәйде, бер-береңә хыянәт итү һәм урлашу бик җиңел күренешкә әйләнде. Соңгы вакытларда газеталар татар егетләре һәм кызларының чукыну һәм тәре тагуы күренешләре турында да яза башладылар. Шулай итеп, үз милләтеннән, аның әхлакый нигезләреннән баш тарту гадәти күренешкә әйләнде.

Милләтебезне эчтән җимерә торган бу яман чир алдында бары яңадан торгызылган милли гаилә генә куәтле киртә була ала. Шуңа күрә киң җәмәгатьчелекнең кичектергесез бурычы — татар гаиләсен милли нигезләренә кайтару, аның яшәешен милли буразналарга салу. Гаиләдәге әхлакый мохит, андагы уй-фикерләр милли рух белән өретелгән булсалар, мондый гаиләләрдә үскән балаларга да милли сафлык, милләтне аңлау һәм аңа бирелгәнлек хас булыр.

Гаилә тәрбиясенең үзәгендә ана тора. Шуңа күрә бу гасырның башында тукайлар, әмирханнар, татар баласының мәгърифәтле анадан тууы, мәгърифәтле ана куенында үсүе-тәрбияләнүе турында хыялландылар. Алар татар халкының алга китүе, дөнья цивилизациясенең җимешләреннән файдалана алуы турында уйладылар һәм моңа ирешүдә мәгърифәтле ананың хәлиткеч ролен күрә алдылар. Бүгенге әхлакый баткаклык шартларында, халкыбыз яшәешенең милли нагезләре таркалуы шартларында без тукайлар, әмирханнар күтәргән мәгърифәтле ана төшенчәсен иманлы ана төшенчәсе белән тулыландырырга тиешбез. Хәзер безнең кызла-

рыбыз тормыш бусагасын фәннең нигезләрен күпмедер күләмдә үзләштереп атлыйлар. Әмма алар замана балалары һәм заманабызга хас әхлакый югалтуларга да дучар ителгәннәр. Шуңа күрә гаиләдә кыз балаларны халкыбызга хас әхлакый сафлык, камиллек, түземлелек, сабырлык, мәрхәмәт, шәфкать һәм олы мәхәббәт принциплары нигезендә тәрбияли алсак, аларның аңына иман нуры, ислам нуры иңдерә алсак, әлбәттә, милләт улларын һәм кызларын тәрбияләүдә мөһим эш эшләгән булыр идек.

Ана балалар тәрбияләүдә үзенең бурычын үти алсын өчен аның хәзерге җәмгыятьтәге һәм гаиләдәге хәленең тамырдан үзгәртелүе дә мөһим шартларның берсе. Совет хакимияте чорында хатын-кызны җитештерү сферасына тарту сәясәте үткәрелде. Бу сәясәт хатын-кыз азатлыгы идеясе, аның эмансипациясе байрагы астында үткәрелде. Коммунистик идеология бу җәһәттән максатына иреште: хәзерге хатын-кыз җитештерү сферасына баша-ягы белән чумган, шуның өстенә ул актив җәмәгать эшлеклесе дә, Хатын-кызның азатлык өчен көрәштәге бу казанышлары гаилә бәйләнешләрен йомшарту белән параллель рәвештә үсте. Шуның белән беррәттән ир-егетләрне гаилә алдындагы бурычларыннан азат итү процессы да барды. Элек гаиләнең эчке тормышы хатын-кыз кулында иде. Ә ир заты гаилә тормышының материаль нигезен тәэмин итүне үз өстенә алды. Ул эшләде, мал тапты, шуның белән гаилә тормышының авыр йөген тартып барды. Шул ук вакытта балалар өчен дә ул мораль авторитет булып торды. Балалар аңа карап үстеләр, әниләре моны куәтләп торды. Ә хәзерге ирләр боларның барысыннан да азат. Аларның күпчелеге җитештерү сферасында эшләп кайта да диванга тәгәрәп, телевизор карый. Ә күбәүләр бу вазыйфаны эчүчелек белән баеталар. Ә хатын-кыз исә җитештерү сферасында ирләр белән бер сафта эшләп өенә кайтышлый, кибетләргә кереп ашамлык җыя, балалар бакчасына кереп, баласын да алып чыга. Ике кулында ике сумка, тагы баласын җитәкләгән. Өйгә кайткач, аш-су пешерергә, исерек ирен карарга да кирәк. Болар «эмансипация» җимешләре. Гаиләне мондый «эмансипациядән» коткарырга, анда нормаль эш бүленеше, ир белән хатын арасында нормаль мөнәсәбәтләр урнаштырырга кирәк. Шул чакта гына татар гаиләсе милли рухта тәрбияләнгән яңа буын үстерүдә үзенең изге бурычын үти алаячак.

Кеше формалаша торган мохитның икенче мөһим катламы — мәктәп, уку-укыту системасы. Ул үз эченә балалар бакчаларын, гомуми белем мәктәпләрен, һөнәри уку йортларын, махсус урта уку йортларын һәм югары уку йортларын ала. Кеше аларда шәхес булып формалашу процессы үтә, фән һәм мәдәният нигезләрен үзләштерә, гаиләдә башланган әхлакый тәрбия шунда дәвам иттерелә. Мәктәп эшчәнлеге милли рух белән сугарылган булса, аның диварларыннан миллилек аңкып торса, ул милләт уллары һәм кызларында миллилек тәрбияләүдә хәлиткеч роль уйный ала. Әмма безнең уку йортларыбызга һәм тәрбия учакларыбызга ни дәрәҗәдә миллилек иңдерелгән соң? Аларда ни дәрәҗәдә милли мохит тудырылган?

Балалар бакчасыннан башлыйк. Бәхәссез, соңгы елларда татар балалар бакчаларының һәм аларда тәрбияләнүчеләрнең саны артты. Татарстан Мәгариф министры урынбасары Г.Садриев китергән мәгълүматларга караганда, хәзер мәктәпкәчә яшьтәге татар балаларының 62,4 проценты татар балалар бакчаларында һәм катнаш бакчаларның татар группаларында тәрбияләнә («Ватаным Татарстан», 1996 ел, 15 октябрь). Димәк, татар балаларының 37,6 проценты урыс балалар бакчаларында тәрбияләнүен дәвам итә, урыс мохитенең тәэсирендә формалаша башлый. Татар группаларында тәрбияләнүче балалар да катнаш бакчаларда, урыс мохите хакимлеге шартларында үсәләр һәм урыс тәрбиясе алалар. Димәк, без сабыйларыбызның зур күпчелеген үз мохитебездә үзебезчә милли рухта тәрбияләүдән әлегә ерак торабыз. Мәктәпләр белән дә, шуннан ерак китә алганыбыз юк. Дөрес, соңгы елларда байтак кына татар мәктәпләре һәм гимназияләре ачылды, аларның күбесендә күпмедер дәрәҗәдә татар мохите тудырылган һәм милли рух индерелгән. Министрлар Кабинеты рәисе Ф.Мөхәммәтшин «Мәгариф» журналының 1 санында, татар балаларының 43 проценты ана телендә белем һәм тәрбия ала, дип язды. 43 процент. Ә татар балаларының калган өлеше, димәк, зур күпчелеге урыс мәктәбендә укый, урыс мохитендә тәрбияләнә. Бу — Татарстанда. Ә Татарстаннан читтә татар балалары баштанаяк урыс мохитенә чумып кала.

Рәсми мәгълүматларга караганда, Татарстанда 1136 татар мәктәбе эшли. Әмма аларның күпчелеге чын мәгънәсендә татар мәктәбеме — бу турыда саннар китерелми. Ә менә И.Баһавиев «Ватаным Татарстан»ның 1996 елның 5 апрелендә

басылган «Түземлелекнең дә чиге була» дигән мәкаләсендә шундый гыйбрәтле фактлар китерә: Әлмәт шәһәрендә 4 татар мәктәбе бар, дип исәпләнә. Әмма аларның бары икесен генә купмедер күләмдә татар мәктәбе дип санарга мөмкин. Калганнарында исә бары 1—2 башлангыч сыйныфларда гына татарча укытыла. Соңгы вакытларда урыс телле татар мәктәпләре тамыр җәйде. Татар теле тирәнрәк өйрәтелсә, башка фәннәр урысча укытылса да, ул мәктәпләр татар мәктәбе дип саналалар. Мондый мәктәпләрдә урыс мохите хакимлек итә. Һәм балалар шуның тәэсирен татып үсәләр.

Татар мәктәпләре беркадәр җанлана башлагач, бу процессны авызлыклау максатында идарәче даирәләр урыс-татар мәктәбе идеясе күтәреп чыктылар. Хәзер күп кенә татар балалары шушындый мәктәпләрдә укый һәм тәрбияләнә. Урыс мохите хакимлек иткән мәктәпләрдә. Озак еллар буе шушындый катнаш мәктәпләрдә укытучы-тәрбияче булып эшләгән мөгаллим Мәсгут Юнысов алар эшчәнлегенең ачы нәтиҗәләре турында болай дип язды: «Мәктәбебез катнаш мәктәп иде. Укыту-тәрбия эшләре башлыча урыс телендә алып барылды. Мондый типтагы мәктәпләрдә татар баласының рухы гарипләнүенең җанлы шаһите булдым» («Ватаным Татарстан», 1996, 13 август).

Югары уку йортларында хәл тагы да мөшкелрәк. Россия белән шартнамә төзегәндә алар аның карамагында калдырылды. Аларда Түбән Новгород яисә Омск югары уку йортларындагы кебек атмосфера хакимлек итә. Мәскәү төзегән программалар нигезендә, шунда тәгаенләнгән фәннәр укытыла. Ә алар урыс рухы белән сугарылганнар. Югары уку йортының көндәлек тормышында шул ук атмосфера. Татар баласы аларга үтеп керә алса, урыслык атмосферасын татып яшәргә мәҗбүр. Үтеп керә алса?! Татар мәктәбен бетергән татар егет-кызларына анда үтеп керүе дә җиңелләрдән түгел. Журналист А.Филиппов «Ватаным Татарстан»ның 1996 елгы 4 июнь санында өч татар егетенең ничек итеп Казан югары уку йортларының бусагаларын таптауларын ачынып язды. Шәфикъ, Мәлс һәм Хәниф өчесе дә авылда татар мәктәбен тәмамлыйлар. Мәктәптә яхшы укыйлар. Өчесе дә Казандагы өч югары уку йортына гариза бирәләр. Һәрберсендә беренче имтихан — урыс теленнән инша. Моңарчы урыс кешесен күрмәгән авыл малайлары өчен бу имтихан үтә алмастай киртә булып чыга. Казан вузларында бу татар егетләренең урынын чит өлкәләрдән килгән егетләр һәм кызлар яулый.

Татар милли хәрәкәтенең Казанда милли университетны ачу идеясен күтәреп чыгуына инде берничә ел үтте. Ләкин милли университет ачуга бәйләнешле тәкъдимнәр идарәче даирәләрдә хуплау тапмады. Ахыр чиктә милли хәрәкәтнең актив көчләре тырышлыгы белән милли университет җәмәгать тәртибендә оештырылды. Студентлар тупланды. Милләтпәрвәр галимнәр һичнинди түләүсез аның эшен башлап җибәрделәр. Әмма бу да хакимияттә яклау тапмады. Хакимият даирәләре милли университетны рәсмиләштермәделәр. Милли университет идеясен күмү өчен идарәче даирәләр Казан дәүләт университеты каршында Татар гуманитар институты ачу тәкъдиме белән чактылар. Нигә гуманитар гына? Шуның өстенә Казан дәүләт университетында гуманитар профильдә татар филологиясе һәм тарихы факультеты бар бит. Андый факультет Казан педагогия университетында да бар. Ары китеп, Казан дәүләт университетында Гуманитар институт булдыру турында карар да кабул ителде, әмма аның әлегәчә ачылганы юк. Төрле сәбәпләр табыла. Шуларның берсе — бина юк. Ә шул ук вакытта инде яшәп килә торган югары уку йортлары профилендә үк түләүле университетлар ачыла тора. Бинасы да табыла, башкасы да.

Әйтелгәннәр Татар гуманитар институтын ачу турындагы карарның, инде әйтелгәнчә, милли университет идеясен күмү өчен уйлап табылган уен гына булганлыгын раслый. Университет — универсаль югары уку йорты. Ул үз эченә бөген фәннәрне, шул хисаптан физика-математика фәннәрен дә, табигать белемен дә ала. Әгәр татар милләте хәзерге дөнья цивилизациясе югарылыгында атлый алсын дисәк, күп профильле милли университет һичшиксез кирәк. Шунсыз татар мәдәнияты, шул хисаптан аның теле дә хәзерге дөнья мәдәнияты дәрәҗәсендә үсә алмаячак. Татар теле терминнары үсешен генә алыйк. Ул хәзерге фәннәр татар телендә укытылса гына үсә ала. Хакимият даирәләре моны теләмәде. Аның кайбер вәкилләре бу турыда ачыктан-ачык әйттеләр. Янәсе, табигать һәм физика-математика фәннәрен татар телендә укытуның кирәге юк, аны алар урыс югары уку йортларында өйрәнә алалар. Бу — Мәскәү белән конфликтка кермичә, тыныч кына хакимлек итәргә тырышуның чагылышы. Әмма бу тенденция милләтне, аның язмышын урыс арбасына бәйләп куя. Моның дәвам иттерелүе — татар кешесе формалашуында мөһим роль уйнардай бер буынның өзелүе дигән сүз.

Милли мохитнең зур әһәмияткә ия булган тагы бер катламы — информация кыры (информационное поле). Ул үз эченә барлык информация чараларын, беренче читратта газета-журналларны һәм радио-телевидениене ала. Алар барысы да хәзерге дөньяда кешенең аңы формалашуга көчле йогынты ясыйлар. Әмма тулысынча милли дип әйтә алабызмы соң без аларны? Милли мохит тудырырга алар ни дәрәҗәдә хезмәт итәләр? Болар арасында милли рух иң нык сизелеп торганы — кайбер газета-журналлар. Соңгы елларда алар яхшы ук миллиләштеләр. Милләт кайгысы кайгыртып язган мәкаләләрне аларда еш кына күрергә мөмкин. Шулай да, аларны әле тулысынча милли дип әйтеп булмый. Дистәләгән еллар буе алар интернационализм идеологиясе калпагы астында яшәделәр. Һәм бу идеология аларда нык тамыр җәйде. Газета-журналларыбыз никадәр генә тыпырчынсалар да интернационализм капкынынннан әлегә тәмам арына алганнары юк.

Радио-телевидениедә эш тагы да мөшкелрәк. Иртән торып радио борасың. Аннан чиратлашып урыс һәм татар телләрендә татар тормышына аз бәйләнешле хәбәрләр яңгырый башлый. Шулай ук чиратлаштырып ике телдә дә музыкаль тапшырулар, игъланнар. Радиода эшләүче иптәшләребез, күрәсең, татарча әйтелгән һәр фразаның эквиваленты урысча да әйтелмәсә, дөнья җимерелер дип куркалар. Югыйсә, Мәскәү көне буена урысча берничә программада тапшыру алып бара бит. Нигә Татарстан радиосы татар телендә көне буена ичмаса бер программада тапшырулар алып бара алмый?

Телевидение белән дә шул ук хәл. Татарстан телевидениесе көненә 5—6 сәгать чамасы тапшырулар алып бара. Көн саен аның кимендә яртысы урысча булыр. Ә икенче канал — «Эфир» исә көнозын урысча сөйли. Шуның өстенә Казанда 6—7 каналда Мәскәү белән Петербург тапшыруларын карарга мөмкин. Шулай итеп, татар тәүлек буе урыс радио-телевидениесе тәэсирендә яшәргә мәҗбүр ителә. Казан телевидениесенең көненә 2—3 сәгать дәвам иткән татарча тапшырулары да милли проблемалардан ерак тора. Аларда башлыча интернационализм рухы белән сугарылган официаль информация яңгырый. Милли хәрәкәт көчәеп киткән вакытта телевизор экраннарында ара-тирә аның вәкилләре дә күренгәли иде. Хәзер алар телевидениегә якын да китерелмиләр. Бик сирәк кенә экранда

милләт позициясендә торган депутатларыбыз гына күренгәләп ала. Ләкин бик сирәк. Татарстаннан читтә яшәгән милләттәшләребез исә бу тапшырулардан да мәхрүмнәр.

Информация кырыбызның камиллеге турыдан-туры нинди язу куллануыбыз белән дә бәйләнгән. Язуыбыз рәвеше — милли мохитебезнең аерылгысыз өлеше. Ислам белән бергә безнең бабаларыбыз инде унбер гасырдан артыграк чорда ук гарәп язуын кабул итәләр. Шушы язу белән бәйле рәвештә безнең мәдәниятебез үсә, әдәби ядкарьләребез туа. Гарәп язуы белән инде борынгы бабаларыбыз фәнни-фәлсәфи әсәрләрен дә язалар. Советлар хакимияте урнашкач, идарәче даирәләр безне бу мирасыбыздан аеру чарасын күрә башлыйлар. Башта язуыбыз латинга күчерелә, күп тә үтми безгә телебезнең үзенчәлекләренә бөтенләй ят булган кириллица тагыла. Бу безне милли мохитебездән аеруга юнәлдерелгән сәясәт җимеше иде.

Милли мохитебезгә тулысынча кайтырга, үзебезне мөстәкыйль милләт итеп расларга теләсәк, безгә язуыбызны да үзгәртергә кирәк. Аны ничек итеп үзгәртергә, нинди язуга күчәргә? Бу сорауга җавап эзләгәндә беренче чиратта гарәп язуы күз алдына килеп баса. Әмма гарәп язуының хәрефләре телебезнең авазлар системасына туры килеп бетми. Шуңа күрә тулысынча гарәп язуына күчү идеясе шик тудыра. Шулай да бу язу белән безнең үткәнебез бәйләнгән. Шуңа күрә киләчәк буыннар бай тарихи һәм мәдәни мирасыбызны белеп яшәсеннәр дисәк, аларга гарәп язуын, һичшиксез, өйрәтергә кирәк. Гарәп язуын, аның графикасын һәм төрләрен балаларыбыз белеп үсәргә тиешләр.

Әмма халкыбызның киләчәген күз алдында тотып фикер йөртсәк, рәсми яктан безгә латинга нигезләнгән алфавитка күчү максатка ярашлырак булыр иде. Бу алфавит телебезнең авазлар системасына якын. Балаларыбызның аңы формалашканда, ул алар алдында кириллица тудырган проблемаларны тудырмаячак. Шуның өстенә хәзерге заманның фәнни-техник казанышлары латин графикасына нигезләнгән язмаларда теркәлә. Хәзер фәнни казанышларны гына түгел, иҗтимагый-сәяси тормышны да компьютерлаштыру процессы бара. Компьютерлар теле шулай ук латин графикасы белән бәйләнгән. Шуңа күрә киләчәгебез турында уйлап эш итсәк, безгә кичекмәстән латин графикасына күчү мәгъкуль булыр. Бу чара мохитебезне миллиләштерүгә дә үзенең өлешен кертер иде.

Һәм ниһаять, җәмгыяви бәйләнешләр сферасы. Академик И.Таһиров язганча, революциягә кадәр татарлар Россия шәһәрләрендә, авыл җирләрендә үз тормышлары белән, үз дөньяларында яшәделәр. Аларның бистәләре һәм авыллары кечкенә генә татар дөньясын тәшкил итә иде. Аларда татарча сөйләшәләр, татарча укыйлар, татар моңнары ишетелә, мәчет манараларыннан азан авазлары яңгырый. Ислам милләтне ассимиляциядән саклый. Зур-зур шәһәрләрнең бистәләрендә яшәгән татарлар үзара аралашып, үзләрен мөселман дөньясының бер өлешедәй тоеп, үзенә бер татар дөньясы булып яшиләр. Мәгърифәтчелек, китап бастыру, газет-журналлар чыгару да алга бара. («Ватаным Татарстан», 1996, 6 ноябрь). Кыскасы, татар үз дөньясында туа, үсә, формалаша һәм яши. Бу милли мохит иде.

Революциядән соңгы иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр бу мохитне чәлпәрәмә китерде. Шәһәрләрдә татар бистәләре юкка чыкты. Заманының зур-зур йортларында татарлар хәзер башка милләт вәкилләре, бигрәк тә урыслар белән аралашып яшиләр. Фатирлар биргәндә милли һәм дини аермалыклар искә алынмый. Шулай итеп, татарларның торган җирләрендә милли мохит юкка чыкты. Алар эшләгән предприятиеләрдә һәм оешмаларда урыс теле хакимлек итә. Ике теллелек турында закон кабул ителсә дә, дәүләт эшләре урыс телендә алып барыла. Дәүләт Советындагы депутатларның күбрәге татарлар. Ләкин сессияләрдә аларның бары бер-икесе генә татарча сөйләргә җөрьәт итә. Урамга чыксаң, игъланнар урысча яңгырый. Ул урамнарның зур күпчелегенең исемнәре дә урысча. Җәмәгатьчелек күп мәртәбәләр аларга татарча исемнәр бирү турында тәкъдимнәр белән чыкса да идарәче даирәләр моңа колак салмыйлар. Трамвай, троллейбусларга керсәң дә урыс телендәге игъланнар каршылый. Тукталыш исемнәрен татарча әйтүгә кечү омтылышлары ясалды. Әмма бу озакка бармый. Берничә көннән яңадан урысча гына әйтелә башлый. Армия хезмәтенә алынса, татар баласы тулысынча урыс мохитенә чума, хәтта хезмәттәшләре белән бергә православие руханиларының вәгазьләрен тыңларга да мәҗбүр ителә. Шулай итеп, хәзер җәмгыяви тормышта татарның үз мохите юк, ул урыс идеясе белән сугарылган мохиттә яшәргә мәҗбүр.

Миллилек безнең яшәешебездә өзгәләнгән аерым элементлар һәм төсмерләр рәвешендә генә сакланып калды. Тулаем алганда мохитебез интернационализм рухы белән сугарылган һәм урыс

мохите калпагы астында калган. Хәлебез бу рәвешчә калса, милләт буларак безнең киләчәгебез өметсез. Мохитебезне сафландырырга, яшәешебезне милли буразналарга салырга кирәк. Бу бөтен халкыбыз эше. Милләтебез турында уйлап эш итүче зыялыларыбыз бу процессның алгы сафында барырга тиешләр. Моңа милли хәрәкәт тә, идарәче даирәләр дә үзләренең өлешен кертә ала. Мәсәлән, мәктәпләрне тулысынча милли буразналарга салу, балалар бакчаларыннан алып югары уку йортларына кадәр укыту-тәрбия эшләренең эзлекле милли системасын булдыру, тулысынча алар ихтыярына бәйле. Җәмгыяви мөнәсәбәтләр сферасы белән дә эш шулай булып кала. Инде ничә ел икетеллелек турында сүз бара. Әмма дәүләт учреждениеләрендә, завод-фабрикаларда әлегәчә татар теле эшләми. Бу — идарәче даирәләрнең моңа ихтыяры җитмәве нәтиҗәсе.

Милли мохитнең ныклыгы җөмһүриятебездә милли катламның никадәр калын булуы белән дә бәйләнгән. Бу катламны көчәйтүнең бер чарасы — чит төбәкләрдән кайтучыларга капкаларны киң итеп ачып кую. Хәзер Әзербәйҗан, Үзбәкстан, Казакъстан, Кыргызстан кебек бәйсез республикаларда калган милләттәшләребез асыл ватаннарына кайтырга дип чәбәләнәләр. Казакъстанда ватаннарына кайтырга теләүче казакълар өчен махсус льготалар булдырылган, бу процессны эзлекле рәвештә алып бару юнәлешендә программа да төзелгән, кайтучыларга фатир бирү каралган. Ә бездә боларның исе дә юк. Бары Татар иҗтимагый үзәгендә генә җәмәгатьчелек тәртибендә эшли торган, качакларга ярдәм итү комитеты яшәп килә. Идарәче даирәләр бу процесска ярдәм итмиләр генә түгел, аңа каршы һәртөрле киртәләр салалар. Шуларның берсе — хөкүмәтнең Казан шәһәрендә качакларны пропискага алмаска дигән күрсәтмәсе. Моңа охшаш тенденцияләрдән никадәр тизрәк арына алсак, милләтебезнең киләчәгенә шулкадәр файдалы өлеш кертә алырбыз. Безгә милләттәшләребезне җыярга, таркалган, урыс мохитендә сибелгән-чәчелгән милләтебезне бердәм сафларга тупларга кирәк.

1997 ел.

МИЛЛИ УНИВЕРСИТЕТТА МИЛЛӘТНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ

Безнең алдыбызда татар баласын татар итеп үстерү бурычы тора. Моңа бары ул үсә-формалаша торган мохит милли булганда гына ирешергә мөмкин. Милли мохит — күп катлам-

лы. Бу турыда алдарак урнаштырылган «Милли мохит һәм милләт язмышы» исемле язмада тәфсыйльле сүз барды. Бу язмада исә милли мохитның рухи эчтәлеген билгеләүче бу күпкырлы һәм катлаулы системаның бары бер буыны — югары уку йортлары турында гына сүз алып барырга телим. Бу кеше яши һәм формалаша торган мохитнең мөһим тармагы. Анда кешенең дөньяга, иҗтимагый тормышка, андагы мөнәсәбәтләргә карашы чарлана, анда ул тормыш алып баруга хәзерлек мәктәбе үтә. Кызганычка каршы, хәзерге татар баласы бу хәзерлекне урыс рухы белән сугарылган югары уку йортларында үтә. Аларда Мәскәү төзегән программалар нигезендә, шунда тәгаенләнгән фәннәр укытыла. Ә алар урыс рухы белән сугарылганнар. Югары уку йортының көндәлек тормышында да шул ук атмосфера. Алардагы уку-укытуның эчтәлеге дә, көндәлек тормыш та билгеле бер идеологиягә буйсындырылганнар. Бу — дәүләтчел шовинистик идеология. Татар баласы югары уку йортларына үтеп керә алса, шушы идеологик атмосфераны татып яшәргә мәҗбүр була.

Бу хәлнең татар җәмәгатьчелегендә канәгатьсезлек хисе уятуы очраклы түгел. Менә ничә ел инде халкыбызның уяу уллары һәм кызлары бу мәсьәләдә чаң сугалар, татар милли университеты ачылуын таләп итәләр. Әмма милли университет ачылуга бәйләнешле тәкъдимнәр, кызганычка каршы, идарәче даирәләрдә яклау таба алмады. Ахыр чиктә милли хәрәкәтнең актив көчләре тырышлыгы белән милли университет җәмәгатьчелек тәртибендә оештырылды. Студентлар да тупланды. Милләтпәрвәр галимнәр һичнинди түләүсез аның эшен башлап җибәрделәр. Әмма бу да хакимияттә яклау тапмады. Хакимият даирәләре милли униврситетны рәсмиләштермәделәр. Төрле сәбәп табылды. Шуларның берсе — бина юк. Ә шул ук вакытта инде яшәп килә торган югары уку йортлары профилендә урыс телле түләүле университетлар ачыла тора. Акчасы да табыла, башкасы да.

Милли университет ачу идеясенә каршы идарәче даирәләр Казан дәүләт университеты кысаларында татар гуманитар институтын оештыру фикерен күтәреп чыктылар. Әмма нигә гуманитар гына? Шуның өстенә Казан дәүләт университетында гуманитар профильдә татар филологиясе һәм тарихы факультеты бар. Андый факультет Педагогия университетында да бар.

Ахырда гуманитар профильдә институт ачылды да. Әйтергә кирәк, бу милли университет ачу идеясен күмү өчен оештырылган бер уен гына булды.

Университет — универсаль югары уку йорты. Ул үз эченә бөтен фәннәрне, шул хисаптан физика-математика фәннәрен дә, техника-технология гыйлемен дә, табигать белемен дә ала. Гуманитар фәннәрне дә әлегә билгеле булган татар гуманитар факультетларына караганда киңрәк колачлый. Соңгыларыннан үзгә буларак, аларда хокук фәннәре дә, икътисад та, психология дә, башка гуманитар профильдә булган фәннәр дә укытыла. Әгәр татар милләте хәзерге дөнья цивилизациясе югарылыгында атлый алсын дисәк, боларның барысын да үз эченә алган күп профильле милли университет һичшиксез кирәк. Шунсыз татар милләте һәм аның мәдәнияте хәзерге дөнья цивилизациясе югарылыгында үсә алмаячак. Безнең чор — югары технологияләр чоры, шуның өстенә кешелек җәмгыяте хәзер информация дәверенә дә аяк басты. Халкыбыз цивилизациянең бу казанышларын милләт буларак үзләштерә алсын дисәк, аның уллары һәм кызлары хәзерге фәннәрне ана телебездә өйрәнергә тиешләр.

Аяныч, әмма факт, милли университет ачу турында бәхәсләр куерганда, татар баласы фундаменталь һәм техник фәннәрне дә үз телендә өйрәнә алсын, дигән тәкъдимне, кайбер җитәкчеләребез, моның нигә кирәге бар, татар балалары аларны хәзер яши торган урыс телле югары уку йортларында да үзләштерә алалар, дип кире кактылар. Урыс телендә, урыс атмосферасы хакимлек иткән уку йортында. Бу милләттәшләребезнең аңына гасырлар буе сеңдерелгән, без — түбән дәрәҗәдәге милләт, урыс әйткәнгә карап торырга һәм аның мәдәниятына мөкиббән китеп яшәргә тиешбез, дигән коллык психологиясенең ачык чаглышы иде.

Тел үсеше мәсьәләсен алыйк. Ул, тел үсеше, әгәр татар баласы бөтен фәннәрне, шул хисаптан югары мәктәптә укытыла торганнарын да, үз ана телебездә өйрәнә алса гына, гасыр белән бергә атлый алачак. Терминнар мәсьәләсенә күз салыйк. Фәннәр югары уку йортларында ана телендә укытылса гына, аның кулланышта булган фәнни терминнары үсәчәк һәм баетылачак. Бу эшләнмәсә, безнең телебез һаман кухня теле дәрәҗәсендә калачак һәм шуның белән бергә милләтебез дә стагнация кичерәчәк. Бу — үлем юлы. Тел үсмәсә милләт тә үсми, аның фикерләү куәте дә үсми. Ә теле, фикерләү куәте үсмәгән милләт үлемгә дучар була; бу — инкыйразга илтә торган юл.

Шуңа күрә, халкыбыз милләт буларак киләчәккә ышанычлы адымнар белән атласын дисәк, яшьләребез сопроматны да, патологик анатомияне дә татар югары уку йортында үз ана телебездә өйрәнә алуларына ирешергә тиешбез. Бу хокукый һәм икътисади фәннәр мәсьәләсенә дә, психологиягә дә кагыла, тарих фәнен дә читләтеп үтми.

Фән — бербөтен, бердәм, аның төрле тармаклары бер-берсенә бәйләнгән. Югары белем алу мөмкинлеген гуманитар фәннәр белән генә чикләсәк, бездә аның бер ягы гына — гуманитар өлеше генә үсү мөмкинлеге алачак. Милләтебезнең мәдәниятының гармонияле рәвештә үсеше өчен бөтен фәннәрнең дә ана телебездә укытылуына ирешергә кирәк. Югары уку йортынача, аспирантурагача. Татар баласына югары белемнең бары гуманитар өлешен генә ана телендә бирүгә омтылыш — ул, Р.Шакирҗанов бик урынлы күрсәтеп үткәнчә, татарча югары белем бирү системасын яралгы чагында ук өлешләргә бүлеп таркату дигән сүз. Һәм бу мәсьәләне урысча чишеп, татарның мөмкинлеген чикләү, аның белемен берьяклы гына итеп калдыруга омтылышның чагылышы. Ары китеп, бу берьяклы гына фәнни эш алып бару, җиһанны (объектны) берьяклы гына өйрәнүгә китерә. Татарча фикерләп, татар телендә күпкырлы фәнни эш алып бару мөмкинлеге һәм барлык фәннәрне татарча укытуга ирешү — әлеге куркынычны бетерү, тормыш диалектикасын дөресрәк аңлау, аның динамикасын тою дигән сүз (Кара: Татар телендә югары белем бирү мәсьәләләре. Казан, 1996, 21 б.).

Милли университет булмавы татар урта белем бирү системасының яши алуына да куркыныч тудыра. 50—60 елларда татар мәктәпләренең ябылу сәбәпләреннән берсе — татар югары уку йорты булмау. Бу шартларда ата-ана баласын татар мәктәбендә укытуны перспективасыз, дип карады. Соңгы елларда без, шөкер, татар мәктәпләре һәм гимназияләре ачылуның шаһитлары булдык. Дөрес, әлегә балаларыбызның яртысыннан артыграгы урыс телле мәктәпләрдә белем ала. Шулай да, татар мәктәп-гимназияләренең ачылган кадәресе — зур казаныш. Әмма аларның язмышы ничек булыр, аларны тәмамлаган балалар кайда укырлар? Бу турыда борчылу авазлары Югары Совет сессияләренең берсендә дә яңгырады. Азнакай хакимияте башлыгы Ә.Исхаков, мәсәлән, «Инде дәртләнә-дәртләнә күпме татар мәктәпләре һәм гимназияләре ачтык. Милли университет ачмасак, урта беләм алган балаларыбыз киләчәктә

кайда укырга тиеш булачак?» дип белдерде. («Татарстан яшьләре», 1997, 27 май). Димәк, милли университет ачылу — татар урта мәктәбе яшәве өчен дә мөһим алшартларның берсе булып тора.

Инде менә ничә ел киң җәмәгатьчелек Татарстанда икетеллелек мәсьәләсен чишү, татар теленең дә урыс теле дәрәҗәсендәге дәүләт теле булуы өчен көрәшә. Әмма йөк урыныннан кузгалмый. Татар теле тормышның бөтен сфераларына үтеп керә алмый. Моның сәбәпләре күп. Шуларның берсе — җитештерү сферасында эшли торган белгечләрнең, шул хисаптан җитәкчеләрнең, профессиональ хәзерлекне югары уку йортларында да, махсус урта уку йортларында да урыс телендә генә үтүләре, татар теленнән хәзерлекләре булмау. Шуңа күрә татар теле кеше яши һәм эш итә торган мохитнең бик мөһим бу тармагына — җитештерү сферасына үтеп керә алмады.

Җитештерү өлкәсендә җитәкче урыннарны махсус урта һәм югары белемне урысча алган белгечләр били. Аларның татар булганнары да урысча уйларга һәм сөйләшергә күнеккән. Документлар да урысча тутырыла һәм нәтиҗәдә татар теле берьякта кала бирә.

Икетеллелек шартларында дәүләт теле буларак татар теле үз урынын алсын өчен аның житештерү сферасына үтеп керүе — мөһим шарт. Моңа исә татар телендә югары квалификацияле белгечләр хәзерләми торып, ирешеп булмаячак. Шулай булгач, милли университет булдыру — ул милләт язмышы мәсьәләсе, аның киләчәктә фән, сәнгать һәм мәдәният өлкәсендә башка милләтләр белән бер сафта аяк баса алуы мәсьәләсе.

Без Татарстанның дәүләти суверенлыгын игълан иттек. Әмма әлегә хакыйкый суверенлыктан ерак торабыз, урыс империясе тырнакларында чәбәләнүебезне дәвам итәбез. Хакыйкый суверенитетка ирешү өчен без беренче чиратта рухи суверенитетка ирешергә, коллык психологиясеннән арынырга, милләтебезнең рухи һәм әхлакый бердәмлегенә ирешергә тиешбез. Милли университет ачылуы һәм эшләп җибәрүе — моның мөһим алшарты булачак. Бөтен фәннәрне дә татар телендә өйрәнү — милли алгарышның нигезе, милләтнең гармонияле үсешенең нигезе. Милли университет исә — моны хәл итүнең мөһим чарасы.

1997 ел

ФИКЕРИ ЭЗЛӘНҮЛӘР ЮЛЫНДА

(Китапның авторы турында)

Абдуллин Яхъя Габдулла углы 1920 елның 9 гыйнварында Казаннан ерак түгел (Теләче районы) Олы Кибәхуҗа авылында туа. 1936 елның 11 мартында Теләче районы газетасында эшли башлый (башта техник секретарь, аннары әдәби хезмәткәр). 1938 елның сентябрендә Алабуга шәһәренә (Татарстан) сәяси-агарту мәктәбенә укырга китә. 1940 елны армиягә алына һәм сугышның башыннан алып ахырынача фронтта була. Сталинградтан алып Берлингача сугыш юлларын уза. I дәрәҗә Ватан сугышы, 2 Кызыл Йолдыз орденнары һәм 15 медаль белән бүләкләнә. 1945 елның октябрендә армиядән демобилизацияләнә һәм 1959 елга кадәр Казан шәһәрендә иҗтимагый-сәяси, оештыру эшләрендә эшли.

1959 елда бу эштән бушануга ирешә һәм югары уку йортында фәлсәфә укыта башлый. Ул моңа кадәр, 1957 елда, философия фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен диссертация яклый. 1962 елда аңа доцент исеме бирелә. Шул ук елны «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләнә.

1965 елда (инде 45 яшь булгач) ныклап фәнни-тикшеренү эшләре белән шөгыльләнергә ниятли — татар иҗтимагый-фәлсәфи фикере тарихына бәйле чыганакларны өйрәнә башлый. Г.Курсави, Ш.Мәрҗани мирасын күтәрә. Фәнни тикшеренүләрнең беренче нәтиҗәләрен 1968 елда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында үткәрелгән фәнни конференциядә укылган «Татар мәгърифәтчелек фикеренең кайбер үзенчәлекләре» дигән докладта яктырта. Бу докладта Ш.Мәрҗанигә карата беренче мәртәбә мәгърифәтче исеме кулланыла (ә ул вакыттагы фәнни әдәбиятта Курсави да, Мәрҗани дә реакцион дворян-буржуаз идеологлар дип бәяләнә иделәр). Бу доклад 1969 елда «Казан утлары» журналының 10 нчы санында мәкалә итеп басылып та чыга.

1971 елда элекке елларда башланган фәнни эшен нәтиҗәлерәк алып бару өчен югары уку йортыннан Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына өлкән гыйльми хезмәткәр булып күчә. 1975 елдан шушы институтта Яхъя Абдуллин җитәкчелегендә яңа фәнни юнәлеш формалаша — татар иҗтимагый фикере тарихы бүлеге төзелә, шушы тармак буенча фәнни кадрлар хәзерләнә. Бу бүлектә татар мәдәниятының моңа кадәр онытылып килгән катламнары — иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер катламы күтәрелә, яңа исемнәр ачыла. Бу бүлектә эшләүче фәнни хезмәткәрләр татар иҗтимагый-фикере тарихына кагылышлы 40тан артык китап, бик күп фәнни мәкаләләр бастырып чыгардылар.

Яхъя Абдуллин 1979 елда «Татар мәгърифәтчелек фикеренә социаль-фәлсәфи характеристика» дигән темага докторлык диссертациясе яклый. 1981 елда аңа профессор исеме бирелә. Ә 1980 елда ул Татарстанның атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исемгә лаек була.

1980 елда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директорының урынбасары итеп тәгаенләнә, ә 1981 елда институтның директоры итеп билгеләнә. 1985 елда Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе дигән исем бирелә. 1986 елны, пенсиягә китү сәбәпле, институт директоры вазыйфаларыннан азат ителә. Әмма институттан бөтенләй китми, әле хәзер дә институтның (хәзер Тарих институтының) баш фәнни хезмәткәр-консультанты вазыйфасын үти. 1995 елда Яхъя Абдуллин Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле академигы итеп сайлана. 1996 елда аңа Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге исемле премиясе бирелә.

Хезмәтләре:

1976 елда Казанда «Татар мәгърифәтчелек фикере» («Татарская просветительская мысль») дигән монографиясе басылып чыга (320 б.). Бу китапта һәм 80 нче елларда төрле җыентыкларда һәм журналларда татар мәгърифәтчелек хәрәкәтенә кагылышлы мәкаләләрендә Яхъя Абдуллин беренче буларак татар мәгърифәтчеләренең фәлсәфи вә социаль карашларына анализ бирә, Г.Курсави, Ш.Мәрҗани, Ш.Күлтәси кебек мөтәфәккирләрнең карашларының прогрессив характерда булуын ачып сала, татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәтенең үсеш этапларын актырта.

«Джадидизм, его социальная природа и эволюция» — «Җәдитчелек, аның социаль табигате һәм эволюциясе» (1979), «Джадидизм среди татар: возникновение, развитие, историческое место» — «Татарлар арасында җәдитчелек: барлыкка килүе, үсеше, тарихи урыны» (1998) дигән хезмәтләрендә Яхъя Абдуллин бу катлаулы хәрәкәткә һәрьяклы анализ ясый, аның татар иҗтимагый фикере үсешендәге урынын билгели, социаль табигатен, эволюциясен һәм иҗтимагый фикер үсешендә уңай күренеш булуын ачып сала, аны ул вакытта яшәп килгән тискәре бәялардән арындыра.

«Мәгърифәт нуры ачар...» (Казан, 1987, 200 бит) исемле китабында татар иҗтимагый һәм фәлсәфи фикере үсешенең төп этапларына әтрафлы характеристика бирә, аның күренекле вәкилләренең иҗади мирасына, аларның фәлсәфи һәм социаль-сәяси карашларына төпле анализ үткәрә.

Яхъя Абдуллин җитәкчелегендә хәзерләнгән һәм аерым бүлекләре аның тарафыннан язылган — «Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри» — «Күренекле мәгърифәтче-демократ Каюм Насыйри» (Казан, 1976, 216 бит) дигән китапта бу күренекле фикер иясенең мирасына яңача бәя бирелә, бу бәя моңа кадәр яшәп килгән догматик богаулардан арындырыла.

Шулай ук аның җитәкчелегендә һәм турыдан туры катнашында хәзерләнгән «Марджани: ученый, мыслитель, просветитель» — «Мәрҗани: галим, мөтәфәккир, мәгърифәтче» (Казан, 1990, 192 бит) дигән китапта бу олы затның фәнни һәм мәгърифәтчелек эшчәнлегенә әтрафлы характеристика бирелә, иҗади мирасына анализ үткәрелә, аның татар иҗтимагый фикере үсешендәге роле ачып салына. Бу китапта яктыртылган фикерләр аның катнашында хәзерләнгән һәм 1998 елда басылып чыккан «Мәрҗани һәм хәзерге заман» дигән китапта алга таба үстереләләр.

Яхъя Абдуллинның үзенең шәкертләре белән бергәләп язылган «Общественная и философская мысль в Татарии начала XX века» — «XX гасыр башында Татарстанда иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер» (Мәскәү, 1990, 200 бит) дигән китапта әдәби чыганакларга һәрьяклап үткәрелгән анализ нигезендә гасыр башында иҗат иткән татар мөтәфәккирләренең һәм мәдәният вәкилләренең социаль-фәлсәфи карашлары яктыртыла.

Яхъя Абдуллин тарафыннан барлыгы 225 фәнни хезмәт бастырылган. Аларның гомуми күләме 210 табакка якын.

Яхъя Абдуллин татар халкының фикери мирасын хәзерләп дөньяга чыгаруга да үзеннән өлеш кертте. Аерым алганда, аның җитәкчелегендә Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» дигән ике томлы китабы текстологик яктан хәзерләнеп, комментарийлар һәм кереш сүз белән басылып чыкты. Ш.Мәрҗанинең «Вафийат аль-әслаф вә тахийат аль-әхлаф» исемле җиде томлык китабы да аның җитәкчелегендә гарәп теленнән тәрҗемә ителеп, басмага хәзерләнде һәм нәшрияткә тапшырылды.

Яхъя Абдуллин җитәкчелегендә татар иҗтимагый фикере һәм фәлсәфә тарихы буенча 10нан артык фән кандидатлары хәзерләнде һәм диссертацияләр якланды.

Татар иҗтимагый фикере һәм мәдәнияты тарихы буенча аның редакциясендә 30дан артык китап чыкты.

Соңгы вакытта Яхъя Абдуллин совет хакимияте елларында татар халкы хәтереннән куылып киленгән күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, татар милли хәрәкәтенең абруйлы вәкиле, галим вә мөтәфәккир Садри Максуди — Арсалның мирасын халык күңеленә кире кайтару буенча да мөһим эш башлап җибәрде. «Шәһри Казан» газетасының 1993 ел, 6, 9, 10 февраль саннарында аның «Милли идеология мәсьәләсе һәм Садри Максуди мирасы» дигән күләмле мәкаләсе басылып чыкты. «Независимость» («Бәйсезлек») газетасының 1993 ел, 5 нче санында аның «Садри Максуди милләт вә миллият турында», ә «Ватаным Татарстан» газетасының 1994 ел, 21 октябрь санында «Садри Максуди: иҗат һәм көрәш баскычлары» дигән күләмле мәкаләләре басылды. 1993 елның 27 октябрендә Казанда Яхъя Абдуллин катнашында С.Максудиның 115 еллыгына багышланган зур фәнни конференция булды. Конференция материаллары нигезендә «Садри Максуди (1879-1957)» дигән китап хәзерләнде һәм ул 1996 елда Яхъя Абдуллин редакциясендә басылып чыкты. 1998 елда аның катнашында Садри Максудиның 120 еллыгына багышланган халыкара фәнни конференция уздырылды, аның материаллары да 1999 елда «Садри Максуди: наследие и современность» исеме астында дөнья күрде.

Яхъя Абдуллинның инициативасы белән һәм җитәкчелегендә Садри Максудиның «Миллият тойгысының социологик әсаслары» дигән китабы татар теленә тәрҗемә ителде һәм «Мирас» журналында басылды. Хәзер Яхъя Абдуллин аны китап итеп бастырырга әзерли.

Соңгы елларда Яхъя Абдуллин татар халкы тарихында һәм мәдәниятында ислам уйнаган рольне яктыртуга да үзеннән өлеш кертте. Бу турыдагы хезмәтләре Казанда, ә бер мәкаләсе Англиядә басылып чыкты.

Яхъя Абдуллинның соңгы еллардагы хезмәтләрендә татар милләте, аның асылы, үткәне, бүгенге халәте, киләчәге, милли-азатлык хәрәкәтенең идеологик проблемалары да үзләренең чагылышларын таптылар.

Фәрит Солтанов,
фәлсәфә фәннәре
кандидаты

ЭЧТӘЛЕК

Кереш 5

I

Яңача фикерләү һәм татар иҗтимагый фикере тарихының кайбер мәсьәләләре 9
Ислам безнең тарихыбызда һәм мәдәниятыбызда 23
Исламның башка диннәргә мөнәсәбәтенә карата 37
Җәдитчелек һәм хәзерге заман 43
Ислам. Тарих. Заман. 51
Милләт. Мәдәният. Исламият. 60
Милли бәйрәмнәребез 75
Татарның диаспорасы кайда? 85

II

Мәрҗани шәхесе һәм аның татар иҗтимагый фикере тарихында урыны 87
Риза Фәхретдинов - галим, дин белгече, мәгрифәтче 97
Һади Атласи - галим һәм җәмәгать эшлеклесе 103
Г.Тукай: халык язмышын күз алдында тотып 112
Думавиның дөньяви уйлары 117
Г.Ибраһимов: фикери һәм иҗади эволюциясе 130
Гаяз Исхакый: фикери эзләнүләр юлында 147

III

Ышанмаучылык киртәләре, шик-шөбһәләр аша үтеп 169
Кыйтгаларны тоташтырган шәһәрдә 182
Хиҗҗазга сәяхәт 197

IV

Бердәм максат, бердәм көрәш.
(Татар Иҗтимагый үзәге корылтаеннан соң уйланулар) 216
Ирек һәм бәйсезлек 223
Фатыйх Мәрдәнев яки милләтчелек карачкысы 228
Милләт һәм милләтчелек 232
Демократия, федерализм һәм кеше хокуклары 245
Милли битарафлык каян килә 255
Әсәрдә милләт язмышы 262
Милли идеология мәсьәләсе
һәм Садри Максуди мирасы 267
Милли хәрәкәткә ни булды? 282
Милли мохит һәм милләт язмышы 295
Милли университетта милләтнең киләчәге 305
Фәрит Солтанов. Фикери эзләнүләр юлында.
(Китапның авторы турында) 310

Яхъя Габдуллович Абдуллин

СУДЬБА НАЦИИ: РАЗДУМЬЯ

(на татарском языке)

Мөхәррире *Мәгъсум Хәбибуллин*
Рәссам *Герман Трифонов*
Техник мөхәррире *Вера Галкина*
Компьютерда җыючылар *Алсу Хәйруллина, Мөршидә Гатауллина*
Компьютер версткасы *Дина Галеева*

Басарга кул куелды 24.08.99
Кәгазь форматы 60х84 1/16 Басма табагы 20,0.
Шартлы басма табагы 18,80.
Тираж 1000. Заказ 3-473

Татарстан Фәннәр академиясенең «Фән» нәшрияты.
420044, Казан шәһәре, Волгоградская урамы, 49.

Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан Татарстан Фәннәр академиясенең «Фән» нәшриятына 1998 елның 10 мартында бирелгән 0226 нчы номерлы лицензия.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты басмаханәсендә басылды.
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.